ISSN 0206—4189



# Казан утлары

11.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1988

11

(793)

## Бу санда

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

М. ШАБАЕВ. **Кара ханым. Шигырьләр** 3
Р. НИЗАМИЕВ. **Язмыштан көчлерәк.** *Роман-хроника* 6
М. ГАЗИЗОВ. **Капка ыгыта эти...** *Шигырьләр* 78
Н. АКМАЛОВ. **Йөк атының абзар баганасына сөйләгәне.** *Шигырьләр* 80
М. ГАЛИЕВ. **Алтын тотка.** *Повесть.* 84
С. МУЛЛАГАЛИЕВ. **Намус исеме белән.** *Шигырьләр* 127
Д. ХӘЙРУЛЛИН. **Улым тугач.** *Шигырьләр* 129

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ХӘСӘНОВ. **Бер уч арыш.** *Көндәлек дәфтәреннән* 131

ВӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

С. ПОВАРИСОВ. **Гөл бакчасына керәмен...** 152
**Бәхәскә укучы кушыла** 156

ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Ш. ГАЛИЕВ. **Халкыбызга ышанам!** 160

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Тормыш имтиханы** 173

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

И. НУРУЛЛИН. **Татар мәгърифәтчелеге һәм җәдитчелек дип йөртелгән күренешкә карата** 175

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, Җ. МИҢНУЛЛИН. **Җәйге театр** *(А. Тимергалина рәсеме)* 184

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Ф. ГАРИПОВА. Арча 187

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

Өченче дәрес 188

Культура тормышы көндәлеге 191

Тышлыктагы сурәтләр 192



*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН


## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Начало роман-хроники Р. НИЗАМИЕВА «Сильнее своей судьбы». Повесть М. ГАЛЕЕВА «Золотая скоба». Стихи М. ШАБАЕВА, Н. АКМАЛОВА, С. МУЛЛАГАЛИЕВА, Д. ХАЙРУЛЛИНА.
«Публицистика». М. ХАСАНОВ — «Колосится рожь золотая» (из дневника писателя).
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статья С. ПОВАРИСОВА, письма читателей.
Беседа поэта Ш. ГАЛИЕВА «Верю своему народу».
В рубрике «Библиография» рецензируются книги Р. Ишмурата «Ступени жизни» и «Друзья-наставники».
«К истории литературы». Статья И. НУРУЛЛИНА о татарском просветительстве и джадидизме.
«Памятники татарской культуры в Уфе» — летний театр.
«Города древней Булгарии» — статья Ф. ГАРИПОВОЙ «Арск».
Навыки чтения и письма на основе арабской графики. Занятие 3-е.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: вышитые калфаки; костюм городской татарки.


Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-69,
җаваплы секретарь — 53-07-65.
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.



Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 2.09.1988 ел. Басарга кул куелды 27.10.1988 ел. ПФ 10538. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64554. Заказ А-360. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.



С «Казан утлары», 1988 ел.

# ПОЭЗИЯ

## Марс Шабаев

### Кара ханым

Төн уртасы иде.
Кап-кара төн.
Ак фәрештәм,
Җәеп ак канатын,
Изрәп киткәч йомшак мендәрендә,
Мин, кунаклап шигъри мөнбәремә,
Булдым сырламакчы-җырламакчы:
«Дөнья матур!
                    Тормыш әйбәт!!
                                        Бакчы!!!»
...Кинәт кемдер төбәп караганын
Тоеп, күз күтәрсәм —
К а р а   х а н ы м!
Кара ханым —
Ягъни Кара Муза
Түргә уза,
Йөрәгемә уза...
Таныйм сине, таныйм, Кара ханым...
Бардыр бәлки мине каргаганың:
Ишек шакымадың син бер генә,
Кермәк булып минем шигыремә.
Ә мин синнән һаман кача килдем,
Кызыл шигырьләрне чәчә килдем.
Кызылыннан арсам, ак шигырьләр
Ак кәгазьгә иде тезелерләр...
Бүген, ахры, сине куа алмам:
Бик туйдырган иде кызыл ялган...
Боер миңа, боер, Кара ханым!

К а р а   х а н ы м:
— Әйе, бу тормышның кара ягын
Күрмәмештә булды синең каләм.
Күбрәк рифмаладың:
                                        «әләм-сәләм!»
Син курыктың, имеш, каралтырга,
Кирәк иде, имеш, агартырга,
Агартканны, имеш, шомартырга,
Шомартканны аннан кызартырга...

---

*Марс* ШАБАЕВ *(1933) — шагыйрь, «Яңа җыр», «Җикән камыш», «Көн арты көн» һ. б. татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык шигырь китабы авторы. Ул — Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Юк, кидермим сиңа кара күзлек,
Як-ягыңа төбәп кара үзең:
Кояшта да бар, дип, кара таплар,
Куркак кына үзенең җанын саклар.
Күңелеңдә ята куркак цензор,
Белмим, һаман кемнән куркасыңдыр?
Халык көтә бары хакыйкатьне:
Булсын карамы ул,
Булсын акмы.
Синең йөгрек каләм бүгеннән соң,
Кара күрсә, куркып йөгермәсен.
Бүгеннән соң күңеленә килер
Кара икмәк төсле кара шигырь.
Кара шигырь —
Кара җирең төсле,
Җиргә тамган кара тирең төсле.
Ачы булса да ул,
Булыр татлы...
Кара булса да ул,
Булыр якты...
Газапларың чөнки илһам атлы.

## Канатлы малай

Җан иңүгә ана карынында,
Куандырып үзенең әнкәсен,
Очындырды, кинәндерде генә!—
Йә, аңарга нәрсә әйтәсең?
Кабул итеп алган «кендек әби»—
Ак халатлы акушерка да
Куанып әйтте:
— Очып китә язды...
Булыр икән тере, булса да!
Кул-канатлар, ими имгәндә дә,
Талпынды да һаман җилпенде:
— Язган моңа,— диде дәү әнисе,—
Яшәү күктә, җилләр иркендә.
Бакчасында булсын, мәктәбендә —
Һаман күктә иде карашы.
Күккә карап абыныр, борыны канар...
Кемдер әйтте:
— Җиргә карасын!
Ә ул
Бер атласа, ике сикереп куя.
Кул-канатын җилпи-җилпи дә...
Күккә аша!
Кала шунда җилләр иркендә.
Битләренә таң алсуы куна...
Һәркөн шулай иртә таңнарда
Очына ул хыял күкләрендә —
Кирәк бары үзен аңларга.
Офыклары аның иркенрәк,
Ераграк күрә бу малай.
Ышаныгыз:
Кешеләрдән дә кайчак
Шундый канатлылар тугалый.

Әнә оча малай!
Аста — шәһәр...
Дөнья кила ыгы да зыгы:
Көнлек мәшәкатьтә, ваклыкларда,
Әйтерсең лә, тормыш кызыгы...
Әйтерсең лә, кибет чиратында
Импорт ыштан-колготкаларга —
Яшәү тәме!
Мыш-мыш ышкынабыз...
Вакыт кая канат кагарга!
Кемнәрнедер, имеш, үстергәннәр...
Кемнәрнедер, имеш, төшергәннәр...
«Волга» алган, имеш, кемнәрдер...
Кемнәр — аерылышкан...
Кем — талашкан...—
Үтә шулай алтын көннәрең.

Оча малай!
Ә без риза түгел:
— Чама белебрәк очсын ул.
Җирдән-бездән биек күтәрелми
Үзенең дөньяларын ачсын ул.
Күңелләрдә үсә ризасызлык,
Аваз сала хөсет көнчелек:
— Нигә оча?

— Башкалардан өстә...
— Юк, без аны җиргә төшерик!
— Ә кем белгән, кая очып кунар?
— Әгәр дә ул нитсә... тегендә...

Ә бит малай яратылган иде,
Яратылган иде, яратылган
Тик очарга үзенең күгендә...

Инде очмый малай!
Җирдә йөри...
Юк бер хәвеф-хәтәр, куркыныч...
Канатларын каерып алдың аның —
Син,
К а н а т с ы з  д ө н ь я,
Бул тыныч!

## Чәчәкләргә йөзен яшергән ул...

Аны бүген зурлап сөйләделәр,
Аның хезмәтен дә күрделәр...
«Алтын кулларыңа рәхмәт!»— диеп,
Чәчәкләргә үзен күмделәр.
Мәнә шунда, бәлки, гомере буе
Көтеп алган якты мизгелдә
Күзләрендә аның сагыш иде...
Бер моң иде...
Бигрәк изге дә,
И хатыннар,
Сезнең күңелегез!
Ничек шундый була беләсез:
Шатлыктан да кайчак моңаясыз,
Кайгыдан да кайчак көләсез.
Мәнә ул да үзен зурлаганда,
Тәм тапмаган кебек эшеннән,
Чәчәкләргә йөзен яшергән дә
Арына алмый һич күз яшеннән:
«Йә ходаем!
Дуадак каз төсле,
Каңгыраеп урам чатында,
Чайкалмасын иде...
Бер пар булып,
Бер ояда яшәр чагында...
Йә ходаем!
Тик бүгенгә генә
Үтәлсәче минем теләгем:
Бүген көтсен иде аек килеш,
Кисен иде бәйрәм күлмәген.
Ул кырынган булсын, чистарынган,
Хәмер сөременнән арынган...
Тотып алсын иде кулларымнан...
Булсын иде мине сагынган...»

Чәчәкләргә йөзен яшергән ул,
Күзләрендә көйри сагыш-моң...
«Ул бәхетле!» диеп ничек җырлыйм,
Ничек җырлыйм аның язмышын?..
Әйтегезче...

## Бушлай гына...

Бушлай гына киләсең дә дөньяга,
Җир йөзендә —
Кешеләрнең уртак өендә
Бер түләүсез яши бирәсең,—
Сиңа шулай тоела,—
Бушлай гына...
Аннары, гомереңбелән түләп,
Китеп барасың якты дөньядан,
Җир йөзеннән —
Кешеләрнең уртак өеннән,
Кемгәдер,
Яңа бер килүчегә
Урыныңны калдырып,
Бушлай гына...
Ул да яшәсен өчен бушлай гына
Һәм китеп барсын өчен
Гомере белән түләп,
Урынын калдырып
Кемгәдер өченчегә,
Бушлай гына...
Аннары —
Өченче дүртенчегә,
Дүртенче бишенчегә —
Шулай бихисап...
Һәммәсе бушлай гына...
Түләнгән гомерләрдән чылбыр ялгана —
Мәңгелек чылбыры —
Бушлай гына...
Шулай тоела,
Шулай тоела,
Ах! шулай тоела,
Тоела тик шулай гына...
Бушлай гына...

*1987—88*

# ПРОЗА

## Рашат Низамиев

# ЯЗМЫШТАН КӨЧЛЕРӘК

РОМАН-ХРОНИКА

Адәм баласы дөньяга үз-үзен танып белү, кеше дигән исемен раслау, матурлык калдыру өчен туа. Табигатьнең зирәклегеме, әллә саранлыгымы — кешегә гомер дигәнең бик тә чикле, үлчәп кенә бирелгән. Ул менә шушы вакыт арасына сыярга, исәннәргә үзеннән билгеле бер өлеш — күңел хәзинәсен калдырып китәргә тиеш. Заманның нинди генә чоңгылларына эләкмәсен, кагыйдә буларак, зур шәхесләр үзләренә тигән гомердә әйтәсе сүзләрен әйтеп өлгерәләр. Гаҗәп хәл: Тукайга моның өчен нибары егерме җиде ел вакыт җиткән.

Композитор Фәрит Яруллин үзенең «Шүрәле» балетын Тукай яшендә тәмамлый һәм туган илен саклар өчен Бөек Ватан сугышына китә. Ул матурлык хакына яшәде, иҗат итте һәм һәлак та булды.

Яруллин яхшылык һәм яманлык, тагын да төгәлрәк әйтсәк, гуманизм һәм фашизм дуэлендә үтерелде. Үлем аны чынлыкта тән көрәшендә генә җиңде. Ромен Роллан иҗат эшенең асылы турында бик тә мәгънәле сүзләр әйтеп калдырган: «Иҗат итү, димәк, үлемне үтерү...» Әйе, Фәрит Яруллин үзенең иҗаты белән үлемне үтерде. «Шүрәле» балеты моңнары, илебезнең төрле почмакларына гына түгел, хәтта Азия, Европа, Америка халыкларына кадәр барып җитте. Аның бүгенге көндә дә сәхнәләрдән төшми уйналуы композиторның һаман да безнең арада яшәве, музыкасының озын гомерле булуы турында сөйли.

Давыл кубарылдымы, диңгездә битарафлыкка урын юк: ул тоташ актарыла башлый, тау-тау дулкыннар дәррәү хәрәкәткә килә. Илебез тарихында Бөек Ватан сугышы да әнә шундый давылга тиң иде. Композитор ике ил, ике иман, ике дөнья бәрелешкән гарасат уртасына килеп эләкте. Бер якта — тормышны җимерүче кара көчләр, икенче якта — Ватанын, яшәү матурлыгын саклаучы якты җаннар. Гражданлык намусы һәм иҗади фаҗига әнә шулай ут эчендә төенләнә. Мондый көрәш кырында кешенең шәхесе, иҗтимагый кыйммәте тагын да зурая. Гомумән, гади бер кешеме, әллә даһимы — бу дөньяның һәр кешесендә тирән сер яшеренеп ята. Фәрит Яруллин үзенең иртә үлеме белән зур бер серне дә алып китте. Шул серне аңларга тырышу теләге безне каядыр ерак офыкларга чакыра, тәгәри киткән йомгак шикелле үзенә иярте.

«Шүрәле» балеты гына түгел, композиторның шәхесе дә бердәй дәрәҗәдә үзенә тарта, кызыктыра безне. Зур рухи байлык калдырган иҗатчылар һәммәсе шулай, чөнки әсәр белән авторны бер-берсеннән аерып карау мөмкин түгел. Әдәбиятта яки музыкада булсын, сәнгать дөньясындагы теләсә кайсы әсәр — шәхеснең дәвамы, йөрәк баласы, күңел кайтавазы...

Кеше, тарихның кайсы гына дәверендә яшәмәсен, матур булып туарга, батыр булып үләргә тиеш. Батырлыкны кылыч тотып утка-суга керү дип кенә аңларга ярамый. Намуслы яшәү, гадел булу, халкыңа һәм Ватанга тугрылык, әхлакый яктан үз-үзеңне даими камилләштерү — кешедән күңел хезмәте, фидакарьлек, рухи җегәр сорый торган иң зур батырлык. Үзенең иҗаты һәм яшәү үрнәге белән Яруллин безгә әнә шуны раслап күрсәтте.

Күңел батырлыгы кылыр өчен кеше гомере буе әзерләнә. Фәрит Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләгәндә без күп кенә сорауларга җавапны аның балачагыннан, ул яшәгән заманнан, мохиттан, композиторның шәхесеннән эзләргә тиеш булабыз.

# I. Заманалар авыр, еллар ябык...



ел. Казан урамнарына декабрьнең соңгы кары ява.

Әле кайчан гына раштуа салкыннары шәһәрне тәмам сыкыга батырган иде. Кирпеч биналар куырылып, кечерәеп калды, агач йорт бүрәнәләреннең кинәттән шартлап-шартлап куюы ил өстенә хәвеф киләсен искәртте кебек. Агач ботагына яисә телеграф чыбыгына кош-мазар килеп кагылган саен мәрҗән-мәрҗән бәс коелды. Ярлы халык кабергә житкәндә дә бетми торган мәшәкатьләре белән әвәрә килсә, дөньяның сыртына тибеп яшәүче байлар исә кайнарланып илдәге вакыйгалар, сәясәт турында бәхәсләштеләр, вакытларының күп өлешен гыйш-гашрәт һәм отыш уеннарына багышларга да онытмадылар. Чиркәү колокольнялары, карлыккан тавыш белән чаң сугып, әле кайчан гына Рождество бәйрәмен озатып калган иде.

Инде менә декабрьнең соңгы көннәре. Татар бистәсе мәчетләренең аена һәм шималь яктагы чиркәү тәреләренә ышкылып кар ява. Йөзәсе-тирбәләсе килеп күпме генә талпынмасын, кар бөртекләре барыбер жиргә суырылып төшә. Шулай булмый ни: кеше әнә күккә карап күпме генә гозерләнмәсен, сәҗдә кылганда барыбер гәүдәсе белән жиргә баш ора. Жир — аның таяныр ноктасы, тәпи атлап киткән биләмәсе, миллионнарның кайгы һәм шатлыгын сыендырган уртак йорты. Дин ирегендә яшәүчеләр өчен күктә тәңредән гайре берни юк, кояш, ай һәм йолдызлар — нибары жирне күзәтү өчен эленгән яктырткычлар. Адәм баласы жирдән, туфрактан яралган. Үзенең якты намен калдырып, көннәрнең берендә ул кабат жиргә китәргә тиеш.

Казан каласы — зур кала. Кабан күле ягындагы агач йортлардан башланып, завод һәм фабрика морҗалары, ташпулатлар белән бизәлә-бизәлә, Елга аръягына кадәр биниһая җәелгән ул. Чиркәү гөмбәзе белән мәчет манаралары чиратлашкан кебек, урам арты урамнар, тыкрык арты тыкрык тезелеп китә. Университет, Пассаж, Щетинкин номерлары кебек мәһабәт биналарны күз алдына китерсәң, бистәнең бер яки ике катлы йортлары алар янында чүгеп калган шикелләрәк күренә. Кирпечтән салган кибет-келәтләр, лабазлар тезмәсе, үзләре яшәү яки фатир төшерү өчен салынган торак йортлар күзгә ташлана. Болары — күбесенчә сәүдәгәр халыкныкы.

Тормыш төпкелендәге саилчеләрне исәпләмәгәндә, шәһәрнең гади халкы урамда, ачык түбә астында яшәми, әлбәттә. Агач йортлар яисә арендага алган фатир эчләренә төрле-төрле язмышлар сибелгән: алар да яши, сулый, дөнья куа, бала-чага үстерә. Алар да хәл кадәренчә Яңа елны каршыларга, табынны кулдан килгәнчә кибет һәм базар ризыгы белән бизәргә тырышачаклар. Булган кадәресенә дә сөенә белгән мондый йортларда шампан шәрабы да ташымас, купшы тостлар да әйтелмәс, билгеле. Аның каравы, күңелләрендә — никә кабатласаң да искерми торган ихлас сүзләр, фани теләкләр, килер көннең күзенә туры карый белү үҗәтлеге.

Асты кирпечтән, өсте агачтан салынган ике катлы йорт. Култыкса һәм басмалары шомарып беткән баскычтан өскә менәсең. Борынга кухня исләре, кайнаган су пары бәрелә. Коридорда шәлъяулык япкан әбиләрнең күренеп китүендә ниндидер зур эш белән мәтавыклану,

---

Рашат НИЗАМИЕВ *(1950)— шагыйрь, прозаик. «Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй», «Боек сер» китаплары авторы. Казанда яши.*

кабалану, ашыкканлык сизелә. Бүлмә эчендә исә ләгән-комган шалтырый, хатын-кыз таифәсенең кайгыртучан-әдәпле тавышлары ишетелеп куя. Фатир хуҗасы Зәһидулла — егерме биш яшьлек ир-егет — хатын-кыз арасына керергә кыймыйча, ишегалдында таптана. Шатлыгыннан гәүдәсенә урын табалмаганга күрә, әле урамга чыгып арлы-бирле йөренә, әле татлы уйларга бирелеп кулындагы тәмәкесен кабыза. Ничек шатланмыйсың ди: малай туган, малай!

Малай дигәнебезнең булачак композитор Фәрит Яруллин икәнлеге, шаять аңлашыладыр. Шулай итеп, ул 1914 елның 1 январенда Казанның Суконный бистәсендә дөньяга килә. Баланы, бер кат коендырып биләүгә төргәннән соң, яхшы теләкләр әйтә-әйтә әнисе кулына тапшыралар.

Ярый, бәхете белән тусын «егетебез». Әмма анын вакыт-вакыт кычкырып елап җибәргәненә карап кына Яңа ел фәйтүне һич тә туктап калмады! Кыйтга һәм урманнар аша узып кырдан-кырга чапты, өйдән-өйгә керде, кешеләргә карлы-чыршылы бәйрәм алып килде. Әйдә, күңел ачыгыз, кунак-кунак уйнагыз, табында гомер буена җитәрлек матур теләкләр яңгырасын! Вакыт галиҗәнапләре өчен сыйныфлар юк, адәмнәрнең ярлы һәм бай дигән капма-каршы төркемнәргә бүленүен белми дә, аңламый да ул... Ә хакыйкать бар! Бу минутта бистә фәкыйрьләре, көнлекчеләр, вак һөнәрчеләр, тормышның очын-очка ялгап яшәүче завод һәм фабрика эшчеләре иртәгесен ничек итеп җан асрау турында баш ватса, бай йортлы дворяннар, ука погонлы гаскәриләр, югары гильдия сәүдәгәр һәм байгуралар Яңа ел сәгате сукканны ризык-нигъмәтләрдән сыгылып торган табын тирәсендә каршылый. Бозлы әрҗәдән шампан шешәләре чыга, ак перчаткалы официантлар бокалларга шәраб коя. Күкрәк турысына кайтарып куелган ак салфеткалар, табындагы эскәтерләр, эполет һәм аксельбантлар яңа яңасын, әмма тостлар һаман да иске:

— Патша хәзрәтләре шәрәфенә!

— Россиянең бердәмлеге, бөеклеге хакына!

Бай йортлардагы халык кызды, бәйрәм итте.

Чү, монысы ниткән шартлаулар тагын? Зарар юк, аллы-гөлле фонтан чөеп, конфетти аттыралар икән! Ханымнарның ялангач беләгенә, затлы ислемай аңкытып торган ярым ачык күлмәгенә, европача бөдрәләткән чәчләренә, ирләрнең ялтыр башлы пеләшенә, өстәлгә һәм идәннәргә тәнкә-тәнкә кәгазь бизәкләр сибелә... Яңа дип аталган 1914 ел, Беренче Бөтендөнья сугышы тупларыннан атып, тиздән адәмнәр өстенә кайгы-хәсрәт утлары сибә башлаячак. Ләкин ул авыр хәсрәтләр полька һәм мазуркага әйләнгән бу кешеләр өстенә дә капланыр микән соң, әллә инде шинель киеп ярманга каршы китүче гади халык өстенә генә ишелерме?

1914 елның августына кергәндә тарих бу сорауларга төгәл җавабын бирер. Ә хәзергә Казан урамнарында иске һәм яңа елның очрашкан, кул кысышкан мәле. Әнә инде саубуллашып та өлгерделәр. Гүя, Тукайны соңгы юлга озаткан унөченче ел эстафета таягын тапшырганда, яңа яуган карлар булып, ундүртенче елның колагына пышылдый: «Мин югалттым, ә син яңаларын тап дөньяга...»

Әйе, унөченче ел тарихта татар халкының олуг шагыйре Габдулла Тукайны соңгы юлга озату дәвере булып теркәлде. Казан яхшы хәтерли: 4 апрель көнне иртән Клячкин больницасыннан мәрхүмнең гәүдәсен түгел, гүя чәчәкләргә күмелгән кадерле һәм илаһи бер затны, бәһа биргесез зурлыкны күтәреп чыктылар. Печән базары аша Юнысовлар мәйданына агылган ташкын, көчле магнит сыман суырып алып, үзе артыннан яңадан-яңа төркемнәрне иярткә. Урамга сыеша алмаганнар киртәкойма башларына кунаклый. Бүрекләр салынган, башлар аска иелгән. Шәһәр өстендә завод-фабрика гудоклары, паровозлар гүләве яңгырый. Болар — шагыйрь белән хушлашу авазлары...

Тукайны күмү мәрасиме болганчык тормышны тагын бер кат айкалдырып ташлады. Хәят диңгезе төбендә асылташлар да житәрлек анысы, тик алар кайчан өскә калкып чыгарлар да жиһанны нур белән балкытырлар соң?

«Мин югалттым...»— дия-дия иске ел жылый. Аны туктатасы, гакыллы сүзләр табып ихластан юатасы иде. Чөнки Тукайның «Шүрәле»сен музыка итеп зур сәхнәләргә күтәрәчәк композитор дөньяга килде!

Яңа — 1914 ел илләр, кыйтгалар өстендә канат жәя. Ул кешелек язмышына зур афәтләр, кан һәм күз яшьләре дә алып килер. Чакма белән чакма бәрелгәндәй, халыкларны үзара сугыштырыр. Әлегә туплар шартламый, дарылар дөрләп кабынмый, ләкин тарих сәхнәсендә инде канлы болытлар куерып килә...

Кара чәчле, йомры битле Фәритебез инде имезлек сорарга өйрәнеп житте. Өстәмәгә кәжә сөте эчүдән дә тартынып тормый. Шешәдәге куе сөтне суырганнан соң битләре алланып китә, кул-аяклары хәрәкәт сорый башлый. Әйдәгез, булачак героебыз үсә төшсен, тәпи атларга һәм беренче сүзләрен әйтергә өйрәнсен. Ә без шул арада әти-әнисенең язмышлары белән танышa торыйк.

Әтисенең нәсел-нәсәбе турында язма шәҗәрә юк. Каян булсын ди, чөнки якындагы буыннарның кайсын гына алып карама, һәммәсе — чын игенчеләр, жир кешеләре. Таңнан торып жир сөргән, иген иккән кешеләрнең, укый-яза белсәләр дә, ыру тарихын теркәп бармаулары ул заман өчен табигый хәл.

Заһидулла Яруллин 1888 елда Мамадыш өязенә караган Кече Сөн авылында туа. Әтисе Ярулла нык бәдәнле, дәртле булса кирәк — сабан туйларында көрәшергә, «кәмәринкә» һәм «чабата» көйләренә биергә яраткан. Озак та үтмәстән, Яруллага Түбән Кыерлы дигән авылдан килен төшерәләр. Алты-жиде баланың, шул исәптән төпчек малай Заһидулланың да булачак әнисе инде бу. Гөлзәлифә исемле килен ил-йорт арасында үзен эшкә-кулга оста, уңган хатын итеп таныта. Чибәр. Хәтта бервакыт, иренең көнчелегенә түзә алмыйча, Түбән Кыерлысына кайтып та китә. Ләкин Ярулласында да үжәтлек житәрлек икән: ат жигеп килеп төшә, кулын бәйләп диярлек арбага утырта, урман читендә ял итәргә туктагач кына, хатынның беләгендәге бауны чишә...

Гөлзәлифә, авылның үзенчә итеп әйтсәк, итәк тутырып балалар таба. Иң олысы Гайнулла — бик җете, терчә, усал. Туган авылы мәдрәсәсендә укый, шуңа күрә кечерәкләр аңа киләчәктә «шәкерт абый» дип эндәшәчәкләр. Егетлек чорына аяк баскач та читкә чыгып китә, Донбасс шахталарында күмер чаба. Беренче тапкырында кайтып төшә — егетне танырлык түгел! Басу капкасыннан кергәч тә чирәмлектә уйнаган балаларга чуклы конфет сибә. Ә олыларны иң нык гажәпләндергәне — аягындагы ыспай күн итек. Кунычлары балтырга сыланып тора, калын резин табаннар исә таш өстеннән йөрер өчен генә ясалган диярсең. Егетләнәсе килгән чак бит, сөйләшкәндә русча сүзләр дә кыстыргалап жибәрә икән бу, шуңа күрә авылда «урыс Гайнул» дигән кушамат тагалар үзенә. Икенче кайтуында исә Гайнулла кешеләрне тагын бер яңалык белән шаккатыра. Юл капчыгыннан тальян гармун тартып чыгара да «Шахта көе»н уйный башлый. Үзе уйный, үзе жырлый:

Шахтер егет күмер вата
Вак-вак итеп кисәген.
Гомерем булып таш басмаса,
Ташламам, жанкисәгем...

Күпләрнең үз гомерендә беренче тапкыр мондый гармун күрүе. Гайнулланың төс-кыяфәтеннән генә түгел, жыруыннан да шахта исе бөркелеп тора. Ире яки улы читтә йөргәннәр өчен аерата сагышлы һәм тәэсирле күренеш булгандыр бу, әлбәттә.

Икенче уллары Газизулланы солдат хезмәтенә чакырталар. Падишаһ агъзам хәзрәтләренә егерме биш ел хезмәт итеп кайтканнан соң, ул атасыннан калган йортны тергезергә керешә. Каннарында моң-музыкага һәвәслек яшеренеп яткан, күрәсең: монысы да гармунда уйнарга өйрәнеп кайткан, кайчакта колак ишетмәгән көйләрне дә сиптергәли. Аны «солдат абый» дип йөрткәннәр. Солдат хезмәтеннән иртеп кайткан мылтыгы чоланда саклана. Көпшәсе һәм түтәләре шомарып беткән бу мылтык әле дә булса гамәлгә ярарлык лабаса. Газизулла аның белән еш кына ауга йөри, төлке һәм куян атып кайта. Шул сәбәпле, Газизуллага тора-бара «куян бабай» дигән кушамат ябышып кала. Ау унган көн — бәхетле көн: табынга өреле шулпа һәм табак тутырып куян башлары куела. Куяннарның гәүдә өлеше кая соң, дип гаҗәпләнмик. Алары базарга киткән — тормышны алып бару өчен акча да юнәтергә кирәк бит әле.

Алгарак сикердек бугай, яңадан Ярулла абзыйга кайтып төшик...

Күзләрен, иген-таруны җыеп алганнан соң, авылның ир-атлары шахтага күмер чабарга китә, дигән идек. Тормыш авыр, бала-чага күп. Акча эшләү, гаиләсенә кием-салым юнәтү максаты белән Ярулла да читкә чыгып китә... Һәм, күпме көтсәләр дә, туган йортына әйләнеп кайтмый. Өстәвенә, кисәктән урын өстенә егылган әниләренең дә гомере кыл өстендә тора. «Якупныкылар шахтадан әйләнеп кайткан»,— дигән сүзне ишетү белән сырхау Гөлзәлифә олы кызы Гайшәне югары очка менгереп җибәрә: бар, белеш, әтиегездән бер-бер хәбәр юкмы, янәсе.

Гайшә инде җитү кыз булып өлгергән. Оялып-тартынып кына Якупныкыларның капка келәсенә кагыла. Капка тавышынамы, әллә тәрәзәдән күрепме, каршысына юка мыеклы егет чыга. Каушый кыз, бит очларына кадәр кызара, телен көчкә әйләндереп:

— Әтине... күрмәдегезме?— дип сорый егеттән.

Егет баштарак телдән язгандай тотлыгып кала. Ни әйтсен ул: кызның әтисен бит шахта күмере басып үтерде... Калганын ничек аңлашканнардыр, анысы безгә караңгы. Ләкин көннәрнең берендә Гайшә шушы йортка килен булып төшә. Ятимә калуы түгел, яшьлеге һәм чибәрлеге егетнең төн йокысын качырган, күрәсең.

Яруллансы артыннан ук үлем Гөлзәлифәне дә түшәктән суырып ала. Өлкән малайлар — читтә, кызлар да инде мөстәкыйль яшәргә тернәкләнеп җиткән. Ә менә биш яшеннән дөм ятим калган Заһидулла нишләргә тиеш соң? Кат-кат үкереп елый, күз яшьләре бернichә тапкыр кибә аның — әмма болар берсе дә хәлне җиңеләйтми. Малайлыкка бирер идең, әлегә эшкә ярарлык түгел, буыны сыек. Авылның шәфкатьле кешеләре аны үзләренә сыендыралар, өй саен чиратка куеп та тәрбияләләр.

Гайшә апасына бик тартыла Заһидулла, ләкин ул инде хәзер «кеше кешесе», өйләрендәге кебек алай бик җәелеп китә алмый. Энекәше белән күбрәк юана башладымы, каенанасының күзләренә күпсенү галәмәте бәреп чыга. Килен кеше — ким кеше, дип белми әйтмәгәннәр шул. Чү, ашыкмыйк торыйк, Заһидулланың да кирәге чыкты бит әле бу йортка! Гайшә апасы алып кайткан бәбине карашырга аңардан да кулай ярдәмче юк.

Чирәмле юл төшкәч, Заһидулла кабык арбага салынган баланы урам йөртә, тыкрык буена алып чыгып йоклата. Арбаның юка кабыгыннан яртылаш ачык итеп эшләнгән әрҗәсе, чана табанындай бөгелеп килгән тоткычлары май кояшы астында акрын гына җылына башлый. Аулак урын, аулак минутлар. Менә хәзер баланы йокысыннан уятмый гына мендәр астына ничек тә кулны тыгарга кирәк. Заһидулла якягына карана, тəкреген йотып куя. Ниһаять, аның нәни куллары мендәр астына яшерен куелган икмәк телеме белән очраша. Кем тыксын аны, Гайшә апасы, билгеле. Өстәлдәге икмәк валчыгын да бөртекләп ашый

торган авыл гаиләсендә ризыкның һәр сыныгы санаулы. Каенана каршында кураләтә аркасыннан сөеп бирүгә караганда, малайга ипине яшереп ашатуың хәерлерәк. Ә малайның мондый хәйләләрдә эше юк: икмәк тәмлеме — тәмле! Чәйнәгән саен сөтле чикләвек тәме килеп тора.

Кече Сөннең үзендә мәдрәсә бар, шактый ераклардан да килеп укыйлар анда. Ләкин Заһидуллагамы соң уку турында хыяллану! Киләчәктә хәреф тану, уку-язуны үзлегеннән өйрәнергә туры килер аңа.

Мәдрәсә димәктән, шулай да бер кагылып уза ул аның итәгенә. Сөйләсәң... көлке дә, оят та. Заһидулла уникенче яшенә кереп бара. Иң авыр чаклар — артта! Чын-чынлап кул астына керер вакыты житте, хәзер инде малайлыкка биреп жибәрсән дә ярыйдыр.

Һәм менә Заһидулланы ерак сәфәргә әзерлиләр. Башында мескен бүрек, өстендә таманчарак иске бишмәт. Шул бишмәт өстеннән юлда туңмасын дип, Гайшә апасы үз куллары белән яшел билбау бәйли. Тастымалга төреп малайның куенына ипи кыерчыгы тыгучы да ул. Ончы Хәйрулла абзый жигүле ат белән Якуплар капка төбенә килеп тә житкән. Ул он һәм ашлык белән сәүдә итә, Чистай юлында йөри. Бүген каенана да юмартланган, тәмле тел белән сөйләнә-сөйләнә сәфәр чыгасы малайга кулындагы янчыгын — юл күчтәнәче суза. Таш бәгырьле түгел ләбаса, бала хакына йомшамый хәле юк. Моңа кадәрге кырыслыгы да бары житмәүчелектән, ризык кадеренә өйрәтергә тырышудан гына иде.

Тик менә бәла: аягына киярдәй рәтле-башлы итеге юк малайның. Кичә кичтән киптерергә куелган каталары, гөнаһ шомлыгына каршы, иртән мич түрендә онытылып калган. Табагач белән сыңарын тартып алырга өлгергәннәр, тик кая ул — болай да алама итегенең яртысы төтен булып җилгә очкан! Кат-кат иске аякчу чорнаганнан соң малайның аякларын олау печәне белән күмәләр. Ончы Хәйрулла Чистайда таныш байлары барлыгын тагын бер кат сөйләп ала да, гадәтенчә, хәйран осталык белән атына чөңгерә: «На-а!»

Киттек! Алда — кырык чакрым юл...

Авыл урамының юлы такыр. Чана табаннары астында, хушлашу жыры булып, кар шыгырдый. Алда зәһәр жилләр дә буласын аңлатырга теләгәндәй, ачы көйгә жырлый: «Аякларың туңачак... шыгыр... шыгыр...» — дип бертуктаусыз колакны игәүли кебек. Ә аякларга, чыннан да, салкын булачак. Суыкның авызын коры печән белән генә кемнең томалаганы бар әле?

Хуш, инде мәдрәсә яныннан узып барышлары икән. Тавык төшенә тары керә, диләр бит. Шуның шикелле, әллә Заһидулланың күзенә генә күренәме? Мәдрәсә ишеге төбендә — бер-беренә сөяп куелган киез каталар... суыкны бар дип тә белмичә, аклы-каралы сарык бәрәннәредәй, бер-беренә елышып, йокымсырап утыралар. «Бирим дигән колына — чыгарып куйган юлына» дигәннәре шул микәнни? Шәкертләр сабакта чакта, әйдә, әләктер шуларның берсен...

Чанадан сикереп төшкән малайның бу «һөҗүмен» хаҗәтханәгә чыккан бер шәкерт күреп калган икән. Әнә, һай-һаулап, чатыр чабып Заһидулланы куа килә. Хәйрулла абзыйның аты хәйран ераклашып өлгергән. Шәкертнең кулына бер дә эләгәсе килми, итекне ташлау да кызганыч. Нишләргә? Иң яхшысы — итекнең сыңарын булса да куа килүченең борын төбенә ташлап калдыру!

Заһидулла шулай эшли дә. Сыңар итекне тотам дип алданган шәкерт, килгән шәпкә, көрт эченә кереп чума. Итекнең икенче сыңарын кочаклаган малай, ниһаять, чанага килеп каплана. Ярамаган эш эшләнде бит — Хәйрулла абзый кече юлдашын баштарак әдәп өчен орышып та ала. Үзе эченнән генә сөенә: ни әйтсәң дә, малайны аяк-кулларын өшетми илтеп тапшыру кирәк аңа. Заһидулла, сулышы басылганнан соң, аякларын бер-бер артлы киез ката эченә чумдыра. Ике аякка — бер ката! Чистайга әнә шулай барып керәләр.

Еракта шәйләнгән чиркәү гөмбәзләре, мәчет манаралары якынайган саен өстенә авардай булып зурая, биегәя баралар. Таш йортлар рәтендә челтәрле, зәңгәр буяулы тәрәзәләр балкып-балкып кала. Кама буена утырган борынгы шәһәрнең кешеләре, эреле-ваклы манзаралары төш кебек кенә чагылып уза. Ә менә биек коймалы, урыс капкалы таш йортны, шуның ишегалдын тутырып өргән чылбырлы этне Заһидулла гомерендә дә онытмаячак. Тире-яры белән эш итүче Иманкол бай йорты икән бу. Сүзләрен, исәп-хисапларын түгәрәкләп бетергәннән соң Хәйрулла абзый, аркасыннан сөя-сөя ягымлы сүзләр әйтеп, Заһидулланы шушында хезмәткә калдыра.

Савыт-саба, коштабаклар юучы булып эшкә ялланды малай. Иманкол бай турында: «Колы гына бар, иманы юк»,— дип буш сүз сөйләмиләр икән. Йомышчы булып ярты ел чамасы эшлиме-юкмы, колагыннан сөйри-сөйри малайны урамга чыгарып ташлый хуҗа. Сәбәпчесе — байның яраткан эте. Көндезләрен аны кайчак чылбырыннан ычкындыргалыйлар. Иреккә чыккан эт ишегалдының һәр почмагын иснәп-тикшереп чыга, иркәләнәсе килеп кулга сарыла. Сөяк-санакның кайсы ишектән чыкканын яхшы белгәнгә күрә, ул кухня тирәсендә ыграк кайнаша. Юынтык су ташларга чыккан Заһидулланың буш чиләк күтәреп кире кергән мәле икән. Игътибар ителмәгән, күрәсең: менә шул чак этнең аяклары ишек тупсасына кысыла. Чинау тавышына йөгереп чыккан Иманкол бай: «Ах син, йолкыш!»— дия-дия зәһәрләнеп, малайның колагына ябыша...

Алабай этнең ишеккә кысылуына рәхмәт кенә әйтергәдер, бәлки? Чөнки нәкъ менә шушы вакыйгадан соң Заһидулланың тормышында кискен үзгәреш була. Очраклык — кеше язмышларын хәл итүдәге бөек бер тылсымчы! Өрәңгенең җилпәзәле орлыклары кышын дөньяның дүрт ягына сибелә дә тамыр җибәрергә җай чыкканын көтә башлый. Язын арба тәгәрмәчләре аны сытып узарга яки үзе белән ияртеп алып китәргә мөмкин. Тишеләсе орлыкның язмышы нинди туфракка, нинди шартларга эләгүенә бәйле, хәтта нык бәйле. Адәм баласының язмышы да нәкъ шулай. Табигать тумыштан һәркемне үз-үзен раслап яшәрлек көч, сәләт, иҗтиһат белән бүләкләгән. Ләкин кай җирлеккә, нинди мохиткә эләгәсең бит...

Бу җәһәттән язмыш Заһидулланы, җитәкләп, нәкъ менә кирәкле туфрагына илтеп ташлый. Урамда каңгырап йөргән ач малайны Иосиф Шнейдер дигән кеше үзенә тәрбиягә ала. Чистайга Петербург яклары ннан килеп чыккан ул. Һәрхәлдә, нужа кушканнан булмаска тиеш. Бәлки, патшага каршы ярамас сүзләр сөйләгәне өчен пайтәхеттән сөргәннәрдер үзен? Заһидулла боларны белми, аны яңа хуҗасының кешелекле һәм эшкә оста булуы сокландыра. Хәер, хуҗа дип әйтү килешер микән, малай аны беренче көнне үк үз итә, баштан кичергәннәрен түкмичәчми сөйләп бирә. Берсенең — «улым», икенчесенең «Йосыф абый» дип үзара эндәшүләреннән дә җылылык, якынлык бөркелеп тора.

Йосыф абыйсының төп эше — музыкаль инструментлар көйләү. Сәүдә юлларының байтагы Чистай аша уза. Сәүдәгәр һәм базарчылар артыннан җибәрелгән уен коралларының һәркайсы менә шушы йортка килеп эләгә. Бай бар, ярлы бар дигәндәй, Чистайның үзендә дә рояль һәм пианино тотучы гаиләләр күренгәли. Ватылды яки көйсезләндеме, алары да аякланып бирә килә. Менә шуларны көнозын диярлек сүтә, җыя, көйли, боргалый Йосыф абыйсы. Почмакта верстак, стенада — эш кораллары. Ниндидер агачларны юна, шомарта, тигезли, эскәнҗәгә кыстырылган сәер-сәер детальләрне игәү белән ышкылый остабыз. Малай карап тора, Йосыф абыйсы сораган коралларны алып бирә, кирәк урында ярдәм дә итешә.

Беренче тапкыр күргәндә рояльне алгы ягы дугаланып килгән аяклы сандыкка охшаткан иде ул. Зур сандыкның кече капкачы астында аклы-каралы клавишлар тезмәсе посып тора икән. Өлкән капкачны

күтәрдеңме, анда буйдан-буйга тарттырылган кыллар, агач башмаклар рәте. Йосыф абыйсы клавишларның әле берсенә, әле икенчесенә бармаклары белән кагыла да бүлмәне серле авазлар белән тутыра. Тикшерүе дә, уйнавы да — бергә. Көй турында әйтәсе дә юк. Заһидулла остазының кул һәм бармак хәрәкәтләрен дә отып калырга тырыша. Кыскасы, күңеленең кай төшендәдер яткан бер «җен» уянып килә Заһидуллада. Көн тудымы, куллары уйнап карауны сорый башлый аның.

Малайда табигый сәләт барлыгын күргәч, Йосыф абыйсы көннәрнең берендә кәгазь-каләм ала, дәфтәр битенә нота билгеләре төшерә. Шулай итеп, Заһидулла музыкадан беренче дәресләр ала, кыенлык һәм акрынлык белән булса да нота әлифбасын үзләштерә. Мәсьәлә ачык ки: гармунчы абыйларының каны малайда да бәреп чыкты...

Яшүсмер булып килгән, рояль һәм гармунны кош урынына сайрата торган Заһидулла хәзер инде скрипка яки гармундыр, патефон яки граммофон кебек нәрсәләрне ялгызы гына да рәхәтләнеп төзәтә ала. Укучысының — ятимлектә үскән крестьян тумасының шулай уңышлы күтәрелеп китүенә Петербург музыканты сокланмый калмагандыр, билгеле.

Заһидулланың музыкага булган сусынын басар өчен хәйлә дә уйлап таба болар. Пианино һаман-һаман килеп тормый — кулга бер эләктеме, тиз генә ычкындырмау җаен карарга кирәк. Такта яру заводы хуҗасы төзәтергә биргән пианино артыннан инде ничә тапкыр хезмәтчеләрен җибәрә, тегеләрнең җавабы бер генә:

— Сабыр итә күрсен, бер-ике кылы көйләнеп бетмәгән әле...

Соңгы килүендә хезмәтчеләр аеруча ашыктыра: хуҗаның йортына Мәскәү тикле Мәскәү каласыннан кунаклар кайтып төшкән, араларында пианинода уйный белүче гимназистка кыз да бар, янәсе. Монысы инде шактый җитди, ышандырырлык дәлил. Карт һәм яшь оста, күзгә-күз карашып алалар да, пианиноны тиз генә «төзәтеп» бирәләр! Бер сүз әйтер хәл юк: бүре дә тук, сарык та бөтен...

Көтмәгәндә Заһидулла өстенә тагын бер зур бәхетсезлек килә: аны укыткан, тәрбияләгән, музыка дигән могҗизалы дөньяга алып кергән Йосыф абыйсы кинәттән үлеп китә. Нинди генә авыр дигән балачакның да якты бер сәхифәсе булмый калмый. Язмыш Заһидуллага әнә шундый сәхифәне бүләк иткән иде: Йосыф абыйсыннан ул яхшылыкка, тормышының алга табасын хәл итәрдәй һөнәргә, осталыкка өйрәнде.

Заһидулланың авыр югалту кичергән, икенче тапкыр ятим калган көннәре. Әти-әнисенең туфрагы өстендә дәфен әйтелгән минутларны юньләп хәтерләми дә ул. Ә менә каршындагы кабер туфрагы — күз яшедәй кайнар, сагышлы җыр кебек моңсу... Яшүсмернең күңелендә үзе дә аңлап бетермәгән матәм көе өзгәләнә. Кем белә, бәлки, «Тукай маршы» булып дөньяга туачак моңнарның беренче кайтавазыдыр бу?

Йосыф абыйсыннан күпме рухи мирас күчте — монысын чамалап бәяләргә мөмкин. Матди яктан исә төгәл әйтә алабыз: Заһидуллага остазыннан бер капчык мирас кала. Болар — музыкаль инструментларны көйләү һәм төзәтү өчен яраклы эш кораллары. Хәзергә Заһидулланың бөтен байлыгы менә шулар. Әйдә, капчыкны җилкәңә сал да сәфәр чык, яшь егет! Ил-җир күрерсең, халык белән аралашырсың, хакыйкать җимешләрен авыз итәрсең.

Билгесез киләчәгенә ашкынган Заһидулла шулай эшли дә — сәфәргә чыгып китә. Сембер, Самара, Уфа, Оренбург шәһәрләрен гизә, скрипка уйнап, музыкаль инструментлар һәм уен кораллары төзәтеп тамак туйдыра.

Ниһаять, 1908 елның җәендә Казан каласына аяк баса егет. Ул инде байтак шәһәрләрне күргән кеше, төн кунарга постоялый дворга керәсе булыр. Ә хәзергә, ягъни көндезен, шәһәр белән таныша торсаң да ярый.

...Иске Татар бистәсенең үзәге Мәскәү һәм Печән* урамнары кисешкән чатка урнашкан. Алтын хәреф йөгертелгән вывескалар кибет эченә чакырып, әйдәкләп тора. Татар сәүдәгәрләре Үтәмишев, Мусин, Хәйбуллин, Үтәгәневләр үз фамилияләрен вывескага рус телендә яздырганнар. Күбрәк керсеннәр, товарны күбрәк алсыннар гына — кайсы милләт кавеменнән булса да ярый, дигәнне аңлата инде бу. Алга таба шкафчылар биләмәсе китә. Үзенең яшькелт мәчете һәм сәүдә рәтләре белән данлыклы Печән базары шушы инде. Бирегә Гәреч юлыннан юкә мунчаласы һәм суккан чыпта китерәләр. Ит, он-ярма, төрле тәм-том, җиләк-җимеш рәтләрендә халык мәйханә килә. Маклерлар, чәйлек өмет итеп, авыз ачып торганнарга базар серләрен өйрәтә. Сәүдә юлында шомарган алыпсатарлар, берсен-берсе уздырып, товарын мактый. Читек-кәвеш, кәләпүш, калфак, бүрек, мех, эскәтер, тугыздан үргән чабата, җиз комган, чалма, шәмаил дисеңме — һәммәсе яңалар, өсләренә тузан кунарга да өлгермәгән. Кызыл малчылар исә вакарь беләнрәк сөйләшергә ярата — ни әйтсәң дә, бакалея һәм галантерея товарлары күз явыңны алырлык шул. Менә шулар тирәсендә — алыш-биреш, бәхәс-тарткалаш, сәүдә гөрелтесе. Биредә күп нәрсә «хәйләи шәргыя»гә корылган: кемдер алдый, кемдер алдана... Кыскасы, җомга көннәрендә аеруча җанланып китә торган бу базар — Мәкәрҗә ярминкәсенә барырга җыенучылар өчен менә дигән репетиция!

Бер читтәрәк исә трамвай һәм извозчиклардан кала иң ышанычлы, арзанлы транспорт — «барабыз»лар төркеме, җигүле атлар. Андагы тамашаны, солы һәм печән сәүдәсен күргәннән соң, әлеге мәйданның ни өчен Печән базары дип аталуына ныграк төшенербез. Шәһәрнең җигүле транспортына печән дә кирәк ләбаса! Ә печәнне элек-электән бары тик шушында гына табарга мөмкин.

«Болгар», «Амур», «Сарай» номерлары, хәрчәүнә, чәйханә, трактирлар да шушы тирәләргә тупланган. Кибет хуҗалары, базарчылар, шомарганрак приказчиклар мосафирханә ресторанына яисә хәрчәүнәгә кереп яшертен генә пирәшләп чыгуны да онытмыйлар.

Озак торган йортның бер-бер почмагы чери башлаган шикелле, биредә дә мүкләнеп беткән бер урын бар. Монысын «Көфер почмагы» дип йөртәләр. Җыен эшлексез, гайбәтче, ысулы кадимче, диндар кешеләр шушында җыелган. Теләсә нинди яңалыкка теше-тырнагы белән каршы бу адәмнәр, дин һәм мәчет байрагына ышыкланып, үткән-сүткәнне тикшереп, мәсхәрә кылып калалар:

— Милләт йөзенә нәҗес яккан нәрсә! Мөселман рухын рәнҗетеп, эшләпә кигән бит, дуңгыз кавеме...

— Аллаһы тәгаләдән оялыр идең, көфер калдыгы, күмерче!

Европача киенгән татар яшьләре һәм зыялылары өстенә әнә шулай күркә сыман ташланалар. Ак манжет яка һәм галстук — болар өчен кирәксез бер муенчак. Кара цилиндр эшләпә исә түбәтәйдән бүтәнгә күнекмәгән күзләренә корым торбасы булып күренә. «Күмерче!»— дигән сүзләренә нәкъ менә шул мәгънәне салалар да: динебезнең чисталыгын каралтасың, янәсе.

Заһидулла беренче көндә үк Печән базарына килеп чыга, андагы чуарлыкны тамаша кыла.

Печән урамы Кәримовлар матбагасы белән дә атаклы. Шушы ук урамда «Сабах» көтепханәсе хуҗасы, татар укытучылар мәктәбе инспекторы, гыйлем иясе Шиһаб Әхмәровлар тора. Аның йортында җиде-сигез яшьлек гадәти бер малай да яши. Гадәти дию генә дөрес булмыр микән? Салих Сәйдәшев дигән бу бала Заһидулла Яруллиннан беренче дәресләр алачак һәм татар профессиональ музыкасының якты юлдызына әвереләчәк. Каршы якта, «Болгар»ның кырыгынчы бүл-

* Мәскәү һәм Печән — хәзерге Киров һәм Париж коммунасы урамнары

мәсендә тискәре дөнья белән тарткалашып, Тукай үзенең гомер йомгагын сүтәчәк әле. Казанның йөрәге булып типкән Фатих Әмирханның торган җире һәм аның җитәкчелегендәге «Әльислах» газетасы идарәсе дә моннан ерак түгел.

Алга таба Заһидулланың тормышы менә шушы йортлар һәм урамнар, шәһәр кешеләренең төрле-төрле катламнары тирәсендә агачак инде...

Беренче кичне үк тамак хакына ресторанга кереп уйный ул, пианинода татар көйләрен башкара. Эт тыкрыгы урамындагы бу ресторан хуҗасы күктән төшкән «табыш»ка сөенеп бетә алмый. Әнә бит, милли көйләр тыңлап ләззәт алучы кунаклар подноска акча арты акчаны ташлап кына торалар! Аракы пары һәм тәмәке төтене эчендә шома, кызыл йөзләр төсмерләнә, «афәрин!» дип кычкырган канәгать тавышлар яңгырый. Билгеле инде, эшләр болай барса, музыкант егетне акча белән канатландырып торырга да кирәк булачак...

Кесәсенә акча тама башлагач, «һөнәрле югалмас» дигән сүзләрнең мәгънәсенә Заһидулла ныграк төшенә. «Свет» кинотеатры тотучы Шәйхетдин әфәнде дә, милли көйләргә ихтыяҗның зурлыгын чамалап, егетне якты йөз белән каршылый. Заһидулла — кинотеатрда иллюстратор. Ул чакта кинoны «томанный» дип йөртәләр. Каршындагы ак җәймәдә Париж, Лондон кебек шәһәрләр манзарасы, дөньяның җиде читендәге биек-биек таулар, стенадай агып төшкән шарламалар күрсәтелә. Комик артист Макс Линдер катнашындагы көлке картиналар да чыккалый. Каршында — хәрәкәт һәм сурәтләр агышы, ләкин вакыйгалар сүзсез бара. Менә шуларны җанландыру, тагын да тәэсирлерәк итү өчен музыка кирәк. Скрипка, мандолина һәм пианинодан торган оркестрның башында — Заһидулла Яруллин. Залда татар, башкорт, гарәп көйләре яңгырагач, билгеле инде, «томанный»га халык күбрәк йөри башлый.

Инде Заһидулланың Тукай белән аралашуы хакында да берничә сүз әйтер чак җитте бугай.

«...Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнәргә, яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаҗ»,— дигән сүзләрне ачынып әйткән шагыйрь пианинода уйнаучы һәм милли көйләрне күңелгә үтәзеп башкаручы бу егетне күрми калырмы соң? Тукай номерында зур гына шәхесләрдән алып гади сукбайларга хәтле төрле катлам вәкилләренең булуы мәгълүм. Язмыш кешеләрне кайсы гына нокталарда кисештермәгән. Казанга килүгә кунар урыны да ачык билгеле булмаган Заһидулланың көннәрнең берендә Тукай номерында куныпчыгуы да ихтимал иң. Без боларны белмибез. Бик кызганыч хәл: Тукай белән Заһидулланың кайда, ничек, ни рәвешле аралашулары турында язма истәлекләр теркәлеп калмаган. Аннары, бу очрашуларның әһәмияте бардыр, дип ул чакта кем уйлап торсын икән...

Кич. «Болгар» мосафирханәсендәге ресторан. Залга төрле тәм-том, кыздырган ит һәм балык исләре таралган. Өстәл тирәли утырган халык, пычак-чәнечкесен эшкә җигеп, ашау белән комарлана. Бүлмәсе янәшә булгангамы, ашау-эчү өчен ресторанга Тукай да еш кергәли. Һәрвакыт тәрәзә тирәсендәге өстәлне сайлап ала. Оркестрдагы Заһидулланы ымкагып кына үзе янына өстәлгә чакыргалый. Күпмедер сөйләшеп-фикерләшеп утырганнан соң Тукай, гадәтенчә, әйтеп куя:

— Мин яраткан көйләрне уйна әле, Заһидулла!

Шагыйрьгә кайсы көйләрне уйнайсын яхшы белгән Заһидулла пианино артына утыра. «Тәфтиләү», «Әллүки», «Ашказар» моңнары... Боларны Тукай яратып, ихластан бирелеп тыңлый. Берсендә килеп Заһидулланың кулын да кыса һәм шушы ук көйләрнең «Шәрык» клубында күп тапкыр гүзәлрәк яңгыравын әйтә.

Бу сүзләрне Тукайның «Шәрык» клубына карата булган хөрмәте, симпатиясе әйттергән дип тә уйларга кирәк. Әйе, татар культурасының янар учагын хәтерләтүче әлеге йортны суган исләре аңкып торган ресторан белән чагыштыру мөмкинме соң!

XX гасыр башында да мәгърифәтчеләр «татар йоклый» дип һаман саен тукый тордылар. Бу сүзләрдә хаклык зур иде, әлбәттә. Давыл-ланып килгән 1905 елгы революция исә алмаз кылычы белән селтәнде дә хөррият капкаларын каерып ачты, тормыш урамын яңа җилләр белән тутырды. Милли төбәкләр өчен күз күрмәгән хәл иде бу: әле анда, әле монда яңадан-яңа газета һәм журналлар аваз бирә, китап басу матбагалары канат җәя, театр труппалары калкып чыга, китап-ханә һәм клублар ачыла. Әйе, бишенче ел күгендә чатнаган яшен утлары җәмгыятьнең иң караңгы почмакларын да яктыртты ул чакта.

«Шәрык» клубы — революция дулкыны тудырган әнә шундый ка-назышларның берсе иде.

Губернатор рөхсәте белән ачылган бу клуб демократик татар яшьләренең үзегенә әверелә. Клубның программасын тәфсир иткән белдерүдә игътибарга лаек мондый юллар да бар: «...буфет эшли, милли пәрәмәч һәм алькогольсез эчемлекләр сатыла». Күпмедер ва-кыттан соң клуб сәхнәсенә скрипка һәм пианино, Тукай сүзләре белән әйтсәк, «чүмеч төсле мандолиналар» менә. Татарлар арасыннан оеш-тырылган беренче опера труппасы чыгышлар ясый. 1910 елдан исә монда даими рәвештә милли спектакльләр куела башлый. Хәтта Гоголь-нең «Ревизор», Островскийның «Гроза» әсәрләре татар телендә күрсә-телә. Клубның демократик һәм интернациональ юнәлештәге эшчән-леге болар белән генә дә чикләнми әле. Саный китсәң, адашырга мөмкин...

Хәзер инде, әйдәгез, «Шәрык» клубының эченә күз салыйк. Шул заманның танылган журналисты Исмәгыйль Рәмиев аны болайрак тасвирлый:

«...Өч катлы торак йортның икенче каты тамаша залы итеп җай-лаштырылган. Анда йөздән артык урын. Идәннән ярты метр биеклектә сәхнә. Ягъни тәбәнәк залда тәбәнәк сәхнә. Сәхнәдән кул сузымы ераклыкта тамашачы утыра. Алгы сафта утырган тамашачының борын төбендә — суфлер будкасы, колак төбендә суфлер мыгырдавы.

Зәһидулла Яруллин житәкчелегендә оешкан беренче татар кыллы оркестры да шушы залның бер почмагына урнашкан. Клубка килүчеләр оркестрның уенын зур кызыксыну белән тыңлый».

Җәй көне гастрольләрдә йөреп кайткан «Сәйяр» труппасы кыш-ларын бирегә сыена. Рампа утлары. Хөрмәтле кунаклар өчен урын-нар. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Коләхметов, Ш. Әхмәров һәм Казанга килгән дәрәҗәле затлар, гадәттә, шушы рәткә утыра. Габдулла Кариев житәкләгән «Сәйяр»ның парлак чагы. Аны карый-лар, яраталар, алкышлыйлар.

Татар театрының атасы саналган Габдулла Кариев — Зәһидулла Яруллин кебек үк ярлы баласы. Тукайның күптәнге дусты, яшьтәше. Уральскида чакта мәдрәсәдә бергә диярлек укыйлар. Соңрак Тукай үзенең хатларында: «Хөрмәтле аркадаш Габдулла Хәйруллин* җәнап-ләре»,— дип кенә язачак аңа... Мәкәрҗә ярминкәсенә килеп эләккәч, Кариев беренче тапкыр театр караганнан соң шатлыгыннан кәпәчен сәхнәгә ыргыта! Менә шуннан соң, ягъни 1908 елның көзендә Казанга кайткач, «Сәйяр» труппасын оештыра. Труппаның парлак чагы дидек. Ләкин дан казану — медальнең бер ягы гына. Икенче ягында — патша жандармериясе тарафыннан даими күзәтелү, эзәрлекләнү, шәригать исе-

* Кариев — псевдоним, чын фамилиясе Тукай язганча.

меннән тамга җыючы динчеләр һәм кадимчеләрнең спектакльләргә аяк чалуы. 1913 елда егермеләп шәһәрнең жандарм идарәсе труппаның гастрольләрен яшерен күзәтүгә ала. Патша өчен менә нинди «куркыныч-лы» төркем булган алар!

Боларга тагын юл йөрү һәм акча кытлыгын, афиша бастыру кыенлыкларын, власть вәкилләреннән рөхсәт кәгазе өчен йөз суы түгүләрне дә өстәсәк, безгә беренче карлыгачларның фидакарьлегенә сокланырга гына кала.

Татар мәдәнияты туфрагына театр каяндыр күктән сикереп төшмәде. Дин һәм самодержавие никадәр генә кысмасын, аның беренче үсентеләре, ташны ярып үскән агачтай, караңгыны ертып яктыга чыкты. Артыгын сикереп булмый — тәҗрибә һәм мая туплар өчен әлегә өй театрлары да ярап тора. Урындык, өстәл, таяк һәм такта ише кул астындагы әйберләрдән әмәлләнгән сәхнә, декорация, ике якка ачылмалы пәрдә. «Артистлар» — йорт хуҗасы һәм күрше-күләннең укучы балалары, гимназия янсә училищеда укучы яшьләр. Ике кешене атап китик: Көнчыгыш Төркестанда Россия илчелегендә эшләгән Шәрәфетдин Габитов һәм рус-татар школасы инспекторы Ибраһим Терегулов. Соңгысы берара «Шәрык» клубы идарәсенең рәисе булып та тора. Өй театрының беренче сәхифәләрен Казанда шушы кешеләрнең гаиләләре башлап җибәрә.

Казанда рәсми төстә беренче ачык спектакль куелу исә 1906 елның 22 декабренә карый.

Аның тарихы болайрак. Бер төркем татар яшьләре — нигездә, интеллигенция вәкилләре, курсистка һәм гимназисткалар — татар телендә спектакль куярга уйлыйлар. Оештыру комиссиясе «Кызганыч бала» дигән драманы сайлап ала. Спектакльне сәхнәгә чыгару өчен иң әүвәле әсәрнең кыскача эчтәлеге, аны куюның максаты, җаваплы оештыручының һәм тамашада катнашачак артистларның биографиясе турында язма рәвештә аңлатма кирәк икән әле. Бу эшләр эшләнү белән газетада игълан басыла. Татар хатын-кызларының пәрәнҗәсез сурәттә ирләр белән бер залда утырасын белеп алган дин сакчылары һәм реакцион сәүдәгәрләр, спектакль куярга рөхсәт бирелмәвен таләп итеп, полиция башлыгына делегация җибәрәләр.

Бәхеткә күрә, алар соңга кала. Спектакль куюга рөхсәт кәгазе инде күптән артистлар кулында! Бишенче ел революциясеннән соң азмы-күпме юашлана төшкән полиция үзенең карарын үзгәртергә теләмәгән, күрәсең. Тыелган әйбер, гадәттә, күңелне тагын да кытыклаучан бит ул. Бу очракта да нәкъ шулай: мөселман руханиларының ду кубып йөрүләре, таяк тыгарга маташулары халыкта театрга карата кызыксынуны көчәйтә генә. «Новый клуб» бинасының ишеге төбендә аһ-ваһ килеп билетсызлар айкала. Тамаша залында алма төшәр урын юк. Кереш сүзне шагыйрь Сәгыйть Рәмиев әйтә. Ул беренче тапкыр спектакльгә килгән татар хатын-кызларын котлый, милләтнең һимматле яшьләренә — спектакльдә катнашачак һәвәскәр артистларга уңыш тели.

Спектакль тәмам. Сәхнәгә чәчәк арты чәчәк бәйләмнәре ява...

Бу уңайдан тагын бер гыйбрәтле хәлне искә төшереп үтик.

1798 ел. Император Павел I Казанга килгәч, Лаеш алпавыты П. Есипов патшадан публичный театр ачарга рөхсәт сорый. Ул чактагы шәһәр читендә, ягъни кайчандыр Пугачев окоплар казыткан төбәктә, тамаша залы корыла. Театр труппасы алпавытның крепостной артистларыннан төзелә. Тора-бара театрга Казан татарлары да йөри башлый. Бервакыт Есипов театрында Вольтерның «Мөхәммәт» исемле трагедиясе куела. Залда татарлар да күп була. Залда чалмалы Мөхәммәт күренүгә, мөселманнар арасында ыгы-зыгы куба. «Пәйгамбәр үзе килгән!» — дия-дия кычкырып, алар театрдан ук чыгып чабалар. Бер өлеше исә сәхнәдәге актерны үзләрен кәферләр җиненә йөргәннәре өчен шелтәләргә килгән «Мөхәммәт рәсүл аллаһ» дип кабул итә.

һәм, тиз генә аяк киемнәрен салып атып, алладан ярлыкауны, гафу итүне сорый-сорый йөзтүбән егылалар. Бу вакыйгадан соң алар бик озак вакыт театрга йөрмәгән, имеш.

Бөтенләй капма-каршы күренешләр: бер якта — мәдәни сукырлык, икенче якта — алкыш һәм ихтирам булып яуган чәчәкләр. Никадәр алгарыш! Шәт, аңлатма биреп тору кирәкмидер, революция дулкынының үз эшен эшләве көн кебек ачык.

Кыскасы, «Сәйяр» труппасы әнә шушы һәвәскәрләр җирлегендә оеша. Габдулла Кариев җитәкли башлаганнан соң ул яңа бер баскычка күтәрелә. Юл йөрүдән туймаган мосафир шикеллерәк, тора-бара «Сәйяр» үзенең географик чикләрен киңәйтә башлый. Җәй кердеме, читтәге татарларны уяту теләге белән, ул әле Урал, әле Урта Азия якларына юл тота. Мәкәрҗә ярминкәсен дә читләп узмый, әлбәттә.

Петербург — Россиянең мие, Мәскәү — йөрәге, дигәннәр ул чакта. Мәкәрҗәне исә Россиянең кесәсенә тиңләгәннәр. Бу чынлап та шулай. Нижний Новгород. Макарьев монастыре янындагы мәйданга июль урталарында Рәсәйнең дүрт ягыннан мал-мөлкәт төялгән олаулар агыла башлый. Һиндстан, Иран, Кытай кебек илләрдән килгән кызыл малчыларны да өстәсәк, базарның дәрәҗәсен һәм масштабын чамалау кыен түгел. Азмы-күпме акча юнәтергә теләгән йомышчы малайлар, пылаучы шәкертләр дә шушында кайнаша. Жандармериянең очлы күзләре дә бирегә төбәлгән: тирә-якта шымчылар мыжгып тора. Халыкның рухи эзләнүләрен һәм сәяси халәтен өйрәнү өчен менә дигән җирлек. Ләкин иң өстә калкып торган нәрсә — гөрләп торган сәүдә рәтләре, шау-шу, товар тирәсендә барган бәхәс, аңлашу. Әнә күңел иткән кешегә бохари тышлы китапларга хәтле бар биредә...

«Двухсветная» кунакханәсе. Миллионер Хөсәеновларның шәфкатен китереп, аны Тимерша Саллави дигән кеше арендага алып тора. Татарның зыялылары, эшкуар байлары фатирга шунда төшә. Белдерү такталарында хәтта «татарский Шаляпин» дигән афишалар да ялтырап китә. Һәвәскәр артистлар һәм музыкантларга да эш җитәрлек. Заһидулла Яруллин — шулар арасында. Мосафирханәнең иркен залын татар клубы рәвешенә китергәннәр, кичләрен ул кунаклар белән шыгрым тула. Шигырь, җыр, музыка яңгырый. Аракы эчү юк, алларында сәйлүн чәе һәм Казан пәрәмәче торган халык болай да ифрат кәефле күренә. Кесәсен киң ачарга өйрәнмәгән гади халык кына бу сәгатьләрдә, гадәттә, ясту һәм нәфел намазы белән мәшгуль.

Көндезләрен чатыр һәм балаганнар җанлана, цирк тәгәрмәчләре хәрәкәткә килә. «Восточная лира» граммофон җәмгыяте үзенең тамгалы тәлинкәләрен үтереп мактый. «Фо-ля-Бержер» бакчасында Кариевлар труппасы спектакль күрсәтә...

Арып-талып Казанга кайтып төшәләр. Мәкәрҗә «сәдакасы» алдагы көн өчен ярап торыр: Заһидулланың башлы-күзле булырга, гаилә корып җибәрергә дә исәбе юк түгел. Шиһаб Әхмәровлар гаиләсендә ул һаман да үз кеше. Җизнәсе тәрбиясендәге кечкенә Салих укытучысы Яруллинның һәм гаиләдәгеләрнең ышанычын артыгы белән аклады. Пианинода иркен, йөгерек уйный торган Салих Сәйдәшев хәзер инде рус музыканты Бормусовтан дәресләр ала.

Тукай Клячкин больницасына кергән көннәрдә Заһидулла солдат хезмәтенә карала. Төгәл сәбәпләре мәгълүм түгел, әмма шунысы хак: армия хезмәтенә яраксыз дип табалар аны һәм кулына «ак билет» тоттырып чыгаралар.

Вакыт Тукай гомеренең соңгы көннәрен саный...

«Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам»,— дип кыю шигарә ташлаган, әмма бар вөҗүде белән үз халкына бирелгән шагыйрьнең күңел кошы әле дөнья читлеген ташлап чыкмаган. Шәм кебек тып-тын гына сүнәчәк тә аннары кинәт якты кояш булып кабыначак Тукайның йөрәк мае сызып ята. Иң ышанычлы дуслары әдипне соңгы көннәрендә аеруча

игътибар белән уратып алалар. Хәл белергә килүчеләрнең берсе — Заһидулла Яруллин.

Әйдәгез, аларның очраушын хыялда җанландырып китик булмаса...

### *Авторның күзаллавы*

Тышта яз, март аеның соңгы көннәре. Челтәр калай белән бизәлгән түбә кыекларында — сөңгеләнеп килгән бозлар тезмәсе. Кояш кыйпылчыкларын үзенә йоткан якты, терекөмештәй тамчылар берәм-берәм җиргә сикерә. «Чулт... Чулт!» — иткән ягымлы авазлар дөньяның яшәүяшәрүгә таба барганын аңлатырга тырыша кебек. Нигәдер моңсу, бик моңсу... Кар челтәре астында күгәрчен сыярлык куышлар барлыкка килгән. Соңгы көннәрдә Заһидулланың күңелендә дә әнә шундый бушлык ясалып килә, аны ни белән тутырырга да белгән юк.

Больницаның авыр ишеге ят, шомлы аваз белән шыгырдап калды. Дежур хатын биргән ак халат эчендә Заһидулла үзен чит бер кеше хәлендәрәк тойды. Сырхаулык әсирлегендә яткан Тукай өчен мәшәкать булмасмы аның бу килүе?

Ишек шакып бертын басып торганнан соң Заһидулла эчкәре узды. Бүлмәдә бар да элеккечә иде: көн яктысын сыйдырган биек тәрәзә, дару шешәләре утыртылган кечерәк өстәл, кәгазь-каләм куелган биек тумбочка. Ак һәм ябык чырайлы Тукай, тәрәзә аша киләчәгенә баккандай, карават башындагы мендәрләренә сөялеп ята. Гәүдәсе кечерәеп калган. Заһидулланы күргәч тә аның йөзе яктырып, моңсу күзләре җанланып китте. Белмәссең, тыштан кергән шәпкәме, шулай тоелдымы — шагыйрьнең куллары кайнар һәм дымлы иде. Бүлмә хуҗасы, күз карашы белән ишарәләп, иптәшенә урын күрсәтте.

— Хәлең ничек, Габдулла-җан?

— Менә, күрәсеңдер, тәрәзәдән язга карыйм...

Сөйләшенеп куйган шикелле, икесе берьюлы тәрәзәгә текәлделәр. Бу хәл аларны күзгә-күз карашып утырудан коткарды, болай да яхшы аңлаешлы нәрсәләр турында сөйләшүгә караганда бераз эчтән уйланып алуың хәерлерәктер дә әле. Әнә бит күкнең каршыдагы йортлар түбәсенә таянган зәңгәр гөмбәзе, чиксез һәм билгесез дөньядан хәбәр ирештерергә теләгәндәй, җем-җем килеп тора. Шушы манзараны уртала бүлеп очкан ак күгәрчен, сискәндереп, аларны тагын бүлмәгә кайтарды. Тукай музыкант дустының Нәгыймә исемле кызга өйләнүен белә иде, иске дуслар буларак, турыдан-туры шул хакта сорыйсы итте:

— Нәгыймәң ничек, татулыкмы сездә?

— Безнең хәлләр шөкер генә... Менә син тизрәк савыксаң иде, дибез.

— Кичә тагын доктор карады. Ни актан, ни карадан сүз әйтми. Ә мин сорамыйм...— Аннары сүзен акрын гына икенчегә борды: — Заһидулла, беләсеңме, синең теге чаклардагы уйнаганың һаман да колак төбендәдер...

— Рәхмәт яхшы сүзеңә.

— Әхмәров әфәнделәрдәге баланы... әйе, Салихны өйрәтүеңне әйтәм... Музыкага пәрвәрлегең тагын шулай берәр балага йоксын иде...

Шулчак ак халатлы марҗа хатын кереп Тукайның пульсын тикшерде, кулындагы мамык белән маңгай тирләрен сөрткәләде. Аның, дару эчмисеңме, дигән соалена шагыйрь «соңрак теләр идем» дигәнрәк җавабын кайтарды.

Тукайның тавышы тоньк һәм хәлсез чыга иде. Ябык кул аркасы белән авызын каплап йөткергәләп тә ала. Менә шул чакта аның сабыйланып калган йөзенә гаҗизлек, газаплану билгеләре чыга. Ләкин Тукай каяндыр көч таба һәм юка ак күлмәк эченнән яктырып тагын әүвәлге хәленә кайта. Бәлки, мае бетеп яткан шәмнең сүнәр алдыннан «гөлт!» итеп талпынуыдыр бу?

Саубуллашыр алдыннан Тукай күңеленнән иң әрнеткеч сүзләрне сыгып чыгарды: «Язылмый калган шигырьләрем җан сорый...» Бу сүзләр Заһидулланы юл буе эзәрлекләп килде, күңелендәге уйларына убылып-убылып сагыш бәрелде.

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән кубәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

Йә, чынмы бу: шушы сүзләрне әйтә алган Тукай гомеренең соңына кереп бара. Табигать аны дөньяга бүләк итте. Табигать аны инде кире тартып алмак була. Бу югалтуны туктатырлык, яшәүнең мәгънәсе нидә икәнен аңлатырлык көч бармы? Тамчылар җыры, күкләрнең зәңгәрлеге, кояшның ут шарыдай дөрләп януы ни аңлата бу минутта? Колакта, язгы көн җамыннан чайпалып, моң яңгырый, моң! Берсенберсе этеп, Казан урамында сагыш болытлары актарыла...

* * *

1913 елның 2 апрелендә Тукай мәңгелекнең туфрагына күчте. Шагыйрьнең рәсемен кара каймалар белән биргән газеталар әле һаман да тетрәүдә. Үлгән артыннан йодрык янамыйлар. Хәтта Тукайның шигырь укларын үз җилкәсендә татыган татар буржуазиясе дә кемне, нинди шәхесне югалтуын көне-сәгате белән үк аңлап ала.

Халык бәгыренең зурлыгын, бөеклеген әйтеп бирү өчен сәнгатьтә кайчак бер әсәр дә җитә. Тукай вафатыннан соң андый әсәрне халык музыканты Заһидулла Яруллин иҗат итте. Шагыйрьнең кабер туфрагы да суынырга өлгермәгән бер вакытта язылган матәм музыкасы, елларны кичә торгач, «Тукай маршы»на әверелеп, халык күңелендә мәңгелеккә урын алды.

...Дәрья сулары кайный, тау-ташлар җимерелә, кояш-йолдызлары белән бөтен җиһан айкала. Һәрбер үлән, яфрак, агач елый. Үлгәннәр терелеп баса, исәннәрнең халәте рухиясенә дөнья гамьнәре актарылып керә. Мәңгелекнең башы кайда да чиге кайда? Кылган эшләрең дөньяның кай җирен булса да яктырттымы? Аяк астындагы туфрактан алып баш очындагы кояшлы, болытлы киңлекләр — бар да кешеләргә кала. Адәм баласы — көньяшәр күбәләк түгел. Ул тәне белән дә, рухы белән дә көчле, гайрәтле зат, үлем каршында ансат кына тезләнүне белми. Аның тормышында бөеклек сукмагы белән фаҗигале упкыннар һәрвакыт янәшә. Киләчәк каршына шулар аша узарга тиешсең. Үлем — яшәүнең, халык күңеленә күчә баруның башы гына. Үзеңдәге зурлыкның намен югары тот, кешем!

«Тукай маршы»ның моңнары әнә шулай дип иңри. Ләкин бу — елау түгел, ә бәлки фаҗига аша яшәүне зурлау, күкрәгеннән дәрт китмәс япь-яшь шагыйрьнең мәңгелек Тукай булып калырына ышану.

Яруллиннар гаиләсе бу вакытта Архангельск* урамында фатир алып яши. Ике катлы йортның баскычлары, кухнясы, Яңа ел алды мәшәкатьләре турында алда әйтеп киткән идек инде. Йорт хуҗасы — заманында урта хәлле сәүдәгәр, вакытлар узу белән бөлгән, ялгызы калган татар карчыгы.

Фәритнең әнисе булачак кеше — Гатаулла кызы Нәгыймә — Лаеш өязенең Хәерби авылында туа. Атлы, сыерлы, ару тормышлы Гатаулла балта эшенә дә оста булган. Гаиләдә күбесе — ир балалар. Биш-алты яшьләр тирәсендәге Нәгыймәне атасы ягыннан туган тиешле Әбрар

* Архангельск — хәзерге Һади Такташ урамы.

Бәхтиев дигән кеше Казанга, үзләренә кызлыкка алып китә. Сәүдәгәрләрнең дәртенә бирелгән бу кешенең баласы юк икән. Исәбе — кызны укыту, кеше итү, әдәп-хезмәткә өйрәтү. Ирләрнең бүреге уйлар, хатын-кызның яулыгы елар, дигәннәр бит. Кызның әнисе Фәридә тәтә күпме генә каршылык күрсәтмәсен — файдасыз. Сәүдәгәрнең яшь хатыны исә кызны үзенә карату өчен күп көч куя һәм теләгенә ирешә: төрле тәмтомга, шәһәр ялтыравыгына гаҗәпләнеп караган бала тиздән аларны «әти», «әни» дип йөртә башлый.

Авылга кунакка кайткач, кыз үзенең әнисенә «апа» дип кенә эндәшә. Андый чакларда Фәридә тәтә бик уңайсызлана, лапаска чыгып яулык почмагы чыланганчы яшертен генә ялгызы елый.

Нәгыймә укырга, исәп-хисап эшенә өйрәнә. Инде аңардан файда күрер чак якынаясын көткән хуҗа Суконныйда ике тәрәзәле будка салдыра. Оренбург юлыннан килгән тә җәяүле һәм атлыларны каршылаучы, бер үк вакытта күпер хезмәтен дә үтәүче таш капка. Нәгыймәнең язу-сызу һәм йомырка кабул итү бүлмәсе шуны узып кергәч тә уң кул якта. Тирә-яктагы авыл кешеләре олау белән килүләр, җыйган йомыркаларын Әбрар сәүдәгәр хәзинәсенә тапшыралар. Кәнсәдә утырган кара чәчле чибәр кыз шушы эшләрнең үзәгендә кайный.

Рус-япон сугышы патша Россиясенең халыкара хәлләрдәге булдыксызлыгын, җәмгыять төзелешенең түбән тәгәрәвен күрсәтте. Кайдадыр еракта, җәһәннәм читендә үк барган бу сугышның кыйпылчыклары Хәерби авылына да килеп тия! Гатаулла абзыйның ике улы шушы канлы бәрелештә — Порт-Артурда башын сала. Порт-Артур... Соңгы вакытларда бу исем телдән-телгә йөри, җыр булып җырлана. Бу җырны тыңлаганда Гатаулла абзый: «Ике улым да шунда калды, эх!..» — дип, йодрык белән өстәл төя-төя елый. Кемне сүккәнен дә аңлап бетермәстән, дөньяны ләгънәтли.

Гатаулла абзыйның Гарифулла исемле икенче бер улы — яшь мөгаллим, авыл мәдрәсәсендә шәкертләр укыта. Указы-ние юк югын, укучысының сәләтен яхшы белгәнгә күрә, мулла аны үзе билгеләп куйган.

— Нинди мөгаллим ул, миңа ат белән эшләр кеше кирәк! — дип әтисе каршы төшеп караса да, мулладан уза алмаган, күрәсең.

Хәерби — мәдрәсәле, укымышлы авыл. Бередәге өч-дүрт кеше газета-журналлар, шул исәптән, «Йолдыз» һәм «Эльислах» газеталарын алдыра. Көннәрнең берендә ни сәбәпледер «Эльислах» газетасы килүдән туктый. Дөньядан бихәбәр утыруны рәтле эшкә санамаганнар, күрәсең, өлкәнрәкләр яшь мөгаллимне Казанга газета идарәсенә җибәрәләр. Редакция бинасын эзләп таба Гарифулла, газеталар килүнең тукталуын әйтә. Кунакның гозерен тыңлаганнан соң өстәл артында утырган ачык йөзле, яшь, уйчан егет кәрҗиннән кирәкле саннарны табып бирә. Урамга чыккач, тәэсирен уртаклашасы килүдәнме, Гарифулла:

— Кара нинди яшь, матур егет эшли икән бередә! — дия-дия болдыр буендагы берәүгә үзенең соклануын әйтеп ташлый. Таныш түгел кеше, мыек астыннан елмаеп:

— Тукаегыз шул инде,— дип салкын гына җавап кайтара.

Ни өчен «Тукаебыз» түгел? Күрәсең, шагыйрьне бигүк өнәп бетермәгән, ләкин редакция тирәсендә чуалучы җилкуарларның берсе булган ул.

Сеңлесе Нәгыймә кияүгә чыккач, Гарифулла үзләре мохитендәге яңа кеше — Заһидулла җизнәсе белән бик тиз туганлашып китә. Берсе мөгаллим, икенчесе музыкант, ни әйтсәң дә, аңлашыр-сөйләшер сүзләре күп. Фәрит туганчы ук әле җизнәләре авылга парлап кайталар. Кунак күңелен күрәм, дигәннең үзенә дә ял итәргә форсат чыгып тора лабаса. Җигүле ат әзер, дилбегәсен как та, әйдә, элдер сәхрәгә! Урман буена җитәрәк, алпавытның умарта бакчасы ачылып китә. Чәчәк һәм

үлән диңгезенә чумылган тәпән-тәпән нәни йортлар кояш астында изрәп ята. Биләмәне дүрт яктан читән белән һәйбәтләп коршаганнар. Әйе, умарталыкның коймасы биек, сакчылары усал, узып барышлый хуш исләрен күбрәк иснәсәң генә инде... Гарифның тәкъдиме белән Мишә елгасының ял итәр өчен иң кулай җиренә тукталалар. Нәгыймә ухага дигән бәрәңгене, савыт-сабаны бушата башлый. Заһидулла күн капчыктагы гармунын иреккә чыгара. «Жизни, уйнамый тор, балыкларны куркытасың»,— дия-дия кайнише кармак сапларын сүтә. Мул сулы Мишәнең тугайланып килгән тын почмагына укмашалар. Көрәнсу-яшькелт су өстендә үзәннең чагылышыннны күрү — кызыклы да, сәер дә. Дөньяда үзенең барлыгын сиздерергә теләгәндәй, су уртасында балык сикереп ала. Ярлар текә, биек. Кемгә ни язган бит: яр читендәге үләннәрнең җепсел-җепсел тамырлары һавада асылынып калган. Әйтерсең, кемдер аларны яр читенә этеп китергән дә, менә-менә төртеп төшерәм, дип даими өсләрендә тора. Табигатьнең үзендә дә һәлакәт бар, бу үләннәр инде озак яшәмәс, яшәсә дә, нәсел калдыра алмас...

Казанга юлы төшсә, Гарифулла да җизнәсе һәм сеңлесенә керми китми. Соңгы вакытларда ике бүлмәнең икесендә тиң үзгәреш: берсендә — сиртмәле бишек, икенчесендә — капкачлы пианино. Сеңлесе кулында «музыка»ның елый торганы, җизнәсе кулында — җырлый торганы. Бала туганнан соң бу фатирда еш кына әнә шундый авазлар чиратлаша икән.

Зарланырлык түгел, Фәритнең дә тавышы әйбәт кенә чыга. Гаиләнең бөтен игътибары — аңарда. Юаталар, уйнаталар, тәрбия итәләр. Кояшлы, җылы көндә урамга алып чыгулар да еш эләгә аңа. Шулай бервакыт кечкенә Фәритне күтәргән Нәгыймәгә таныш хатыны очрый. Азмы-күпме сөйләшеп, хәл-әхвәл белешкәннән соң хатын баланы кулларына ала, сак кына кысып кочаклый, чүпрәк арасыннан күренеп торган ялангач тәпиләрен кат-кат үбә... Чит кешеләр дә шулай мөкиббән киткәнне, ана кеше үз баласын ничек яратмасын соң? Алга таба тормыш ни күрсәтер, хәзергә сабыйның бар белгәне — үсү, дөнья буйлап тәпи атларга өйрәнү...

Бу вакытта Россия империясе, шул исәптән, Казан шәһәре дә, үзенең тарихында киеренке көннәр кичерә.

1914 елның 1 августы. Дөнья базары өчен көрәшүче Германия белән Англия арасындагы каршылыклар гөлт итеп кабынып та китә. Капиталистлар зуррак калҗа эләктерергә, шул исәптән, үзләрендәге эшче сыйныфның революцион көрәшен һәм колонияләрдәге милли-азатлык хәрәкәтен бастырырга да исәп тоталар.

Тарихта беренче тапкыр химик корал, танк һәм самолетлар кулланылачак бу сугыш тиздән төрле кыйтгалардагы егерме сигез илне үзенең канлы чоңгылына суырып алачак...

Россия — төрле милләт халыкларын төягән гигант кораб — үзенең хәлиткеч көннәренә кереп бара.

## II. Революция чаң суга

Казан урамнарында солдатка китүчеләр кайный. Падишаһ хәзрәтләренә гадел хезмәт итәргә тиешле иң гаярь егетләр сугышка китә. Юл капчыкларында — ике көнлек ризык. Мондый тамашага күнекмәгән атларның рәте чуала, кемнеңдер җилкәсенә тартә башлары төртелә. Бала күтәргән хатыннарның ачыргаланып елавы, кычкырыш, сүгенү, кул болгаулар, йөрәктән савылган саубуллашу сүзләре. Вагон тәрәзәсе саен бүселеп чыккан ялангач башлар, гимнастеркалы җилкәләр төркеменнән кемнеңдер үзәк өзгеч җыры саркып чыга:

Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...

«Шәрык» клубы ябыла, аның гөрләп торган залы һәм сәхнәсе салкынаеп кала. Эшче һәм крестьян халкын әйтәсе дә юк, артистларның да күпчелеге фронтка алына.

Заһидулла Яруллин — саф музыкант, политик агымнарда катнашмый, берниндн партиядә дә тормый. Билгеле инде, күңеле белән ул — ярлы, изелгән халык ягында. Большевикларга теләктәшлек итә, аларның тормышны яхшыга таба үзгәртәсенә иман китерергә мөмкин.

Суконный бистәсе тулаем диярлек фронт тәртәсенә җигелә. Көн һәм сумала исләре аңкытып торган «Поляр» фабрикасы армия өчен итекләр тегә, вокзалда йөге-йөге белән төяп шулар малын көнбатышка озаталар. Шабанов фабрикасы да шырпы, кием-салым әзерләү, хәрби заказлар үтәүгә күчерелә. Хәрби заказлардан промышленникларның кесәсе калыная. Ит, сабын, керосин бәяләренең күтәрелә баруын күргән алпавытлар да тик ятмый. Революция алдыннан икмәкнең бәясе алты тапкырга арта. Зинин икмәк заводы янында бер төркем бала-чага. Икмәк исен иснәп карау да — алар өчен нәни бер бәхет, юаныч...

«Аваз» газетасы күп кенә заводларның ябылуы, эшсезлек һәм кыйммәтчелекнең арта баруы турында борчылып хәбәр итә.

Дары заводы гына түгел, ул көннәрдә Алафузов, Крестовников, Шабанов, Ярцев заводлары да чын мәгънәсендә дары мичкәсенә охшап кала. Стачка. Забастовка. Митинглар. Кыскасы, бикфорд шнурына ут капкан! Самодержавиенең тупас итеге өстән китереп басканда да сүнмәячәк ул, әчтән янып, барыбер алга үрләячәк...

Революция алдыннан Казан Идел буендагы иң зур шәһәр һәм административ үзәкләрдән санала. Монда унбиш милләт халкы яши, иң күбесе — рус һәм татарлар. Чиркәү гөмбәзе белән чиратлашкан мәчет манаралары шәһәргә хас күренеш. Бистәләрдә илле мең эшче исәпләнә. Артык киңәеп тормастан, тагын ике санга тукталыйк: 800 педагог һәм 700 генерал. Әйе, хәрбиләр белән мәгърифәт әһелләренең үлчәү тәлинкәсе тигезләшә язган. Гаҗәпмени: кайберәүләр уйлавынча, каләм тота белгән «черек интеллигенция»гә караганда бүгенге көндә Россиягә кылыч тота белгән гаскәриләр күп тапкыр кирәклерәк.

...Казанның мондый хәлне беренче күрүе: шәһәр йортлары өстендә, митинг һәм демонстрация сафларында кызыл әләмнәр җилферди. Кая карама, халык диңгезе. Кешеләргә кушылып, урамнар үзләре дә «Варшавянка» һәм «Марсельеза»ны җырлый кебек. Беләкләренә кызыл тасма бәйләгән солдатлар һәм җайдаклар, урам ташларына чакы-чокы басып, бер очтан икенчесенә чаба. Ни житте генә түгел, болар — революция сакчылары, генерал Сандецкийны кулга алган каһарман затлар. Халыкның сусап көткәнен бүген нибары ике сүз белән аңлатып була:

— Яшәсен революция!

— Яшәсен хөррият!

Казан большевикларының «Рабочий» газетасы революциянең икенче стадиягә керүе турында киң аңлату эшләре алып бара. «Корылтай» газетасы, төкерекләрен чәчә-чәчә, Советларны сүгә. «Керенка» акчалар хуҗка китте. Тормыш үзгәрде дә, үзгәрмәде дә кебек. Һәм менә аяз көнне яшен суккандай хәбәр: Петроградта революцион солдат һәм эшчеләр демонстрациясе канга батырылган! Ике властьлылык бетә, большевиклар — тагын подпольеда.

Гамьсезлек нәтиҗәсе булгандырмы, әллә контрреволюция агентлары кулымы — 14 август көнне Казанның Дары заводы станциясендә куәтле янгын күтәрелә. Сакчы хатын һәм берничә солдат кына вагоннан-вагонга сикергән утны туктата алмый. Дүрт көн буе котырган янгын нәтиҗәсендә ике дары базы, әрдәнәләп өелгән ящик-ящик снарядлар шартлый. Тәрәзәсе коелган йортлар эчендә меңнәр йоннары тузгый. Кешеләр, өлгергән кадәре мал-мөлкәтен күтәреп, Игумный урманына сыена. Рәсми документлар сөйләвенә ышансак, шартлау дулкыны икеөч чакрым радиустагы җайдакларны да ат өстеннән бәреп төшергән. Нефть запасы һәм торак йортлар янган. Һәлак булучылар арасында

өлкәннәр һәм балалар, яңгынчылар һәм солдатлар күп. Бу фаҗига шәһәрдәге азык-төлек һәм торак кризисын көчәйтүгә тагын бер җитди сәбәп була.

Революциянең икенче баскычын тәгәлләү өчен политик, социаль һәм идеологик шартлар тулысынча өлгереп җиткән иде. Тагын бер ыргым — һәм менә шул барын да хәл итәчәк! Петроград белән бер үк вакытта диярлек, Казанда 1917 елның 26 октябрендә кораллы восстание җиңә, власть эшче, крестьян һәм солдат депутатлары Советы кулына күчә. Яңа сайланган революцион комитет составына Камил Якубов, Мулланур Вахитов, Николай Ершов, Якуб Чанышев һәм башкалар кертелә.

Бу вакытта инде Фәритнең дүртенче яше тулып килә. Россия кебек зур бер илне тетрәткән әлеге вакыйгалар аның хәтеренә әллә ни йогып калмас, билгеле. Ләкин революциянең дәвамы булган икенче бер көрәш сулышы аның сабый күңелендә, томанлы гына булса да, билгеле бер эз калдыргандыр дип икеләнми әйтә алабыз.

Казанга аклар һәм чехлар якыная, дигән хәбәр Яруллиннар гаиләсенә дә килеп җитә. Нишләргә? Тормышлар зир-зәбәр килеп торганда шәһәрдә бала белән калу ышанычлымы соң? Әнә, кайберәүләр инде, беренчел кирәк-яракны әләктереп, Аракчинодагы дачаларына китеп бара. Хатынының авылы Казаннан утыз гына чакрым ич, нигә шунда кайтып сыенмаска ди?

Озак җыенып тормастан, гаилә белән Хәерби авылына кайтып төшәләр. Араларында чибәр йөзле, интеллигент кыяфәтле бер ир-егет тә бар. Телдән ишеткән истәлекләргә караганда, ул кеше композитор Солтан Габәши булырга тиеш. Кораллы, ят киемле чехлар Оренбург юлыннан Казанга таба агыла. Аларның бер отряды иртән, чыннан да, Хәерби аша уза. Кечкенә Фәритне күкрәгенә кыскан Нәгыймә елыйелый Гарифулла абыйсына ялвара:

— Зинһар, капканы ачма, абый! Керә генә күрмәсеннәр...

Кемнән курка бу өлкәннәр? Ни өчен әле шулкадәр коелып төшкәннәр дә, тәрәзәгә карарга да куркып, бер почмакка елышканнар?

Бәхетләренә күрә, аларның капкасына тегеләр ничектер кагылмый уза. Авылда зар елап, җир тырнап калучылар да юк түгел: кайсы кешеләрнең атларын, бушлай яисә сукыр бер тиенгә алмашып үзләре белән алып киткәннәр әнә.

Кичкә таба шәһәр ягыннан тонык гөрелте ишетелә башлый. Әллә туптан аталар, әллә яшен атлары дөберди — аңламассың...

Чехлар һәм аклар Казанны 1918 елның 6 августында кулга төшерә. Ул чакта шәһәрне саклау башлыгы булган большевик А. И. Селявкин истәлекләрендә: «Гомер буе исемдә калачак бу көнне шәһәр өстендә яшенле яңгыр актарылды. Күк күкрәгән тавышка артиллерия авазлары килеп кушылды. Урам буйлап болганчык сулар акты. Безгә фронттан гына түгел, тылдагы барлык чарлак һәм тәрәзәләрдән дә аттылар — Казанда контрреволюцион фетнә кузгалды»,— дип яза.

Әйе, әлегә кадәр посып яткан контрреволюция, ярыктан төшкән таракан шикелле, урамга саркып чыга. Бер-берсен котлау өчен өйдән өйгә, кварталдан-кварталга чабулый. Дошман снарядлары шәһәрнең күп кенә корылмаларын, коммуникация челтәрен җимерә. Урам тулы атылган гәүдәләр. Кешеләр шәһәрне саклаган эшчеләр һәм кызылгвардиячеләрнең гәүдәләрен җыеп алырга куркалар, чөнки андыйларны, кем икәнен дә сорап тормастан, шундук атып үтерәләр. Канга сусаган патрульләр, һәр шикле кешене туктатып, подпольедагы чекист, большевикларны аулый. Кремль һәм Пләтән төрмәләре тоткыннар белән тулы. Алар арасында Үзәк Мөселман комиссариаты председателе, Ленин фәрманы белән Казанны сакларга килгән Мулланур Вахитов та бар. Кремльнең ак стеналары шаһит: гомеренең соңгы минутларында да башын большевикларча горур, югары тотачак ул...

Завод һәм фабрикалар эшләми, трамвайлар йөрми, хезмәтчел Казан паралич суккандай туктап, зәгыйфьләнеп кала. Үзләрен шәһәрдә теләсә ни эшләргә хаклы дип санаган ак чехлар электр трамвайларын снаряд ташу эшенә җигәләр. Вагоннар ремонтлау бригадиры Г. Чумаков, андый трамвайларны рельстан чыгарып, линиядә тоткарлыклар оештыра. Бу эше өчен аны чак кына атып үтермиләр. Тормышның шиңеп калган иске тәртипләре террор һәм хакимият җирлегендә яңадан тураеп баса, чәчәк атарга җыена.

Ленинның мәгълүм сүзләрен хәтергә төшерик: «Хәзерге вакытта революциянең бөтен язмышы бер картага куелган: Казан — Урал — Самара фронтында чехословакларны бик тиз җиңәргә кирәк. Бөтен нәрсә шуңа бәйле». Әйе, үзенең яшәүчәнлеген һәм киләчәген раслар өчен революция Казанны кайтарып алырга тиеш иде.

Бер айдан соң диярлек, ягъни 10 сентябрьдә, шәһәр аклардан тулысынча азат ителә, меңнәрчә кешеләр төрмәдән чыгарыла.

Яруллиннар гаиләсе яңадан Казанга кайта. Диварлар снаряд һәм ядрә эзе белән чуарланган. Шөкер, йорт исән, тормышны яңа эздән алып китәргә мөмкин. Фәрит күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп дөньяга карый: бу тормышны аңлау кыен, шактый кыен әле. Кесәсенә гильзалар тутырып кайтканы өчен аны орышалар, урамда һәм өйдә ялгызын калдырмаска тырышалар. Көн арты көн уза, тәрәзәдән тын гына, сиздерми генә эңгер-меңгер саркылып керә. Кичен, гадәттә, әти-әни өйдә була, моңсу кичләр шомлы-тылсымлы әкият булып күңелгә үрмәли...

## *Авторның күзаллавы*

Кечкенә Фәрит, уйнап туйгач, урам эте һәм извозчик атларыннан сакланып кына өйләренә кайта.

Кич. Ярыйсы гына иркен бүлмәнең почмакларын ике керосин лампасы яктырта. Аларның берсе — мич буенда, икенчесе — чуклы ашъяулык ябылган өстәл өстендә моңсу гына көлемсерәп утыра. Әтисе, мич буендагы лампа яктысына елыша төшеп, үз шөгыленә күмелгән. Муен өстенә атландырып бәйләгән күн алъяпкычын тезләре өстенә җәеп салган да кырлы игәү белән ниндидер агач кисәген ышкылый. Шулкадәр бирелеп, җентекләп, кулындагы әйберләрне ут яктысына кат-кат куеп карый-карый эшли ул, мондый төгәллек сукыр энәгә җеп саплаганчакта гына кирәктер, мөгаен. Әмма аңлаган кешегә «алтын куллы» этисенең шөгыле энә саплаудан күп тапкыр четереклерәк: шалтырап торган буш, иске мандолина кабырчыгына җан өрмәкче була ул!

Кичә әтисе күршедәге Гыйльфан сәүдәгәрнең айгырыннан бер уч-лам кыл өзеп алган иде. Койрык кылы диләр икән аны, скрипка сызгычына тарттыру өчен шуңардан да кулае юк. Аларны әтисе юды, сөртте, иң тазаларын сайлап югартын киштәгә куйды. Киштәдәге әйберләргә этисенең рөхсәтеннән башка кагылырга ярамый. Ярый, шулай да булсын, ди. Тик менә ат кылы сызгыч кылларына әверелгәч, Фәритнең кулларына кайчан да бер эләгеп зеңләми калмас әле. Малайның сабыйларча өмете хәзергә шул тирәдәрәк йөзеп йөри.

— Улым, яле, өстәл янынарак утырыйк.

Моңысында ягымлы тавыш белән әнисе дәшә икән. Борынгы көйләрне җырлап җибәрсә, Фәритнең сулышы тамагына килеп бөялә, күзләреннән яшь тәгәрәп чыгардай була. «Тәфтиләү» дигәнен тыңлаганда бигрәк тә шулай...

Әнисенең дә үз киштәсе бар. Анысына да рөхсәттән башка кагылырга ярамый. Биредә тарак, көзге, чүлпы, хәситә шикелле рәк хатын-кыз әйберләре, ә бер читтәрәк тышлары искерә төшкән эреле-ваклы китаплар, каты тышлы калын альбом. Фәрит өчен хикмәтләрнең иң зурысы әнә шунда, дөресрәге, таякны әлиф дип танытa башлаган китаплар эчендә ята иде.

Әнисе кош баласы тоткандай итеп, сак кына тота китапны. Бармак битләре белән җиңелчә орынып кына үзенә кирәкле битләрне эзли. Менә шул чакта Фәритнең каршында гаҗәеп серле капка ачыла: гарәп хәрефләре белән язылган сүзләр, тигез-тигез сукмаклар, бормалы бизәкләр... Монысы кая илтә дә, тегесе кая барып чыга икән? Юк, сукмак кына түгел, бер-беренә таянып үскән чытырманлык, ерып чыккысыз карурман бу! Капкасы ачыла ачылуын, тик менә атлап керер юлы кая соң аның? Кай җиреннән тотынырга белми аптырый Фәрит, берничә хәрефне генә укый да килеп төртелә. Их, шартлатып укый белсәң иде шуларны — дөньяда синнән дә акыллы, синнән дә көчлерәк кеше булмас иде! Берни эшләр чара юк, хәзергә өлкәннәр укыганны колак торгызып тыңларга гына кала.

Әнисенең бармаклары арасында китап битләре кыштырдый. Китап түгел, ә бәлки кәкре-бөкре, сыгылмалы-төрткеле рәвештә тезелгән хәрефләрнең шулай үзара сөйләшүедер ул? Тавышын көйләү өчен әнисе йомшак кына тамак кырып куя, йорт башының рөхсәтен алырга теләгәндәй, әти кеше ягына карап ала.

— Укып җибәр, әнисе. Тукайны тыңлап үскән бала игелекле булыр. Олыга да, кечегә дә ярый аның язганнары. Кулым эшләсә дә, колагым ишетә минем...

Шулай ди дә, мандолина сәдәфләренең ныклыгын тикшергәндәй итә әтисе. Кечкенә Фәрит Тукайны китаплар яза торган юмарт бер абый дип күз алдына китерә. Әтисенең Тукай белән якыннан танышлыгы, шагыйрь абыйның музыка яратканлыгы турында ул чакта кайдан беләсең ди. Әтисе боларны соңрак, үсә төшкәч сөйләр аңа. Ә хәзергә Фәритнең бөтен игътибары әнисенә юнәлгән: ниләр укыр икән ул, янәсе...

Әни кеше ак яулыгын маңгай турыннан артка кайтарып бәйләгән. Яулык астыннан чыгып торган бер тотам чәче һәм балан зурлыгындагы кып-кызыл алкалары аңа гаҗәеп бер матурлык өсти. Өйдә беразга тынлык урнаша — әнисенең бер ноктага тупланып укый башларга әзерләнүе.

Әнисе укый башлауга, Фәрит тәмам онытыла, барлык хыял-кичерешләре белән әкият ихтыярына бирелә. Ул урманның матурлыклары! Җир җиләге, күбәләкләр, гөлләр-гонҗәләр дисеңме — һәммәсе берьюлы хыялны биләп ала. Рәхәт менә шушы тылсымлы, йомшак, ягымлы дулкында тирбәлү. Әнисенең тавышымы соң бу, әллә Фәрит чыннан да Кырлай урманнары уртасына килеп эләктеме? Айлы кич. Әнә батыр егет урманга утынга китте..., Чү, рәхәт кенә түгел, куркыныч та икән әле әкият тыңлау:

Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!
Борыны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел, куллар-аяклар да — ботак-тармак кеби.

Әнә нинди икән ул шүрәле! Җилче икәү уйныйк бераз кети-кети, дигән булып кешеләрне куркыта, хәлдән тайганчы кытыклый. Ярый әле Былтыр атлы егет батыр булып чыкты — шүрәленең бармагын бүрәнә ярыгына хәйлә белән «һоп» итеп кенә каптырды да куйды!

Әнисе укып бетерә дә ни өчендер сүзсез генә елмая.

— Әни, шүрәле чынлап та бармы ул?

— Бардыр, улым, юкса китап тикле китапка язмаслар иде. Шулай бит, әтисе!

— Әкият сөйләр һәм укыр өчен матур ул, Тукай абыең шуны истә тотып язган.— Әтисе улын үз янына чакырып ала: — Кил әле бире. Күрәсеңме, менә бу кыллар үзе бер әкият. Ә уйнау һәм тыңлау нинди күңелле!

Әтисе Фәриткә дигән мандолинаны көйләп тә бетергән икән. Яле, карап карыйк дигәндәй, башын хикмәтле генә селкеп алды ди нәни яфрак чаклы пластинка белән кылларга чиртә башлады. Зең... зең...

трил... лил... Әтисенең бармаклары озынаеп килгән кара сап буйлап йөренә, уң кулы исә кыллар өстендә каз канатыдай леперди. «Каз канаты» көе... Көйгә кушылып, лампа ялкыны да пыяла кувык эчендә сизелер-сизелмәс кенә бии шикелле — әйтерсең, өйдә канат җиле агыла. Я хода, гап-гади кылларда шулкадәр дә илаһи, сагышлы моңнар булыр икән!

Бу кич Фәриткә мандолина чиртеп карау бәхете бүләк итте.

* * *

Ил өстендә — оран, чакыру авазы. Утлы чолганыш эчендә калган яшь республика, шуңа җавап итеп, Колчак, Деникин, Врангель походларына каршы кызыл тасмалы күкрәген куя. Минзәлә, Бөгелмә, Чистай, Алабуганы басып алган Колчак башкисәрләре Казан бусагасына якыная. Шушы хәвефле көннәрдә, Ленин кушуы буенча, татар бригадалары оеша башлый. Милли музыкадан башка аларның адымнары дәртле, рухлары күтәренке булырмы? Юк, әлбәттә. Менә шуңа күрә Казан революцион-хәрби коллегиясе карамагындагы культура бүлеге сәнгать кешеләрен бер тирәгә туплый. Әйтик, Заһидулла Яруллинның шәкерте, инде хәзер танылган композитор Салих Сәйдәшев баштарак комклубта (хәзерге Офицерлар йорты) кыллы оркестр оештыра. Аннары үзе теләп Кызыл Армия сафларына китә.

Казанда яңа оешкан хәрби бригадаларга шефлык концертлары кирәк. Музалар — азатлык яклы, халыкчан музыка революциягә хезмәт күрсәтә. Андый концертларга этисе кайчак Фәритне дә алып йөргәли. Келтер-келтер килеп, мостовой ташлары өстеннән извозчик аты чаба. Ярымачык арбада биш-алты яшьлек малай, этисе, тагын берничә музыкант. Күн капчык эчендә — гармун, скрипка әрҗәсендә ни икәнлеге дә аңлашыла. Шәһәр читендәге хәрби частьнең клубына килеп туктыйлар. Якын көннәрдә Колчакка каршы сугышка китәчәк татар бригадасы икән бу. Зал тулы кызыл гаскәриләр. Гимнастерка-каештан, кулларында винтовка. Буденовкалары саен, чәчәктәй балкып, кызыл йолдыз яна. «Солдат» дигән сүздән ничектер курку калган, ә болар бөтенләй башка — ягымлы, мәрхәмәтле.

Фәрит андый концертларны солдат абыйларының тез башында, ә бәлки сәхнә эчендә килеш карагандыр, мәсьәлә анда түгел. Мөһиме шул: ул этисенең һәм музыкант абыйларының уйнавын бирелеп тыңлый, халык моңнарын ишетә. Әтисе артка таралган чәчләрен кулы белән сыпырып ала да пианино каршына килеп утыра. Ике музыкант скрипка һәм мандолина белән «Кара урман» көенә кушыла... Сагышлы-шомлы итеп карурман шаулый, анда бүреләр, юлбасарлар бар. Акларның отряды да шунда посып ятадыр кебек. Әмма нигә куркып торырга, кызылгвардияче абыйлар янәшәдә генә ич...

Көй тәмам. Залдагылар тамашаны дәррәү алкышлый, «афәрин!» дип кычкыра, этисе иптәшләренә кушылып баш ия, шул хәлендә чигенә-чигенә гармунына таба бара, кулына тальян ала.

Дәртле маршны бию көйләре алыштыра. Концерт беткәч, сугышчылар тагын бер кат озаклап кул чабалар. Әтисенең гармунда, мандолина һәм пианинода да бердәй осталык белән уйный алуына соклана малай, горурлык хисләре кичерә. Музыка тыңлаганнан соң әнә ничек дәртләнә, канатлана халык! Малайның күңелендә яшерен һәм якты хыял тамырлана: үскәч, һичшиксез, музыкант булырга...

Кайтканда ат тоякларының чыкылдавы, арба тәгәрмәчләренең күңелле келтерәве матур бер көй булып ишетелсә, гаҗәпмени?

Ниһаять, 1919 елның июнендә Татарстан төбәкләре Колчак гаскәрләреннән тулысынча азат ителә.

Авылларда — яңа тормыш сулышы...

Шәһәрдә — үзгәрешләр, инкыйлаб җиле...

Әтисе Фәритне еш кына Ботан бакчасына алып керә.

Биш-алты яшьлек бала өчен кечерәк бер урман булып тоелгандыр ул. Ботан бакчасы — шәһәр халкының, яшьләрнең аеруча яраткан урыны. Кичләрен монда буш эскәмия таба алмыйсың. Уртадагы мәйданчыкта җыр, уен-көлке, яңгырый, гармун ярышлары ишетелә. Халыкның шуңа багышланган махсус җыры да бар:

> Яңа Бистәнең кызлары
> Калфак эшләп акча ала.
> Җәйгә чыксаң, шулар була
> Ботанский бакчада.

Эскәмияләр рәтен узып эчкәре кергән саен һава сафлана, җиләслек арта. Чөнки каршында сине Кабан күле манзарасы көтеп тора. Анда кайчак кечкенә пароходларның узганы күренеп кала. Күлнең теге ягында — соры биналар, инде эшчеләрнең үз кулына күчкән, алар җырын җырлый торган завод морҗалары. Күл буена килгән саен Фәрит су төбеннән учлам-учлам бәреп чыккан камышларга исе китеп карый. Кабан күленә еш барачак, аңа карап күп тапкырлар соклану хисе кичерәчәк әле ул. Ял көннәрендә, гадәттә, Яңа Бистә һәм Суконный халкы кызыл әләм җилфердәтеп, көймәләргә төялеп пикникка чыгарга яраткан. Су өстендә тагын җыр, уен-көлке, гармун авазлары. Фәрит менә шуларны тамаша кылып, кечкенәдән халык моңнарына сыенып үсә.

Кайда халык — шунда тормышның аңлашылып бетми торган серләре, билгесезлек пәрдәсе белән өртелгән сәер күренешләре. Бер вакыйга Фәритнең күңелендә аеруча нык, тирән уелып калачак. Кара каймалы табутта кемнеңдер гәүдәсен күтәреп баручы кайгылы төркем салмак адымнар белән мәйданга килеп керә. Төркем алдыннан рәт-рәт тезелгән гаскәрләр дә бара икән. Алар үзләре башкарган матәм маршына тәмам йотылганнар: барабан дөбердәве, тәлинкәләр чыңы, торбалар авазы... Казанның таш йортларын, таш урамнарын тетрәткән бу музыка күкләргә кадәр агыла да сагыш пәрдәсе булып тагын җиргә сарыла. Шәһәр айкала, үзенең кайгылы кешеләре белән бергә елый, ыңгыраша шикелле. Дәшми генә атлаган олпат ирләрнең йөзендә кырыслык, ачыну билгеләре, кара шәл ябынган хатыннар исә елый-елый шешенеп, хәлсезләнеп беткәннәр. Фәрит әтисенә ныграк елыша, кулын ычкындырмаска тырышып, һаман алга карый.

— Әти, апалар нигә елыйлар?

— Алар иң кадерле кешесен югалтканнар...

Кеше нигә үләргә тиеш? Үлгәннән соң яңадан тормышка әйләнеп кайтамы ул? Шулай кадерле булгач, аны саклап калу мөмкин түгел идемикәнни? Мең авазлы тормышны аңларга тырышуның беренче дулкыны, композитор дигән шәхеснең яралуы, бәлки, нәкъ менә шушы минутларга туры киләдер? Әйтү кыен. Үзенең серләрен алай бик тиз чишәргә ашыкмаучы табигать моны үзе генә беләдер...

1921 елның җәендә Идел буен ачлык каплап ала.

Акча, икмәк, рәтле-башлы кием табарга кирәк. Ачлык Яруллиннар гаиләсенең ишеген дә шакый. Өлкәннәр белән бергә, җиде яшьлек Фәрит тә ачлыкның ачы җимешләрен татый. Дөнья белән танышудан, уйнау һәм ашаудан бүтәнне белмәгән бала өчен бу кечкенә нәрсә түгел. Фәритнең үсә төшкәч тә үз эченә бикләнгәнлеге, моңсулыгы, вакыт-вакыт боеклыкка бирелүе нәрсәдән килә соң? Болар — булачак композиторның шәхесен, иҗат үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итәчәк сораулар. Алга таба без аларга тирәнрәк тә тукталырбыз әле. Ә хәзергә шуны хәтергә салыйк: егерме беренче ел вакыйгалары аның табигатенә, холык-фигыленә күпмедер йогынты ясамый калмаган. Тамагы туймаган баланың ихластан уйнап-көлеп йөргәнен кемнең күргәне бар әле? Ләкин

шунысы яхшы: тормыш үлчәү тәлинкәсенең икенче ягына табигый сәләт, күңел күтәренкелеге, зур максатларга омтылып яшәү кебек сыйфатларны да мул салган икән. Үз-үзен җиңә алырлык көчне дә кызганмаган. Гомеренең алдагы елларында әнә шушы сыйфатлары өскә калкып чыгачак аның.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының «Кустарь һәм вак промышленностьлар турында»гы 1921 ел, 7 июль карары ил тормышында яңа сәхифә ачып җибәрә.

Казан кала Советына да остаханәләр, кибетләр, ресторан һәм кунакханә ачарга теләүче гражданнардан күплэп гаризалар керә башлый. Канында сәүдәгәр комарлыгы суынып та җитмәгәннәр өчен бу инде күктән төшкән бәхет. Иске һәм яңа кибетләрнең ишеге төбенә кадәр ачыла, базар җанлана, кыйммәт булса да киштәләрдә чәй-шикәр, икмәк күренә башлый. Революциянең эчке һәм тышкы дошманнары яшерен генә тантана итә: әһә, иске тәртипләрдән башка яши алмыйсызмы, янәсе. Нэпманнар бер яктан үзләре баеса, икенче яктан алар халыкның матди ихтыяҗын канәгатьләндерүгә сизелерлек өлеш кертәләр. Шул заман өчен кирәкле булган бу яңа экономик политиканы «артка чигенү» дип бәяләүчеләр нык ялгыша. Тиздән, бик тиздән илнең экономикасы ныклы рәвештә социалистик рельсларга күчереләчәк...

Заһидулла Яруллинның әби-бабалары яшәгән нигез — Кече Сөн дигән авыл да бар бит әле дөньяда. Шушында туып-үскән, унике яшеннән үк озын-озак сәфәргә чыгып киткән Заһидулла, әлбәттә, туган ягына тартыла. Ак пароход. Яр буйлары. Берсут пристане. Аннары да әле урман-кырлар аша егерме чакрым кайтасы бар. Авылның сабан туйлары, табигате, кешеләре — яшь күңелне калыплаштыру, гүзәллеккә өйрәнү өчен бәяләп бетергесез чыганак. Киләчәктә сәнгатьнең музыка кебек катлаулы өлкәсенә аяк басачак кеше өчен бу бигрәк тә шулай. Фәрит шәһәрдә туды, ләкин авыл табигате белән беркайчан да арасы өзелми аның...

## *Авторның күзаллавы*

Шәйхулла белән Фәрхетдин киндер капчыкларын асып килеп тә җиткәннәр. Шәйхулласы кыска кара ыштан, утыртма якалы зәңгәр күлмәк кигән. Фәрхетдиннең өстендә дә шул ук киемнәр, ләкин аныклар яңарак, күлмәк җиңендәге сәдәфләренә хәтле ялтырап тора. Өстәвенә, ул каюлы бәрхет кәләпүш тә киеп җибәргән. Гаҗәпмени, әтисе тирә-якта атаклы тегүче икән аның. Авылда малайга такмак та чыгарып өлгергәннәр:

> Энекәем Фәрхетдин,
> Түбәтәең бәрхеттин.

Фәритләрдән берничә яшькә олырак Фәрхетдиннең исе дә китми, елмаеп тик тора. Бүген алар кунак малай белән урманга чикләвеккә менәргә сөйләштеләр. Өчәү бергә җыйналуларының сәбәбе дә шул.

Урман аларны кочак җәеп каршылады. арба эзе төшкән чирәмле юлдан эчкәре әйдәкләде, юл буендагы биек үләннәре белән муеннардан кытыклап калды. Эчкәре кергән саен уймак-уймак аланнар, бөдрә куаклыклар, стенадай баскан агачлар тезмәсе. Менә нинди икән ул чикләвек! Ботак очлары саен учлам-учлам кишәнкеләр эленгән. Үрелдеңме, капчыгыңа сикерергә генә тора. Биектәгеләрен ыргаклы таяк белән аска сыгып төшердеңме, алары да үзеннән-үзе синеке инде.

Фәрит олы бер кишәнкене кат-кат тотып карады. учларында сикертте. Санап караса, берүзендә — тугыз чикләвек! Йомры күзләрен шар ачып, тәмам берегеп үскәннәр. Менә болары — чуклы-чуклы керфекләр

Чикләвек төнлә керфекләрен йома микән? Шул хакта сорагач, Фәрхетдин чатнатып җавап бирде:

— Керфекләрен йомса, тиен урлап китә аны, бик беләсегез килсә.

Тапкыр сүздән рәхәтләнеп көлештеләр. Фәрхетдин гел шулай: теле-телгә йокмый, дөрес булса — йоклаганда да сөйләшә ди ул. Фәритнең беразга ялгыз каласы, урмандагы бихисап авазларны тыңлый-тыңлый рәхәтлек кичерәсе килә. Аның уйлавынча, малайлар шушы куаклык тирәсеннән ерак китмәскә тиеш. Аннары бер көн әбисе, сандугачның оялары да менә шулай язулы була, дип Коръән китабындагы сүзләрне күрсәткән иде. Бәлки, сандугач оясын да эзләп табар әле ул, андагы серле хәрефләрне иҗекләп укырга тырышыр.

Малай каршында мөлдерәмә тулы моң дәрьясы тирбәлә иде.

Сандугачның язулы ояларын очратмады Фәрит, аның каравы менә нинди хикмәткә тап булды ул. Самавыр юанлыгындагы бер каенны әллә давыл, әллә яшен төптән үк аударып салган. Түбендәге озынлыкыскалы чырымталары күккә таба тырпаеп тора. Алар коры, шалтырап кипкән, кулың белән орындыңмы, мандолина кылыдай зеңләргә генә тора. Вәт могҗиза: урманның да үз «мандолинасы» бар икән ләбаса! Нечкә чырымтаны чиртсәң, нечкә аваз чыга, калыны — калын тавыш белән җавап кайтара.

Кинәнде генә Фәрит урман мандолинасында уйнап! Үзе дә белеп бетермәгән өр-яңа көйләрне чиртте. Күбәләкләр гел аның тирәсендә бөтерелде шикелле. Димәк, көй начар чыкмаган...

— Ау-у-у!!!

Шәйхулла белән Фәрхетдин аның югалуын сизделәр, ахры, әнә бит ничек итеп борчулы аваз салалар. Фәрит җилкәсенә аскан капчыгын янбашына таба шудырды да иптәшләре ягына элдерде. Элдерде дип әйтү генә ансат: чынлыкта исә шүрәле бармагыдай кәкре ботаклар күлмәктән янсә ыштан балагыннан эләктерә дә җибәрмәскә маташа. Кайсылары муенга ук үрелә башлады, исәпләре — кытыклап карау микәнни? Тукта, әгәр бу чынлап та шүрәленең үзе булып чыкса? «Әйдәле, тәти егет, кети-кети уйныйкчы бер»,— дип күлмәк чабуыңнан тарта башласа, җыйган чикләвегеңне биреп тә котыла алмассың!.. Нишләргә? Иң яхшысы — йөгерү, оят булса да тизрәк Фәрхетдиннәр янына барып каплану...

Әнә шул йөгерү, кабалану харап итте дә инде Фәритне! Нииндидер черек төпкә абынды да гөрселдәп үлән арасына егылды ул. Бернигә тапкыр мәтәлчек тә атып алды. Ә иң хәтәре менә нәрсә: сыңар мөгезле шүрәле инде тәмам якын килеп җиткән, янәп, озын-озын бармакларын селкеткәләп баш очында тулгана...

Сикереп торды Фәрит, кычкырып елый-елый тагын алга ташланды. Берни аңламаган ике дус, кунак малайны шундый хәлдә күргәч, куркышып калдылар.

— Ни булды, елан чактымы әллә?

— Шүрәле... шүрәле күрдем...

Фәрхетдин инде сабакка йөргән, өченче сыйныфны бетергән малай иде. Фәритнең бу сүзләрен ишетүгә, кулы белән эчен тотып сыгыла-сыгыла көлә башлады.

— Их син, камырсыз пәрәмәч! Урманда шүрәле була димени. Әкиятләрдә генә язалар аны.

— Ипидер, күрдем...

— Яле, күрсәт шүрәлеңне.

Барып карасалар, Фәрит абынып егылган урында, корыган ботаклары белән күкне ермачлап, нибары карт шомырт агачы басып тора. Курыкканга — куш дигәндәй, шуның ботаклары шүрәле бармагы булып күренгән ләбаса...

* * *

Ниһаять, Фәритнең мәктәпкә барыр чагы җитә. Аркасыннан сөеп әнисе, әллә әтисе озатты микән аны, һәрхәлдә, балачакның иң тәэсирле минутлары бу. Класс тулы әлегә таныш түгел малайлар, кызлар. Кара такта буйлап акбур кыштырдый. Нинди горурлык: кешенең үз дәфтәре, үз каләме бар! Дәфтәрнең ап-ак битенә «таяклар» тезәсең, өсләренә «дулкын» йөгертәсең — әлиф дигән мәгънә килә дә чыга. Нота дәфтәрендәге табагачсыман билгеләрне күреп үскән Фәрит акрынлап гарәп имласына үтеп керә, укырга-язарга өйрәнә.

Кыш уртасыннан мәктәптә көнгә бер тапкыр бушлай ашату кертелә. Укучы балалар өчен монысы инде могҗиза белән бер. Шырпы кабы зурлыгындагы бер телем икмәк, ботка булмаган көннәрдә кәбестә яисә шалкан шулпасы. Каян килгән ярдәм соң бу? Совет хөкүмәтенең балаларга — илнең иң яшь гражданнарына бүлеп биргән ярдәме. Киләчәктә алар арасыннан кемнәр генә чыкмас әле. Юл салырлар, йорт төзерләр, тарихта тиңе булмаган ачышларны да ясарлар. Шик юк: кайда эшләсәләр дә, илнең арка таянычы, ныклы терәге булырлар. Әнә, алар арасында беренче татар милли балетына нигез салачак кеше — оялчан, тузгак чәчле, кеп-кечкенә Фәрит Яруллин да бар...

Һәрбер дәрес — ачыш, могҗиза, яңа дөньяга сәяхәт. Күбрәк белгән саен тирә-юнь тагын да серлерәк, кызыклырак тоела башлый. Фәритнең мәктәптә укыган көннәрен бары шулай күзалларга мөмкин.

Әтисе белән әнисе арасындагы мөнәсәбәтләрдә казыну әдәп кагыйдәләренә туры килеп бетмәс. Мәшәкатьле дөнья бит, төрлесе булгандыр. Ләкин бер вакыйганы күздән кичерми дә ярамас. Яруллиннар гаиләсендәге серле, аңлатуга ансат кына бирелми торган хәлләрнең берсе бу.

Җәйге эссе көн. Казанда яшәүче Нәгыймә бакча артлап кына Хәербигә — Гарифулла абыйсының болдырына кайтып егыла. Җәяү кайткан булса кирәк, өсте-башы, аяклары тәмам тузанга баткан. Сөйләшерлеге калмаган — тотлыга, калтырый, тузгыган чәчләрен селки-селки елый гына бит сеңлесе.

— Туктачы, ни булды? Сөйлә рәтләп...

— Фәрит юк... Фәритем юк...

Җаваплый торгач аңлашыла: Нәгыймә ниндидер йомыш белән Ослан ягындагы ахирәтенә бер кичкә кунакка барган икән, әйләнеп кайтса — ире дә, баласы да өйдә юк, суга төшкәндәй каядыр китеп югалганнар.

Гарифулла абыйсы баштарак аптырап кала, аннары кичекмәстән Казанга юл тота.

Хәерби тирәсендәге җирләр революциягә кадәр алпавыт кулында була. Аның ташлап качкан җирләре хәзер халыкныкы. Авылның үз көче генә җитмәгәндер, күрәсең, каладан булышырга килүчеләр дә көнозын шушында кайнаша. Лобогрейка белән ашлык чаптыралар, молотилкалар гөрелди, куларбалар хәрәкәтләнә. Ирләр кулында өчәр сөңгесен тырпайткан таза агач сәнәкләр уйный. Алар арасында аркылы каеш буган, биленә наган таккан яшь комиссар Якуб Чанышев та бар. Бу кеше белән ныклы гына дуслык тотканга күрә, Казанда Гарифулла туп-туры шуның бүлмәсенә барып керә һәм Заһидулла җизнәсенең Уфага китеп барганлыгын ачыклый...

## III. Уфа сәхифәләре

1923 елның кояшлы, якты җәе.

Суны күбекләндереп, тәгәрмәч калакларын салмак шапылдатып, Уфа пристанена Казаннан пароход килеп туктый. Кояшта уңып беткән

иске дебаркадерга басма ташлаганнан соң, пассажирлар арасында ыгы-зыгы, шау-шу куба. Җилкәдәге йөкләрен уңга-сулга айкандырып, берсен-берсе этә-төртә һәркем тизрәк ярга ашыга. Улы Фәритне җитәкләп мондый бимаза уртасына ташланудан мөрәүвәт юк, сабыр холыклы Заһидулла басманың бушый төшкәнен көтә. Аннары гына ярга аяк басалар. Төрлечә таралып яткан бүрәнәләрне һәм бер читтәге лабазлар рәтен исәпкә алмаганда, пристань тирәсе ялангач диярлек.

Уфа — мөселман халыклар тормышында электән үк мәгълүм роль уйнаган культура үзәге. Буын арты буын килә тора. Татар укымышларының да күп кенә вәкилләре шушында яши һәм эшли, яңа тормыш коруда катнаша. Матди җәһәттән генә түгел, рухи-мәдәни яктан да Уфаның күтәрелгән чагы, аның бүгенге тормышы өчен музыкантлар да бик кирәк. Сер сыярдай дуслары, таныш-белешләре күп, каланың клубларын, урам һәм бакчасындагы һәр баганасын дигәндәй яхшы белә — Заһидулла Яруллинны Уфага тартып китергән сәбәпләрнең тагын берсе әнә шул булса кирәк.

Озак та үтми, Фәритнең әнисе дә Уфага күчеп килә. Алар Никольский (хәзерге Мәҗит Гафури) урамындагы ике катлы агач йортның өске катында яши башлыйлар. Гаилә тормышы яңа шәһәр җирлегендә тамырланып китә. Әнисе, нигездә, йорт эшләре һәм тегү-чигү белән шөгыльләнә. Музыкант Заһидулланың мал-туары, эшкәртер җире, атысабаны юк, ә тамакны туйдырырга кирәк. Билгеле инде, ул табигать биргән сәләтен эшкә җигә: «Мираж» кинотеатрында, ресторанда һәм җәйге бакчада уйный, кечерәк оркестрлар оештыра.

Фәриткә укуын дәвам итәргә, киләчәгенең нигез ташларын кору өчен ныклы белем алырга кирәк.

Бәхетенә күрә, мәктәпнең якындагысы һәм заман таләпләренә җавап бирердәй алдынгысы туры килә аңа. Лазарет һәм Кече Казан урамнары кисешкән чатта кызыл кирпечтән салынган ике катлы күркәм бина балкып тора. Алгы якта гына да илле биш тәрәзә, шуларның җидесе — парадный ишек өстендәгеләре — билгесез осталар кулы белән көймәләп, бизәкләп эшләнгән. Алардан да өстәрәк — бинаның кыл уртасына тулган ай сыман түгәрәк тәрәзә дә уелган. Эчкәре узасың да бередәге иркенлеккә таң каласың. Түшәмнәр биек, коридорлар киң, икенче катка менгерүче баскычлар да таза, саллы, ипле күренә. Класс эченә һәм парталарга тәрәзәләрдән мул булып көн яктысы төшә. Урталыкта — зур зал, хәзергечә әйтсәк — актлар залы. Сәхнәсендә рояль дигән беркадәр ятрак, сирәк очрый торган уен коралы да бар.

«Агамалы Гали углы» исеме кушылган мәктәп менә шушы була инде. Рәсми кәгазьләрдә ул дүртенче номерлы икенче баскыч татарбашкорт хезмәт мәктәбе дип йөртелә. Мәктәпнең оешу тарихына күз салыйк, чөнки беренче карашка гадәти генә тоелган бу сәхифәдә революция китереп чыгарган үзгәртеп корулар, заман сулышы аермачык ярылып ята.

1917 елда, февраль революциясеннән соң, Уфада программасы рус гимназияләрендәгечә булган татар гимназиясе ачыла. Бу эшнең башында яңалыкка сусаган, мәгърифәт һәм культурага омтылган, яшь буынга урта белем бирергә теләүче алдынгы карашлы татар укытучылары тора. Совет власте ныклап урнашканнан соң, шул гимназия җирлегендә, әлеге дүртенче татар-башкорт мәктәбе оеша. Шушы ике катлы йорт, белем учагы буларак, Уфадагы татар һәм башкорт балаларын, өлешчә күрше кантоннардан килеп укучыларны да үзенә сыендыра. Алга китеп булса да әйтик, илгә күп кадрлар бирә бу мәктәп, арадан күренекле җитәкчеләр, фән һәм сәнгать эшлеклеләре дә чыга. Вузга керерлек кешеләр әзерли алгач, әлеге мәктәпнең дәрәҗәсен, заманына күрә анда әзерлекле педагоглар эшләвен чамалау кыен түгел.

Гражданнар сугышыннан соң мәгърифәт эшен җайга салу, торак ягын көйләү шулкадәр читен хәл итела ки, яңа ачылган мәктәп бер ел

эчендә генә дә унике тапкыр бинасын алыштырырга мәҗбүр була. Монысы инде соңгы тукталыш: ике катлы кирпеч йортка бөтенләйгә төпләнгәч кенә, ниһаять, күчеп йөрүләргә чик куела. «Лазарет урамы» дип шушы бинага бәйле рәвештә әйтелгән. Әле кайчан гына бирелә лазарет тормышы кайнагандыр. Ак бинтка чорналган яралы кызылармеецлар, кояшка арка куеп, сугыш хәлләре һәм яңа тормыш турында сөйләшкәндер. Инде бина башка тормыш белән яши: солдат караваты куелган урыннарны яшел буяулы парталар билә гән, дәрес вакытларында кара тактага мәрҗән-мәрҗән булып гарәпчә хәрефләр тезелә. Коридор өстәлендә — зур көмеш кыңгырау, тәнәфес арасында аның чыңнары дәртле бер музыка, яңа тормыш авазы сыман яңгырый. Түшәмгә, диварларга сеңгән дару исләре чыгып бетмәгән бетүен, әмма бинаң булуга житәме соң! Тиздән мәктәпкә яңа тормыш билгесе — өмәләр килер: менә шул чакта стена-түшәм агарту кебек эшләр гөрли башлар.

Хуш, мәктәп тормышын яктыртырдай тагын нинди мисалларга тукталыйк соң? Архив мәгълүматлары раслаганча, 1924-25 уку елында мәктәпкә 533 бала укырга йөри. Составы ягыннан татарлар — 68, руслар — 19, башкортлар 13 процентны тәшкил итә. 16 педагогның өчесе — югары белемле, калганнары махсус урта белемгә ия. Төп предметлардан тыш, исәп-хисап һәм товар эше, хәтта немец теле дә укытыла. Кышкы кичтә бүлмәләрне яктырту өчен бер лапма һәм илле данә шәм бүлеп бирелгән. Укучылар карамагындагы клубта алласызлар, математика, хезмәт һәм музыка түгәрәкләре эшли. Политәзерлек түгәрәгендә исә СССРның халыкара хәле, революцион көрәш һәм партия тарихы өйрәнелә. Мәктәп үзенең төрле, шул исәптән «Известия», «Башкортстан», «Кызыл Татарстан», «Яшь юксыл», «Безнең юл», «Яшь иптәшләр», «Безбожник», «Смехач», «В мастерской природы» һәм башка шуның кебек газета-журналлар алдыра.

Кыскасы, дәреслек һәм уку әсбапларына кытлыкны исәпләмәгәндә, яшь буынга укыр өчен, илнең лаеклы гражданины булып үсәр өчен менә дигән шартлар тудырылган.

Киндер букчасын асып, озын тәнәфестә ашыйсы ризыгын һәм дәфтәр-каләмнәрен күтәреп, Фәрит көн дә мәктәпкә йөри.

Класста ничә укучы булса, шуның санынча — характер, язмыш, бала шәхесе. Фәрит укытучысы сөйләгәнне бирелеп тыңлаучан, дәрес вакытында иптәшләренең үзе белән шаярганын яратмый. Басынкы, оялчан, юаш табигатьле малайның уенчаклыгы да юк түгел, ләкин аңарда әчке, яшерен, аңлашылып бетми торган серле бер тормыш бара. Бу халәтне, бәлки, гаҗәпләнә белү фәне диярләрдер? Малай өчен бөтен нәрсә яңа, кызыклы, мавыктыргыч. Дәрестә тыңлаучан, дигән фикеребезгә капма-каршы булган икенче бер сыйфатын да әйтеп китми ярамый. Укытучы күзеннәнерактарак булуны истә тотып, Фәрит һәрвакыт арткы рәттәге парталарның берсенә утыра. Аннары, артында кемнеңдер барлыгын тою аңа эшләргә дә, хыялланырга да комачау итә кебек. Әйтик, каләм сорап янсә башка вак-төяк үтенеч белән ме дәрестә берәү кабыргаңа төртсен әле — шундый да ямьсез, урынсыз мөгамәләне ни жаның белән күтәрмәк кирәк ди? Үзе сайлап алган арттагы урыны жайлы аның. Теләгән чагында тәрәзә аша тынычлап кына табигать күренешләрен тамаша кылырга мөмкин. Текәлебрәк карасаң, тәрәзәдән Агыйдел буйлары, таулар һәм яшел урман тезмәләре күренә. Агыйделне каплап торган яшеллек арасында кайчак көтмәгәндә төтен баганасы пәйда була. Монысы — узган-барган пароходлар койрыгы. Колак салып тыңласаң, аларның гудок биргәне дә ишетелә кебек. Тәмам онытылган, хискә бирелгән чагында малайны укытучы шелтәле тон белән кабат класска кайтара. Менә шул чактагы оялулары Фәритнең! Колакларына хәтле кызарып чыга, әмма үз-үзенә ант бирүләре түкран тәүбәсе шикеллерәк: берничә дәрес тыелып торганнан соң аның хыяллары яңадан канат кагына башлый, табигатьтәге авазларга иярә...

Бәйрәм көн бәйрәмчә шул инде: бүген текә муенлы атлар да буяулы дугасы, чуклы-чачаклы дирбияләре белән әллә кайдан үзенә тартып тора. Малайларны иң кызыктырганы — җиз тәңкәле йөгән, әлбәттә. Йөгән каешына, әйтерсең, берәм-берәм нәни кояш тезеп чыкканнар. Күктәге зур кояш белән ярышырга теләгәндәй, алар җем-җем килеп ялтыраша, ат юырткан көйгә салмак кына тирбәлеп бара. Шушы тирбәлеш дулкынында туры айгырның зур итеп ачылган күзләре исә кара кояшны хәтерләтә. Кара кояш була микәнни? Куркынычтыр ул... Алай дисәң, нигә соң айгырның томрап торган күзләренә һаман саен карыйсы, төбәләсе килеп тора? Шуңа җавап эзлисең, әмма озаграк текәлгән саен серлелек арта гына бара. Көчле, күндәм, йөгерек атның күзләрендә ансат кына аңлап булмый торган ниндидер могҗиза бар...

Халык Дим буена сәхрәгә чыккан. Болынга җиткәч, җигүле атларның дугасы һәм аркалык баулары чишелә, кеше күплектән югалып калган колыннар әнкәсенә елышарак төшә. Гармун асып, җәяүләп килгән яшь-җилкенчәк әлегә салмак, басынкы, үзләрен күрсәтергә ашыкмыйчарак торалар. Мәйдан тәмам тупланып, өлгереп җитсен — менә шунда алар дилбегәне үз кулларына алачак инде. Чәчәктәй нәфис кызлар җитәкләшеп янәшәңнән узганда борынга җиңелчә хушбуй исе бәрелә. Яр читендә торган көймәләрнең берсендә кызыл әләм җилферди, чәчләрне кытыклап Дим ягыннан бәйрәм җиле исә. Я, түбәтәйле балачак өчен моңардан да ямьлерәк, ләззәтлерәк ни булырга мөмкин тагын?

Фәритнең бер генә тамашадан да читтә каласы килми. Ул озаклап-озаклап әле гармунчы егетләрне күзли, әле чыркылдап көлешкән кызларга текәлә, әле түгәрәкләнеп утырган ирләр табынына караш ташлый. Мондый «кыюлык»ны сак кына, сиздермичәрәк эшләвең хәерлерәк, юкса өлкәннәр бу шөгыльңне бик тиз сизеп алыр һәм ачуланыр шикелле.

Берзаман җыр-гармун авазлары көчәя, куера башлый. Кояш астында балкып яткан тугайның әле бер, әле икенче почмагында җанлы түгәрәкләр оеша. Бер киңәеп, бер кысылып килгән түгәрәк уртасына чая егет атылып чыга. Кызыксыну тулы йөзләрдә бер генә сорау: булдырырмы, сынатмасмы бу асыл кош? Юк, сыната торганнардан түгел икән. «Их-ма!»— дип учы белән тезенә бер-ике сугып алуына, халыкның йөзе яктырды. Егет әүвәл җилкенеп, аяк очларына басып кына мәйданны әйләнеп чыкты, киңәш-табыш иткәндәй, гармунчыга караш ташлады. Аннары китте бу, китте биеп — орчыктай бөтерелеп ме-бөтерелә генә! Аяклары үләнгә тисә тия, тимәсә юк моның. Шул арада, кулларын җиргә тидерми генә, мәтәлчек атып та өлгерә. Егет үзенең дәрте, осталыгы белән: «Гаепләмәгез, менә шундый чагым минем! Арагыздагы берәр чибәргә сүз кушам икән, зинһар, ул миннән читләшмәсен...»— дип әйтергә тели кебек.

Икенче бер читтәрәк җырда ярышалар. Тальян гармун күрегенә сандугачлар басып сайрый диярсең! Унике телле кеп-кечкенә гармун һәркемгә җитәрлек моңнарны ничек, кай җиренә сыйдырган — шуны аңлый алмый Фәрит. Могҗизалы гармун яшьләрне үз тирәсенә җыйган. Бер якта — кызлар, икенче якта — егетләр. Ашыкмый гына, үз дәрәҗәләрен белеп кенә җырда аңлашалар. Кайсыдыр башлаган җырны егетләр калын тавышка күтәреп ала:

Бакча эчләрендә бакча,
Бадыян түтәлләре.
Ал булса да, гөл булса да,
Кирәкми бүтәннәре.

Кызлар сафыннан бәхетле елмаю сирпелеп уза. Шушы кадәр мактауга түзеп кара әле син! Гармунчы егет иптәшләренә күз кыса да кыз-

лар ягына таба борыла төшә: инде сез ни әйтерсез, янәсе... Кызлар алай ялындырырга уйламый, форсаттан файдаланып, икәүдән-икәү генә калган чакта әйтеп булмый торган хисләрен җиткерергә ашыгалар:

Бакча эчләренә кереп
Өзеп алдым бер алма.
Эчем ялкын, тышым ялкын —
Ятлар белән чуалма!

Кушучлап яки чүмечләп күпме генә эчмә, чишмәләрнең суы беркайчан кимеми. Халык моңнары да нәкъ шулай икән. Җырлаган саен ул арта гына бара, күңелдән күңелгә күчә, мәңгә тапкырлана. Ә шулай да бүген Фәритне иң нык гаҗәпләндергәне курай булды бугай. Кура үләненнән ясалган гап-гади курай. Аның төрле зурлыктагысы, хәтта ярты-тышар метрга җиткәннәре дә була икән. Буынтыклы коры кура таягына ногыт борчагыннан кечерәк итеп биш тишек уелган (биш аваз кушылмасының пентатоника дип аталуын Фәрит соңыннанрак беләчәк әле). Иренгә тидереп, әлеге тишекләр өстендә бармакларыңны йөрткәләсәң, курай телгә килә — сөйли, җырлый, моңлана башлый. Малайның тыңлаганы бар: кайчак җил, койма-рәшәткәләр арасына посып, әллә ниткән авазлар чыгара. Хәтта песнәк яки шәүләгән булып сызгыра. Җил курай уйный, дигәннәре дөрес, димәк...

Кара-каршы басып ике егет курай уйный. Курайдан татар һәм башкорт моңнары коела. Бу моң сине үзенә әлдәкетереп ала, болай да очынырга торган күңелне әллә кайларга ияртеп алып китә: карурманда йөртә, дәрья киңлегенә чыгара, тургайлар очкан биеклеккә күтәрә. Ничектер моңсу булып китә, менә-менә атылырга торган күз яшьләрен күрсәтмәс өчен Фәрит читкә тайпыла. Болай гына да котылу юк икән, моң Фәритне эзәрлекли, бер тотам калмый артыннан ияреп бара: «Качма миннән. Син дөньяга моңлы бала булып тугансың. Күңелеңдә сагыш чишмәләре тибә икән, ирек бир аңа, суларында йөзеңне чайка. Гомерлек сафлану, игелек куәтләре алырсың...»

Үз-үзен һәм күңелендәге халәтне аңламыйча, Фәрит озак кына басып тора әле. Кем, нинди көчләр дәште аңа шулай? Әллә колакка гына ишетелдеме юкса? Эчке бер тавыш аны юата, тынычландыра, шат һәм бәхетле булырга чакыра. Әти-әнисе орышса орышыр, күлмәкләр яшелләнгәнче сусыл үләнгә ятып ауныйсы, тәгәрисе, чикерткә һәм кылганнар җырын туйганчы тыңлыйсы, күңеленә сеңдерәсе килә малайның...

Көймәдәгеләр суны ишә-ишә Дим уртасына кереп баралар. Ишкәк калаклары чупылдаганны тыңлау үзе бер рәхәт. Дим өстендә шаярган-көлгән тавышлар, гармун-җыр авазлары яңгырый. Сөзәк яр буена утыр да рәхәтләнеп күзәт, тамаша кыл бәйрәмне. Көймәләрнең кайсына хәтта самавыр да алганнар. Башы кәкрәйтеп ясалган калай торбадан җиңел зәңгәрсу төтен күтәрелә. Су уртасында табын корып та җибәргәннәр, дөньяның тәмле ризыклары шундадыр, дип уйлый торгач, түкрегеңне йотып җибәргәнне сизми дә каласың.

Чү, монысы нинди кирәкмәгән шау-шу тагын? Берәрсе ялгыш хәрәкәт ясады микәнни — көймә читендә утырган гармунчы егет тальяны-ние белән суга капланып төште. Менә сиңа мә! Нишләргә? Ярдәм итүче табылырмы?

Бәхеткә, түбәтәе каядыр су төбенә киткән егеткә көймәдәгеләр ярдәм кулы суза. Тигезле-тигезсез айканудан көймә чайкала, бер якка янтая. Суга батучыны коткару — казалы эш икән ләбаса! Ярый, ниһаять, иптәшләре көймәгә тартып менгерделәр аны, ә менә гармуны белән нишләргә соң? Ул инде, әлбәттә, нык кына чылангандыр, эченә су кереп тулгандыр, телләре яраксыз хәлгә килгәндер. Бу егет һәм аның иптәшләре җан дустың булырдай тальянны бер дә кадерли белмиләр микәнни? Менә кемнәрне үрле-кырлы сикерерлек итеп кытыклатасы иде шүрәледән!

Бик кызганды Фәрит гармунны. Әгәр көченнән килсә, бу егетләрне беркайчан да су гизәргә чыгармас иде ул...

* * *

1924 ел. Кыш. Гыйнвар...

— Ленин үлгән...

Класс тетрәп аякка баса. Дөрес хәбәрме бу? Балаларга бүлмә түрендәге рәсемнән зирәк бер елмаю һәм кайгыртучанлык белән юлбашчы карап тора. Шушы кешененме йөрәге тибүдән туктаган? Моңа берәүнең дә ышанасы килми.

Зәңгәрләнеп торган чатнама суык көн. Очкан шәпкә кошлар егылып төшәрлек. Күп кенә биналарның түбәсенә кара каймалы әләмнәр эленгән. Урамнан чаналы атлар кая табадыр җан-фәрман чаптырып уза. Чана табаннары аеруча бер шом белән шыгырдый, әйтерсең, кемдер тешкә тиярдәй аваз белән алагаем зур скрипкада матәм маршы башкара. Яшәү һәм үлем. Капма-каршы әлеге ике чик арасында бүген бәхәс, тарткалаш бара. Ленинның үлеме аның яшәүчәнлеген көчәйтәчәк кенә — моны һәркем күңеле белән сизә...

Һәркайда кайгы митинглары оеша, мәктәптә укулар өзелә. Митингтан соң балалар паркта учак ягу вакыйгасында да катнашалар. Учак — дөньяны яктырту, җылыту билгесе. Үсеп килүче яшь буынга, дөньяны яктырту һәм җылыту кебек олуг эшләрдә катнашу өчен иң элек ныклап укырга кирәк әле. Мондый мөмкинлекне аларга Ленин төзегән эшче һәм крестьяннар дәүләте бирде. «Ленин үлгән»,— дип балалар җан елаша. Хәлбуки, укучыларның аңы политик вакыйгаларны бәйләүдән шактый ерак тора әле. Ләкин шикләнми әйтергә мөмкин: иң кадерле кешене югалту ачысын алар көннән-көн ныграк аңлыйлар. Тәнәфестәге җырлы уеннарга яңа эчтәлек, яңа сүзләр үтеп керә.

Ленин бабай, тыныч йокла<br>
Мавзолеең эчендә.<br>
Көрәшергә әйткән сүзең<br>
Һәммәбезнең исендә.

Шулай дип җырлаган буын, әйтерсең, үзенең сөекле юлбашчысы каршында ант бирә.

Мәктәп кенәме соң, бөтен ил Ленин сулышы белән яши. Уфадагы үзәк урамнарның берсендә юлбашчыга һәйкәл ачарга җыеналар. Булачак һәйкәл өчен Урал эшчеләре мәрмәр кискәләрен шомарта. Ленинградның «Красный выборжец» заводы эшчеләре дә республикага ярдәм кулы суза: алар Ленинның бронза сынын коеп бирәләр. Мондый тарихи вакыйгадан мәктәп укучылары да читтә калмый. Булачак һәйкәл мәйданчыгын отрядлар шефлыкка ала, дәресләрдән соң яки ял көннәрендә барабан кагып, быргы уйнатып дәррәү өмәгә чыгалар. Мәйдан тирәсен чүп-чардан чистарту, җир казу, казылган җирне ташлардан арчу, кирпеч һәм ком ташу — менә шушы эшләрнең уртасында балалар кырмыска кебек кайнаша. Юлбашчы һәйкәленә илтәсе юллар матур булырга тиеш: якын тирәдәге урамнар төзәтелә, сазлыклар киптерелә.

Без яшь өмәчеләр арасында Фәритне дә күрәбез. Һәркайда — шул заманга хас бердәмлек, рух күтәренкелеге. Кай тарафка гына юлыкмасын, андый күтәренкелекне Фәрит киләчәктә дә адым саен сизеп торачак. Зур вакыйгалар эргәсендә чыныгып үскән бу буын илнең иң җаваплы көннәрендә дә шәхси ваклыклардан өстен кала белер. Тугрылык, намус, гаделлек хисе кеше күңеленә көннәрнең берендә кинәт кенә күктән тамып төшми, аның орлыклары балачак көннәреннән үк салына. Үсенте тернәкләнеп китсен өчен аңа иң беренче нәүбәттә дым, һава, кояш яктысы кирәк. Хезмәттә һәм җәмгыять тормышында

якыннан торып катнашу яшь күңелләрне калыплаштыруда, һичшиксез, әнә шундый роль уйнаган.

Фәритнең исендә калачак тагын бер вакыйганы хәтергә теркәп китик. Бу — үз кулларың белән агач утырту шатлыгы. Булачак һәйкәл тирәсен тагын балалар сырып алган, чокыр казыйлар. Кулдагы көрәкләр ялт-йолт килә. Тамырларында бүрек кадәрле туфрак укмашкан яшь юкәләр чокыр авызына төшерелә. Андый юкәләр каршыдагы урам буена да утыртыла. Агач утырту өмәсеннән соң укучыларга кайнар сөт бирелә.

Монумент тирәсендәге бу юкәләр хәзер инде шактый олыгайган, олпат кыяфәткә кергән. Аларның язмышы, үткәне һәм бүгенгесе бөтенләйгә шушы парк туфрагына береккән. Беләсе иде: лепердәшеп утырган әлеге юкәләрнең кайсына Фәритнең бармак эзләре йогып калды икән? Вакыт эндәшми. Бу сорнең җавабын кәүсәдәге җыерчыклар эчкәре йоткан...

Фәритнең шагыйрь Сәгыйть Рәмиевне күмү мәрасимендә катнашуы да билгеле. С. Рәмиев озак еллар Казанда яши, театр һәм матбугат тормышында актив катнаша, Тукай һәм Әмирханнар мохитендә үз кеше була. Гомеренең соңгы елларында ул Уфага килеп төпләнә, Наркомземда эшли. Үзендә аллаларга, дөньяга «каш җиерырлык» көч тапкан дәртле, кайнар йөрәкле шагыйрь, әдәбиятта якты эз калдырып, 1926 елның 17 мартында мәңгегә күзләрен йома.

Мәрхүмнең гәүдәсен «Рабпрос» клубыннан дәфенләү комиссиясе кешеләре алып чыга. Шуларга кушылып, озата баручылар да татар зиратына юнәлә. Ачык кабер янында берничә кеше нотык сөйли. Шагыйрьнең гәүдәсен Нәкый Исәнбәт һәм Сәйфи Кудаш ләхеткә төшерәләр...

Фәритнең якын дусты, сабакташы Хәсән Гобәйдуллин бу вакыйга турында болай дип яза:

«Менә бервакытны безнең мәктәпкә, Сәгыйть Рәмиев үлгән икән, дигән хәбәр килеп житте. Аның үлү хәбәре күктән таш төшкән шикелле булды. Чөнки безнең укытучыларыбыз Рәмиев һәм аның иҗаты турында зур хөрмәт белән сөйлиләр иде. С. Рәмиевне күмәргә мәктәбебез белән оешкан төстә бардык. Укучылар арасында... Фәрит Яруллин да бар иде».

Фәритнең мәктәп яшеннән үк бай рухлы мохиткә, укымышлы шәхесләр кулына эләгүен алдарак азмы-күпме әйтеп киткән идек. Моның тамырларын тагын да тирәнрәк ачар өчен без Нәкый Исәнбәтнең Уфадагы мөгаллимлек эшчәнлегенә аерым тукталырга тиешбез.

Югарырак классларны татар теле һәм әдәбияты фәненнән Нәкый Исәнбәт укыта. Аның кайбер сүзләргә басым ясый-ясый дәртле итеп сөйләвендә, кул хәрәкәтләре белән дә ниндидер мәгънә аңлатырга тырышуында үзенә күрә илаһи бер тылсым, сихер бар. Яңа укытучыларының Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури кебек шагыйрьләр турында якыннан белеп сөйләве, аның үзенең дә шигырьләр, хикәя һәм пьесалар язуы — малайлар өчен соклангыч өлге, бүй җитмәслек абруй. Бишенче класстан соң Фәрит менә шундый педагог кулында укый. Музыка сыман, әдәбият дәресләре дә аны тылсымлы дөньяга алып керә, үзенә йотып ала. Тукайның «Шүрәле»се матур әкият икәнен Фәрит инде аңлап, ләззәт кичереп укый. Ләкин күңеленең кай төшендәдер барыбер яшерен өмет уяна: шүрәле, чыннан да, бардыр ул, мин шуны ерактан гына күрсәң иде бер...

Дәрмәнд шигырьләре кыска, төзек, чатнап тора. Аның «Кораб» шигырендә аңлашылып бетми торган шом, билгесезлек, хәвеф бар. Дәрмәнднең алтын прискасы хуҗасы булуын да әйткәннән соң, Нәкый абыйлары үзенең фикерен әнә шушыңа бик оста китереп ялгый: «Аның шигырьләре дә алтынның үзе кебек нәфис эшләнгән, нык шомартылган...»

Революция дулкынында калкып чыккан хөр фикерле, мәгърифәт өчен җанын-тәнен аямый торган педагоглар мәктәп тормышына яңа

сулыш өрәләр, тәрбия ысулларын тамырдан яңарталар. Укучыларга баласытып карау юк, парта артында утырган гап-гади кызлар-малайларның үзендә илнең якын киләчәген күрә алар. Зурларга караган кебек житдилекне, ышанычны укучылар адым саен сизеп тора. Укытучы дәреснең кай төшендәдер кинәт тукталып кала һәм әйтә:

— Сез яңа заманда яшисе, киләчәктә ил тормышында кайнашасы кешеләр. Һәркем үз юлын, үз хезмәтен табар. Сез бүгеннән үк ныклап менә нәрсәгә әзерләнергә тиешсез!

Нәкый Исәнбәт мәктәпкә көрән пальтодан, шиблет янсә резин галоштан килә. Тагын да гаҗәбрәге — ул берара колакчынлы буденовкадан йөри. Толстовка кигән, ягымлы, алсу-ак йөзле бу кешенең сөйләгәнен тын да алмый тыңлыйлар. Яшь күңелләрне хакыйкатькә якынайтасы килеп, дәресен тормыштагы төрле-төрле хәлләргә бәйләп аңлата. Ул чакта иншалар яздыру да — зур яңалык әле. Исәнбәт моны гамәлгә кертә, укучыларның фикер йөртү һәм язу сәләтен чарлый. Рус әдәбияты белән бәйләнеш тә онытылмый, күрәсең: «Обломов безнең арада» дигән язмалар әнә шул хакта сөйли. Икенче бер вакыт укучылар үзләре белгән кайсы да булса кеше турында инша язып килергә тиеш булалар.

— Әйдәгез, бәяне бөтен класс белән бергәләп бирәбез,— ди укытучы һәм иң өстә яткан берничә дәфтәрне кычкырып укып чыга. Урта мәкләрдә утыручы бер кыз остабикә турында язган икән. Аның кыланышлары оста сурәтләнгән урында балалар көлешеп тә алалар.

— Ягез, бу иншага нинди билге куябыз?

— Югарыны!— дип гөрләтеп җавап кайтара класс.

Кояшлы, җылы көннәрдә кайбер дәресләр мәктәп ишегалдында үтә. Табигатьнең чирәм иданле, түбәсез-тәрәзәсез биләмәсендә ачык дәрес — күңел күтәренкелеге өчен бу инде кечкенә нәрсә түгел. Каникулга таралыр чак җиттеме, Нәкый Исәнбәт балаларга мавыктыргыч эш йөкли — әкиятләр, җырлар, табышмак һәм мәкальләр җыярга куша. Моның бердәнбер чыганагы — өлкәннәр, әлбәттә. Кичләрен аларның сөйләгәнен тыңлап, язып кына өлгер. Әтисе күпне күргән, ил-җир гизгән кеше, әнисендә дә сүзгә тапкырлык җитәрлек. Фәритнең дәфтәренә әти-әнисеннән ишеткән фольклор хәзинәсе туплана*. Әдәбиятка, халык авыз иҗатына мәхәббәт очкыны әнә шулай кечкенәдән салына.

Мәктәпнең актлар залы. Үзенә күрә иркен генә сәхнәсе дә бар аның. Әдәби һәм музыкаль кичәләр узганда вакыты-вакыты белән умарта күчедәй гөжләп ала бу зал. Нәрсә, кунакка артистлар килгән әллә? Юк, укучыларның үз көче белән спектакль күрсәтеләчәк. Бу эшнең дә башлап йөрүчесе — Нәкый Исәнбәт. Театрдан гаять оста декламатор, үзенчәлекле артист, талантлы режиссер Мәкәрим Мәһдиевне чакырта. Бу ике кешенең «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән үк килгән танышлыгы инде күптән иҗади дуслыкка, рухи туганлыкка әверелгән. Бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар. Шундый дустың чакырып торганда балалар өчен вакыт тапмый хәлең юк. Килә Мәһдиев, киңәш-табыш корганнан соң, мәктәптә драма түгәрәге ачып җибәрәләр. Тамашачы зәвыгына туры килерлек итеп репертуар да сайлана.

Укучылар Мәкәрим Мәһдиев әзерлегендә Н. Исәнбәт, И. Рәмиев, Ә. Рахманкулов һәм башкаларның байтак әсәрләрен сәхнәдә уйныйлар. Аларның осталык дәрәҗәсен шуннан чамаларга мөмкин: иң яхшы спектакльләрен хәтта шәһәр күләмендә, төгәлрәк әйтсәк — каланың публичный залларында, театр биналарында да еш күрсәткәлиләр икән. «Чалбарлы хатын»— Исмәгыйль Рәмиев әсәренең исеме генә дә әллә ничаклы тамашачыны җыеп китерә. Нәкый Исәнбәт белән Әхмәт Рах-

* Фәритнең әлеге фольклор дәфтәре Н. Исәнбәтнең шәхси архивында сакланырга тиеш. Киләчәктә моңа игътибар итүчеләр табылыр, бәлки? (Автор искәрмәсе.)

манкулов татар хәятын, бигрәк тә иске мәдрәсә тормышын яхшы беләләр. Аларның да пьесалары данлы бара.

Ул еллар өчен тагын бер характерлы билгене — педагогиканың тормышка йөз белән борылуын да әйтеп китик. Мәктәпләрнең материаль-техник базасы ныгый бара, уку программасы киңәйтелә. Физика һәм химия дәресләренең якындагы институт лабораториясендә үткәрелүе дә ул заман өчен шактый зур яңалык. Фанер фабрикасына, күн әйберләр заводына, туку һәм тегү остаханәләренә ясалган экскурсияләр дәресләрне тагын да җанландыра, яңа эчтәлек белән баета. Мәктәпнең хезмәт бүлмәсендә малайлар агач һәм тимер эшенә өйрәнә, кызлар исә тегү-чигү, чәчәк үстерү белән шөгыльләнәләр.

«Мәктәп кооперативы» дип йөртелгән почмакка да күз төшерик. Прилавкага һәм шкаф бүлемнәренә каләм, карандаш, дәфтәр, бетергеч кебек уку әсбаплары тезеп куелган. Үзенә күрә коммунизм «чаткы»сы бу: сатучы-мазар һәм күзәтүче юк, кирәк товарны укучылар үзләре бара да ала. Бәяләре язылган, тиешле акчаңны түләргә генә онытма. Намус эшенә корылган мондый ирекле сәүдә йөзләгән балаларны гаделлеккә, мөстәкыйльлеккә өйрәткән. Көн азагында исәпләп карыйлар: керем акчасы тиенгә-тиен дөрес чыга. Сүз дә юк, яшь гражданнардан торган тулы бер коллектив өчен әйбәт кенә казаныш бу.

Әле ныклап аякка басарга да өлгермәгән Совет власте белем алу өчен әнә нинди шартлар тудырды. Илнең барлык мәктәпләрендә яңарыш бара. «Укырга, укырга һәм укырга!»— мәсьәлә фәкать шулай, ленинча куелган.

Әтисе Фәритне Уфада да еш кына үзе белән концертларга алып йөргән. Элекке сәүдәгәр Видинеев бакчасы тәртипкә китерелә һәм парк дип үзгәртелә. Иркен террасалары, челтәрле култыкса һәм баскычлары үзенә чакырып торган ике катлы зур бина җәйге театр ролен үти. Заһидулла Яруллинның революциягә кадәр үк инде бу мәйданчыкта татар-башкорт көйләрен күп тапкырлар уйнаганы бар. Хәзер дә скрипка һәм гармун белән чыгышлар ясарга туры килгәли аңа.

1924 елның җәе. Күңел ачар өчен халык Видинеев бакчасына җыелган. Алдагы рәтләрнең берсендә коляскасы белән Фатих Әмирхан да утыра. Утыргычка кадакланган булуына карамастан, ул һаман да йөрергә, сәфәр кылырга, халык белән аралашырга ярата. Күңеленә азык эзләп, милләтнең сәнгать гөлләре ничек үсүен кайгыртып килгән. Кечкенә Фәрит күзлекле, үткен карашлы, үзе исән чакта ук абруе нык таралган әдипне күрми калмас, билгеле. Ул көнне халык Солтан Габәши белән җырчы Газиз Әлмөхәммәтов концертын алкышлый. Җырчының тәэсирле, нечкә тембрлы тавышын Фәрит башка чакларда да тыңлаган. Солтан Габәши исә булачак композиторыбызга Казан сәнгать техникумында музыка теориясеннән дәресләр дә бирәчәк әле. Төрле-төрле язмышлар ничектер бер тирәгә укмашкан. Балачактан ук Фәритнең сукмагы татар профессиональ сәнгатенә нигез салучылар тирәсеннән уза. Музыка «жене» йогып калуның тагын бер сәбәбен, һичшиксез, шуңардан да эзләргә кирәк.

Солтан Габәши белән Газиз Әлмөхәммәтовның искиткеч җаваплы эшкә керешкән чаклары бу. Композитор Василий Виноградов белән берлектә, тиздән алар татар операсының беренче карлыгачын — «Сания» операсын иҗат итәләр. Татарстан җөмһүрияте төзелүгә биш ел тулган көннәрдә Казанда аның премьерасы күрсәтелә. Беренче опера тантанасында кемнең генә катнашасы килмәс икән: халык күп, бар да бәйрәмчә төзәнеп-ясанып килгән, затлы киенгән нэпманчылар да юк түгел. Ул кичтә тәрәзәләр алкышның күплегеннән чатнардай булып зыңлый... Әйе, татар опера сәнгате үзенең байрагын өскә күтәрде, инде шуны югары тотардай дәвамчылар, фидакарь җаннар кирәк. Андыйлар бар, тормыш әнә меңәрләгән кызлар һәм малайлар арасыннан талантларны барлый, олы дөньяга илтәсе сукмакларын билгели.

Уфа чорында Яруллиннар гаиләсе шагыйрь Мәҗит Гафури белән дә якыннан аралашып яшәгән. Казаннан Уфага Фәйзулла Туишев һәм Фәйзи Биккинин кебек оста гармунчылар еш кына килгәли, ачык сәхнәдә концерт бирәләр. Андый концертларда Заһидулла Яруллин пианино яки скрипкада гармунчыларга кушамалык итә. Шундый концертларның берсендә сәхнәгә калын-кара мыеклы берәү күтәрелә. Бераз аксабрак атлавыннан аның Мәҗит Гафури икәнен белербез. «А-а, Казаннар килгән!» — дип ул музыкантларны ихластан тәбрикли, өенә кунакка чакыра. Гафуриның хатыны Зөһрә ханым, җырга-моңга гашыйк кеше, аларны якты чырай, такта чәй белән дигәндәй каршы ала. Чәй һәм әңгәмә арасында кунаклар «Тукай маршы»н һәм башка көйләрне яңгыраталар.

Инде килеп, Сәйфи Кудаш истәлекләренә мөрәҗәгать итик. Без анда түбәндәге юлларны укыйбыз:

«1924 елда булырга кирәк, мин бер барган чакта Гафури кыска буйлы, тузган чәчле һәм юаш табигатьле бер кеше белән сөйләшеп утыра иде. Бу кешене ул миңа:

— Таныш булыгыз, «Тукай маршы» һәм «Каз канаты» көйләренең авторы Заһидулла Яруллин,— дип тәкъдим итте. Ә икенче вакыт, 1925 елда, редакциядә гонорар түләнгән бер көнне яшь журналист Гомәр Илбай эштән кайтышлый безне берәр кружка сыра эчәргә чакырды. Гафури да моны кире какмады, тик:

— Алай булгач, әйдәгез, Заһидулла Яруллин скрипка уйный торган сигезенче номерлы сыраханәгә барыйк,— диде. Сыраханәгә кереп утыру белән теге тузган чәчле кеше Гафури янына килеп тә җитте. Яруллин безнең яннан киткәч Гафури:

— «Тукай маршы»н язган бердәнбер композиторыбыз бар, ул да булса ресторанда уйнап кына тамак туйдыра,— дип көрсенеп куйды. Гафуриның сүзләренә җавап биргән кебек итеп, Заһидулла Яруллин скрипкада «Тукай маршы»н уйнап та җибәрде».

Агач йортның икенче катында яшәгәнгә күрә, Фәрит ишегалды баскычыннан аска таба да, өскә таба да көненә әллә ничә тапкыр йөгереп уза. Култыксалы агач баскычның күпне күргән такталары инде тәмам шомарып беткән. Ботаклы урыннары гына, ансаттан бирешергә теләмичә, бераз калкып-кабарып тора. Дөньяда ксилофон дигән уен коралы барлыгын ишеткәне юк Фәритнең, ләкин баскычтан менгәндәге аяк тавышлары аның колагына ягымлы музыка булып ишетелә. Ишекне ачкан уңайга зур залга килеп керәсең, аннары мич каршында кечерәк кухня, түр якта исә йокы бүлмәсе. Өйнең тәрәзәләре урамга да, ишегалдына да карый. Шкаф, өстәл, ялангач утыргыч-эскәмиядән кала, зур бүлмәнең бер почмагында тагын соргылт төстәге искерәк пианино тора. Фәритнең җан атып йөргән нәрсәсе менә шушы була инде. Музыка дөньясы аны Казанда чакта ук сихерләп өлгергән иде. Әтисе уйнагандагы күпме авазлар, тылсымлы йомарлам булып, хәтеренең кай төшендәдер оеп тора. Инде менә ул үзе дә пианинода уйный башлады.

Фәритне пианинода уйнарга әтисе өйрәтә. Күпмедер вакыттан соң ул инде нота әлифбасын да үзләштереп өлгерә. Әтисе дәфтәрендәге билгеләр кайчандыр аңа табагачны, телеграф чыбыгындагы кошларны яки нәни яфракны хәтерләткән булса, хәзер инде нота тамгалары үсмер малайга төгәл бер мәгънәне, аваз төсмерләрен аңлата, сөйли, телгә килә. Хисапчы отчет төймәләрен никадәр оста уйнатса, тора-бара Фәрит тә, нота билгеләре белән шулайрак эш итәргә күнегә башлый.

Ул чакта кала мәктәпләрендә җыр дәресләрен укыту яхшы гына куелган була. Әйтик, Фәрит укыган мәктәптә җыр укытучысы скрипкада уйный белгән, җырларның килеп чыгу тарихын сөйләргә яраткан. Татар һәм башкорт җырларын гына түгел, хәтта итальян халык көе «Сан-

та лючио»ны да өйрәнеп, хор белән җырлыйлар. Укытучы, кара тактага язып-язып, элементар нота билгеләрен аңлата. Фәриткә белгән нәрсә турында тыңлау кызык түгел, ләкин күңеле масаюдан ерак аның: андый вакытларда ул ноталар язып утыра, кулын һәм зиһенен чыныктыра.

Фәрит — оялчан, басынкы табигатьле, дәресләрен игътибар белән тыңлаучан. Әрсез-битсез дә түгел, әдәпле. Кычкырып көләргә яратмый: бөтен кеше аңа борылып карар да күңелендәге дөньясына бармак белән төртеп күрсәтер кебек. Оялчан, уйга бирелүчән булгангамы, кызларга якын утырмаска тырыша, малайлар тирәсен сайлый. Ләкин болар — мескенлек дәрәҗәсендәге юашлык, йомыкыйлык дигән сүз түгел әле. Уенчаклыгы, үз сүзен сүз итәрдәй ныклыгы, үҗәтлеге, җаптәшлеге дә бар аның.

Дуслык мәсьәләсенә килгәндә, Фәрит бик талымчан, әмма бер дуслаштымы — күңел җылысын биреп аралаша, иптәшлек хисләренә ахыргача тугрылык саклый. Шәриктәшләре арасыннан Хәсән исемле малай белән дуслашып китүләре аеруча игътибарга лаек. Хәсәннең әтисе сәүдәгәр кеше, тормышлары таза, йорт-җирләре иркен. Спасский (хәзерге Ново-мостовая) урамындагы бу йортта артист Гыйләҗ Казанский, «Кызыл яу» газетасы редакторы Фәрхи Әхмәров фатир тора. Ул елларда алар янына Мәҗит Гафури, Шакир Шамильский, Вәли Мортазин-Иманский, җырчы Фәттах Латыйпов кебек күренекле кешеләр еш кына килеп йөргән. Гомумән, бу урамда татар интеллигенциясе мәхәлләсе белән тора. Хәсәннең күп кенә артист һәм әдипләрне йөз-кыяфәтеннән бик тиз танып алуы, очратканда исәнләшергә тырышып узуы бер дә юкка түгел — ул аларны, чыннан да, «яхшы» белә.

Үсмер булып килгән бу ике малайны нәрсә берләштерде, күңелләрен нинди уртаклык җепләре бәйләп торды икән соң? Күрганебезчә, һәр икесендә дә сәнгатькә мәхәббәт зур, яшәгән тирәлекләре дә җыр-музыка, әдәбият һавасы белән сугарылган. Аннары тагын бер мөһим як: дусны, иптәшне сайлап аласың, күңелеңә таңгал килердәй кешегә тартыласың бит. Бу җәһәттән дә холык-фигыльләре ярашмаслык түгел. Сирәк көлә торган Фәрит, классташы Хәсәнне күргәч, елмая. Пароль сыйфатында йөргән бу елмаю аларны тагын да якынайтып, туганлаштырып җибәрә.

Кайвакытларда мәктәптән туры Хәсәннәргә кайталар. Хуҗалар тарафыннан үгилек, салкын мөнәсәбәт күрсәтелсә, Фәрит бу йортка атлыгып тора алмас иде. Мондагы ягымлылык, игътибарлы караш ошый аңа, тагын да куанычлысы — эчкәрге бүлмәләрнең берсендә пианино бар. Хәсәннең кияүдәге чибәр генә апасы ике сабакташны якты йөз белән каршылый, табынга сый-хөрмәт чыгара. Җизни кеше — «Нур» труппасында һәвәскәр биюче. Беккер фирмасында эшләнгән затлы пианино — шуларныкы. Дәресләрне әзерләп бетәр-бетмәс борын Фәрит пианинода уйнарга тотына. Төрле татар көйләрен башкара Фәрит, өйдәгеләр исә, эшлисе эшләрен дә онытып, аның уйнаганын тыңлыйлар. Кунып калган чакларында ул Хәсәнгә Казан турында, андагы кешеләрнең трамвай дигән түбәле арбага төялеп йөрүләрен зур яңалык итеп сөйли, Кабан күлен сагынуын әйтә.

1927-29 елларны Уфага еш кына Сагайдачный җитәкчелегендәге оперетта труппасы кышкы гастрольгә килә. Хәсәннең Сәрби исемле әлеге ачык йөзле апасы театрда кассир булып эшли, шуннан файдаланып, малайлар «Сильва», «Баядера», «Мартин рудокоп» һ. б. опереталарны карау бәхетенә ирешәләр. Ә икенче көннәрне Фәрит шул опереттәлардан аерым өзекләрне пианинода уйный, импровизация ясый. Димәк, табигать дигәнең булачак композиторга музыканы сиземләү, аны бер ишетүдә дә хәтердә калдыру сәләтен юмарт биргән икән.

Уйнарга өйрәнә башлаганрак вакытларында пианино телләре Фәриткә ансат кына буйсынырга теләмәгән. Көйнең очын эләктереп алу кая, ул инде клавишлар арасына кереп бутала, адаша башлый. Фәрит,

ашап та тормыйча, сабагыннан кайту белән үҗәтләнеп тагын пианино артына утыра. Әнисе өстәлгә бәрәңге шулпасы китергән, Фәрит исә һаман үзенекен тукый:

— Әни, «Хафизәләм иркәм» көенең башын җырлап бир әле.

— И улым, кайнар килеш әүвәл шулпа эчәр идең.

— Кирәк бит, җырла инде, әни!

— Тизрәк үсеп житсәң, Хафизә дигән берәр кыз димләми булмас сиңа.

— Безнең класста ничәмә кыз бар, берсенең дә исеме Хафизә түгел шул...

Житдилек белән бергә, өйдә шулай шаяртып сөйләшергә дә җай тапканнар. Андый чакларда Фәрит үзе дә балаларча шаяртып җавап кайтара белгән, күрәсең.

Пианинода уйнарга Фәритне әтисе өйрәткән, дибез. Әһәмияте артык зур булмаган, ләкин Заһидулла Яруллинны башкачарак яктан сурәтләгән мондый вакыйга да билгеле. Фәритнең пианинода уйнап утырган чагы икән. Көтмәгәндә әтисе кайтып керә дә, уйнаудан бүтәнне белмисең дип, улының кулларына агач линейка белән суга. Моны ничек дип аңларга? Музыкант кеше анда-монда чаба, шәһәрдән шәһәргә йөри, ә килер табышы кесә төбен капларлык кына. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, әти кешенең музыкант һөнәренә өметсезрәк шөгыль дип карый башлавымы әллә? Ничә карасаң, мәктәптән кайту белән Фәрит пианино янына ашыга, көйдән-көйгә күчә, куллары талганнан соң да әле озак кына урыныннан купмый утыра. Җыр-музыка белән артык мавыгып, бәлки, дәресләренә зыян китерәдер ул? Фаразыбызның соңгысы дәрескә ныграк туры килә.

Әтиләре дус булган шикелле, Мәҗит Гафуриның улы Әнвәр дә Фәрит белән кечкенәдән якын дуслыкта яшәгән. Чирәмлектә бергә аунагандыр. Агыйделдәге пароходларны тамаша кылырга бергәләп йөргәндер алар. Әтиләренең пианинода уйнавы һәм шигырьләр язуы хакында үзара мактанышмый да калмаслар. Һәрхәлдә, тормышны һәм дөньяны аңларга өйрәнү, характер чыныктыру, рухи тәҗрибә туплау нисбәтеннән әлеге аралашулар икесе өчен дә файдага киткән.

Дуслык буш урында туа алмый, аны пакь хисләр, рухи бергәлек, хөрмәт һәм тугрылык белән туендырып тору зарур. Заһидулла Яруллин әнә, Уфадан бөтенләйгә китәр алдыннан, дусты Гафури янына саубуллашырга керә һәм егет чагының бер истәлеген — сандык төбендә яткан алтатарын бүләк итә. Тукайның да, бүлмәсендәге тартмаларының берсендә, коръән белән янәшә револьвер саклап торуы мәгълүм бит. Революциягә кадәргерәк заманнарда үзен ир-егет итеп санаган кешеләрнең утлы корал йөртүе — таралган күренеш. Дәрәҗә саклау һәм күп очракта фасон өченрәк тә эшләнә бу. Шулай да Заһидуллага үз гомерендә бер тапкыр әлеге алтатарны кулланырга туры килә...

Вакыйга болай була. 1914 еллар тирәсе бу, малайга ярты яшь тулып, Заһидулла армия хезмәтенә караласы вакытларда, гаилә белән Казаннан Кече Сөнгә кунакка кайтырга чыгалар. Кабык эчле арба төбенә иске бишмәт җәелгән, әнә шунда гөнаһсыз сабыен кочаклап яшь ана утыра. Икенче бер почмакта юл төенчекләре, ямаулы солы капчыгы. Барасы юл ерак, ләкин хуҗа кулында атның яхшысы: дилбегәне кагып алдыңмы, малкай терек-терек килеп җай гына юрта башлый. Бала сулыш алсын дип, унбиш-егерме чакрым саен ялга туктаганга күрә, урманда кичкә калалар. Хәтәр еллар бу, куелыкта качкыннар яши, бандитлар посып ята, дигән хәбәрләрнең буш сүз түгеллеген яхшы белә Заһидулла. Шикләнүе рас икән: күләгәдәй калкып чыккан ике бәндә кинәт кенә ат башын эләктереп алалар. Менә шул чакта алтатарның кирәге чыга да инде Заһидуллага — ул шартлатып торып һавага атып җибәрә! Шартлау тавышыннан куркынган ат, күкрәге белән юл ярып, алга ыргыла. Бандитлар исә, салам көлтәседәй, икесе ике якка тәгәрәп китә.

Алтатар — яшьлек истәлеге, ир-егетлек билгесе. Заманнар бүтән, бу коралның инде дәвере узган. Ике дус саубуллашкан чакта ул, төс булып сакланыр өчен, Гафури кулына күчә.

Ә менә бер-беренә бүләк иткән күңел истәлекләре күпме аларның! Казанда яки Уфада, өйдә яки сәхрәдә, табында яки сәхнәдә дисеңме — һәркайсы акыл, хис, йөрәк белән җылытылган сәхифәләр, гомернең үзенә күрә ялтырап яткан якутлары. Кызганыч: көннәрнең берендә кеше, үзе белән бергә, дөньяның күпме хатирәләрен дә мәңгелеккә куенына алып китә. Тарихка, җырга, кеше язмышларына бәйле күпме вакыйгалар кул җитмәстәй ераклыкта — вакыт елгасы төбендә күмелеп кала...



## IV. Казанга кайту

Рус, татар, башкорт халыклары кулга-кул тотынып яшәгән Уфа шәһәре булачак композиторның язмышын, иҗат юнәлешен хәл итүдә бәрәкәтле роль уйнады. Ул, күренекле татар педагогларында укып, ныклы белем алды, туган халкының музыкасын, телен, әдәбиятын тирән үзләштереп үсте. Шулар янына нотаны белүен, пианинода уйнавын да китереп кушсак, безнең каршыбызда характеры формалашып килгән, тормышка шактый әзерлекле, сәләтле, киләчәге өмет уятырдай яшь егет басып торганын күрәбез. Иң мөһиме — күңеле саф, уйлары матур, йөрәге яхшы аның. Мондый йөрәкләр тиз яраланучан, ләкин алар үзләренең сафлыгы белән вак җаннардан өстен кала беләләр. Йөзек кашы шикелле, тормышны бизәп, матурлап, тулыландырып торалар.

Фәрит сәгатьләр буе пианино артында утыра, күзләрен йомып уйный, әйтерсең, нидер эзли, киләчәгенең сукмак очын табарга тырыша. Әтисе улына читтән генә карап соклана, башын кыңгыр салып ниндидер тирән уйларга бирелә... Тагын да алга китү өчен зуррак педагоглардан өйрәнергә, махсус музыка мәктәбендә укырга кирәк малайга.

— Улым, сиңа, һичшиксез, ары таба укырга кирәк. Телисеңме, Казанга бөтенләйгә күчеп кайтабыз. Анда Шәрык музыка техникумы бар, шунда укырга керерсең.

Казан! Фәритнең балачагы үткән таныш кала. Проломный урамнары, Ташаяк ярминкәләре белән кайнап торган газиз шәһәр. Тукайча әйтсәк, «монда мәгърифәт, монда гыйрфан, монда нур...» Шәрык белән гарепне тоташтырган бу мәркәз Яруллиннар гаиләсен тагын үзенә чакыра.

1930 ел. Җәй. Агыйдел яры. Пристань буенда икәү — кырык өч яшьлек Заһидулла белән уналтысы тулган Фәрит басып тора. Әтисе салам эшләпәдән, көрән костюмнан. Фәрит яланбаш, бер читкә кайтарылган чәчләрен кулы белән аралап куя, күлмәгенең изүләре ачык. Чемодан күтәреп килгәнлектән, уч төпләре әле дә булса кызышып тора. Ата белән баланың уйлары Казан ягына төбәлгән. Пристаньда халык кайнаша. Чемодан тоткан ирләр һәм зонтик күләгәсендәге ханымнар үз дәрәҗәсен белеп, аяк-куллары бәрелүдән сакланып кына пароход эченә уза. Өченче класслы урыннар өчен әле басмага аяк басканчы ук көрәш: иңенә капҗин, муенына клиндер бәйләме аскан апалар баскан урынында торалмый этенә, таптана, терсәкләре белән юл ярып әзаплана... Ыгы-зыгы тәмам. Пароход: «Ту-ту, ту-ту, юлга!» — дип өч тапкыр кычкырта да, тәгәрмәчләре белән суны шапылдатып, дебаркадердан аерыла.

Халык палубага чыгып баскан. Пассажирлар арасында култыклашып йөрүче парлылар да, гади халык белән бергә, бәйрәмчә киенгән көяз ханымнар да, пароходтагы аклыкка исе китеп караган бала-чагалар да бар.

Хушлашып калырга теләгәндәй, үзләре яшәгән якны чамалый биреп, Фәрит тагын бер тапкыр тау башындагы калага борылып карый.

Йортлар, яшеллек, шәһәр күренеше акрын-акрын гына артка чигенә, рәшә эченә күмелә бара. Табигатьнең бернинди яшерен көчләре дә белми әле: дүрт-биш елдан соң Фәрит Мәскәү шәһәрендә Уфадан килгән татар кызы белән танышачак. Беренче мәхәббәт дигән бу матурлык аңа өр-яңа хисләр, кадерле һәм якты дөнья бүләк итәр... Сугыш тынгач, нәкъ чирек гасырдан соң, «Шүрәле» балетының премьерасы Уфа сәхнәсенә күтәрелер... Болары — соңыннан буласы эшләр. Хәзергә исә Фәритне утырткан «Чердын» пароходы, каладан ераклашып, Агыйдел суын ишә-ишә Казанга юл яра.

Ул чакта Казан-Уфа арасында ике катлы, чибәр генә пассажир пароходлары йөри. «Чердын» пароходы капитаны Марат Әхтәмов — бик мәрхәмәтле, татар интеллигенциясен һәм музыкантларны яратучан кеше. Кирәк икән, ул аларны бушка йөртүдән, үз каютасына чакырудан да тайчанып тормый. Аскы катта буфет эшли, көнозын диярлек «кипәтүк» самавыры пар бөркеп утыра, беренче классла салонның ял бүлмәсенә хәтта пианино да куелган.

Дүрт-биш тәүлеккә сузылачак сәфәр, пассажирларның талгын тормышы менә шушы пароходта узачак инде.

## *Авторның күзаллавы*

Заһидулла белән беренче күрешүләре генә түгел, иркенрәк бер арада капитан аны үз бүлмәсенә чакырды. Сөйләшергә, тормыш хәлләрен сорашырга яратучан бу кеше янында салмак табигатьле Заһидулла да ачылып китә, үзен иркен сизә. Бүлмәсендә пөхтәлек, стенага Айвазовскийның «Тугызынчы вал» картинасы эленгән, кечерәк киштәдә китаплар тезелгән. Капитан кокардалы фуражкасын бер читкә алып куйды да өстәлгә бутерброд һәм бер шешә кымыз чыгарды.

— Казанга юл озын безнең. Иделдә су саекмаса, ничек тә бер барып житәрбез, шулай бит, Заһидулла?— дип әңгәмә куертып җибәрде.— Озаккамы, ни йомышлар белән?

— Бу юлы Казанга бөтенләйгә кайту...

— Әйтәм аны мәшәкать йоткандай күренәсең. Димәк, бөтенләйгә күчеп кайтырга булдыгыз. Әйе, туган яклар үзенә тартадыр шул. Бәндәнең табигате шулай. Менә мин үзем дә, суда озак йөрдемме, җирне сагына башлыйм.

— Туган якка тартылу да бар инде. Аннары... малай җитеп килә. Укысын, белемен зурайтсын, бәлки киләчәктә үзенә файдасы тияр дим.

— Бик мәгъкуль эш! Үзең беләсең, рәхәтләнеп укыр заман килде. Фәрит дисең бит әле... Оясында ни күрсә дигәндәй, музыкант булырга хыялланамы?

— Барып чыкса, музыка техникумына бирәсе иде үзен...

— Һичшиксез, барып чыгачак. Татар музыкасының куәт алган чагы. Салих Сәйдәшев кебек талантыбыз әнә ничек күтәрелә! Аның эшен дәвам итәрдәй егетләр кирәктер ич.

— Заманында Салихны музыкадан үзем укыткан идем... Инде менә ул да кулалмашка Фәритне кайбер нәрсәләргә өйрәтми калмас дип өметләнәм.

Заһидулланың бу уйлары тиенкы гына каядыр төптә оеп ята иде. Нишләтәсең, әңгәмә барышында әллә ничек шунда теленә үк бәреп чыкты менә.

Байтак сөйләштеләр, бу очрашу икесенә дә канәгатьлек китерде шикелле. Татар театрында Кәрим Тинчурин, Тажи Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш пьесаларының зур уңыш белән баруын да сөенеп, уртак куаныч итеп сөйләделәр. Игътибар иткән, күрәсең, сүзнең ахырындарак капитан турыдан-туры сорыйсы итте:

— Юлга Фәрит белән икегез генә чыккансыз. Әнисе күренмәде шикелле, тормышыгызда ул-бу үзгәрешләр юктыр ич?

— Ничек дип әйтергә, туган...— Заһидулла тирән сулыш алып бер-ара тынып калды. Җавап кайтарасы сүзләрен йөрәгендә озаграк тотарга теләгәндәй, ике кулын күкрәгенә кушырып салды.— Фәрит инде үсеп җитте, оясыннан очар кош булып җитлекте... Шулай икән, ир белән хатын нигә әле бер-берсен мәҗбүри бәйләп тотарга тиеш?

— Бергә калу-калмау үз эшегез, әлбәттә. Улыгызга кыен булмасмы соң?

— Без аңа күп нәрсәләрне сиздермәскә тырыштык... Эчендәген кем белгән, тыштан исә шулай кирәклеген аңлады шикелле.

Капитан, вакыт җиткәнлеген сиздереп, урыныннан торды. Вахтадагы эшләрнең торышы, экипаж эшчәнлеге белән танышыр чагы җиткән иде аның. Калын чәчләрен фуражкасы астына яшергәннән соң, бергәләп ишеккә юнәлделәр. Аерылышыр алдыннан ул милли көйләрне тыңларга теләге барлыгын белдерде, кечкә якта ял бүлмәсенә рәхим итегез, дип чакыру ясады.

Ялгыз калуы бушка китмәгән иде: Фәрит озаклап, рәхәтләнеп яр буйларын тамаша кылды. Кайдадыр төптә, дөресрәге пароходның аскы өлешендә, машина моторы тигез ритм белән тонык кына гүли. Су шавына кушылып, алар пароходка ияреп баручы билгесез, таныш түгел моңга әвереләләр, Фәрит, палуба култыксасында бармакларын биеткәләп, әлеге моңнарны кабатларга да тырышып карады әле...

Әтисе әйткән хәбәр аны тагын да ныграк шатландырды: аларның пароходында пианино бар икән ләбаса!

...Салон ишеге ачык иде. Ләкин эчкәре узар өчен яшел төстәге калын пәрдәне иң элек кул белән тотып кына ике якка аерырга кирәк. Менә шунда җитү белән Фәритнең ике битенә ут капты, чигәләренә шаулап кан йөгерде: әйтерсең, зур бер сәхнә түренә узып баруы аның... Залдагы урындыкларда берничә пассажир ял итеп утыра иде. Уңайсызланудан Фәрит салондагы тантаналы күренешне тойды да, тоймады да кебек. Якты, биек тәрәзәләрдәге пәрдәдә кичке кояшның соңгы нурлары тукталып калган. Алсу пәрдәләр алсу нурланыш белән тулы. Бүлмәнең бер почмагында, кемнеңдер куллары кагылганны сабыр гына көтеп, пианино тора. Әтисе улының тартынып торуын аңлый, шуңа күрә куәт өстәргә тырышып:

— Әйдә, яңгырын яратасың икән, чыланудан да курыкма,— диде.

Салонда тынлык урнашты. Залдагылар, нидер буласын көтеп, кызыксынулы караш белән үсмер кыяфәтле егеткә төбәлгән иде.

Клавишларга кагылу белән Фәриткә эчке тынычлану килде. Бармаклары гына түгел, җаны, тәне, бөтен күзәнәкләре пианинода уйнауны сагынып өлгергән. Бернинди көчәнү, мәҗбүрилек кирәкми, бармаклар үзеннән-үзе талпына: көй үзенә-үзе юл ярып, әле көчәя, әле салмаклана...

Бер читтәрәк утырган әтисе, сыңар кул белән ияген учлап, хатирәгә бирелә. Казан-Уфа арасында азмы булды аның уйнап йөргәннәре! Мандолиначы Миңнулла, сукыр скрипкачы Ибенәмин, шулар уртасында зәңгәр-карасу күзлек кигән гармунчы Заһидулла утыра. Милли көйләр яңгырый: үзенә күрә оркестр ясап, өчесе бер эздән сиптерәләр генә! Пассажир халкының олысы-кечесе дигәндәй берәм-берәм алар тирәсенә җыела, шәкертләр музыканы аеруча сихерләнеп тыңлый. Өчесе дә төсле күзлектән булганга, аларны күпләр сукыр музыкант дип уйлый. Әнә шулай пароходтан пароходка йөриләр. Халык хәл кадәренчә акча сала. Нишлисең бит, заман бүтән иде, нужа йөретте... Улының бүгенге уйнавы белән чагыштырып кара син — замана җәһәтеннән генә түгел, язмышлар үзгәлеге ягыннан да дөнья чаклы аерма! Әлек булса, әлегер идеме бу? Ярабби, инде шулай Фәритнең бәхет капкаларын киң ачарга насыйп итсен алла...

* * *

Безнең пароход акрын-акрын гына һаман алга баруында. Казанга кайту сәфәре... Яшүсмер күңелендә өч дөньяның кисешкән, бергә-бергә кушылып кайнаган чагы.

Беренчедән, әти-әнисе арасындагы драманы эчтән, күңеле сызып кына кичерде ул. Әйбәт кенә яшәп яткан кешеләр ни өчен көннәрнең берендә икесе ике юлдан аерылып китәргә тиеш? Хикмәт нәрсәдә? Моның сәбәпләрен этисе аңлаткандырмы-юктырмы — билгесез. Ничек кенә булмасын, тормышның чуалчык төеннәрен чишү, хакыйкатькә җавап табу мәсьәләсендә Фәритнең тәҗрибәсе әлегә җитәрлек түгел. Гаилә тормышындагы мондый кискен үзгәрешләр аның күңелендә тирән эз калдыра.

Икенчедән, көн туу белән ул тизрәк палубага ашыга, су өсте һәм яр буе күренешләрен йотылып карый. Пристань арты пристань саен каршыда катлам-катлам булып ташлы, кызыл балчыклы текә ярлар ачыла. Кара ноктадай тезелеп киткән кәрәшә оялары күзгә чалына. Уктай атылып чыккан бу кошчыклар нигә чыелдый, нинди телдә сөйләшә алар — аңламассың. Яр өстендә кайчак биек-биек манаралар, башлы суганны хәтерләткән дәү гөмбәзләр күренеп кала. Күктә утрау-утрау болытлар. Дулкыннар өстендә, су асты патшалыгына чакырып, алтын багана җемелди: кояшның судагы чагылышы әнә каян-кая кадәр сузылган! Җиһанны көнозын кыздырып әлсерәгән кояш, әйтерсең, елга өстенә ятып су эчә. Үзендәге сусауны басарга тели...

Өченчедән, туган-үскән җиренә Фәритнең бөтенләйгә кайтышы бу. Ашкынып, балачагына бәйле Суконный бистәсен, Ботан бакчасын, Кабан күле камышларын сагынып кайтуы. Инде килеп, Фәритнең киләчәге язмыш тактасына куелырга тора: музыкантлар әзерли торган уку йортына керә алырмы, юкмы ул? Бик тә таныш, кадерле Казан туфрагында нинди юллар, нинди яңа сукмаклар көтә аны? Билгесезлек белән өретелгән бу сораулар ашкындыра да, куркыта да Фәритне...

Менә зур сулы Иделгә килеп керәләр. Ерактагы ярлар, урманнар инде күгелҗем тасма булып кына күренә. Такталанып яткан саллар, карсак борынлы баржалар, эреле-ваклы пароходлар торган саен ешрак очрый. Идел үзенең киңлеге, мәһабәтлеге, колач-колач дулкыннары белән әсир итә. Кайчандыр бурлаклар Идел яры буйлап үзләренең ачы язмышын, Россиянең кара тормышын иңнәренә салып сөйрәгәннәр. Гайрәтле җилкәләрне аркан бавы кисеп кергән, өметкә сусаган йөзләрне җил һәм кояш ашаган. Идел өстендә әле һаман да бурлак җырлары, аһ-зар авазлары иңрәп тора кебек...

Ниһаять, алда Казан күренә!

Дүрт тәүлек буе тирбәлеп кайткан пассажирлар, кемдер чакырып чыгаргандай, дәррәү тулып палубага бөялә. Саксыз кылануданмы, кемнеңдер яулыгы кулыннан төшеп китә һәм дулкын кочагына күмелә. Күкне терәп торган корылмадай сураеп, Мәрҗани һәм Әҗем мәчетләре калка. Тагын да түрдәрәк, шәһәрнең иң калку урынында, Кремль агарып күренә. Шулар янәшәсендә иң биеге, иң серлесе, күңелләрне иң нык ымсындырганы — Сөембикә манарасы. Үткәннәрдән хәбәр иткәндәй, галибанә оеп, борынгыча уйланып-сагаеп утыра. Аңа карау белән моңы тирән, тарихы зур, киләчәге чиксез булган шәһәргә атлап керәчәгеңне сизәсең...

Пароход, йөрешен акрынайта да балык һәм сумала исләре аңкып торган Үсия портына килеп туктый.

## V. Үз-үзеңне җиңү батырлыгы

Жуковский урамындагы чибәр генә бер йорт үзенчәлекле архитектурасы, каршындагы юка һәм өрәңгеләр рәте белән әллә кайдан ук игъ-

тибарны үзенә җәлеп итә. Көймәләп эшләнгән зур, биек тәрәзәләр арасында ак төстәге ярымколонналар яктыра. Икенче катның фигуралы балконнары урам якка караган. XX гасыр башларында монда шәһәрнең земский идарәсе урнашкан була. Бинаның өске йөзлегеннән — түгәрәк каймалар эченнән — тәрәзәләр санынча, ягъни алты арыслан башы карап тора. Совет республикасының сәнгать әсәрләреннән үч алу гадәте юк — тарих чүплегенә очкан империянең кодрәтен гәүдәләндерүче бу символлар сакланып калган. Ярым ачык тәрәзәләрдән музыка авазлары ишетелеп куймаса, әлеге бинаның Казан сәнгать техникумы* икәнлегенә тиз генә ышанасың да килмәс.

Тарихка күз салсак, Казан музыка училищесының шәһәрдә яшәп килгән шәхси музыкаль мәктәпләр җирлегендә 1904 елда оешканын белербез. Аның төзелү тарихы Н. А. Римский-Корсаков шәкертенә — Россиянең күренекле музыка эшлеклесе, дирижер, пианист һәм композитор Р. А. Гуммерт исеменә бәйле. Ул яңа ачылган училищеның беренче директоры итеп билгеләнә.

Революциягә кадәрге заманнарда училище үз тармагында урта Идел буендагы бердәнбер культура учагы була. Ләкин патша Россиясе шартларында ул музыка сәнгатен үстерүдәге чын үзәк ролен уйный алмый, чөнки укучылары фәкать югары сыйныф балаларыннан гына торган.

Татарларга һәм азчылыкны тәшкил иткән бүтән милләт вәкилләренә бирегә әләгү бәхете турында уйлыйсы да юк. 1887 елларда ук инде илнең мәгариф министры Делянов циркуляр хат әзерли: гимназиягә һәм башка уку йортларына «кучер, ялчы, аш пешерүче, кер юучы, вак кибетче һәм башка шуның ишеләрнең балаларын якын китермәскә». Андый балаларны аллаһы тәгалә бирг н мохитләреннән бер адым да читкә чыгармаска, дигән күрсәтмә дә бирә. Бу политиканың асылын, шаять, аңлатып тору кирәкмидер.

Бөек Октябрь революциясеннән соң, музыкаль белем бирү өлкәсендә тамырдан үзгәртеп кору башлангач кына, киң катлам халык массаларына уку мөмкинлекләре ачыла. Октябрь казанышларын дөрес аңламаганлыктан, Р. Гуммерт җитәкче вазифасыннан баш тарта.

Училище 1921 елдан Шәрык музыка техникумы дип йөртелә башлый һәм аның директоры итеп дирижер, скрипкачы А. А. Литвинов куела.

Егерменче елларда ук инде техникум профессиональ музыка культурасының Казанда нык үскәнлеген күрсәтә. Опера һәм оркестр класслары тарафыннан Гуноның «Фауст», Даргомыжскийның «Су кызы», Вердиның «Аида» опералары куела. Укучылар көче белән күрсәтелгән симфоник концертлар җәмәгатьчелекнең ихтирамын яулый. Шул елларда, Татар драма театры артистлары белән берлектә, техникум педагоглары Солтан Габәши һәм Василий Виноградов язган беренче милли опера «Сания»дән зур-зур өзекләр уйнала. Вокал классларында Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләйманова, Галия Кайбицкая, Мөнирә Булатова кебек беренче татар җырчылары тәрбияләнә.

Социаль чикләүләр бетерелгән, эшче һәм крестьяннар бердәмлегенә нигезләнгән яшь, әле яңа төзелеп килүче җәмгыять әнә шундый тормыш белән яшәп ята. Училище тарихы белән азмы-күпме танышканнан соң, күз алдына китерү кыен түгел: хәзер инде бирегә музыкаль сәләте булган теләсә кем — ятимнәр йортында үскән Заһит тә, авылдан җәяүләп килгән чабаталы Мөбарәк тә, гади халык арасыннан чыккан Фәритләр дә укырга керә ала!

Әтисе улына уку йортының кайда икәнлеген күрсәткәндер, үзе белән ияртеп тә алып баргандыр, ләкин укырга керү мәсьәләсендә Фәриткә мораль ярдәмнән тыш бүтәне кирәкми: шөкер, табигый сәләт,

* Казан сәнгать техникумы — 1930 елда шәһәрнең хәзерге өч училищесын — музыка, художество һәм театр училищеларын берләштергән уку йорты була.

музыкаль фикер йөртү башлангычы житәрлек аңарда. Сәләтле яшьләрне имтихансыз-нисез генә махсус әзерлек классларына алганны. Фәритнең виолончель классына тоткарлыксыз кабул ителүе дә гаҗәп түгел.

Шулай итеп, Фәрит Яруллин студент булып китте. Укырга керү бер хәл, торырга урын да кирәк бит әле. Бәхеткә, монысы да әзер икән: Мәктәп тыкрыгы урамында, академик Арбузовлар йорты белән күрше бинада — тулай торакта яшиләр. Биек тәрәзәле, тәбәнәк чарлаклы, челтәр кәрнизле, сарыга буялган такта белән тышланган матур агач йорт. Тумышы-тарихы белән урта хәлле берәр сәүдәгәр йорты булса кирәк. Кызгылт калай түбә, тәрәзәләр Маяковский урамына карый. Торак бүлмәләр аерым, түшәмнәр биек, бер як читтә иркен зал — репетиция бүлмәсе дә бар.

Якуб Чанышевның якын кардәше, контрабаста уйнаучы Сөләйман Чанышев белән Фәрит бүлмәдәш булып китәләр. Күпмедер вакыттан соң, бүлмәдәше хәрби оркестрга эшкә күчеп китә. «Урын бушады, әйдә, минем янга кер»,— дип, Фәрит гобой классында укып йөргән Мөбәрәк Батталовны үзе янына чакыра. Алар арасында үзара ихтирам итешүгә, күңел якынлыгы һәм максатлар уртаклыгына корылган чын дуслык барлыкка килә. Тыйнаклыгы, ярдәмчел булганы өчен, гомумән, Фәритне хөрмәт итәләр. Залга чыгып рояльдә уйнаган беренче минутларда ук аны иптәшләре урап ала, сокланудан тын да алмый бирелеп тыңлыйлар. Татар төркемнәрендә дә дәресләрнең күбесе русча укытылганлыктан, Фәритнең ике телне бердәй дәрәҗәдә әйбәт белүе дә күпләр өчен гаҗәп тоела ул чакта.

Ашханәләре Комлев урамында, подвал сыманрак бер нәрсә. Яшь организмны ныгытыр өчен кирәк булган ризыкларга кытлык заман. Ипи чамалы, норма белән. Өстәлгә ите сирәк күренгән кәбестә ашы, шалкан шулпасы, тары боткасы, кайчакларда чикмәнле бәрәңге куела. Чәй урынына күп вакыт «кипәтүк» эчәләр. Колхозлар әле төзелә генә башлаган чак, Казан үзе ярлы, гамәлдә — карточка системасы. Студентлар дежурлык чиратына йөри — завхоз белән берлектә азык-төлеккә баралар, ипине дә үзләре бүләләр. Стипендия тулысы белән ашауэчүгә китеп бара.

Күнелләр көр дип мактанып булмый. Утын житмәгәнлектән, көзенкышын торак бүлмәләре аеруча салкын: өстәлдәге кара савыты бозланып-бизәкләнеп туңа, уен коралында репетицияләр ясар өчен иң әүвәл бармакларны бер-беренә озаклап ышкырга кирәк. Подвалда зур казан бар, менә шуңа мөмкин кадәр чистарак кар ташыйсың, эретәсең дә эчәргә яраклы су ясыйсың. Фәритнең, тешләрем авырта, дип зәңгелә авыруыннан зарлануы да хак... Ләкин болар гына кәеф көрлеген сындыра алмый, һәркайсының күңелен жылытып торган киләчәк бар, уку мәшәкатьләре, музыка дөньясы, күмәклек хисе һәм фидакарьлек бар.

Уйлый китсәң, ил күләмендәге кыенлыклар да аз түгел анысы, әмма тормышның куәтле агымы маяклар кабызылган киң, тирән, ышанычлы эздән ага. Әнә Кабан буена салына торган гидроэлектростанция төзелешендә кызыл комач жилферди. Шуның янәшәсенә «Беренче бишьеллыкны — дүрт елда!» дигән лозунг та эленгән. Мондый өндәмәләрне шәһәрнең тагын бик күп почмакларында очратырга мөмкин. Яңа заводлар кору өчен эшче көчләр житешми, шуңа күрә хезмәткә авылдан «сезонник»лар килә. Казанда шәһәрчә киенгәннәр дә, чабаталы авыл кешеләре дә очрый. Казан каласында трамвайлар инде электр белән йөри башлаган, сәер кыяфәтле, ялтыравык автомашиналар да еш күренгәли. Урамнарның күбесенә таш түшәлгән, дагалы атлар узган чакта тояклар астыннан очкын чәчрәп кала. Куллары сөялләнеп беткән йөкчеләр ат белән пристаньнан күмер, керосин, төрледән-төрле әрҗә һәм тюклар өемен ташый. Кайчак аркасына озынча тартма аскан һөнәрчеләр: «Пыяла куям, пыяла!»— дип кычкырып уза.

Кыскасы, игътибарлы кешенең үзенә дә, күңел күзенә дә житәрлек чуар тормыш кайный Казанда.

Унжиде яшьлек вакыт — үзеңне «зур»га санаган, асылда исә тормышның күп кенә четерекле якларын аңлап бетермәгән чак. Яшьлекнең бу сыйфаты балигълыкка аяк баскан Фәритне дә, аның сабакташларын да урап узмагандыр. Фәрит — салмак, басынкы, житди, аз сүзле, йомшак табигатьле, уйчан-моңсу йөзле. Менә шушы сыйфатларын беркайчан да үзгәртмәячәк ул. Шуңа таянып, аның холкы-фигыленә кечкенәдән үк даимилек хас булган дип әйтә алабыз. Кемнең кем икәнен тиз генә чамалый белгәнгәме, теләсә кем белән дуслашмый. Ансат кына ачылып китми, бәйрәмчәлекне, алак-шалак йөргәнне яратмый. Үзен аңламаган кешеләр өчен ул, чыннан да, серле һәм сәер тоела. Ярый, аз да сөйләшсен, ди, ләкин киләчәктә Фәрит Яруллин үзенең ижаты белән музыка телендә бик күп нәрсәләрне әйтеп бирәчәк әле.

Утызынчы еллар башында төшкән фоторәсемнән безгә талгын карашлы, жәенкерәк борынлы, калын иренле, түгәрәк йөзле унжиде яшьлек егет карап тора. Башындагы чүпрәк кепкасы бер якка янтайтыбрак куелган. Өстендә киң ачык, биек якалы көзге пальто, әллә ни түгел үзе, әмма хужасын кышкы суыклардан да саклаячак ул. Аякта сай эчле ботинка, ул чактагыча итеп әйтсәк, штиблет. Фәрит кара-зәңгәрсу төстәге толстовка киеп йөри. Авылдан килгән кайбер иптәшләре арасында аның киеме азмы-күпме шәһәрчәрәк күренә.

Әтисе улы янына хәл белергә килгәли: һич тә буш кул белән йөрмәс, студент табынына сумкасыннан тегесен-монысын чыгарыр. Андый чакларда Фәрит яктырып, сөенеп китә. Соңыннан бүлмәдә яисә бакчадагы беседкада икесе генә иркенләп сөйләшәләр.

Әнисенең дә тулай торакка берничә мәртәбә килүе мәгълүм. Әтиәнисенең аерылышуын Фәрит авыр кичерә, әмма түгелеп-чәчелеп китә торганнардан түгел — тышка чыгармыйча, күбрәк эчтән сызган, борчылган, билгеле.

Музыкага булган мәхәббәт Фәритне булачак композитор Заһид Хәбибуллин белән дә дуслаштыра. Алар, дәресләрдә алган белемнәр белән генә чикләнмичә, хәтта буш вакытларында да музыка белән мавыгалар: берсенең кулында скрипка, икенчесе рояль янына утыра — теләсә нинди көйгә импровизация килә дә чыга! Гадәттә, алар халык көйләрен алып, шуларга төрле вариация башкаралар, үзләре дә сизмәстән, кайчак музыкаль мәзәкләр дә туа икән. Техникумның тәрәзәләре ачык, шул тирәдән узып баручыларның колак салып тыңламый хәле юк.

Менә Фәрит техникумның челтәрле тимер баскычларыннан төшеп килә, аяк табаннары астында баскычлар «жырлап» кала. Урамга килеп чыгуга, Кекин йортының почмакланып килгән балконнары, асфальт өстенә перпендикуляр төшкән ярымманаралары, готика стилендәге очлы түбәләре күзгә ташлана. Чаттан борылуга, афишалар белән балкып, сул якта Татар драма театры, аннары ике ягында агачлар үсеп утырган Маяковский урамы каршылый. Урамдагы төрле авазларны тыңлыйтыңлый, Фәрит тулай торакка кайтып бара.

Бер тәрәзәле бүлмәнең уртасында өстәл, ике якта ике карават, бер як читтә тумбочка. Тәрәзәдән яктылык мул төшә, утырып дәрес әзерлим дисәң, өстәлгә икәүләп тә сыешырга мөмкин. Фәрит әдәбият дәресләрен, нәфис әдәбият китапларын укуны аеруча ярата. Әгәр шулай әйтергә яраса, аның инде кечкенә генә «китапханә»се дә бар. Уку дәреслекләре белән бергә, тумбочка киштәсендә Пушкин, Лермонтов, Тукай, Такташ һәм Галимжан Ибраһимов әсәрләре тезелеп тора.

Оеп-оеп яуган карларын яисә урам тутырып дулаган буражнарын яратса да, кышның салкын көннәрен Фәрит бигүк өнәп бетерми. Алар ничектер авыр, кайгы-хәсрәтле сурәттә истә калган.

1930 ел, 8 декабрь.

Казан халкы Һади Такташны — үзенең трибун шагыйрен соңгы юлга озатырга җыена... Мәрхүмнең гәүдәсе Мәдәният йорты* залына куелган. Халык иртәдән җыела башлый. Ул көнне техникумда да дәресләр булмый. Фәрит тә иптәшләре белән кайгылы йортка килә. Шагыйрьнең якын дусты, фикердәше Хәсән Туфан инде күптән биредә. Боек, хәсрәтле югалту ачысыннан тагын да ябыга төшкән егерме тугыз яшьлек Туфан әле венокларны рәтләп куя, әле сүзсез генә бер урында озаклап басып тора. Кисәк кенә башын күтәргән чакларда аның артка таралган кара чәчләре давыл булып тузгый шикелле. Әле кайчан гына вулкандай кайнап яшәгән, иҗат иткән Такташ бары йокыга талган сыман...

Кайгы митингысы шәһәрнең Ирек мәйданында уза. Урам тулы халык, хәрби оркестр матәм маршы уйный. Папахалы, күн пальтолы, халыкның ихтирамын казанып өлгергән яшь командир — гарнизон башлыгы Якуб Чанышев та речь тота. Язмышларындагы уртаклык чалымын күрми мөмкин түгел: берсе — штык, икенчесе каләм белән революция казанышын яклаган шәхесләр... Салкын көчәя бара, аяк астында кар шыгырдый. Шагыйрьне җәяүләп Арча кыры зиратына илтәләр. Күмү мәрасиме Якуб Чанышев китерткән солдатларның мылтыктан аткан хөрмәт салюты белән тәмамлана.

Ленин үлгән көннәрдәге кайгыны һәм салкынны да исенә төшерми калмас Фәрит. Сәгыйть Рәмиевне күмүдә катнашкан минутлар да хәтереннән узар. Инде менә тагын бер үкенечле үлем, татар халкының зур шагыйрен югалту. Рәсемнәрдә үлем — кулына чалгы тоткан явыз карчык, шәрә бер скелет итеп сурәтләнә. Ничек кенә булмасын, ул — аяусыз, кемнең кемлегенә карамастан, көннәрнең берендә кешене кояшлы-чәчәкле хәят уртасыннан йолкып ала, тәнен туфрак белән тигезли. Ләкин кемнеңдер күкрәгендә типкән җан, рух исән каладыр, кешенең гомере бүтәннәр йөрәгенә ялгана, истәлекләрдә, дөньяга кылган гамәлләрендә дәвам итә. Сугышта үлем белән йөзгә-йөз очрашачак Фәрит менә шушы хакыйкатьне иртә үзләштергән булырга тиеш. Шуңа күрә ул кыска гына гомерендә мөмкин кадәр күбрәк янарга, рухи яктан бай тормышлы дулкында яшәп калырга ашыккандыр сыман.

Техникумның икенче катына күтәрелгәч, биек коридор буйлап уң яктагы соңгы бүлмәгә керәсең. Фәрит көн дә менә шушында — виолончель классында укый һәм житди, ягымлы, гадәттә, кара пиджак һәм галстуктан йөрүче, баш түбәсендә чәче сирәкләнә төшкән Р. Л. Поляковтан дәресләр ала. Шул ук вакытта тулы битле, таза гәүдәле, күзлекле һәм акрын хәрәкәтле М. А. Пятницкая алып барган махсус фортепиано классында да укый башлый. Фәритне әлеге музыка коралларында уйнарга өйрәтүдә, аның гомуми музыкаль белемен киңәйтүдә бу ике педагогның тырышлыгы зур роль уйный.

Тама торгач, тамчы ташны тишә, диләр. Тын гына аккан чишмәләр дә тора-бара зур сулы елгага әверелә. Кулны чыныктыру, осталыкка ирешү өчен музыкант буласы кешегә һәрвакыт репетицияләр ясап торырга, уйнау күнекмәләрен дәресләрдән тыш та даими шомарта барырга кирәк. Шуңа күрә техникумда кайбер уен коралларын вакытлыча өйгә алып торырга да рөхсәт ителгән. Фәритнең дә үзенә беркетелгән виолончеле бар. Бервакыт, инструменты бозылгач, Поляков аңа грифына арыслан башы ясалган үз виолончелен биреп тора: шәкертенең күнегүләре өзелмәсен, янәсе... Яшь талантка ышаныч, өмет белән карау булмаса, мондый юмартлык, ай-һай, әләгер иде микән?

Фәрит укытучысына гашыйк: аныңча уйнарга тырышу гына түгел, хәтта аныңча язарга өйрәнү дәртенә дә бирелеп китә. Хәрефләр бербереннән аерымрак урнашкан шактый пөхтә, койрыклы стиль... Фәритнең үз кулы белән нота дәфтәренә, фронттан язган хатларына игъти-

*Мәдәният йорты — 1927 елның 4 июлендә тантаналы рәвештә ачыла. Хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы.

бар беләнрәк карасак, без анда яшьлектәге шушы мавыгуның ныгып өлгергән чалымнарын күрербез.

Инде безгә яхшы ук таныш кеше, композитор Солтан Габәши, Фәритләрне музыка теориясеннән укыта. Дүрт тавышка махсус көйләр дә яза һәм студентлардан хор оештыра. Дүрт тавышка җырлаган, гармониягә өйрәнгән татар хоры — ул заман өчен шактый зур казаныш, билгеле. Әлеге хор кайбер җырларны театрлаштырып та башкара. Әйтик, урак уру, көлтә бәйләү, ашлык чистарту яисә тимер чүкү, кирпеч салу кебек хезмәт процессларын хәрәкәт белән бәйләп җырлауны тамашачылар бик яратып кабул иткән.

Бервакыт Фәрит тулай торакка кайтып керә һәм карап-карап тора да үзенең бүлмәдәше, гобой классында укучы Мөбәрәктән сорап куя:

— Сез музыкаль ачкычларны үттегезме әле?

— Әйе.

— Музыкада ничә сорт ачкыч була?

Мөбәрәк, җавап кайтарасы урында, аңышмыйм дигәнне белдереп җилкәсен сикертә.

— Менә шул шул,— дип көттереп кенә елмая Фәрит.— Солтан абый безгә «ачкычларның берничә сорты була» дип ялгыш ычкындырды. Берничә төре, дип әйтергә кирәк иң...

Бу сүзләрдән соң Мөбәрәк тә елмая, рәхәтләнеп көлешеп алалар. Әйе, уен-көлкегә Фәритнең «вакыты» гына җитми, чынлыкта исә сизелерсизелмәс кенә юмор бар аңарда. Киләчәктә «Шүрәле» балетын, дөресрәге, туй өлешендәге мәзәк урыннарны һәм халыкның җорлыгын тасвирлаганда бу хис үзенә кирәк юлны табачак әле...

Фәритләр укыган заманны тулырак күзаллар өчен, тагын бер шәхеснең эшчәнлеген әйтеп китми ярамый. Ул — өлкән яшьтәге, абруйлы һәм тәҗрибәле педагог А. А. Литвинов. Ян-яктагы юка, озын чәчләре арасыннан зур, ләкин үзенә бик тә килешле, аның музыкаль сизгерлегенә ишарәләүче колаклар калкынып тора. Кылыч борыны, калын кашлары аны тагын да җитди, эшлекле итеп күрсәтә. Оркестр классында ул һәркемнең тою сәләтен, кул-бармакларының дөреслеген, үпкәләрнең тазалыгын тикшереп, карап ала. Студентларның симфоник оркестрын да җитәкли.

Оркестр кадәр оркестр өчен кадрлар да кирәк бит әле. Беренче елын гына укый башлаганнар арасыннан да кемнәрнедер алмый хәлең юк. Һәм менә Литвинов бүлмәдәш булып яшәгән ике дусны — Фәрит белән Мөбәрәкне оркестр коллективына чакыра. Барабанга кеше юк — Фәритне куя, бер-беренә сугып чыңлата торган тәлинкәләргә — Мөбәрәкне. «Әйдә ярар, пауза санарга өйрәнсәк тә файда булыр,— дип дустын тынычландыра Фәрит,— аннары музыкасы да колакка керә торыр». Ризалашалар. «Кайсын кайчан икәнен үзем кул хәрәкәтләре белән күрсәтермен»,— ди оркестр хуҗасы. Күпмедер тәҗрибәдән соң елмаеп ук җибәрә. Шундый җитди кеше дә елмайгач, димәк, безнең яңа «пешеп» килгән оркестрантларыбыз үзләренең бурычын әйбәт һәм дөрес башкаралар!

Литвинов, шәһәр күләмендә уйнар өчен, профессиональ музыкантлардан да оркестр оештыра. Үзенең шәкертләрен онытмаган икән ул, соңрак аларны да эшкә тарта. Шәһәр тормышының барлык оешмаларында халыкның культура дәрәҗәсен күтәрү хәрәкәте кызган вакыт. Оркестр әле паркларда, әле сезонлы эшчеләр каршында чыгышлар ясый. Егетләргә бераз гына акчасы да килә моның.

Күргәнебезчә, ныгып-күтәрелеп китү өчен Фәрит Яруллин кебек яшьләргә шартлар начар түгел. Ләкин чын музыкант булып өлгерү өчен болар гына җитәрме соң?

Дәресләр программасы тыгыз, укуда ифрат тырыш Фәритнең бер генә дә буш вакыты юк. Кайчан карама, класста рояль артында утырыр ул. Дәресләренә бөтен күңелен, сәләтен, вакытын бирә. Замандашлары сөйләвенә караганда, тулай торакта да иртә белән йокыдан таң әтәчедәй иң элек Фәрит уяна икән. Бераздан залга саркып-саркып кына виолон-

чель моңнары агыла башлый. Музыкаль тоемлау сәләтен үстерү, кул һәм бармак хәрәкәтләрен чыныктыру өчен репетицияләрне ешрак ясарга кирәк. Моның өчен тавыш гаммаларын, бер үк октава авазларын аска төшү яисә өскә менү тәртибендә озаклап-озаклап кабатлыйсың. Зур черки безләп торган шикелле, гел бер төсле озын моң чыга.

Адәм баласының табигатенә тырышлык һәм ялкаулык дигән капма-каршы сыйфатлар бердәй дәрәҗәдә тигез салынган. Кешедә шуларның кайсы ныграк өстенлек алыр — бу инде турыдан-туры үз-үзеңне җыя алу, тирәндә посып яткан көчләреңне нинди дә булса шөгыльгә мәҗбүр итә белү сәләтенә бәйле. Сольфеджионың кара тир агызырдай күнекмәләре беренче карашка гаять күңелсез, авыр шөгыль булып күренергә мөмкин. Асылда бу чынлап та шулай. Ләкин күңелең сайлап алган максатка омтылыш көчле икән, аның һәрбер кыенлыгы сиңа җиңү ләззәте, үз-үзеңне раслау, хыялга ирешү тантанасы алып килә.

Сольфеджиодан соң Фәрит, Бетховен һәм Шопен әсәрләреннән өзекләр уйнап, өйдәге дәресен тәмамлый. Студент чагында ук инде музыка Фәрит өчен тормышының альфа һәм омегасын тәшкил итә. Музыкадан башка бер генә нәрсәгә дә күңеле ятмый аның.

Берьюлы виолончель һәм фортепиано классларында уку Фәрит өчен җиңел эш булмагандыр. Яшьтәшләрең ишегалдында футбол типкән чакта кемнең генә күңеле ирек ачуга кытыкланмас икән! Боларга Фәритнең вакыты калмаган, аннары күңеле дә атлыгып тормаган. Тамчы да үкенерлеге юк: музыка дәресләрен, бәрхет тавышлы виолончельне һәм яңгыравыклы фортепиано авазларын дөньядагы бернинди рәхәтлекләргә дә алыштырмас иде ул. Зуррак максатлар куйган саен кеше үзе дә зураеп, җитдиләнеп китә, шәхес буларак иртә өлгерә. Бу кагыйдә яшьлекнең бөек максатлар белән янарга тиешлеген аңлаган Фәриткә дә тулысынча туры килә.

Техникумның актлар залына Фәрит һәрвакыт ашкыну, дулкынлану белән керә. Каршы як стенада — Бах, Бетховен, Глинка, Чайковский кебек мәшһүр композиторларның рәсеме. Үзләренең үлемсез иҗаты белән алар кул җитмәслек биеклектә тора. Күңел менә шулар дөньясына, иҗатта янып яшәгән шәхесләр үрнәгенә тарта. Оялчан, тыйнак хыяллар, кар астында яткан чишмә кебек, тын гына җанда челтери. Стена һәм түшәмгә таш чәчәкләр рәвешендә ясалган искиткеч матур нәкышләр, баш очындагы эленеп торган чуклы-бизәкле зур кандил күңелдә шундук тантаналы хис уята. Тәрәзә рамнары һәм аның тимер бикләвечләре борынгыча эшләнгән. Өске катта — вазаларга охшаш юан рәшәткә белән бүленгән иркен ложа. Студентлар концерт куйган чакларда монда, гадәттә, кунаклар һәм педагоглар утыра.

Казанда сәнгать «йолдызлар»ының иң балкыган чагы: сәхнәдә — Салих Сәйдәшев, шигърият трибунасында — Хәсән Туфан, театр сәхнәсендә — Фатыйма Ильская. Мәдәният учакларын беренче чиратта менә шулар балкыта да инде! Фәрит кеңәме соң, аның иптәшләре дә Сәйдәшев катнашындагы концерт һәм спектакльләрне мөмкин кадәр күздән ычкындырмаска тырышалар.

1930 ел башында, ленинградлылар үрнәгенә ияреп, Казанда да эшче яшьләр театры коллективы — ТРАМ* барлыкка килә. Елга аръягында — рус, ә Вахитов исемендәге завод клубында татар труппасы оеша. Татар труппасына кырыктан артык яшьләр йөри.

Заманчалыгы белән үзенә чакырып торган мондый театрга Фәритнең килеп эләгүе бер дә гаҗәп түгел. Алар, өч музыкант, триода уйныйлар. Бу җәһәттән Зәйнәп Хәйруллинаның истәлекләре игътибарга лаек.

«Көннәрнең берендә Хәким Батыршин репетициягә үзе белән бергә укучы ике егетне — Нәҗип Җиһанов һәм Фәрит Яруллинны алып килә.

---

* ТРАМ — «театр рабочий молодежи» дигән сүзләрдән кыскартып ясалган исем.

Нәҗип — рояльдә, Фәрит виолончельдә уйный. Ачык хәтерлим, Хәким, Нәҗип ул заман өчен шактый купшы киенгәннәр. Ә Фәрит — ярлырак. Аның өстендә куе зәңгәр блуза, искерәк кара чалбар. Аның конгырт чәче үзе озын, үзе куе, ничектер күпереп тора. Фәрит сөйләшми. Режиссер һәм музыка җитәкчесе әмерләрен игътибар белән тыңлый, уйный. Тәнәфес вакытларында Нәҗип һәркем белән сөйләшә, шаярта, ә Фәрит читтә. Тик игътибар белән барысын күзәтә. Әнә тамаша залының иң арткы урындыклардан соң буш калган урынында ике егет акробатик күнегүләр ясый, көч сынаша. Ә бу почмакта Мөхәммәт Садри яңа шигырьләр укый. Сәхнәдә Батыршин берничә кызга яңа җырын өйрәтә, ә рояльдән читтәрәк Фәрит виолончелен кулына тоткан да тын гына, монсу гына утыра... Репетицияләрдә булачак композиторлар белән күп тапкырлар очрашсам да, Фәрит белән кара-каршы килеп сөйләшкәнебезне хәтерләмим. ТРАМдагы беренче очрашуда мин аны тирә-юньгә игътибар итүчән, уйчан-монсу йөзле, сүзсез музыкант итеп хәтерләп калдым».

Эшче-яшьләр театрын татар профессиональ сәнгатенә нигез салучы Хәким Сәлимҗанов, Гай Таһиров кебек тәҗрибәле артистлар җитәкли. Бәхәссез ки, биредә Фәрит яңа заман сулышына ныграк якыная, музыкаль осталыгын үстерә, комсомол-яшьләр белән якыннан аралаша. Бәлки әле хореографиягә булган мәхәббәте дә нәкъ менә шушы елларда бөреләнгәндер аның.

## VI. Талантлар янында — талант

Уфадагы сабакташ дусты белән ике арада бәйләнеш сакланган, күрәсең: 1931 елның гыйнварында Хәсән Казанда булып китә, берничә тапкыр тулай торакка Фәрит янына килә. Бер елдан соң ул Казанга бөтенләйгә күчә, университетта укый башлый. (Менә бит сәнгать кешеләре белән аралашып яшәүнең көче: университетның физмат бүлеген тәмамласа да, соңыннан Хәсән Гобәйдуллин барыбер театр белгече булып китә!) Фәриткә яхшы таныш булган җизнәсе белән апасы инде күптән Казанда яшиләр. Алар хәл белергә килгән ике егетне беркайчан да кунак итмичә җибәрмиләр. Комклубтагы концертларга Фәрит белән Хәсән бергәләп йөриләр. Аларның «роль»ләре алмашына: урамда янсә сәхнәдә күренекле кешеләр очрадымы, хәзер инде Фәрит, монысы фәлән кеше була, дип горурлык белән дустына аңлатмалар бирә.

«Чаткы» кинотеатрына исә Фәрит бүлмәдәше Мөбәрәк белән бара. Кайчандыр әтисе шунда эшләгәнгә күрә, музыкант Заһидулла малае дип, аны бик тиз таныйлар. Болар биредә юк-бар кеше түгел, музыкантлар, залга билетсыз гына керәләр дә берсе — пианинода, икенчесе гобойда уйный. Егетләр үзләренең «тапер» ролендә йөрүләрен беренче кат шушында ишетеп кайталар.

Утызынчы еллар башында Татар академия театрында вакыйга булырлык зур үзгәрешләр барлыкка килә. «Зәңгәр шәл», «Ил», «Наемщик», «Кандыр буе» һәм башка спектакльләрнең гөрләп барган чагы. Күбесе — музыкаль драмалар, спектакль барышында Салих Сәйдәшев иҗат иткән искиткеч камил музыка, тамашадан аерылгысыз булган милли җырлар яңгырый. Театрга табигый рәвештә музыканың, бию хәрәкәтләренең килеп керүе, аларның идея-художество эчтәлеген ачуга хезмәт итүләре шулай ук алга китеш билгесе. Иң мөһиме: театрның хәзер инде үз симфоник оркестры бар! Аны музыкаль бүлек мөдире Салих Сәйдәшев җитәкли, үзе үк дирижерлык вазифасын да башкара. Дирижер пультына аның беренче тапкыр 1930 елның 3 январенда — «Сания» операсының яңа премьерасы куелган көнне күтәрелүен дә хәтергә салыйк. Сәнгать сөючеләрнең игътибарын, көчле магнит сыман, менә шушы мөлаем, чибәр, якты кеше тартып тора.

Сәйдәшевнең сәхнәгә чыгуын замандашы Әнәс Камал төгәл сызыклар белән болай сурәтли:

«Композитор нәфис бармаклары белән йомшак чәчләрен артка сыпырып, аны җиңелчә генә күпертә дә халыкка зур ихтирам белән баш ия. Ул, горур башын салмак йөртеп, әле бельэтажга, әле партерга карап елмая. Бер кулын икенчесе белән кыса-кыса, шул кушкулын төрле якка йөртеп, әйтерсең лә ул халыкка булган дуслык-мәхәббәтен изһар кыла...»

Театрның симфоник оркестрына да әзерлекле кадрлар кирәк. Салих Сәйдәшев, укуларыннан аермыйча гына, инде шактый тәҗрибә туплаган, барабан-тәлинкәдән — виолончель һәм гобойга кадәрле үскән Фәрит белән Мөбәрәкне үзенең оркестрына эшкә чакыра. Композитор һәм дирижер Салих абыйлары кул астына эләгү — егетләр өчен чын мәгънәсендә язмыш бүләге, музыкаль осталыкны чарлау мәктәбе. Рухи яктан баерга, оркестрдан буш көннәрдә спектакльләрне дә карарга кирәк бит әле. Әмма кесә ягы мактанырлык түгел. Егетләр кайчакта, намуска көч килмәслек итеп кенә, хәйләдән дә файдаланалар: гобойның буш футлярын кыстырып киләсең, билет тикшерүче апа рәхәтләнеп уздыра да җибәрә. Яңа тормышка дәртләндергән һәм укырга, гражданин булып үсәргә өйрәткән спектакльләрне карау яшьләргә зур йогынты ясый, аларның офыгын киңәйтә.

Татар профессиональ музыкасының шулай үсә, ныгый баруын таныганнан соң, табигый рәвештә сорау туа: тулы бер губернаны биләп торган халыкның моңа кадәр ни өчен соң профессиональ композиторлары һәм җырчылары, опера һәм балет театры, махсус хор коллективлары булмаган? Сәер хәл түгелме: татарлар ул чакта ук Россиядә иң укымышлы милләтләрдән санала, ә үзенең музыкада башка халыклар белән ярышырлык талантлары күренми диярлек. Фән, культура, экономика һ. б. тармакларда Казан ике зур дөньяны — Гарәп белән Шәрыкны тоташтыручы капка ролен үти, ә милли музыка капкалары озак дәверләр буе караңгылык бигендә томаланып яткан. Нилектән шулай бу?

Сорауларга җавап биргәнче, әйдәгез, иң элек тарихка һәм кайбер фактларга күз салыйк.

Рус һәм татар халкы арасында культура бәйләнешләре XVII гасырның икенче яртысында аеруча җанланып китә. Бу күренешнең капма-каршы характердагы ике юнәлеше күзгә ташланып тора. Беренчесе — хөкүмәтнең, рус администрациясенең татар дөньясындагы руханилар һәм феодал катлам белән якынаюы. Руслаштыруга корылган бу политика ахыр чиктә барыбер татар милли культурасын бетерүгә хезмәт иткән. Икенчесе — демократик рухтагы бәйләнешләр. Бу юнәлештә Казан университетының Шәрык факультеты, атабрак әйтсәк, XIX гасырның күренекле галимнәре К. Фукс, С. Шпилевский, И. Эрдман, Х. Фәезханов, Хәлфиннәр гаиләсе, күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри һәм башкалар зур роль уйныйлар.

Дилбегәсе патша кулында булган диннең милли сәнгатькә тупас рәвештә аяк чалып торуы — тарихта мәгълүм әйбер. Шәһит Әхмәдиев «Йолдыз» газетасында шул хактагы уйлары белән дә уртаклаша һәм бик дөрес нәтиҗә чыгара:

«Татарда руханилар сәнаигъ нәфисәдән булган рәссамлык, һәйкәлтәрашлыкны булдырмауда муаффәкъ булсалар да, мөэминнәрнең аларга булган карашларын салкынайтсалар да, музыка хакында андый ук тәэсир итә алмаганнар... «Музыка уйнау хәрам, тыңлау да зур гөнаһ, аның көе белән ләззәт табу көферлек» дисәләр дә, халыкның җыр-моңга ихтыяҗын баса алмаганнар. Чөнки рухның музыкага ихтыяҗын, омтылуын нәрсә дә бетерергә мөмкин түгел...»

Мисаллар да шуны раслый. Әйтик, «Казанские губернские ведомости» газетасының 1843 елда чыккан бер санында Казан университеты студенты Нигъмәтуллинның флейта өчен язылган концертны (композитор Бербигье әсәре) уңышлы башкаруы турында хәбәр итә. Ак белән караны

аера белик: ул, әлбәттә, югары сыйныф баласы булгандыр, әмма аның сәхнәдәге чыгышы дәлил буларак кызыклы. Шул ук газета икенче бер вакытта дегет карасы тамызудан да тартынып тормый: «Әгәр сез театрга бармагансыз икән, берни дә югалтмадыгыз: театр татар балалары белән тулган иде». Шул ук вакытта, күп кенә рус композиторларының татар көйләрен эшкәртеп сәхнәдә яңгыратулары да мәгълүм. Татарның үзеннән дә музыкаль әзерлекле зур шәхесләр чыккан. Унтугызынчы гасыр азакларында скрипкачы Исмәгыйль Аитов Казанда опера оркестрының концертмейстеры булып эшли, музыка мәктәбендә укыта. Аның Париж, Лондон, Берлин шәһәрләрендә гастрольдә булып, зур уңыш казануы билгеле. 1887 елда Наратлы авылында, морза гаиләсендә туган Мансур Солтанов Мәскәү консерваториясен «Зур көмеш медаль» белән тәмамлый һәм шәһәрнең Зур академия театрында эшли башлый. 1912 елдан ул — Саратов консерваториясендә профессор, педагогика эшенә җигелә...

Ә инде Казанның «Шәрык» клубында татар һәм рус җырларының башкарылуын хәтергә төшерсәк, чыннан да, халыкның музыкага булган мәхәббәте сүнмәвенә ышанырбыз. Шул ук клубта Г. А. Трейтер ханым хор оештыра, соклангыч тавышы белән үзе дә татар җырларын җырлый, скрипкачы И. Козлов татар музыкасын пропагандалый. Скрипкачы Гали Зайпин исә, үз фантазиясен дә кушып, «Травиата» операсыннан өзекләр башкара.

Татар җыр һәм биюләренең беренче үрнәкләре 1816 елда Әстерханда оешкан «Азиатский музыкальный журнал» битләрендә басылып чыга. XX гасыр башында композитор В. Виноградов, милли җырларга нигезләнеп, сабантуй күренешеннән беренче татар фортепиано пьесасы яза һәм 1904 елда аны үзе үк башкарып та күрсәтә. 1902 елда Кәримовлар типографиясендә «Князь Игорь» операсының (А. Бородин әсәре) эчтәлеге брошюра итеп татар телендә басылуы да күпне аңлата безгә. Икенче юнәлешне тулыландыра торган мәгълүматлар моның белән генә дә бетми әле.

Музыка хәраммы, хәләлме? Шул заман өчен бик әһәмиятле сорау! Хуш, татар зыялылары, алдынгы карашлы фикер ияләре бу хакта үзләре ничек уйлыйлар соң? Артык читкә ташланмыйча, ике генә кешенең фикере белән танышып китик.

Күренекле галим, тарихчы, гомере буе диярлек мулла киемендә йөргән, шул ук вакытта, татарлардан беренче буларак, музыка тарихын, аның әһәмиятен дәлилләп язган Шиһабетдин Мәрҗани сүзләренә колак салыйк: «Музыканың... дөрес түгеллегенә шәрган дәлил юк, бәлки сандугач кебек матур кошларның тавышларын ишетмәк вә тыңламак дөрес, вә тавышларның хайваннардан чыкмакы белән җансыз нәрсәләрдән чыкмакы арасында аерма юк... Музыкадан төп максат — төрле тавыш һәм көйләрне бер-беренә яраштырып күркәм һәм матур итеп төзү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына этәрү...»

Аңа кушылып икенче бер галим, Дөбъяз ягы мулласы Хәсәнгата Габәши болай ди: «Музыка табигатькә тәэсир итә, халыкны күркәмләндерә, вәхшилекне бетерә, канны сафлый, фикерне киңәйтә, фән күрсәтүе илә сабиттыр».

Музыканың халык тормышын, көнкүреш һәм культураны баетудагы әһәмиятен аңлаган татар кешеләре аны өйрәнү, туплау, тарату эшен башлап җибәрәләр. 1869 елда Г. Ваһапов өч йөздән артык кыска җырларны үз эченә алган «Җырулар» китабы бастырып чыгара. Фольклорчы Г. Сәйфуллин татар көйләрен җыю белән генә чикләнми, аларны «Стелла» дигән музыка коралында уйнату өчен пластинкаларга язу белән дә шөгыльләнә. Татар көйләре уелган беренче пластинкалар 1890 елларда ук күренә башлый.

Инде 1915 елда нәфис сәнгатьне сөючеләр өчен махсус чыгарылган альбомның беренче битләрен ачыйк. Альбомга кереш сүз язган Галим-

жан Ибраһимов татар халкында шушы көнгә кадәр профессиональ композиторларның булмавына тирән борчылу белдерә:

«Ашказар» вә «Тәфтиләү» нәләре русның Чайковскийлары, полякның Шопеннары була алмаган икән — моның өчен табигатькә түгел, тарихка, язмышка үпкәләргә мәҗбүрбез. Теләгән гөлнең туўы өчен орлык кына җитми, аның яхшы туфракка чәчелүе, вакытында кояш вә янгыр тиюе, таш белән, фәлән белән басылып калмавы шарт. Безнең халыкның табигатенә чәчелгән истигъдадлары — орлыклары шул шартлар булмаганнан гөл булып үсә алмый калганнар, чәчәк ату, җимеш бирүне хәтергә дә китереп булмый инде.

Музыка хәрамдырмы, юктырмы — хәзер аны тикшермиләр. Халык киң бер һөҗүм белән музыкага ташланды, аңар гомуми мәел, гомуми дәрт; яшь кызлар, яшь егетләр эчендә музыка коралларыннан берсен белүне үзенә идеал итмәгәннәр сирәк табылачак. Бу гомуми дәрт, бу гомуми мәел — т у а ч а к к о м п о з и т о р (аерып күрсәтү безнеке. **Р. Н.)** өчен суларга һава, тамыр җәяргә туфрактыр».

Гасыр башында ук нинди зирәк сүзләр әйтелгән! Күренекле әдипнең фикер йөртү тирәнлегенә, алдан күрүчәнлегенә сокланырга гына мөмкин.

Гатаулла Исхакый дигән мөгаллим 1913-1916 елларда, нота һәм мандолинага үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен, ике кисәктән торган «Нота дәфтәре» бастырып чыгара. Музыкадан татарча беренче әлифба үрнәге буларак, моңа кадәр кайнап, куерып килгән омтылышларны чынга ашыруда, халык көйләрен яңадан кайтаруда зур адым иде бу. Ике китапны бергә кушып исәпләсәк, «Нота дәфтәре»нә барлыгы илледән артык көй кертелгән.

Тарихка азмы-күпме караш ташлаганнан соң, алда куелган сорауларга җавап үзеннән-үзе табылды шикелле. Халык талантларсыз булмый. Үсүе өчен иҗтимагый-политик шартлар тудырылмаса, талант зәгыйфьләнә, яфракта килеш шиңә, һәлакәткә дучар ителә. Татарда сәнгатьнең күп кенә төрләрен, шул исәптән музыкаль культура үсешен тоткарлауда динне генә гаепләү дөресләккә туры килмәс иде. Төп гаеп — патша самодержавиесенең колонизаторлык сәясәтендә. Кайда җыр, музыка, барабан — шунда халык җыйнала, туплана, аның рухы күтәрелә. Ә бу — самодержавие өчен куркынычлы! Шуңа күрә алар музыканы реакцион карашлы мөфти һәм муллалар кулы белән тыйдыртып килделәр. Мөфтиләр — асылда патша чиновниклары, аның җырын җырлаучылар иде. Русның үзендә дә староверларны кудыртып, алар урынына кара киемле симез поплар билгеләнде. Дәрәҗәле руханиларга патша акча түли, шулай булгач, аны якламый кемне якласын ди алар?

Россия мәмләкәтендә кыерсытылган, үксез халыклар байтак иде. Үзенең бай тарихы, мең ел белән исәпләнгән матур әдәбияты, матбагасы, үз әлифбасы һәм мәптәк-мәдрәсәләре булган татар халкы исә яңа культурага нигез салуны, кайбер надан галимнәр язганча, Бөек Октябрьдән соң гына башлап җибәрмәде. Ләкин хак: 1917 елгы октябрь революциясе күп кенә халыклар язмышын куәтле елгадай урталай бүлеп ташлады, сәнгать чишмәләрен томалап торган кара ташларны читкә себереп түкте, караңгыда басылып яткан көчләргә яңа тизлек, куәт, дәртле хәрәкәт бирде. Елганың теге ягында, моңаеп кына, талантлары тиешенчә ачылмый калган Заһидулла Яруллин, Солтан Габәшиләр яшьлеге басып тора. Бу якта — яңа буын композиторы булачак Фәрит Яруллиннар, сынлы сәнгатьтә тиздән үз сүзен әйтәчәк Бакый Урманчылар яшьлеге...

Аларның иҗади язмышын тарихтан аерып карау мөмкин түгел. Даһиларны, шәхесләрне һәрвакыт заман үзе тудырган. Табигать биргән талантын инкарь итмәстән, шуны әйтергә кирәк: Фәрит Яруллинны совет дәвере үзе сорап, үзе чакыртып ала. Моның шулай икәнен алга таба без тагын да ачыграк күрербез әле.

Менә Мәдәният йортында яшь талантлар кичәсе бара. Чират Фәриткә җитә. Залдагылар белән таныштыру өчен иң әлек яшь музыкант ту-

рында кыскача кереш сүз әйтелә. Җылы һәм тәэсирле язылган бу текстны Хәсән Туфан әзерләгән булырга тиеш. Чөнки әлеге кичә аның тәкъдиме белән оештырыла.

«Кереш сүздән соң Фәрит сәхнәгә чыкты,— дип хәтерли ул чакта кичәне алып барган Шәраф Рахманкулов,— ниндидер бер тыйнаклык белән кыяр-кыймас кына рояль янына килеп, сизелер-сизелмәс кенә башын игәндәй итте дә уйнарга тотынды. Программа буенча ике генә көй уйнарга тиешле булса да, тамашачы аны кат-кат чакырып чыгарды, минемчә, ул шушы кичәдә биш-алты көй башкарды».

Тамашачы белән шыгрым тулы залда, халык белән бергә, күп кенә әдипләр, музыка осталары да утыра. Аларның байтагы сәхнә артына кереп яшь талантларны уңышлы чыгышы белән котлыйлар. Гадел Кутуй исә Фәритне кочаклаган хәлдә әйтеп куя:

— Рәхмәт, егет, гасырлар буе халкыбыз көткән композитор булып житеш. Салих абыең янына икенче булып бас...

«Эрмитаж» бакчасының ачык эстрадасында бирелгән икенче бер концерттан соң шагыйрь Фатих Кәрим, үзе дә шунда катнашканлыктан, егетнең уйнавына читтән генә сокланып утырган икән. Проломныйга таба төшкәндә иптәшләренә болай дип белдерә:

— Фәрит акыллы һәм талантлы малай булырга охшый. Ул егеттән кем дә булса чыгар... Аның кешелек матурлыгына һәм житдилегенә гашыйк булдым.

Ул елларда әле филармония юк, шуңа күрә концертлар, әдәби-музыкаль кичәләрне оештыру күбесенчә диярлек радио һәм театрлар жилкәсенә төшә. Театр шикелле үк, радиостудия дә үз тирәсенә зур талантларны җыя, яшьләрне дә шул үзәккә якынайтырга тырыша. Бервакыт студиядә, радио аша яшь көчләрнең чыгышын яңгыратасы иде, дигән сүз чыга.

— Әйе шул, тыңлаучылар өчен яңалык, ә студентларга аз гына матди ярдәм булыр,— дип, Хәсән Туфан белән Кәшифә Тумашева бу тәкъдимне хуплыйлар.

Берничә кеше катнашындагы әлеге концерт, «Ударниклар иртәсе» тапшыруына ялганып, көндезге сәгатьләрдә эфирга чыга. Концерт ошаган, күрәсең, кабатлауны сорап радиотыңлаучылардан бик күп хатлар килә. Менә акча алыр көн дә житә. Моны белгәч, Фәрит үзенең иптәше белән концерт өчен язылган акчаны алудан баш тартып маташалар:

— Бу кадәр гонорар күп түгелме? Без бит хәзергә укучы-өйрәнчекләр генә...

Аларның тыйнаклык һәм үтә намуслылык күрсәтүе ихластан булуга карамастан, Туфан белән Кәшифә ханым бу эшнең урынсыз икәнлеген аңлатырга тырышалар. Киләчәктә завод-фабрика клубларында бушлай бирелә торган концертларда да катнашырсыз, дигәч кенә яшьләр ризалашалар.

Бервакыт Фәриткә өй мәжлесендә катнашырга туры килә. Башта фортепианода, аннары виолончельдә татар халык көйләрен уйнап күрсәтә. Табында унбишләп кеше, ниндидер бәйрәм уңаеннан оешкан мәжлес бик жанлы һәм күңелле бара. Терсәкләре белән урындык жилкәсенә таянган шагыйрь Хәсән Туфан музыканы гаять бирелеп, онытылып, уйга талып тыңлый. Күмәк жырга үзе дә кушыла, хәтта кулларын дирижерча йөртә-йөртә кайбер көйләрне тәмам жаны аша үткәрә. Аның соравы буенча «Көзге ачы жилләрдә» көен генә дә шушы кичтә өч мәртәбә жырлыйлар... Илне зур, фажигале сынаулар көткән кебек, мәжлестә утыручыларның да күбесен алда катлаулы язмышлар көтеп тора. «Сибелә чәчәк» көен жырлаучы бу кешеләребез киләчәктә үзләренең дә тузганак гажыдай төрле якларга сибеләчәкләрен тоялар микән? Аларның тормышында әле ничәмә тапкыр көзге ачы жилләр исәр, кышкы зәһәр буран битләрне кисәр — тик сугыштан соң, фашизмны тар-мар иткәч, болай бергәләшеп жыйналу насыйп булмас аларга...

Хәзер инде Фәрит төрле концертларда ешрак катнаша, язучылар һәм артистлар арасына, сәнгать дөньясына һаман саен ныграк үтеп керә. Коллективта үзен бик гади тота, аз сүзле, салмак, тымызык, уйчан. Ләкин бу һич тә гамьсезлек, битарафлык, тирә-юньгә игътибарсызлык билгесе түгел. Шулай бит ул: инешнең төптәге комы да күзгә бәрелеп тора, ә диңгез төбен кешеләр беркайчан да күрә алмыйлар. Фәриттә дә чит күзләрдән яшерелгән киеренке эчке тормыш бара: кайдадыр күңел төпкелендә уйлар, хисләр, заман агышы кисешә, фикер давыллары уяна. Бала чагыннан ераклашкан саен ул олыларча фикер йөртү биеклегенә ныграк якыная. Тулышасы ай шикелле, аңарда акрын өлгерү бара. Кешелек бәгырендә әллә ничаклы моңнар хәзинәсе күмелеп ята. Алтынны юып тапкан шикелле, күңел көчен сала-сала, киләчәктә менә шуларны эзләп табасы бар аның.

Җәмгыять тормышындагы күтәренкелек, социаль һәм рухи үзгәрешләр Фәритне чын мәгънәсендә үзенә бөтереп ала. 1932 елның җәеннән ул — Татарстан радиокомитетында пианист-аккомпаниатор. Менә шул елларда инде аның республика музыкаль культурасын үстерүдәге, милли моңнарны халыкка җиткерүдәге яңа эшчәнлеге башлана.

Татарстан радиокомитеты Карл Маркс урамындагы өч катлы зур, күркәм бинага урнашкан. Стенасында — биек көзгеләр, килеп керү белән шундук төс-кыяфәтеңне чамалыйсың, үз-үзеңә эчке ышаныч беркетәсең. Мәрмәр баскычлар сине йөздереп кенә өске катларга алып менә. Почмактагы борылышта пальма сыман зур яфраклы гөлләр үзләренчә уйланып, моңаеп утыра. Кемнеңдер куллары мондагы матурлыкны кайгырткан, күзне иркәләп торсын дип гөлләр үстергән икән — алар яныннан битараф кына узып китә алмыйсың.

Бу йортның парадный ишекләре туктаусыз диярлек ачылып-ябылып тора. Килеп йөрүчеләрнең кемнәр икәнлеге билгеле инде: музыкантлар, җырчылар, әдипләр, драма артистлары — кыскасы, республиканың күренекле осталары, сәнгать әһелләре. Ишекләре ябык булуга карамастан, репетиция вакытында бүлмәләрдән скрипка, думбыра, курай, гармун һәм җыр авазлары ишетелеп тора. Икенче бер почмактан симфоник оркестр моңнары түгелә. Үзалдына тонык кына гөжләп торган бу бинаның диварлары, әйтерсең, тоташтан моңга манчылган!

Фәрит рояль артына утыра. Нотага салынган үрнәкләр аз булу сәбәпле, халык көйләренең күбесен ул хәтердән уйный. Әле нотага теркәлеп тә өлгермәгән йөзләгән көйләрне Гөлсем Сөләйманова, Газиз Әлмөхәммәтов, Мәрьям Рахманкулова, Ситдыйкъ Айдаров кебек танылган җырчылар «һава»дан карап дигәндәй башкаралар. Фәйзи Биккинин төрле зурлыктагы гармуннары белән мәш килә. Мөхәммәт Яушев үзенең җан «дусты» булган скрипкасын кулына тоткан.

Икенче бер көнне биредә Фәритне «имтихан»га килгән егетләр-кызлар каршылый. «Микрофон алдында — радиотыңлаучылар» дигән концерт программасын төзү мәшәкатьләре башлана. Музыкаль редакция җитәкчеләре дә җыйналган. Төрле урыннан, завод һәм фабрикалардан килгән яшьләр арасыннан иң сәләтле җырчыларны, төрле музыка коралларында уйнаучыларны сайлап алырга кирәк. Табигый тавыш белән күңелгә хуш килердәй итеп башкаручыларны ярата Фәрит. Андыйлар җырлаганда онытылып, канатланып китә.

Кайбер талантсызлар, ничектер иләктән узып, концерт программасына да эләгәләр икән. Гадәттәгечә, концертта катнашучыларны тагын бер кабат күздән кичергәндә, Фәрит музыкаль редакция бүлегендә эшләүче Зәйнәпне үз янына дәшеп ала да колагына әйтә:

— Әнә теге кыз икенче тапкыр монда килеп йөрмәс, мөгаен. Мин аңар хәзер ша-бемоль тональностендә уйныйм, икенче җырламаслык итәм.

Мондый алымнарны Фәрит яхшы ният тән — сәләтсезлекне вакытында туктату, эфирга зәгыйфь моңнарны чыгармау теләге белән эшләгән.

әлбәттә. Әйе, беренче карашка басынкы гына тоелган бу кеше кирәк урында үз мөнәсәбәтен сиздерү, үз фикерләрен ахыргача яклауда катгыйлык та күрсәтә белгән.

Тәнәфес араларында, өченче катның балконына чыгып, тирә-юньне, шәһәр тормышын күзәтергә мөмкин. Уң якта, каршыда гына диярлек, Ирек мәйданы. Күкне кыйгачлап күгәрченнәр оча, алар мәйдан читенә дә төшкәлиләр. Аяк астында җәйрәп яткан урамнар югарыдан караганда кечерәеп, тротуардагы агачлар тәбәнәкләнеп калган кебек. Бер-беренә юл бирә-бирә атлар, машиналар, җәяүлеләр узып китә. Тормыш бер урында таптануны яратмый, ул һаман хәрәкәттә, кайнамакта, алга баруында. Зур бәйрәм якынлашканы әллә каян күзгә ташланып тора: йортлар, урамнар кызыл әләм, транспарантлар белән бизәлгән. Гүя, шәһәргә кызыл канатлар үсеп чыккан, шулар белән талпынып, ул талгын гына үзенең киләчәгенә йөзеп бара шикелле.

1932 елның 7 ноябре.

Шанлы бәйрәм хөрмәтенә яңгыраячак концертка ныклы әзерлек бара. Бүгенге концерт аеруча дәртле, күтәренке рухта булырга тиеш. Репетициядә катнашучылар, махсус тәнәфес ясап, студия бинасының челтәрле балконына чыгып басалар. Фәрит Яруллин да шулар арасында.

Урам тулы халык. Бар җирдә бәйрәмчә тантана. Әнә, Бөек Октябрь революциясенең унбиш еллыгына багышланган демонстрация колонналары саф-саф булып Ирек мәйданына керә. Аллы-гөлле шарлар белән кушылып, һавага «Ур-ра!» авазлары чөелә. Колонналар өстендә — ал байраклар урманы. Иң алда пролетариат юлбашчысы Ленинның комач белән каймаланган зур сурәте балкый. Үзе төзеп калдырган Татарстан республикасын, аның иң яхшы улларын һәм кызларын, әйтерсең, бергә-бергә туплап, алга әйдәкләп бара ул.

Комклуб каршында хәрби оркестр марш уйный. Барабан һәм торбалар тавышы һаваны тетрәтә. Шушы тантаналы, күтәренке авазлар астында колонна киләчәк капкаларына таба уза.

Кинәт... күзләрдән яшь китерерлек яңа бер күренеш: адымнарын нык басып, кулларын тигез селти-селти мәйданга игезәк яшьләр килеп керә! Алар, чыннан да, Ватанның игезәк улларын һәм кызларын хәтерләтәләр: һәркайсында — кызыл йолдызлы буденовка, күкрәкләрендә кызыл бант балкый. Әйтерсең, әле генә утлы яу эченнән чыкканнар да, яраларын бәйләп, инде илнең удар төзелешеләренә китеп барышлары. Әйе, Кызыл Армия һәм аның шундый варислары булганда яңа тормышны буарга теләүчеләрнең кара нияте барып чыкмас! Яшь совет дәүләтенең нигезен ачлык та, өч елга сузылган гражданнар сугышы да какшата алмады. Социализм бөтен фронт буйлап һөҗүмгә күчте: авыллар, күмәк хуҗалыкка оешып, билен турайта, халык укырга-язарга өйрәнә, чыра яктысына алмашка Ильич утлары килә...

Сафлар шуны сөйли, сафлар шуны аңлата.

«Кызыл Татарстан» газетасы хәбәр иткәнчә, тиздән «Фордзон»ны совет маркалы беренче тракторлар алыштырачак... Тормышның көннән-көн яңара баруы Фәритне зур эшләргә дәртләндерә. Заманга тиң яңа җырлар, маршлар язасы килә аның, тик әлегә профессиональ белеме, музыкаль тәҗрибәсе җитәрлек түгел.

Радиокомитетта эшләү Фәрит өчен икеләтә отышлы булгандыр. Беренчедән, азмы-күпме матди якны кайгырта ала — студент егет өчен анысы да мөһим. Икенчедән, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Фәйзи Биккинин кебек күренекле музыкантлар, сәнгать дөньясы белән даими аралашырга мөмкинлек ачыла аңарга.

Кауры́й сыман көпшәк болытлар беркайчан да давыл ясый алмый. Яшен болытлары очрашса гына һавада яңа бер көчәнеш, яктылык, авырлык, көчле хәрәкәт барлыкка килә. Сәнгатьтә дә шулай: яңа талантның, үз сукмагын югалтмаган хәлдә, тагын күп кенә башка талантлар орбитасына да килеп эләгүе мәҗбүри. Бу аны туендырып, үсендереп тору

өчен кирәк. Кеше үзе дә белми торган эчке көчләрне хәрәкәткә китерү өчен кирәк бу.

### *Авторның күзаллавы*

«Эрмитаж» бакчасы. Җәйге ачык сәхнәдән концерт моңнары түгелә. Халык бик күп, урыннар җитмәгәнлектән, аларның күбесе аягүрә басып тыңлый. Тамашачылар арасында Салих абыйлары да булган икән, концерт бетүгә ул сәхнә артына кереп яшьләр белән күреште. «Булдырасың, егет!» дигәндәй, Фәритнең аркасыннан ук сөеп куйды.

Салих абыйның театрдан гына килеше, ахры, муеныңдагы кара күбәләген салырга да өлгермәгән. Ачык маңгай, сөйкемле күзләр, кабарынкы чәчләре исә артка тарап куелган. Елмаймаган чакта аның йөзеннән болай да менә-менә түгеләм дип торган ягымлылык тагын да мулрак бөркелә башлый. Бу кешене эчтән ниндидер табигый бер сафлык яктыртып тора шикелле. Үзеңдә шундый елмаюны йөртер өчен нәкъ менә Салих Сәйдәшев булып туарга кирәктер, мөгаен.

Ул Фәритне читкәрәк алып китте дә үзенең фатирына кунакка чакырды. Бакчадан бергәләп чыктылар да сөйләшә-сөйләшә театр урамына борылдылар. Әңгәмә дияр иден моны, кулларын алга суза төшеп, күбрәк Салих абыйсы сөйли. Фәрит «әйе», «юк» кебек сүзләр белән җавап кайтаргалый. Аны яшьлеге, тыйнаклыгы да тотып тора. Шундый кеше белән янәшә атлау — зур бәхет, бәлки, юк-бар сораулар белән борчыганчы, аның сөйләгәннәрен тыңлап бару күпкә хәерлерәктер әле.

Салих абыйсы бүгенге концертны игътибар белән тыңлаган икән, үзенчә нәтиҗә дә ясап куйды:

— Сөенечле хәл, музыкабызда да сәләтле яшьләр үсеп килә. Халыкның гомерлек хыялы иде бу. Күрәсеңме, ничек итеп кул чабалар, сәхнәгә кабат-кабат чакыралар... Синең уйнавыңны да яратып тыңладым. Алда ниләр булмас әле, киләчәгең өметле синең, туганкаем.

Танылган композитордан шундый сүзләр ишетү күңелле дә, уңайсыз да шикелле. Алай ук мактарлык ни эш майтарганы бар аның? Менә үзең дә көйләр язсаң,' шуларны сәхнәдә үзең чыгып уйнасаң икән ул...

Аулак сәгатьләр икән — Сәйдәшевның өендә берәү дә туры килмәде. Салих абыйсы чәй куйган арада Фәрит өй эченә күз йөртеп чыкты. Берәр рәссамның бүләгедерме, стенада кыр чәчәкләре сурәтләнгән картина эленеп тора. Икенче якта саргая төшкән эреле-ваклы фоторәсемнәр. Сәгать гере тәмам авырайган, аяклы этажерка өстендәге китапларга менә-менә орыныргa җыена төсле. Һәм, әлбәттә, Фәритнең игътибарын аеруча җәлеп иткән нәрсә композитор көн дә уйный торган чем-кара пианино иде. Хуҗасының илһамлы минутлар кичергән, яңа көйләр иҗат иткән бәхетле чакларын ул гына яхшы хәтерлидер...

Чү! Тәрәзәдән кояш нурлары төшкәнгәме, өстәлдә серле нурланыш белән таякчык балкып ята. Дирижер таякчыгы. Салих абый аны, бик кадерле нәрсә сыман, өстәл түренә үк куйган. Яшел бәрхет кисәге өстендә кара сызыктай ярылып яткан таяк егеткә могҗизалы тәэсир итте. Шушы кеп-кечкенә нәрсәгә әллә ничаклы моңнарны актарып салырлык көч, тылсым яшеренгән ләбаса. Өнсез-телсез яткандай тоелса да, Салих абыйсының кулларына эләктеме, ул тулы бер оркестрны дәррәү хәрәкәткә китерә: урман шаулай, диңгез кубарыла, күкләр елый башлый... Әллә кайдагы әкиятләрдән эзлисе юк — тылсымлы таяк, үзенә ымсындырып, кул тотам ераклыкта гына ята...

Караклык өстендә тотылгандай, Фәрит сискәнеп китте. Салих абыйсының чылбырыннан тарта-тарта сәгать герен өскә күтәртүе икән. Ул үз уйларына йомылган иде, ахрысы, Фәрит янынннан сүзсез генә узып китте дә пианиносы каршына утырды. Беренче аккордлар өйдәге тынлыкны таркатып ташлады... Сәйдәшевнең уйнавы моңлы, тәэсирле иде. «Туган тел» моңнары йөрәкне телем-телем кискәли кебек, әллә рәхәтлек,

эллә авырту бу — аңламассың. Көйнең алдына төшә-төшә колак төбендә бик тә таныш, сөекле сүзләр яңгырый:

> И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
> Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы...

Уйнап бетергәч тә моңнар яшәвен дәвам иттеләр. Шуларны рәнҗетергә теләмәгәндәй, композитор тагын күпмедер сүзсез утырды, аннары гына күтәрелә төшеп Фәриткә борылды:

— Беләсеңме, шушы көйне уйнаган, тыңлаган саен яңадан тугандай бер халәт кичерәм мин... Халкыбызның күңел сафлыгын, сагышларын, телебезнең бөеклеген гап-гади моңнар белән әйтә дә бирә бу җыр. Әйе, халыкта моң ияләре җитәрлек булган... Менә кемнәрдән өйрәнү кирәк безгә.

Чәй дә өлгергән икән, кунагы каршына чынаяк-тәлинкә куеп, ниһаять, Салих абый үзе дә табынга утырды. Кайнар чәй янына йомры савытта шикәр дә куелган иде, мондый тансык нәрсәне Фәрит кечкенә-кечкенә итеп кабарга тырышты. Салих абыйсы тартынмаска кушты, «бер утыру — бер гомер» дия-дия кунагының тормыш хәлләрен сорашты, заманында Фәритнең әтисеннән ничек итеп беренче дәресләр алганын сөйләп күрсәтте. Аннары елмая төшеп болай диде:

— Кайтарасы бурыч булып һаман да җилкәмдә тора ул. Ләкин мөмкинлек кенә юк, син инде музыкада тәмам аякланып беткәнсең...

Бу сүзләрне арттыру шикеллерәк кабул иткәнгә күрә, Фәрит тыйнак кына җавап кайтарды:

— Алга таба да укыйсы, өйрәнәсе иде, Салих абый. Композиция буенча хәзергә белемем бик сай тоела.

— Шулай, дөрес уйлыйсың, энем. Сиңа гынамы, алга таба безгә дә бик нык укырга кирәк әле. Заман шуны сорый. Ә беләсеңме, Мәскәү консерваториясендә ачылган рабфактан да кулае юк синең өчен. Уйлап йөр әле, бәлки, шунда тәвәккәлләү хәерлерәктер...

Музыкага җаны-тәне белән бирелгән Салих Сәйдәшев милли музыкабызның үсеше, киләчәге хакында сөйләгәндә тагын да җитдиләнеп, дәртләнеп китте:

— Үзең беләсеңдер, бездә хәзер кайнар бәхәсләр купты. Янәсе, татар музыкасының үсеше нинди юлдан барырга тиеш? Бик вакытлы һәм урынлы сорау. Берәүләр безне искелеккә кул селтәргә, рус һәм европалылар үрнәгенә кушылырга чакыра. Икенчеләр «европалашу»дан сак булырга, милли кысалардан читкә чыкмаска өнди. Миңа калса, дөреслек менә шуларның уртасында шикелле. «Гөлҗамал», «Карурман» кебек җырларыбызны ни җаның белән искелек дип атарга мөмкин? Аларда — халыкның гасырлар буе сакланып килгән моңы, язмышы, хәсрәте, мәхәббәте. Болардан йөз чөерү ахмаклык булыр иде. Шул ук вакытта без нигә әле башка халыкларның алдынгы культурасын өйрәнүдән куркып калырга тиешбез? Милли чикләнгәнлек шулай ук ярлылыкка китерә. Бирелә иң мөһиме — чама хисе, әсәрнең табигый яңгырашта булуы... — Бу урында Сәйдәшев, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, берара туктап торды.— Бородинның оркестр өчен язылган «Урта Азия»сен тыңлаганым бар минем. Дала. Бушлык. Менә шушы киңлеккә берзаман шәрык моңнары, аннары рус көйләре агылып керә. Шуларның бербөтен булып кушылуы, тора-бара әкрен генә сүнә, еракалаша баруы, беләсеңме, нинди тәэсирле күренеш тудыра! Хәер, моны аңлатып булмый, моны тоярга гына мөмкин... Нәрсәдә калдым соң әле? Әйе, милли музыкабыз, үз йөзен саклаган хәлдә, башка халыклар туплаган тәҗрибәгә дә таянырга тиеш. Боларны сиңа киләчәктә уйланып карау өчен дигәндәй әйтүем.

Ике-өч сәгатькә сузылган бу очрашу Фәритнең күңелендә тирән эз калдырды. Хыялында әле кыр чәчәкләре чайкала, әле дирижер таякчыгы нурлана, әле герле сәгать «тек-тек» килеп Салих абыйсы әйткән сүзләрне колагына пышылдый...

* * *

Үзенең биографиясен Солых һәм Җир турындагы декретлар белән башлап җибәргән совет власте талантларга юлны киң итеп ачты. Тормыш кырларының туфрагы һәм һавасы яңа фикер белән ашланган, халыкчанлык рухы белән сугарылган иде. Табигать тарафыннан Фәриткә «вакытында» туа белү бәхете эләкте — монысын да истән чыгарырга ярамый.

Фәрит Яруллинның Казанда укып йөргән дәвере тәмамланып килә. Ул инде мөстәкыйльлеккә, активлыкка өйрәнде, музыкант өчен кирәкле белемнәрне алды, милли сәнгатьнең үзәгендә кайнарга да өлгерде. Профессиональ һәм әхлакый яктан үз-үзеңне камилләштерү юнәлешендә менә дигән мәктәп узды. Кечкенәме-зурмы, тарихтагы барлык хәрәкәт алга бару белән билгеләнә. Фәритнең акрын, ләкин ышанычлы адымнар белән алга барышы. Фәкать шушы сукмагы аны олы тормышның тагын да зуррак тырышлык, яну, фидакарьлек сорый торган урләренә алып менәчәк.

Сәнгать күгендә яңа йолдыз кабынып килә. Әлегә аның яктысы үзе тирәсеннән еракка төшми. Ләкин, көннәрнең берендә атылып сүнгәч тә, кешеләргә нур сибүдән туктамаячак якты йолдыз бу.

Омтылыш үзенекен итә: тиздән ул, күп кенә талантлы музыкантлар белән бергә, Мәскәүгә укырга китә.

## VII. Зур корабка — олы дәрья

Фәритне Мәскәү үзенең зурлыгы, бер-берсен кабатламый торган биек йортлары, әле исемнәре дә таныш булмаган таш урамнары, болындай иркен мәйданнары, лабиринтны хәтерләткән тар тыкрыклары, бай архитектурасы белән таң калдыра.

Көн тудымы, Фәрит Герцен урамындагы унөченче йортка ашыга. Музыкаль сәләтен тыңлап-тикшереп караганнан соң, Мәскәү консерваториясе каршындагы рабфакка бертавыштан кабул итәләр аны. Консерваториянең җиз тоткалы авыр ишекләре егеткә шактый ансат ачыла. Ул Б. С. Шехтер классында яңа фәнгә — композициягә өйрәнә башлый.

Консерваториянең Зур залына килеп эләксәң, үзеңне дә зур итеп сизми хәлең юк. Фойеда сине рәт-рәт тезелгән мәһабәт ак колонналар каршылый. Алтын йөгертелгән култыксалар, мәрмәр баскычлар югарыга — концерт залына алып менә. Дугаланып төшкән якты, биек, иркен сәхнә. Шуның түренә орган куелган. Шәм кебек төз торбалары, агач манаралар төгәлләнеше белән ул тылсымлы бер корылманы, гүзәллек сараен хәтерләтә. Музыкадагы уен коралларының алласы шушы була инде. Үзендәге моң дәрьясын, җир һәм күкләрне сөйләштерердәй кодрәтне кайлардан ала икән ул? Залның эчке архитектурасы музыкадагы гүзәллеккә тәңгәл: амфитеатр балконнары, ишек йөзлекләре, тәлгәш-тәлгәш шәмдәлләр дисеңме — алар һәммәсе дә антик чор билгеләре, мифик образлар, имән яфрагы һәм тасмалар белән бизәлгән. Стенага мәгарәдәй уелып кергән аулак ложалар серле куышны хәтерләтә. Түшәм өслегендә — йөзек кашыдай кабарып чыккан яссы люстралар. Амфитеатрның гөмбәзле тын тәрәзәләре тышкы дөньяга карый. Менә шул урында бөек композиторларның рәсемнәре белән очрашасың: Чайковский, Бетховен, Глинка, Бах, Моцарт, Даргомыжский, Римский-Корсаков, Вагнер, Бородин, Мусоргский, Шуберт, Шуман, Шопен, Рубинштейн. Барлыгы ундүрт исем, музыка дөньясында һәркайсы яңа «тәрәзә» ачкан зур шәхесләр. Аларның карашы әйтә кебек: «Музыкага җаның-тәнең белән бирелгәндә генә җиңүгә ирешергә мөмкин. Син шушы авыр көрәшкә әзерме?»

Бу залга беренче тапкыр аяк басканда, ихтимал, Фәрит әнә шун-

дыйрак хисләр кичергәндер.

Студентлар шәһәрчеге Ржев вокзалы белән янәшә генә диярлек. Тулай торакка кайтып-китеп йөргән саен юллары вокзал тирәсеннән уза. Барган уңайга халыкның кырмыска күчедәй кайнашуын, йөкчеләрнең тыз-быз ашыгуын, паровозларның эш атыдай пар бөркеп пошкыруын күзәтергә мөмкин. Фәлән поезд фәлән сәгатьтә китә, кебек белдерүләрдән соң кайчак: «Гражданнар, кесә каракларыннан сак булыгыз!» — дигән кисәтүләр дә яңгырап куя. Төнге поездлар кычкыртып узганда, кичләрен тулай торак тәрәзәсенә моңсу авазлар килеп кагыла... Кече Дмитриевский тыкрыгындагы бәләкәйрәк кенә бер бүлмәдә дүртәү яшәп яталар: Фәрит Яруллин, Заһит Хәбибуллин, Газиз Сөләйманов, чуваш егете Геннадий Воробьев. Заһит Хәбибуллин — бүлмә старостасы. Ул, вак-төяк вазифаларны үтәү белән бергә, инструментта уйнау чиратына да күзәтчелек итә. Үзе уйнаганда чит кешенең тыңлап утырганын бигүк яратмаганга күрә, дәрес әзерләү өчен Фәрит аулак сәгатьләрне сайларга тырыша. Мондый чакларда онытылып, ялгызың калып, үзең тудырган яңа бер дөньяда яшәп алырга мөмкин. Ашаулэчү дан түгел, кайчак берәр булка янына кипкән балык сатып алалар да шуны тартып-сузып көн буена житкерәләр. Тормышның, юрганыңа карап аягыңны суз, дигән кырыс кагыйдәсе Казанда чакта анда-монда эшләп бераз иркенлеккә өйрәнә башлаган Фәритне яңадан мохтаҗлык кысаларына куып кертә. Ярый, рәхәтлеккә караганда мохтаҗлык дигәнең кешене күбрәк нәрсәгә өйрәтә, дигәннәр бит. Аннары, укуга муеннан чумганга күрә, Фәритнең күңел төшенкелегенә бирелергә әллә ни вакыты да юк.

Консерватория тиз арада туган йорт шикелле изге, якын, кадерле бер нәрсәгә әверелә. Нишә килсәң дә, ул сине кырыс ягымлылык белән каршылый, белемгә сусаган күңелләрдә дәрт һәм күтәренкелек уята. Биек-биек көзгеләре янынннан узганда сурәтеңне күрәсең дә үз-үзеңә читтән карап алгандай буласың: бу изге йорт фатихасына тап төшермәссеңме, янәсе... Икенче каттагы диварга Репинның «Славян композиторлары» дигән мәшһүр картинасы эленгән. Бу рәсем яныннан да тыныч күңел белән узып китү мөмкин түгел: русның даһи музыкантлары, әйтерсең, һәр адымыңны күзәтеп, бәяләп торалар. Тышкы зал түрендә — Николай Рубинштейнның бөтен буйга эшләнгән ифрат зур портреты, аның бар кыяфәтеннән һәм күзләреннән уйчанлык, тимер ихтыяр көче ташып тора.

Сыңар аяклы өстәл буламы, дип сорасалар, әлегрәк мондый сүзне Фәрит елмаеп кына уздырыр иде. Ә хәзер узган-барган саен карап үтә: фойедагы түгәрәк өстәлнең аягы агач төбенә охшатып эшләнгән, өстәл чынлап та сыңар аякта утыра кебек...

Консерваториянең Зур залы төп корпустан санала. Репетиция һәм уку класслары исә Кече зал бинасына урнашкан. Класс бүлмәләре, тавыш йотылсын өченгә, махсус материал белән тышланган. Класс саен рояль, инструмент авазлары яңгыраганны азмы-күпме киметү өчен ишекләр ике катлы итеп эшләнгән. Опера класслары зур, иркен, хәтта кечерәк кенә сәхнәсе һәм тыңлаучылар өчен утыргычлары да бар аның.

Рабфакта Фәрит нибары сигез ай чамасы укый, музыкаль белемен тирәнәйтә. Әсәрләр язып карау теләге егетнең күңелен көннән-көн ныграк били. Дөрес, белем ягы әлегә һаман да чикле аның, ләкин шушы вакыт эчендә Фәрит Яруллин беренче җырларын, романс, скрипка һәм фортепиано өчен кечкенә күләмле әсәрләр иҗат итә башлый. Иҗади дулкында яшәүнең зурлыгын, хозурлыгын, үз-үзеңне табу ләззәтен татый. Мең авазлы дөньяга синең дә үз җырың килеп кушылсын әле — шатлык түгелмени бу! Җырлар язганда Фәрит Габдулла Тукай һәм Һади Такташ шигырьләрен аеруча яратып файдалана, Әхмәт Ерикәй иҗатына да мөрәҗәгать иткәли. Беренче әсәрләр... Алар нинди булды икән соң? Кызганыч ки, беренче тәҗрибә үрнәкләре сакланма-

ган. Аларның өйрәнчек булуын, художество кыйммәте артык зур түгеллеген автор үзе дә аңлаган, күрәсең.

Гаҗәп хәл: тизрәк композитор булып җитлексен, зур шәхесләр белән аралашып яшәсен өчен язмыш Фәрит Яруллинга үзенең капкаларын киң ачып куя...

Милли культураларның үсүе, чәчәк атуы өчен бәрәкәтле туфрак салынды дигән идек. Ләкин, милли составтан тиешле кадрлар әзерләми торып, сәнгатьнең бер генә төрен дә алга җибәрү мөмкин түгел. 1934 елны Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында беренчеләрдән булып Татар дәүләт опера студиясе ачыла. Ил тарихында беренче милли студия... Ул үз тирәсенә татар халкының иң талантлы вәкилләрен туплый, иҗади аралашу һәм культура үзәгенә әверелә. Үзенең «Татар опера театры» дигән мәкаләсендә Муса Җәлил болай дип язды:

«Бу студиянең төп бурычы — булачак татар опера театрына җырчы һәм композитор кадрларын хәзерләү иде. Студиягә укучылар җыю өчен Татарстанда консерваториянең һәм Казан музыка уку йортының белгечләреннән торган махсус комиссия эшләде. Ул яшь җырчы көчләрне барлады, аларга сынаулар үткәрде. Студиянең беренче төп составы аңарчы Татар дәүләт академия театрында уйнап килгән һәм радиода эшләгән җырчы артистлардан, җыр өлкәсендәге зур хезмәтләре белән татар халкына киң танылган җырчылардан һәм музыка техникумының талантлы яшь көчләреннән тупланды. Җырчылар белән бергә, Татар студиясе Мәскәү консерваториясендә һәм Мәскәү музыка техникумында укучы татар композиторларын, шулай ук аңарчы Казанда эшләп килгән композиторларны үз тирәсенә җыйды».

Шулай итеп, рабфак белән саубуллашкач, Фәрит Яруллин Татар опера студиясендә укый башлый. Уку программасы тыгыз, катлаулы, бай эчтәлекле.

Композитор өчен кирәкле булган белемнәрне Фәрит профессор Генрих Ильич Литинскийдан ала. Егерменче гасыр башында ук туган бу кешенең язмышы шактый кызыклы. Очраклы хәл булмаса кирәк: беренче музыкаль әсәрләрен ул Бөек Октябрь революциясе елында яза башлый. Мәскәү консерваториясен алтын медаль белән тәмамлаганнан соң совет музыкаль культурасын төзү эшенә актив кушылып китә. Төрле милләтләр музыкасындагы интонацияләрне оста файдаланып, балет һәм опералар иҗат итә. Уртача буйлы, җиңел хәрәкәтле, ачык йөзле, турыозынчарак борын өстенә пенснэ элгән, житди кыяфәтле бу профессорга табигать тагын бер зирәклек бүләк иткән: кешедәге талант һәм мөмкинлек дәрәҗәсен ул бик тиз сиземләп ала, бәяләүдә ялгышмый, бер тотындымы, композиторны үстерү-формалаштыруга барлык көчен, сәләтен бирә. Аңарда игътибарлы мөнәсәбәт белән кырыс таләпчәнлек бергә үрелгән. Студиягә алган вакытта Сәйдәшевне тикшергәннән соң, Литинский болай дип әйтә:

— Салих Җамалетдинович, сез, һичшиксез, талантлы кеше. Мин зур канәгатьләнү белән сезне үз классыма алам. Тик бер шарт белән: бу язган әсәрләрегезне онытып торасыз. Киләчәктә мин таләп иткән әсәрләр язачаксыз...

Фәрит Яруллинга карата да шундый ук таләпләрнең куелуын ансат чамаларга мөмкин. Җилкәннәр җил яраткан шикелле, иҗат кешесе өчен болар файда өстенә файда гына, әлбәттә.

Кече залның утыз өченче классы. Фәрит үзенең остазы белән күбрәк шушы бүлмәдә очраша, дәресләр ала, кайчак үзенең әсәрләрен уйнап күрсәтә. Генрих Ильич янында күбрәк булган саен Фәрит шуңа ныграк ышана: күңел хәзинәсен башкалар белән күбрәк уртаклашкан саен кеше үзе дә югарырак күтәрелә, бүтәннәр каршында дәрәҗәлерәк була бара икән... Юк, Литинский үзе теләгәнчә «ышкып-юнып» берәүне дә үзгәртергә җыенмый, аның төп нияте — булачак музыкантларга үз-үзен табуда булышу, индивидуаль сәләтләрен дөрес эздән үстерү

— Беләсеңме, егетем, карап-карап торам, синдә яхшы мәгънәсендәге үҗәтлек зур,— ди ул сөйләшүләрнең берсендә Фәриткә.— Теория белән генә чикләнмичә, практик дәресләрне дә ешрак үткәрербез.

Баштагырак чорда Фәрит теоретик фәннәрдә үзен чынлап та йомшаграк сизә. Ләкин, остазы әйткәнчә, табигать аны үҗәтлек, ихтыяр көче, максатка ирешә алу җегәре белән мул бүләкләгән. Дәресләренә төгәл йөри, хәл итәсе сораулар өстендә озаклап-озаклап утыра. Гармония һәм полифония нигезләрен күнекмәләр белән ныгыта барып, музыкаль фикер йөртү сәләтен үстерә.

Консерватория педагогларының һәркайсы — зур шәхес, музыкаль фикер иясе, җәмәгать эшлеклесе. Менә А. Б. Гольденвейзер — күренекле композитор һәм пианист, башкаланың музыкаль тормышына җан өрүчеләрнең берсе... Профессор Р. М. Глиэр — революцион темага язылган беренче совет балеты — «Кызыл мәк» (1927) әсәренең авторы... Профессор Г. Г. Нейгауз — үзенең уйнавы белән меңнәрнең күңелен яулаган атаклы пианист... Сүзләре һәм уйнауларыннан гына түгел, аларның карашыннан, кул хәрәкәтләреннән генә дә әллә ничаклы мәгънәләр табарга мөмкин. Мохит бай, уңдырышлы. Соклану, үрнәк алу, кыйбланың дөреслегенә инану өчен мәйдан җитәрлек.

Консерваториянең Зур залы...

Биредә еш кына концертлар булгангамы, көчле магнит сыман, гел үзенә тартып тора ул. Фәрит концертларны калдырмаска тырыша. Дөрес, аларны оешкан төстә группа белән дә алып кергәлиләр, ләкин мондый бәхет бик сирәк эләгә. Ә менә репетицияләр барган чакта урыннар бөтенләй буш диярлек: керә, дәшми-тынмый гына тыңлап утыра, үзенә кирәк нәрсәләрне «мыекка чорный» егет.

Фәрит Мәскәүдә күп тапкыр органчыларны да тыңлый, аларның виртуозлыгына, кул-аяк хәрәкәтләренә тәмам бирелеп, бөтен гәүдә белән йотылып-йомарланып уйнауларына соклана. Бигрәк тә органның каяндыр күкләрдән агылып, тылсымлы аваздай тамып-тамып төшкән моңнарына таң кала. Андый концертлардан ул электрлангандай чыгып китә. Болар да үзенә күрә шулай ук гармония һәм полифония дәресләре ләбаса...

Ул заманда кызыклы кешеләр, күренекле шәхесләр белән очрашу традициягә кереп китә. Әйтик, көннәрнең берендә «Чапаев» фильмын эшләгән иҗат группасы студентлар янына кунакка килә. Бу очрашуда легендар геройның улы, хәрби училище курсанты А. Чапаев та катнаша. Кунаклар фильмны ничек төшерүләре турында сөйлиләр. Чапаев ролен башкарган артист Борис Бабочкин, үзе белән булган вакыйганы сөйләп, залдагыларны көлдереп тә ала. Тәнәфес араларының берсендә ул ялгызы гына кечерәк елга буена килеп чыга. Папахалы, кара буркалы җайдакны күргәч, шул тирәдә кайнашкан балыкчылар, Чапаев үзе түгелме соң бу дип, «ах!» итәләр, кулларыннан җәтмәсе төшеп үк китә тегеләрнең... Атаклы очучы Михаил Громов белән очрашу һәм Америкадан килгән скрипкачыны тыңлау да һәркемнең күңеленә сеңеп кала.

Мәскәүдә метро казу эшләренең кызган-кайнаган чагын да искә төшерик. Кул көче, лебедка янсә транспортерлар ярдәмендә тау-тау балчык өскә актарылып чыга. Машина һәм җигүле транспорт шуны шәһәр читенә ташый. Каядыр тирәндә җир асты юлы арчыла, биек-биек коймалар корылганга күрә, хәзергә аны юньләп күрә дә алмыйсың. Эшче көчләр җитмәгәнлектән, атна саен диярлек шимбә өмәләре оештырыла. Мондый данлы төзелешкә кемнең генә үзеннән хәләл өлеш кертәсе килмәс икән! Метроны бөтен Мәскәү төзи. Дәртләнеп өмәгә чыгалар, эшнең нindиеннән дә куркып тормыйча, ком, балчык, цемент, мәрмәр, рельс ташыйлар, измә әзерлиләр, төзелеш мәйданын чүп-чардан чистарталар. Укалары коелмас иде коелуын, әмма консерватория студентларына өмәдә катнашырга рөхсәт юк: инструментта уйныйсы кул-бармакларның нәфислеген сакларга кирәк, янәсе. Музыка өлкәсе —

нечкә-нәфис сәнгать, мәсьәләнең шулай куелышы, бәлки, чынлап та дөрес булгандыр...

Парижда һәм Лондонда гастрольдә йөреп кайткан педагоглар, жай чыккан саен, студентларга метроның нинди нәрсә икәнлеген сөйләми калмый. Аларның сүзенә ышансаң, ожмах сарае янсә жир асты патшалыгы шикеллерәк искиткеч бер дөнья икән ул.

Йөз кат ишеткәнче, бер кат күрүең хәерлерәк, дигәннәр бит. Ниһаять, 1935 елда Мәскәү метросының беренче чираты сафка баса. Кырым мәйданыннан Сокольникигә кадәр сузылган жир асты линиясе беренче пассажирлар өчен ул чакта гаять озын тоелгандыр, мөгаен. Метрога кем генә килеп эләксә дә бирелгәге матурлыкка таң кала: менә ул күз күрмәгән могжиза, кай арада жир астыннан үсеп чыккан мәрмәр сарай! Дугалы түшәмнәрдән, мәрмәр стена һәм колонналардан яктылык, көләчлек, мәһабәтлек бөркелеп тора, күкрәкләргә саф һава тула. Жир астының жыйнак, сары-яшькелт төстәге беренче поездлары... Бәллүр лампалар белән яктыртылган вагон тәрәзәләрендә беренче пассажирларның көләч йөзе шәйләнә. Илнең кыен чакларында хыялланган эшнең гүзәл нәтиҗәсен күргән һәр кеше горурлык кичерә, коммунизмда шулай булачак, дип бер-береңең жилкәсеннән кагалар.

Мәскәү тигез ритмга салынган күпкырлы тормыш белән яши. Аның әле бер-берсен кабатламый торган күпме музейлары, театрлары, культура үзәкләре бар. Музыкаль дөнья зур, бай, аны ансат кына колачлап алу мөмкин дә түгел. Укырга, кеше булырга дип ашкынып килүләрнең тагын бер сәбәбе әнә шул түгелмени? Фәритнең МХАТ сәхнәсеннән «Житлекмәгән егет»не яратып каравы да мәгълүм. Мәһабәт колонналары, түбәсендәге мифологик образлар белән балкып утырган Зур театр бинасы — янәшәдә, юл уңаенда гына. Күңел сусавын басарга теләп, Фәрит театр һәм концертларга ешрак йөри башлый.

Чайковскийның «Евгений Онегин» операсы һәм «Аккош күле» балеты аны тәмам сихерли, чиргә сабыштыра...

Бетховенның Тугызынчы симфониясе концертыннан кайтышлый, онытылып бара торгач, чактан гына трамвай астына эләкми кала...

«Музыка көче ярдәмендә менә нинди могжизалар тудырырга мөмкин икән!» — дигән соклангыч фикергә килә ул.

Тыйнак, аз сүзле, тыныч табигатьле Фәрит шау-гөр килеп йөрүчеләрдән читтәрәк булырга тырыша. Студиядә укыган Салих абыйсы Сәйдәшев белән исә һаман да аерым бер жылы, ихлас, дустанә мөнәсәбәттә алар. Кая барсалар, ни сөйләшсәләр дә серләре килешә. Сәйдәшев аңа кайчак: «Улым кебек якын күрәм сине...» — дип әйтеп куя. Менә шундый чаклардан соң Фәрит эти-әнисен, аларның четерекле язмышын исенә төшерә, еш кына моңсулыкка бирелә. Уку, театр-концертка йөрүләр, үзенең дә музыка белән жөнләнеп яшәве аны күп вакыт житди, уйлы-моңсу итеп күрсәтә. Тышкы тәэсиргә бирелеп, хәтта кайберәүләр: «Кызлар белән йөри алыр микән бу?» — дип тә уйлыйлар аның турында, әмма ялгышалар. Казанда чакта Фәритне оялчанлык, мохтажлык, укуның кадерен белү, тәжрибәсезлек дигән нәрсәләр кызлар белән чын-чынлап аралашудан тыеп торса, Мәскәүгә килеп яши башлагач, аңарда икенче бер мохтажлык — күңел серләрен кем беләндер уртаклашасы килү, мәхәббәткә сусау дулкыны уяна.

Бу дуслык нәрсәдән башлангандыр, әйтү кыен, һәрхәлдә, күңел уртаклыгы, хисләр сафлыгы, яшьлек юлларының янәшәлеге икәүне бер-беренә якынайткан булырга тиеш. Фәритнең тормышына Зөһрә Исмәгыйлова дигән тыйнак бер кыз килеп керә. Чибәр, куе чәчләре иңенә таралып төшкән, елмайганда шикәрдәй ак тешләре балкып-балкып китә. Үкчәле туфлидән йөргәнгәме, кул-аяк хәрәкәтләре сөйкемле, табигый, үзенә бик тә килешле.

Кем ул, кайдан? Бу сорауларга ачык җавап бирә алабыз. Тумышы белән Әгерже районының атаклы Иж-Бубый авылыннан. Егерме-уты-

зынчы еллар арасында булса кирәк, эти-әниләре Уфага килеп төпләнә. Зөһрә дә, күп кенә иптәшләре кебек, студиягә укырга дип килгән җырчы кыз. Яңгыравыклы бәрхет тавышын лирик-драматик сопрано дип бәяләмиләр. Тулай торaклары — Трифоновка урамында, бер бүлмәдә ун кыз яшиләр. Фәрит буш вакытларында шушында килеп йөргәли, иңләшеп, кыюланып китә. Үзен кызлар арасында да, гадәттәгечә, гади һәм итагатьле тота, кешегә файдасы тиярдәй икән — теләсә кай вакытта ярдәмләшергә әзер.

Икәүдән-икәү генә паркта яисә урамда йөргән чакларда Фәрит тәмам ачылып китә, үзенең уй-хыялларын сөйли. Кызык сүзләр әйтеп көлдерергә дә җай таба, андый чакларда аның коңгырт күзләрендә шаянлык очкыннары җемелдәп ала. Зур залда тыңлаган концертлардан соң рәхәтләнеп фикер алышалар. Фәрит музыкасыз яши алмый. Аның җаны арфа кылларыдай сизгер: аулак минутлар тудымы, алныялны белмичә үзеннән-үзе чыңларга, моңланырга тотына... Зөһрә — аның беренче мәхәббәте, күңел дөньясына яңа тойгылар бүләк итүчесе. Бу очрашулар аны музыкаль уйлар давылыннан аралап җиргә төшердеме икән — өзеп кенә әйтү кыен.

Беренче елларда стипендия студентларга бик аз күләмдә түләнә. Шул акчаны тулысы белән диярлек алдан түләп куялар да, консерватория ашханәсендә бушлай ашыйлар. Киенү һәм көндәлек мәшәкатьләргә акчаны башка җирдән табарга кала. Әйе, уку һәм яшәүләр җиңелдән түгел, бар булганына шөкер итәргә кала. Каяндыр акча юнәтеп, көннәрнең берендә Фәрит Зур театрга ике билет ала. Зөһрә белән бергәләп, янәшә утырып, геройларның кичерешен күңел аша үткәрә-үткәрә Мусоргскийның «Борис Годунов» операсын тыңлыйлар...

Фәритнең яраткан композиторлары кемнәр соң? Бу сорауга замандашлары, берничә исемне әйтү белән бергә, Мусоргскийны да атыйлар. Ул чакта «Борис Годунов» операсына шулай бергәләп барулары очраклы хәл түгел, күрәсең.

Алга таба вакыйгалар болайрак үзгәрә.

Әйткәнебезчә, ашау-эчү әллә ни мактанырлык түгел, өстәвенә, уку катлаулы, педагоглар таләпчән. Яхшы тәрбиягә, тынычлыкка мохтаҗ булганлыктан, Зөһрәнең укуында кыенлыклар килеп чыга. Зачетка дип килдеме, мактаулы тавышы кинәт кенә өзелә дә кала. Кызарудан, тавыш яхшырганны көтеп яшәүдән бүтән чара юк. Моны Зөһрә авыр кичерә һәм, алга таба да өмет күренмәгәч, өченче курстан укуын ташлап кире Уфага кайта. Билгеле, Фәрит белән, сәнгать дөньясы белән саубуллашу ансат булмагандыр аңа... Фәрит яңа җырлар яза, икәүдән-икәү генә калган чакларда Зөһрә кайчак шуларны башкара. Бер-берсен ихластан котлыйлар да тагын хыялга биреләләр. Боларны оныту мөмкинме соң!

Ике арада инде яшьлек хатлары йөри...

Бу дуслык аларга канат бирде, күңелләренә бәхет орлыгы чәчте. Беренче мәхәббәт бар, исән! Тик ул, акрын-акрын офыкка чигенә барып, күңел исталегенә әвереләчәк...

Аз гына алгарак күчеп, аларның язмышларын ахыргача күздән кичерик. Чираттагы җәйләрнең берсендә Фәрит Уфага кайта, Җоматау санаториенда ял итә. Кулында адрес бар, эзләп килә, күрешәләр. Каршында нәкъ элекке Зөһрә, күңеле генә бераз үзгәргән, читләшкән кебек. Үзенең Мәскәүдән, музыкадан аерылуын ул ике арадагы тирән упкын итеп күрә... Фәритнең «Шүрәле»гә тотынган, аның аерым күренешләрен язарга керешкән чагы, аңа рухи ярдәмче кирәк. Зөһрә исә: «Сезнең тормыштан артта калдым, мин сиңа тиң түгел»,— дип белдерә. Фәритнең таланты каршында ул үзен артыгы белән җаваплы тойган, күрәсең.

Ләкин дуслык, яшьлеккә тугрылык хисләре озак саклана. 1940 елны Әхмәт Ерикәй Уфага командировкага килә, боларны Фәрит сиңа

тапшырырга кушты, дип Зөһрә Исмәгыйловага ноталы җырлар суза. Фәритнең үз кулы белән язылган ноталар, таныш почерк... Менә кайсы җырларны җибәргән ул: «Җырлама син, иркәм» (Пушкин сүзләренә), «Нигә... нигә?», «Син кер инде» (Такташ сүзләренә), «Лирик җыр», «Бишек җыры», «Йөрәк җыры» (Ә. Ерикәй сүзләренә), эшкәртелгән халык көйләре — «Зөбәрҗәт», «Сандугач», «Сибай кантон».

Композиторның сугышта һәлак булганын ишеткәч, Зөһрә ханым яшьлек дусты Фәритне бер ай буе тоташ төшләрендә күреп саташа... Кызганыч: яшьлекнең самими, эчкерсез, ихлас хатлары сакланмаган. Әгәр алар исән булса, без Фәрит исемле яшь егетнең ул чактагы хисләрен, уй-фикерләрен, нинди утларда януын тулырак төсмерли алыр идек.

Фәритнең беренче мәхәббәтенә кагылышлы сәхифәләр әнә шул.

Инде яңадан Мәскәү чорына әйләнеп кайтыйк. Без Фәрит Яруллинның вокаль музыка, ягъни җырлар язу белән аеруча мавыккан чагына юлыгабыз. Җыр — иң кыска, иң үтемле, тиз аңлаешлы, халык тормышындагы үзгәреш һәм вакыйгаларга карата аеруча сизгер, өлгер жанрларның берсе. Бу урында ирексездән Габдулла Тукайның мәгълүм сүзләре хәтергә килә: «Чү, аз гына берәр нәрсә шылт иттеме, инде аның тугрысында иртәгә урамга бәетләр чыга». Әлеге сүзләрне, мәгънә ягын бераз үзгәртеп, музыкага карата күчереп тә әйтеп булыр иде. Утызынчы еллар — илебез тормышындагы гаять әһәмиятле дәвер, социализм төзү өчен көрәшнең кызган-кайнаган чагы. Комсомольск шәһәре, Магнитка һәм Днепрогэслар сафка баса. Данлы очучыларыбыз Төньяк котыпны буйсындыра. Тарихта тиңе булмаган мондый үзгәрешләр сәнгать кешеләре арасында да зур күтәренкелек тудыра. Көрәшче, дәртле, шат күңелле, яңа рухлы җырлар шәһәр салуда, икмәк үстерүдә, кыенлыкларны җиңүдә көннән-көн активрак катнаша.

Октябрь революциясенең егерме еллыгына багышлап, ул Әхмәт Ерикәй сүзләренә «Комсомолка-партизанка» дигән җыр яза. «Очучылар» җыры, исеменнән үк күренгәнчә, Төньяк полюс аша Америкага барып җитүчеләребезне данлый. «Тельман маршы», «Һаваны күзәт!», «Юл бирегез, ул килә», «Отличниклар җыры», «Колхоз кызына» һәм башка шундый җырларның исемнәрен санап чыкканда гына да ил тормышындагы никадәрле вакыйгалар күз алдыннан үтә.

Җыр артык җыр... Киләчәктә таланты лирикада тагын да тулырак ачылачак яшь композиторны без артыгы белән «кызартып» җибәрдек түгелме? Аның бит хәтта югарыда әйтелгән политик яңгырашлы җырларында да лирик башлангыч төсмерләре ярылып ята. Әйе, баштагы чорында ук Фәрит Яруллин иҗаты лирик эздән күтәрелде. Үзенең күп кенә җырларында ул тормышның гүзәллеген, табигать көләчлеген якты буяулар белән сурәтли, кеше күңелендәге тирбәнешләрне музыка теленә күчереп аңлата. Фәритнең художество зәвыгы үсә, чарлана бара. «Лирик җыр», «Урман кызы» кебек язмаларында стиль төсмерләренең баюы, мелодикасының тирәнәюе дә әнә шуны раслый.

Пушкинның үлеменә 100 ел тулу уңаеннан Фәритнең бөек шагыйрь иҗатына мөрәҗәгать итүе шулай ук күркәм факт. Ул «Җырлама син, иркәм» һәм «Чегәннәр» дигән шигырьләргә ике романс иҗат итә. Белгечләр билгеләгәнчә, беренче романсның һәм вокаль, һәм фортепиано партияләрендә пентатоника чаралары көнчыгыш музыкасындагы ритмнар белән дә баетылган. Бу инде, һичшиксез, авторның музыкаль әзерлек дәрәҗәсе үсә баруын күрсәтүче дәлил.

Инструменталь жанрларга тотыну, аерым алганда, скрипка һәм фортепиано миниатюралары, виолончель белән фортепиано өчен соната, кыллы квартет язу — болар бар да тәҗрибә туплау, профессиональ осталыкка ирешү мәктәбе була. Гармония һәм полифония нигезләрен ныклап үзләштерә барган Фәрит, җыр-романслар һәм кечкенә инструменталь әсәрләр белән генә чикләнмичә, инде зуррак күләмле әсәрләр

язу турында хыяллана башлый. Хыял бер хәл, аны чынга ашыру бөтенләй икенче нәрсә. Вакыт, илһам, әзерлек, рухи туплану, ихтыяр көче, үз-үзеңне мәҗбүр итә белү — тагын-тагын әллә'ничаклы алшартлар кирәк. Үзенең мохитендә һәм күңелендә Фәрит шуларның һәммәсен дә тапкан, булдырган, күрәсең: көннәрнең берендә ул симфония тәмамлау бәхетенә дә ирешә. Аның музыка сәнгатендәге иң югары жанрга мөрәҗәгать итүен иҗади кыюлык дип бәяләргә кирәк, билгеле. Яруллинның бу чордагы активлыгына, үз-үзен җиңә белү сәләтенә таң калырлык. «Кемдер» колагына бихисап моңнарны көйләп-пышылдап торган да, гүя, ул шуларны нибары кәгазьгә генә төшерә барган... Алай гына да түгел, композитор тагын бер зур жанрга — «Зөлхәбирә» операсына керешә, берничә күренешне тәмамлаганнан соң бүленеп кала... Бу хезмәтләрнең, студент эшләре кысасына гына сыймыйча, киңрәк дөнья даулап талпынуларын чамалау кыен түгел.

Мөһим бер этап шуның белән тәгәлләнә.

Болар «Шүрәле» балетына әзерлекне чарлау, тирәнәйтү өчен кирәк иде. Күргәнебезчә, композитор үзенең күренекле булып калачак әсәренә шома, такыр юлдан бәйрәмчә генә атлап, турыдан гына сикереп кермәгән икән.

Фәрит Яруллинның бу чордагы иҗат эшчәнлегенә йомгак ясап, инде аны саннар теленә күчереп карыйк. Исән калганнарын һәм безгә мәгълүм булганнарын җыйнап исәпләгәндә, утызга якын җыр, дистәдән артык эшкәртелгән халык җырлары, күләме ягыннан төрле зурлыктагы уникеләп инструменталь әсәр. Күпме бу, азмы? Аларның уку дәверендә һәм бигрәк тә ике-өч ел эчендә язылуларын исәпкә алсак, бер кеше өчен тау кадәрле хезмәт бу!

Джузеппи Верди үз гомерендә егерме алты опера яза, һәркайсына атап-багышлап имениесендәге бакчасына агач утырта. Тормыш төбеннән, гади халык арасыннан күтәрелгән Фәритне шанлы исемгә, зур байлыкка хуҗа булган Верди белән чагыштыру урынсыз, әлбәттә. Ләкин барыбер, аз гына хыялга бирелеп, Яруллин бакчасындагы яшь-яшь агачларга сокланасы, гыйбрәт аласы килә. Аның хәзер иң соңгы, иң күренекле әсәрен язасы гына калды. Аннары каршындагы нота кәгазенә сугыш утының рәхимсез кайнар күмерләре сикереп төшәчәк...

Татар опера студиясе, белгәнебезчә, җырчы һәм композитор кадрлар әзерләргә тиеш иде. Бу җаваплы эш әйбәт эздән бара, ничәмә-ничә характердан торган коллектив уртак максатка һаман саен ныграк туплана. Әгәр студия җырчылар әзерләү белән генә мавыккан булса, якын киләчәктә милли опера театры төзү, мөгаен, шик астына алыныр иде. Бәхеткә, студиянең ике канаты да бердәй дәрәҗәдә ныгый, тегенди-мондый имгәтүләргә юл куелмый.

Республикада культура тормышы сизелерлек дәрәҗәдә алга китә. Татарстан радиокомитетының музыканы пропагандалаудагы концерт эшчәнлегенә күпмедер тукталган идек инде. Бу эш ары таба тагын да колачлырак бара. Яңа музыкаль уку йортлары төзелә. Республикада халык иҗаты йорты һәм филармония ачу турында сүзләр куера. Опера театрын оештыруны тизләтү мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп баса.

Асылда аның нигез ташлары студия җирлегендә салына башлый.

Композитор Җәүдәт Фәйзи истәлегеннән түбәндәге юлларны укыйбыз:

«1937 ел азагында әдәбият бүлеге мөдире Муса Җәлил, ә студиябез директоры Арканов дигән кеше булып, опера театрының репертуар планнарын тикшерә торган идек. Безгә, яшь композиторларга, нәрсә эшләргә кирәклеге хәл ителә, кызыксындыру максатыннан чыгып, безнең белән килешүләр төзиләр, аванс бирәләр иде. 1938 елда аванслар алган операмны һаман яза алганым юк әле.

Муса Җәлил бүлмәсендә без Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсын

бер пәрдәле генә итмичә, бәлки өч пәрдәле итеп язарга тиешлеген хәл иттек...»

Заман шушы егетләргә текәлгән: әйдә, социализм биргән мөмкинлекләрдән иркенләп файдаланыгыз, сәнгатегезне югары күтәрегез, ди. Милли сәнгатьнең чикләрен тагын да киңәйтү, опера театрын тергезеп җибәрү өчен исә зур, киң полотнолы әсәрләр, әдәби материал кирәк. Заман үзе шуны сорый. Әнә аның беренче үрнәкләре эшләнә, языла тора. Яшь композитор Нәҗип Җиһановның студия заказы белән язылган «Качкын» операсы 1938 елда консерваторияне тәмам иткәндәге диплом эше дә булачак. Хәзергә ул язылып кына ята, либреттосы әле төгәлләнеп тә бетмәгән. Дөресен әйткәндә, либреттолар мәсьәләсендә тәҗрибә гаять аз, бу җәһәттән күп нәрсәләрне әле шомартасы, үткерлисе, камилләштерәсе бар. Әхмәт Фәйзи тарафыннан язылган бу либретто, студия җитәкчеләре күрсәтмәләрен истә тотып, ун тапкыр чамасы диярлек кабаттан эшләнә.

Бу эшләрнең уртасында шагыйрь Муса Җәлил кайный. Теоретик һәм практик белеме зур, колачы киң. «Кечкенә иптәшләр» журналында — редактор, Мәскәү университетында — студент, «Коммунист» журналында бүлек мөдире булганнан соң ул көннәрнең берендә Татар опера студиясенә эшкә чакырыла, әдәбият бүлеген җитәкли. Татар опера студиясендә эшләгән елларында музыка сәнгатен ныклап өйрәнә, барлык композитор һәм шагыйрьләр белән якыннан аралашып, иҗади элемтәдә яши. Гомумән, аның театрны аякка бастырудагы күпкырлы эшчәнлеге аерым тикшеренүгә лаек.

Муса Җәлилгә бәйле мондыйрак бер вакыйганы да сөйлиләр. Шагыйрь Әхмәт Ерикәй Мәскәүдә яши, фатиры шактый иркен. Фатир хуҗасы кунакчыл булгангамы, консерватория һәм студия егетләре атна саен диярлек шушында җыелалар икән. Араларында Фәрит тә бар. Шахмат көрәше кызып китә. Тапкыр сүзле, терекөмеш кебек хәрәкәтчән Муса барысыннан да остарак уйный. Икенче килгәндә ул, тиражы бер генә дана дип, шахмат турнирына багышланган кичерәк газетаны өстәлгә чыгарып сала. Кулдан кулга йөртеп, көлә-көлә рәхәтләнеп укыйлар. Муса Җәлил үзләренең шахмат уйнагандагы хаталарын юморга манчып кына тәнкыйтьләгән була анда.

Иҗат кешесе — алны-ялны белмәүчән хыялый халык: мондый очрашуларда эш турында да сөйләшенми калмас. Бәхәсләшү янсә иҗат планнары уртаклашу дисеңме — боларның да мохитне баетып, тулыландырып торуы көн кебек ачык. Студиянең бөтен игътибары бу көннәрдә «Качкын» операсына юнәлгән. Берәр яңа ария язылдымы, тыңлап карыйлар, шунда ук репетициясе дә башланып китә. Дусларының һәр уңышы өчен шатлана белгән Фәрит җырчыларны тыңлый, бигрәк тә солистка Галия Кайбицкая репетицияләреннән дәртләнеп, рухланып чыга. Яруллин Зур театрга йөри, симфоник концертлар тыңлый. Кулында «Шәһрезадә» (Римский-Корсаков) сюитасының партитурасы... Шәрык һәм көнбатыш музыкасын өйрәнә, «Урта Азия» (Бородин) картинасындагы гармоник яңгырашка соклана. «Ялантаудагы төн» (Мусоргский) музыкаль поэмасын тыңлаганда фантастик алымнарның сәерлегенә, кларнетлар дуэтының матурлыгына игътибар итә. Чайковскийның Дүртенче симфониясе аша колагына вальслар, халык темасы килеп керә...

Аның үзенең дә иҗат планнары зурдан. Күңелендә музыкаль моңнар корт иледәй кайнап, тынгысызлап, тышка бәреп чыгарга тора. «Зөлхәбирә» операсының башланып та төгәлләнми калуы «Шүрәле» белән чын-чынлап мавыгуына бәйле. Тукайның соклангыч әкият-поэмасын музыкада гәүдәләндерәсе килә аның. Киңәшкән чакта дуслары да бу фикерне хуплыйлар, Фәриткә өмет баглыйлар. Симфоник сюитага дип материал туплаган арада Яруллин аның кайбер күренешләренә эскизлар да язгáн була инде. Әлегә әсәр — авторның үзе өчен дә бил-

гесез утрау кебегрәк, уртасына керми торып, аңардан ни килеп чыгасын чамалау мөмкин түгел. Бәлки, опера янсә балет итеп үстерергә, күләмлерәк әсәргә йөз тотаргадыр? Фәритнең талантын инде күреп өлгерделәр. Студия җитәкчелеге, шул исәптән Муса Җәлил һәм Литинский, чираттагы сөйләшүләрнең берсендә әсәрнең язмышын хәл итәләр — ул, һичшиксез, беренче татар балеты булырга тиеш!

Бу заказ Фәритне тагын да җилкендереп, канатландырып җибәрә. Балетның якынча планын төзиләр, либреттосын язуны Әхмәт Фәйзигә тапшыралар. Яруллинга студия фондыннан шундук аванс бирелә, иҗат итү өчен тиешле шартлар тудырыла. Литинский ярдәме белән булса кирәк, Фәрит тулай тораклан җайлырак фатирга күчелә. Аерым бүлмә, бер почмагында прокатка алынган пианино. Ирле-хатынлы, өлкән яшьтәге Минкевичлар фатир кергән егеткә әйбәт карыйлар, тыйнак һәм житдилеген яраталар. Фәриткә авыр да, мактаулы да булган ифрат җаваплы бурыч — балет тикле балетны язу эше тапшырылды.

Бу чорда Фәрит үз эченә тагын да ныграк бикләнә, хәсрәте бар кешедәй гел уйга чумып йөри. Хөрлек, тынычлык, иҗат ирсге өчен аңарга ялгызлык, фәкать ялгызлык кирәк! Фәритнең шау-шулы компанияләрдә болганып йөрмәвен, мораль ялгызлыкка омтылып яшәвен бары шуның белән аңлатырга мөмкин.

Якыннан белгән дуслары — бер төсле, сирәк аралашкан сабакташлары исә Фәрит Яруллинга икенче төрлерәк характеристика бирә, шуларны чагыштырып карасаң — җир белән күк аермасы... Нидән бу? Асылда бер дә гаҗәпләнер нәрсә юк: алар чыннан да, икесе ике төрле Фәритне «күргәннәр». Берсе — ашый, эчә, йөри, укый, сирәк сөйләшә торган гап-гади Фәрит; икенчесе — ирекле, фантазияле, очыштагы кеше, музыкаль фикер иясе, үз дөньясында яшәүче иҗади шәхес. Тыштан беренче карашка салмак, сабыр, тыныч, сәер күренүе дә алдавыч тәэсир! Эчендә әллә ничаклы уйлар, борчулар кайный аның. Композитор шәхесен аңларга тырышу дигәндә моны беркайчан да истән чыгарырга ярамый.

Мактануны яратмаучы Фәрит шул дәрәҗәдә тыйнак ки, «Шүрәле»сен тәмамламый торып күпләр әле аның ни язганын да белмичәрәк калалар. Моны да аңларга мөмкин, чөнки Мәскәү зур, төрлесе төрле тулай торак һәм фатирларда яшиләр. «Шүрәле»нең ничек, ни рәвешле язылуына бердәнбер шаһитләр — пианино, нота битләре һәм автор үзе. Шулай да консерваториядә укып йөргән Нәҗип Җиһанов Фәрит янына сирәк-мирәк килеп чыккалый. Җиһанов — эшчән, талантлы, белем һәм максатка омтылучан егет, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, һәр эштә беренче булуны ярата, аңарда бераз гына яшертен хәйләкәрлек тә бар кебек...

Аларны берләштергән нәрсәләр күп: студия заказы белән икесе дә күләмле әсәр өстендә эшлиләр, икесе дә татар профессиональ музыкасы башка халыклар туплаган тәҗрибәне үзләштерү юлыннан үсәргә тиеш дигән караштә торалар, икесе дә профессор Г. И. Литинский классында укыйлар. Ниһаять, тагын бер уртаклык — икесе дә әүвәл фортепианодан башлап, виолончельгә күчә, аннары композицияне өйрәнә башлый. Кыскасы, сөйләшер-бәхәсләшер сүзләре күп. Бер килүендә Җиһанов ике көн рәттән кунып ук кала. Пианинода уйныйлар, сөйләшәләр, түгәрәк өстәл дә корып җибәрәләр... Болар табигый нәрсә, тик менә дәрес калдырулары гына кыйммәткә төшә: укытучылары Литинский өсләренә кереп икесен дә бик һәйбәтләп пешерә!

Әйе, Генрих Ильич талантларга карата таләпчәнлекне беркайчан да киметмәгән.

Аның мәктәбе югары әзерлек, принципиальлек, заманчалык, һәр шәкертенең индивидуаль табигатен истә тотып эш итү алымнары белән аерылып тора. Тихон Хренников кебек рус егетләре белән бергә, милли республикаларның талантлы вәкилләре — әрмән А. Бабаджанян,

грузин А. Кераселидзе, төркмән Ч. Нарымов һәм татарлардан Ф. Яруллин, Н. Җиһанов һ. б. якташларыбыз Литинскийдан полифониянең гаять катлаулы курсын тыңлыйлар, гармония алгебрасын үзләштерәләр.

Литинский, тәҗрибәле педагог булу өстенә, универсаль композитор да бит әле, күпсанлы музыкаль әсәрләр авторы. Үзенең иҗади үсешендә ул яңа музыкаль интонацияләрне үзләштерә. Шәкертләреннән дә заманча сурәтләү чаралары, яңа алымнар, оригинальлек таләп итә. Гади генә итеп әйткәндә, Литинский шәкертләрен дә өйрәтә, алардан үзе дә өйрәнә. Милли музыкаль культура, милли җирлекне саклаган хәлдә, рус һәм чит ил классикасы алымнарын иҗади үзләштереп үсәргә тиеш — Генрих Ильич заманның шушы зарурлыгын тирәнтен аңлап эш икән.

Озак вакытлар суын алмый торсаң, кое кибә, коргаксып кала. Талант белән дә мәсьәлә шулайрак тора түгелме? Эш, эш, тагын бер тапкыр эш! Теоретик һәм практик әзерлекнең билгеле бер баскычында профессор әкренләп шәкертләрен зуррак һәм катлаулырак формаларга тотынырга мәҗбүр итә, аларны иҗат дәрте белән сихерли. Н. Җиһановның «Качкын»дагы, Ф. Яруллин «Шүрәле»сендәге һәр яңа өзекне дә тыңлый, карый, тикшерә. Ләкин беркайчан да аларның кәгазьләренә карандаш белән тыкшынмый, ә бәлки «профессиональ яктан камиллеккә ирешүне, милли бизәкләр мул куллануны, музыкаль фикерне үзләренчә әйтүне таләп итә».

Бу чорда Фәрит, һичшиксез, күп укыган, күп өйрәнгән. Менә аның киштәсеннән кайбер китаплар исемлеге:

П. Чайковский. Алтынчы симфония (патетик).

В. Калинников. Беренче симфония.

Н. Мясковский. Уналтынчы симфония. (Зур оркестр өчен).

Аларны сатуга чыгу белән алган булса кирәк. Һәркайсының почмагына үз кулы белән имзасын сырлаган. Китап тышлыкларының берсенә, эчке якка, ике радиолампаның схемасы, «диез» һәм «бемоль»не аңлатучы нота билгеләре язылган. Укыган чакта Фәрит радиотехника белән дә кызыксынган, күрәсең. Нота тамгалары исә күңеленең һаман да музыка тирәсендәрәк уралуы хакында сөйли.

Бервакыт Уфадагы балачак дусты, инде хәзер Казанда укып йөргән Хәсән Гобәйдуллин Мәскәүгә килеп чыга. Билгеле инде, Фәритнең фатирына китәләр. Икесеннән дә китереп куша торгач, Казан һәм Уфа истәлекләре байтакка җыйнала. Иҗат планнары турында сөйләшми хәле юк, Фәрит әйтә куя:


— Үгезне мөгезеннән диләрме әле... «Шүрәле» әкиятенә балет яза башладым мин.

— Алайса, үгезне түгел, шүрәлене мөгезеннән эләктергән буласың түгелме соң син?

Көлешеп алалар. Фәрит, дуслык хөрмәтенә дип, балетның кайбер язмаларын уйнап та күрсәтә. Кунак табынына тагын бер сый-хөрмәт — әле беркайчан да яңгырамаган искиткеч ягымлы моңнар өстәлә.

Фәритнең киләчәге ачык төсмерләнә башлады шикелле. Ә менә әтисенең язмышында ниндирәк үзгәрешләр килеп чыкты соң?

Заһидулла Яруллин илгәзәклеген һаман да ташламый әле. Мамадышка барып чыга. Анда күпмедер эшләп алганнан соң, ниһаять, туган авылы Күче Сөнгә бөтенләйгә кайтып төпләнә, авыллашып китә. Утызынчы еллар уртасы бу. Тормыш җиңелдән түгел, ләкин халыкның күңеле көр, колхозлашуга аяк баскан авыл килер көнгә ышаныч белән яши. Кырык биш яшьлек Заһидулла Хәнифә исемле тол хатынга өйләнеп җибәрә, тормыш йөген бергәләп тарта башлыйлар. Өч тәрәзәле кечерәк кенә агач йорт, ике тәрәзәсе ишегалдына карый. Кояшта, карангырда төсе уңган, ярыклар белән чуарланган иске бүрәнәләр. Ачык болдыр, өй каршында чикләвек куагыннан үргән тәбәнәк читән. Каралган, такта чәй кебек тыгызланган салам түбә өстенә беләк юанлыгы



*А. Тимергалина рәсеме*

киртәләр сырышкан. Кыскасы, шул чор өчен типик авыл йорты. Биш тәрәзәле яңа йортны байтак еллардан соң гына салып керәчәкләр...

Хәнифәнең унбер яшьләр чамасындагы Фәләх исемле малаен Заһидулла үз улыдай якын кабул итә. Озак та үтми, яңа бер малай дөньяга килә. Альфред дигән сүзне яраклаштырып булса кирәк, аңарга Әлфәрит дип исем кушалар. Акыллы һәм матур гына бала үсеп килә дигәндә, эче авыртып, малай кисәктән үлеп китә. Заһидулла, сагышларын күз яше белән юарга, киметергә теләптер инде, бер ел буе көн саен улының каберенә йөри... Шушы кайгы килер алдыннан гына баланың әнисе:

— Атна кич көн юлга чыга күрмә, этисе, хәерлегә булмас,— дип нык кына үгетләгән булган икән. Соңыннан шушы сүзләрнең уфтану катыш кабат-кабат әйтелүе дә эти кешенең сагышын тирәнәйткәндер, бәлки?

Йортлары — авыл читендә, сөзәкләнеп менгән кечкенә тау өстендә. Бәрәңге бакчалары иген кыры белән чиктәш. Кичләрен Заһидулла менә шунда чыгып, бүкәнгә утырып гармунда яисә скрипкада уйный. Өздереп-өздереп уйнаганда үзенең дә үзәкләре өзелә аның: әле зират каеннары, әле шәһре Казанның яшьлектәге хатирәләре күз алдына килеп баса... Авылның икенче бер почмагыннан кемдер берәү аңарга гармун белән җавап кайтара. Бу кеше — шахтадан уң кулын имгәтеп һәм сыңар күзен сукырайтып кайткан авылдашы Кәрам Мәрдәнов. Уң кулының бармаклары исән булмагач, ничек шулай матур, кимчелексез уйный ала соң ул? Хикмәт шунда ки, каешларын көйләп-үзгәртеп, Заһидулла аңа махсус гармун ясап бирә. Шахтага хәтле үк оста гармунчы булган Кәрам, тальянын кирегә әйләндереп тез башына куя да сул кул белән сиптерә башлый! Гыйбрәтле хәл. Һәммәсе бергә укмашкан: талант, фаҗига, үҗәтлек...

1938 елның җәе. Июль урталары.

Менә шундый көннәрдә, Мәскәүдә укуын тәмамлар алдыннан, Фәрит Яруллин Кече Сөнгә кунакка кайта. Озаклап ял итә, авыл һавасы сулый, көннәрен табигать кочагында үткәрә. Әлегә берәү дә белми: Мамадыш якларына аның соңгы кайтуы бу...

Фәритнең ул чактагы кайтуын ничегрәк хәтерлиләр соң?

## *Авторның күзаллавы*

Авылга җитәрәк Фәрит, кайтуына тәмам ышану өчен, тәэсирләнеп, уйга бирелеп, басу читендәге чирәмлеккә утырды, нindидер үлән сабагын өзеп авызына капты. Тулган, авырайган арыш башаклары талгын гына тирбәлеп сәлам бирә шикелле. Аларның яшькелт-сары кылчыклары скрипка кылыдай тартылган: менә шулар бер-беренә бәрелеп туктаусыз кыштырдый, җырлый, пышылдаган авазлар чыгара. Күктән, салмак кына челтерәп, тургай моңы коела. Үлән арасыннан кинәт-кинәт чикерткәләр җыры бәреп чыга... Табигатьнең үзендә тулышып яткан мәңгелек бу симфония нота битләренә генә сыяр иде микән?

Фәрит этисенең туган авылына кайтып төште. Малай чактагы кебек, бу юлы да кунакка. Ләкин лепер-лепер серләшкән агачлар, тыкрык-койма читәннәре, казык башында әлсерәшеп утырган берән-сәрән чүлмәкләр кунак егетне танымады. Ул, чыннан да, бөтенләй башка кеше иде шул: дулкын-дулкын чәчләре артка таба кайтарылып төшкән, өстендә шәһәрчә күлмәк-чалбар, аякта шнурлы елтыр ботинка. Кулда да букча-мазар ише генә түгел, почмаклары күн белән каймаланган кибет чемоданы.

Заһидулла абый ишегалдында тырма теше көйләп маташа иде. «Исәнме, эти!» — дигән сүзгә сискәнеп борылды, йөзендә берьюлы елмаю һәм гаҗәпләнү чаткылары кабынды. Этисе студент улын озаклап кочаклады, артка чигенә төшеп таза, сөйкемле егетне тагын бер

кат күздән кичерде. Башын чайкый-чайкый, күрсәтмәскә тырышып кына дымлы керфекләрен сөртеп тә алды бугай әле. Нәрсә иде бу? Башкала тикле ерак җирдән әйләнеп кайткан баласы өчен горурлануме, әллә Казан һәм Уфа шәһәрләрендә яшәгән чакта бергә-бергә нужаны да байтак татыган улының бүгенге язмышына ышанып житә алмавымы? Икесе дә бардыр, мөгаен, ни әйтсәң дә байтактан күрешкәннәре юк иде аларның.

— Улым, син бөтенләйгә түгелдер ич? — Ир уртасы Заһидулла бу сорауның урынсыз икәнен белә торып, сүзне каян башларга аптыраганнан әйтеп ташлады.

— Күпкә түгел, әти. Ике атна чамасы торам да китәм.

— Азрак икән шул... Бу Мәскәүләр тәмам каптырган, мәйтәм, иркенләп йөрер чамаң да юк.

— Үзебез дә нык каптырабыз, әти. «Шүрәле»не төгәлләп киләм менә.

Әтисе Фәритнең укуы, иҗат планнары белән хат аша яхшы таныш иде, шуңа күрә булачак әсәренең язмышы турында сорашып алды, хуплау хәрәкәтләре ясый-ясый, бүлдерми генә улын тыңлады. Аннары әйтеп куйды:

— «Шүрәле» дисең алайса... Хәтерлисеңме, малай чакта әле кайчан гына урманнан шүрләп, еламсырап кайткан идең. Инде хәзер шүрәленең үзен биетергә чамалыйсың, ә?

Әтисенә кушылып, Фәрит тә рәхәтләнеп көлде, балачак дуслары Шәйхулла белән Фәрхетдинне исенә төшерде. Тик менә алар икесе дә, әтисенең әйтүенә караганда, әллә кайчан авылдан читкә чыгып киткәннәр икән.

— Улым, беләсеңме, вакыйганың зурысына чамалап кайттың бит әле син...— Нинидер сер әйтергә җыенгандай, әтисенең як-ягына каранып, көттереп һәм дулкынланып сөйләвендә чынлап та нинидер әһәмиятле вакыйга булганга охшый.— Ходай инде монысын гомерле итә күрсен... Хәнифә апаң сиңа энекәш алып кайтты бүген!

Фәрит әтисенә туры карады да көлемсерәп куйды. «Әйбәт булган. Тизрәк үсеп, йөреп китсен. Безнең арада урын табылыр аңа»,— дигәнрәк мәгънәне аңлата иде бу караш.

Шулай сөйләшә-сөйләшә өйгә керделәр. Үзенчә кунак каршылавы идеме, чаршау артыннан бала елаганы ишетелде... Күрешү куанычыннан өлкәннәр утырып дога кылдылар, кунак егетнең юлын, тормыш хәлен сораштылар. Фәләх атлы яшүсмер малай кайдандыр еракт ан кайткан «музыкант» абыйсына читтән генә сокланып-кызыксынып карый, тартма шикеллерәк чемоданының «черт» итеп ачылуы да аңарга гаҗәп тоела. Фәрит Хәнифә апасына бүләккә дип алган чуклы калын шәлне тартып чыгарды. Әтисенә һәм яшүсмер малайга — кәрән төстәге берәр пар кибет оекбашы... Рәхмәт әйтә-әйтә алдылар, ерактагы башкала исе аңкып торган бу бүләкләр һәркайсының күңеленә куаныч-шатлык тутырды. «Кендек әби» кергән иде, аның сөйләшүеннән Фәрит энекәшенең битләре кызыл, чәчләре кара икәнлеген генә аңлап калды...

Кич. Кече мичтә ялкын телләре биешә, казанда су җылына. Мич каршына утырган әтисенең күзләрендә утчак шәүләсе яктырып-яктырып китә. Моңсу, серле, ләкин тормышка мәхәббәт белән карый торган акыллы-сабыр күзләр. Аларда нинди яшен чагылып уйнаганын, нинди моңнар кайнаганын инде тормышның уртасына ерып кергән Фәрит аңлый да, аңламый да кебек.

Самавырга күмер өстәргә кирәк. Әтисе, күмер кыскычын табалмагач, ялангач кул белән учакка үрелеп утлы күмер чүпли башлый. Кузлы күмерләрне уч тан-учка сикертә дә самавыр моржасына куып төшерә. Бу хәтәр эшне шулкадәр җиңел, тыныч башкара ки, кулларында гүя тылсымлы пирчәткә аның... Кеше башына килгән хәсрәтләр утлы күмер шикеллерәк: көйдерә-әрнетә башлый, аларны да күңелдән

менә шулай ансат кына куып чыгара алсаң икән ул!

«Заһидулланың Мәскәүдә укый торган улы кайткан!» — дигән хәбәр тиз таралган, күрәсең, ул көнне җил капканы ачып керүчеләр байтак булды. Күрше-күлән, чыбык очы кардәшләр бер күрешү өчен атап кергәннәр, хәл-әхвәл сорашалар. Алар белән Фәрит күбрәк ишегалдында яисә капка төбендә сөйләшеп утырды. Ә күңел кичне, ялгызлыкны көтә! Менә шул чакта гына беркемнән тартынмый уйланырга, моңаерга, табигатьтәге авазлар чалымын иркенләп тыңларга мөмкин булачак...

Кичен Фәрит, ишегалдына чыгып, күктәге йолдызлар җемелдәвен күзәтте, ай нурында коенучы алмагачларның үзара серләшүен тыңлады. Табигать, үзе белгән моңнар кочагында тирбәлеп, каядыр билгесезлеккә таба йөзә. Менә шул чакны өздереп-өздереп сандугач сайрарга кереште. Әйтерсең, кунак егет хөрмәтенә адажио башкара! Ул да түгел, авыл уртасында гармун тавышы, җанын кая куярга белми йөргән егетләр җыры яңгырады. Гармунның шашып өзгәләнүе авыл өсләтеп кенә агыла да йолдызлар белән чуарланган галәм коесына китеп югала шикелле. Ата-бабалар дөньяга килгән, яшәгән, тормыш иткән газиз туфрак кадерле һәм изге икән. Авылның күге тулы моң, туфрагы тулы хикмәт, чишмәсе тулы сихәт...

Икенче көнне, кармак таягы асып, әтисе белән балыкка төштеләр. Тегермәнле Сөн елгасы — аста, авыл читендә генә, тегермән буасыннан соң борылма саен диярлек куе таллыклар үсеп утыра. Чирәмле яр буйларын төймә зурлыгындагы сары чәчәк баскан. Кармакка җим каптырып, тәтәлкәле җепне суга ыргытканнан соң бераз гына сүзсез утырдылар. Аннары тагын әңгәмәләре ялганып китте.

— Әти, Тукайны күргәннәрең турында тагын бер сөйлә әле. Гапгади бер кеше иде, дигәнеңә никтер ышанасы килми. Көчле, кыю, дөньяны учында тоткан хаким кеше шикеллерәк күз алдына китерәм мин аны...

— Әлегә кадәр сөйләгәннәрем бар да дөрес, һичбер арттыру-киметү юк. Артист Габдулла абыең Кариев белән дә табындаш дуслар идек. Ике Габдулла да миннән ике яшькә олырак иде олысын, тик андый аерманы әллә ни сизмәдек. Гадилек дигәндә, алар тыштан гына шулай күренәләр иде. Ә күңелләре! Күңел зурлыгын үлчәп булмый, аны мин генә аңлата алырмын микән? Тукай әчтән дөрләп, халкының язмышын кайгыртып, уртаклашып яшәде. Үзе туңса туңар, ләкин дөньяны җылыту уе белән янар иде. Нәләт төшкән чир аны иртә, бик иртә арабыздан тартып алды шул... Минем скрипкада уйнаганны яратып тыңлар иде. Җыр турында сөйләшсәк, татарның музыкасы үсәргә тиеш, дип хыялланды. Әй, улым, теге чакта «Шүрәле»сенә шулай көйләр языласын белгән булсамы ул! Мөгаен, шатлыгыннан сабыйлар күк сикереп куяр иде... Менә бит син нинди мәртәбәле эшкә тотынгансың. Кулың җиңел булсын берүк.

Сөйләшү дәртенә бирелеп, каурыйлы тәтәлкәнең сикерә-сикерә уйнавын да күрми торалар икән. Беренчелек Фәриткә елмайган иде: кармакның очында хәйран зурлыктагы көмеш чабак ялтырый! Улыннан калышырга теләмәгәндәй, Заһидулла абый тагын да зуррак икенче бер балыкны яр читенә суырып чыгарды. Әнә шулай ике шөгыль бергә кушылды: гәп кордылар, балыгын да тоттылар. Балык һәйбәт каба иде, бәртәс, кызылканат, чабак, дисеңме — тегермән суында шуларның һәммәсе рәхәт чигә икән, бары кармагыңнан җим генә өзелмәсен, тамак дигәндә атылышып киләләр. Кызылканатны гына күр син, үлчәп карасаң, валлаһи, берәр килога тартадыр бу...

Хәнифә апа ир-егетләр күтәреп кайткан балыкны чистарта. Хатынның эш сөючән, таза-чыдам беләкләренә балык тәңкәсе чәчри. Йолдыз атылган шикеллерәк... Чистартып, тоз сибеп салкын базда бер кич кундыра да, икенче көнне ул алардан балык бәлеше пешерә. Телеңне

йотарлык тәмле бәлеш — әллә инде «эшләп» ашаганга микән?

Берничә көннән, кунак егеткә атап, авыл мунчасы ягылды. Фәрит тыкрыктан бер учлам яшел кычыткан күтәреп кайткан иде, кирәге чыгачак дип, шуны мунча алачыгына кертеп куйды. Андый мунчаны тагын кайчан күрерсең икән! Идәнгә кычыткан җәелгән — кайнар су койган саен исе бөркелеп чыга. Аяк табаннарына да сихәте җитәрлек. Әрем, мәтрүшкә, кычыткан кисәге кыстырылган каен себерке — җилләнеп чапкан саен җәйге хуш исләр тарала. Тамагың кипте исә, мунча алачыгында сине әйрән көтеп тора. Бу рәхәтлекләрдән соң тәнең генә түгел, җаның да сулыш ала башлый, бөтен дөньяң пакьләнә. Мунчадан чыгышка — тансыкка гына пешкән коймак, өстендә кура җиләге йөзеп йөргән татлы-әчкелтем чәй.

Табигатьнең үзеннән өзелеп төшкән мондый ләззәт, рәхәтлекне бары авыл җирендә генә татырга мөмкин...

* * *

Хушлашыр көн бик тиз килеп җитә. Нужа вакыт, хәзинәдә барын төйнәп, Фәриткә юл күчтәнәче әзерлиләр. Китәр алдыннан ул биләүдәге сабыйга — Мирсәет дип исем кушылган кечкенә энесенә яратып, үз итеп тагы бер тапкыр ягымлы караш ташлый.

Фәритне егерме биш чакрымдагы Берсут пристанена этисе илтә.

Кече Сөннең җемелдек арышлары, малахит төстәге Берсут урманнары егетне Мәскәүдәге фатирына хәтле озата бара.

Инде «Шүрәле» балетына якынрак килик.

Әхмәт Фәйзи либреттоның беренче вариантын Мәскәүдә 1938 ел азакларында тәмамлый. Фәрит кулында, ниһаять, өч пәрдәле балетның тулаем тексты — инде хәзер азакта ниләр буласын төп-төгәл белеп, аерым күренешне ахыргача күзаллап, тагын да зуррак дәрт белән иҗат эшенә ташланырга мөмкин. Фәрит Яруллин балетның икенче пәрдәсенә әнә шундый күтәренкелек белән тотына.

1938 ел азагында тагын бер зур вакыйга була әле. Татар опера студиясенең вокал классын тәмамлаучылар, имтиханнарны уңышлы тапшырып, Казанга эшкә кайталар. Милли опера сәнгатен үстерү өчен никадәр көч дигән сүз! Шуңа өстәп әйтик: студия һәм консерватория залларында Г. Литинский, Р. Глиэр, А. Александров, В. Белый, Б. Шехтер җитәкчелегендә тулы бер буын композиторларыбыз профессиональ әзерлек мәктәбе узды. Тиздән алар да, укуларын төгәлләп, республика мәйданына кайтачаклар.

Чоры шундый иде: давылдай күкрәп килгән революция иске тормыш кануннарын дер селкетте, мәйданга яңа көчләр ташлады. Шуның нәтиҗәсе буларак, халыкның төрле катламнары арасыннан талант һәм энергия чишмәләре бәреп чыкты. Моңа ышану өчен татар музыкасының, кыска гына арада, гади җырлардан опера һәм балет кебек иң катлаулы жанрларга кискен сикереш ясавын хәтердән кичерү дә җитә. Әйе, ул заманда талантлар чын мәгънәсендә сикереп үсте. Фәрит Яруллин әнә шундыйларның берсе иде.

*Ахыры бар*

## Мәхмүт Газизов

### Капка ныгыта эти...

— Сайланып та, сырланып та
йөри, диген, бер адәм:
андыйларга тир түгеп
ипи ашату хәрәм.
Илен ташлап чыга да,
«ялгышынган икән», дип,
сайрап ята, «кертсәгез,
китмәс идем бүтән», дип.
Ил капкасы — зур капка,
ул бит түгел җилкапка,
теләсә кем ачарга
йомышка йөргән чакта...
Җилкапканы да менә
барлап-карап торасы,—
күгәнен тарттырасы,
тегесен-бусын борасы.
Аларга — ил капкасы!—
Чыгалар да керәләр;
бушамый да какшамый
торсын әле keләләр.
Ачуны китерсәләр,
бик нык булыр бик бездә,
үтеп-сүтеп йөрергә
ындыр арты юк бездә.

...Картның үз фәлсәфәсе,
белмим нәрсә әйтергә.
Әти капка ныгыта,
мин булышам әтигә...

### Морҗа

Җимерелде дөньясы —
ишелеп төште морҗасы;
агач өйне сүттеләр,
төяп алып киттеләр.

«Шәп булган! Яңа йорттан
фатир алыр хуҗасы,
оҗмах анда — ис тими,
юк мич ягып торасы»,

Әйе, өйне сүттеләр,
тузылып калды морҗасы...
Туздырылган морҗага —
уйласы да уйласы:
ә кем төтен чыгарыр
без утырган нигездә?
Бульдозерлар килер дә
эһ дигәнче тигезләр,—
Һәркемнең үз нужасы.

...Яңа шәһәр астында
ята авыл морҗасы,—
катлам-катлам дөньясы...

---

Мәхмүт ГАЗИЗОВ *(1940) — шагыйрь, «Миләш сиртмә», «Бер, ике, өч...», «Тәгәри китте йомгагым» исемле шигырь китаплары авторы. Чаллыда яши.*

## Соңгы окоп

(БАЛЛАДА)

Ак, сары, кара тәнлеләр —
барыбыз да бергә монда;
басып торабыз җирдәге
иң соңгы окоп янында.
Без аны күмәргә килдек,
тигезләргә килдек аны,
томаларга, җир күкрәген
әрнетүче ул яраны.
Аһ, ничек соң күрмәгәнбез
моңа чаклы?!— Күпме вакыт
яп-якты кояш астында
яткан бер кап-кара окоп...
Без аны күмәргә килдек,
мәрхүмнәр, бездән көнләгез:
сез күмә алмый калдырган
соңгы окопны күмәбез,
көтәбез сукыр солдатның
килеп җиткәнен генә без.
Көрәкләр алып килмәдек,
нигә кирәк алар монда,
аяксызда — кул, кулсызда
исән аяклар барында.
Ни аягы, ни куллары
булмаганнар нәрсә эшләр?
Окопка балчык-туфракны
гәүдә белән аунап ишәр!
Булды, башлыйк,— сукыр солдат
килеп җитте, бетеп хәле:
— Үзем чәчәм!— һәм күрсәтте
эре бодай бөртекләре...

❁

Безне тудырган — вакыт,
безне үстергән — вакыт,
маймылдан аерып, адәм
хәленә җиткергән — вакыт.
Вакыт кылган бөек эш!

Без — бала, вакыт — ана,
үз баласыннан ана
игелек көтә ала,
изгелек көтә ала,—
шәфкатең булу тиеш!

# Нияз Акмалов

## Йөк атының абзар баганасына сөйләгәне

Син, багана, тыңлый беләсең шул —
Бу җәһәттән холкың-фигылең әйбәт.
Мине сиңа бәйләп куйдылармы,
Куйдылармы сине миңа бәйләп?

Ахмак, дияр берәү, баганага
Зарын сөйли, диеп көләр берәү.
Син, багана, минем күкләремне
Каплап торган түбәләргә терәү.

Син беләсең минем төннәремне,
Җиде кат тир исен, тире исен.
Күп нәрсәне беләсең син, дускай...
Күп нәрсәне ләкин син белмисең.
Син беләсең минем тәннәремдә
Төннәр буе мускул шыгырдавын.
Төшкә керә таудай йөкне тартып
Менеп барган чагым Шөгер тавын.
Хуҗам минем мәнсез бер зат булды,

Мәңге айный белмәс мужик сыман,—
Урап кына үтеп китәр үрне
Минә бирде һаман турысыннан.
Үзе какты һаман дилбегәсен,
Чыбыркысын төшермәде кулдан.
Үргә куды, сазга илтеп тыкты,
Йөртәм диеп, имеш, туры юлдан.
Юк, типмәдем түгел, сабыр беткәч,
Тугарылып типтем тәртәгә мин.
Чыбыркылап ярды мине хуҗам,
Хәлсез яттым ничә мәртәбә мин.
Бәйгеләргә бүтән атлар китте,
Эш аты мин — булмый сатулашып.
Гомер үтте шулай, сарыкларга,
Дуңгызларга яшел азык ташып.
И багана!... Мин бер колын булсам,
Син дә нәзек киртә булыр идең.
Тик синең дә язмыш: йә — бастырык,
Йә, барыбер, тәртә булыр идең.
Ачуланма, болай сөйләшергә
Өйрәндем мин шактый соңга калып.
Бар белгәнем — авызлык та тышау,
Татыганым — чыбыркы да камыт.

Инде менә соңгы сәгать сукты...
Җибәр мине, зинһар, булма надан?!
Минем өчен синнән үч алмаслар,

---

Нияз АКМАЛОВ *(1954) — шагыйрь, «Учак» исемле шигырьләр җыентыгы авторы. Проза әсәрләре дә яза. Казанда яши.*

Кем үч алсын синнән — баганадан?
Җан бирәсем килә иркенлектә,
Иркеннәрдән иркен бер далада.
Нинди хурлык, әгәр үлә калсам
Асылынып сиңа — баганага!

Йөгәнемне салыр чаклар узган,
Кызган мине, зинһар, җибәрә күр?!

Син дәшмисең... Димәк җибәрмисең,—
Каян килде сиңа шундый мәкер?
Син дәшмисең?! Әйе... Син — багана,
Холкың әйбәт синең, фигылең әйбәт.
Мине сиңа бәйләп куйдыlarмы,
Куйдыlarмы сине миңа бәйләп?..

## Үч

Алпавытның ихатасы яна!..
Халык тынган кино залында.
Мин утырам сәер ләззәт тоеп,
Бер тантана тоеп җанымда.
Бу фильмда — гарасатлы хәлләр,
Бу кадрлар — шундый кырыслар.
Алпавытның ихатасы яна,
Шартлап оча нарат борыслар!
Үч алучы — күптән ат өстендә,
Чалынып кына калды гәүдәсе.
Аның бүген бөек тантанасы —
Офыктагы ялкын шәүләсе.
Ул үч алды — шушы алпавыттан
Мәсхәрәгә тарган яр өчен.
Ул үч алды — сөйгән яры өчен,
Кара төнгә салды бар үчен.
Ул үч алды — үз яшьлеге өчен
Һәм яшьлеге өчен ярының.
Ул үч алды — ярлы гомере өчен
Дусларының-туганнарының.
Ах, бу җанның үчтән шашкан чагы!
Ах, бу җанның сәер гадәте!
Җимерүнең татлы мизгелләре,
Үч алуның татлы сәгате!
Дошман курка, диләр, гайрәтледән,
Дошман курка, диләр, көчледән.
Көчледән ул курка... Әмма дошман
Икеләтә курка үчледән!
Үч алучы егет атта чаба,
Табылмас күк юлын бүлүче.
Үч алынган... Әмма белүче юк —
Тынды микән аның бу үче?
Тый атыңны, егет! Ял ит бераз,
Шәүләсенә утның төбәл дә.
Тик мин генә чынлап аңлармын күк
Тантанаңны синең бу мәлдә.
Алпавытның ихатасы яна!
Алпавыттан яман көчләр бар.
Күкрәкләрне каерып-киереп торган,
Ватып-җимереп торган үчләр бар.
Башкаларның үче сискәндерә
Үз үчләрең көчсез чагында.
Алпавытның ихатасы яна!
Халык тынган кино залында...

## Эз югала!..

Күк капусы ачылмады, юк-юк!
Тик, атылып киткән йолдыз сыман,
Төн карасын кыл урталай ярып,
Вакыт үтте минем баш очымнан.
Мин тойдыммы аны бик ашыгып,
Мин тойдыммы аны соңга калып? —
Кыргый атка менгән җайдак кебек,
Үтеп китте Вакыт сөрән салып:
— Эз югала Җирдә, эз югала!
Былтыргыдан бигрәк тиз югала
Быелгы эз!
Сезнең өчен оятымнан үләм,
Җеназама минем җыелыгыз!..
Мин атылдым Вакыт артларыннан,
Табармын дип аның яшен ташын.
Тарих дигән мең колачлы имән
Коеп калды чорлар ябалдашын.
— Хәрәкәттә — бәрәкәтнең башы,

Хәрәкәттә — һәлакәтнең башы! —
Бер хакыйкать белеп калды тарих
Коелганда соңгы ябалдашы.
Күк капусы ачылмады, юк-юк!
Тик, атылып киткән йолдыз сыман,
Һәрбер чорның кисәтүле тавышы
Үтеп китте минем баш очымнан:
— Эз югала Җирдә, эз югала!

Былтыргыдан бигрәк тиз югала
Быелгы эз!
Сезнең өчен оятымнан үләм,
Җеназама минем җыелыгыз!..
...Китте тавыш без барасы көнгә,
Ә мин калдым шушы бүгенгедә.
Җеназадан кайткан кеше сыман,
Каршыгызда басып торам менә...

## Шулай да?..

*Җил тегермәне икәнен*
*Аңлыйм, ләкин шулай да,*
*Аның ташын әйләндергән*
*Суы, улагы кайда?*

Алсу таңнар, айлы төннәр
Калды яшел тугайда.
Яшьлек кире кайтмый, диләр —
Аңлыйм... Ләкин шулай да?..

Зөһрә кызның үзе дә юк,
Чиләге дә юк айда.
Аңлап торам, күреп торам,
Беләм. Ләкин шулай да?..

Бәхтиярлар кабат тумас,
Кабат тумас Юлай да.
Аккан сулар кире кайтмый.
Кайтмый. Ләкин шулай да?..

Дон Кихотлар көлке хәлдә,
Җилләр исми уңайга.
Тегермәннең ташы тыгыз,
Аңлыйм. Ләкин шулай да?..

Җил тегермәне икәнен
Аңлавымнан ни файда?
Аның ташын әйләндергән
Суы, улагы кайда?

## Белеп китәм

Юлларыңа синең яр ишелмәс,
Сыкрау тавышларың ишетелмәс,
Ишетелмәс, әгәр мин китсәм.
Мин ашкынып кире кайтыр идем,
«Ялгыш миндә...» диеп әйтер идем,
Әйтер идем, әгәр ишетсәм.

Юк,
Алдан ук әйтәм төгәл белеп:
Озатырсың мине бары көлеп,
Аязланып калыр бар күгең.
Шуңа күрә китәм мин бүген...

# Хәбәр

Күпме көтеп, көтеп яшәдем мин
Сезнең яктан килер хәбәрне.
Җиде ятлар, җиде ятлар килеп
Сөйли миңа синең хәлләрне.
Еллар үткәч, безнең баш очында
Тагын бер кат яфрак коелыр.
Һәм ул чакта безнең бу ялгышлар
Бик мәгънәсез булып тоелыр.
Ә аңынчы Җирдә сагыну яшәр,
Кабатланыр шул ук рәнҗүләр.
Җиргә вакытлыча килүебезне
Соңлап тойганбыз шул, без җүләр.
Тиранлектә, вакыт, чиксезлектә
Очраклы һәм зарур табышу.
Очрак җинде: яңгырап калды җанда
«Хуш, мәңгегә!..» дигән тавышың.
Ярга ятып яккан ул учаклар,
Безне озата барган ул утлар!
Гомерләрнең кыйбла ягы икән
Зар-интизар булган минутлар.
Кабат яна хәтер учаклары,
Кабатлана шул ук рәнҗүләр.
Җиргә мәңгелеккә килүебезне
Тәмам тойдым, ахры, мин җүләр.
Очраштырыр очрак — ялган назлар
Сискәндерсен өчен көн тугач.
Сулышлары бәгырьләргә кабар —
Тик ул инде барыбер син булмас.
Һәм кайдадыр, бәлки бик якында,
Мендәр күмелер синең толымыңнан.
Бар да якын, бар да таныш тоелыр —
Тик ул инде барыбер мин булмам.
Бу дөньяда бер яраткан ярлар
Сүнмәс газап белән тоташкан.
Мәңге шулай: Җирдә сагыну яшәр,
Газап яшәр аннан тоташтан.
Мең ел үткәч, безнең баш очында
Тагын бер кат яфрак коелыр.
Җилләр исәр, күктән йолдыз явар —
Миннән хәбәр сиңа шул булыр...



# ПРОЗА

## Марсель Галиев

# АЛТЫН ТОТКА

ПОВЕСТЬ

*— Кайсы гасырда тудың син?*
*— Борынгы ташлардан сора.*
*— Алар дәшми.*
*— Таш хәтере — кешеләрдә.*
*— Алар дәшми.*
*— Кеше хәтере — ташларда...*



Шәһәрдә минем үз тукталышым бар. Тимер рәшәткәле бакча эчендә, юкәләр күләгәсенә сыенган челтәр кәрнизле йортта минем дә сыңар тәрәзәле куышым бар. Кайчакларда читтән карыйм да үзем яшәгән йортны карт кеше белән чагыштырам. Әнә ул урам чатына баскан, ап-ак сакаллы, фәрештә кебек эчтән [1] яктыртылган йөзле, төсе уңа, уты сүнә барган күзләрен дөньяга текәп, тын гына тора. Туган елын да оныткан, кайчан үләсен дә белми...

Юкә яфраклары шыбырдавына йокымсыраган бу йорт Казанны тетрәтеп узган хәтәр янгын-давыллардан да исән калып, мәһабәт биналар рәтендә менә ничә гасыр инде җылы кош оясы кебек утыра.

Ашыгырга гадәтләнгән бүгенге заман кешесе искәрми дә үтәр иде, бәлки, әгәр бу йортның ике канаты булмаса... Менә син унтугызынчы гасыр урамыннан хуҗасының зәвыгына, байлык-мөмкинлегенә карап, төрле архитектура үрнәгендә чуарлап, бизәкләп эшләнгән купшы биналар күләгәсеннән хыялның ташта чагылышын тантана кылып барасың. Янәшәдә генә бер катлы агач йорт утырып кала. Син аны күрәсең дә, күрмисең дә. Урамның аргы ягындагы зур биналарга карап барган чагында җиргә иңә төшкән бу мескен флигельгә игътибар итәсең димени! Бераз киткәч, тротуар кырыенда әлеге йорт тагын пәйда була. Син аптырап тукталасың, артыңа борылып карыйсың. Акка буялган агач колонналы бу йортлар игезәкләр икән ләбаса. Аралары тимер рәшәткә белән тоташкан. Бакча түрендәге ике катлы, челтәр кәрнизле, чардак түбәсенә флюгер куелган төп йортка менә шунда инде син игътибар итәрсең. Тимер челтәрләре тутыга төшкән, такталары урыны-урыны белән калҗайган, ә шулай да үзенең горурлыгын җуймаган бу иске йортка карата синдә соклану һәм бер үк вакытта кызгану хисе дә уяныр. Була бит шу-

---

Марсель ГАЛИЕВ *(1946) — шагыйрь һәм прозаик. «Апрель кызы», «Ерак урман авазы», «Сиңа мин кирәк» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

[1] Журнал варианты.

лай: олы урамда эреле-ваклы машиналар арасыннан бердэнбер жигүле ат бара. Нигэдер сокландыра да, кызгандыра да...

Син, бу тобэктэн үтеп киткэнче, тагын бер борылып кара, соңгы тапкыр... Икенче вакыт элеге урамга юлың төшсэ дэ, юкэлэр ышыгында утырган бу йортны бүтэн инде күрэ алмассың. Юкэ чэчэклэрендэ тузан гына утырып калган булыр. Иске йорт тузаны... Син ул йортның рэвешен күз алдына бастырып карарсың, лэкин хэтерендэ, кара авызлы нигез урыны кебек, ямансу бушлык барлыкка килер. Гадэттэ шулай бит: мең мэртэбэ үтеп-сүтеп йөргэн таныш урамыңда нинди дэ булса йортның сүтеп ташланганын күрэсең дэ, кичэ генэ исэн иде, нинди иде соң эле ул? дип, бер бөтен итеп йорт чалымын күз алдыңа китерэ алмыйсың. Хэтернең үч алуымы бу?

Картаю һэм яшэү икесе бер үк вакытта бара — иске нигездэ яңалар калка.

Шэһэрнең дэ югалган үз атлантидасы бар...

## I

Тышта — апрель иртэсе. Керлэнгэн жепшек карда батып калган бакыр акчалар булып, узган елгы күксел яфраклар күренэ. Юкэ ботакларында утырган чыпчыкларның чыркылдашуы аеруча дэртле яңгырый.

Мин киенэм дэ, узган гасырларның байбичэлэре крахмалланган киң итэклэре белэн йөзеп кенэ чыксын өчен ике якка ачылмалы, этэч кикригедэй купшы прическалары тимэсен өчен биек итеп эшлэнгэн ишекнең сыңарын гына ачып коридорга чыгам. Витраж тэрэзэлэрдэн төшкэн кызыллы-сарылы, шэмэхэле-зэңгэрле яктылыкка манылып баскычтан эз генэ төшүгэ, кызган май, әчегэн аш исләре саркып килгэн кухня мэйданчыгы башлана. Плиткага иелгэн гэүдэ менэ хэзер, утка пешкэндэй, сискэнеп борылачак.

— Гиппократка сэлам!

Калагын яларганиятлэп торган Вольдемар Лопес сискэнеп башын бора. Алдагы катлы-катлы тешлэрен аңкауга кадэр чишендереп канэгать елмая.

— Куркыттың бит.

Мин аны һэрчак шулай берэр бөекнең исемен эйтеп сэламлим. Аңа ошый бу — йөзе, авызы көлэ, э күзлэре исэ шиклэнүчэн, сагаюлы.

Вольдемар Лопес, ике ел элек, ягъни институтны бетерер алдыннан үзе белэн бергэ укыган чит ил кызына өйлэнергэ уйлаган. Бөдрэ чэчле мулат кызга өйлэнеп, океан артындагы илгэ китү тэкатьсез бер хыялга эйлэнгэн. Көн-төн испан телен өйрэнэ башлаган. Мэхэббэтен исбатлау өчен ул мулат кэлэшнең фамилиясенэ үк күчкэн. Фамилия кырыена затлы исем дэ кирэк бит. Юрүзэндэ йөзэргэ өйрэнэсе малайның килэчэктэ океан кичэсен ата-анасы каян белсен ди, кушканнар Зиннэтулла дип кадими бер исем, яңгырашы нинди диген эле: алла дип бетэ диярлек. Шулай итеп, Зиннэтулла Вэлиуллин Вольдемар Лопеска эйлэнэ дэ куя. Этисе башкорт, энисе татар, паспортында миллэте рус дип язылган. «Чыгышың кем?» — дисэлэр, чит ил кешелэре алдында эйтергэ жиңел, «мөгезле татар» дигэн курку да тудырмый.

Нинди дэр сэбэплэр аркасында Лопес чит илгэ китэ алмый кала. ЗАГСка язган гаризасын учлап калган егеткэ мулат кыз үз фамилиясен бүлэк итэ дэ иленэ кайтып хэбэрсез югала...

— Бүген беренче апрель, бер-бер хэйлэң булса эйтеп кал,-барыбер алданмыйм,— дип, Вольдемар сакал чыкмый торган уңдырышсыз ияген сыпырып куйды.

— Э нигэ бүген генэ, кеше гомере буе алданырга ярата.

Лопесның үтэ тар чырае тагын да сузынкыланды. Ул нидер сөйли, мин аны ишетэм дэ, ишетмим дэ, күзем каршы ишектэ. Менэ ул хэзер минем тэлэгемэ буйсынып ачылып китэчэк. Шулай булды да. Йортыбыз-

ның иң чибәр кызы — Айсылу савыт-саба тотып килеп чыкты. Әлегә уянып житмәгән чәченең тараламаган булуы да үзенә килешеп тора. Халат итәгенең аскы сәдәфләрен эләктереп мәшәкатьләнмәгән. Атлаганда серле дөньяның мәрмәр яктысы чагылып-чагылып китә. Айсылу баш кагып кына исәнләшүгә, Лопесның калагы кулыннан төшеп китте. Калагын иелеп алырга үрелгәч, өч аяклы урындыкны аударды. Клеопатра тантаналы рәвештә Римгә килеп кергәндә юлына аркылы чыгып баскан ишәк кебек булды бу. Айсылуның атлап килү рәвешен бозмас өчен, җәһәт кенә урындыкны күтәреп алырга миңа җай чыкты. Айсылу, тәкәббер карашын икебезгә дә тигез өләшеп, су кранын ачты.

— Айсылу, бүген сиңа Лопес мәхәббәтен аңлатса, ышана күрмә.

— Нигә алай дисең?— Айсылу, башын яхшы ат кебек чайкап, маңгаена төшкән чәч учмасын икенче якка авыштырып куйды.

— Бүген алдау көне.

— Маратны тыңласаң,— дип, Лопес сүзгә кушылды.— Табактагы йомыркаларны ташка әйләнеп кила, ә ул әле кереп китәргә ашыкмый.

— Ло-пес...— дип, Айсылу үзалдына мыскыллы көлеп куйды. Алдан һөҗүмгә күчмәсәң, хәзер миңа чират җитәчәк:

— Мин сиңа беркайчан да гашыйк булмаячакмын, дисәм, ышан. Беренче апрель көнне дөреслекне белү җиңелрәк.

Айсылу күз кырые белән генә мине кистереп алды. Ул да — студент, Лопес та ординатурада укый. Аларга нәрсә — көн үз кулларында. Ә миңа эшкә китәргә кирәк. Һәр баскычның үз шыгырдавын тыңлап, аскы катка төшеп киләм. Уң яктагы ишеккә «Крыловъ Юрий Леонардович» дип язылган борынгы калай беркетелгән. Бу фатирда кайчандар шушы йорт хуҗасы булган купец Крыловның кызы — җитмеш яшьлек Анна Леонардовна яши.

Баскычның уң ягында Ризван агай фатиры. Ишеген, тәмәке төтенен җилләтү өчендер инде, төбенә кадәр ачып куйган. Тимердән чигеп эшләнгән култыксалы баскыч төбендә Ризван агай белән бәрелешә яздык.

— Нихәл, энекәш! — дип ул коргаксыган кулын учыма китереп тыкты. Эте гөнҗәлә койрыгын бутый-бутый шатлыклы өреп килде дә аякларымны кочып алды.

— Эшкә киттекме?

— Беренче апрель көнне ял итәргә иде дә...

— Шулай...— дип Ризван агай кызарган, шешенке күз кабакларын сыпырып алды.— Беренче апрель көнне өйләнергә туры килде миңа,— дип, кызыктыргыч сөйли башлаган җиреннән кинәт бүленеп, Наянга эндәште:— Брось, сичажже! Ну ка! Кому говорят! — Искереп беткән сөяк капкан Наян икеләнеп торды да, сүлпән генә китеп, табышын бер кырыйга илтеп ташлады. Тәме авызында калды, күрәсең, мөлдерәп, бер сөяккә, бер хуҗасына сораулы карап алды. Ризван агай аңа татарча итеп бармак янады да баягы сүзенә әйләнеп кайтты:— Яшьлектә алдынартын уйлап торасыңмыни. Шулай, беренче апрель көнне, кемне дә булса алдап, кызык табасы килә бит. Авылда кеше ышанучан, үзең беләсең. Хәер, син авыл малае түгел бит әле. Түбән очта Нурия дигән бер кыз бар иде. Кыяфәт дисәң, кыяфәте әллә кем түгел, буй дисәң, буе юк. Бөкрерәк тә күренә иде бугай. Шуңа яучы җибәрдем мин шушы каһәр суккан беренче апрель көнендә. Бер мәзәк булсын әле минәйтәм. Ышанган бит, чукынчык. Ду килеп әзерләнә дә башлаганнар болар. Юри генә әйттем, дип карыйм, юк, айга-вайга куймыйлар. Кичкә таба ике абыйсы килеп житте өйгә. Өрлектәй тазалар, ике метр булыр буйлары. Койрыкка басты болар минем. Берсе мылтык тотып төшкән, икенчесе — су буе чыбыркы... Умырып тотып алдылар да аякны идәнгә тидерми генә ишекле-түрле йөртәләр. Авылга исем чыкты, өйләнәсең, вәссәлам! Ату баскан урынында чәнчелдерәбез, диләр. Нишлисең, килешергә туры килде. Яшәп киттек Нурия белән. Алай ук ямьсез булмаган икән үзе, күзгә күренеп чибәрләнде минем белән тора башлагач...— Ризван агай хәйләкәр елмаеп

сигарет чыгарды. Кулы сизелер-сизелмәс кенә дерелди.— Әә син бар, эшенә соңга каласың, минем әкият бетмәс ул,— дип, читкә борылып этенә дәшкән булды. Мин шунда гына түбә кыегыннан тамчылар тамуына игътибар иттем. Өй түбәләрен җылытып яз килә.

Шәһәрнең үзәк урамында чит ил туристларының да игътибарын җәлеп итәрдәй, фото һәм киноаппаратларның да үткер күзләрен үзенә төбәлдерә алган гаҗәеп бер чиркәү манарасы бар. Ныклыгы, мәһабәтлеге белән ул вакытка көндәш булырлык. Измәгә йомырка агы, сөт кушып, таза кызыл кирпечтәй кайчандыр аны шулай көннәр-айлар дәвамында оста ташчылар төзегәнлегенә ышанасы да килми. Искиткеч төгәллек, саллы тантаналык — кемнеңдер күңеленнән тылсым өреп, бер сулышта яратылгандыр бу! Ян-якларындагы кечерәк буйлы ике манара гүя күз карашын әзерләр өчен генә... Башны күтәреп карауга, сыгылып китәсең: һәр бөгелеше күләгәләнеп карасу-кызыл төскә кергән үзәк манара, колонналы яруслары белән нәзегәя барып, бер чама биеклектәге йортлар агымыннан тантаналы аккорд булып өскә чөелә дә авыр, куксел гөмбәз белән тәмамлана. Кояшлы көнне бер төскә, болытлы көнне икенче төскә кергән көмеш гөмбәзне челтәрле тәре күк белән бәйләп тора. Биеклек, ташка индерелгән зирәк көч астында үз-үзеңне юатырдай ихтыяр килә бу манараның борынгы сулышын тоеп үзганда.

Бүген мин көтелмәгән хәлгә юлыктым. Боламыкка әйләнгән сусыл карлы тротуардан юк уйларымны бар итеп атлаган чакта шушы манара төбендә әсәренеп җыелган кешеләр төркеменә житеп тукталдым. Һәммәсенең йөзендә хәвефле халәткә хас дулкынлану. Төркемнең һәрчак лидеры була. Сораулар тик бераүгә — уртада торган озын буйлы, ак куян бүрекле адәмгә бирелә.

«Ничек менгән соң ул анда?» «Җүләрдер». «Ир кешеме, хатын-кызмы?» «Ир кеше. Бая бүреген дә җиргә ыргытты. Әнә-әнә!».

Мин манараның соңгы ярусындагы серле караңгылыкка төбәлдем. Чынлап та, ниндидер шәүлә селкенеп куйган шикелле булды.

— Тагын качты,— диде куян бүрекле.— Бая милиция килеп китте. Вертолет чакыртырга дип. Болай гына алырлык түгел икән. Әнә-әнә! Сул якка китте!

Сулышы кайнарланган йөзләгән кеше манара очына төбәлгән.

— Кая соң ул?— дип кычкырды арадан берәү өзгәләнеп.

— Күзеңне ачыбрак кара! — дип аңа берьюлы әллә ничә кеше өсеп куйды. Кинәт берәү шаркылдап көлә башлады:

— Җүләрләр, бүген бит беренче апрель!

Төркем, капылт аңга килеп, бер мәлгә сулышсыз калды. Менә хәзер куян бүрекле манарага чынлап та кеше менгәнлеген үзенең калын, ышанычлы тавышы белән исбатлап бирсә, шаркылдап көлүчене чөеп ыргытырлар иде. Ләкин куян бүрекле суга төшкән кебек юкка чыккан иде шул. Шулай җиңел алданганына аптырап, үзеннән-үзе тарала башлаган төркемгә «Ни булган?», «Ни күрдегез?»— дип яңалар килеп кушылды. Әле генә алданганнарның кайберләре һаман да икеләнепме, бүтәннәрнең дә алдануын тамаша кылырга дипме, читкәрәк китеп бастылар. Ул арада эшләпәле яңа лидер калыкты. Тагын да дәртлерәк тавыш белән манара башына төртеп күрсәтеп, үз тирәсенә илле-алтмышлап кешене туплап та өлгерде.

Кызык... Менә бу алдану ичмасам. Ялгызың гына түгел, бергә-бергә, иңгә-иң торып алдану. Беркемгә үпкәли алмыйсың.

Мин эш урынына биш минутка соңга калып килеп житәм. Ишек жиле аркама бәрүгә, йөгереп диярлек баскычлардан күтәреләм. Таныш шау. Агач исе. Кечкенә кыру станогы беркетелгән өстәлем янына килеп утырам да, тартманы ачып, инструментлар белән күз йөгертеп исәнләшәм. Хуҗасы килүен белеп алар да уяныргa тиеш ич. Кемдер җилкәмә кулын сала. Кемдер дисең, борылып карамасаң да билгеле — Мастер үзе!

— Нихәл, килдеңме? — дип Мастер, җилкәмә таянган килеш иелеп, бәрхет тавышын колагыма өрә. Аңа быел утыз өч тула. «Христос яшенә кадәр дөньяда бар икәнеңне исбатларлык эш кылмасаң, аннары инде соң була»,— ди ул. Үзеңнән өлкән кешенең сине үз итүен тою рәхәт. Иркәләнеп, бераз кыланып та аласы килә.

Мин аңа чиркәү манарасы янында булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Мастер җәелеп көлде. Ул тумыштан килгән сыйфатына хыянәт итмичә көлә белә; рәхәтләнеп, тавышын үз көенә таратып, бөтен барлыгы белән ачылып көлә. Аны көлдергәндә үзеңнең яшәвеңне аңлыйсың.

Беренче күргәндә мин аны бер дә ошатмаган идем. Түгәрәк, бүртмәч чырай. Бөдрәрәк куе чәчләрен күпертеп артка тараган. Киң төпле чалбары аягының кыскалыгын тагын да искәртеп тора. Танышканда ул:

— Мастер Моратов,— дип кул бирә.

— Мастер булуың әйбәт, исемең ничек? — дип сорыйлар аннан. Мастер дип әтисенең исем кушканлыгы турында ул бер дә иренмичә, меңенче тапкыр аңлатып бирә.

Беренче эшкә чыккан көндә ул минем янга килде дә өстәлгә урталай ярылган бүкән утыртып куйды:

— Бу нәрсә? Агач, шулай бит! Ә шушы агач эчендә нинди гүзәл сын үзен уятучыны көтеп ята. Шакый гына белергә кирәк, ул үзе чишенә. Бик җайлы бит, ә! Хикмәт нәрсәдә? Уйлан, егет!— дип, Мастер чалбар балакларын җилфердәтеп китеп барды.

Милли сувенирлар ясау цехында мин инде үз кеше. Агач исен яратам. Үзем теләгән әйбер ясарга да кул кычыткалый, әмма алга куелган план һәр эш көнен исәптә тота. Планны мин галәмәт зур авызлы җәнлек итеп күз алдына китерәм. Ай башында шыгырдап авызы ачыла да ай азагында шапылдап ябыла. Шул вакыт арасында кирәкле санны тел өстенә салып өлгермәсәң, ул тузынып, синең кесәңнән тешләп ала...

Кашык ясау айлыгы икән, син инде сигез сәгать буена, гел бер ритмга көйләнеп, дөньяда кашыктан кала берни дә юк икәненә инанганчы тырышырга тиешсең. Әлбәттә, гел бертөрле әйбер ясап утыра торгач, кеше түгел маймыл да остарып китәр иде. Тик, маймылдан аермалы буларак, кеше остарып киттеме — тизрәк өлгерә, вакытны янга калдыра башлый, үз-үзен канәгатьләндерерлек шөгыльгә дә мөмкинлек таба.

Инеш ярында гына була торган, дымсу ис аңкып торган ап-ак тал агачыннан шүрәле башын ясый башлагансың икән — ул инде бер кырыйда үз чиратын көтеп утыра. Әнә, сусыл, кызгылт эзләр сузылган зирек агачының кайрысы яңа гына куптарылган. Агачка карата миндә мәҗүси бер мөнәсәбәт тә уянды бугай. Мастер гаебе... Әгәр мин әлеге зирек түмәрен кискәләп, уйлаган әйберемне ашыгып ясарга тотынсам... юк, нәкъ мин теләгәнчә барып чыкмас иде. Ул әле күптән түгел генә тамырыннан аерылган — саф, сусыл килеш. Зирекнең әлегә бөтен күзәнәкләре, табигый яшәвеннән кузгатылып, авыртулы халәт кичерә. Агачка тынычланырга кирәк... Менә шул чакта инде ул сиңа карышмаячак.

Мин бүген капкачлы бал савытлары ясадым. Әлегә алардан гадәти агач исе килә. Махсус цехта нәфис пумала тоткан кызлар аларны гөл итеп бизәячәк.

Кичен без Мастер белән бергә кайтырга чыктык.

— Мин сиңа хәзер бер кызык күрсәтәм,— диде ул.

— Беренче апрель әлегә үз көчендә,— дидем мин Мастерның бер-бер хәйлә коруына исәп тотып.

— Син алданган урыннан үтик әле,— диде Мастер.

Менә бусын инде мин көтмәгән дә, уйламаган да идем: чиркәү манарасы төбендә, нәкъ иртәнге кебек, кешеләр төркеме җыелып тора.

— Шулай буласын сизгән идем,— дип Мастер беләкне чеметеп куйды. Төркемнең лидеры — сары куртка кигән, иренен ут кызылга буяган ханым иде. Русча да, татарча да сөйләнеп, манара башына төртеп күрсәтә-күрсәтә кешеләрне әсәртеп тота. Күккә кадалган манарада сер-

лелек... Мастер үзенең көчле тавышы белән кычкырып җибәрде:

— Эх вы, люди, сегодня же первое апреля!

Төркем кинәттән аңа борылып карады. Китте көлешү. Светофор кебек янып торган ханым гына әллә кая югалды. Төркем күз алдында сирәкләнде. Ул арада «Ни бар?», «Нәрсә булган?» — дип яңалар килеп туктала башлады. Мастер шунда ук лидерлыкны үз кулына алды. Илле-алтмышлап кеше тупланып та өлгерде.

— Әнә-әнә,— дип, Мастер колокольняның соңгы ярусына төртеп күрсәтте. Бер ноктага төбәлгән кешеләрне тәмам әзерләп бетергәч, ул кинәт кенә:

— Ах, сикерде! — дип тетрәнеп кычкырып куйды. Шул мәлдә, ни хикмәт, кешеләр төркеме, сулышсыз калып, Мастер белән бергә чүгеп куйды. Белгән килеш, мин үзем дә бу гипнозга иярүдән чак тыелып калдым. Шулчак, баягы төркемнән калганнарданмы берәү:

— Ышанмагыз аңа, бүген бит беренче апрель! — дип сөрән салды. Көлүгә кадәр башта ризасызлык туа икән. «Төп башы»на утыртучы кем? Мастер. Әмма алданган күзләр аны табарлык түгел иде инде. Мин куып җиткәч, ул үтә бер ләззәт белән көлә башлады.

— Беләсеңме, иртәдән бирле монда күпме кеше алданган? Кимендә ярты миллион. Кызык. Толпага эләктеме, кеше шәхес буларак югала. Толпа лидерны салып таптарга җай гына көтә. Буйсынасы да килә, шул ук вакытта коллыкны да яратмый...

## II

Әни туган шәһәр булгангамы, Казанга мин тиз ияләштем. Бу — минем шәһәр. Әти миңа бәләкәйдән үк татар җырларын тыңлата торган булган. Бәлки шул моңнар, күренмәс җеп булып, язмышымны монда тартып кайтаргандыр әле.

Кайтып бер ел яшәүгә, ишектән тагын ерак юллар җиле килеп керде. Германиягә китәргә приказ алган әти белән әни вокзалларны күп күргән чемоданнарны тагын кузгаттылар. Ә миңа сөенеч. Ниһаять, мин үземчә яши башлыйм! Саубуллашканда әнине тынычландырам:

— Фатирлар төрле җирдә булса да, әби белән икәү бер шәһәрдә калабыз, син борчылма,— дим.

Әни, икебезне кочаклап, әбигә күрсәтмәләр бирә:

— Маратны күздән яздырма. Атнаның өч көнендә син аңа киләсең, калган өч көнендә Марат синең хәлне белеп китә.

— Бер көн ялмы? — дим мин. Әнинең йөзендә укытучыларга хас кырыс җитдилек.

Әти белән минем арада ниндидер салкынлык бар. Бәлки минем дә хәрби кеше булуымны теләгәндер. Җитмеш төрле һөнәр арасыннан ул башта икесен сайлады: мине машина йөртергә һәм мылтык тотарга өйрәтте. Курсларны үтеп, таныклык алып чыккач, машинасын кызганмыйча биреп тора башлады. Мылтык белән хәл катлаулырак булып чыкты. Кулга корал алуга, борынгыдан килгән тиенкы бер гаярьлек уяна миндә дә... тик гөнаһсыз җәнлекне атып, күзләрен сүндерергә кодрәтем җитми. Миңа ундүрт яшьләр булгандыр. Әти мине Ерак Көнчыгышның субтропик урманына ауга алып чыгып китте. Без шактый йөреп, арып-талып, бернәрсәсез кайтып барганда, кечерәк күлдә тын күлдә йөзеп йөргән ике үрдәкне күреп алдык. Камышлык кырыенда гамьсез генә суда тирбәлеп утыралар. Ара да ерак түгел. Әти корулы мылтыкны тиз генә алды да миңа тоттырып, көпшәсен иңемә яткырды.

— Баскан килеш кенә ат,— дип пышылдады.

Әти сулышын да алмыйча тора. Мин төзим. Үрдәкнең әле судагысын, әле үндагысын мушкага алам. Әти яңакларын кысып тешен шыкырдата. Бармагым салкын курокта. Егетлекне күрсәтергә бер мизгел җитә. Ә мин һаман сузам. Үрдәкләрнең бу кадәр дә гамьсезлегенә ачу килә.

Тизрәк очып китәргә бит инде, юк, кайнар пуля килеп тиясен көтеп рәхәт тирбәләләр. Мин һаман сузам. Курокка басу ләззәтеннән нинди көч тыеп тора — үзем дә аңламыйм. Шулчак эти түзмәде, хәрбиләргә хас корыч тавыш белән:

— Стреляй! — дип кычкырып җибәрде.

Үрдәкләр канатларын шапылдатып күтәрелергә өлгергәнче, мин өскәрәк каратып тәтегә бастым. Шартлау белән бергә, мылтык түтәсе иңгә китереп бәрде. Үрдәкләр тайгага таба очып киттеләр.

— Җебегән! — дип, эти кулдан мылтыкны тартып алды.— Бу нинди сентиментальлек!

Юл буе сөйләшмичә кайттык.

Ике ел үткәч, Мәскәүдә кыр үрдәкләренең кешеләргә исе дә китмичә, нәни бәбкәләрен ияртеп, Останкино паркында йөрүләрен күргәч, шаккатып калдык. Без генәме, үткән-сүткәннәрнең һәрберсе туктала, йөзләрендә сабыйлык елмаюы. Тын табигатьне яңгыраткан мылтык шартлауларыннан качып, зур шәһәрләргә килеп сыенган кыргый үрдәкләр турында ишетеп түгел, үз күзләрең белән күрү икенчерәк икән. Шунда мин этигә:

— Теге чакта үрдәкләргә тигергән булсам, нәсел чылбыры өзелгән булыр иде. Останкино күлендә йөзәсе үрдәкләр тумаган булыр иде, күпме кешеләр сокланудан мәхрүм калыр иде,— дигәч, эти ирен чите белән мыскыллы елмаеп:

— Философ... Сиңа вегетарианец булырга кирәк, Толстой кебек,— диде.— Софья Андреевна аның ашына яшертен генә тавык шулпасы өсти торган булган, аң бул.

Биология факультетына керәсе килү теләгемне белгәч, ул дәшмәде. Самолетта, дистәләрчә чакрым биеклектән, зур-зур шәһәрләрне дә уенчык бер макет итеп кенә күреп өйрәнгән эти вакчыллана белми иде. Минем микроскоп белән бөҗәкләр күзәтүем, күзгә күренмәс микроблар дөньясы ачасы килүем бәлки шул авыруым аркасында тугандыр. Нинди врачларга гына күрсәтмәделәр. Авыру тарихы көннән-көн калынайды, әмма аллергенны ачыклый алмадылар. Мин хәтта азыкка кагылырга курка башладым. Ярыймы, ярамыймы дигән сорау ашауның тәмен бетерә иде. Һәр төрле җиләк-җимеш, һәртөрле ризык шик астына алынды. Мәкерле аллергия янәшәдә генә посып яткан икән. Әбинең күршесендә профессор Бакир Еникеев яшәмәгән булса, мин әле бүген дә өмет белән курку арасында йөрер идем. Ул минем авыру тарихын, тулы бер томны, детектив әсәрдән дә болайрак өйрәнде. Үзенең укучыларын да эшкә җикте. Бетмәс сеанслар, уколлар, тәҗрибәләр... Өч айдан соң профессор шундый нәтиҗә чыгарды:

— Син, егет, егерменче гасырда ялгыш тугансың. Комиссионкада борынгы мебельләр бар хәзергә, шуларны сатып алып кына котыла аласың.

Минем мәкерле аллерген — ялтыравыклы шома мебель өстенә кунган өрфия кебек йомшак тузан икән.

— Аллергенны табуга караганда, галәмдә яңа галактика ачу җиңелрәк,— диде профессор.

— Мин бит күктә туганмын, Бакир Тәминдарович, бәлки җирдә яшәү миңа зарарлыдыр?

— Күктә...— профессор күзлеге өстеннән карап мут елмайды.— Алланың уң канаты астында димәкчесеңме?

— Хабаровск-Мәскәү самолетында. Тайгадан ун чакрым биеклектә.

— Сирәк була торган хәл.

— Әни ялга кайтып барганда. Врачлар әйткәннән ике айга алдан туганмын. Минем аркада йөз кырык биш кешелек лайнер Новосибирскида төшәргә мәҗбүр булган.

— Ну-ну-ну!.. Бөек кешеләрнең күбесе җиде айдан туган. Без, үзебез дә белмичә, яңа бер Эйнштейнны дәвалаганбыз түгелме, ә?

— Туган көнем дә кешечә түгел бит минем, Бакир Тәминдарович. Дүрт елга бер генә килә — егерме тугызынчы февраль.

Профессор башын чайкый-чайкый көлде. Институт проректоры, кафедра житәкчесе, әллә күпме фәнни хезмәтләр язган могтәбәр Еникеевның үзен көлдереп кара әле!

Әнинең куанычы — югослав стенкасы, шәрыкча бизәкле пакистан сервантлары, минем хакка, сызланып булса да иске мебельгә алыштырылыр иде бәлки. Бәхеткә каршы, аларның чит илгә китәргә тиешлеге хәлне җиңеләйтеп куйды. Әби ике бүлмәле фатирга хуҗа булып монда кала, мин аның бер бүлмәле, иске мебельле фатирына күчәм. Алышабыз! Бу хәбәргә әти: «Вегетарианец»,— дип мыек астыннан елмайды гына, әни башын селкеп торды да күнде. Шулай итеп, әбинең ике башлы бөркеткә охшаган саллы ачкычы минем кесәгә күчте. Әти киткәч моңаеп калачак «Волга» һәм гараж ачкычы да, шактый вәгазь укулардан соң, чылбырга тагылып, җинси кесәсенә чумды. Әти тарафыннан мәсьәлә шулай куелды: әгәр талонны бер генә тиштерсәм дә, машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителәчәкмен икән. Талонны чиста саклар өчен сиңа нишләргә кала?! Гаражны сирәк ачып керергә.

Тормышны үземчә, кашык ясаудан башлыйсым килә...

### III

Борынгы йортлар биеклеге белән түгел, ә бизәнү рәвеше белән генә ярыша алалар. Бер-берсенә иңгә-иң терәлеп, бер-берсен җылытып утырган бу йортларда күрше һәм ишегалды дигән төшенчә сакланып килә: кайсы ишек артында кем яши, бу кем тәрәзәсе, чыгышы, нәсел-нәсәбе кайдан, нинди урында эшли — барысы да билгеле. Монда гадел ярдәмләшү дә, хәл-әхвәл белешү дә, мәкер-гайбәт тә житәрлек. Тормыш дигән оркестрның бөтен кыллары да үз тавышын бирә.

Бүген салына торган күп катлы йортлар нинди? Алар ялгыз калка, алар ялангач күренә, аларны киендерәсе бар. Тоташ йокы бүлмәсеннән генә тора кебек мондый йортлар. Кешеләр ташкыны эш урыннарыннан кайтып, урамнардан агылып керә дә, үз гаиләсе белән чикләнеп, йокыга тала. Сөйләшә — йоклый. Телевизор карый — йоклый. Газета-журнал укый — йоклый. Күмәк ялгызлык.

Мин ишегалдына кайтып керәм. Түбәдән боз сөңгеләр асылынган. Борынгы йортларның, гадәттә, искергән, үзенчәлекле исе була. Син аны ишекне ачып кергәнче үк тоя башлыйсың. Баскыч төбендә тагын Ризван абый тора. Иреннәре кыймылдавына өлгерә алмыйча, сүзләре соңлабрак чыга, тузган магнитофон кебек. Димәк, бер стакан кызылны сендереп тә өлгергән!

— Нәсимә килгән иде, әйдә, миңа керик әле,— дип, ул ишекне ачты. Минем әбинең исемен әллә ничек ягымлы итеп әйтә белә ул.

Ризван абыйның бүлмә җиһазы бик гади. Керләнгән пәрдә, иске одеал ябылган кушетка. Азык калдыклары таралып яткан өстәл, бер якка кыйшайган шифоньер. Өстәлдә балта белән юынып ясалган сыман шешәле бормотуха тора.

Ризван агай мыдыр-мыдыр сөйләнеп, өстәлгә яньчелеп беткән чәйнек китереп куйды.

— Сиңа Нәсимә менә бу төргәкне калдырды.

Әбиләргә ике көн инде барганым юк иде, менә бит, алма пирогы, калын миләш кагы калдырып киткән.

— Минем әби камыр ашларын Париж кухнясын шаккатырырлык итеп пешерә белә, кая, Ризван агай, сыйланып алыйк.

— Минем чәй синеке сыман булмас инде ул, гаепләмәссең.

Ризван агай шкафтан касәләр алды, боларга вино куелыгы сыланмаган.

— Нәсимә бер дә картаймый, үзен тәрбиядә тота белә шул. Алт-

мышка да житмәгән икән әле ул, нигә картайсың. Әллә мин әйтәм... ул да ялгыз, мин дә ялгыз... йә, йә, кашыңны җимермә, шаярып кына әйтәм.— Ризван агай үзе үк оялып, уңайсызланып куйды.— Чиста ханым шул... Кая инде безгә, таушалып, керләнеп беткән адәмгә янадан тормыш кору...

— Нинди керләнү ди, син бит көн аралаш мунча кереп торасың.

— Шулаен шулай да. Тән түгел, җан керләнүне әйтәм. Альбомны карап утырдым да карчыгымны искә төшердем әле бүген. Шушы бүлмәдә берьялгызым утыз ел гомер кичергәнмен. Вино эчеп, китап белән закусить итеп ятам шулай,— дип ул почмакта өелеп яткан китапларга ымлады. Кушеткада яткан тимер бикләвечле альбомны алды. Беренче битендә кыр-кырлары саргая башлаган фото. Кыңгыр салган кепкасы астыннан бөселеп чыккан куе чәчле, ак якасын костюмы өстенә чыгарып салган егет. Бераз мактанчык кыяфәт. Янәшәсендә күтәртмә җилкәле костюм кигән, чәч үремен маңгай өстеннән ике мәртәбә урап куйган чибәр генә кыз. Егетенә ул мена-мена борылып карар кебек, тик фотограф аңа объективка төбәлергә кушкан.

— Менә бу Нурия апаң була инде. Ә бусы — авылның беренче егете. Кайтып төшә шахтадан, хром итек кунычына кыныллы хәнҗәр тыгылган, кулында тальян гармун... Шушы бостон костюм һаман да исән әле, тузмады. Үзем генә кырау суккан помидор кебек җыерылып беттем.

Вакыт никадәр рәхимсез! Фотодагы егет чалымнарына Ризван агайның йөзендәге бер генә сызык та туры килми. Ышанырлык түгел. Ничек шулчаклы үзгәрергә мөмкин?

— Менә бу каһәр суккан бетерә кешене,— дип, Ризван агай вино шешәсен тартып китерде, авыр сыекчаны стаканга яртылаш агызды.— Ансыз яшәп тә булмый. Син эчмичә дөрес эшлисең. Чиста кал. Миңа үзгәрергә соң инде. Гомерләр диген... Ничек башлап җибәргән идем тормышны; алып киттем Нурияне Донбасс шахталарына, яши башладык гөрләтеп... Сугыш барысын да җимерде. Яшь бала белән озатып калды Нурия. Поезд кузгалыр алдыннан, тимер футлярга салынган бармак башы кадәр генә корьәнне муеныма асты. «Күз карасы кебек сакла, исән каласың»,— диде. Пленга эләккәч, каерып алдылар. Дөрес әйткән икән, мин шул чакта инде үлгән булганмын. Аннан соңгы яшәвем — җан асрау гына...

— Сугыштан соң кавыштыгызмы, Ризван агай?

— Пленнан котылгач та урау юллар үтәргә туры килде шул. Себердән илле алтынчы елда гына кайтып егылдым Донбасска. Нурия... Шәһәргә немецлар керер алдыннан гына китәргә уйлаган. Соңгы поездга утыра алмаган, бичара. Ул чакларны күз алдына китерәсеңдер: кеше өстендә кеше. Товар поезды кузгалгач, баламны гына булса да алыгыз, зинһар, дип җылап яреп бара башлагач, бер хатын үрелеп алган баланы. Партизаннарны эзләп урманга качып барганда Нурияне немецлар тотып алып харап иткәннәр.

— Ә бала?

— Башта эзләтә алмадым. Фамилиясенне әйтергә дә куркыныч заманнар иде шул. Таптым егерме биш елдан соң. Монда, Казанда яши.

— Бәхет бар шулай да.

— Бәхет, дисең... Ишегеннән дә үткәрмәде. Кем соң мин утыз яшьлек ханым каршында. «Кайда идең син миңа бик авыр чакларда?»— дип бер генә сүз әйтте. Башымны иеп китеп бардым.

— Аңлатмадыңмыни ниләр күргәнеңне?

— Аңлатып ни файда? Ә ул хаклы.

— Үзем барып сөйләшеп карыйммы?

— Кирәкми? Мәңге үпкәлим, кирәкми!

Ул арада Наянның тәрәзә катына килеп өргәне ишетелде. Ризван агай сәгатенә карап алды:

— Ун минут үткән. Прогулкага чыгарган идем, хәзер,— дип чыгып та китте.

Кыерсытылган язмышны киереп торган стеналар тараеп калды сыман. Мин, авыр уйлардан арынырга теләп, яшел төсен саклап кипкән себеркеләрне санарга керештем. Аз калганнар инде. Кул белән кагылуга коры кыштырдап, узган елгы җәй исе сирпелеп китә. Ризван агай мунчачы булып эшли. Хезмәт хакы аз. Җәй буе ул себерке бәйли. Түшәмгә әллә ничә рәт бау тартылган. Түшәм-стеналар бервакыт яшел себерке белән тула. Сортлары төрле, имәннән, каеннан, зиректән, мәтрүшкә, төрле исле үләннәр кушылганы — шуңа карап бәяләре дә үзгә.

Ишектән шатлыклы көлгән кебек өрә-өрә Наян килеп керде. Аякларымны иснәп, иҗен-буен үлчәп карады да, шул ук мин икәненә ышангач, тынычланып, ишекле-түрле йөренә башлады.

— Менә барысы унике себерке калды. Деликатес. Мунчада чабыну түмен кырыкка җиткәннән соң гына аңлый башлыйсың. Яратып чабынучылар минем аерым исәптә. Кызык эш. Министрдан алып каравылчыга кадәр күз алдымнан үтә. Кемнең тәнендә нинди яра, нинди житешсезлеге бар — бөтенесен белеп торам,— дип, Ризван агай кыеш тешләрен күрсәтеп елмайды.

Шешәдә эчемлек бетеп килә икән шул. Ризван агай исерми исерүен, артыгын сөйләнә башлый. Кузгалырга вакыт.

— Ишек тоткаң шәп синең, Ризван агай.

— Кергән саен кызыгасың, каер да ал!

— Торсын...

— Ясап та күрсәткәннәр элгәреләр, ә!

Чынлап та саллы тотка бу. Елан кебек бөтерелгән орнамент төшә дә, кабарынып килеп, арыслан башына ялгана. Үткен азау тешләрен күрсәтеп авызын ачкан арыслан — ишекнең сакчысы кебек. Тотка өлеше шомарган, калган җире кат-кат буялып, керләнеп беткән. Буяу чатнаган урыннардан гына аның жиз икәнен чамаларга була.

— Ал, барыбер күченәсе.

Ишекне япкач та Ризван агайның тавышы колак төбендә яңгырап торды: «Барыбер күченәсе... барыбер күченәсе...»

Өске катка күтәрелә башлауга, арттан Анна Леонардовнаның ягымлы тавышы ишетелде:

— Маратик, прошу прощения, вас не затруднит, если я вас попрошу уделить мне минутку времени, если не очень спешите, зайдите, пожалуйста.

Һәр сүзне үтә бер тәм белән жырлатып эндәшүгә ничек инде битараф каласың! Анна Леонардовна тәтенсу гәрәбә төсендәге нәфис бармаклы кулын иңемә куеп бүлмәсенә алып керде. Почмактагы алтын кысалы икона каршында янган ладан (канәфер) исенә тагын мин белмәгән ниндидер җылымса ис тә килеп өсталгән. Моның сәбәбе менә хәзер аңлашылды.

— Миндә бәйрәм бүген, күр әле,— Анна Леонардовна мишәрчәләтеп татарча да сөйләшә белә. Креслода кара бәрхет җәймә өстендә әле юеше дә кипмәгән песи балалары ята. Зәгыйфь чыелдашып, аякка басарга, тизрәк йөреп китәргә азапланган бүләләр тагын. Ана мәче, балаларын каплап, миңа төбәлде. Күзләрендә — тәвәккәллек, ялвару. Гадәттә, әзрәк үскәч, песи балаларын Анна Леонардовна кешеләргә бүләк итеп бетерә.

— Бик матурлар икән, исән үссеннәр инде.

— Рәхмәт, шулай булсын. Бу юлы беркемгә дә бирмим инде. Я песинең рәнжеше төшәр. Сорыйлар бит, кызыгалар, каршы килә алмыйм... Мин сөткә киткән арада Нәсимә килгән булган, кызганыч, күрешмичә калдык.

— Үзегез кунакка барыгыз.

— Чакыра да бит. Күрәсең, тагын мәшәкать килеп чыкты: балалар...

Анна Леонардовнаның тагын нидер әйтергә җыенып та уңайсызланган кебек торуын сизенеп, мин:

— Берәр ярдәм кирәкмиме? — дидем.

Анна Леонардовнаның яшь кызлар кебек алсулык йөгергән йөзе ачылып китте:

— Уңайсыз да инде... Мин бүген тыз-быз йөргән булып, вазамны төшереп ваттым. Сугышта үлеп калган иремнең бүләге, аның төсе итеп саклый идем, бердәнбер хрусталь вазам, минем бүтән байлыгым юк, күреп торасың... Шуны ябыштыра торган салон бар диләр...

— Бөтен борчуыгыз шул гына булса, эшлибез аны, Анна Леонардовна.

— Менә рәхмәт.

## IV

Китап битләрендә гасырлар бер йодрыкка сыя. Йодрыктан тарих битенә кан тама. Гел сугышлардан, җимерү-кырулардан гына торган микәнни бу дөнья? Укып чыгарга бер гомер җитмәс дастаннар ат тоягы астында калып чатнаган гасырлар арасында — бер мизгеллек ял вакытында гына барлыкка килмәгәндер бит?

Азия киңлекләреннән ниндидер могҗиза белән кайнап чыккан халыкларның бөек көчешен син — егерменче гасыр малае — башыңа сыйдыра алмыйча ятасың. Торшерның тоныкутыкитаптагы саран сүзләр артында вакыт каберенә әйләнгән упкыннарны яктырта алмый. Син шул упкыннар аша сикереп артка, тормыш агачы тамыр җибәргән дәверләргә омтыласың. Вак мәшәкатьләр белән талчыккан җаның үткән зурлыкларны сыйдыра алмый. Алтын бүре башы чигелгән байракларын җилфердәтеп киңлек яуларга чыккан төркиләрнең офыккача җәелгән атлы чирүе, җир тетрәтеп тупырдаган тояк тавышлары, ерагая барып, диңгез шавына әйләнә дә сине рәхәт йокыга талдыра. Сак кына ишек шакыганны да, йомшак чүәкләрнең киез паласка тияр-тимәс басып килүен дә сизмисең. Ялангач күкрәгеңә боз кагылгач кына сискәнеп күзеңне ачасың. Юк, каршыңда атын аягүрә бастырган зәңгәр күзле һун сугышчысы да, угын төзәгән кысык күзле монгол да түгел, гап-гади кыз елмаеп тора — Айсылу. Йогып калган кул салкыны күкрәгеңне пешерә башлый. Сине адаштырып йокыга талдырган китапның идәнгә төшүендә дә аның эше юк. Урындыкны тартып китерә дә, тезен тезгә куеп, кырыеңа килеп утыра. Син үзең дә сизмәстән, һәр күзәнәге сулап торган йомры тез башына тәҗрибәсез кулыңны суза башлыйсың. Айсылу, чебен үтергән кебек, чап итеп кул аркаңа сугып куйгач кына, йокыңнан тәмам айнып, мендәреңбелән бергә башыңны күтәребрәк куясың.

— Гафу ит, уяттым бугай.

Айсылуның тавышына ялганып, сәгать иркенләп кенә уникене суга башлады.

— Болай иртә йокыга киткән өчен кыйнасаң да була.

— Сине эзләп бүген бер дама килгән иде.

— Мине?.. Эзләп?.. Дама?..

Дилярәдән кала минем кемем бар? Ә аның мин яшәгән йортка бер тапкыр да килгәне юк. Аңа үпкәләп, бер атна буе күренмәскә дип ант иткән идем. Үзе сагынып килүенә ышана алмыйм. Кызыксынуымны сиздермәскә кирәк. Битараф кылансаң гына Айсылу ачылачак.

— Син дискотекадан кайттыңмы?

— Каян беләсең?

— Битләрең ут янып тора.

— Салкыннандыр.

— Пешеп биегәнсең. Егетең беләнме?

Айсылу дәшмәде. Дискотекада мин үзем елга бер-ике генә булам. Узган атнада да барасы түгел идем, Айсылу билетлар алып куймаган булса. Анда — бүтән дөнья. Онытылып кереп киткәнеңне сизми дә каласың. Ҡанны уйната торган ритм-музыка, кыргый көченә буйсындырып, җирсез, уйсыз, гамьсез калдырып, сине тоташ хәрәкәткә әйләндерә. Мизгел эчендә бер балкып, бер сүнеп алган төсле утлар кешене кисәкләргә

таркатып күрсәтә. Өзек-өзек хәрәкәт эчендә тырпайган кул, гәүдәсеннән аерылган баш сурәтләре күз алдында бутала. Музыка шаша, күкрәк читлеген җимереп керә дә бөтен уйларыңны актарып чыгара, буш гәүдәңне котыртып, галәм киңлегенә ыргытылган дулкында талкый башлый. Төсләр камаша; канлы кул, сары йөз, ак гәүдә, яшел тешләр чагылып-чагылып ала, әле су төбендә, әле ут эчендә каласың. Җете төсләр арасына килеп кергән куе караңгылык төсләр кискәләгән баш-аякларны бергә туплый да бию мәйданы кулларын сузып бәргәләнгән тере харәбә өеменә әйләнә. Музыка бетеп залда ут кабынуга, кыргый буталыш, табигый кешеләргә әверелеп, мәйданны бушата. Дөнья үз хәленә кайта. Танцы вакытында мин Айсылуны күрмәгәнмен, ә тойганмын гына икән. Ул күзләре белән һаман кемнедер эзли, минем сүзләргә ярым-йорты гына җавап бирә. Диск-жокей карлыккан тавыш белән яңа музыканың эчтәлеген таныштыра башлагач кына миңа килеп сыена.

— Бүтән кешегә дип алган идеңме билетыңны?

Айсылу ачу белән кулымны кыса. «Сорама! Сорама! Сорама!» — дип сулкылдый аның учындагы кан тибеше.

Ләкин бүген мин Айсылуны төсле музыка белән исереп кайткан дип ялгыштым.

— Бүген дүшәмбе. Дискотека кичә булды. Бүтән бармаячакмын мин анда.

— Нигә?

— Әй, сөйләргә дә оят. Ритм-музыканы мин күңел иреге, чистарыну, ваклыклардан өстен көчкә омтылу дип кабул итә идем. Әтинең «эмоциональный опиум» дигәне дөрескә чыга ахрысы.

— Көне-төне тыңласаң, бөтенләй акылсыз калырга да мөмкин.

Беренче тапкыр рок-музыканы мин үзем сигезенчедә укыган елны тыңладым. Саша исемле малайның спортсмен абыйсы Америкадан шундый бер пластинка алып кайткан булган. Аның әти-әнисе театрда чакта без, малайлар, җыелыштык та моңарчы колак ишетмәгән, тыелган музыка күкрәвендә сәгатьләр буена йотылдык. Хәтәр аһәң бер сыта, бер чөя, күкрәк читлегендә йөрәк тәннән аерылыр дәрәҗәдә бәргәләнә, без, тәмам исерешеп, төнге паркка чыгып киттек. Дөнья тубыктан. Шашып кычкыра-кычкыра, бер-беребезне уздырырга теләп агач эскәмияләрне, балалар уйный торган мәйданчыктагы кечкенә өйләрне, баскычларны вата башладык. Аннары — милиция, ата-аналарны чакырту, мәктәптә тикшерүләр, ваткан нәрсәләрне яңадан төзәтү...

— Буыннар арасындагы чылбырны өзә торган музыка бу,— ди минем әти. Ул тальянын шыңгырдатса, миңа көлке. Беләсеңме, кичә дискотекада ни булды? Позор... Кинәт кенә музыканы туктаттылар — врачлар, милиция икән. Кызлардан барыбызны да җыеп алып киттеләр.— Айсылу йөзен куллары белән каплап торды.— Тикшергәннән соң җиде кызны алып калдылар. Мин берни дә аңламадым. Әтигә кайтып әйткән идем, ул бүген белешкән. Теге җиде кыз, уналты-унҗиде яшьлекләр, колготкиларын урта бер җирдән лезвие белән кисеп килгән булганнар. Ап-ачык дәлил... Ничек аңлатырга инде сиңа... Танца вакытында бозыклык эшләр өчен.

— Син андый түгел, Айсылу...

— Барыбызга да кагыла ул.

— Бу музыка хәзергә җимерә, вата, шартлый. Аннары ул һәр халыкның үз аһәңе белән баетылып, тынычрак агымга күчәчәк.

Мин үзем дә сизмичә Айсылуның кулын учыма алып, сыйпап утырам икән. Икебез өчен уртак тынлыктан айнып киткәч, ул кисәк кенә кулын тартып алды. Җир түгәрәк. «Магеллан» чыгып киткән ноктасына кире әйләнеп кайтты:

— Исеме ничек ул дамаӊның?

— Син күргәнсең бит, мин түгел. Чибәр идеме?

— Так себе. Кара сипкелле.

Диларә икәненә шигем калмады. Айсылу киң халат кесәсеннән күн белән тышланган китап чыгарды.

— Менә, сиңа тапшырырга кушты. Красивый повод, правда,— дип китапны күкрәгемә куйды.

Казан ханлыгы тарихы — ксерокопия. Кайбер битләре бигрәк тонык чыккан.

— Биология факультетында син тарих укып әзерләнәсеңме?

— Халыкларның каян чыкканын белми торып, микробларны өйрәнеп булмый.

— Синең дамаң кайчандыр балет түгәрәгенә йөргән ахрысы, походкасы вызывающе независимая.

— Гимнаст. Мастерлыкка кандидат.

— Хәзер тренермы?

— Э-һы, миңа тарих укыта.

— Хуш, мин киттем,— дип Айсылу кисәк кузгалды.

Сизеп торам, кызыйның күңелендә бөтенләй икенче тормыш бара. Бүген ул гадәтенчә салкын-горур түгел. Ни газаплый аны? Күзләрендә моң, ят күләгә шәйләнә. Эзләр аңа таба киләме, офыкка китеп барамы — миңа караңгы...

## V

Минем алда гына үткен конькилары белән бозны чыжылдатып, кинәт таеп егылмаган булса (хатын-кыз егылган чакта да нәфислеген сакларга тырыша, ирләр кебек гөрселдәп барып төшми), әйе, нәкъ менә шул секундта таеп егылмаган булса, без таныша алмый калыр идек. Кар астыннан ишетелгәндәй карлыккан музыка һәм көчле прожекторлар яктысында мыжлаган халык арасында безнең юллар кисешмәс иде. Аны күтәрешеп торгызганда күкрәгенә ялгыш орындым бугай. Ул рәхмәтле дә, шелтәле дә карашы белән мине көйдереп алды, кул житмәс арага тартылып куйды. Саф һаваданмы, егылуына оялуданмы — аның йөзе кызарып чыккан. Шул кызыллыкка мул булып кара тут сибелгән. Башлыгы астыннан ишелеп чыккан кап-кара чәче ут яктысында шәмәхәләнеп китә. Бу бит — төн кызы. Очраклы танышу гадәтем булмаса да, нигәдер телгә куәт иңә:

— Марат. Өйләнмәгән. Егерме бер яшь. Алтмыш тугыз килограмм,— дип кулымны сузам.

— Диларә. Яшемне оныттым. Авырлыгымны белмим,— дип, ул сузылган кулны игътибарсыз калдыра.

— Милли сувенирлар цехында кашыклар ясыйм хәзергә...

— Аннары?..

— Аннары өйләнәм... Сиңа.

— Миңа?! — Диларәнең ирен читендә саран гына елмаю чагылып алды.— Мин бик усал бит.

— Мин дә фәрештә түгел. Эчәм. Тартам. Өйгә вакытында кайтмыйм. Кыскасы, коточкыч начар кеше. Усаллык белән генә кулда тотып була.

— Хуш алайса,— дип, Диларә ыспай гына шуып китте. Коньки очын бозга каптырып, мин дә алга ыргылдым.

— Курыктыңмы? — дим.

— Балалар вакыты чыгып бара, иртәгә мәктәпкә барасың бардыр.

Бусы инде артык иде. Мин ачу белән битне сыпырып куйдым. Шулай артык яшь күренәм микәнни? Ах, почык борын, син үзең минем чырайга һаман малайлык шаукымы биреп торасың түгелме?

— Шулай... Әйбәт егетне ярату жиңел ул. Син менә минем кебек юньсезне кеше итеп кара!

Без юл буе кирле-мырлы сөйләшеп кайттык. Диларә Фукс бакчасы янында мансардасы белән өч катлы булып күренгән иске бер йортта

тора икән. Капкага җиткәч ул кырысланды.

— Хуш. Бүтән күрешмәбез дип уйлыйм.

— Үзеңә кыен булыр бит.

— Ни өчен икән?

— Өеңдә дә, төшеңдә дә мине күрергә зар булып интегәчәксең.

— Бөтен акселератлар да синең кебекме?

— Минем белән танышкан кызларның берсе дә әлегә миңа гашыйк булмый калганы юк. Сау бул!

Капка келәсенең чыкылдавы Диләрәнең көлүе булып яңгырады. Барыбер бүтән очрашасы юк, сөйләнеп калырга кирәк ичмасам. Кызу-кызу атлап барган җирдән аяклар әкренәя башлады. Йөгереп әлеге йорт каршысына килдем дә юан тополь агачы артына постым. Диләрә кергәч, тын йортта ниндидер үзгәреш булырга тиеш, кайсыдыр тәрәзә пәрдәсе булса да дерт итеп селкенеп куяр сыман. Көтәм. Тымызык кына кар ява. Әнә, иң өстәге катта, сыңар тәрәзәле мансардада ут кабынды. Борынгы йортның шундый чарлагында яшәү минем күптәнге хыялым иде. Диләрә пәрдәне ачып урамга карады. Мине яшереп торасын йөз ел алдан белеп, бу топольне утырткан кешегә рәхмәт әйттем дә кайтып киттем. Киңәегез, урамнар! Бер кул җылпүе белән карларны эретеп бетерәм, яз китерәм сезгә!

Икенче көнне килеп, яшел пәрдәле тәрәзәгә йомарлап кар ыргыттым да китеп бардым. Өченче көнне дә шулай. Дүртенче көнне килгәч, карыйм: тәрәзәгә сылanган кар эзләре өчпочмак булып тора. Тагын кар йомарлап алып ыргытам гына дигәндә кулымнан кемдер тотып алды. Карасам, Диләрә! Тополь артында сагалап торган икән.

— Элэктеңме?

— Тәрәзәңә сарылып, елап эрисе кар иде бу, насыйп булмады.

— Сабый син.

— Әйдә, Казанны аяк астыңа ыргытам! Кая телисең?

— Ресторанга!

Минем бармак очы кесәдәге какланып беткән «өчлек»кә килеп төртелде. Бүтән кесәләрдә тынлык, акча шылтырамый иде. Диләрә астыртын елмаеп мине күзәтә.

— Шаярттым гына. Син Казанныкы түгел бит, әйеме?

— Каян белдең?

— Татарча әйбәт сөйләшәсең.

— Тын океаннан килгәнемә бер ел.

— Алайса, Казан синең өчен ачылмаган утрау. Киттек!

Йомшак кына кар ява. Борынгы йортлар моңсу аклыкка күмелеп утыра. Фукс бакчасын үтеп, без текә яр кырыена килеп туктыйбыз. Кинәт кар явудан туктый, ак пәрдә күтәрелә. Аста — боз юрганын ябынган Казан елгасы. Аргы ярда кара куаклыклар, тоташ стена булып тезелгән яңа шәһәрчекнең утлары тоныкжемелди.

— Казанның һәр карышы — тарих,— ди Диләрә.— Син үзеңнең нинди урында басып торганыңны беләсеңме? Унтугыз яшь... Очынып, яшәргә омтылган чак югыйсә... Ә ул, кесәсенә салкын револьвер тыгып, үз-үзен атып үтерергә дип нәкъ менә шушы урынга килә. 1887 елның уникенче декабре... Күз алдыңа китер, беркемгә билгесез Алексей Пешков, кар шыгырдатып, монда таба килә. Әгәр ул шунда песи баласы белән сөйләшеп утырган төнге каравылчыны күреп туктамаган булса, салкыннан калтыранган песи баласын жәлләп, толып эченә алып җылыт, димәгән булса... Ул киткән яктан яңгыраган револьвер тавышына, бәлки, төнге каравылчы бөтенләй дә игътибар итмәгән булыр иде. Ул йөгереп килеп карый да, тиз арада извозчик табып, авыр яралы Пешковны больницага озата, соңыннан да янына килеп йөри.

— Бәхетле очраклылык.

— Киләчәктә Максим Горький булачак кешене үлемнән коткарып калганын башына да китермәгәндер каравылчы ул чакта.

— Кем икәне билгелеме аның?

— Мостафа Юнысов. Гап-гади бер татар агае.

Утлары саран булган ул чорның салкын бер төнен күз алдына китерүдән, өшеп, куырылып куясың. Тизрәк моннан китәргә, ишелеп ява башлаган карлар арасыннан яктыга чыгарга кирәк.

Урам безне үзенә бөтереп алды. Мин — сукыр. Диләрә мине җитәкләгән. Үзең яшәгән шәһәрнең тарихын белмәгән килеш: «Мин күрәм!»— дип ничек әйтә аласың?

— И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Төнге Казан... Менә бу чиркәүдә малай чагында Шаляпин хорда җырлаган. Менә бу!..— Диләрәнең серле тавышы минем өчен соңга калган билгесезлекне уята, минем горурлыгыма суга, ни өчен соң әле мин түгел, барын да ул белә? — Менә бу бинада Деренков пекарнясы булган. Алексей Пешков күмәч пешергән җир... Ә бу — Кекин йорты. Гаҗәп бит: таштан үреп эшләнгән. Нинди мәһабәт йортның түбәсе кызык, бернинди архитектура рамкаларына сыймый: читкәрәк китеп карасаң, өстә калай түбә белән ябылган гап-гади авыл йорты күрәсең. Имеш, ярлы чагында Кекин шундый йортта яшәгән. Соңыннан шул йортны истәлек итеп түбәгә менгертеп калдырган, диләр.

— Бай булсам, мин дә шулай итәр идем.

Диләрә мине, җитәкләп, узган дәверләргә алып кереп бара. Урамнарның исеме үзгәрә. Кар бизәкле тәрәзәләр яктырыбрак китә. Дивар-лар, калкынып, Диләрә теле белән сөйли башлый: «Миндә Сәйдәш торды», «Тукталып китегез, минһем тәрәзәләрдән Такташ дөньяга карый иде...»

Без беркемне күрмибез, искәрмибез, урам — икебезнеке генә. Ак бишегендә тирбәткән шәһәр минем өчен ачыла бара, ачыла бара.

Университет бинасы үзенең зыңлап торган колонналары белән ак рояльгә охшаган. Россия язмышын тетрәтерлек симфониянең беренче ноталарын яшь Ульянов шушында язган. Постаментка баскан яшь Ульяновның мәрмәр чәченә, мәрмәр иңнәренә әле генә яуган җылы кар яткан.

Колонналар арасыннан, авыр ишекне тантаналы ябып, Аксаков кереп китә.

Колонналар арасыннан, авыр ишекне соңгы мәртәбә ачып, яшь граф килеп чыга — «сәләте җитмәү» сәбәпле укудан чыгарылган Толстой, яңа яуган кар өстендә тарихи эзләр калдырып, Воскресенский урамы буйлап үлемсезлек иленә китеп бара...

Шәһәр оеп калган диңгез дулкыны өстендә утырган кебек. Бер урамнан карасаң, маяк булып манаралар калыккан борынгы түбәләр генә күренә. Калкулыктан төшүгә, тоташ стеналар арасында чумып каласың. Болак күперен чыккач, йортлар вагая, тагын да тыгызлана төшә. Кулымнан җитәкләп, Диләрә мине карлы әкият дөньясына алып керә.

— Менә Пушкин тукталган йорт. Бусы — Тукай яшәп алган «Амур» кунакханәсе. Монда шаулап торган «Печән базары» булган.

Бер заман бардым Печән базарына,—
Шунда мин таптым азык язарыма.

Тукайны беләсеңдер дип уйларга кирәк...

— Русча укыдым. Татарчасы авыр аңлашыла.

— Ул чакта чын шагыйрьләр теле булган шул...— Диләрә авыртты-рып кулымны кысты.

Безнең сәяхәт Татар бистәсендә тәмамланды. Кайчандыр бу — шаулы шәһәрнең бер-ике катлы йортлардан торган тын култыгы булган. Хәзер инде монда да күп катлы йортлар бәреп кергән.

— Максим Горький монда йөрергә яраткан. Беләсеңме, бу турыда ул ничек язып калдырган.— Диләрә, хәтерен барлап, күзләрен кыса төшеп бер тын торды да биек койма эчендә утырган йортларга карап сөйли башлады: «На чтениях было скучно, хотелось уйти в Татарскую слободу,

где живут какой-то особенной, чистоплотной жизнью добродушные, ласковые люди; они говорят смешно искаженным русским языком; по вечерам с высоких минаретов их зовут в мечети странные голоса муэдзинов,— мне думалось, что у татар вся жизнь построена иначе, незнакомо мне, не похоже на то, что я знаю и что не радует меня»

Менә шулай. Күпме исемнәр белән бәйле безнең шәһәр. Килеп, Казанның изге суын эчеп киткән кеше, һичшиксез, бөек була.

— Бу безгә кагылмыйдыр бит, Диларә?

Икенче көнне инде мин аның тәрәзәсенә кар атып та, тополь артына качып та мәшәкатьләнмәдем. Төнге шәһәрне икәү кулга-кул тотышып «алдык» бит, ул мине, мин аны гүя бик күптән инде белгәнбез, очраша гына алмаганбыз. Бәхетле очраклылыкны сузарга теләп, күңел алга йөгерә. Ком сәгате ага тора, мин аның шавын ишетәм, бүгенге төн дә, иртәгәге көн дә кабатланмаячак, нигә әле кыюсызланып торырга?.. Шундый тәвәккәл уйлар белән очынып, мин Диларәнең фатирына килеп кердем. Кердем дә бер мәлгә аптырап калдым. Кара тут йөзенә якут кызыллыгы балкытып хисләнгән кичәге Диларәне алыштырып куйганнармыни — йөзе сүнеп калган. Кулында китап. Янәшәсендә яткан магнитофоннан сагышлы көй саркый.

— Чишен, уз,— сүрән ут яктысы кебек үк салкынлык белән әйтелгән сүз минем дә ашкынып килгән кызулыкны суытып куйды. Өс киемен салып мин аның каршысына килеп утырдым. Бүлмәсе зур түгел. Кая карама, иске тышлы, кыр-кырлары саргайган китаплар. Диларә саран гына елмайды:

— Ник килдең?

— Сагынганга.

— Мине сагыну яхшыга китермәс бит.

— Тарихка кереп югалуың бар, уятырга дип килдем сине.

— Мине уятырга соң инде. Ун елга алданрак туасың калган.

Нечкә биленә сыланып торган трико кигән Диларә белән үземнең арада бернинди яшь аермасын сизмим, ә ул һаман шуны искәртә.

— Тарихны белмәгәннәр — тере мәет, ашау өчен генә яшиләр.

— Мин бүген иртән чәй эчкән килеш, димәк, ашар өчен генә яшәмим.

— И бичара, хәзер чәй куям үзеңә. Бичара дигән өчен үпкәләмә, ул якын кешеләргә генә әйтелә торган сүзем.

Тора-бара ачыкланды: Диларә Фәннәр академиясе филиалында эшли икән. Ике ел элек диссертация язып бетергән. һаман әле якларга җыенмый. «Яклау спектакль белән бер, шуңа сценарий язасым килми»,— ди.

Аның бүлмәсендә утырганда (иске китаплар, сагышлы музыка) үзеңнән-үзең олыгая башлыйсың кебек. Урамга чыккач кына Диларә кабынып китә. Саубуллашыр алдыннан кулымны җибәрми тора да:

— Сабый шул әле син, нәкъ синең шикелле абыең булса иде синең,— ди.

Айлар буена шулай бер утка, бер суга салып мине тәмам аптыраткан, йөдәткән Диларәгә мин, бер атна күренмәячәкмен, дип үпкәләп киткән идем, бүген менә сәбәп табып үзе килгән. Бу минем кечкенә генә җиңүем түгелме!

## VI

Җиз кранны боруга, мин Идел белән тоташам. Җир тирәнлегеннән кысылып килгән су, ирекка чыккач, күңелле чыркылдап, учка сыя алмыйча бии башлый. Юеш сөлге белән тәнгә ут бөркеп ышкынуга,

бөтен күзәнәкләр уяным сине яңа көнгә әзерли. Әбинең тавышсыз йөргән җиз телле Париж сәгате, арган тавыш белән, иренеп кенә җидене суга.

Иртәнге кәеф — көннең кояшы. Ишектән үзалдыңа елмаеп чыгарга кирәк. Ишек төбендә тагын Ризван агай белән очраштык. Наян, атылып килеп, чалбар балагына тамга салып өлгерде. Ризван агай авыр поход сумкасын иңеннән төшергәндә буш шешәләр зеңгелдәп тавыш бирде. Ул иртүк парклардан, елга буйларыннан буш шешәләр җыеп кайта. Юып чистарта да сатарга илтә. Этен дә өйрәтеп бетергән. Куе куак араларыннан Наян шешәне муеныннан кабып кына алып чыгып бирә. Шешә саткан көнне прәннек эләгәсен белә Наян.

Ризван агайның авыр сумкасын күтәрешеп керттем.

— Наян шулкадәр остарды хәзер. Кар астында яткан шешәне исеннән сизеп казып чыгара.

— Бусын арттырасың инде, Ризван агай.

— Чынлап! Әйт әле, Наян, абыең ышанмый торган була.

Наян, маңгай йонын селкеп, хуҗасына төбәлеп торды да ике мәртәбә вак-вак кына өреп алды.

— Молодец, Наян,— дип Ризван агай аның башыннан сөйде.— ике шешә тапканын әйтеп бирдеме, ышандыңмы инде хәзер?!

Ризван агай канәгать елмая. Наянның да авызы ерык, ишек тоткасындагы арыслан башы да елмайган шикелле.

— Шәп тотка бу, Ризван агай.

— Бүләк итте дип сана. Кайчан телисең, каер да ал, барыбер күченәсе...

Бу сүздән мин дертләп киттем. Шулай ук сүтәрләр микәнни бу йортны, күчерерләр микәнни безне? Яңа йортта иске мебель тузаны да аллергия кузгатыр кебек, тамак төбе кытыкланып алды.

Апрель юеше эшкә барып җиткәнче ботинка эченә үтеп өлгерде. Кичне чак җиткердем. Бүген мин Диләрәне күрергә тиеш. Сагынмаска дип игълан ителгән бер атналык рухи ачлыкның соңгы минутлары җитеп килә. Бүген Мастерның бер айга ялга китүе билгеле булды. Урамга чыккач, тагын яңа хәбәр: ул Пассаждагы кечкенә кинотеатрда кичләрен афишалар язып торучы художник булып эшли икән. Бер айга үз урынына мине калдырырга тели.

— Анда әйтелгән. Күрсәтеп, сиңа ачкычны гына тапшырасы,— ди.

Пассажга барганчы Диләрәне күреп чыгарга булдык.

Карлыгач оясында, яшел пәрдәле тәрәзәдә ут яна иде. Миңа калса атна буена монда ут сүнмәгәндер кебек тоелды. Иелеп вак ташлар алдым. Беренчесе өскәрәк китте, икенчесе кырыйгарак, өченчесе... тәрәзә зеңләп куюга, пәрдә ачылды, тирләгән пыяла аша Диләрәнең шәүләсе күренде. Мин һәрчак үзем генә килә идем, бу юлы тротуарда икәү басып торганны күргәч, форточкадан башын сузган Диләрә аптырабрак карап торды да: «Хәзер чыгам!» — дип кул болгап, пәрдә артында югалды.

— Бәхетле син, Марат, бәхетле...— дип, Мастер иңемнән умырып тотып бер селкетеп алды.— Нинди гүзәл йорт, шуның күккә тиярдәй чарлагында гүзәл кыз яши. Карлыгач оясы дисеңме әле? Шәп!

— Без... болай... дуслар гына,— дидем нигәдер кыенсынып. Мастердан бәхетлерәк булып күренәсе килми иде бу минутта.

— Мин менә, Христос яшенә җитеп, мәхәббәт күрмәдем дисәм дә ярый. Авылда чакта яратып йөргән булдым берәүне. Укытучы кызлары, гадәттә, кыланчык булалар бит, бу да үзен әллә кемгә куеп йөргән булды да... ни үзенең тормышы барып чыкмады, ни минем...

Ак башлыктан, нечкә билле кара пальтосы өстенә озын ак шарф чыгарып салган Диләрә житез-житез атлап килеп чыкты. Янәшәмдә Мастер торгангамы, дулкынланып, яңа бер караш белән Диләрәгә сокланып карадым.

— Таныш бул, Диларә, синең каршыда Мастер үзе.

— Исәнмесез,— дип ул Мастерның сузылган кулына бармак очларын гына тидереп алды.

— Бәхетле кеше сез,— диде Мастер.

— Нигә? — гаҗәпләнүдән Диларәнең йөзендәге елмаюы сүрелде.

— Шушындый җирдә яшисез.

— Көләсезме әллә?

— Иң өске катта ялгыз бүлмә. Сездән өстә бары фәрештәләр генә. Ә җирдә сезне чибәр егет көтә.

Диларә өшеп киткәндәй куырылып куйды. Кузгалдык. Сизелерлек суык төшкән икән. Аяк астында юка боз чылтырап уала. Ул арада, чаттан килеп чыккан кебек, кинәт кенә яфрак-яфрак кар ява башлады. Сүз берләшкәндәй, Диларәне ике яктан култыклап алдык. Язгы кар бәйләнчек, йөзгә, киемгә сылана. Пассажга килеп керү белән, өсләрне кагарга да өлгермәдек, эреде дә бетте. Диларәнең бит очлары алсу-юеш, кара тутлары вак балык тәңкәседәй елтырый. Хуш исле кулъяулыгы белән ул минем каш-керфекләрне дә сыпырып алды.

— Ә мине? — дип муенын сузып килгән Мастерның күмәч битенә дә Диларә кулъяулык тигереп алды.

— Менә рәхмәт! Фәрештә канат очы белән сыйпап алгандай булды.

Диларә җилкә аша аскан сумкасының кечкенә кесәсен ачты. Мастерның да елмаюы сеңгән кулъяулык хәзер шунда кереп чумачак. Кулъяулык почмагындагы сурәт — роза чәчәгенең үткен чәнечкесе минем күңелне тырнап алды. Янып чыккан бит очына салкын учны куям — көнләшүме бу?..

Пассажга Черек күл ягыннан кердек. Алгы ягы бикләнгән, эчтә ремонт бара икән.

— Менә бу минем апартамент,— диде Мастер. Тимер балконнан караганда ярым караңгы, кабарынкы пыяла түшәм күренә. Як-якта көзгеле стеналар.

— Безнең шәһәр өчен уникаль бина бу,— диде Мастер.— Әле берничә ел элек кенә монда магазиннар, халык шаулап тора иде.

Кинозал зур түгел икән. Әле генә сеанс беткән. Җиллэтергә дип ишекне ачып куйганнар. Эчтә тавыш яңгырап ишетелә. Түшәм, сәхнә аллары гаҗәп орнаментлар белән бизәкләп эшләнгән. Тик малярлар аны майлы буяу белән ялтыратып, артык җете, чуар төсләргә җиңел кулдан гына буяп куйганнар.

— Монда элек ресторан булган,— диде Мастер.— Бу стеналар аргентина тангосын, чечетка биюләрен хәтерлидер әле. Күз алдына китерегез: шаулап торган зал, әнә теге почмакта купецлар, яшь фабрикантлар; ә монда — Кавказ, Азия якларыннан Мәскәүгә, Петербургка кайтып баручы графлар, князьләр. Нигә көләсез, беренче класслы ресторан. Ничек атала соң әле? Челтәр колготкиларыннан тән кайнарлыгы бәреп торган ярым ялангач кызлар биюе? Ах, черт, хәтердән чыкты...

— Канкан.

— О! Сезгә «биш»ле, Диларә туташ,— Мастер реверанс ясап алды, терсәген бөкләп официант рәвешенә керде дә, кыланчыкланып сөйли башлады: — Рольгә керегез, янәшәрәк басыгыз! Менә шулай. Гәүдә тотышы, кыяфәт, поза!.. Сез бүген минем кунакларым. Князь Юсупов, рәхим итегез, сезнең өстәл монда. Нәрсә телисез, туташ? Пардон, меню карамасагыз да була, ул безнең яңа гына мәжиклыктан чыккан купецлар өчен язылган. Ә сезнең кебек затлы кунакларга... Әлбәттә, мин сизенәм: губернаторның бал-мәҗлесеннән качып китеп, олуг князьнең провинциядә гади генә күңел ачасы, бер ял итеп аласы килә. Бу төндә бөтен дәүләтен бүләк итүдән чиксез бәхет күрәчәк гүзәл дамаңы... Гафу ит, Диларә, чибәр дамаңы иртәп килгән шундый кунакка без мебельле бүлмә дә тәкъдим итә алабыз. Сер беркемгә чыкмаячак. Иртәгә инде шәп фаэтоннарда төшкән шәһәр башлыклары

князьне вокзалда озаткан чакта әлеге дама, кара вуаль аша карап, перронның бер читендә тавышсыз гына елап озатып калыр. Поезд кузгалыр алдыннан князь, тамбурга чыгып, ике бармагын тырпайткан ак перчаткалы кулын иренеп кенә болгар. Чибәр дама исә князь бүләк иткән бриллиант кашлы йөзеген тешләп перронда басып калыр. Бусы — иртәгә. Ә бүген — күңел ачу, сез минем кунакларым! Сизәсездер, кесәгә керәчәк чәйлек турында да онытмыйм. Нәфсе алай зурдан түгел. Гадәттә, исереп киткән купецтан гына икеләтә каерырга мөмкин. Хикмәт андамыни! Париж, Лондон, Петербург салоннарының хуш исе килеп торган князьнең күңелен күрү — җан рәхәте. Европа! Хәзер мин зәвыклы кунаклар өчен генә саклана торган шәрабны алырга дип подвалга төшеп китәм. Мадераның үзеннән кайткан Серцеаль шәрабе! Ә сез, тавис койрыгыдай сузылган итәкләрен шаулатып, кастаньет шыкылдадып биюче испан кызларын карый торыгыз. Фламенко! Ә сез, туташ, князьдән күзегезне алмагыз. Бераздан сәхнәгә искиткеч гүзәл шансонетка чыгачак. Залда утыручы хатын-кызларның йөзенә күләгә төшергән гүзәллек каршында князь, һичшиксез, сокланудан...

— Князь һәм шансонетка. Полюсларны бутадың, Мастер!

Дилара шундый бирелеп, рәхәт елмаеп тыңлый иде, бүлдермә, дип минем кулымны кысты. Мастер аптырап калмады, үзе уйлап чыгарган хыял дулкынында иркен йөзә бирде.

— Әгәр шансонетка язгы күбәләк канаты да тимәгән чәчәк кебек саф та булса... Канында шәрык мутлыгы һәм европа акылы кушылган князь Юсупов аңа бер карауда француз өлгерлеге белән бәя бирәчәк.

— Җитте!

Залда нидер төшеп ватылганнан соң була торган тынлык урнашты. Мастер, артыграк сөйләп ташладым ахры, дигән курку белән, хәзер үк гафу үтенергә әзер булып, Диларәгә төбәлде. Дилара исә, көлеп җибәрүдән чак тыелып, иреннәрен мыскыллы бөрештереп, Мастерга өстән, сытып карады:

— Гарсон, мин сине иртәгәдән монда күрмим! — дип күзгә күренмәгән өстәлдәге сервизларны сыпырып идәнгә койды.— Үзеннән чибәррәкне таныган хатын-кызның дөньяда булганы юк әле!

— Пардон, туташ, сез француз теленең Патуа диалектында сөйләшәсез икән.

— Ә сезнең телдә арча диалекты сизелә,— дип, мин дә арага кердем. Мастер сәхнә белән ресторан залын элекке хәленә кайтарды:

— Сәхнәдә —грация! Чегән моңы! Гүзәллек!

— Князь, бу шансонетканың тавышы йөрәгемә ярамый,— дип, ягымлы үтенеп, Дилара башын иңемә куйды. Ниһаять, миңа да рольгә керергә чират җитте. Концертта, җырчы туйдырса, залдан торып кычкыручы сергач мишәрләре сыман мин дә:

— Икенчең чыксын! — дип, кул җилпүе белән шансонетканы сәхнә артына озаттым. «Князь» өчен бераз тупасрак жест булды булуын, нишлисең, бүтән тәрбия...

Мастер, тезләнеп, Диларәнең кул аркасын үпте.

— Тынычланыгыз, туташ, князь сезнеке генә...

Дилара канәгать, каршында шаярып кына тезләнүне дә хатын-кыз матриархат чорыннан калган тоем белән чын күңелдән кабул итә, күрәсең.

— Спектакль тәмам!

Мастер безне, без аны алкышладык. Диларәнең дә күңелен күтәрерлек шундый сүзчән, эчкерсез дустым булуына эчтән сөенеп куйдым.

Аннары Мастер безне гаҗәп бер бүлмәгә алып керде. Үзебез дә сизмичә бер урында әйләнәбез — түм-түгәрәк бүлмә, күңел сыеныр почмак эзли. Үзенең бик үк камил яратылмавын кеше дигәнең түгәрәк эчендә калгач кына сизә, күрәсең. Стеналар алтын бизәк белән чуарланган. Кая карама, көзгеләр. Бу якты түгәрәк бүлмәдә аяк очына

басып әйләнгән балерина гына килешле күренәдер.

— Бая син сәхнәдән куып чыгарган шансонетканың бизәнү бүлмәсе бу,— диде Мастер.

Танышу дәвам итә. Калын тимердән нәкышләп эшләнгән иркен баскыч буйлап аскы катка төшәбез. Аяк тавышлары биек түшәм катларына житеп шомлы яңгырый. Борынгы тынлык уяна да, уфтанып, тирән бер сулыш ала шикелле. Мастер аска ымлап күрсәтте:

— Әнә унтугызынчы гасыр техникасы ята — лифт. Гөнаһлы куртизанкаларны кул белән әйләндереп күтәрү жиңел булмагандыр, ә!

Калын стеналы ярым караңгы лабиринтларны үткәч, Мастер «художник» дип язылган кара ишекне ачты. Борынга төче акбур исе бәрелде.

— Менә бу минем куышым,— дип, Мастер утны кабызды. Яктыга иялэшүгә күзләр йөгерекләнде. Кая карама, буяу банкалары, ботаклар, әллә нинди сурәтләрдә катып калган тамырлар, стенада рәсемнәр — боларны көне буена да карап бетерерлек түгел. Диларә иске урындык янәшәсендә торган бердәнбер креслога утырды. Мастер плиткәгә чәйнек утыртты. Өстәлгә «Кечке Мәскәү» конфетлары таратып ташлады. Аннары мине жебегән акбур исе килеп торган икенче бүлмәгә алып керде.

— Менә иске афишалар. Юып, жирлеген буйыйсың да, яңаны язарга әзер була. Афишаны урамга чыгарып элүче махсус кеше бар — Мансур абзый. Ул монда каравылчы булып эшли. Төшендеңме?

Без әйләнеп кергәндә Диларә кулына агач тамыры тотып, үзалдына елмаеп утыра иде. Бераздан ул аны миңа сузды. Мин бер мәлгә тынсыз калдым. Гажәп әсәр! Моны табып алыр өчен бәхетле очраклылык кына түгел, женең булу да кирәктер шул. Бирчәеп, ташка әйләнгән тамырга урыны-урыны белән генә тылсымлы пәке очы тигән. Бер ягыннан карыйсың: битен жыерчыклар сырлаган карт маймыл башы — нигәдер үпкәләгән шикелле, аскы иренен турсайткан. Сынның икенче ягын әйләндерәсең: кара жир төсенә кереп яргаланган уч төбендә әле яңа гына йомыркасыннан чыккан, ялангач, чип-чиста кош баласы бөгәрләнеп ята.

Мастер безгә аркасы белән борылып афиша яза иде.

— Ошыймы? — диде ул күтәрелеп карамыйча гына.

— Искиткеч! — диде Диларә. Мастер тамырны сак кына алып учына куйды да Диларәгә сузды:

— Танышу көнендә кечкенә генә бүләгем булсын, кабул итеп алыгыз.

— Юк, юк! — диде Диларә кызарып.— Бу бит сезнең коллекция өчен кирәктер.

Мастер кырт кисте:

— Ике сөйләшмибез!

Диларә уңайсызланып кына бүләкне алып өстәлгә куйды.

Мастер афиша астына ут кызыл хәрефләр тезә башлады.

— «Уналты яшькәчә балалар кертелми»,— дип язаң, директорның иң яраткан кешесенә әйләнәсең. Реклама!

Чәйдән соң ул тагын бер «спектакль» күрсәтте.

— Гел бер урында кузгалмыйча үсеп утыру агачларны ялыктырмый дип уйлыйсызмы?! Алар уйный да, шаяра да беләләр. Бер-берсенә тартылу — мәхәббәт аларга да хас. Һәр агач тирә-юнен күреп, тамаша кылып яши. Кош-корт, жәнлекләрнең рәвеш-кыяфәтен хәтеренда калдырмасалар, тамырларыннан шушындый хикмәтләр ярарлыр идеме?! Якынрак килегез әле,— дип Мастер түр почмакны бүлгән пәрдәне ачты. Башта мин әллә ни ис китәрлек нәрсә күрмәдем. Ботаклы-чатаклы гадәти агач кәүсәләре. Күз тәмам иялэшкәч кенә, аңлап, үзалдыңа елмая башлыйсың. Мастер, тын калыгыз, дигән кебек ишарә ясады да, утны сүндереп, өстәл лампасын кабызды һәм магнитофон төймәсенә

басты. Африкалыларның бакый заманда ут белән бергә яратылган, җан адашырлык җунглилардан чыгарга, киңлек эзләп биеккә ыргытылырга талпынган дәртле көе гүя без төбәлгән агачларны да хәрәкәткә китерде. Җирдә оят, гаделсезлек дигән төшенчәләр барлыкка килгәнче, кеше җаны куләгәсез чакта туган кыргый бию ич бу! Агачларның берсе — ир, икенчесе хатын-кыз, икесе дә ялангач, антик статуялардагы кебек. Бөтен дәүләтләре дә сәнгатьчә төгәллектә... Әнә ничек, гәүдәләрен назлы сыгылдырып, кулларын як-якка ташлап, бер-берсенең уй-хәрәкәтен тойган хәлдә биилэр. Мастер өстәл лампасын боргалап тора, стенада тере күләгәләр дәртле талпына.

Музыка тына. Түшәмдә ут кабына. Мастер, елмаеп, тамашачыларга карый. Диләрәнең йөзендә мәҗүси елмаю. Ә Мастер үз хыялыннан юана белгән эчкерсез сабый хәлендә.

— Кайдан таптыгыз димим, ничек күреп алдыгыз моны?

Диләрәнең кызыксынуыннан үтә бер канәгатьлек кичергән Мастер, күзләрен кысып, бер мәлгә рәхәт онытылып торды.

— Кеше аяк басмаган урман ешкынлыгыннан. Карыйм, яшь куаклык уртасында — болар. Корыган, кайрылары кубып беткән. Кырыйдарак карт каенлык. Беләсезме ни уйладым мин ул минутта? Бу «кыз» белән «егет» агачларның тыйнак кануннарын бозып, анадан тума чишенеп ташлаганнар да, бер-берсенә мәхәббәтен аңлатып, кыргыйларча биергә керешкәннәр. Бу хәлне кабул итә алмаган карт агачлар, ләгънәт укып, каһәрләп, боларны тараташ калдырганнар. Ышанмыйсызмы?! Ә нигә соң алай булгач, боларны төреп алган яшь куакларның бер генә ботагы да корымаган иде?.. Икенче җәйне ул төшкә тагын сугылдым. Чытырманлы ешкынлыкны таныр-лык түгел иде. Корыган, сирәгәйгән. Үземнең нинди хата эшләгәнемне шул чакта гына аңладым. Агачларның шатлыгын да, кайгысын да без күрә, ишетә белмибез. Уртага чыгып, бу ике пар яшь куакларның күңелен ачып торгандыр. Ә мин, тамырыннан аерып, аларны шул кызыктан мәхрүм иткәнмен. Сез шул чакта минем урында булсагыз, хәлемне аңлар идегез...

Йөзенә әрнүле кыяфәт чыгарып, үз хыялына үзе ышанып сөйләгән Мастерны каршы ни дә булса әйтеп үпкәләтү гөнаһ булыр иде бу минутта.

Урамга чыккач, юллар төрле якка булса да, без аерылыша алмый тордык. Мастер, иртәгә килеп кирәк-яракларын алгач, «художник» ачкычын минем почта әрҗәсенә салып калдырырга булды. Шул вакыт Спасс манарасындагы сәгать суга башлады. Без тын калып унны санадык та шул якка борылдык. Апрель төне кремльнең калын стеналары эчендә борынгы тынлык белән өртелгән иде. Министрлыклар урнашкан бина тәрәзәләре караңгы, каршы яктагы бинада гына утлар яна. Арырак Сөембикә манарасы калыккан. Монда һәр таш үткән дәверләр сулышында яши. Аз-маз ишеткәннәр генә мине канәгатьләндерми, белмәвеңне сиздермәү горурлыгын җиңеп, сорыйсы килә:

— Сөембикә шушы манарадан ташланганмы?

Диләрә минем кулны кысып сүзсез елмая.

— Дөресен белэм югыйсә, әмма бәләкәйдән ишетеп үскәнгәме, миңа да ул шушы манарадан ташланып үлгәндер кебек тоела,— диде Мастер.

— Мәскәүгә, Иван Грозныйга мәҗбүри алып киткәннәр аны. Елап озаткан халык, соңыннан инде яраткан ханбикәнең манарадан ташланып горур үлүе турында риваять чыгарган. Беләсезме, Иван Глазатый Сөембикә турында ничек язып калдырган?..

Мастер белән икебез дә, җим көткән кош балалары кебек, Диләрәгә таба тартылдык.

И была та царица казанская,
Так прекрасна, умна, рассудительна,

Что подобной ей не было женщины
Среди жен всех казанских и девушек!
Даже в стольной Москве нашей царственной
Между жен, дочерей наших княжеских,
Отыскать не легко ей соперницы.

Соңгы юлларны әйткәндә Мастер да кушылды. Күп нәрсәне белгән кеше мине һәрчак көнләштерә. Боларны куып житү өчен миңа күпме төннәрне йокысыз калдырырга кирәк әле...

— Казанның йөрәге — шушында,— диде Мастер.— Моннан сигез йөз ел элек, осталар килеп, нигез урыны билгеләгәч, хан боларга әйткән: «Иң әүвәл иртә белән кем дә кем очраса, ай-ваена карамыйча, каланың нигезе астына тотып салыгыз»,— дигән. Осталар иртән күрәләр: ханның улы килә, артыннан бер эт тә ияргән. Ханның яраткан улын харап итеп булмый бит инде, осталар этне тотып китереп нигезгә салалар. Хәбәр барып ирешкәч, хан: «Бу шәһәр этләр кулына кала икән»,— дигән.

— Кызык... без этләр булып чыгабызмыни инде?

— Нигә, эт иң турылыклы хайван,— дип миңа каршы төште Диларә.— Безнең борынгы бабаларыбыз эткә, бүрегә табынганнар. Һәр кабилә үзен нинди дә булса җәнлек-хайваннан чыккан дип уйлаган.

— Игътибар белән карасаң, һәр кеше билгеле бер җәнлеккә, кошка, хайванга охшаган. Менә Маратны гына алыйк...

— Моңлы, зур күзле атка охшаган,— дип көлде Диларә.

— Чабышкы аты. Борынгы бабалары төрекмәннән. Ахалтәкә нәселеннән килә,— дип өстәгән булды Мастер.

— Ә син иркәләгәнне көтеп мыраулап утыручы бохар мәчесе,— дип, Диларә кул чабып көлә башлады.

— Килешәм,— диде Мастер,— әни дә шулай дип әйтә иде. Кызганыч, мәченең иркәләр хуҗасы юк...

— Диларә, Диларә кемгә охшаган?! — Мин аның уң ягына да, сул ягына да чыгып карыйм. Мастер башыр кыйгайтып, рәхәт елмаеп читтән генә күзәтә.

— Аңа тимик. Диларә — Сөембикә! — дип, ул чагыштырыр җәнлек эзләүгә шуның белән нокта куйды, мин инде Африкадагы әллә нинди кошларны күз алдымнан үткәрергә әзер идем югыйсә.

Кремль сәгате уникене сукты. Көн тәмам. Мастер белән саубуллашабыз. Өчлек союзы таркалгач, әллә ничек, сүз ялганмый, Диларә дә моңсуланды. Бүгенге көннең хәтердә калган кайтавазын тыңлап, сүзсез генә кайтабыз.

Капка төбенә җиткәч кенә Диларә Мастерның бүләген Пассажда онытып калдырганын исенә төшерде.

Диларәнең күңелен күтәрергә нәни генә булса да яңалык, гел яңалык кирәк. Кабатлануны, торгынлыкны, гадәтилекне өнәми, яшәү аның өчен тоташ иҗат булырга тиеш, күрәсең.

## VII

Ач калын пәрдәләрне, тышта кояш икән бит! Сагындырган кояш. Тәрәзәне ачуга, бүлмәгә кошлар чыркылдавы бәреп керде. Ризван агай ясаган ояларга сыерчыклар килгән! Йорт бүлешү бара. Былтыргы сыерчыклар... пыр туздырып оядан чыпчыкларның бөтен «мебель»ләрен чыгарып ыргыталар. Телгә беткән чыпчыклар болай гына бирешми әле, муенсыз башларын сузып, кыска тәпиләрендә сикерә-сикерә, чырк та чырк килеп аяусыз талашалар. «Сез кайтып күренәсез дә югаласыз. Менә безнең кебек кыш буена торып карасагыз иде! Нәзберекләр, аксөякләр, сездән булмый ул!..»

Ерак илләр күреп кайткан, затлы смокинг кигән сыерчыкларның

гәрбия башка: чыпчыкларның тузанга баткан иске җиләнենә өстән генә мыскыллы карап «о кей!» дип бер генә сүз әйтеп куялар. Көчле янында һәрвакыт куштаннар табыла. Бер чыпчык, үз кардәшләренә хыянәт итеп, сыерчыклар тирәсендә мәш килгән була, оядан чыпчыкларның мендәр-юрганнарын, кастрюльләрен чыгарып ыргытыша. Сыерчыклар, урнашып беткәч, бу бичараны да типкәләп куачаклар бит инде. Куштанлыкның соңы һәрвакыт шулай бетә...

Бүген иркенләп ашарга пешерергә дә була. Такы-токы капкалап яисә әбиендә сыйланып күпме йөрергә мөмкин? Атна буе базар-кибетләрдән җыйган әйберләреңне өстәлгә чыгарып тез, берсе дә онытылып калмасын. Бөтен юк-бар уйларыңны онытып, бу изге эшкә чистарынып тотын. Ризык, теләп кагылмаганыңны сизсә, карыша башлый.

Исеннән ук туясың, ахрысы, пешкән ризыкны өстәлгә куюга, әзерләп йөргәндәге дәрт сүнә. Ялгызың җәелеп ашап утыруы да әллә ничек. Айсылуны чакырыр идең, кызларның кашык тотып ашап утыруын өнәп бетермим. Аларга шоколадны нәзек кенә тешләп, чәшкә тоткасын ике бармак белән чеметеп, артып калган бармакларны нәфис тырпайтып чәй йә кофе эчеп утыру килешә.

Ризван агай бар бит әле минем.

Ул кыстатып тормады. Наянны ишегалдына чыгарып җибәрде дә минем арттан ук менеп җитте. Кәефе әйбәт. Бераз йөгертеп өлгергән. Вино салынган стаканга кулы гына тиеп китсә дә ике колагы кызарып чыга аның.

Икәү генә булсак та табын түгәрәк.

— Артык тәмле пешергәнсең,— ди Ризван агай.— Көн дә болай ашап торсаң, коммунизмга чыктым, дип исереп китүең бар. Ашау дигәннән, патшаларны әйтәм, җир йөзендә ни тәмле ризык бар, шуны ашап, кеше сөтенә кадәр эчеп торалар югыйсә, барыбер, йөз яшькә дә җитә алмыйлар, ә!

— Ашауга гына карамый, күрәсең.

— Кичә өч егет мунча керделәр. Озын чәчле булсалар да, бик чиста күренәләр үзләре. Магнитофон алып килгәннәр, акырталар гына, теге... рок дисезме әле, ракмы? Дуңгыз суйгандагы тавышлар чыга, пәрәме йөрәккә бәрә. Ярты көн керделәр мунчаны, борынгы Римдә мунча ял урыны булган, диган булалар. Акыртмагыз, мин әйтәм шуны. Тел бар чукынчыкларда, сезнең буын — куркып яшәгән буын, диләр. Безгә дә күчмәсен өчен шул куркуны бәреп чыгарырга туган музыка бу, диләр. Кара син аны, нәрсә уйлап чыгаралар бит! Менә син, Марат энекәш, яшь кеше бит, ничек карыйсың ул кувалда белән сандалга бәргән тавышка?

— Йөрәк таза чакта тыңлаштырсаң ярый инде.

— Дисеңме... Мин менә яшь чакта җырланган көйләрне ишетсәм, күзгә яшь тыгыла. Авылның сукмакларына кадәр күз алдына килә. Сез менә олыгайгач, шул тимер бәргән көйләрне яңадан тыңлый алырсызмы, берәр нәрсә хәтерегезгә төшәрме? Әллә, минәйтәм, яшьләрнең башын җилләтеп, хәтерсез калдыру өчен... тегеннән... юри тараталармы ул көйләрне, ә? Эчмичә исерү — хәтәр, хәтәр...

— Үтәр ул, Ризван агай, борчылмагыз.

— Үтәр дә, җимереп үтәр шул. Сиңа атап түгел, болай... аптыраганнан әйтүем.

Чәй эчеп бетергәндә тыштан Наянның өргәне ишетелде. Ризван агай миңа бер кочак рәхмәт әйтеп, юка гәүдәсен җиңел генә кузгатып чыгып китте.

Мин дә зарыктырган кояшлы урамга атладым. Карасам, трамвай тукталышында Лопес тора. Аяк янәшәсендә бүселгән зур сумка, хәйран олы чемодан. Кай чакта өйдәге хәлне урамга чыккач беләсең икән.

— Китәм, икенче районга,— диде Лопес.— Надя түтигә дворник булып эшләгән җиреннән яңа фатир бирделәр.

Трамвай тәрәзәсендә чагылган бакча рәшәткәләре аша Лопесның йөзе чәрдәкләнеп күренә. Трамвай кузгала башлагач, ул, елмаерга тырышып, миңа кул болгый. Кулны кесәдән чыгарырга өлгерә алмый калам. Шулай тормыш... Китте. Ике исемен дә хәтеремдә калдырып, мин аңлап бетерә алмаган зат миллион кеше кайнап торган шәһәр эченә кереп китте. Нигәдер барыбер моңсу. Күңелдән сары яфрак өзелеп төште. Йортның таралуы шушы көяшлы көннән башланыр микәнни?..

* * *

Кичен мин Пассажда. Готика розасы итеп эшләнгән тимер чәчәкле тәрәзәнең калын бәрхет пәрдәсен тартып куйгач, дөньям дүрт стена арасында, кайсы заманда яшәвемне онытырлык ялгызлыкта калам. Өске катта кино беткәч, хәрәкәт туктала. Ара-тирә ишетелеп киткән аяк тавышлары, кемнәрнеңдер сөйләшеп алуы ерак кайтаваз булып калын стеналар эчендә йотыла да бакый тынлык урнаша. Фасадын гүзәл нимфалар, горур корриатидалар тотып торган, гасыр дәвамында нинди генә язмышларның серен хәтерле ташына сеңдермәгән мәһабәт бинаның өнсез авырлыгын тоеп, мин аскы катның кечкенә генә бүлмәсендә кырмыска кебек тырмашам. Бармакларга күнегү, кыюлык җитми, шуңа күрә пумала астыннан хәрефләр Мастерныкы кебек савылып чыкмый. Ярдәмгә линейка алам. Афиша язар өчен әллә ни фантазия кирәкми. Хәрефләр оялчан булырга тиеш түгел. «Менә мин!» — дип ерактан чакырып, кычкырып торсын — бары шул. Куллар гына эшли югыйсә, ә бөтен киеренкелек аякларга төшә. Шулай бирелеп кенә эшләп утырганда артымда кемнеңдер сулышын тойган кебек булдым. Сизәм, әмма борылып карый алмыйм. Алданырмын кебек, әллә соң үзләшеп бетмәгәнгә, бу бинаның сак тынлыгы мине шикләндерәме? Юк, чит бер караш һаман мине бораулый, сагаю кулларга күчә. Күпме болай билгесезлек шаукымында утырырга мөмкин, кинәт борылам... күрер күзгә ышанып өлгергәнче бөтен гәүдәм буйлап кайнар дулкын убылып төшә! Кычкырып җибәрүдән чак тыелып, торараташ калам. Ачык ишектән караңгы коридорга төшкән квадрат яктылык уртасында коточкыч өрәк тора, стенадан яралып чыккан шәүлә кебек. Китаплардан укып, төшкә кереп йөдәткән борынгы замоклардагы коточкыч өрәкләр бу секундта, бик мескен булып, еракка чигенде. Ә бу... башы иңенә чумып торган караңгы чырай, кыска буй, озын куллар — нәкъ үрмәкүч. Һәм аның үле тынлыкка җан өреп елмаюы минем өчен могҗиза булып тоелды, шунда гына һушыма килдем.

— Марат буласызмы? Куркыттым инде әллә? — дип, ул ишектән килеп керде.— Мастер әйткәндер, мин монда каравылчы булып эшлим.

Куркудан тавышым да хәтта үзгәреп куйган. Көчкә иренемне ачып:

— Мансур абый буласызмы? — дип сорадым.

Шунысы гаҗәп: бит тиресе яра-җөй эзләреннән торган, калын кашлы бу төмсә, бөкре кешенең елмаюы гадәттән тыш ягымлы иде.

— Сез мине гафу итегез, комачауламаска тырышырмын. Тышкы ишекне бикләдем дә... берьялгызыма күңелсез. Афишаларың әзер булса, чыгарып эләрмен.

— Үзем эләрмен, сез борчылмагыз.

— Миңа бит аның өчен айга егерме сум акча түлиләр,— дип, ул тагын елмайды. Сулыш алу аңа авыр иде, күрәсең. Йомшак, бәрхет тавышы күкрәк гыжылдавына кушылып чыга.

Бераздан мин чәй куйдым. Мастер магнитофон кебек үзенең кирәк-яракларын алып китсә дә, өстәл тартмасында конфетларын калдырган икән. Сыйланырга була. Тәртипсезлек килешеп торган бу бүлмәдә ни барын, ни югын белеп тә бетермим әлегә.

Көн дә диярлек шулай кереп йөри торгач, Мансур абзыйга мин ияләшеп киттем. Өйдән төрле үләннәр алып килдем. Хуш исле чәйне

ул кайнар килеш өрә-өрә тәмләп эчә. Беркөнне ул миңа шундый бер вакыйга сөйләде:

— Хәзер мин якты көннән, кояштан куркам. Төн кошы мин. Элек бу кадәр үк кыяфәтсез түгел идем, кешеләр белән аралашудан да тайчанмый идем. Утызынчы елларда художниклар йортында вахтер булып эшләдем. Төрлесен күрергә туры килде ул чакта. Арадан берәү — бүгенгедәй хәтеремдә. Әллә каян гына калкып чыкты ул. Яшь иде. Менә мин гариплегемнән оялам, ямьсез икәнемне бер генә минутка да истән чыгара алмыйм. Онытыр идең, миңа чирканып, кызганып караган күзләр һәрчак искәртеп тора аны. Ә ул егет гариплегеннән кимсенә белми иде. Тройка астында калып тапталган булган ул. Муен умырткасы сынып, кан эчендә яткан. Әллә каян гына килеп чыкты дим, сәбәбе шул... әлеге фаҗигадән соң, терелеп аякка баскач,— аңа кадәр карандаш, пумала тотып карамаган малай,— капылт кына рәсем ясарга керешкән. Аны вакытында күреп алалар. Училищеның беренче курсында ук остаханә бирделәр үзенә. Ярты ел укуга, аны икенче курска күчерделәр. Тагын ярты елдан — өченчегә... Шаккаткыч вакыйга ясады ул. Мин төннәрен, шушылай, аның янына кергәли идем. Ул беркемне искәрми, шашынып, үз-үзен онытып, киндерне гаҗәп төсләргә мана иде. Аның эшләгәнен карарга күпләр килә, комачаулыйсың дию юк, әйтәм бит, эшләгән чакта ул беркемне күрми, искәрми иде. Женме, кешеме — аера алмассың. Яна бит бу, харап була бит бу, дип уйлый идем мин аның үз-үзен аямыйча эшләвенә карап. Кулына ул беркайчан да карандаш алмый, турыдан-туры буяулар белән ясарга керешә иде. Төн урталары узгач, кыйналып ташланган кебек кушеткага барып ава, мин аңа чәй китерәм. Ул арган күзләрен чүпрәк белән бәйли, аз сөйләшә, ятим үскәнгәме, йомыкыйрак иде. Кунар урыны да шушы мастерской, мин аңа еш керәм, бервакыт, икебез генә калгач, ул ачылып китте. «Ат астында калып, кан эчендә яткан чакта, коточкыч авырту белән бергә, ниндидер әйтеп аңлатып булмый торган ләззәт кичердем,— дип сөйләгәне хәтердә.— Һуштан язып упкынга төшеп барам, үзем уяна барам, тирә-юнемне гаҗәеп төсләр чолгап алды. Шуннан бирле төсләр миңа тынгы бирми. Әллә каян, биектән сурәтләр рәвешендә нур агыла башлый да мин күк белән тоташам. Ашыгырга, шул мизгелне тотып кала белергә генә кирәк. Кем гаепле моңа — белмим... Авыру бу, беркемгә дә теләмим мин мондый авыруны, куркам мин бу газаплы бәхеттән...» Шулай диган иде ул. Соңыннан инде... минем, үз-үзен яндырып харап итмәгәе, дип хафалануым дөрескә чыкты — училищены тәмамлый алмады ул. Өченче курс соңында канатлары салынып төште егетнең. Остаханәгә беренче тапкыр кергән сабый хәлендә калды, кулы бармый, берни ясый алмый башлады. Куеп тор, сабыр ит, сиңа ял кирәк, дип карадылар, юк, аның саен бәргәләнә, үз-үзен кая куярга белми. Күз алдында сула башлады, бичара, хәтта чырае олыгаеп китте. Менә шундый фаҗига булган иде ул елларда. Талантның югалганын, беткәнен көтеп кенә торалар бит, соңыннан сагыныр өчен. Әкренләп аннары сагыну да онытыла. Изомузейда аның бердәнбер картинасы тора хәзерге көндә.

— Ул рәссамның исеме Сиринме?

Янәшәдә генә торсам да, сынлы сәнгать музеена алай еш кергәнем юк. Анна Леонардовна пенсиягә чыкканчы шунда эшләгән икән.

— Мин яшьлегемдә сәнгать училищесында укып йөргән булдым. Рәссам чыкмады миннән. Барыбер шул картиналар тирәсеннән ерак китә алмадым. Әйдә, бер кызык картина күрсәтәм үзеңә, аны күпләр искәрми үтә,— дип, Анна Леонардовна мине музейга алып кергән иде. Чынлап та, «Моң» дип аталган бу картинаны мин алай ис китәрлек итеп хәтердә калдырмаганмын икән.

...Тын манзара. Кичке шәфәкъ вакыты. Күктә төрле төсләргә манылган болытлар. Офыкка төшеп чумган кояшның кызгылт чите сызык

кына булып шәйләнә. Аяк очына басып аның күбрәк өлешен күрәсе килә. Еракта караеп күренгән куаклыклар. Үлән арасындагы сукмактан кулына төенчек тоткан кыз килә. Башын иеп, йөзе моңсу...

— Шәфәкъне болай биралган бүтән художникны дөнья хәтерләми,— диде Анна Леонардовна.— Шәфәкъ вакытында төсләр секундның меңнән бер өлешендә үзгәрә бара. Художник бу төсләрне истә калдыра алмый, киндергә күчерергә өлгерми, соңыннан инде алдарга, үзеннән кушарга мәжбүр була. Ә Сирин мизгелне тотып калырга өлгергән сирәк талант! Физиклар, спектраль анализ белән чагыштырып, бу картинадагы төсләр гаммасының күчеше табигыйлеккә туры килгәнен исбатладылар. Менә бу ноктага килеп бас әле,— дип, Анна Леонардовна, иңемнән тотып, мине бер кырыйгарак китереп бастырды.— Уң як почмактагы болытка кара әле, ни күрәсең?

Мин текәлеп карыйм, болыт чал чәчле хатын-кызга әверелә бара.

— Кызын шәһәргә, бәхет эзләргә озаткан сагышлы ана,— диде Анна Леонардовна.— Хәзер уңга, менә монда килеп бас, күрәсеңме, сукмак уңга борылды, төенчекле кыз болай таба килә. Ул хәзер туктап калыр да кире борылыр кебек, теләр-теләмәс кенә атлый. Хәзер сулга китеп басыйк...

Гаҗәп: сукмак сулга таба борылды, төенчекле кыз хәзер болай таба килә.

— Син бу ноктапарны онытма, бүтән төштән карасаң, мондый эффект булмый,— дип Анна Леонардовна ялтыр паркет идәнгә күрсәтте. Анда кечкенә генә ноктапар билгеләнгән иде.— Куинджи «Днепрда айлы төн» картинасын күргәзмә залына куйгач, билгеле бер ераклыктан карар өчен бау суздырган. Төнге күктә айның шулкадәр тере, чын булып янганын күреп, тамашачылардан берәү түзмәгән: «Картина артыннан утны алыгыз!» — дип кычкырып җибәргән. Шулай, күп картиналарның сере ачылмаган әле. Без ашыгабыз, картина эченә керә белмибез, үзебезне акыллыга санап, үтеп кенә китәбез,— диде Анна Леонардовна.— Сирин, һичшиксез, бөек рәссам... Онытырлыкмыни, ул чакта без дөньяны үзгәртергә дип ашкынып килеп кергән идек. Ә Сирин, үзе бер дулкын булып, барыбызны да күмеп китте: «Мин»! — дип йөргән күпләр тоныкланып калды. Зур талант күнегелгән төшенчәләрне үзгәртә, таркатып ташлый бит ул. Аның әсәрләрен карарга дип Мәскәүдән килделәр. Егерменче гасырга яңа дәһи туа, дип язып чыктылар. Әгәр бөтен картиналары да сакланган булса...— Минем сорау бирәсемне сизгән кебек, Анна Леонардовна ашыгып әйтеп куйды:— Саклый алмадык шул, үзен дә, картиналарын да...

— Үлеме ничек булды соң аның?

— «Үз-үзеңне үтерү — меланхолик халәтнең илаһи поэмасы»,— дияргә ярата иде ул. Бальзакның «Шагрен күне» әсәреннән. Сирин кебек бөекләрне тәңре җирдәге ваклыклар арасында озак яшәтми, нелеп үзенә ала шул...

Бу сүзләрне әйткәндә Анна Леонардовнаның күзләрен өлкән кешеләргә хас тыенкы, яшерен яшь пәрдәсе каплаган иде.

Менә хәзер Пассажның тын бүлмәсендә «бердәнбер» дигән сүз чыгуга, мин әлеге картинаны искә төшердем. «Сиринме?» — дип сорауга Мансур абзыйның күзләрендә хәтәр очкыннар кабынып алды, тыны кысылды.

— Син беләсеңмени ул картинаны?

— Беләм. Хикмәтле картина.

— Гадәти бер пейзаж инде...

Мин Мансур абзыйга картинаның серен сөйләп бирдем. Сиринне күреп белгән кешегә яңалык түгелдер, дип уйласам да сөйләмичә тукталып кала алмадым. Ләкин Мансур абзый, сәер итеп, иреннәрен калтыратып көлде генә:

— Булмас, булмас! Ничек инде... әкият бу,— диде.

— Ышанмасагыз, бергә барып карый алабыз.

— Сукмак борыла димени, юк, юк, ышанмыйм!

Мансур абзый, үпкәләгән шикелле, ашыгып кына саубуллашып чыгып китте. Мин, аптырап, тимер баскычта яңгырап ишетелгән аяк тавышларын тыңлап басып калдым.

* * *

Диларә һаман шулай: бер яктырып китә, бер моңсулана. Музыка тыңлый, китап укый. Китап укый һәм музыка тыңлый. Дөньяда бик озак яшәп арган кеше сыман тирән сулап куя да озак кына бер ноктага текәлеп утыра. Андый чакта күңеленә шакып та, шакымыйча да керә алмыйсың. Өстәл лампасының яшел абажуры күләгәләгән бүлмә, саркып кына агылган музыка әллә нинди ямансу уйларга этәрә. Диларә, әйтерсең, аргы ярда басып тора. Арада — төпсез упкын. Мин кычкырам, ул ишетми, мин кычкырам, ул ишетергә теләми. Минем барлыкны онытып аның шундый битараф кыяфәттә утыруына тәмам ачуым чыга.

— Катокта, теге чакта, нигә таеп егылдың микән син? Мең кеше арасыннан искәрмәгән була идем бит!

Диларә кинәт елмая, үтешли генә минем чәчне туздырып китә. Шифоньер артына кереп әле бер төрле күлмәген киеп чыга, әле икенчесен... Көзге алдында боргаланып, үзалдына җыр көйләп әйләнгәли. Киң итәкле озын юбкалар, юка блузкалар алышынып кына тора. Мин аптырап, ни әйтергә белми күзәтәм. Менә ул итәге тездән шактый югары, зәңгәр җирлеккә ак борчак сибелгән күлмәк киеп чыкты. Әле генә искәргән кебек, миңа таба борылды:

— Унсигез яшьтә кигән күлмәгем, килешәме?

— Мин сине күргәнмен икән бит ул чакта! Хәзер хәтерләдем, күлмәгеңнән.

Мин очынып килеп Диларәне күтәреп алдым да әйләндерә башладым. Ә ул, унсигез яшенә кайтып, шаркылдап көлә, мин аның саен әйләндерәм. Кочагымнан шудырып, сак кына идәнгә төшерсәм... Күзләрендә — мөлдерәмә яшь, ул көлмәгән, елаган икән бит... Йөзен яшереп, ул минем кочагыма сыенды. Күз яшьле керфекләре, иреннәре, бөтен тәне пышылдый:

— Мин бүген яшьлегем белән саубуллашам...

— Мин булганда син мәңге картаймаячаксың.

— Кайчан күргән идең мине, кайда?

— Тын океан ярында. Шторм вакыты иде. Син шушы күлмәктән. Җил чәчләреңне тузгыта. Очыртып алып китә бит инде, дип куркып, таш артына яшеренеп кенә мин сиңа таба киләм. Миңа ул чакта ун яшь иде.

— Минем анда булганым юк бит.

— Беләм... Дивизияне тревога белән күтәрделәр. Самолетлар гүләвеннән җир тетрәп торды. Сугыш чыккан кебек иде. Беркем берни белә алмады, этидән ике-өч көн бернинди хәбәр булмады. Шул көннәрдә үзен кая куярга белми йөргән әниенең океан ярында басып торуы хәтердә калган. Нәкъ шушындый күлмәктән иде ул. Хәзер миңа ул ярда син басып торгансыңдыр шикелле тоела.

— Иң кадерле кешеңне генә әниең белән чагыштыралар.

— Син...

— Дәшмә,— дип Диларә миңа креслоны этәрде, үзе тахтага барып утырды.— Тын гына торыйк әле.

Ярым караңгы бүлмә. Сагышлы музыка. Диларә моң тулы күзләрен минем аша каядыр төбәгән. Тышта җил шаулый. Миңа ул дулкыннар шавы булып ишетелә. Ак борчак сибелгән зәңгәр күлмәкле кыз дулкыннар ерып кереп бара. Таш артыннан күзәтеп торган малай-

ның яр читенә килеп, өзгәләнеп кычкырганын да ишетмиме әллә?

Тышта май җиле яшь яфракларның көчен сыный. Музыка бетеп, бушка әйләнә башлаган магнитофонны Диләрә сүндерә. Кулымны үрелеп алып учына кыса да:

— Рәхмәт сиңа, барысы өчен дә...— ди.

— Үләргә җыенмыйсыңдыр бит, Диләрә?..

— Киресенчә. Яшәргә уйлыйм. Соңга калып булса да.

Чәчемнән сыйпарга дип үреләдә, утка пешкән кебек, кулын кире ала. Күзләрендә томан, йөзе олыгаеп киткән кебек.

— Бар кайт, Марат.

Мин ишеккә таба чигенә барам, чигенә барам. Нидер әйтәсе килә, әйтә алмыйм. Баскычка чыгам, яңадан ишекне ачып карыйм. Диләрә йөзен учлары белән кысып утыра бирә. Гади бер ягымлылык сирпелеп торган бу кош оясы кебек бүлмәне әллә соң мин соңгы тапкыр күрәмме? Нигә соң әле мин баскычлардан йөгереп төшәм, өметсез ялгызлык көтеп торган урамга нигә ашыгам? Диләрәнең, һәрвакыттагыча, тәрәзәдән кул болгап калуын күрер өченме?

Ләкин тәрәзә бүген җансыз иде. Тополь төбендә күпме генә басып торсам да яшел пәрдә селкенмәде. Үҗәтлек, рәнҗү тулган йөрәк күкрәкне тутырып тибә башлады. Баскычларның икесен бер итеп менгәнемне сизми дә калдым. Диләрә борын төбендә ишекне ачты. Үземә дә ят тавыш белән кычкырып мин аны куркыттым да бугай:

— Нигә кул болгамадың? Мин бит көттем!

— Гафу ит, синеңчә булыр. Бар, кайт инде, кереп торма... Аннары соң була... Мине аңларга тырыш. Бар...

Диләрә бер кулы белән мине кысып тоткан, икенче кулы белән этә, шулай аскы катка кадәр төште дә ишектән кул болгап калды.

Ярый әле чәчне сыйпап-юатып җил исә. «Нигә алай, нигә бу дөнья гади генә түгел!?» — дип кычкырсам да төнге урам барыбер җавап бирә алмас иде.

* * *

Ял көне дип тормый, көтелмәгән хәбәрләр үз аягы белән килеп керә. Пассажга барып, соңгы тапкыр афишаларны язып кайтырга кирәк, иртәгә ачкычларны тапшырасы булыр, кай арада бер ай вакыт үткән, дип уйларга гына өлгердем, ишек артында таныш тавыш ишетелде. Гөрелдәп, үтешли генә кемнәрдер белән сөйләшеп алган Мастер ишектә күренде. Хәзер ул дөньяда булмый торган берәр яңалык әйтеп минем кәефне күтәрәчәк.

— Син исән! Молодец! — дип Мастер иңемнән тотып дер селкетеп алды. Бу нинди сәер исәнләшү соң әле?

— Бәлки, мин үләргә тиеш булганмындыр. Ишеттеңме әле?.. Бүген төнлә Пассаж җимерелгән бит...

— Җимерелгән?!

— Нәкъ без эшли торган бүлмә туры — арка өсте түбәдән аска кадәр убылып төшкән.

Мондый трагик шаярту Мастерга хас түгел иде. Күнелдән мең сорау йөгереп узды. Кылт итеп каравылчы Мансур абзый искә төште. Аңа бер-бер хәл булмаганмы икән? Сүз башларга да куркам. Кичә кич мин аны күрми калган идем. Уемны сизгән кебек, Мастер:

— Бәхеткә күрә, Мансур абзыйның урамга афиша эләргә чыккан чагы булган,— диде.— Шәһәрнең йөзек кашы кебек бина иде, кызганыч, тиз генә кеше итәрлек түгел. Кинотеатр ябылачак инде хәзер.

— Ни сәбәптән җимерелгән икән?

— Нигезен су ашаган.

— Су?..

— Янәшәдәге Черек күл урынында элек, Казан ханлыгы чорында,

зур күлләр булган. Берсендә кер юганнар, икенчесендә су коенганнар, өченче күл — иң чистасы — эчәргә генә тотылган. Дәверләр үтеп, шәһәр зурая башлагач, күлләр әкренләп йомыла, саега башлаган. Таш юллар салып, ярларын да бетонлагач, астан бәреп чыгасы чишмә юллары бөтенләй томаланып кала. Менә шул чишмәләр, чыгар юл эзләп, җир астында үз эшен эшләп ятканнар.

— Барып карыйбызмы?

— Ни бит... Мөмкин булса чәй куй әле. Бераздан... ни бит.— Мастерның күзләре ниндидер шуклык эшләгән сабыйныкы кебек оялчан елтырап алды. Сүз сөрешенә куәт бирә алмыйча учын учка сугып куйды да тәрәзә катына барып басты.

Мин чәй әзерләп йөргән арада Диләрә килеп керде. Мастерның йөзе тимгел-тимгел кызарып чыкты. «Килеп җиттеңме?» — дип, миннән алда өлгереп, ул Диләрәнең юка курткасын салырга булыша башлады. Аның хуҗаларча әйтелгән: «Килеп җиттеңме?» — дигән сүзләре чаң суккандай бөтен аңыма тарала башлады. Теге чакта, таныштырган көнне, Диләрә Мастер бүләк иткән сувенирны Пассажда онытып калдырган иде бит. Икенче көнне Мастер миңа ачкычын калдырды, ә сувенир турында берни дә әйтмәде, мин аны таба алмадым. Яңадан мин аны Диләрәнең китап шкафында күрдем бугай. Күрдем, әмма игътибарга алмаганмын, шунда ук онытканмын. Менә хәзер генә зиһен ачылып китте. Шик йомгагы коточкыч тизлек белән сүтелә башлады. Юк, ниндидер өмет әле тартыша, шикләнү кебек ваклыктан мине йолып алырга, оялтырга тырыша.

Алар икесе янәшә, шат елмаеп, минем каршыга килеп бастылар.

— Марат, син безнең иң кадерле дустыбыз. Мин сине энекәшем кебек якын күрәм. Диләрә дә... Без...

Икесенең дә күзләрен бәхет каплаган, мин нигә кирәк монда? Барысы да аңлашылды, бүтән бер сүз дә ишетергә теләмим! Өстәлнең почмагын чытырдатып кыстым. Сабыр бул, сабыр бул! Сиздермә, түз, чыда!

— Без Диләрә белән өйләнешергә булдык.

Аларның шатлыгы минем күзләрне чагылдыра, туры карый алмыйм. Әйтелгән сүзнең чынлыгын аңым кабул итми. Чарасызлыктан нишләргә белмичә, өстәлгә үреләм. Бөтенесе бутала, кул калтырый, касә чәйнеккә әверелә, чәйнеккә тотыныйм дисәм, ул шикәр савыты булып чыга. Алар да миннән мыскыллы көләме?..

— Син безне котламыйсыңмыни, Марат? — Диләрәнең тавышы әллә кая, еракка китеп, кичәге тавыш белән кушыла: «Мин яшьлегем белән саубуллашам...» Менә ни өчен бәргәләнгән икән ул кичә?... Чыгып китегез! Күрәсем килми! Ай буе мин берни белми йөргәнмен... Бар да ялган, ялган, ялган! Кычкырасы иде хәзер. Акылыңа кил, сиздермә, түз, чыда! Күз кабаклары авыр гына күтәрелә, елмаерга итәм — иреннәр агач кебек.

— Мондый очракта ни әйтәләр соң, мин белмим бит?.. Котлыйм.

— Менә шул сүзең кирәк тә инде безгә! — дип, Мастер кулымны көчләп диярлек алып кысты.

Өчәү, кочаклашкан килеш, башны башка куеп сүзсез калдык. Күңелдәге юшкынны коеп, сәгать суга башлады. Бетмәсен иде, соңы булмасын иде бүлмәнең тынлыгын чүкеп торган бу авазлар.

Сәгать сугудан туктаса, тынлыкта бөтен уйлар тагын ялангач калачак бит.

Мастер пышылдап диярлек сөйли:

— Сиңа рәхмәт, Марат. Син таныштырмаган булсаң... Безнең яшьтә мәхәббәт авыр килә, гомерлеккә китмәс өчен. Сиңа әле күп нәрсә башкача күренәдер — яшьлек. Бүген генә килүебез өчен үпкәләмә. Без үзебез дә аңлап бетермәдек башта. Менә мин хәзер дә бәхетле җүләр хәлендә. Диләрә генә җитәкләп йөртә, шулай бит, акыллым?!

Диләрәнең кайнар сулышы битне кытыклый:

— Син минем күземне ачтың, Марат. Дөньяга алып чыктың. Бу тормыштан өмет өзеп, йокымсырап яши идем. Еллар үткәч, безнең дуслыкны көлеп кенә искә алырсың әле. Син тормышка килеп кенә керәсең, без сонгарак калдык. Син безгә бәхет телә...

Диләрәнең ягымлы тавышы бозны эретә бара, эретә бара. Үпкәләгән сабыйны юаткан ана кебек, ул минем чәчемнән сыйпый. Бүгенге белән килешергә теләмичә, күңел үткән көннәргә сыена. Карлы урамнар... Яшел пәрдәле тәрәзә... шул пәрдәне ачып, кул болгаган кыз,— юк, Диләрә түгел инде ул,— аның исеме бер мизгелдә мин генә белгән легендага әйләнде. Ул беркайчан да җиргә төшмәячәк. Аны беркем дә миннән тартып ала алмаячак.

Арага шәүлә булып кергән Мастердан мин ямьсез сыйфатлар эзлим. Борыны тупас, йөзе ошамый, ничек мин аны элек искәрмәгәнмен? Ә Диләрә аңа яратып, сокланып карый. Хәзер бер тупас сүз әйтсәм, мин Диләрәне үпкәләтәчәкмен. Нишлим соң әле, ни хакым бар! Алар көне бүген, алар теләге... Менә хәзер, үземне үк оялткан уйларымны сизәчәкләр дә, җитәкләшеп чыгып китәчәкләр, мин тома ялгыз басып калырмын, бүтән инде беркайчан да күрешмәбез, дигән курку мине айнытып җибәрә.

Фужерлар табылмады, затлы эчемлекне касәләргә бүлеп учка алгач, Мастер торып басты:

— Ташларны чәчәр вакыт, ташларны җыяр вакыт, дигән борынгылар. Без инде хәзер шул яшьтә. Бәясен белеп, дуслыкны саклый белгән яшьтә. Карт нарат агачына карагыз, ябалдашының иң очында гына ботаклар калган була. Бу инде гомер соңына килеп җиткән, сыналган һәм санаулы гына калган дуслык символы.

— Аллавирде! — Диләрә грузинча әйтеп кул күтәрде.— Мөмкинме?

— Аллабирде, диген, ул бездән кергән сүз,— дип бүлдерде аны Мастер.

— Син безне бөтенләй картайтып ташлама әле. Гаилә тормышын мин крепость эченә кереп бикләнеп, тормыштан аерылу дип күз алдына китермим. Дуслыкны саклау ул — аралашу, бер-береңнең кайгы-шатлыгын уртаклашып яшәү дигән сүз. Менә бүген, әле эти-әниләр белән дә киңәшләшмәгән дә килеш, Маратка керүебез...

— Туктагыз әле! Нигә сез һаман мине кыстырасыз. Бүген — сезнең көн. Сез бер-берегезне олыгаюдан саклагыз, ул турыда бөтенләй онытыгыз. Ун елдан соң да, егерме елдан соң да гел шушы килеш калсагыз, димәк, вакыт сезне түгел, ә сез вакытны җиңгән булачаксыз. Бәхет телим сезгә!

— Тост бу, җәмәгать! — дип Мастер касәләрне чыкылдатып чәкештерде.

Эчтән әчеттереп көйрәгән учакка мин ялкын өстәдем. Шушы секундтагы бергәлекнең кадерен белү кебек тойгы мине исертеп җибәрде. Җүләр бер шатлык биләп алды, бер сәбәпсезгә көләсе, елмаясы килә. Кухняга атылып чыккан арада кемнедер бәреп ега яздым. Аш әзерләп йөргән Айсылуны кысып, битеннән үптем. Ул, күзләрен атныкы сыман зур ачып, телсез калды.

Утыра торгач Диләрәнең яңа бер сәләте ачылды.

— «Зөлхиҗә»не җырлыйммы? — дип ул безгә карады. Мастер, ике кулын күтәреп, нинди сорау булырга мөмкин, дигән түбәнчелек белән баш иде, тын калырга ишарә ясады. Диләрә тамак кырып, урындыгына җайлабрак утырды. Сыерчык та шулай бит, сайрар алдыннан бер төзәтенеп ала.

Гасырлар аша әллә кай чорларга алып китә, җанны тәннән аера торган сыкранулы җыр икән бу. Мин аны беренче тапкыр ишетәмме, әллә соң бик күптәннән беләмме? Мастер бәрхет тавышы белән кушы-

лып карады да, тыны житмичә туктап калды. Моң, салмак тәгәрәгән дулкын булып, офыкка кадәр югала да, инде бетә, инде сүнә дигәндә, көчәеп янадан сиңа таба килә башлый. Шушы мәңгелек хәрәкәтне бер сулышка сыйдырган моң син белмәгән дөньяның ачылып китүе өчен кул сузымы ара калуга туктала. Җырның азагы булмас дигән нәүмиз алдану юкка чыга, күңелдә кайтавазы гына тирбәлә.

Әле генә шул җыр киңлегендә үз-үзен онытып яшәп алган Диларә кызарып башын түбән ия. Без дәррәү кул чабабыз.

— Оялтмагыз, тавышым юк бүген.

— Һәр җырчы шулай дияргә тиеш,— ди Мастер.— Сиңа кушылып булмый икән, тыңлап кына була. Гаҗәп! Загска кадәр мактап калыйм әле үзеңне.

Табыннан кузгалгач, теләк белән исәпләшеп тормыйча, алар мине үзләре белән иярлеп чыгып киттеләр. «Моң» картинасын, җимерелгән Пассажны карау — безнең сәяхәт шулай итеп кафеда, салкын коктейль эчү белән тәмамланды.

Өйгә кайтып керүгә, читлеккә эләккән кебек, тын кысыла башлады. Сулышым буылудан хәлсезләнеп, тахтага чалкан төштем. Гел бер ноктага карап ята торгач, түшәм аклыгы төпсез күк зәңгәрлеге чагылган карлы урамга әйләнә. Кардагы күгелҗем эзләр күз яшендә эреп юыла бара, юыла бара. Мин үз күңелемә кереп адашам...

## VIII

Җиз кранны боргач, эчтән ыңгырашу ишетелде дә тынды — Идел дәшми, суы ерак чигенгән. Ут та өзелгән. Газ да юк. Буш йорт эче барабан кебек, тамак кыруың да күкрәү булып яңгырый. Минем монда соңгы көнем. Бүген күченмәсәм, апрельдә чыпчыкларны оясыннан куган кебек, көчләп чыгарып ыргытачаклар. Затлы кабинетларын смокинг итеп кигән дәрәҗәлеләр тарафыннан әмер бирелгән. Сүтү, җимерү эше төзү-коруга караганда житезрәк башкарыла. Чыпчыклардан аермам шул: минем торыр фатирым бар, җил таеп егылырлык шома стеналы йортның уникенче катында лоджиялы фатир көтә мине, әби исеменә рәсмиләштерелгән.

Йорт сүтеләә икән, сүтелми икән, дигән төрле имеш-мимешләргә чик куярга теләп без, моннан унбиш көн элек, Мастер белән Кремльгә киттек. Мастерның иңендә фотоаппарат та булгач, секретарь кыз безне корреспондентлар дип уйлады булса кирәк, гафу үтенгән сыман: «Ун минуттан киңәшмә башлана, шуңынчы өлгерәсезме?» — дип, баш архитектор кабинетына тоткарлыксыз кертеп җибәрде. Өстәл артында оебрак утырган урта яшьләрдәге кешене күргәч, мин түргә үк барып житә алмадым. Мастер өстәл аша үрелеп, баш архитекторның кулын нык кысып күреште, ашык-пошык кына исемнәрне әйтеп таныштырганнан соң, үгезне кыздырырга әзерләнгән матадор кебек, һөҗүмгә күчте:

— Вакытсыз чаккарак туры килдек, мөмкин булса... безнең берике сорау бар иде...

— Рәхим итегез,— диде баш архитектор.

— Казанда унҗиденче гасырдан бирле сакланып килгән бердәнбер особняк бар. Безне шуның язмышы кызыксындыра иде.

— Кайчандыр Аксаковлар яшәгән йортмы? Тиздән сүтелергә тиеш.

— Димәк, юк ителәчәк?

— Архитектура ягыннан караганда үзенчәлекле особняк. Тарихи истәлек. Шуңа күрә без аны нәкъ элекке хәлендә башка җиргә күчереп салачакбыз.

— Рәхмәт сезгә. Хуҗаның үзеннән ишетү икеләнүләргә юл калдырмый. Сезгә еш эләгеп булмас, бер кергәч инде... Шәһәрнең киләчәге, булачак төзелешләр турында да бер-ике сүз әйтмәссезме, кыскача гына

— Була ул,— дип баш архитектор өстәлгә зур-зур планшетларны җәеп ташлады. Ул арада Мастер «Рөхсәт итсәгез...» дип, фотоаппаратын көйләп, баш архитекторны алдан да, яннан да җәһәт кенә фотога төшереп алды.

— Менә, кош очар биеклектән Казан өстенә карый аласыз. Бусы — яңа районнар. Генераль план буенча, шәһәрнең иске үзәкләре дә танымаслык булып үзгәрәчәк. Дөрес, әлегә бу план расланып, гамәлгә кермәгән...

— Кәгазьдә матур күренә ул,— диде Мастер.

— Агач йортларны реставрацияләп күп чыгымнар тотканчы, сүтеп, алар урынына яңаларны төзү кулайрак.

— Бу — шәһәрнең йөзен, хәтерен бетерү була түгелме?!

Баш архитекторның йөзе гадәттән тыш тыныч иде. Мастерның кайнарлана башлавына ул бөтенләй битараф калды:

— Идеалист булу бер хәл. Мәсьәләгә житдирәк карый белү кирәк.

— Әйтик, кипарис шавын тыңлап үскән төбәктәге кеше белән, каен шавын тыңлап үскән кешенең моңы бер буламы? Архитектура ул, белгәнегезчә, табигатьнең ташта гәүдәләнеше. Элек шәһәр төзүчеләр урынны, ландшафтны, шунда яшәүче халыкларның гореф-гадәтен исәпкә алганнар. Казан — уникаль урында, калкулыкларга урнашкан. Бүгенге объектлар шәһәрнең рельефын, панорамасын, бөтенләй исәпкә алып төзелми. Сезнең генераль планда да бу нәрсә... шикләнәм... шәһәр тәненнән шештәй бүселеп чыккан биналар күбрәк күренә.

— Институт чаклы институт эшләгән проект каршында тик сез акыллы булып чыгасыз түгелме?!

— Нигә мин генә. Меңнәрнең фикерен ишетергә теләгегез юкмы?

Дилетантлык ул компетенция җитмәүдән туа.

— Мин әйтмим һәр иске йорт менә дигән архитектура үрнәге дип. Ләкин агачтан гөл итеп эшләнгән күпме йортларның юк ителүенә без шаһит. Аларны төзәтеп, заповедниклар итеп калдырырга, яңалар белән аралаштырырга була бит! Сез аны үзегез дә яхшы аңлыйсыз, тик...

— Сүзегездә бөтенләй хаклык юк, диясем килми. Ләкин мәсьәләгә объектив карарга киңәш итәр идем. Мондый да киң колачлы төзелешне бүтән бер гасырның да күргәне юк. Когда лес рубят, щепки летят, ди рус мәкале.

— Хатаны һәрчак компетентлы берничә кеше эшли. Ә хатаны төзәтү — меңнәр җилкәсенә төшә.

— Без баррикаданың ике ягында торып сөйләшәбез. Сез, имеш, шәһәрнең киләчәген кайгыртып җан атучылар, без — геростратлар... Эзләнү чорында төрлесе булыр. Бүгенге архитектура да үз сүзен әйтәчәк әле. Оптимист булыйк.

— Сыйпап йоклату инде бу, уянгач үкенер өчен.

Баш архитекторның яңаклары кысылып куйды. Ирен читеннән мыскыллы елмаю саркытып, ул миңа өстән генә күз атты:

— Яшь иптәш нигә бер сүз дә дәшми, безнең барыбыздан да акыллырак буын вәкиле?

— Алар буыны берни дә җимерергә өлгермәде әлегә,— дип Мастер чеметеп алды.

— Минем бер соравым бар,— дип, мактаптан калган гадәт белән торып бастым.— Узган гасырларда гап-гади төзүче дә белгән, патша теленә дә кергән архитектор тылсымлы шәхес булган. Ә бүген төзелешкә барып, берәр ташчыдан: «Моның архитекторы кем?» — дип сорасаң, ул, һич югында, шаркылдапköләчәк. Кызганычка каршы, алтмышынчы еллар архитектурасының мактанычы аз... Минем соравым шул: Ирек мәйданындагы бина — консерваториянең актлар залы кем проекты буенча төзелгән?

Баш архитекторның ирен читендә елмаю сүнде. Аның, йә, тагын ни әйтмәкче буласың, дигән соарулы карашы телгә куәт бирде.

— Тыштан караганда актлар залы кыяр үстерә торган парникка охшаган. Бөтен мәйданны бозып тора. Инде хәзер аның фасадын үзгәртеп булса... коткару өчен берәр чара күреләме?

— Кеше хезмәтен алай тупас бәяләргә киңәш итмәс идем. Уңышсыз чыкканлыгын мин үзем дә таныйм. Ләкин аңлагыз... Әгәр минем карамакта Парфенон сарайларына тотылган шикелле мәрмәрләр булса... Юк, аны сезгә болай гына аңлату мөмкин түгел. Читтән карап кына нәтиҗә чыгару җиңел ул.

— Мәрмәрне дә үтереп була бит...— диде Мастер.

Мин, әйтеп бетерә алмам дип куркып, сүзләрне бер-берсе өстенә ашыгып өя башладым:

— Кайчандыр, Петербург һәм Мәскәүдән кала, Казан өченче урында торган. Шәһәрнең бүгенге йөзен карагыз: гадәти шырпы кабы архитектурасы. Минем Ереван, Баку, Ташкент, Алма-Ата шәһәрләрендә булганым бар. Милли орнаментларны архитектурада куллануның үрнәкләрен менә кемнәрдән өйрәнергә була! Әгәр сезнең аңа кыюлыгыгыз җитми икән,— Казанда бөтен дөньяга билгеле бөек шәхесләр яшәгән,— шулар исеменә лаек архитектура булмаса, тарих безнең чорга төкереп карамасмы?!

Баш архитектор, тимгел-тимгел кызарып, өстәлдәге планшетларны ашыгып җыя башлады.

— Искене төзәтү күзгә күренми. Мин аңлыйм, сезгә колачлы эш, зур планнар кирәк! — дип кызыбрак сүз башлады Мастер. Ишек артында сөйләшкән тавышлар куера, безнең вакыт бетеп бара иде. Ул миңа күз кысып алды да, монда кергәнче үк алдан сөйләшкән идеяне чыгарып салды: — Беләсезме без нәрсә эшләргә уйлыйбыз? Бөтен иске йортларны фотога алабыз. Сез төзәткән объект урынында элек нинди булган — шуның фотосын зурайтып эләчәкбез. Чагыштырып карасыннар — күрсеннәр нинди матурлык харап ителгәнен. Ә карыйга сезнең фотоны куячакбыз. Кем гаепле икәнен дә белсеннәр! Тыныч кына аренадан китү булыр микән... Бөтен кылган эшләр өскә калкып чыгачак!

Баш архитектор тыныч кына сорау бирде:

— Сез кайсы газетадан?

— Бернинди газетадан да түгел,— диде Мастер.

— Ничек, ни өчен кердегез алай булгач?

— Сорау белән. Гади кешенең соравы булырга мөмкин түгелмени?

Баш архитектор каршында без шул секундта ук үтә күренмәле шәүләләргә әвереләдек.

— Минем вакытым бетте! — дип архитектор арты белән борылды. Ул арада ишектән, шаулашып, киңәшмәгә җыелучылар керә башлады.

— Әгәр сезнең генераль планыгыз расланса, бу — Казан өчен фаҗига булачак! — дип кычкырды Мастер ишек катыннан.

Ярый әле безгә ун гына минут бирелгән иде, озакка китсә, сөйләшүнең ни белән бетәсен кем белгән?..

— Академик Лихачевка язарга кирәк Казанның хәлен,— диде Мастер урамга чыккач.

— Үзебездә дә газеталар бар ич.

— Булмый. Татар — картайган милләт. Эш аты. Уйлана белми. Һәр халык тарих сәхнәсендә бер биеп күрсәтә дә... дүртбиш гасырлык «мизгел»дән соң, язмыш пәрдәне яба. Сәхнәгә икенчеләр килә.

Горький урамыннан күпме үтеп йөрсәм дә искәргәнем юк иде, кайтышлый, Мастер күрсәткәч кенә игътибар иттем: архитекторлар йорты җыйнак кына особнякка урнашкан икән.

— Моны бер хуҗа шәп булсын дип төзеткән бит инде. Күр әле, өстә вазалары ватылып беткән, фронтондагы бизәкләре купкан, җимерелеп бара бу. Үз йортларын да кеше италмаган архитекторлардан ни көтәргә була?! — дип Мастер өметсез сурәттә кул селтәде.

Баш архитекторның әйткәне дөрескә чыкты. Без яшәгән особняк-

ның башка җиргә күчерелеп салыначагы турында газетада белдерү басылды. Анна Леонардовна гына: «Минем гомердә әйтелгән күпме нәрсәләр үтәлмичә калды, ышанмыйм, дача төзергә таратып бетерәчәкләр моны»,— дип, күңелгә шик салып куйды.

Тәрәзәләреннән пәрдәсе алынган йорт — салкын көзле кеше кебек, ягымлылыгын җуя. Ул инде үзен җылытып торган хуҗалары белән сүзсез генә хушлашырга әзерләнә. Күченер алдыннан йортыбыз нәни генә вокзалга охшап калды. Чемоданнар тутырылган. Кемнең поезды кайчан килә — юллар төрле якка.

Иң беренче профессор Еникеев гаиләсе купты. Ул көнне мин, эштән соң, «Волга»ны гараждан алып чыгып, капка төбенә кайтып туктадым. Ишегалдына кирәрлек түгел — мәхшәр. Таза-таза егетләр зур машинага әйбер төйиләр. Бакир ага да алар тирәсендә кайнаша. Әминә ханымның команда тавышыннан тәрәзәләр зыңгылдап тора.

Артымнан ук бүлмәмә Айсылу килеп керде. Сыланып торган спорт киеменнән. Үзе генә белгән көйгә гәүдәсен сыгылдырып, Куба кызлары сыман, башын муенында биетеп тора.

— Безне аерып торган стена калыная. Китәбез!

— Адресыңны калдыр.

Айсылу дүрткә бөкләнгән кәгазь сузды.

— Телефон юк әлегә. Нигә башыңны читкә борасың?

— Артык чибәр син. Не грешно ли быть такой красивой, дигән бераү.

— Бераү түгел, Пушкин.

— Беләсең, ә?!

— Китаплар эчендә үстем ич мин. Менә хәзер шуларны ташып азапландылар.

— Матурлык, гадәттә, эчтәлексез була. Баштан сыйпале, күңелсез миңа.

Шулвакыт Әминә ханымның шәрран ярып кычкырганы ишетелде:

— Айсылу, кая олактың?!

Айсылу артыннан мин дә атылып чыктым. Әминә ханым миңа төксе караш ташлап алды.

— Бар әле, тап әле кешесен, капка төбендәге машинаны алсыннар, чыгып булмый бит! Аннары, такси чакыртып, боларны аерым алып барырбыз! — дип, Әминә ханым хрусталь савытлар җемелдәп күренгән буаз сумкаларга ымлады.

Мәсьәлә тиз хәл ителде. Мин руль артына утырдым. Әминә ханым горур күкрәкле мул гәүдәсен минем кырыйдагы утыргычка көчкә сыйдырды. Бакир ага йөк машинасында — юл күрсәтүче. Айсылу арткы утыргычка чумәште. Вакыт-вакыт аңа карап алу өчен, көзгене борыбрак куярга туры килә инде. Әминә ханым машинаның «минеке» икәнлеген белгәч, профессор хатыны булуын да онытты. Моңа кадәр кайда саклап йөрткәндер елмаюын — йөзе яктырып китте.

— Кунакка килгәлә, Марат, безне онытып бетермә. Безнең Айсылу тыштан гына шулай кырыс күренә, үзе бер дә алай түгел...

— Әни!

— Нигә, кызым, ачуланасың мине?..— дип, Әминә ханым артка борылып карарга иткән иде дә, таза муен бирешергә теләмәде. Дөнья хәлләренә кереп алганнан соң, Әминә ханым кинәт кенә:

— Эшең әйбәтме, хезмәт хакы күпме аласың? — дип сорады.

— Түзәрлек,— дидем мин, айлык йөз дә ун тәңкәне күңелемнән бишкә тапкырлап.

— Әни дим!..

Әйберләрне бушатышкан арада Айсылуның шелтәле тавышы яңгырап торачак бүлмәне дә күрергә туры килде ул көнне.

Анна Леонардовна күченәсе көнне бөтен бүлмәләрне йөреп чыкты. Мич кафельләрен сыйпап ала, стеналарны каккалап карый. Үзе туып

үскән йорт белән ул шулай хушлашамы, әллә һаман да сүтеләсенә ышанмыйча, төзеклеген кайгыртып йөриме — белмәссең...

Анна Леонардовна үткәннәрен искә төшереп, җылап та алды.

— Көрешкәләп торырбыз. Әбиең белән без ахирәтләр ич,— дип ул бераз тын гына утырды да аркамнан сөеп:

— Син гафу ит инде, Маратик. Картлар киңәш бирергә ярата, әйтсәм дә уңайсыз... Айсылу әйбәт кыз, мин сезне гел бергә итеп күз алдыма китерәм. Янәшә яшәгәнгә генә бер-берегезнең кадерен белмисез, ара ерагайгач, аңларсыз әле. Синең яратыр чагың. Нинди генә язмышка дучар булса да, олы мәхәббәт кичергән кеше бәхетсез була алмый. Мәхәббәт хисе гомер буе җылытып тора. Тыштан мескен, ялгыз күренергә мөмкинсең, ә эчтә үзең генә белгән серле учак алдагы көнеңә өмет нуры төшереп яна. Ул — сирәкләр бәхете... Ашыгып үтеп китмә үз тукталышыңнан... Их, үкенечле яшьлегем турында мин сиңа бер сөйләрмен әле.

«Бер сөйләрмен әле...» — дип, Анна Леонардовна гүя гомерен озайту өчен өмет калдырып китте.

Ризван агайның әйберләре унбиш минут эчендә төялеп бетте. Ике колагы кай арада кызарып та өлгергән. Эчелеп бетмәгән виносы чайпалган шешәне идән уртасына бастырып куйды.

— Өй иясенә, миннән рәнҗеп калмасын.

Өй эче шып-шыр, ишектә арыслан башлы тотка тырпаеп күзгә бәрелде. Бөтенләй оныта язганбыз, балта белән көчкә каерып алдык.

— Тоткасыз ишек борынсыз кеше кебек,— диде Ризван агай. Бүлмәгә моңсу бер караш ташлады да башын иеп чыгып китте. Саллы тотканы алып кереп мин тәрәзә төбенә куйдым.

Машина кузгалыр алдыннан Наян юкка чыкты. Кычкырып та, сызгырып та карыйбыз — юк. Янап та, ялварып та чакырып карый Ризван агай — юк, тыны да чыкмый. Әллә урлап киттеләр инде. Ярты сәгатьләп эзләгәннән соң гына табып алдык. Бакчаның куе ешкынлыгына кереп поскан. Ризван агай, шатлыгын сиздермәскә теләүдән, шелтәле сөйләнәсөйләнә этне күтәреп алды. Наян шыңшып елый, маңгаен каплаган гөнҗәлә йон арасыннан күзләрен мөлдерәтеп карый. Сизелә, яңа җиргә китәргә теләми акыллы хайван. Бу бакчада ул кайсы яфракның кайчан өзелеп төшәренә кадәр белеп тора иде бит...

Янәшәдә бәйләнгән алты кап китап — бар байлыгым шул. Калган нәрсәләр — әбинеке.

Тиздән Мастер машина алып килергә тиеш.

Аста ишек дөбердәткәнгә йөгереп төшсәм, почтальон басып тора. Хат Анна Леонардовнага адресланган. Йорт инде гамәлдән сызылган, ә хатлар килә тора, тормыш берни булмагандай дәвам итә. Кичә мин дә әнидән бу адреска язылган соңгы хатны алдым. Бер елдан кайтабыз, дигән.

Һәрчак сүзендә тора белгән Мастер шактый соңлап, төш авышкач кына килеп җитте. Гадәттәгечә шаулап килеп кермәде, кыяфәте дә сүрән, арган шикелле. Керде дә, картларча тирән сулап, урындыкка утырды. Ул сүз башлауга ук дерт итеп куйдым.

— Мансур абыйны җирләп кайттык...

Пассаждагы бүлмә, Мансур абзыйның пумалаларны сыйпап-сыйпап караган нәфис, озын бармаклары күз алдына килде. Картаймыйча калган бармаклар...

— Нигә миңа әйтмәдең?

— Үземне дә ашыгыч кына килеп алды директор. Кинотеатр ябылгач, минем анда барганым юк иде. Мансур абый соңгы көннәрдә сырхаулап йөргән. Керләрен юып, хәлен белешеп торган күрше хатыны әйтә: «Кичә иртән күрдем, почтага таба барадыр ие,— ди,— шат чырайлы ие. Бераздан сөтләр күтәреп кайтып керде»,— ди. Мансур абыйның ишеген бикләү гадәте булмаган. Күрше хатыны кичтән кереп ка-

раса... Бар иде кеше, юк инде кеше!

Иртәдән бирле җиенып йөргән мәшәкатьләр мәгънәсен җуеп, кечерәеп калды. Эчтән әчеттереп күтәрелгән дулкынны тынлык баса.

— Теге чакта... Пассаж җимерелгәнне әйтүгә үк, син Мансур абыйны искә төшергән идең,— дип, Мастер авырлык белән йөзен сыпырып алды.

— Сиңа ул Сирин турында сөйләгән идеме?

— Художникмы? Юк. Сөйләмәде.

Сәер, ул мине бик аз белә иде югыйсә. «Бер сөйләрмен әле...» — дигән өметнең вакыты кыскара барганлыгын сизеп, сөйләп калыйм дип уйлады микәнни?..

## IX

Өстәл тартмасында адашып калган сыңар өрек чикләвеген арыслан башлы тотка белән бәреп ватам. Катлы-катлы буяу кубып төшә, арысланның аскы ияге ялтырап кала — алтын кебек. Пычакның үтмәс ягы белән, каткан буяуны чатнатып, кубарып бетерәм. Тотка чистартып кала. Каралыбрак сеңгән үтә күренмәле буявын да кырсаң, бөтен җирлеге сыдырылып бетәчәк. Шушылай калсын, моны хәзер комиссионкага тапшырырга була бит! — менә бу фикер ичмасам. Саллы тотка, төсле металлдан, ике башлы кош сурәте төшерелгән мөһере дә бар — ретро! Карар кылынды, хәзер дөньяга чыгарга була. Иң якын сердәшемне, җилкәгә аса торган сумкамны алырга да... Аның кесәсендә Анна Леонардовнага тапшырасы хат та бар бит әле.

Комиссион кибеттә кабул итүче кыз: «Яхшылап чистартырга иде»,— дип минем тотканы әйләндереп-әйләндереп карады, каядыр кереп чыкты. «Мондый кыйммәтле әйберне бездә кабул итмиләр»,— дип «Яхонт»ка барырга кушты. Үз-үзен сәер тоткан бу кыз белән мин бәхәсләшеп тормадым.

«Яхонт»ка кабул итүче ишеге төбендә чират икән. Черки безелдәве кебек нәзек хушбуй исе аңкытып, алтын бәяләре хакында серле пышылдашып сөйләшкән тук чырайлы хатын-кызлар, бу нинди йолкыш дигән кебек, миңа шикләнеп карап алалар да нәфис сумкаларын кысыбрак тоталар. Ис китмәгән кыяфәт чыгарып тора торгач, миңа да чират җитте. Көмеш кашлы балдак кигән, тырнаклары гаҗәп пөхтә чистартылган егет тотканы алып, арткы бүлмәгә кереп китте. Шактый торып чыкты, кулында бая гына мин биргән тоткамы соң — танырлык түгел, ниндидер эретмә белән чистарткан ахрысы, көлеп, ялтырап тора. Ул миңа күз генә төшереп алды да ниндидер кәгазьләр өстенә иелде. Бер кулы — тоткада ята. «Туксан алтынчы проба. Чын алтын...» Минем баш әйләнеп китте. Тагын ниндидер саннар, процентлар — колак ишетмәс булды. Кесәмдә бер тиен акча юклыкны белеп шаяртамы әллә бу?

— Сез ризамы? Чукрак түгелсездер бит?!

Тел әйләнми, нәрсәгә, ни өчен икәнен белмәстән «Әйе» дип баш селкім.

— Шушы суммага риза булсагыз, акчасын бүген үк ала аласыз.

Кабул итүче егет хәрефләрне сулга авыштырып, шактый озак ниләрдер язды. Мин тотканы яңадан сорап алырга, кулга тотып карарга телим, тик нигәдер бу теләгемнән үзем үк куркам.

Саннар биешкән ниндидер кәгазьләргә аңсыз рәвештә генә кул куйдым. Кассир миңа, бик сынап карап: «Санап алыгыз, сигез мең дә ике йөз илле өч сум»,— дип, тәлинкәгә пачкалар өя башлады. Мин бу кадәр акчаны теләсәм дә саный алмас идем. Вафли калынлыгы пачкаларны сумкага бушаттым да тизрәк урамга чыктым. Сулыш ала алмыйм, баш әйләнә. Бөтен узган-барганнар гел миңа карап үтә кебек. Сумканы капшап карыйм — акчалар төшеп калмаганмы? Алтын кешене җүләрләндерә, дигәнне ишеткәнем бар иде, мәкерле пары башка кап-

тымы әллә? Нигә әле мин кибет ишеге төбендә терәлеп торам. Урам үзгәргән. Кешеләр сәер. Кояш икенче. Ни булды соң әле? Тынычлан! Миеңне суытып ал бераз. Барысын да кабаттан кичереп чык. Җиз дип алып килгән тотка алтын булып чыктымы? Сөенечтән бөтен урамга кычкырасың киләме? Тынычлан. Син акчага беркайчан да кызыкмадың, аннан өстен кала бел! Җир астындагы бөтен байлыкны казып алып бетергәннән соң, нәфеснең чиге күренәчәк. Ул чагында инде Җир шары согы сыгып алынган лимонга охшап калачак. Ул чакта да алтын хакимлек итәрме? Коръәндәге Яҗүҗ-Мәәҗүҗ — картлар күз алдына китергәнчә коточкыч җанвар түгел,— кеше уйлап чыгарган цивилизация җирдәге бөтен нәрсәне ашап килә. Тукта, еракка сикермә, син нишләргә тиеш хәзер, шул турыда уйла. Тотканы сиңа кем биргән иде? Ул да бит аны алтын дип уйламагандыр. Шулай булгач, бу акча кемгә тиешле?.. Шул-шул... Син бу акчаны хуҗасына кайтар. Кызурак атла, шәһәр үзәгендәге комбинат дип аталган затлы мунчага. Ризван агай исемен әйтсәң, сине анда чиратсыз кертәчәкләр.

Мунчада санитар көн икән, такси алып Горкига киттем. Ризван агай өйдә иде. Кухня ягыннан өреп чыккан Наян аякка килеп сарылды. Ризван агайның авыз ерык, колаклары кызарган, килдеңме, менә рәхмәт, дип җилкәмнән кагып алды.

Чиста обойлы якты бүлмәдә аның тузган одеял ябылган ятагы, иске-москылары ничектер ятышсыз күренә, өстәлдә шул ук куе яшел шешә тора.

— Яшәп ятабызмы, Ризван агай?

— Әйтмә инде... Әйбәт болай, тик барыбер иске йорт сагындыра... Минем күпме яшьтәшләр подваллардан, иске йортлардан шушындый якты фатирларга күчтеләр дә... берсе дә озак яши алмады, үлеп беттеләр. Картайгач, урын күчерү ярамыйдыр шул...

— Алай димә, Ризван агай, яшисең әле!

Мин, акча турында ничегрәк әйтергә икән, дип кыбырсып утырам. Сумка аяк арасында ята. Ризван агай берни сизми, һаман үзенекен сөйли:

— Менә, бердәнбер себерке калды, маяга,— дип, ишек өстендәге каен себеркегә ымлады.— Иртәгәдән яңаны әзерли башлыйм. Көннең иң озын вакыты җиткәч, агач ныгый, яфрагы коелмый торган була, исе дә шәбәя... Мин һаман үземнең юк-барны сөйлим дә сөйлим, үзең ничек? Яңа йорт килештеме? Агарып калгансың, авырмыйсыңмы?

— Хәзергә лоджияда йоклыйм.

Ризван агайның сүзеннән яңа йорт тузаны искә төшеп, тамак төбе кытыкланып куйды. Аллерген еракта гүя сәлам җибәрде. Сумкамны ачып, акча пачкаларын идәнгә койдым.

— Бу акчалар сиңа, Ризван агай...

Ул арада Наян килеп, акча пачкаларын иснәп, йонлач тәпиләре белән кагылып алды. Ризван агай күзләрен челт-челт йомып тик карап утыра, ирене селкенә, авызыннан сүзе чыкмый.

— Бу акчалар синеке, Ризван агай.

Ул, иелеп, пачкаларны тотып-тотып карады да курыкынган тавыш белән:

— Син нәрсә, көпә-көндез банк басмагансыңдыр бит! Юньле генә малай үзең, карт кешедән көләргә дип килдеңме!

— Кызма әле, Ризван агай. Бу акчалар сиңа тиешле. Теге тотканы комиссионкага алып барган идем — чын алтыннан булып чыкты.

— Алтын?! Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, ди. Ничек алтын булсын ул. Мин бит аны шушы кулларым белән утыз ел буе тотып йөргән!

— Мин үзем дә аптырап калдым.

Ризван агай:

— Булмас, булмас, ялгышканнардыр! Мин бит аны утыз ел буе!..—

Ризван агай акча пачкаларын сүтеп, өр-яңа унлыкларны өскә чөя, коена башлады.— Моңа күпме себерке сатып алып була, бөтен Казанны чабындырырлык! Күпме себерке! — дип ул исереп, шаркылдап көлә-көлә акчаларны учында йомарлый, туздыра башлады. Миңа тынчу булып китте. Сумканы каешыннан өстерәп ишеккә таба чигенә барам. Ә Ризван агай һаман кычкыра-көлә, шашына — шатлык та түгел бу, елау да түгел.

Лифт ишеге төбенә җиткәч ул, йөгереп чыгып, якамнан умырып тотты:

— Син кая?! Мине шушындый хәлдә калдырып китәсеңме? Ю-үук, туган, болай булмый. Тыныч кына яшәп яткан җирдән җүләрләндермә син, кер әле, әйдә. Төкерәм, мин бу акчага! Мескен кешегә берни дә кирәкми! Мин — мескен. Мин — куркак. Әйе, милиция күрсәм дә, урамның икенче ягына чыгам. Теге озын чәчле малайлар дөрес әйтә: куркып яшәдек без. Куркытырга көч табылсын гына, сез дә шундый ук булачаксыз! Шулай, «сез — винтик», дигәнгә сөенеп кул чаба иде миллионнар! Борынгы чорда кол дигәннәр, ә утызынчы елларда без бер башка үстек, кара ничек яңгырый, вин-тик! Аның өстенә минем хәтәр ярлык та бар: пленный! Гади солдат буларак, мин әсирлеккә эләгүемне белми дә калдым. Соңыннан инде исән калуым өчен гаепләделәр.— Ризван агай, ярсып сөйләгән җиреннән тукталып, вино шешәсенә үрелде, ярты-лаш салды да стаканны күтәреп, бер сулышта эчеп куйды. Ачы итеп тамак кырганнан соң, баягы кызуын сүрелдеребрәк, яшьле күзләрен төбәп сүзен дәвам итте: — Мин дә кеше идем бит. Без, татар егетләре, Париж урамыннан аккордеон сузып, «Гөлҗамал»ны җырлап уздык. Наполеонны куып килгән бабайлар эзеннән. Тарихка башкорт дивизиясе дип керсә дә — анда күбесе татарлар булган. Пленнан Франциягә элэктем мин. Морис Торез үзе кул куйган партия билетын кесәмдә йөрттем, дисәм, кемне ышандыра алам хәзер?! Француз Сопротивлениесендә фашистларга каршы сугышуым да, ике орден алуым да ярамаган икән шул. Анда да без югыйсә: «Сталин өчен!» — дип утка керә идек. Ә безгә исән калырга ярамаган икән... Илгә кайткач, йөзгә төкереп, Себергә озаттылар. Ә син, акча, дисең. Миңа берни дә кирәкми хәзер, соң инде, соң!

Ризван агай хәлсезләнеп диванга барып утырды. Мин дә кырыена чүгеп, иңенә кулны салдым. Ни әйтим, ничек юатыйм мин бу өлкән кешене? Аңа бары яхшылык теләп кенә килдем, андый теләкне сүз белән аңлату, ай-һай, кыен икән! Ни әйтсәм дә рәнҗетермен кебек. Күпмедер тын утырганнан соң, Ризван агай авыр сулап урыныннан торды, чәйнек борыныннан су эчеп куйды:

— Син алмаган булсаң да ул каһәр суккан тотканы барыбер калдырып китә идем.

— Алтын чәчеп йөрергә, син миллионер түгел бит, Ризван агай.

— Чынлап уйласаң, минеке дә түгел әле ул, кемнәндер калган нәрсә. Утыз ел буена шушы кулларым белән!.. Төкерик лә... Марат, магазинга барып сорасак, күрсәтерләр микән, ә? Бер генә тапкыр тотып карыйсы иде. Алтын дисең бит. Утыз ел буе шушы кулларым белән тотып йөре дә! Нәрсә сөйлим мин, җүләр, нигә кирәк! Башымны бутадың. Әле син килер алдыннан гына чүтлап куйган идем тапшырасы шешәләрне. Көйле генә барган тормышны бозып куйдың бу акчаларың белән! Яхшыга түгел бу...

— Кызым бар дигән идең, Ризван агай...

— Кирәкми! Ул турыда искә дә төшермә. Менә син (тьфу, тьфу!) ятим үстең дә, ди, утыз яшеңдә берәү килеп кереп: «Мин синең әтиең булам»,— дип әйтте, ди, син шуннан соң нишләр идең? «Ах, әтием!» — дип кочагына ташланыр идеңме? Алай булмый ул. Кызыма үпкәли алмыйм мин. Оныгым бар, алты яшьлек, гел үземә охшаган. Без дуслар аның белән. Ишегалдында уйнаганда сөеп китkәлим, энисе күр-

мәгәндә... Менә аңа велосипед алып бирсәк ярар иде.

— Әйдә, Ризван агай, бу акчаның бер өлешенә үзебезнең йортта яшәгәннәрнең яңа фатирларын котлап бүләк алабыз, ә?

* * *

Анна Леонардовнага бүләккә дип хрусталь ваза алдык. Аның ишек төбенә житкәч, Ризван агай икеләнеп тукталды.

— Үзең генә кер инде, бүләк бирүдән дә авыр нәрсә юк икән,— диде.— Оныгымны күреп булмасмы, нинди велосипед кирәген үзеннән сорармын, шул тирәгә барыйм әле, ардым да... Иртәгә кил,— диде.

Ничек кенә кыстап карасам да, кермәде. Соңгы тапкыр күрешкән кебек, әллә ничек моңсу итеп төбәлде дә, ябык иңнәрен калкытып, башын игән хәлдә китеп барды.

Анна Леонардовна һәрвакыттагыча пөхтә киенгән, яшәреп киткән кебек. Килгән кешегә сөенә белү этикетын шундый табигый итеп башкара белә, кулымнан чәчәкләрне алуга йөзе алсуланып чыкты. Ишек катыннан узганчы минем дә, әбинең дә хәл-әхвәлләрен сорашып өлгерде.

Бүлмәдә миңа таныш ладан исе саркып тора. Почмактагы икона да, кара агачтан эшләнгән мебельләр дә: «Без кая эләктек?» — дигән сыман ятсыныбрак калган шикелле.

— Иске йорт төшләремә керә, сагынам,— дип Анна Леонардовна кулъяулык очы белән күз төпләрен сөртеп алды.— Яктыга ияләнә алмыйм. Тегендә агач күләгәсенә өйрәнелгән.

Мин бәллүр вазаны сумкамнан алып өстәлгә, Анна Леонардовнаның каршысына куйдым.

— Яңа фатирыгызны котлап, Анна Леонардовна.

— Миңа хәзер иң зур бүләк — жинел үлем инде,— дип ул роза чәчәкләрен алып иснәп-иснәп карады.— Менә шушылай килеп, бер-ике жылы сүз әйтүче булса, бөтен бүләкләрдән дә зуррагы шул инде. Ә моны... — дип ул тырнак очы белән вазага чиртеп алды.

— Бу — иске йорт исеменнән, Анна Леонардовна,— дип мин алтын тотка кыйссасын тагын бер тапкыр сөйләп чыктым.

— Алтын...— дип, Анна Леонардовна исе китмичә генә бер ноктага текәлеп утырды.— Менә хәзер генә төшендем. Безнең бөтен ишекләрдә дә шундый тоткалар иде бит. Димәк, эти аларны махсус ясатып, алтын икәнне белмәсен өчен өстән буятып куйган булган. Кибетләр тота иде ул. Без шактый бай яши идек. Бүгенгедәй хәтеремдә — миңа ул чакта ун яшьләр булгандыр — төнлә кем беләндер эти кайтып керде де... Мин машина тавышына, аннары каты-каты басып йөргән аяк тавышларына уяндым. Алар ашыга-ашыга ишек тоткаларын сүтә башладылар. Әни — хаста, чахотка белән авырып ята, торырга хәле юк иде. Аскы каттагы, теге Ризван торган бүлмәдә безнең асрау кыз яши иде, ул каядыр киткән булган, күрәсең, этиләр аның ишеген дөбердәтеп тә, каерып та карадылар — ача алмадылар. Бик ашыгалар да иде. Эти мине кысып, кочагына алып сөйде дә: «Мин тиздән кайтырмын, кызым, көт»,— диде. Әни бүлмәсенә кабат кереп, саубуллашып та тормады. Соңыннан белдем: нэпманнарны эзәрлекли башлаган еллар булган икән ул. Эти шул көннән әйләнеп кайтмады. Яшь хатын ияртеп чит илгә чыгып киткән икән, диделәр. Дөрестерме, анысын белә алмадык, болгавыр заманнар иде шул... Икенче көнне карыйбыз, асрау кызның бүлмәсеннән кала, бөтен ишекләр дә тоткасыз... Адәм балаларының кыйммәтле әйбергә алданып уйнавы көлке бер уйласаң. Матур яшәү өчен бик аз кирәк бит, күңелең бай булса... Кеше жиргә буш кул белән килә, буш кул белән китә — менә кайда бөек хакыйкать...

Анна Леонардовна калын альбом алып килде. Мин шунда гына, искә төшереп, сумкамнан хатны чыгардым. Озак китерми торганым өчен гафу үтенеп, хатны Анна Леонардовнага суздым.

— Син альбомны карый тор, хәзер чәй өлгертәм,— дип ул кухняга чыгып китте.

Альбомнан борынгылык исе килә: эполетлар, аксельбантлар затлылык, кинәнеп яшәү теләге янып торган канәгать чырайлар, купшы эт житәкләп төшкән күркә прическалы ханымнар — мәңге кире кайтмаска киткән дәвер. Камыш урындыкта кулына жилпәзә тотып төшкән кызчык — Анна түтинең үсмер чагы. Ниндидер чалымнарыннан танып, төсмерләп була. Ә бусы — туй күлмәгеннән. Яшь Анна янәшәсендә кара бөдрә чәчле егет. Сугышта үлгән ире шулдыр, ахры. Онытылып, кәнәфигә чумып альбом карап утырганда кинәт сагая калдым. Тып-тын. Жан әсәре сизелмәгән шомлы тынлык. Аяк очына гына басып, кухня ягына чыксам... Стенага башын терәп утырган Анна түтинең йөзе апак, күзләре йомык. Мин куркып эндәшүгә, керфекләре селкенеп куйды. Тиз генә графиннан су алдым да иренәнә китердем. Ул бер-ике генә йотым эчте дә:

— Рәхмәт... Мин болай гына...— дип урыныннан торды,— мә бу хатны укып чык,— дип миңа сузды.

Хәрефләрне матур тезеп, өлкән кеше кулы белән язылган хатны кулыма алдым.

«Аннета!

Моннан мең ел элек Сирин сиңа шулай эндәшә иде.

Янәшәмдә илһам биреп, сулышың белән мине жылытып торган хрусталь кыз... Саксыз кагылудан чылтырап уалыр шикелле нәфислек жирдән генә түгел, күктән дә иңгән иде бугай сиңа. Миндә туган хисләрне син, кыю кыз, иң беренче булып сүзләргә әйләндердең. Ә мин, табигатьнең мәңгелек гаделлеген төсле буяулар белән кабатлап, үземчә, яңа дөньялар ачып кына синең биеклегеңә ирешә алачак идем. Син миңа рәнжи-рәнжи яратуыңны белдергән чакта, садә мәхәббәтеңә торырлык дөньяның беренче баскычында, билгесез көч каршында хәер сорашып торган фәкыйрь хәлендә идем әле мин. Бәлки, читтән караганнар өчен мин үз сәләте белән тантана иткән бер исәр булып тоелганмындыр.

Минем каршыма төсләр мириадасы агылып килә, кайсы дулкын артында моңа кадәр беркем өлешенә тимәгән асыл төс балкып китәчәк — шуны тотып калырга дип алгысынам, жирдәге бөтен рәхәтлекләр минем өчен газап булып тоела.

Ерак йолдыздан күзәтеп торган Демон мине ашыктыра, йокымнан уята, аңымны ала, аның мәкерле елмаюыннан шашынып, мин үртәлә-үртәлә үземне расларга ашыгам. Жаныма үрләгән утлы гөл вакытлы бәхеттәр, ялгыш кына миңа кагылгандыр, бер көн килеп сизәрләр дә миннән тартып алырлар, өреп сүндерерләр кебек иде.

Ә син мине аңламыйсың. Картиналарым эченә кереп китәсең дә, үз хозурлыгыңда ялгыз калгач, артыңа борылып карыйсың. Син бит мине түгел, соклану рәшәсе аша минем чагылышымны гына идеал итеп кабул итә идең. Матур алданудан котылгач кына син минем чын кыяфәтемне күрәчәк идең.

Сиңа багышланган яңа дөньялар ачып, тышкы кабыгымны күңелем белән яшереп, гомер соңына кадәр бергә бару теләге — үземнән дә яшерен бер еракльпкта тора иде. Гомер соңы... Ул бик озын-озак буласы икән, синең тере гүзәллеккә куләгә төшермичә саклап алып барырга кодрәтем житәр иде микән?..

Туктаусыз бимазалап торган шик озак көттермәде, ул көн килде: Демон каһкаһәләп көлде дә миңа аркасы белән борылды: «Үен тәмам! Вакытында үлә белмәдең, хәзер яшә инде, шөһрәт-дан кабере өстендә озак яшә! Мин сиңа тимим!» Кинәт мин утсыз калдым. Күккә караган тәрәзәләремә караңгылык иңде. Кайчандыр үзем ясаган картиналарны танымыйм. Минем кул тигәнме аларга? Минем күз карашым сеңгәнме — ышана алмыйм. Элек мин күргән төсләр кайда?

Кичтән үпкәләп китсәң дә, иртәгә син елмаеп килеп кердең. Шул чакта тирә-юнемне чолгап алган картиналарымда таралып югаласым килде. Сине күрәсем дә килә, күрмим дә, ишетәсем дә килә, ишетмим дә. Убылып килгән коточкыч фаҗигане сизү бөтен барлыгымны биләп алган. Син әлегә берни сизмисең. Мин арганмын, имеш, барысын да куеп торырга, ял итәргә кирәк. Юатуыңа каршы юану сүзләре әйтергә иде югыйсә, юк, мин бәргәләнәм, үз-үземне тынычландыру өчен тупаслык бердәнбер чарага әйләнә.

Сиңа ул чор ерактагы бер төш кенәдер, Аннета. Бөтенләйгә оныткан булсаң да, гаепләргә җөрьәт итә алмас идем. Күп нәрсәне аңлата алмадым мин сиңа ул чакта.

Шуннан соң һәр туган көн минем өчен сират күпере кичү, тәмугның ин хәтәр упкынынннан үтүгә бәрабәр иде. Өмет белән өметсезлек арасындагы курку ярты ел буена барды. Тартылган чиста киндер каршында чарасыз басып торам. Кара күмер тоткан кулымны көчләп йөртеп карыйм. Хәлсез сызыклар күз алдымда үлә бара, мин аларга җан иңдерә алмыйм. Төсләр диңгезе мин торган ярдан һаман ераккарак чигенә.

Дулкыны ташлап киткән ятим ярда утырам. Син әллә каян ук кычкырып миңа таба йөгерәсең. Елмаеп, янәшәмә килеп чүгәлисең. Күпме вакытлар буе алданып йөргәнеңне аңлап сүзсез каласың, җете мираж күз алдыннан тарала башлый. Елмаюың гаҗәпләнү белән алмашына. Кызганып караган күзләрең зур булып ачыла. Минем кулда палитра түгел, гап-гади җылы таш, тигез комга камыш сабагы белән сызылган көчсез сызыклар — мине мәңгегә ташлап киткән илһамның соңгы хәрабәләре... Мин — канатсыз. Синең ачы күз яшеңдә бөкре гәүдәм мескен чайкала-чайкала ерагая бара. Кызгануыңны күрмәс өчен, ярату дигән бөек хисне йөрәгемә күмеп китеп барам. Иреннәрдә ком кебек коры пышылдау: кош очканда гына матур. Җиргә төштеме, җәяүле бөкре кала. Кош очканда гына горур...

Мин шунда иҗат кешесенең асылын аңладым. Тәңре уты һәммә кешегә дә бик вакытлы гына бирелә дә, балкып сүнә икән. Шул изге ут белән бергә янып бетә алганнарны гына күк иелеп үзенә ала. Бу хәтәр сызыкны исән узасың икән, сүнгән рухыңны яшереп, пыскып кына иҗат итәргә мәҗбүр буласың. Әлбәттә, бу халәтеңне сизәләр, моңа кадәр ирешкәннәрең җылысында җан асравыңны сизеп тә әйтергә кызганалар, чөнки синең даирәдәгеләр дә шундый ук хәлдә — сүнгән учак урыныннан көл актаручылар.

Мин бу хөкем ителми торган җинаятькә барырга теләмәдем.

Ярда сине калдырып киткән көнне, кул астында булган бөтен картиналарымны тураклап өйдем дә яндырдым. Мин үземне, соңга калып булса да, беренче мәртәбә әнә шунда үтердем.

Демон, вакыт-вакыт миңа таба борыла, мыскыллы көлә дә, җилпеп, төн пәрәнҗәсен ача. Төсләр, мине уртәп, ерактагы ажаган кебек сулкылдашып куя. Якын килә башласам, эреп, тагын юкка чыга. Араны юка пәрдә булә. Мин шул пәрдәне умырып төшерергә дә, элеккеге серле дөньяларга чыгарга дип барам да барам, ә офык ымсындырып һаман ерагая. Җир читенә җитеп, дәрья ярына тукталганчы мин шулай могжиза булыр да, кире үз хәлемә кайтырмын, дигән өмет белән бардым.

Аннары — Командор утраулары. Яңа бер планета. Мин балыкчы да, аучы да, мич ягучы да — тагын әллә кемнәр. Язмыш мине кагасуга, тугызар валлы дулкын астында калдыра. Томаннарда адаштыра, аюлар белән очраштыра — киләчәгем хакына исән калам. Гарип күкрәк читлегенә сыеша алмыйча канатларын киергән рухымны тыярга тырышып, киләчәк хакына үземне әсирлектә газаплыйм. Еракта синең булуың миңа икеләтә түземлек бирә.

Әмма язмыш миңа тагын бер рәхимсезлек әзерләп торган икән. Янгын эчендә калып, чыраема да танымаслык яралар алганнан соң,

чит планета уртасында тормышка лэгънэт укып, үз-үземне онытырга булдым. Тын дэрья бишегеннэн күтэрелгэн кояшны синең тарафка озатып калуның инде мэгънэсе җуелган иде. Җан белэн тэн көрэше бетте. Сирин дигэн рэссам булмаган. Күк уты аңа бер мизгелгэ ялгыш кына төшкэн икэн. Яшэү дигэн бөек газапка килеп кермэс борын, ул канатларын яндырды.

«Сирин үлде» дип суккан телеграмманы син алгансың икэн, Аннета. Аннан соң мин исемемне алыштырдым. Инде үлэр алдыннан гына син яшэгэн шэһэргэ нигэ дип кайттым соң эле? Ятим үткэн тормышыма бер җылы эзлэпме? «Бер сүз белэн генэ ничек аңлатыйм? Үткэннэрне уятмаска телэп, Пассажда төнге каравылчы булып, көн күзеннэн яшеренсэм дэ, барыбер түзэ алмадым, таныш урамнар үзенэ тартты. Син һаман шул йортта яшисең икэн. Кыюланып бардым, эмма керергэ кыймадым. Тирлэгэн тэрэзэ аша, ябылмый калган пэрдэ читеннэн йөзеңне күрүгэ үк таныдым. Еллар сине үзгэртмэгэн, син һаман элеккечэ. Сагыну томаны аша караган күзлэремнең алданмавына чынлап ышанасым килде...

Изомузейның авыр ишеклэрен калтыранган кулларым белэн ачып кергэндэ мин эле берни дэ белми идем. Үземнең картинам белэн ярты гасырдан соң очрашырмын дип башыма да китермэгэн идем. Ничек исэн калган ул? Кем китергэн аны монда? Синме?

Картина каршында оеп сэгатьлэр буе басып торганмын. Алтынланган рам почмагына: «Моң». Сирин. 1917—1939» дип язылган. Музейның биклэнер вакыты җиткэн икэн. Ике ханым килеп, миңа шиклэнеп карый-карый, чыгарга куштылар. Аларның тупас эндэшүенэ рэнҗемэдем мин. Керлэнеп беткэн гарип бер бэндэ гүзэллек белэн хозурланып, сэгатьлэр буе басып торырга җөрьэт итсен эле! Кичке манзара, моңлы төслэр аңымны исерткэн иде. «Бу картинаны ясаган кеше исэн, ул — мин булам!» — дип кычкырасым килде шул чакта. Ярый эле тыелып калдым. Югыйсэ җүлэрлэр йортына озаткан булырлар иде. Чөнки мин кайчандыр Сирин булганлыгымны кешегэ түгел, үземэ дэ исбатлый алмас идем.

Сирэк чыккан көннэрнең берсендэ мин сине урамда очраттым. Эндэшеп, үземне таныта алсам, күзлэреңдэ тагын коточкыч кызгану күрермен дип курыктым.

Син бу хатны алганда мин инде булмам. Сизэм, каһэрлэнгэн гэүдэмне җирдэ калдырасы җан, ниһаять, эсирлектэн котылып, күккэ ашачак. Хыял ирешмэслек илаһи киңлектэ яшэү дэвам итэ икэн, без эле очрашырбыз. Анда инде, без күлэгэсез җаннар булып, икебез бер биеклектэ очарбыз.

Хуш, Анна!

Яшэвеңэ рэхмэт.

Сирин (Мансур)»

* * *

Төнге шэһэр.

Дамбадан караганда Идел өсте шэмэхэ дулкыннардан шадраланып күренэ. Офыкка җитеп туарылган болытларга сүрэн яктылык сирпелгэн. Күңелдэ — бүгенге тээсирлэр. Ерак болытта онытылып калган нур, изге Мэрьям ананың күзлэренэ төшкэн шэм ялкыны кебек, сүнэ алмыйча талгын гына яна. Икона каршына баскан карчык үзалдына пышылдый: «Миңа да күп калмады... Тэңре катында көт мине, Сирин...» Икенче якта бөкре шэүлэ, ул яктыра, һаман яктыра барып күздэн югала. Хэтердэ ягымлы елмаю, тылсымлы бармаклар гына кала. Янэшэ яшэп тэ күрешэ алмаган җаннар... Тормышның алтын тоткасы булырдай кешелэр! Мин аларның икесен дэ белгэнмен. Аларны очраштыру өчен ялгыш кына эйтелгэн бер сүз дэ җитэсе булган. Эйтмэгэнмен.

димәк, язмыш шулай кушкан. Сирин... Мин сине кызганып түгел, көнләшеп искә төшерәм. Бөек хисне үзеңнән соң да калдырып киткәнең өчен рәхмәт сиңа. Борчылма, җаның күбәләк булып, билгесез каберне эзләп йөрмәс. Синең баш очыңа мәрмәр ташны без куярга тиеш, без... Бу җирдә икенче кабат туарга синең хакың бар.

Ерак болытлар тымызык караңгылыкка чума.

Күперне чыгып, үзем торган якка, ялангач йортлар арасына кайтасы килми, борынгы урамнарга барып керәм. Кайсыдыр чаттан, яшәү кадерен гади бер елмаю белән аңлатырдай билгесезлек килеп чыгар да, җирдәге ваклыклардан аерып алыр кебек.

Төнге шәһәр йокыга китәр алдыннан уфтанып бер сулый.

Үзем дә сизмәстән, элек Диларә яшәгән йорт янында туктап калганмын. Менә хәзер күтәрелеп карыйм да... Таныш тәрәзәдә таныш кул сузылып яшел пәрдәне ачар да... Юк икән шул, кабатлану булмый. Утсыз йомык тәрәзә берни дәшми. Янымда карт тополь генә элеккечә шаулый. Урам кысыла. Сулыш тарая. Мин белмәгән якта, югалтулар аша гына барып була торган исемсез утрауда янган моңлы учак мине үзенә чакыра.

Һәркемнең күңелендә үз атлантидасы бар...



# ПОЭЗИЯ

## Сафуан Муллагалиев

### «Намус» исеме белән

Ышанмадык,
Шикләнмәдек тәме?
Әллә артык сабыр идекме...
Әллә күрмәс өчен,
Гамьсезләнеп,
Башыбызга «чүлмәк» кидекме?
Ләкин
Сизендек бит...
Әйтер сүзне
Ничек итеп әйтми калдык соң? —
«Намус» исеме белән
«Штык» тыгып,
Актарганда кеше намусын,
Урак белән урып өзгән кебек,
Йолкыганда күңел кылларын...
Кул куйдырып яла-актларга —
«Кыскыч» белән борып кулларын,
Актардылар миен,
Йөрәкләрен,
Имгәттеләр сизү тамырын.
Бозауларга гүя ашаткан күк,
Ашаттылар мәкер камырын.
Ашаттылар хәтта балаларга
(Какшатырга рухын халыкның!)
Күпме батыр — асфальт юл астыннан
Еллар үткәч өскә калыкты.
...Ватандарлар җанын
Өзгән «ватандар»лар
Игәп торды очлы безләрен —
Төртте халыкка —
Көтте халыкның
Туып үскән җирдән бизгәнен...

Соң булса да күзне ачтык — яхшы,
Гүя яшен суга акылга —
Үткәннәрдән актарылып, бүген
Йөрәкләрдән нәфрәт атыла...

*

Гаҗәпләнмә,
Минем баш өстемдә
Ярты төндә кояш калыкса —
Ул бит җырым:
Чиксез мәхәббәтем —
Рәхмәтем ул минем халыкка...

*

Сүтелмәслек итеп,
Ике гашыйк
Бәйләп куйса әгәр чәчләрен —
Чәчәк аткан ике мәхәббәтнең
Беркем коя алмый чәчәген.

---

Сафуан МУЛЛАГАЛИЕВ *(1927) — ике шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

...Кызарып таң аткан кебек, чәчәк
Нурын сибә өйнең түренә.
Кем теләмәс шундый таң чәчәген
Үз өендә хет бер күрергә...

Андый чәчәк бу дөньяда юк, дип,
Сөрән сала өстә йөзгәннәр.
Андый чәчәк өчен —
Утта янып,
Салкыннарда туңган гүзәлләр...
Сөрән сала өстә йөзгәннәр.

## Адым белән үлчәп арасын

Безнең тарихлар да
Буй җитмәслек түгел,
Юк хәлендә түгел бөекләр;
Бөекләргә илткән поездларга
Сатып алып булмый билетлар,—
Биек тауга караган күк карап,
Адым белән үлчәп арасын,
Читтән ярдәм көтеп тормый гына
Кем булсаң да җәяү барасың.
Барасың...

## Үземнән дә артык

«Тимер» иде яшьлек,
Килде
Көмеш айлы картлык...
Үткәнебезнең юлымы
Бүгенгедән артык?

Салкын бураны беләнме
Бөек безнең үткән?
Шул карлы яңгырлар безне,
Төшмиенчә күктән,
Көткән: яуган — күшектергән,
Гүя колы иткән...

Мин табигать булсам әгәр,—
Кая алай итү! —
Җылы сөт чишмәсе булып,
Юлчыларны көтеп,
Агар идем яшел таудан
Челтер-челтер итеп.

...Үтте яшьлек,
Килде көткән:
Нәтиҗәле картлык...
Киләсе буыннар миңа
Үземнән дә артык.

# Данис Хәйруллин

## Улым тугач

Мәңгелекме кеше? Әйтә алмыйм.
Беләм бары: вакыт — мәңгелек,—
Әллә уйный, әллә уйлый шулай
Безнең тән һәм безнең гамь булып.

Мәңгелекме бу җир? Әйтә алмыйм.
Уйга сала әмма һәрбер таң.
Уйлар өчен, эшләр, яшәр өчен
Миннән акыл сиңа, миннән аң.

Гөл бакчасы гына түгел бу җир.
Тик һәр көнен өзелеп ярат син!
Мең табышмак дөнья. Мин берсенә
Җавап таптым бүген: җавап — син!

## Ком сәгате

Берәмләп ага сары ком.
Санап тор, әйдә, сана, кем,—
Ничә ел калды, ничә көн?..

Сулар сыксаң да таштан,
Әйләндерә алмассың шул
Гомернең башын башка.

## Перронда

Карап торам, күреп торам,
Әрле-бирле йөреп торам:
Кайный тормыш, дөрли монда —
Шуңа җаным эреп торам.

Китү авыр — киткән белә,
Көтү авыр — көткән белә.
Торам әле бүген менә
Шундыйларга бәхет теләп.

Күрешәләр, үбешәләр,
Гүя бер мин ятим монда:
Озатмыйм да һәм көтмим дә,
Килмәдем дә һәм китмим дә.

Алай дисәм... һәрбер иртә
һәммәбезгә вокзал бит ул;
Үтәсе көн — барасы юл —
Китәсе кыз, китәсе ул.
Бәхетле юл!
Бәхетле юл!

---

Данис ХӘЙРУЛЛИН — *матбугатта исеме күренә килгән яшь шагыйрь. Чаллыда яши.*

## Туган телем

Сүз-чәчәкләр...
                    Такыялар үрәм,
Кочак-кочак күккә чөямен.
Туган телдән чәчәк исе килә,
Чәчәкләрне өзелеп сөямен.

Сүз-яшеннәр...
                    Яшьлек күкрәүләре
Ялкынында һаман көямен:
«Сөя-сөйми, сөя-сөйми...»— чәчәк
Таҗын саный-саный сөямен.

Сүз-сөнгеләр...
                    «Юньсез... Сөмсез... Комсыз...»
Җаныгызга угы тияме?
Тисен әйдә, тисен! Туган телне
Үткерлеге өчен сөямен.

Сүз-упкыннар...
                    Тигезләргә теләп
Төпләренә өмет өямен:
«Сугыш» сүзен бер онытыр әле
Туган телем, диеп сөямен.

## Шундый вакыт

Көн диеп тә, төн диеп тә булмый —
Шундый вакыт менә, шундый вакыт:
Күктә кемдер йолдыз кабындыра,
Янар-янмасларын җиргә атып.

Көз диеп тә булмый, кыш диеп тә —
Шундый вакыт менә, шундый вакыт:
Шәрә агачларда кырыс ныклык,
Таҗсыз гөлләр елый җиргә ятып.

Яшьлек үткән, картлык кагылмаган —
Шундый вакыт менә, шундый вакыт:
Һәр сулган гөл — хәтер-сагыш минем,
Һәр кабыныр йолдыз — өмет-шатлык.

***

Уема уелып керден.
Кумадым, тыелып тордым.

Күземә каелып керден.
Сакладым, керфеккә төрдем.

Йөрәгемдә йөрдең биеп.
Дәшмәдем, тордым баш иеп.

Инде менә хыянәтең...
Артты җирдә ике ятим.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Мәхмүт Хәсәнов

# БЕР УЧ АРЫШ

КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

Кайда егыласыңны белсәң, мәкальдә әйтелгәнчә, йомшаграк түшәп куяр идең. Миңа, командировкага чыккан җиремдә, уйламаганда-көтмәгәндә, больницага кереп ятарга туры килде. Һаман да шул — йөрәк.

Үземә калса, юлга бик тә уңай, бик тә кулай чакта чыккан идем. Яратам, бик яратам мин уттай кызу урак өстен — игенченең кояшны кырда каршылап, эш урынында озатып кала торган чагын. Аннан алып кайткан тәэсирләр елның-ел буена күңелне җилкендереп, көч-дәрт өстәп, рухландырып, илһам биреп тора.

Салам исе, икмәк исе бөркелгән киң басулар буйлап атлыйсың. Якягыңда иген дулкынлана. Талгын җилдә тирбәлүче тук башаклар колагыңа балачактан таныш булган иң матур, иң изге, иң якын көйне суза сыман. Баш өстемдә тургайларның көмеш чыңы. Аларга туй ясаучы чикерткә тавышлары кушыла...

Игеннәр җитлеккән чак. Урак өсте. Ул гомер-гомергә елның иң әһәмиятле фасылы булды. Чөнки ул чор игенченең изге туфракка күкрәк көчен салып, маңгай тире белән сугарып, фидакарь һәм мөкатдәс хезмәтен биреп үстергән җимеше — икмәк белән очрашу мизгеле...

Икмәк! Безнең бөтен гореф-гадәтләребез икмәк дигән изге ризыктан аерылгысыз. Икмәк тарихы — безнең тарихыбыз, яшәешебез тарихы. Безнең шәҗәрә, безнең нәсел җебе, нәсел агачы тарихы. Бу турыда без бер генә минутка да онытырга тиеш түгелбез. Онытырга хакыбыз юк! Революция еллары икмәге, гражданнар сугышы чоры икмәге... Арада, 1921 елгы, кара афәт — ачлык елы икмәге дә бар. Илебезне индустрияләштерү һәм колхозлашу чоры икмәге. Һәм, ниһаять, көек исе сеңгән Бөек Ватан сугышы еллары икмәге. Аның кадерен чамалау өчен Ленинград блокадасы ипекәен искә төшерү дә җитәдер...

Һәрбер бөртеге гаять зур авырлыклар белән табылганга күрә дә, бөек тә ул Икмәк! Тирәннәнрәк уйлый китсәң, безнең басуларыбыз күкрәк көче, маңгай тире белән генә түгел, ата-бабаларыбызның кайнар каннары белән дә сугарылган...

*

**3 август.** Чалт аяз көн. Игенче өчен иң хозур, шул ук вакытта, иң кызу чор, вакытны тәүлекләп түгел, минутлап саный торган чак. Ә мин шундый вакытта тынчу палатада ятам. Хәлем мөшкел, үзем генә беләм. Әмма врачым белән уртак тел таптым кебек, санаулы минутларга гына булса да,

саклык белән генә, урамга чыгам, аллеяның бирге башындагы эскәмияләрдә утыргалыйм. Шактый гына кешеләр белән танышырга да өлгердем инде.

Ике кешелек палатада берүзем ятам. Бу хәл башта, үз-үземне күрәсем килмәгән чакта, куандырса да, икеме-өчме көн узгач, берәрсен кертсеннәр иде ичмаса, дигән теләк уянды.

Салтыков-Щедрин теге яки бу шәһәр белән танышуны зираттан башларга киңәш иткән. Мин исә әлеге төбәк белән «Маяк» исемле газета аша таныша башладым. Өченчеме, дүртенчеме тапкыр инде, моннан атна-ун көн элек чыккан газетаны укып ятам. Укымыйча чараң юк. «...Менә без — «Карамалы кыры» дип аталган күпьеллык үлән басуында,— дип яза автор.— Эшнең кызган урыны — нәкъ шушында икән. Басу түрендә — «Авангард» колхозының алдынгы механизаторларыннан Мөхәсим Ибраев белән Нурислам Кәримовлар.

— Быел бу басуның һәр гектарыннан 270 әр центнер яшел масса алабыз,— ди колхоз председателе Идият Фәтхуллович Миңлебаев.— Ә узган ел — нибары 65 центнер гына иде...»

Шул вакыт палата ишеге ачылып китте. Махсус озын арбага салынган авыруны алып керделәр. Шәфкать туташлары авыруны караватка күчерделәр. Аннары авыруның баш очында җилкәсенә халат салган өлкән яшьтәге хатын гына калды. Ул, санитарка хәзерләгән урынны ошатмагандай, мендәрне рәтләде:

— Болай җайлымы, сиңа әйтәм?

— Ярыйсы...— диде авыру.

Авыру ягына күз салдым. Яше җитмешләр тирәсенә якынлашкан агай. Җил искән кара тут йөзен тирән-тирән җыерчыклар бизәгән. Куе тузынкы кашын кояш ашаган. Яңак калканнары күпереп тора. Кысынкы күзләрендә тетрәндергеч моң-сагыш һәм тагын үкенеч сыман нәрсә чагыла. Иң хәйранга калдырганы — кардай ак җәймә өстендәге куллары иде. Карабодайның зәңгәрсу-шәмәхә сабагына охшаган кан тамырлары бүлтәеп чыккан, куллар зур, тупас, тоташтан кара көйгән кебек.

— Әх-х, менә бит!..— дип, тирән көрсенеп куйды авыру.— Үлгәннәр каберләреннән кубарылырлык көннәрдә... шушында кереп ят инде...

— Тыныч кына ятчы, зинһар!— диде апа кеше.— Бу тиклем дә кырмыскалы йөрәк булырсың икән. Гомерең буе шул инде синең. Үзеңнән башка дөнья тукталыр дисеңме әллә? Эшләмәдең түгел, эшләдең. Әнә, докторлар нәрсә диде: бернинди борчылу, бернинди кирәкмәгән уй-хәсрәткә бирелмәскә! Урыныңа менә дигән яшь агроном калды. Югары белемле...

— Дипломлы диген...— Авыру агай әрнү-сызлануларын яшерә алмаган бер кыяфәт белән сөйли иде.— Китап кына укытучыны да, тәҗрибәне дә алыштыра алмый. «Иген җаен иккән белер», ди торган иде эти мәрхүм...

— Иөрәкме?— дип сорап куйдым.

— Шул каһәр инде...— диде күршем.

Барлык авырулар да палаталарын ташлап тышка күчкән диярсең, кая карама — халат, пижама киеп алган авырулар. Алар аллеядагы эскәмияләрне генә түгел, коймa буендагы яшел-хәтфә чирәмлекне дә тутырган.

Хәлем әллә ни ерак китәрлек булмаганлыктан, киң таш баскычтан төшүгә, шунда, каршыда гына үсеп утырган өрәңге ышыгындагы эскәмиягә юнәлдем. Анда минем кичә генә танышкан кешем дә утыра иде. Зур гәүдәле, нык бәдәнле ул. Һәрчак җитди. «Бөер»,— дип зарлана. Үзен, абруйлы кешеләргә хас булганча, шактый ук дәрәҗәле, һавалы тота. Авыл хуҗалыгы работниклары профсоюзының район комитеты председателе икән. Берүзе аерым палатада ята. Ул, килеш-килбәтенә караганда, авырудан бигрәк, җылы якта ял итүчене хәтерләтә.

Иптәш Мортазин белән сүземне палатама авыру кертүләреннән башладым.

— Ниһаять, миңа да иптәш табылды,— дидем.

— Беләм мин ул бәндәне... «Авангард» колхозының агрономы ул. Үзсүзле, кирebеткән бер нәмәстә шунда.

— Чыннан да, бераз сәеррәк кешегә охшаган...

— Бик белдекле булып, киреаксә-кирәкмәсә дә тыгылып-тыкшынып, ертыктан сүтек эзләүдән бушамый торган бер бәндә — Әшрәф Әхмәтов. Заманында миңа бөтен район күләмендә җир белән, уңыш белән идарә итәргә туры килгән иде. Нәкъ менә шул елларда канга бик күп тоз салды.

— Башбирмәс, бунтарь кеше алайса?

— Каян килеп бунтарь булсын?!.

Шәфкать туташы мине чакырып алды. Укол ясар чак җиткән.

Процедура кабинетында кан басымы белән иза чигүче тагын бер танышымны очраттым. Дамир Зарипов. КПСС райкомының бүлек мөдире. Палатамдагы күршем турында әйттем. Ул да инде бу турыда ишеткән икән:

— Бәхет елмаймаган үзегезгә. Әшрәф ага кебек, хезмәтне вөҗдан таләбенә әйләндергән фидакарь, җиргә җаны-тәне белән бирелгән, ил гаме белән яшәүче бүтән кешене белмим мин,— диде.

— Бераз кырысрак күренә...

— Мортазин сүзенә бик ук ышанып бетмә әле син,— диде.— Аларның беркайчан да боткалары пешмәде. Әшрәф ага — туры, гадел кеше. Берважытта да кемнең кем булуы белән санашып тормады, турыдан ярды. Ә Миңлебай Закирович кебекләр тәнкыйтьне, абруйларына күләгә төшерүчеләрне, ай-һай ла, яратмыйлар. Моннан байтак еллар элек, аларның бер җыелышта пычакка-пычак килүләре әле дә хәтердә. Мортазин, игенчеләрне шактый ук түбәнсетеп: «Нәрсә эшләгәнебезне беләбездер?!» — дип, бик катгый боерыклар бирен маташкан иде. Трибунага чыгып баскан Әшрәф ага элеп алып селкеде дә салды тегене. «Юк, хөрмәтле Миңлебай Закирович, бигайбә!..— дип башлады ул сүзен.— Без сезнең, тормыш үзе гамәлдән сызып аткан, кадими заманнан калган күрсәтмәләрегезне кабул итә алмыйбыз. Җир белән хаталанырга ярамый, бу хатаның бик кыйммәткә төшүе бар. Җир бит ул — нәкъ аш табагы, аңардан, ни салсаң, шуны гына алып була. Нишләп әле сез игенне кабинет тәрәзәсеннән яхшырак күренә дип уйлыйсыз? Сез бит кайчан, күпме һәм нинди ашламалар чыгаруыбызны да, басуларыбызны нинди ысул, нинди максатлар куеп эшкәртүебезне дә, чәчү әйләнеше кануннарын да белмисез. Җир бала көтә торган яшь килен кебек, аның ризык талымлавын сез кайдан белә аласыз соң, иптәш Мортазин, белмисез!..»

— Билгеле, шома гына узмады аның ул чыгышы. Шелтә чәпәделәр.— Дамир, нидер исенә төшергәндәй, елмайды да дәвам итте: — Менә шундый кеше ул Әшрәф ага.

Әшрәф ага турында район газетасы битләрендә шактый гына кызыклы материаллар чыккалаган. Дамир миңа шул иске газеталарны табып бирергә булды.

Шулчак озын коридорның аргы башында, безне дәвалаучы врач Сафина күренде. Авырулар арасында аны үз итеп: «Сылу Миңсылу» дип тә, «Җилле доктор», дип тә йөртәләр. Аның ике кулын халат кесәләренә батырып, итәкләрен җилфердәтеп, җил-җил якынлашып килүен күргәч, без дә, җәһәт кенә урыннарыбыздан кубып, палаталарыбызга таралыштык.

— Апа, тиз булыгыз, врачлар обход ясый. Зинһар, тизрәк селкенегез!— диде ул Әшрәф аганың хатынына.

Аксыз да каушап-югалып калган апа кеше, кая барып бәрелергә белмәде. Әшрәф аганың сүзе бетмәгән икән:

— Рәфискә әйт!.. Башакларны иртәгә ук алып килсен. Төрле урыннан алсын. Бутамасын... Урман буеннан, үзәнлектән, басу уртасыннан, калкулыктан... Аерым кәгазьләргә төрсен. Бутамас өчен, кайдан алганлыгын язып куйсын. Башакларга карап, аларның җитлеккәнен тикшереп, кайсын кайчан ура башларга үзем команда бирермен. Ишетсен колагың, минем командадан башка — комбайннар кертте юк! Басуның гадәти түгеллеген онытa күрмәсеннәр, сынау-тәҗрибә участогы ул...

Озак та үтмәде, ишек ике якка ачылып китте. Аннан, коллегаларын

ияртеп, Сафина килеп керде. Туп-туры Әшрәф ага караватына юнәлде. Апа кешедән калган урындыкка килеп утырды да авыруның хезмәт мәһе-ре сугылган — җир карасы йоккан кулын алып, йөрәк тибешен санады.

— Менә нәрсә, Әшрәф ага. Сезгә хәзер иң төп дәва — тынычлык. Җыен юк-бар белән җаныгызны кыйнамау. Беләм, уттай кызу урак өстендә сезгә монда ятуның әҗәлгә тиң иканлеген дә беләм. Тик нишләмәк кирәк, авыру сорап килми. Колхозыгызда эшләр һәйбәт кенә бара. Район газетасы да, радиосы да мактап телгә ала. «Безнең депутатыбызның хәле ничегрәк?» — дип, райисполком да, райком да кызыксынып тора...

Яткан җиремнән врачны күзәтәм. «Сылу — Миңсылу» дип йөртүләре урынлы, чыннан да, матур, мөлаем хатын.

— Тизрәк савыгып, аягыгызга басасыгыз килә икән, һәрнәрсәне бары тик мин дигәнчә генә эшлибез. Шулай итсәк, бар да яхшы булыр,— диде ул ахырдан.

Минем янда туктап та тормады.

**4 август.**

— Әнә, безгә кирәк егет тә монда...— диде Дамир, сәрви агачы күләгәсендәге эскәмиядә утыручылар төркеменә күрсәтеп,— район газетасында эшли. Хәтерегездә тотыгыз, иseme — Әсгать, фамилиясе — Сәгыйтов.

Исәнләшеп без дә, тәмләп кенә гәп сатучылар төркеменә кушылдык. Дамир, минем якка ым кагып, Әшрәф ага белән кызыксынуымны әйтте, берьюлы Әсгать Сәгыйтовка да үзенең үтенечен белдерде.

— Эшлибез аны, Дамир абый,— диде егет бик күндәм кыяфәт белән.— Әшрәф ага турында минем дә язган бар ул!..— Егет Дамир абыйсы әйткән мәкаләне дә, үзенең язмаларын да бүген үк миңа тапшырырга вәгъдә итте.

Шулчак безнең янда гына утырган берәү, мәзәк сөйләргә теләгәндәй, сүз башлады. Имештер ул, хатынын култык астына кыстырып, Кырымнан ялдан кайтып килә. Караса, каршысында — Әшрәф ага! Кайда диген әле?! Мәскәү метросында. Әшрәф аганың җилкәсендә — арыш капчыгы! Кулында — тагын нииндидер янчык. Шунда якташы Әшрәф агага чак кына ярдәм дә итә. Кулындагы төенне үзенә ала. «Әһә-ә, дип уйлый үзе, димәк, безнең якка яңадан нииндидер яңа сортлы орлык кайта.»

Бу сүзләр мәзәк кебек иттереп сөйләнелсә дә, тыңлап торучылар җитдигә бордылар. Әшрәф аганың илебезнең күп кенә атаклы селекционерлары белән дусларча аралашуы, яңа сортларны үзе яшәгән район шартларында сынап караулары турында сүз куертып алдылар. Әгәр дә хак булса, бер танылган галим, Әшрәф ага Әхмәтовны хәтта үз янына эшкә дә чакырган, имеш.

Уртада өлкән яшьтәге авыру утыра. Операциядән соң. Аның да әйтергә теләгәне Әшрәф турында иде. Беренче сүзләреннән үк шул аңлашылды: авылдашлар икән.

— Замана авырлыкларын үз җилкәсендә күп татыды минем яшьти. Кем әйтмешли, җанын җир урынына сөрделәр аның. Анда нинди нервы, нинди йөрәк түзсен, ди. Гаделсезлек күрсә, башкалар кебек, телен аркылы тешләп, дәшми кала алмады. Ничек кенә кыланмадылар адәм өстеннән. Бер дә юкка мең төрле шелтәләр бирү дисеңме, икмәк урлады дип, нахакка хөкемгә тарттырулар дисеңме, барысын да кичерде... Берсендә, нәкъ менә хәзергедәй, кылны кырыкка ярыр вакыт иде. Таң сарысыннан, караңгы төнгә кадәр, өеңә кайтырмын димә. Мин, машинам белән, басудагы механизаторларга ашарга алып барырга тиеш идем. Әшрәф-яшьти дә минем янда.— Абзый кеше ирен кырыйлары белән генә елмайды.— Безнең халыкта: «Исереккә сәлам бирмә, ул бирсә дә, син алма», дигән сүз бар. Махсус савытларга тутырып, һәйбәтләп томаланган аш-суларны алырга дип, ашханәгә кердем. Безнең ашханә — олы юл өстендә. Шунлыктан үткән-сүткән сугылып чыкмыйча калмый. Без кергәндә дә, ни күрик, тәрәзә буендагы өстәл янында, акырып-бакырып, сүгенеп өч-дүрт исерек утыра. Шунда Әш-

рәф яшьти томырылып тегеләр янына ыргылды, барып та җитте, арттан килеп, берсенең муен тамырыннан эләктереп тә алды. Үзе бер үк сүзләрне тәкрарлый: «Кабахәт җан! Хәзер үк ал икмәкне!.. Ал диләр сиңа!.. Югыйсә, җаныңны җәһәннәмгә олактырам...» — дип, бер сугуда яшь үгезне тезләндерерлек егетне өстәл астына бөгә бу. Бу көтелмәгән хәлдән кинәт айныган егет: «Вот псих!.. Мә! Синеңчә булсын!..» — дип, өстәл аягы астына кыстырылган ипи катысын тәлинкәгә алып салды. Әшрәф яшьти әлеге Алып батырдай егетнең өстәл аягы астына, аракы тулы стаканнары чайпалмасын өчен, икмәк кыстырып куюын күреп калган икән...

Әшрәф юл буена ярсып барды. Мин инде үземчә: «Иә сәнә, тынычлан, ташла, азмы әле андый бәдбәхетләр»,— дип тә караган идем, кая ул тынычлану!»

Сүзгә яңадан яшь журналист Әсгать кушылды:

— Районда авыл хуҗалыгы алдынгыларының слетын уздырырга хәзерлек барган көннәрдә, кабат Әшрәф ага янында булырга туры килде. Аңа РСФСРның атказанган агрономы дигән исем бирелгән көннәр иде. Газета өчен фоторәсеме кирәк. Сирәк була торган хәл: идарәдә, кабинетында очраттык үзен. Бераз әңгәмә корып алдык. Нинди йомыш белән йөрүебезне аңлаттым. Киенеп килү өчен өенә кайтарып җибәрдек.

Кырынып, ап-ак күлмәк, яңа костюм киеп килгән бу, тик галстук такмаган. Фотограф Садриевның хөрмәгә үрмәләүче маймыл сурәте төшерелгән галстугын алдык та тактык. Редактор, ярты еллык подшивканы күтәреп: «Колхоз-совхозлардан алып кайткан фотоларыгызга күз салыгыз!.. Һәркайсында — әлеге дә баягы маймыл...» — дип, бирде генә кирәгебезне.

Зур бүләкләрдә — Әшрәф аганың бөтен биографиясе. Ул шушы төбәктә туып-үскән. Сугышка киткән. Будапешт, Прага шәһәрләрен азат итүдә катнашкан. Аннан соң Порт-Артур ягына чыгып китканнәр. Германияне, Японияне җиңгән өчен бирелгән медальләре янында өченче дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары да бар. Армиядә җиде ел булырга туры килгән Әшрәф ага Әхмәтовка. Туган якларын, туган-тумачаларын, үзе югында дөньяга килгән кызын үлердәй булып сагынып кайткан ул. Сугыштан соңгы гомерен тулысынча Җиргә багышлый. Башта — техникум, читтән торып, институт тәмамлый. Гел агрономлык эше белән мәшгуль була.

Әсгать Сагыйтов, бераз төтен җибәрергә яратса да, сүзендә торучан икән. Көндезге йокы сәгатьләре үтү белән, ул миңа дүрт-биш газета китереп тоттырды.

Иң әүвәл, Әшрәф аганың портреты урнаштырылган газетаны кулыма алдым. Редактор шелтә белдергән галстукка игътибар итәм. Кара җирлеккә хөрмә һәм маймыл сурәте төшерелгән галстук, чыннан да, Әшрәф агага ятышып бетми сыман.

Рәсем астын укыйм: «Авангард» колхозы игенчелектә югары культуралы коллектив исемен йөртә. Моңа агрочараларның ныклы сыналган системасын эшләү нәтиҗәсендә ирешелде. Ә бу өлкәдәге уңышлар, беренче чиратта, колхозның баш агрономы Ә. А. Әхмәтовның эзләнүләренә, фән казанышларын, алдынгылар тәҗрибәсен кертүдә армый-талмый эшләвенә бәйләнгән...»

Кулымда — икенче газета. Дамир әйткән мәкалә нәкъ шушы санда урнаштырылган. «Эзләгәннең эзе кала» исемле язма газетаның тулы бер битен биләгән. Менә аның кайбер юллары: «Кеше җиргә могҗиза тудыру, үз эзен калдыру өчен килә. Бу — Әшрәф аганың яраткан сүзләре. Минем алда — «Авангард» колхозының баш агрономы Әшрәф ага Әхмәтовның күн тышлы — калын-калын көндәлекләре һәм күптөрле сынаулар үткәргәннән соң теркәп куелган язмалары.

Бер дәфтәрдә халкыбызның иген игү хакындагы тәгъбирләре, риваятьләр, гыйбарәләр, дастаннар, җыр-такмаклар, хәтта әкиятләр тупланган. Язмаларның күп өлеше сынамышлардан тора. Менә, кош-кортларга караган сынамышлардан берничә мисал: «Чаңгырау торна биегән җирдә иген булмый», «Тургай сайрый башласа, сабанга чык», «Кыр казлары түбәннән очса, сабан аш-

лыгы уңар», «Бытбылдык язын тартардан элек кычкырса, ашлык мул булыр, мал-туар симерер», «Карлыгач килгәч, борчак чәчәргә кирәк»...

Дәфтәрләрнең берсендә игенче һөнәренә кагылышлы халык җырлары, такмак-такмазалар да бар:

Арыш чәчтем — уңмады,
Бодай чәчтем — уңмады;
Һичкемгә дә үпкәләмим,
Үз бәхетем булмады...

Агрономия һәм җир эшкәртү технологиясендә ифрат бай тәҗрибә туплаган Әшрәф аганың язмаларында «Программалаштырылган уңыш» кебек, моңарчы бик сирәк очрый торган сүзләр дә бар. Шундук ул, Җир-ана белән уртак тел тапкан кешегә генә хас оптимистлык белән: «Җирнең мөмкинлекләре чикләнмәгән», дигән сүзләр әйтә һәм конкрет мисаллар китерә. Мәсәлән, ул үзенең бакчасындагы тәҗрибә түтәлләрендә, һәрбер төбе сигезәр килограмм һәм аннан да артыграк тарткан чөгендерләр үстергән. Шулай ук көзге бодайдан да (гектарга чыгарып исәпләгәндә) 200—250 шәр центнер уңыш алырга мөмкин икәнлекне исбат иткән. «Менә ул игенченең резервлары кайда!» — ди атаклы агроном, үзенең соклануын яшерә алмыйча. Әмма: «Боларның барысына да Җирне яратканда, игенчелек хезмәтенә иҗади караганда гына ирешергә мөмкин»,— дип куя.

Моның өчен, әлбәттә, туфракның уңдырышын арттыру, агротехник чараларны, чәчү әйләнешен төгәл башкару кирәк икән. Мондый нәтиҗәгә ул күп еллар буена сузылган сынау-күзәтүләрдән соң килә.

Әшрәф аганың әлеге язмалары агроном һөнәренә биргән бәясе белән төгәлләнә: «Агроном туфракның яшәү серләрен, табигый шартлар тәэсирендә үзгәрү процессларын бик яхшы белергә тиеш. Бары тик шулай булганда гына авыл хуҗалыгы технологы — агроном илгә, халыкка хезмәт итә һәм материаль байлыклар тудыра ала»...

**5 август.** Бүген мин дә палатада ятам. Көн бозылды. Иртәдән бирле җил котыра. Җәйге челләдә сирәк була торган хәл.

Күршем Әшрәф агага игътибар итәм. Күзләре — тәрәзәдә. Тын да алмый сыман. Сизәм: җаны, бөтен барлыгы белән, басу киңлекләрендә, иген өчен хәлиткеч көрәш барган җирдә ул.

— Быел да урып-җыю бик җиңел булмас, ахры...— дигән булдым мин, күршемнең дә ни турында уйлаганлыгына күрәзәлек ясагандай итеп.— Һич аңламассың бу табигатьне...

— Әй-йе-е!..— дип сузып куйды Әшрәф ага, үзалдына гына сөйләнгән сыман.— Сүз дә юк, ипекәй дип аталган төп ризыгыбызның язмышы, тырыш хезмәт белән бергә табигатьнең миһербанлыгына да бәйле. Шахмат уйнарга яратучы Терентий Семенович сүзләре белән әйтсәк: аклар белән беренче булып һәрчак табигать йөри... димәк, ахыр чиктә, барыбер җир хуҗасы — игенчегә баш ватарга кала.

— Әшрәф ага, Терентий Мальцевны күргәнегез дә бармы әллә?

— Булды андый хәл. Юлым Төмән өлкәсенә барып чыккач, ике генә көнгә сугылган идем...

— Әшрәф ага,— дидем мин, әңгәмәнең шулай җиңел ялганып китүенә куанып.— Шундый зур абруй казанган Мальцев тәгълиматының хикмәте нәрсәдә?

Күршем ялындырмады, сөйләп китте:

— Дөнья галимнәре, шул исәптән, безнекеләр дә, игенчелек өлкәсендәге үсемлекләрне ике төркемгә бүлеп йөртәләр: туфракны бозучы, һәм дә килеп, туфракны дәвалаучы, ныгытучы, туфрак структурасын яхшыртучылар группасына кертәләр. Ә менә башаклы үсемлекләр туфракны бозучылар, җир структурасын җимерүчеләр: арыш, бодай, арпа кебек төп бөртекле культуралар. Терентей Сергеевич, фәнни бәхәскә катнашып, берүзе бөтен галимнәргә каршы чыга, җир белән дөрес эш иткәндә, туфрак

структурасына зыян китермичә, ягъни җирнең астын-өскә әйләндермичә дә, югары уңыш алып була, ди.

Мин, Әшрәф аганы сөйләтә башлавыма куанып, янә сораулар биреп калырга ашыктым. Соңгы елларда матбугат битләреннән, телдән төшми торган яңалыклар: агропромышленность комплексы, шулай ук район агропромышленность берләшмәсе советлары турында сүз кузгаттым. Әшрәф ага үзалдына гына сөйләнгәндәй, дәвам итте:

— Ничек кенә булмасын, һәркайсының нигезендә Җир һәм җиргә җаны-тәне белән бирелгән, ару-талуны белмәс, фидакарь игенче хезмәте калачак...

Ул көнне без, Әшрәф ага белән, бары тик төшке аштан соң гына икәүдән-икәү була алдык. Мин янә — урак өсте, аның мең төрле мәшәкатьләре турында сөйләнә башладым.

Әшрәф агага да җан керде. Иөзен миңа таба борды:

— Иген өчен көрәшнең беркайчан да җиңел булганы юк,— диде ул.— Елларны гына күр син: бер ел корытса, ике ел тоташтан коепмы-коя... Шуңа күрә дә игенче гомере буе ут йотып яши. Тикмәгә генә: игенченең абруе — кыл өстендә, дими торганнардыр...

Әшрәф аганы, кабат сүзгә чакырып, аяусыз сугыш һәм аннан соңгы авыр еллар турында гәп саткандай итәм. Бу юлы да «чиертте» тагын. Җанга үтеп кереп, бәгырьләрне пәрә-пәрә телгәләрлек күренешләрне күзалларлык сурәтләп, янә сөйли башлады:

— Язмышның шәфкатьсезлегеннән зарлану — ир-егет эше түгел. Мин дә зарланып әйтмим, чөнки ул еллардагы авырлык-мохтаҗлыклар бөтен ил белән бергә кичерелде. Шунысы хәтергә гомерлеккә уелып калган: уңыш юк, адәм әйтеп, адәм ышанырлык түгел.

Бер заман председательләр алыштыру модага кереп китте. Сүз дә юк: уңышның сере кешегә бәйле. Кеше, теләгән тәкъдирдә, шәрә таш өстендә дә иген үстерә ала. Безгә андый кешене озак көтәргә туры килде. Ел саен алышынып торган җитәкчеләрдән тәмам гаҗиз булды халык. Әй юк, җә юк, тотарлар иде дә китерерләр иде чираттагы кандидатны. Ниндирәк кеше? Нәрсәгә сәләтле? Халык белән эшләгәне бармы?— беркем бернәрсә белми. Яңа хуҗабыз иң әүвәл үзенә һәйбәтләп алты почмаклы йорт салу хәстәренә керешә. Башка урынга күчерә-нитә калсалар (озак утырмаячагы көн кебек ачык), йортны сатып, кесәсенә шактый йомры сумма салып китә. Председательнең өе авылның һәрьягыннан ялт итеп торса да, авылыбыз, күзгә күренеп, ишелер, коелыр, таркалыр иде.

Нәкъ менә шундый аптырашлы-йөдәшле елларда янә хәбәр: тагын яңа председатель сайлыйбыз икән. Халыкка нәрсә, җыелды. Сәхнәдә райком вәкиле янында утырган булачак председательне дә күрдек. Яшь кеше. Җитди. Ни хикмәттер, ул җыелышта, зур сүзне бүлеп, мәгънәсез сораулар биреп маташмадылар, чөнки булачак председателебез Әнвәр Бәдриевич беренче сүзләреннән үк халыкның иң авырткан, иң әрнегән җиренә кагылды. Безнең азатлыгыбыз өчен яу кырында ятып калган авылдашларыбызны телгә алды...

— Алар безгә, кадерле иптәшләр, дөньяда берни белән дә чагыштыргысыз зур мирас — яшәү хокукы яулап калдырдылар,— диде.— Әгәр дә мин хәзер: колхоз ни өчен шушындый хәлдә калды? Бу авылда бары тик ялкаулар гына яшимени дисәм, мин, беренче чиратта, илебез, туган җиребез хакына ятып калган авылдашларыбызның рухын рәнҗетер идем.

Икенчеме-өченчеме көнне минем белән аерым сөйләште:

— Әшрәф абый,— диде бу, бик гадәти сүз башлагандай итеп.— Сезнең шактый үк үсүзле, авыр холыклы кеше икәнлегегезне миңа җиткерделәр инде. Хаклы булганда, үз позициясе өчен аяк терәп торган кешене яратам мин... Җирне яхшы белүегезне, аны яратуыгызны да беләм. Әйдәгез, без сезнең белән болайрак сөйләшик: мин һичкайчан да сезнең эшкә тыгылып, җаныгызны кыйнап йөрмәм. Әмма, бер шарт. Дәүләткә ашлык тапшыру планын үтәү турында сүз булырлык итмик! Сүз планны арттырып

үтәү турында гына барырга мөмкин. Мин сезне, үз чиратымда, өстән кил гән мең төрле инструкцияләр, административ күрсәтмәләр, положениеләр белән борчымаска тырышырмын. Я, шуңа ризамы?..

Һай-й, егетем, белмисез генә! Ул мәгънәсез таләпләр, төрле инструкцияләр җанны тинтерәтә, җанны рәнҗетә, ярты картайта торган иде.

Соң шул! Без ир-егетләрчә кул кысыштык. Әлеге сөйләшүдән соң иркен сулыш алгандай булдым, үземә пар канат куйгандай хис иттем. Әмма иртәрәк куанганмын, иртәрәк канатланганмын булып чыкты. Беренче язында ук председателебезгә, минем аркада, партия шелтәсе чәпәп кайтардылар...

Ничек итепме? Эш болайрак булды. Чәчүләрне һәйбәт кенә тәгәлләдек. Бәрәңге утыртырга әзерләнәбез. Өстән әлеге дә баягы, яңадан телефон шалтырый. Гүердән чыккан кәр, тук тавыш: «Әй-й, сез, авангардлылар! Бәрәңге утыртуны тәгәлләдегезме?.. Һич югында, күршегез «Эконом»нан үрнәк алыр идегез, понимаешь!..»

Ә мин кичен генә «Эконом»да булып кайткан идем. Аларның бәрәңге утыртуларын күреп җан әрнеде. Басу өстендә лай, пычрак. Агрегат тыгыла. Орлык, тәшкән җиргә төшә, төшмәгәненә — юк. Их-х, мин әйтәм, бер көнлек җиңүче булып саналыр өчен җирне шулай мыскыл итәләрмени?!.

Соң шул. Бюрода да мактадылар «Эконом» колхозын, әй мактыйлар, күкләргә чөяләр, мин сиңа әйтим, ә безнең тетмәбезне теттеләр. Яңа председателебезгә шелтә чәпәп куйдылар. Минем белән тагын да мәрхәмәтсезрәк кыландылар. Чөнки бирәсе шелтәләр күптән бирелеп беткән, соңгы кисәтүләр дә өсте-өстенә өелгән иде. Барысын исәпкә алдылар да, күпчелек тавыш белән партиядән чыгардылар да аттылар. Мин: көзгә кадәр генә булса да калдырып торыгыз, дип тә караган идем, кая ул, колакларына да элмәделәр.

Кайтырга чыктык. Яшь председателебезнең сөмсере коелган. «Үзем өчен түгел, сезнең өчен хафаланам, Әшрәф абый,— ди бу.— Әнә, нинди коточкыч катгый карар кабул иттеләр». Аннары чак кына шелтә белдергән сымак өстәде: «Үзегез дә, Әшрәф абый, бигрәк тә турыдан бәрдегез... Бәлки, алай ук үзсүзлеләнергә кирәкмәгәндер...» «Юк инде, мин әйтәм, туры юлым таш ярыр. Гаделсезлек минем рухымны ялкауландыра, өметемне сүрелтә, ихтыярымны сүлпәнләндерә. Ә минем партия билетым өчен хафаланмагыз. Мин аны фронтта алдым... Әле дә хәтеремдә: уң як күкрәгемне дошман минасы кыйпылчыгы тишеп, санбатка озату өчен, носилкага сузып салгач, политрук үзе китереп тапшырды. «Хороший ты воин, Ахметов! Скорее возвращайся!»— дип кулымны кысты. Санбатка барып җиткәнче кулымда булды партбилетым. Гимнастерка кесәләре адәм карарлык түгел: изү тулы канлы бинтлар... Күпме генә сакласам да, барыбер чак кына кан табы тиде үзенә. Кем әйтмешли, беренче сораганда ук: рәхим итегез! дип, чыгарып салу өчен алмадым мин аны...»

Бюродан кайткан көнне үк КПСС өлкә комитетына хат яздым, көзгә кадәр, партиядән чыгармый торуларын үтендем, көзгә дәүләткә бәрәңге сату буенча, ике план бирергә вәгъдә иттем.

Кала кешесе булсагыз да, беләсездер, туфракның яхшы ашланган, йомшак итеп эшкәртелүе — бәрәңге уңышының мөһим шарты. Шуны истә тотып алдан ук җиңелрәк туфраклы мәйдан сайланды. Һәр гектарга 35-40 тонна исәбеннән органик ашлама чыгарылды. Культивация алдыннан 4 әр центнер минераль ашлама керттек. Кирәк күләмдә аммиак суы бирелде...

Шунда, Әшрәф аганың сүзен бүлеп, партиядән чыгару мәсьәләсенең ничегрәк хәл ителүе белән кызыксынып куйдым. Әшрәф ага ирен кырыйлары белән генә елмайды.

— Бюродан соң ике атна чамасы үттеме икән, райкомнан кабат шалтыраттылар: «Уйлаштык та, көзгә кадәр, партиядә калдырып торырга, дигән үтенечегезне канәгатьләндерергә булдык»,— дип хәбәр иттеләр.— Әшрәф аганың йөзендә кабат елмаю чагылып үтте.

— Ул елны, бәхеткә каршы,— дип дәвам итте күршем,— Тукаебыз әйт-

мешли: җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында яуды. Дәүләткә җиде ел планы күләмендә бәрәңге саттык.

— Димәк, ул елны рекорд уңышы алдыгыз?..

— Юк,— дип кырт кисте Әшрәф ага.— 150-160 центнер каян килеп рекорд була алсын, ди.

— Әшрәф ага, бәрәңге күпме уңыш бирә ала?

— Җир белән уртак тел табып эш иткәндә, адәм әйтеп, адәм ышанмаслык уңыш алып була. Мәсәлән, Краснояр краеннан бригадир Юткина, үзе иккән мәйданның һәр гектарыннан 1 324 әр центнер алган... Хикмәт бит хәзер югары уңышта гына түгел...— Әшрәф ага селекционерларның, бәрәңгенең механикалаштырылган ысул белән утыртылуын һәм җыелуын, «һәм дә килеп» еракларга ташылуын, күпләп һәм озак саклануын исәпкә алып, бәрелеп-сугылуларга чыдам сортларын булдыру белән шөгыльләнүләре турында сөйләп китте.

— Бельгиядә, мәсәлән, дөньяда бердәнбер бәрәңге музее бар ди. Анда «җир алмасы» турында теләсә нинди мәгълүмат табарга була. Америка индеецларының туклану продукты, зур кыенлыклар китереп, дөньяның башка илләрен дә басып ала башлаган. Бәрәңгене Европада башта шайтан азыгы дип атыйлар.

Бельгиядәге музейда, меңнәрчә экспонатлар арасында, Россиядә бәрәңге игә башлауның тарихи документларын да очратырга мөмкин, ди. Анда, мәсәлән, «Әби патша»ның 1765 елда, ул чор өчен, гигант тираж — 10.000 данәдә чыгарылган «Җир алмасы» үстерүгә кагылышлы «Наставление»се саклана икән. Барысы да Петр I нең Голландиядән җибәргән бер капчык бәрәңгесеннән башланган...

— Хәзерге вакытта бөтен дөньяда ел саен 300 миллион тоннага якын бәрәңге уңышы җыеп алына,— дип дәвам итте Әшрәф ага.

Бәрәңгене иң күп җитештерүче ил — Советлар Союзы. Бездә җир шарындагы бәрәңгенең өчтән бер өлеше үстерелә...

Шул урында әңгәмәбез өзелде, палатага җил-җил килеп, шәфкать туташы керде. Иң әүвәл, Әшрәф агага чираттагы уколын кадады, аннары: «боларын чак кына соңрак, аш алдыннан эчәрсез» дип, ап-ак җәймә белән капланган тумбочка өстенә ике-өч төрле таблетка куйды.

— Җә, үскәнем, докторлар мине кайчанрак чыгарырга ниятләнәләр икән, ишетмәдеңме? — дип сорап куйды Әшрәф ага.

— Савыккач та, абзый кеше...— Кызый ничек кергән булса, шундый ук җәһәт-өлгерлек белән чыгып та китте.

Бермәлгә тынып калдык, әмма озакка түгел, хикәянең дәвамын ишетергә атлыгып торуымны сизенде ахрысы, Әшрәф ага, үзе үк: нәрсәдә туктаган идек әле? дип сорап куйды.

— Яшь председатель Әнвәр Бәдриевич турында сөйли идегез,— дидем мин, сабырсызланып.

— Әй-йе, шул,— дип, күршем миндәрен чак кына өскәрәк этәрде.— Соң шул. Күгәрченгә кайда да җим, дигәндәй, башкалар кебек, үзенә алпавыт утарыдай йорт салырга керешмәде бу. Сугышта берьюлы өч улын югалткан Фәгыйлә исемле ялгыз карчыкка фатирга керде. Бераздан, нәни кызын ияртеп, хатыны да килде. Укытучы иде. Анысы да әүлиядәй акыллы, ифрат та кешелекле хатын иде.

Әнвәр Бәдриевич иң әүвәл, авыл советы председателе Гыймрановны ияртеп, авыл буйлап өйдән-өйгә йөреп чыкты. Күп тә үтмәде, ялгыз карт-корының, ирләре, якыннары фронтта һәлак булган күп кенә гаиләләрнең өйләре сипләтелде. Фермалар да төзекләнде. Иң хикмәтлесе — кешеләребез үзгәрде, газетача әйтсәк, кешеләрнең активлыгы артты. Бригадирлар оператив мәсьәләләрне үзләре хәл итә башладылар. Тора-бара, тавышсыз-кычкырышсыз эшлекле сөйләшү генә калды. Тагын бер күркәм сыйфаты бар иде Әнвәр Бәдриевичның, кеше турында сүзенә, биргән вәгъдәләренә түгел, эшенә карап фикер йөртер иде. Колхозыбыз да күзгә күренеп терәкләнә башлады. Моның сере, минемчә, бик гади: кешегә карата кешечә мөгамәлә.

Берсендә шулай председатель белән урам буйлап барабыз: каршыбызга савымчы Зәйтүнә атлы хатын килә. Колхозның атаклы механизаторы Мөхәсим хатыны ул.

Зәйтүнә, безнең турыга җитәрәк, татар хатыннарына гына хас тыйнаклык-тартыну белән, исәнләшү билгесе итеп, ияк кагып кына үтмәкче иде, әмма председатель аны туктатты:

— Саумысез, Зәйтүнә ханым! Тормышлар иминме, бала-чагалар исән-саулармы? Солдат улыгыздан хатлар киләме? Мөхәсим бүген кайда эшли?

— Ерак басуда иде шул...

— Чирләп-нитеп китмәгәндер бит?..

— Юк та... Бүген аның туган көне, Әнвәр абый. Төгәл кырык!

— Кит аннан! Менә бит, ә! Ә сез аны, мунча ягып, таба ашлары белән көтеп торасыз инде, ә?..

— Барысы да бар иде, Әнвәр абый, тутырган тавыкка кадәр... Тик менә бүген кайта алмый икән... Ягулык ташучы Тәлгатьне күргән идем. Сөрәсе җире ярты төнгә җитәрлек, ди...— Зәйтүнә киленнең сүзе бетмәгән булган икән әле.— Бүген, әнә, үч иткән кебек, клубта зур концерт. Мөхәсимнең үлепләр яраткан җырчысы Илһам Шакиров килгән...

Әнвәр Бәдриевич, чигәсен кашыштырды:

— Менә нәрсә, Зәйтүнә ханым.— Тиз генә кайтыгыз да әзерләнегез. Тутырган тавыкны алырга онытмагыз!

Председатель тунга сөрүнең соңгы гектарларын төгәлләп килүче Мөхәсим хөрмәтенә идарә каршындагы Дан флагын күтәртте, аннан килеп, колхоз идарәсе, партоешма, комсомол комитеты исеменнән юбилярны туган көне белән тәбрикләп котлау яздырды. Ул арада, бухгалтерия кызлары мәктәп бакчасыннан олы бер кочак дәлия, кашкарый чәчәкләре алып чыктылар. Ярты сәгать тә узмагандыр, безнең «уазик» «Үрнәк» совхозы белән ызандаш басулар ягына элдертә иде инде. Алга, шофер янына, төеннәрен тотып, Зәйтүнә утырды. Уртадагы урында — Әнвәр Бәдриевич, Илһам Шакиров, мин, артта — контейнер кадәрле тартмасын тоткан баянчы егет утыра...

Әшрәф ага, хикәясенә нокта куйган кебек, бермәлгә тынып калды. Аннары тавышына уфтануга тартым төсмер өстәп дәвам итте.

— Тик менә халыкның рәхмәтен яулап өлгергән председателебезне КПСС райкомының беренче секретаре итеп күтәрделәр. Нур балкышы бик еракка күренә.

Әнвәр Бәдриевич председатель булып торган өч-дүрт ел эчендә хуҗалыгыбызның экономик хәле яхшырды, ел да саф табыш ала башладык, рентабельлелек 25,8 процент тәшкил итте. Әнвәр Бәдриевич безне санарга өйрәтте. Халыкта кызыксыну туды...

Шунда мин, күршемнең сүзен бүлеп:

— Әшрәф ага, Ленин орденын кайчан бирделәр сезгә? — дип сорадым.

Палатадашым: «Бу турыда каян беләсең?» дигән сыман гаҗәпләнеп, минем якка күз төшереп алды.

— Әнвәр Бәдриевич киткәч,— дип җавап кайтарды. Шунда ук аңлатма бирергә теләгәндәй өстәде:

— Әмма, миңа орден тапшырган вакытта аны инде нефтьчеләр башкаласы — Әлмәткә эшкә алганнар иде. Хикмәт безнең кайчандыр бергә эшләүдә генә түгел. Безнең хуҗалык берничә ел рәттән, табигатьнең көйсез килүенә дә карамастан, бөртеклеләрдән дә, кузаклылардан да югары уңыш алып, районда беренчелекне тотты.

Әнвәр Бәдриевич бездә председатель булып торган елларда мин күптәнге хыялымны тормышка ашыра алдым: ягъни, кыр-басуларыбызны тулысынча, нәкъ үзем теләгәнчә, фән кушканча, «ремонтладым». Өч басулы чәчү әйләнеше керттем. Табигатьнең нинди генә көйсез килүенә дә карамастан, уңышны программалаштыру мөмкинлеге туды. Культураларны чиратлаштырмасаң, җир уңышны сизелерлек киметә. Шулай итеп мин уннарча елларга сузылырлык эшне, Әнвәр Бәдриевич ярдәмендә, өч ел ярымда тормышка ашыра алдым. Ашламалар җыелмасын һәм микъдарын төгәл керту чарасын да

күрдем. Әнвәр Бәдриевичка килгәндә, сез дә белергә тиеш аны: иптәш Галәветдиновны соңгы вакытта, Казанга алдылар, буй җитмәслек югарылыкка күтәрделәр үзен.

Мин, «Галәветдинов» дигән фамилияне ишетү белән, сүзнең кем турында барганлыгына төшендем.

**6 август.** Ниһаять, Әсгать Сәгыйтовның язмасын укырга да чират җитте. Ничек кенә булмасын, мәкаләнең исеме күңелгә хуш килде — «Тылсымлы түтәлләр». Эчтәлеге турында укучы үзе фикер йөртер.

«Узган елның август аенда агрономнарның районкүләм семинары булып узды,— дип яза Сәгыйтов.— Ул семинар вакытында районның барлык агрономнары белән, Әшрәф ага Әхмәтовның тәҗрибә-сынау участокларын карап йөрү үзе бер онытылмаслык зур вакыйга булып хәтердә калган. Һәркайсы 0,25 гектар гына мәйданга чәчелгән һәрбер яңа сорт үзенчә кызыклы һәм үзенчәлекле иде.

Менә «Руслан» дип аталган солы. Менә СССР Дәүләт премиясе лауреаты илебезнең атаклы селекционеры Э. Донилович тарафыннан чыгарылган «Факел» исемле арпа. Менә «Лютесценс» — көзге бодай...

Районның атаклы агрономы, Ленин орденлы Әшрәф ага Әхмәтов илебезнең күп кенә күренекле селекционерлары, галимнәре белән тыгыз элемтәдә тора, алардан алып кайткан яңа сортларны безнең шартларда сынап карый.

Әшрәф ага соңгы елларда Себер галимнәре белән дә элемтәдә яши. «Зауральская», «Сибирская-3», «Таежник» сортлы арышларга, Әшрәф ага аеруча зур өметләр баглый. Чөнки безнең якларда, корылыктан тыш, җәе яңгырлы, салкын килгән еллар да булгалый.

Кунак агрономнарны һәрнәрсә кызыксындыра. Мәсәлән, «Йолдыз»ның бер башагыннан 64 бөртек арыш чыкты. Әшрәф ага «Йолдыз» турында кыскача гына аңлатма бирде. Бу сорт арышның 1000 бөртеге 56-62 грамм тәшкил итә, ә гадәти арышның 32-36 граммнан артмый. Шуның өстенә әле хромосомалары да гадәти арышныкыннан ике тапкырга артыграк. Яңа сорт булганы өчен генә бернинди дә өстәмә карау оештырмаган Әшрәф ага: «Яшисең килсә, барысына да чыда, үзеңне күрсәт, тормышка путевка ал», дип, җир-биләмәсенә кагылмаган да. Шулай булуга да карамастан «Йолдыз» җылы һәм салкын кышка да, коры һәм яңгырлы җәйгә дә, хәтта көчле җилдавылларга да бирешмәгән. Әлеге көзге арыштан Әшрәф ага беренче ел тәҗрибә уздырганда чәчелгән һәр килограмм орлыктан 60 ар килограмм уңыш җыеп алган. Үрчү коэффициенты 60 булган. Районыбызның атаклы агрономы бу сорт арышны алдагы елларда зур мәйданнарда чәчүне планлаштыруы турында да әйтте.

Кунак агрономнар сорау артыннан сорау бирәләр:

— Әшрәф ага, бу нинди борчак? Ай-яй!..— дип куйды бер кунак, һәркайсында бишәр-алтышар борчак сырланып яткан кузакларны капшаштырып.— Нинди сорт бу?

— «Неосыпающийся-I» бу. Селекционер академик Анатолий Чевченко тарафыннан чыгарылган. Хикмәтле ягы уңышта гына түгел. Кузаклары кибеп ярылсалар да, борчаклары чәчрәп чыгып очмый. Аларның кузакка берекнән «кендекләре» нык... Агрономнар төркемен тагын бер сорт бодай кызыксындырды. Күбесенең кулында дүрткырлы, гадәттән тыш эре бодай башагы.

— Әшрәф агай, монысы нинди бодай?

— Украинадан алып кайткан идем...

— Ә ни өчен участокның бу башында төпләр сирәгрәк?

— Бу турыга кар ятмаган иде. Сорт бездәге суыкларны яратмый икән.

Әшрәф ага көзен бер квадрат метрда ничә төп бодай калуы һәм язын шуның күпме өлеше туңып һәлак булуы турында, конкрет саннар атап, бик җентекләп аңлата башлады. Болары селекционерларга отчет язу өчен дә кирәк икән.

...Бик яратам мин Әшрәф ага белән очрашырга, сөйләшергә, кояшта ян-

ган, жилләр кискән йөзенә карап утырырга яратам. Бөек галимнәр, элек бер башак үстерелгән җирдә ике башак үстерүчегә кешелек мәңге рәхмәт укыр, диләр. РСФСРның атказанган агрономы Әшрәф ага Әхмәтов бөтен гомерен шул изге эшкә багышлаган. Ничек инде аны җир улы димисең!

**7 август**.— Әйттем бит, барыбер кызыксыначаксыз әле, дип...

— Чыннан да, хикмәтле кеше,— дип, миңа Дамир дустым белән килешүдән башка чара калмады.

Дамир белән без, һәркөнне диярлек, шулай иртүк торып, больница аллеяларыннан әйләнәбез, утырып та торгалыйбыз.

— Тикмәгә генә кызыксынмыйсыздыр,— дип башлады Дамир сүзен.— Шунлыктан, Әшрәф ага турында тагын әйтим әле. Кыска тотарга тырышырмын. Нәрсәдән башлыйм икән? Районда иң беренчеләрдән булып үз колхозында туфрак структурасын өйрәнү лабораториясен булдырды. Тагын нәрсә? Ә, әй-йе! Мең төрле каршылыкларны җиңеп, җир катламын әйләндермичә, ягъни сөрү катламын әрлән балчыгына җиткермичә сөрү ысулын районда ул беренче булып гамәлгә ашырды. Бу чара, белгәнегезчә, туфракта дым туплый, чүп үләннәренә каршы көрәшне җиңеләйтә, җирне эрозиядән саклый. Тагын без моңарчы бу якларда күрмәгән-ишетелмәгән бер яңалыкны куллана башлады. Орлыкларны вибрация юлы белән эшкәртә, Әшрәф аганың үз сүзләре белән әйтсәк, орлыкларга «массаж» ясый. Беренче карашка, аллә ни хикмәтле булып күренмәгән шушы алымны кулланганда, орлыктагы вегетация сроклары кыскара, ферментлар хәрәкәте, үсемлек организмындагы биохимик процесслар, атна-ун көнгә иртәрәк җитлегә икән...

Дамир, тагын нәрсә өстим икән инде дигән сыман, чигәсен кашыштырып алды.

— Ә, әй-йе!..— диде ул бик әһәмиятле нәрсәне исенә төшергәндәй.— Быел язын, чәчү алдыннан, тагын бер бик хикмәтле яңалык белән район белгечләрен шаккатырды. Хәзер районда чәчү орлыкларын лазер нурлары белән эшкәртә башладылар. Моның өчен «Львов-I» маркалы агрегат кулланыла. Әшрәф ага шундый агрегат барлыгын белгән дә, үзе үк артыннан йөрергә тотынган. Заводка барды, заказ бирде һәм кайтартты. Чәчү алдыннан орлыкларны лазер нурлары белән эшкәртү тишелешне яхшырта, шытымнарның үсешен, җитлегүен тизләтә, төрле авыруларны кисәтә, уңышны арттыра.

Дамир шундук колакларымны үрә торгызырлык сүз ычкындырып куйды: илебезнең даны дөньяга билгеле булган селекция һәм орлыкчылык институтына Әшрәф ага Әхмәтовны агрономия бүлегенә практик эшкә чакырган булганнар. Чакыру кәгазенә ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм Дәүләт премиясе лауреаты кул куйган булган.

— Әлеге хатны үз күзләрем белән күрмәгән булсам, бәлки ышанмаган да булыр идем,— диде Дамир.

Мин ирексездән түрә Мортазинның Әшрәф ага турында әйткән сүзләрен исемә төшердем. Бүгенле-кичәле үзе дә күренмәгәч, Дамирдан белешергә булдым.

Дамирның ниндидер мәзәкле сүз сөйләргә җыенуы йөзенә бәреп чыкты, ирен кырыйлары белән генә елмаеп та куйды хәтта.

— «Сакаллы анекдот» дигән сүзне бик еш ишетәсездер, мөгаен. Бездә «аяклы анекдот» дигән сүз дә йөри. Мортазинны шулай атыйлар. Ул гомере бакый эш урыны алыштырды. Үзе — гел җитәкче. Бездә бит шундыйрак гадәт: бер орбитага чыккан кешене, номенклатурный работник, дигән булып кулыннан бернинди эш килмәсә дә, чыгарып ату юк. Мортазинны да «Межколхозстрой» идарәсенә хуҗа итеп куйдылар. Бу эшне җайга салып җибәрә алмасмы, янәсе. Юк, булдыра алмады. Яше дә бар, гәүдә дә авыр. Күпмедер вакыт үткәч, райкомга чакырып алалар да моны бик нык пешеклиләр. Мортазин да бурычлы булып калмый, шул ук кичне производство киңәшмәсе билгели. Ул да прорабларын, бригадирларын кыздыра. Телгә яман, аты-юлы белән җибәрергә дә тартынмый. Беренче кул астына эләккән прорабның йомшак ягы — аз-маз салгалау. Әй-й, элеп ала хуҗа кеше тегене, иптәшләре

күзенә күренерлегән калдырмый. Чират икенче бер бригадирга җитә. Ул — хатын аерган кеше. «Хатын-кыз юбкасы күрсәң, дөньяларыңны онытасың...» фәлән дә төгән дип, тегене дә элеп алып селкеп сала. Ниһаять, чират үзенең улына җитә. Илгиз дә этисе кул астында эшли. Бригадир. Улына карата да сүз эзләп, кесә капшап тормый ата кеше: Ә син малай актыгы, өйгә генә кайт, мин синең анаңны... дип, аты-юлы белән сүгә тегене. Халык та усал, шунда бер авызына шайтан төкергәне: «У-у, җәзаның иң катысы Илгизгә эләгә икән...» дип әйтеп куймасынмы! Тәгәрәшеп, урыннарыннан егылышып төшкәнче көлешкәннәр. Дөнья шаулатып көлүчеләргә Мортазин үзе дә кушылган, ди...

Иртәнге процедуралар башланыр алдыннан корпуска кайттык. Мин палатага кергәнче үк, Әшрәф аганың ялгыз түгеллеген абайлап алдым, хатыны килгән. Ябылып бетмәгән ишектән кабаланып сөйләнүе ишетелеп тора иде.

— Менә, тагын күчтәнәч... Партком секретаре хатыны Кырымнан кайткан...

Мин дә кердем. Исәнләштем. Апа кешенең рөхсәтсез генә кергәне әллә каян сизелеп тора. Кабалана, каушый:

— Ай-й, ходаем!.. Онытып торам икән... Хат бар үзеңә.

Конвертның өске ягында кызыл грифы булуын абайлап алдым. Димәк, рәсми хат.

Әшрәф ага хатны саклык белән генә ачты:

— Себердән...— диде. Бу сүзләрне әйткәндә күзләрендә тирән хәсрәт чагылып киткән кебек булды.— Их-х, шушында керүләрем!.. Менә нәрсә, бакча түрендәге арпаны урып көлтәгә бәйлә. Иң әүвәл, урта бер җиреннән ун башакны уып, орлыкларын җыеп куй. Башакларны сайлап түгел, учма итеп ал...

— Беләм, беләм, этисе... Берег че кат түгел бит.

— Җавабын соңрак, чыккач үзем язармын.

— Ярар, этисе... мин китим инде. Биш кенә минутка керткәннәр иде.

— Сабыр ит! Рәфисне күрдеңме? Нәрсә диде? Ник килми?

— Хәзер килеп җитәр. Матаена атланып Урман буе басуына, дип, атап, чыгып киткән иде.

— Ә хәзер бар,— диде Әшрәф ага катгый-кырыс тавыш белән. Сизелеп тора: бу аның ачулануы да, ризасызлык белдерүе дә түгел, сөйләшү рәвеше шулай аның.— Син, әнисе, болай көн дә газапланып йөрмәсәң иде! Якын ара түгел ич...

— Син, этисе, юк белән хафаланма. Хәзерге юлда машина өзелә димени. Ярар, этисе, тизрәк савыга күр, берүк... Китим, алайса...

Хатын артыннан ишек ябылды. Тынлык урнашты.

— Ярдәмчегез дә икән әле...— дидем мин әлеге тынлыкка чик куярга теләп.

— Ансыз булмый, күрше. Гомерен олуг эшкә багышлаган кешегә хатынның иманлысы кирәк...

— Иманлы хатын беркемнән дә артмый торгандыр ул? — дим.

— Ялгышасың, күрше. Мин — әүлиядәй хатыннарын ташлаган җилкуарларны күргән кеше. Максат-хыялсыз яшәүчеләр алар...— Шунда Әшрәф ага көрсенгән бер тавыш белән дәвам итте.— Әх-х, гамәлгә ашырасы фәрманнар күп иде әле, күрше. Бик күп иде. Ә гомер кыска... Аһ-һ, гомернең кыскалыгы!

Сүзебезне иртәнге обход бүлде. Сылу-Миңсылуның биек үкчәле түфлиләре белән идәннәрне шакы-шокы китереп, җил-җил атлавыннан ук таныдык. Ул кергәч, палатабыз яктырып киткәндәй булды. Режимны саклавыбызны хуплады, хәтта мактап та куйгандай итте.

Врач авыруны дару белән генә түгел, тәмле сүзе, якты йөзе белән дә дәвалый, дип белмичә әйтмәгәннәрдер шул. Икебезнең дә күңелләр күтәрелеп китте. Мин дә канатланып, берниндн хәзерлексез-нисез берничә сорау биреп ташлаганымны сизмичә дә калганмын.

— Әшрәф ага, заман кешесен сез ничегрәк аңлыйсыз?

— Бик гадәти итеп: иртәгәге көн турында уйлаучы, алга таба карый белүче кеше итеп аңлыйм.

— Тагын бер сорау: сезне ниндидер гыйльми институтка эшкә чакырган булганнар, хакмы?

— Хак. Булды андый хәл. Әмма мин беркая да китмәдем. Туган туфрагымны ташлап ник китим, ди.

— Ләкин бит сезгә шактый җәберләр күрергә туры килгән?..

— Ничек кенә булмасын, мин һәрчак үземнең хаклы икәнлегемне белеп яшәдем. Шул миңа ихтыяр көче дә, яшәү дәрте дә бирде...

— Сезне бит хәтта судка да тарттырганнар?..

Күршем капылт кына җавап кайтарырга ашыкмады, күз карашларын түшәмгә төбәп ята бирде.

— Әйе, андый хәл дә булган иде,— диде ул ахыр чиктә.— Күптән инде. Яңа сортлы орлыкларга бәйле вакыйга иде ул.— Күршемнең уйлар агышы бөялеп калган сыман булды. Әмма озакка түгел. Украинаның Немчиновка орлыкчылык тәҗрибә станциясендә эшләүче, үзенең каты бодайлары белән дан казанган академик Анатолий Гончаренко янына барган идем... Мин приемга эләккәнче үк, минем нинди йомыш белән килүемне аңа җиткергән булганнар инде. Кабул итте бу мине.

Ахыр чиктә Әшрәф агага, кайсыдыр орлыкчылык-тәҗрибә станциясе өчен әзерләп куелган фондтан 50 килограмм «Элита-5» сортлы бодай биреп җибәрәләр. Ул аны алып кайтып чәчә. Әлеге сорт сабагы тәбәнәк, нык булуы, сөрлегүләргә, төрле авыруларга бирешмәве, уңышны да, ул елларда перспектив саналган бодайларга караганда, 7-8 центнер артыграк бирүе белән аерылып тора. «Менә кайда булган икән безнең иксез-чиксез басуларыбызны биләячәк яңа сорт бодай!»— дип, Әшрәф ага куанып бетә алмый. Әмма бу юлы да иртәрәк шатланган булып чыга.

— Элегрәк районнан вәкил җибәреп теңкәгә тия торганнар иде,— дип дәвам итте Әшрәф ага.— Хәзер шул вакытларны уйлыйм да, хәйранга калам: Украинадан алып кайткан каты бодайны һәйбәтләп чәчтем, тәрбияләп үстердем. Һәр бөртеген алтын бәрабәренә тиңләп аерым комбайн белән суктырып алдым. Аерым көшелгә салып җилгәрдем, калибрлап капчыкларга тутырып җыеп та куйдым. Киләсе елга бөтен республиканы шаккатырырга исәп. Төп-төгәл 21 капчык чәчү орлыгын кеше күзеннән ераккарак — әчке келәтләрнең берсенә яшердем, барлык ашлыкны кырып-себереп озатуны максат итеп куйган вәкилләрдән саклап калам, янәсе. Илдә — илле, берсеннән берсе җилле дигәндәй, кайсы мөртәтедер, тәки вәкилгә чишкән бит моны. Теге, өермә кебек, килеп тә җитә, хәзер үк келәтне ач, дип, завхозны җилтерәтә дә башлый. Завхоз: ачкыч — агрономда, дип, котылырга чамалый. Бәхетенә каршы, төн җитә. Завхоз хәлне аңлатып миңа хәбәр сала. Мин тиз генә ике ат җиктерәм дә, төн караңгылыгыннан файдаланып, бодайны үзебезнең ишегалдындагы таш келәткә кайтарып шартлатып бикләп тә куям. Уполномоченныйга безнең төнге «кыек эшебезне» дә чишәләр. Аңар нәрсә, районга, милиция идарәсенә шалтырата. Мин, документларны җыеп, райкомга барып, әлеге гадәти булмаган чәчү орлыкларын колхозда калдыруларын сорап язган гаризаларга куллар куйдырганчы, вәкил белән милиция кешесе, пүнәтәйләр яллыйлар да, келәт ишеген ваттырып 15 центнерга якын бәһасез орлыкны озатып та җибәрәләр. Минем өстән беркетмә төзеп, эшне прокуратурага тапшыралар...

Шул вакыт, Әшрәф аганың түземсезлек белән көткән кешесе — яшь коллегасы — Рәфис килеп керде. Озын буй. Чем-кара чәч, шундый ук кара каш. Калын кысалы күзлек. Җитди.

— Ниһаять!..— дип кычкырып җибәрде күршем, хәтта, сикереп торырга җыенган сыман, кулларын болгаштырып куйды.— Син нәрсә шул тиклем озак көттердең?

Егет, Әшрәф ага караваты янындагы урындыкка килеп утырды. Планшетка охшаш сумкасыннан кәгазьгә төрелгән башакларын чыгара башлады.

Ә Әшрәф ага, кулына чиксез хәзинә кергән сыман сөенеп, сорау артыннан сорау бирә: «Мин әйткәнчә иттеңме?.. Басуның төрле урыннарыннан алдыңмы? Язганда бутамадыңмы?»

Әшрәф ага кәгазь төргәкләрнең берсен ачты. Менә, ул түземсезлек белән көткән алтын башакларның берсе — аның кулында.

— Вәт, булдыргансың!.. Әһә-ә, монысы, урман буеннан... Ә бусы — үзәнлектән...

Әшрәф ага шулай сөйләнгәләп дүрт кырлы бер карыш озынлыктагы юан башактан, саклык белән генә сыңар бер бөртеген чокып алды, теш арасына кыстырды.

— Һе-е, була язган бит бу! Күр инде, ә... Әгәр дә, орлыкка дип атап чәчелмәгән булса, моны инде бер-ике көннән теземнәргә сала башларга да ярар иде. Бу уңышның тулысынча орлыкка калдырылуын, янә дә килеп, турыдан-туры урдырачагыбызны исәпкә алсак, тагын, ким дигәндә, 5-6 көн тамырда калдырырга кирәк...

Әшрәф аганың йөзе ачылып, битләренә сәламәт алсулык иңгән сыман булды:

— Ну-у, егетем!.. Әлеге басудагы игеннәрне чәчми-түкми җыеп алу, һәйбәтләп сакларга салу, тулысынча синең карамакка тапшырыла. Кайчан керешергә икәнлеген, көнен-сәгатен әйтеп, үзем команда бирермен. Орлык тәмам җитлеккәч, тәмам тулгач кына, эшкә керешәчәкбез. Бары тик өлгергән орлык кына көткән уңышны бирә.— Ул, бераз уйланып торгач, өстәде: — Комбайн молотилкасы аша уздырган орлык, чабагач белән сугып алынганга караганда, сирәгрәк шыта. Чөнки молотилкадан узганда орлыклар яралана-лар, күзгә күренми торган җәрәхәт алалар. Комбайнның суктыру аппаратын бик төгәл көйләргә, барабан әйләнешен бермә-бер диярлек киметергә туры киләчәк. Бу эштә сиңа, үскәнем Рәфис, Мөхәсим абыең ярдәм итәр. Аның белән киңәш!

Яшь белгечнең йөзе күзгә күренеп төссезләнде:

— И-и, тыңлатып буламы соң аларны!..— диде егет.

Әшрәф ага тыныч, канәгатьсезлеген сиздерми.

— Син аңлата белергә тиеш.

Шунда, яшь агроном, саксызлык белән бер сүз ычкындырды:

— Әгәр дә председатель: ура башлагыз! дип, приказ бирсә?..

Әшрәф аганың ризасызлыгы шундук йөзенә чыкты.

— Нәр-сә-ә?..— дип сорап куйды ул, гадәттән тыш сүз пшеткән сыман.— Нинди приказ ди ул?! Ни сөйләгәнеңне колагың ишетәме синең, тупсасыз авыз! Син бит агроном: үзең командир, үзең җир хуҗасы. Халык сиңа бүгенге көнен генә түгел, киләчәген дә ышанып тапшырган. Агрономның беренче бурычы — җиргә карата һәрчак гадел булу. Кабатлап әйтәм, агроном — җир хуҗасы, аның өчен берниндн приказ да, әмер-боерык та булмаска тиеш. Синең өчен иң олуг авторитет — җир үзе...

Өлкән игенче шәкертенә кисәтеп куйды:

— Икенчеләй ишетмим бу сүзләреңне!

Әшрәф ага тынып калды. Сулышын тигезләде. Бары тик шуннан соң гына караваты кырыена утырган егетнең тәртәдәй озын, арык тезләренә кулын салып, болай диде:

— Мөстәкыйль бул, Рәфис үскәнем. Кеше болай куша, тегеләй әйтә дип, уңга да, сулга да чабуламаска тырыш. Үз фикереңне яклый бел.— Әшрәф ага сүлпән генә елмайды.— Һәрнәрсәдә теләк кирәк, Рәфис үскәнем, теләк! Ният — ярты гамәл, дигән борынгылар. Халык безне кулларыбыз сәялле булган өчен генә түгел, киләчәккә карап яшәвебез өчен хөрмәт итә. Дөрес, сайлаган һөнәребез ифрат та катлаулы, эшебез чамадан тыш авыр. Җан аямый эшләгәндә дә таманга килә. Әйдә, була бирсен! Минем мәрхүм әтием: эштән ару — тәнгә дару, дияргә ярата иде.

Тагын бераз утырганнан соң Рәфис китеп барды. Палатада урнашкан сәер тынлыкны мин боздым.

— Кирәгеннән артык тыйнак,— дидем мин Рәфис турында.

— Тыйнаклыкның артыгы булмый.

Сүз югында сүз булсын дигән сыман, остазлык турында әңгәмә корып җибәрдек. Монда да Әшрәф аганың үз фикере бар иде.

— Белгәнеңә, һөнәреңә серләренә өйрәтү, тупланган тәҗрибәңне уртаклашу да җиңел эш түгел. Әмма иң авыры — чын мәгънәсендә кеше була белергә өйрәтү. Югыйсә соңгы елларда исәннәргә ихтирам, киткәннәрне хәтерләү бетеп бара. Намус, әхлак, кешелеклелек кебек сыйфатлар дефицитка әйләнә кебек...

Нәкъ шул вакытта яңадан палатабыз ишеге ачылып китте. Аннан түгәрәк гәүдәле, ялтылаш пеләшләнергә өлгергән йомры башлы бер кеше килеп керде. Әлеге кешенең үзен кирәгеннән артык иркен тотуыннан, бик тә кыю атлап керүләреннән, Әшрәф ага белән күрешү-исәнләшү рәвешеннән дә, гадәти хәл белергә генә килүче түгеллегенә төшенү әллә ни кыен түгел иде.

— Исәнлектәме, Әшрәф агай! Кәеф-шәрифләрең ничек?

— Бер көйгә генә иде әле хәзергә...

Ялгышмаганмын, беренче сүзләрдән үк төшендем, колхоз председателе икән.

— Килеп чыгып һәйбәт иттең әле,— дип башлады Әшрәф ага сүзен.— Эшләр ничегрәк бара соң? Андый-мондый ЧП яки тоткарлыклар юкмы? Вакыты шундый бит...

Председатель тагын киң итеп елмайды.

— Шулай юк-бар белән кыбырсып ятасыңдыр, дип уйлаган идем аны, хак икән. Әнә, доктор Сафина нәрсә ди: бернинди борчылу ярамый, ди. Колхозда бар да һәйбәт. Үзең беләсең бит: быел да без уракка бөтен район өчен үрнәк-өлге булырлык итеп әзерләндек.— Председатель (Идият Фәтхуллович Миңлебаев) Әшрәф агага авыз да ачарга ирек бирмичә, көйләп-вәзенләп сайравын белде.— Урак ипатовлылар ысулы белән алып барыла. Коллектив подряд белән эшли торган урып-җыю — транспорт комплексы төзедек...

— Чак кына сабыр ит әле... Мине дә тыңла,— диде Әшрәф ага, тәмам гаҗизләнгән кыяфәт белән.— Әйткәннәрең бар да һәйбәт. Әмма хәзер төп игътибарны комбайннарның ашлык суктыру аппаратларын дөрес көйләүгә бирә күрегез. Иң йомшак урыныбыз шул безнең. Бер культурадан икенче культурага күчкәндә генә түгел, бер басудан икенчесенә күчкәндә дә, комбайннарны яңадан көйләү мәҗбүри булырга тиеш...

— Барысы да уйланылган, планлаштырылган, Әшрәф агай...

— Тагын бер үтенечем бар,— диде күршем үтә дә борчылган бер кыяфәттә.— Урман буе басуындагы арышка, сынау-тәҗрибә участогына минем рөхсәтемнән башка кагыласы булмагыз!

— Без инде арышны төгәлләп килә идек...

— Барыбер. Ул участоктагы игеннәрнең тагын биш-алты көн бик рәхәтләнеп тамырда утырырлыгы бар. Ул арышның хәзер көн саен гектарына ике, ике ярым центнерга көчен арттыра торган чагы...

— Әшрәф ага, урып-җыюны соңарту да югалтуга китерә бит...

— Кайда күпме югалуы турында мин сиңа үзем лекция укый алам... Узган елны гына хәтереңә төшер! Игеннәрне, тамырда җитлектереп тапшыру нәтиҗәсендә күпме өстәмә табыш алдык?! Бодайның җилемлелеге югары булган өчен 35-50 процент күләмендә өстәмә түләделәр.

— Барысы да хәтеремдә, Әшрәф агай,— диде председатель, ясалма бер ягымлылык белән.— Бар да син дигәнчә булыр. Кайчан синең сүздән чыканыбыз бар? Син барыннан да элек, тизрәк савыгу турында уйла. Синең саулыгың кирәк безгә. Үзеңне, әнә, Кырымга путевка көтә. Хәдичә апаны култык астыңа кыстырырсың да, әл-лю-юр — җылы якка!..

Идият Фәтхулловичның кечелекле, яхшы атлы булып күренергә тырышуы сизелеп тора иде. Бу хәл күршемдә генә түгел, миндә дә шактый ук кире тәэсир калдырды.

Ниһаять, председатель китеп барды. Бермәлгә тынып калган Әшрәф ага телгә килде. Җәберсенгән бер кыяфәт белән, үч-ярсуын тыя алмаган кеше сыман итеп:

— Һай-й, акыллы баш булып кыланулары!..— дип куйды.

Мин, Әшрәф аганы әлеге күңелсез уйларыннан арындырырга теләп, иң зур яңалык — коллектив подряд турында гәп саткандай иттем. Күршем кирелек, үзсүзлелек белән җавап кайтарды:

— Һәрбер яңалык — онытылган яхшы искелек ул. Без ул алымны моннан ун-унбиш еллар элек үк сынап караган идек инде,— дип, аңлата башлады ул. Безнең экономиканың төп дошманы — хуҗасызлык. Без дә һәр басуның үз хуҗасы, җаваплы кешесе булырга тиеш, дигән принциптан чыгып эш иттек. Берәве сөреп, икенчесе чәчеп, өченчесе төп эшне — урып-җыюны башкарса, дүртенче берәве өстән боерык-әмер биреп торса, бишенчесе: давай-давай! дип таләп итсә, эш чыкмаячак дип, хуҗалык исәбе ясап, коллектив подряд ысулын кертkән идек. Басу хуҗасы булырдай звено да төзедек. Җитәкче итеп эш өчен җанын фида кылырга әзер Мөхәсимне билгеләдек. Төп бәя — АХЫРГЫ НӘТИҖӘ. Исәп-хисап — уңыш башыннан. Артык җитештерелгән продукция өчен аккордлы-премияле түләү буласын төшендердек.

Биш кешедән торган звенога кеше башыннан 300 гектар, җир, биш трактор, биш комбайн, кирәк кадәрле тагылма җайланмалар бүлеп бирелде. Звено кешеләре җиргә ябышып яттылар. Элегрәк әйтеп-әйтеп тә кермәгән нәрсәләрне үзләре күреп, үзләре белеп эшли башладылар. Алар басуларында эрем, тигәнәк ише чүп үләннәре түгел, кыргый тары, кыр кыягы кебек үләннәрнең дә эзе калмады. Моңарчы беркемгә дә «кирәк булмаган» тирес өемнәре звено басуларына күчте, җирне ермап-тырмап үтүләр бетте. Чөнки механизатор үзенә тапшырылган участокта эш башкаручы гына түгел, хуҗа да, төп җаваплы фигура да... Беренче елда ук, уңыш, гомум хуҗалыкныкына караганда, һәр гектардан 3-4 центнерга артыграк чыкты, җитештерелгән бер центнер икмәкнең үзкыйммәте дә, колхозныкына караганда, 32 процентка кимрәк булды. Звено членнарының хезмәт хакы башка механизаторларныкына караганда икеләтә диярлек артык чыкты.

Әшрәф ага, хәле беткән сыман, бермәлгә тынып торды.

— Шул, акча дип, эшләмичә күбрәк умыру ягын караучылар, харап иттеләр дә инде әлеге матур башлангычны. Бернинди хәзерлексез, әпен-төпен китереп, тагын берничә звено төзеп ташладылар. Башта — җир, аннары хезмәт хакын бүлешә алмыйча пыран-заран килделәр. Низаг прокуратурага кадәр барып җитте. Председателебез дә үз күләгәсеннән үзе курка торган бәндә. Өстән: «Сез нәрсә анда мөгез чыгарып маташасыз? Колхозны таратып яңадан аерым хуҗалыкка кайтыргамы әллә исәбегез?!» — дип бер генә җикеренеп шалтыраттылар. Председательгә җитә калды.

Әшрәф ага ул чактагы колхоз председателе турында тагын өстәде:

— Кирәгеннән артык сак кеше — хәтәр кеше. Күпме сынаганым бар: вак җанлы кеше һәрчак куркак. Берәр хәл чыга күрмәсен дип, җан калтыраган кешедән берни дә чыкмый. Мин моны гомерем буе сынадым,— диде.

**8 август.** Кичен, утларны сүндердек тә, бер-беребезгә тыныч йокы, тәмле төшләр теләп, йокларга яттык. Шулчак якында гына, авыр туптан атканга охшаш аваз чыгарып, күк күкрәде. Бер генә тапкыр дөберде ул. Тәрәзәне яшькелт яктылыкка манчып, яшен яшьнәде. Шуны гына көтеп торган кебек, тәрәзәгә орынып ук үсеп утырган сәрви агачларының вак яфракларына шыбырдашып беренче яңгыр тамчылары төшә башлады. Аннары инде озак көттермәде, больницаны урап алган бакча тоташ шауга күмелде.

Әшрәф ага ягына колак салам. Ансыз да дүрт стенага җаны сыеша алмыйча яткан агроном кеше бу минутларда ниләр кичерә икән? Юк, тыштагы тоташ шаулаудан башка, ул-бу ишетелми.

Күңелдә туган шундый болгавыр уйлар белән мавыгып, йокыга киткәнемне сизми дә калганмын. Уянып күзләремне ачсам, хәйран булдым, иртә чалт аяз, бөтен палата алсу, җиңел яктылык белән тулган. Мин мыштым гына тордым да, аяк очларыма гына басып, коридорга чыктым. Тышкы ишеккә юнәлдем. Дөньяны кинәндереп явып узган яңгыр хикмәтедер инде, бөтен

җир өстен дымлы томан чорнап алган. Ә һавасы, тел белән әйтеп аңлатырлык түгел, шундый да саф, күкрәкләргә үзе бәреп керә.

Баскычтан төшеп тынычрак аллеяга борылдым. Ком сибелгән юл өстендә яшел, сары, кызгылт-сары өрәңге, каен яфраклары, төсле паркетны хәтерләтеп, түшәлеп яталар. Агачлар яртылаш диярлек шәрәләнгән иде. Тирә-як киңәебрәк, ачылыбрак киткән сыман. Тавышлар да ачыграк ишетелә. Бу инде — көз билгеләре.

Күпмедер йөргәннән соң палатама керсәм, хәйранга калдырырлык күренеш — Әшрәф ага, миндәрен караваг башына ук күтәргән дә шуңа терәлеп утырып тора. Йөзенә сәламәт алсулык йөгергән. Күзләре тулы нур. Бу нур күршемнең йөзен искиткеч мөлаем итә.

— Хәерле иртә, Әшрәф ага!

— Хәерле иртә, күрше... Иртәләгәнсең.

— Көне искитмәле бит, Әшрәф ага!..— дидем мин, аның ачылып киткән йөзеннән күзләремне алмыйча.— Төнге яңгыр кәефегезне боздымы әллә дигән идем. Юк икән...

Әшрәф ага бөтен йөзе белән нурланып елмаеп куйды.

— Нишләп бозсын, ди. Язгы яңгырның артыгы булмаган кебек, көзге булса да, бу кыска вакытлы явым-төшемнең зыяны юк. Бик тиз җилли ул. Аннары бәрәңге турында да онытмаска кирәк. Аның атна үсәсен көн үсә торган чагы хәзер.— Әшрәф ага кинәт җитдиләнеп калды, йөзеннән күләгә йөгереп үткән сыман булды.— Тик менә... авылдагыларны гына бу җилле яңгыр өркетә күрмәсен иде инде. Әнә, нәрсә дип тора бит: арыш уруны төгәлләп киләбез, янәсе...

— Алай итмәсләр,— дидем мин, аны тынычландырырга теләп.— Әшрәф ага, һаман да шул Урман буе басуын телегездән төшермисез, хикмәте нәрсәдә соң анда чәчкән арышның?

— Башка сортларга караганда «Йолдыз-1» сорты аксымга бай, сөрлекми, сабагы озын, саламы да күп чыга. Заман салам саттыра, кар астыннан таптыра, ди. Салам кытлыгы кичерүләр дә баштан үткән нәрсә. Аннары көзен үк яшел массаны мул бирә, терлекләр өчен менә дигән азык. Әшрәф аганың күзләрендә нур уйный, бите-чырае карап туймаслык мөлаем иде.

— Әле яңарак кына һушларны алырлык матур, могҗизалы төш күреп уяндым...— дип башлады Әшрәф ага, оялган сыман итеп.— Хәерлегә генә була күрсен, берүк... Җир өстендә җәй бәйрәм иткән чак, имештер. Билдән тиң дымлы, салкынча томанны ерып һаман алга таба атлыйм... Якягымда — иге-чиге күренмәгән иген басулары җәйрәп ята. Кайсыдыр яклары белән Урман буе басуларын да хәтерләтә кебек... Мин барган юл өстендә, җиргә елышып ук диярлек, тирбәлә-тирбәлә тургайлар оча. Яңа буын кошчыклары шулай өерләре белән оча. Мин якынлашкан саен, я куаклык арасына, я дулкын булып йөгерешкән игеннәр арасына кереп чумып юк булалар, имештер... Ә үзем, әлеге игеннәрнең бер бөртеген дә югалтмый, бәрәкәтләп, кадерләп җыеп алып булырмы икән, дип, борчылам, хафаланам, имештер...

Мин дә үз чиратымда сүз кыстырып куярга булдым.

— «Төшләргә кереп йөдәтә», дисез инде, алайса?

— Хаклысың, энекәш. Һөнәр — язмышка тиң нәрсә ул. Бигрәк тә безнең һөнәрне яратмау мөмкин түгел. Мин — агроном, дип уйлау гына да юаныч бирә. Безнең эшнең берни белән дә чагыштыргысыз ягы бар: ул һичкайчан да туйдырмас. Чөнки тоташтан үзгәреш. Син басуларга гына игътибар ит: нәкъ төсле кинокадрлар кебек алышынып, үзгәреп кенә тора. Бер караганда, пар бөркегән кара җир, тирә-юньдә җаннарны айкап ала торган яңа гына сөреп ташланган җир исе. Дөнья яз ямена күмелгән. Кая күз салма, могҗизалы хозурлык. Язгы чәчү чоры. Икенче караганда инде, басуларның танырлыгы калмаган — ямь-яшел хәтфә. Аннары инде үзгәрү-төрләнүләргә күз иярми башлый. Карыйсың, арыш баш тутыра, борчак чәчәк

ата, бодай, арпа буынга сикерә. Икенче килгәндә, янә дә үзгәреш, сине диңгез сыман җәйрәп яткан иксез-чиксез киңлекләр өстеннән йөгерешкән яшел дулкыннар каршылый. Әлеге дулкыннар да бер төсле генә түгел, көненә ун төрлегә әверелә: иртән зәңгәр-яшькелт төстә, көндезен бөтенләй үзгә, көн эңгергә авыша башладымы — янә хәйран тамаша.

Игенченең мәшәкатьләре дә иксез-чиксез. Ашлыклар күкрәп уңса, еллар имин-аман килсә, игенченең күңеле көр, йөрәге дәртле. Әмма аңар карап күңел дигән нәрсә барыбер тынгылык белми, башыңда мең төрле уй: кинәт кенә корыга китеп, җитлегеп килгән игеннәрне дымга тилмертмәсме? Ә инде төннәрен җил-давыл чыгып, тәрәзә пыялаларына эрерәк тамчылар бәрдеме, янә йоклармын димә, боз-фәлән түгелме? дип, өннәрең алынып, атылып тышка чыгасың...

Ниһаять, урак өсте җитә. Олы һөҗүмгә әзерләнәләрмени, тирә-юньдә мең төрле машиналар гөрелтесе. Ул көннәрдә күңел түренә иң матур җыр булып иңә әлеге авазлар... Комбайннар артыннан күпереп биек тезмәләр кала, ындыр табакларында — тау-тау алтын көшелләр...

Шулай керфек какмый үткән төннәрне, тынгысыз көннәрне, күкрәк көчен, маңгай тирен, таң чыгын, кояш нурын, туган туфрак җылысын, өметхыялларны, барысын-барысын бергә берләштергәнгә күрә дә бөектер ул икмәк. Икмәк! Никадәр өметләрне, бәхетләрне, шатлыкларны үзенә сыйдыра ала бу гап-гади, шул ук вакытта олуг, хозур, изге сүз. Җир йөзендә аңа тиң, аның белән бер дәрәҗәгә куелырлык бүтән бер нәрсәне дә билмим мин...

Әшрәф ага, учына йомарлап сыңар башак тоткан. Миңа ул аны, саклык белән генә, икенче кулына күчерде. Йөзенә якынайта төшеп, моңарчы беркайчан да күрергә туры килмәгән яңалык табарга теләгәндәй, бик тә җентекләп караштыра башлады. Бары тик шуннан соң гына башакның буен, авырлыгын үлчәргә теләгәндәй итеп, җир, тузан, машина мае сеңгән, көрәктәй зур, сөялле учына аркылы салды. Шулчак күршемнең иреннәрен бәхетле елмаю чаткылары ялмап алды:

— Менә ул чын могҗиза!..— диде ул йөрәк түреннән чыккан бер ягымлылык белән.— Табигатьнең шушы могҗизалы бүләгенә карап, гомерем буе сокланып, хәйран булып туя алганым юк. Җәүһәрләрең бер кырыйда торсын!— Күршемнең күзләре әлеге башакта.— Аңа еш кына: «Алтын башак» диләр. Сүз дә юк, башакны саф алтыннан да ясап буладыр, әмма кая ул алтыннан ясалган башакка бу серле могҗизага тиңләшү?! Бу бит тере... Күр син аны! Ә исе... Орлыкларына игътибар ит син аның, ничек тигез тезелешеп урнашканнар. Бер, ике, өч... Ю-ук, икмәкнең серләрен бернинди компьютерлар да исәпләп бетерә алмаячак! Мәсәлән, игенченең аңа карата булган хис-тойгыларын нинди машина аңласын ди. Арышның үзенә генә хас серләре дә бар. Менә, әйтик, башка культуралар үз эчендә серкәләнәләр. Арыш исә үз мәхәббәтен җил иркенә тапшыра: орлыклардан орлык тусын өчен чәчәкләрнең чәчәк белән кавышуы шарт. Әгәр серкә очырган мәле тымызык, җилсез көннәргә, яки киресенчә, утырып яңгыр койган вакытка туры килсә — бетте, арыш уңышын көтмә. Әмма табигать арышка искиткеч мәле тагын бер сыйфатны да өстәгән: башагы кысыр калмасын өчен ул атнасына өч тапкыр «туй күлмәге» кия, ягъни атна эчендә өч тапкыр серкәләнә. Иң әлек башакның аскы өлеше чәчәк ата. Берничә көннән урта өлеше. Аннары — очы... Арышны «туй» чорында, диңгездәй дулкынланып, серкә очырган мәлдә күрергә тырыш! Андый вакытны халыкта: «Арыш куян куа»,— диләр. Талгын җил уйната, тибрәтә үзләрен, тоташ дулкыннарны куа... Бөтен басу өстендә саргылт-зәңгәрсу рәшә уйный... Шундый чакта башаклар җырына колак сал син: дәртле дә ул, чак кына моңлы-зарлы да...

Уйга талдым: күрче зинһар, менә ничек кадерләп, бөртекләп саналып үстереләсең икән ич син, ипекәй! Ирексездән, олуг шагыйребез Сибгат ага Хәкимнең авылдашлары турында язган мәкаләсендәге: «Юк, җир эше дә — иҗат, рухи иҗат. Җиргә мәхәббәт һәм яратудан туган иҗат. Туфан кебек фанатиклар шигырьдә генә була торгандыр дип йөри идем. Алар җиргә дә кирәк икән», дигән сүзләре искә төште.

Әйе, Әшрәф ага өше кешеләр белән, ил алдында торган теләсә нинди бурычларны да үтәп, кыенлыкларны да җиңеп булачак, дип уйлап куйдым мин. Күршем дә игенчеләре алдына куелган олуг бурычлар турында гәп сата башлады.

— Дөрес, моңарчы да авыл хуҗалыгын кискен күтәрүгә юнәлдерелгән карарлар булмады түгел, булды. Әмма соңгылары күңелгә бик хуш килә. Димәк, партия һәм хөкүмәтебезнең шулай зурдан кубарга мөмкинлеге дә, ышанычы да бар,— дип куйды Әшрәф ага үзенә бер төрле инанган тавыш белән.— Әй-йе, бар! Безгә, игенчеләргә ышана партия. Моны тоеп тору безгә куәт бирә.

Күршем тынып калды. Карасам, бит-чырае җитдиләнде моның:

— Их-х, күрше!— дип көрсенеп куйды ул кинәт.— Әйтеп торасы да юк, тормыш күзгә күренеп ямьләнә бара. Дөньялар гына тыныч-имин була күрсен! Атом-төш коралларының кайберләре, әгәр дә хак булса, җирне ике метр тирәнлеккә кадәр, мәңгегә үсемлек яралмаслык итеп «үтерәчәк», ди. Ә бит җирнең уңдырышлы өлеше метрлар белән түгел, нибары сантиметрлар белән генә исәпләнә. Бу бит — кендегең белән береккән җир-анаңа кизәнү дигән сүз. Моннан да яман вәхшилекнең булуы мөмкинме!..

Шунда, шприцлар салынган ялтыравыклы савытларын тотып, Әшрәф агага уколлар ясый торган медсестра килеп керде. Мине дә процедура кабинетында көтеп торуларын әйтте.

— Ярар, Әшрәф ага,— дидем мин, чыгып китәргә җыенып.

— Барыгыз, бар, күрше,— дип калды ул.

Әшрәф аганы соңгы тапкыр күрүем, соңгы мәртәбә тавышын ишетүем шушы булыр дип, кем уйлаган!..

Процедура кабинетыннан ашханәгә кердем. Дамирны очраттым. Сүз белән мавыгып, бакчага ук чыгып киткәнбез. Күпмедер вакыт узгач, больница персоналларының тыз-быз килеп, ут капкандай йөгерешеп йөрүләренә игътибар иттек. «Авыру Әхмәтовны күрмәдегезме? Палатадан юкка чыкты...» дип, безнең яннан да үтеп киттеләр. Торып йөрү түгел, кискенрәк хәрәкәт тә ясарга ярамаган Әшрәф аганың «җир йоткандай» юк булуы безне дә аптырашта калдырды. Тизрәк корпуска кайттык.

Палата ишеге яртылаш ачык, күршемнең караваты буш. Ыгы-зыгы дәвам итте. Ниһаять, Әшрәф аганың ничегрәк, нинди шартларда «юкка чыгуы» әкренләп ачыла да башлады. Өлкән яшьтәге бер няня аның дежур врач кабинетына кереп китүен күргән, телефон аша бик яман сөйләшүен, бик тә әрнеп-борчылып: «Кем рөхсәте белән керделәр?.. Комбайннарны әйтәм... Кем кушты?..» дигән сүзләрен аерымачык ишетеп торган.

Тагын бер авыру хатын Әшрәф аганың, больница капкасыннан чыгып, мотоциклда үтеп баручы бер яшүсмерне туктатуын, шуның белән китеп баруын күреп калган.

Ике-өч сәгать вакыт уздымы икән, кузовына шыплап төялгән ашлыгын брезент белән каплаган, зур гына йөк машинасы больница ишегалдына килеп керде. Өстә, эш киемнәре кигән механизаторлар арасында, ятып торган тагын бер кешене дә абайлап алдык... Ул арада, йөгерешеп килгән больница хезмәткәрләре, кузовның урта бер җирендә сузылып яткан гәүдәне башта носилкага күчерделәр, аннары, өстенә җәймә ябып, төп корпустан шактый ук читкә, куе агачлар арасындагы кечкенә таш бинага алып киттеләр...

Вакыйганың ничегрәк булганлыгы шул ук көндә бөтен нечкәлекләре белән авырулар арасына таралырга өлгергән иде инде. Әшрәф ага, дежур врач кабинетына кереп, колхозының диспетчерына шалтырата. Кыз, Урман буе басуына яңарак кына берьюлы дүрт комбайн керүен хәбәр итә. Алай гына да түгел, контроль сугу күрсәткәнчә, әлеге басудан моңарчы күрелмәгән уңыш — 60 центнердан артыграк гәрәбәдәй орлык чыгуы белән Әшрәф аганы тәбрик тә итә.

Мотоциклга менеп атланган Әшрәф ага туп-туры әлеге дә баягы арыш басуына юл тота. Барып та җитә, тезелешкән комбайннарның каршына

йөгереп чыгып, беренче булып килгәненең алдында аяктан егыла. Бу көтелмәгән хәлдән тәмам шашып калган механизаторлар, агрегатларын туктатып, Әшрәф ага янына ташланалар. Өлкән яшьтәге авыру агроном аларга урудан туктап, тагын ике-өч көн сабыр итәргә куша. Аннары, үпкәләвен белдергән сыман: «...Үзегез өчен бит...» дип, соңгы сүзен әйтә.

Әлеге вакыйгалар турында сөйләгәндә, минем күз алдыма, үз-үзләрен гранаталар белән бәйләп, дошман танклары астына ташланган, курку белмәс лачыннар килеп басты.

Егылган Әшрәф аганы шундук күтәреп алалар да арыш төягән автомашинаның кузовына сузып салып, туп-туры больницага озаталар.

Шул ук көнне врачлардан тагын бер хәбәр ишеттем: Әшрәф аганың уң кулында гәрәбәдәй эре, чип-чиста бер уч арыш булган. Бөтен гомерен Җир-ана белән уртак тел табуга багышлаган агроном, үлгәндә дә, кемгәдер нәрсәдер исбат итәргә теләгән, күрәсең...

**12 август.** Әшрәф ага белән булган бу вакыйга миңа бик авыр тәэсир итте, йөрәгем яңадан чәнчи башлады. Әле дә ярый, мине алып кайтырга дип, машина белән, Зеленый Долдан сеңлем Хәлимә килеп җитте. Больницада танышырга өлгергән дусларым озата чыктылар. Саубуллашканда Дамир миңа: «Әле генә типографиядән»,— дип, район газетасының соңгы санын сузды.

Юлда газетаны караштырып кайтам. Дүртенче битендә Әшрәф аганың портреты урнаштырылган. Таныш рәсем. Шул ук Әсгать әйткән галстук. Тик хөрмә белән маймыл гына күренми, кайсыдыр әлеге сурәтләрне таный алмаслык хәлгә китергән. Некрологка районның барлык җитәкчеләре кул куйган.

Газетаның беренче битендә, эре хәрефләр белән, Әшрәф агага кагылышлы тагын бер информация урнаштырылган. «Арыштан рекорд уңыш» дигән әлеге хәбәрдә РСФСРның атказанган агрономы Ленин ордены кавалеры Әшрәф ага Әхмәтовның тәҗрибә-сынау участогыннан һәр гектардан 73 әр центнер арыш җыеп алынуы турында әйтелгән.

Юл буена миңа бернichә төрле сорау тынгылык бирмәде: нигә дип авыру кешенең, нигезләп, өзгәләнеп сораган бердәнбер үтенечен исәпкә алмадылар икән? Үземчә, колхоз председателе Идият Фәтхуллович белән яшь белгеч Рәфисне аклап та карагандай итәм. Игеннәрне оптималь срокларда җыеп алу өчен янып-көеп йөрделәр шул... Ләкин бит аны киңәшеп тә эшләргә мөмкин булгандыр? Башымда тагын берничә төрле сорау: бәлки аларны узган төннәрнең берсендә булып узган давыллы яңгыр куркыткандыр? Тагын бер сәбәп бар кебек: егерме центнер белән утыз центнер арасындагы уңышка күнеккән бер чорда, икеләтә, өчләтә артык уңыш турында ишеткәч, бәлки, тыелып кала алмаганнардыр?..

Ләкин, ничек кенә булмасын, председатель белән яшь белгечнең әлеге адымнарын аклыйсым килми иде. Азагы, уйламаганда-көтмәгәндә, фаҗига белән тәмамланса да, Җир-анага гашыйк, «элек бер башак үстерелгән җирдә ике башак үстерергә» тырышкан Әшрәф ага турында барыбер язарга алындым. Тик туган-тумачалары, якыннары үтенечен истә тотып, «һәм дә килеп» тагын башка сәбәпләр аркасында, язмамдагы кайбер исем-фамилияләрне чак кына үзгәрттем. Моның өчен хөрмәтле укучым мине кичерер дип уйлыйм.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

**Суфиян Поварисов**

## ГӨЛ БАКЧАСЫНА КЕРӘМЕН...

Матур, эчтәлекле, йөрәк ялкыны белән язылган шигырь яки поэма укысаң, күңел күтәрелеп, хис-тойгы сафланып, уйлар яңарып китә. Гөл бакчасына кергән кебек хис итәсең үзеңне. Ә поэзия бакчабыз ифрат киң.

Ләкин поэтик тел озак вакытлар дәвамында кеше күңеленә рухи азык бирә алмастай аңлашылмаган сүзләр, абстракт сурәтләү чаралары белән чуарланды. Бу күренеш XX йөз башына чаклы дәвам итте. Борынгы төрки, кыпчак, угыз теленнән кергән сүзләр, төрле грамматик чаралар, фонетик һәм морфологик төрлелекләр халык теленең бай эчке мөмкинлеген, рухын, эстетик тәэсир итү көчен күләгәләп торды. Гади укучы гына түгел, хәтта галимнәр, тел һәм әдәбият белгечләре ул чордагы поэтик телнең халыкка «аңлаешсыз», «ят» булуы турында әйтәләр. Шулай да мондый фикер белән тулысынча килешеп бетеп тә булмый. Борынгы поэзиябездә туган телнең гәүһәрләре, энҗе-мәрҗәннәре, бай сүзлек хәзинәсе дә урын алган бит. Кайбер поэтик бизәкләр хәтта хәзерге шагыйрьләрне көнләштерерлек. Мисал өчен, халык курку белмәсләрне «йөрәкле кеше» дип атый. Кол Гали исә Йосыфның физик һәм рухи ныклыгын «алып йөрәкле» дигән сүзтезмә ярдәмендә тасвирлый. Көчле, эмоциональ, логик-экспрессив эпитет табылган. Зөләйха керфекләрендә эленеп торган «гәүһәр яшь» тә тышкы матурлыкны түгел, эчке психологик тетрәнүне, көчле мәхәббәт тойгысын, йөрәк ялкынын чагылдырып тора.

Аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыру, идея-эчтәлекне ачу — эстетик тәэсир өчен файдаланылган мондый поэтик гәүһәрләрне шагыйрьләребез иҗатыннан күпләп китерергә мөмкин. Шулай да соңгы вакытта поэтик телдә чамасызлык, талымсызлык, уйламый эш итү сизелә башлады. Моннан берничә ел элек «аңлашылган», «аңлашылмаган» шигырьләр турында барган дискуссия шул хакта сөйли. «Казан утлары» журналында бара торган хәзерге фикер алышу да шуңа бәйләнгән. Корал эшләр — ир мактаныр, ди. Каләм язар — шагыйрь мактаныр. Каләм очыннан нинди гәүһәр түгелә? Зур фикерләргә төренгән гәүһәрме? Ул гәүһәр халык күңеленә юл табамы? Йә булмаса шагыйрьнең томанлы фикер болытлары эчендә эреп югаламы? Поэтик телне алтын чылбыр итеп тә күз алдына китерергә мөмкиндер. Бу чылбыр боҗралары бер-берсенә нык берексә генә ул гамәлгә яраклы була. Өзелдеме — бетте дигән сүз.

Хәзерге кайбер шигырьләрдә тел-сурәтләү чарасының ни өчен кулланылганын аңлап булмый. Чөнки тел шагыйрьнең фикере белән «конфликтка керә». Р. Закировның «Туган туфрак» исемле шигырендә, мәсәлән, кыр ягының күңелгә якынлыгы турында да языла. «Кыр ягыдай ачык җаным»кебек чагыштыру-метафоралар әсәр тукымасын бизәп тора. Өч строфада шагыйрь туган туфракка булган мәхәббәтне үзенчә күңелгә ятышлы итеп бирә алган. Ә менә соңгы юллар гаҗәпкә калдыра:

*Су басса да нурлы бу як!*
*Тик аз гына моңсурак:*
*Үрләр ерак, су мулырак,*
*Кыр-туфрак дымсурак...*

Кыр ягы булгач, нишләп әле аны су басарга тиеш? «Су басса да нурлы бу як» дип әйтү дөресме? Су баскан җирдә нур бетәме? Нинди үрләр ул еракта? Кыр ягында нигә су — мулрак, кыр-туфрак дымсурак булып чыкты әле? Биредә сүзләр бер поэтик чылбыр тирәсенә тупланмый. Шагыйрьнең фикере белән теле арасында каршылык яши.

Соңгы вакытта поэзия мәйданына яшь талантлар аз килүгә борчылабыз. Кайберәүләр бу хакта артык төшенкелеккә бирелеп сөйли. Яшьләрдәге табышны күрмәскә теләүчеләр дә бар. Поэтик тел осталарыннан соң хәзерге яшьләргә эстетик зәвыгы һаман үсә барган укучыны яңа табышлар белән шатландыру да кыендыр. Гомум кулланыштагы сүзләргә, традицион сурәтләү чараларына яңа бизәк өстәгән шагыйрьләр дә бар. Берәүләр идея-эстетик хосусияте гаҗәп зур булган бер — телсурәтләү чарасы белән укучыны нык куандырса, икенчесе исә башыңны озак тотып борчылырга мәҗбүр итә. Чөнки шагыйрь матур гына, җай гына язып-сурәтләп килгәндә, кинәт «салулап» китә. Н. Акмаловның «Казан утлары» (1987 ел, 6 сан) журналында басылган шигырьләрен яратып укыдым. Автор чал тарихка поэтик караш ташлап, ерак үткәннәрне күңел «иләгендә или», аларны бүгенге катлаулы вакыйгалар белән чагыштырып, фикер йөртә, гомумиләштерә, күп нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итә. Ләкин кайбер очракта фикерләрен абстракт тел-сурәтләү чаралары пәрдәсенә төрүе генә күңелне кыра. «Соңгы хат» шигыреннән бер мисал:

*Мунча ташы кебек кыза дөнья,*
*Себеркеләр уйный ләүкәдә.*
*Сүнде, сүнде көзнең учаклары,*
*Кышлар тупылы мамык очыра.*
*Каян синдә шундый усаллык дип*
*Сорау бирүең бар бу чорга.*

Һәр чорның үз каршылыгы бар. Мулланур Вахитов 1918 елда Казанга килгәч, аннан Мәскәүдәге хәл турында сорыйлар. «Мәскәүдә таш кайный»,— дип җавап бирә Мулланур. «Халык кайный» — ул тиклем образлы түгел. «Дөнья мунча ташы кебек кыза» дисә дә күңелгә ятышсыз була. Әле генә китерелгән шигырьдә «Себеркеләр уйный ләүкәдә» дип әйтү ни бирә? Моның аша чорыбызның җитди каршылыкларын күз алдына китерү бик кыен. Шуннан соң «Сүнде, сүнде көзнең учаклары» дип әйтү «мунча ташы», «ләүкә», «себерке» сүзләренең эчке мәгънәсенә туры килми. Сак һәм Сок бер-берсе белән мәңге кавыша алмаган кебек, бу ике фикерне һич тә бер-берсенә «ябыштырып» булмый. Менә генә дөнья мунча ташы кебек кыза, ләүкәдә себеркеләр уйный, шундук көзнең учаклары сүнә, «кышлар тупылы» мамык очыра башлый. Аннан автор: «Каян синдә шундый усаллык дип Сорау бирүең бар бу чорга» дип аптырый. Биредә без әле бернинди усаллык та күрмәдек. Бу — сүз уйнату, укучыны шаккатырырга тырышу гына.

Ф. Хөсни яшь вакытта Г. Ибраһимовка бер кулъязмасын җибәрә. Г. Ибраһимов болай дип яза: «Ә җил чабып килә дә вагоннар астына кереп ышыклана»,— дигән җөмләләр бар... гыйнвар үзе тудырган җил, шул гыйнварның үзеннән качып, вагон асларына кереп ышыкланган булып чыга... Болар барысы да, Фатих туган, ничек тә булса шәп итеп, шаккатыргыч итеп язарга тырышудан килә. Ә нигә кирәк безгә кешеләрне шаккатыру? Болай да эш җитәрлек ләбаса. Кыскасы, гадирәк һәм кешеләрчәрәк язарга өйрәнәсегез бар» (Ф. Хөсни. Әдип ярдәме... «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» дигән китапта.— Казан, 1966, 308 бит).

Шаккатырырга тырышу юлы белән бер генә шагыйрь дә поэзия көрәшендә мәйдан тота алмаган. «Аяк белән абынудан тел белән абыну яман»,— ди халык. Соңгы вакытта халыкның поэзиягә күңеле сүрелә башлавы кайбер шагыйрьләрнең сүз дөньясында «абынуы»ннан да килә. Алар поэтик фикерне аңлашылмаган сүзләр исәбенә зурайтмакчы. Бу хәл оста, танылган шагыйрьләр иҗатында да очрый. Н. Арслановның «Очрашу сагышы» дигән шигыре ихлас, самими шигырь, матур тойгы белән язылган. Ике яшь йөрәк очраша. Яратышу карашлар аша аңлатыла. Шуннан егет менә нәрсә ди:

*Гашыйк булу шулдыр бер күрүдән!*
*Без әвереллек якын дусларга:*
*Гыйш вә гашрәт урын бирде түрдән,*
*Мин буйсындым син ни кушсаң да.*

«Гыйш-гашрәттә яшәү»нең мәгънәсе: вакытны ашап-эчеп, типтереп уздыру. Ул М. Гафурида да бар: «Гыйш-гашрәт сөр җиһанда». «Гыйш-гашрәт» татар телендә ялгыз килеш кулланылмый. Гарәп телендә «гыйш» дигән сүз бар. Ләкин ул башка

мәгънәдә: тормыш, тереклек, яшәеш, икмәк, ашау-эчү дигәнне аңлата. Гыйшны ялгыз килеш кулланса, дөрес булыр иде, бәлки. Чөнки мәхәббәт ике яшь йөрәккә яшәеш биргән. Ләкин аны да халык аңламый бит. Телебезнең сүзлек хәзинәсе гаҗәп бай лабаса. Яшәү төшенчәсен бирерлек тел чаралары юкмыни анда? Нури ага шигырендә типтереп яшәүгә түрдән урын биргән булып чыга.

Икенче мисал.

*Бу халәтең? Ләззәт булып синнән*
*Дулкынмы узган? Әллә нур яуган —*
*Авырайткан бөтен вөҗүдеңне —*
*Бәхет мизгеленнән ни калган?*

*(Р. Гатауллин. «Яшәү җыры»).*

«Вөҗүд» сүзе гәүдә дигәнне аңлата. Аның башка мәгънәләре дә бар: барлык, бар булу, бар булып тору, хәзер булу. Тукайның мәгълүм юлларында бу сүз — урынлы. Ул чорга да бәйләнгән. Хәзерге шагыйрь әсәрендә ул яңа күлмәккә ямаулык салган кебек булып тора.

Болай дигәч тә, иске (архаизм), гарәп сүзләрен кулланмаска димим. Икенче бер шигырендә Р. Гатауллин болай ди: «Зур бәхеттер — китсәң, кайта алу, Кайтыр урының булу — сәгадәт...» «Сәгадәт» — гарәп теленнән кергән сүз. Бу урында матур яңгырый ул. Аны укучы да аңлый. Сүзләрне стиль таләп иткәнчә кулланырга кирәк. «Тел астында тел бар, җир астында юл бар»,— ди халык. Тирән мәгънәне, зур фикерне бирү өчен шагыйрь тел катламын актарырга, сүз һәм төшенчәләрнең синонимын эзләргә иренмәскә тиеш.

Әйтик, «гаурәт колы» дигән фразеологик әйтелмә кайчандыр булган. Ф. Әмирханда, мәсәлән, «Йөзеңне, беләкләреңне, тавышыңны, чәчеңне гаурәт дип хөкем итеп торсыннар». Гадәттә, «гаурәт» дип тәннең кешегә күрсәтергә ярамый торган ят җиренә әйтәләр. Ә З. Мансуров болай ди:

*Гыйбрәтләрнең төрләрен*
*Күрдем сугыш юлында:*
*Мәхәббәттән нәфрәткәчә*
*Төшкән гаурәт колын да.*

Әлбәттә, «гаурәт» гарәп телендә хатын-кыз төшенчәсендә дә йөри. Ләкин хәзерге укучы аны аңламый бит. Аннан соң эстетик зәвыкка да хуш килми бу сүз.

Иске сүзләрне урынлы-урынсыз куллану белән яшь шагыйрьләр мавыга төшә. Ә бит татар поэзиясе дөньясында яшьләргә өйрәнү өчен күпме нәфис сүз сәнгате осталары бар! Кол Гали бер урында патшаны — мәлик, икенче урында — газиз, өченче урында — солтан дип ала. Бу сүзләрнең сихри көченә, мәгънә бөтенлегенә асыл сыйфатларына зур игътибар итүдән килә. Гаурәт, җәсәд, вөҗүд, гыйш-гашрәт кебек, бүгенге шагыйрьләр үзләре дә тулысынча аңламаган сүзләрнең мәгънәсен телнең бүтән чаралары белән биреп булмый идемени?

Мин Башкорт дәүләт университетында укытам. Сүз сәнгате турында берничә китап, күп кенә мәкалә бастырырга туры килде. Бәлки, шуңадыр, бер яшь егет әлеге сүзләрне җыеп, минем янга мәгънәләрен сорап килгән. «Нәрсә ул гыйш-гашрәт»? «Җәсәд дигән сүзне ничек аңларга?» Егетнең шагыйрьләргә нык ачуы килгән. «Бу бит, читтән сүз эзләмәсәң, татар теленең үз мөмкинлекләре чикләнгән дип тану, телдән көлү була»,— диде ул.

Көнкүрештәге гади генә сүз белән дә йөрәккә шифа булып ятырдай, күңел хисләндерердәй мәгънә биреп була: «Ә син, яңгыр, күк шагыйре, яу, яу» (Р. Харис). Без, бәләкәй чакта, корылык китсә: «Яңгыркаем, яу, яу, тәти кашык бирермен, тәти кашык базарда, майлы ботка казанда»,— дип йөри идек. Шагыйрьнең бу юллары шул сабый чакларны хәтерләтә. Күк шагыйре дип әйтү мәгънәле дә, образлы һәм хисле дә. Кеше элек-электән табигатьнең искиткеч серле күренешләренә, сихри көч-кодрәтенә, күңелләрне ярсытырдай илаһи хозурлыгына табынган. Кояш, ай, зәңгәр күк, йолдызлар белән сөйләшкән. Яңгырның үзендә генә күпме поэзия: җирдән парга әйләндереп алынган су кире шифалы зөбәрҗәт тамчылар булып тама; һәр тамчы эчендә җиргә кояш нурлары да төшә. Яңгыр яуганны тыңласаң, колакка кемдер шигырь әйтә кебек. Димәк, яңгыр күктә шагыйрьгә әйләнгән. Бу җанландыру, сынландыру җир һәм күк йөрәген поэтик җепләр белән тоташтыра, күңелдә матур хис-тойгылар уята, ләззәтләнеп уйланырга мәҗбүр итә.

«Табып әйтелгән сүз — алтыннан кыйммәт»,— ди бит халык. Кайбер очракта

гади генә сүз зур стилистик һәм эстетик көчкә әверелә, сурәт ясый, җанлы картина тудыра. И. Юзеевның «Сез кабызган утлар» исемле поэмасыннан бер мисал:

*Шомлы уйларыма тынгылык бир,*
*Өйнең йөрәгедәй ян, учак;*
*Узганнарны, бәлки, яктыртырбыз,*
*Әткәм төсле булып балкысак.*

Шагыйрь — туган йортында, Берүзе. Әткәй, әнкәй — мәрхүмнәр. Учак яна. Аны шагыйрь кабызды. Вакытында бу йортта бөтен бер гаилә булган. Ә хәзер берәү дә юк. Шагыйрь туган нигезе белән хушлаша. Өйнең йөрәге — ул гаилә йөрәге. Анда янып яшәгәннәр. Нәкъ менә әле янган учак кебек. Учак узганнарны да яктырта. Ата төсле булып балкый. Бу өй йөрәгендәге учак изге нигез яктылыгын озак еллар балкытачак әле.

Соңгы вакытта яңа чагыштырулар белән эш итәргә тырышу сизелә. Әйтик, әгәр кардиограмма сурәте булмаса, Р. Фәйзуллин «Таулар» циклында киртләч-киртләч тау очларын ничек аңа охшата алыр иде:

*Киртләч-киртләч икән тау очлары —*
*Гүя кардиограмма сурәте!*
*Ничек түздең икән йөрәгеңә*
*Ишелгәндә халкың хәсрәте?*

Өй йөрәге, тау йөрәге... Акның аклыгын, сафның сафлыгын исбат итү кирәкмәгән кебек, бу юлларга анализ ясау да артыктыр. Чөнки аны укучы тиз аңлап ала. Шуны гына әйтик. Биредә предметлардагы тышкы һәм эчке үзенчәлекләр бер-берсенә тоташ бәйләнеп, бөтен бер поэтик фикерне аңлатуга ярдәм итә. Кардиограмма сурәтенә охшаган киртләч-киртләч тау очлары — тышкы, тау йөрәге — эчке күренеш. Хәсрәт күтәргән тау йөрәге янында кардиограмма сурәте булу һич тә гаҗәп түгел.

Әйберләрдә төсләр, эчке һәм тышкы сыйфатлар, яшерен серләр санап беткесез. Алар ярдәмендә чагыштыруның төрле формаларын төзеп була. Моның матур үрнәкләрен поэзиядә — Г. Тукай, прозада Г. Ибраһимов күрсәткән иде. Әмма соңгы вакытта шагыйрьләр яңа чагыштыру эзләү турында аз уйлана. Мең мәртәбә тапталган сурәтләү чарасы белән эш итә. Болыт арасыннан кояш эзләп интеккән кебек, аның да мәгънәсен аңламыйн баш ватасың. Р. Юнысовның исемсез шигыреннән бер мисал («Казан утлары», 1987, 5 сан):

*Җылы яңгыр көткән бөре кебек,*
*Үзгә язмыш һаман көттем мин.*
*Юл читендә үскән гөл күк, майлы*
*Тузаннарга батып беттем мин.*

И. Юзеев белән Р. Фәйзуллинның өй йөрәгенә, тау йөрәгенә бәйле рәвештә төзегән чагыштыруларында нинди эпик киңлек күрдек. Йорт һәм тау тирәсендә бөтен бар дөнья. Үткән, бүгенге һәм киләчәк язмышлар. Өй язмышы, ил язмышы, дөнья язмышы. Р. Юнысовның лирик герое ялгызлык сөйгән уйчан күзле бала булган, язмышына өмет белән баккан. Җылы яңгыр көткән бөре кебек — өстән караганда, матур гына чагыштыру. Әмма нигә әле язмыш көтеп сыктап йөрүеңне табигатьнең илаһи матур күренешләре: бөреләр, яңгырлар белән бутарга? Сыек буыннар хәзер болай да күп. Шагыйрьгә шулар арасына кереп яшь түгү һич тә килешми. Ни өчен майлы тузанга баткан ул? Һәм тузанга батуына кем гаепле? Автор аннан болай ди:

*Су буеннан искән саф җил булып*
*Нидер сөйли һаман киләчәк.*
*Мин һаман да әле бөредә күк,*
*Атармын күк бер көн ал чәчәк.*

Шагыйрь су буеннан исәчәк саф җилне көтеп кала. Аның уйлары, чагыштырулары күбрәк үз тирәсендә. Күз алдына елаучы, авырлыклардан куркучы, ихтыярсыз кеше килеп баса.

«Көзге төн» шигырендә Тукай җил елавы аша ил елавын тасвирлый. Чоры өчен ул бик урынлы. Революцион көрәш турында язганда Такташ җилне елатса ни булыр иде? Юк, ул елатмый. Җилне искелекне туздыручы, яңалык алып килүче

символик образ сыйфатында кулланa. Г. Ибраһимовта исә җил агачны төбе-тамыры белән йолкып ыргыта. М. Җәлилнең «Ана бәйрәме» дигән шигырендә җил Бөек Ватан сугышындагы совет солдатының батырлыгын сурәтләүгә ярдәм итә. Безнең үзгәртеп кору чоры — тормышны, яшәешне революцион үзгәртеп кору түгелмени? Безгә бүген корычтай ихтыяр көче кирәк!

Тел-стиль шагыйрьнең, язучының дөньяга карашын чагылдыра, дип әйтәләр. Һәм, чыннан да, әсәр теленә (бу очракта шигырь теленә) анализ ясасаң, шагыйрьнең сүз сәнгате остасы булу-булмавы гына түгел, ә бәлки аның дөньяга карашы, эстетик идеалы, аң даирәсе ни дәрәҗәдә икәнлеге дә ачыклана.

Йомгак рәвешендә шуны әйтергә кирәк. Соңгы елларда традицион поэтик тел тукымасы сүтелә башлады, ягъни поэтик чылбыр өзелде. Тел һәм фикер бердәмлеге сакланмый. Шагыйрь башлаган фикерен эзлекле алып бара алмый. Моңа, беренчедән, фикернең төбе күренеп торган елга кебек сай булуы комачауласа, икенчедән, шул сай елгага чумам дип, шагыйрьнең башын ташка бәреп тишүе зыян итә. Ә бит халык телне дәрьяга тиңли. Аның төбендә энҗе-мәрҗән булу турында әйтә. Тел гәүһәрләрен шул тирән дәрья төбеннән эзләргә куша.

Шагыйрь кайвакыт фикер җебеннән йомгак ясарга тотына. Җеп урала, чуала, укучы аның очын таба алмый интегә.

Гөл бакчасындагы чүп үләннәр кебек тел һәм фикер чатаклыклары шигъри сүзнең эстетик кыйммәтен киметә. Шул ук вакытта сурәтләү чараларын тышкы эффект, «матурлык өчен» генә куллану да сизелә. Бу — май өстенә май ягу белән бер. Шагыйрьнең зур гына фикерләре кайбер очракта төче, кызыл сүзләр пәрдәсенә төрелеп ваклана. «Кызыл сүзнең күчәре тиз сына»,— дип тә әйтәләр. Кызыл сүзләр арасында шагыйрь түккән күз яшьләре күренү тагын да аянычрак.

Без зур масштаблар заманында, фәнни-техник прогресс чорында яшибез. Кеше психологиясендә гаҗәп катлаулы каршылыклар. Шагыйрьгә халык белән сөйләшү җиңел түгел. Ләкин сөйләшергә кирәк. Йөрәкне йөрәккә ялгап.

*Уфа шәһәре.*

## *Бәхәскә укучы кушыла*

# КАЙДА БӘХЕТ? КАЙДА МОҢ?

„Коймa тиешле җирдән җимерелсә, сукмак салына ул». Язучы Марсель Галиев әсәрендәге шушы юллар минем күңелемдә уелып калганнар. Юк, мин үзем җимерүче дә, гыйсьянчы да түгел, ләкин кирәк-кирәкмәс җиргә коелган коймаларның әллә ни файдасы юк дип уйлыйм. Алар материаль якны гына түгел, кешенең бар нәрсәдән дә кадерле вакыты белән бергәттән көч һәм нервларын да сарыф итәләр. Моңарчы шигърият өлкәсендә дә шундыйрак койма бар иде. Ул —бүгенге көн поэзиясенә карата укучы фикерен белмәү.

Үзем шигырьнең кирәклегенә ышанган, шигырь укучыларның күплеген белгән, ансыз кешелек дөньясының дүрт саны төгәл булмасын аңлаган хәлдә дә, вакытвакыт: «Әллә чынлап та шигырь кирәкмиме икән»,— дигән уй миемне көйдереп ала иде. Тик минем өчен «Шигырь кирәкме? Юкмы? Аны кем укый?» кебек сораулар «Җир әйләнәме? Юкмы? Аның кемгә кирәге бар?» дигән шикеллерәк яңгырый... Мондый сораулар тирәсендәге бәхәсләр дә озак кына барды. Ләкин тигез җирдәге түмгәккә кем тау дип менсен инде! Сүрелде. Сүнде андый бәхәсләр. Чөнки шигырьнең кешелеккә кирәклеге аксиома. Ә менә нинди шигырь кирәклеге турында һәркем үз фикерен әйтә ала. 1987—1988 елларда «Казан утлары», «Татарстан яшьләре», «Кызыл таң» газеталары битләрендә басылып килгән тәнкыйть мәкаләләрендә теге яки бу авторның әсәренә бирелгән бәяләрне, язучылар, редакторлар, һәм наширләрнең фикерләрен укучыга үз фикере белән чагыштырып барырга мөмкинлеге киңәеп китте.

Р. Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасы хакында язучы халкы бәхәс алып барды,

тик гади укучылар фикере күренмәде. Күпме яңа китап чыкты, тәнкыйтьчеләр «яфрак астына» качты. Чөнки авыр сүзне әйтү кыен шул. Яңа китаплар арасында укучының ышанычын аклаудан ерак торганнары да бар. Шул хакта газета-журналларда сөйләшү алып барырга кирәк. Ягъни коймa кирәкле җирдән җимерелде. Сукмак кына түгел, укучы күңеленә «Заман һәм шигырь» рубрикасы зур юл салды. Яраткан журнал битләрендә дөнья күргән шигырьләр турында да үз фикеребезне әйтәсе килә.

Менә «Казан утлары»ның 1987 елда чыккан соңгы саны. Аның 142 нче битендә шигырьләр. Ахыргы шигырьгә күз йөртәм. Һәм... тагы, тагы укыйм шул икешәр генә юллы хис ялкыныннан торган куплетларны. Бу шигырьдә инде кайчаннан бирле мине яндырган, гаҗиз иткән сораулар, өзгәләнүләр...

*Көйдем... Сөйдем... Ирештем...*
*Күкләргә менеп төштем.*

*Төштем сагыш җырга,*
*Күмеп күпме хыялга.*

*Җир болытлы, күк аяз.*
*Шулмы сөю? Шулмы наз?*

*Кая бәхет? Кая моң?*
*Гүргә иртә... Күккә соң...*

Бер генә юлын, сүзен дә аерып алып булмый кебек. Шундый да аз сүз белән, шундый да гади итеп әйткән дә биргән... Кем ул? Тиз-тиз авторын эзлим. 141 нче биттә икән. Рәниф Шәрипов. Бу авторның шигырьләрен тәү тапкыр укуым. Икенчесе дә шундыймы? Инде «Оштарма» көен тыңлыйм. Әйе, әйе, тыңлыйм. Чөнки шигырь юлларына күңел күзем белән кагылуга моң түгелде алардан. Җырлатасы килә Шәмсегаләм ападан «Оштарма» көен. Ишетәсе килә, югалтасы килми ул көйне. Шагыйрь белән укучы теләгенең тәңгәл килүе чын халыкчан поэзия дип атала бит инде.

Әйтем булып яшәр юллар бар Р. Шәриповның «Оштарма» көендә:

*Җыр гомерен халык башлаcа да,*
*Җырлар үлчи халык гомерен.*

Шигырь тәмамлангач, өндәү билгесе түгел, нокта куелган. Ләкин мин автордан әсәренә шушы «нәни» генә үзгәрешне кертүен сорар идем.

Инде килеп С. Хафизовның («Казан утлары», 1988 ел, 3 сан) ачуын бик тә китергән гармунны Рәниф тә уйный. Ләкин һич кенә дә ачуны китерми, ә киресенчә, «Күңел гармунлыбызны кемгә тапшырырга җыенабыз соң әле?» — дигән уйга этәрә Рәниф гармуны:

*Гармун уйныйм, ә күңелдә сагышлы моң —*
*Тиңсез көйләр ятим кала, нишләргә соң?*

— дип өзгәләнә ул. Әйе, өзгәләнер, халыкка мөрәҗәгать итәрлек сорау бу. Чөнки:

*Җырсыз, моңсыз нәселсез һәм тарихсыз — тук*
*Бәндәләрнең беркемгә дә кызыгы юк!*

Ә җан гармунын тапшырып калдырыр, аны кабул итеп алырлык кешеләр кемнәр?

*Гармун уйный, ә күңелдә сагышлы моң —*
*Бу гармунны кайсыгызга тапшырыйм соң?!*

— ди шагыйрь. Шушы ике генә юлга салынган мәгънә тирәнлеге тетрәтте мине. Җан чишмәләре саеккан, күңел күзгеләре томанланган «җан ул, дини төшенчә генә, ә мәхәббәт — сантимент» кына дип йөргән, дөньяга фәкать технократ күзлеге аша гына караган бәндәләргә гасырлар, чорлар аша бүгенге көнгә саркып чыккан халык моңын — гармунны — тапшырып буламы икән?! Уйландыра. Шомландыра. Сискәндерә. Тизлек арбасында барганда җаның түгелеп калганны да тоймыйча кая чабасың, кеше?

Тагын «Сакламадым кулымдагы кош баласын» дип башланган шигырьгә тукталыйк. Халык телендә йөргән «һавадагы торнага ышанып, кулыңдагы чыпчыкны очырма» дигән тапкыр мәкальгә нигезләнгән бу шигырь. Чын шигырь шундый үзенчәлеккә ия: һәркем аны үз тормышы, үз халәтенә якынлаштыра ала, укучы анда үз күңеленә аваздаш хис, моң, уй таба ала. Р. Шәриповның бу шигыре мине

бүгенге көндә күпләрне соң дәрәҗәдә борчыган тел турындагы уйлануларга этәрде. Минем күзаллавымда тел мәсьәләсе шушындыйрак бер картина хасил итә: менә бөтен кешеләр дә зур суларга, диңгез-океаннарга омтыла. Шул «дөнья океанына» бару юлында вак чишмә, инеш, хәтта зур гына елгаларын да югалтып бетерә. Белгәнебезчә — океан сулары эчәргә яраксыз. Ә кеше сусый. Ул тәрбиясез калып саеккан, боеккан чишмә суларын әз генә булса да эчеп яши, канында шул чишмә тибеше. Ул аны аңламыйча һаман диңгездә йөзә бирә һәм үзе дә сизми гомерен диңгезгә койган җан чишмәсен эзләп үткәрә. Диңгездән чишмә эзләп табуның ни икәнен аңлатып тору кирәк түгелдер. Җан чишмәсен югалтканнар бәхетнең ни икәнен белмидер. «Үзең бәхетле булмый торып, башкаларны бәхетле итү мөмкин түгел» — дигән А. Макаренко.

Минем шундый бәхетсезләр белән күп тапкырлар очрашканым бар. Алар туган телләрен югалта язганнар, ләкин рус яки башка халыклар теле белән дә тулы мәгънәсендә эш итә алмыйлар. Үзләре шуны аңлыйлар да. Ләкин башка телне җан чишмәсенә әверелдерү өчен нигездә бер гомер генә җитмәү сәбәпле, үзләре дә, телләре кебек китек-котык гомер кичерәләр. Башка телне җан чишмәсенә әверелдереп, халыкка хезмәт иткән шәхесләрнең саны да дөнья тарихында сирәк.

Ә без шуларның барысын исәпкә алмыйча, уртак тел ясарга тотындык та — көймәбез комга утырды түгелме? Күктәге торнага ымсынып, кулыбыздагы былбылны ишетми башладык. Башкорт шагыйре Рәми Гарипов:

*Теле барның гына иле бар,*
*Иле барның гына теле бар,*

— дигән икән, хаклыктан хаклык эзләмиләр. Телгә илтифатсыз булып, туган авылларыбызны аяныч хәлгә төшердек. Русчалап кына «перспективасыз авыл» дип җибәрдек. Аның туган телгә әйләндергәч «киләчәге булмаган авыл» дигән мәгънә биргәнен уйлап та карамадык ахры. Авыл халыксыз булмый бит инде ул. Ул авыл халкын әллә шайтан каргаган идеме икән? Кайсысының туган җирен су астына, кайсысыныкын ут астына салып калдырдылар. Оясы туздырылган коштай туздыда халык, җан ачысы белән оя тирәли кычкырып йөргән кошны хәтерләтеп, сызлана-сызлана чит җирләргә китте... Ә менә Рәнифнең авылы бардыр. Шул авылдыр аның җан чишмәсе. Гади, фәһемле, төгәл, моңлы, милли, образлы тел белән сөйли ул.

Фәкать биш шигырь. Ләкин миңа алар бер үк дәрәҗәдә барысы да кадерле. Бармакның кайсын тешләсәң дә авырта дигәндәй, берсенә дә сүз тидерәсем килми. Рәнифнең биш шигырен дә җаным кабул итте. Әлегәчә бу шагыйрьне күргәнем юк. Ләкин мин аны таныйм, шагыйрь дип.

Шушы мәкаләнең бер өлешен язгач, кулга төшкән «Татарстан яшьләре» газетасының 13 нче санында шул ук Р. Шәриповның «Фатыйма мәхәббәте» поэмасын укыдым.

Поэманы укыйм, ә үзем шушы фаҗигале дөнья эчендәге шагыйрьне күрәм. Әсәрне укый башлагач та, борынгы поэзия аһәңе килеп кагылса да, Йосыфны сурәтләгән матур нәкышләр, чаралар да, борынгы алымнар да юк монда. Чөнки бу әсәрнең авторы Кол Гали дә, Нәваи дә, Туфан да түгел, ә бары үзенә генә хас мәхәббәте белән Рәниф Шәрипов. Бәлки биредә бөек шагыйрьләрне искә алу артык һавалы тоелыр, ләкин мин шуны төгәл беләм: аларның барысына да хас уртак сыйфат — үз геройларына үлеп гашыйк булу.

*Ничек кенә таушалган сүз, ялган белән*
*Кагылмаска синең матур исемеңә?*

— дип үрсәләнә бу шагыйрь дә.

Һәм аның үрсәләнүе дә үзенчә, заманча.

Поэманы укыганда мин шуны да тойдым: шагыйрь үзен дә, каләмен дә, героен да, укучысын да ачык күреп яза:

*Ә бу җырны мин язмадым. Үзем түгел.*
*Каләмемне йөртте сәер, моңлы тылсым.*
*Ул тырышты, Фатыймакай, үзең төсле*
*Сурәтең дә якты, гүзәл сынлы булсын.*

Шигырь турында сөйләп кенә шигырьне аңлатып булмыйдыр. Юктыр, чөнки, сөйләү — проза, ә проза әйтә алмаганнарны шигырьдән генә тоеп була. Әгәр дә мин поэманы шушында күчереп язып куйсам, ул иң яхшы мәкалә булыр иде кебек.

Ләкин әсәр инде тиешле җирдә басылган.

Поэмада шагыйрь әйтергә теләгән фикер акылыма, ә аның җаныннан агылган моң җаныма килеп ирешә. Бу инде шагыйрь өчен зур мәртәбә.

Рәнифнең бур шигырендә куелган «Кая бәхет? Кая моң?» — дигән сорауга: «Туган җирендә, туган телендә. Сиңа хис, моң биргән халкында, шигърияттә!» — дип җавап бирәсе килә. Шулардан аерылмасаң, алар каршысында җаваплылык хисен югалтмасаң, бәхетеңне табарсың.

**Нәҗибә САФИНА,**
Нефтекамск шәһәре.

## Конкрет эш кирәк!

Китапка һич кенә дә товар итеп карарга ярамый. Китап — ул идеология коралы. Хәтта әле рәсми доктриналар искергән чакта да китап үзенең ролен югалтмый. Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттах, Гариф Ахуновларга үзгәртеп кору кирәкми. Үзгәртеп коруны алар кебек кешеләр тудырды.

Дөрес, китапны сата белмиләр. Татар әдәбиятын түгел, татар телен дә белмәгән кешеләр татар китабын сата. Ә пропаганда бөтенләй юк. Китап кибетләренә чын әдәбият сөючеләрне тупларга кирәк.

Журналдагы әңгәмәне игътибар белән укыдым. Сәер. «Ничек бар, шулай калачак»,— дигәнрәк фикер сизелә. Яшь авторның әсәре дүрт елдан соң гына чыккач, ул нәрсә дигән сүз була соң? Мондый темплар сезне беркайчан да замана белән атлатмас. Утызынчы еллар турында алтмышынчы елда, алтмышынчы еллар турында туксанынчы елда язып барган әдәбият кемгә кирәк?

Ни өчен кемгәдер ияреп эшләргә? Барлык нәшриятлар да дүрт елдан соң бастырсыннар, ә сез бер ел эчендә чыгарыгыз. Сездән үрнәк алсыннар!

Матбугатта бар куәтенә укучыны шигырь яратмауда гаеплиләр. Имеш, шигырь китаплары сатылмый, имеш, халык шигырьне яратмый. Дөрес түгел. Укучы шигырь ярата. Кайсы кибеттән Кол Гали, Утыз Имәнине алып була? Әйдәгез әле, халыкка җитәрлек санда классик шагыйрьләребезне бастырыйк.

Шигырьгә мәхәббәтне классик шагыйрьләребездән башлыйк, бу иң ышанычлы юл. Аннары, ни өчен Кол Гали белән Тукай арасы массовый укучы өчен бушлык? Шул чорның шагыйрьләре булган, ул китапларны кайчан бастырачаксыз? Китапханәләр өчен генә түгел, укучылар өчен дә!

Халыкның әкренләп инкубатор чебиенә әйләнеп баруы — үз халкының тарихын, гореф-гадәтләрен белмәүдән. Ә белергә чыганаклар юк, мәгълүмат юк!

**Шамил Баһаветдинов.**
*Куйбышев шәһәре.*

## Нәрсә язганнары аңлашылмый

Ул шигырь китаплары белән нигә вакыт үткәреп, күз бетереп утырырга? Аларның күбесендә бит берни дә аңлашылмый гади укучыга. Ни көләсе килми, ни елыйсы! Ни ачу чыкмый, ни күңел булмый!

Ә бит классик шагыйрьләрдә (мәсәлән, Г. Тукайда) һич тә алай түгел. Анда сүзнең нәрсә турында барганы ап-ачык аңлашылып тора.

Безнең бүгенге кайбер шагыйрьләрнең халыкка әйтер сүзе юкка күрә шулаймы икән ул әллә?

**Кашаф Юнысов.**
*Таҗикстан ССР,*
*Кайракком шәһәре.*

# ХАЛКЫБЫЗГА ЫШАНАМ!

*Шушы айда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Шәүкәт Галиевкә 60 яшь тула. Шул уңайдан укучыларга шагыйрь белән үткәрелгән әңгәмәне тәкъдим итәбез.*



— Сезнең 60 еллык бәйрәмегез илдәге үзгәртеп кору процессының иң кызыклы бер дәверенә туры килде. Шул уңайдан әйтмәссезме: безнең культура өлкәсендә ашыгыч хәл ителәсе нинди проблемалар күрәсез? Аны хәл итүдә язучыларның роле нинди?

— Таң алдыннан моңланып җырлап кайткан егетләр була торган иде. Өздереп ала инде. «Җырчы булырсың»,— диләр авылдашлар. «Җырчылыкка» укый егет, җырчы була. Ә анда «тавыш кую» дигән нәрсә бар икән... Ничек, кая куйганнардыр — берзаман танымый башлыйлар, ятсыналар җырын. Элеккесен югалтты, яңасын булдыра алмады. Юлын үзгәрткән чишмәдәй әллә кая качты моң, күңелдән аерылды...

Шагыйрь авазын да һәр заман үзенчә көйләргә тырышты. тавышны тиешенчә «куючылар» табыла торды. Үз моңы, канатлы сүзләре бар иде, оча алмый калды яшь шагыйрь, ихлас тавышы «эчкә китте». Осталыгын-техникасын төшенеп алган шигырьчебез «кирәгенчә» җырлый башлады, шуңа иярләште. Әмма бүтән кеше гомерен яшәде бугай ул: ачыргаланып әйтәсе җан авазы шалтыравыклы дан авазына әверелде. Фаҗига — үз хәлен үзе дә төшенми яшәде ул. Ялган гомер, әрәм талант...

Миллионлаган язмышларны ботарлаган кешелексез чорлар тыштан имин күренгән җаннарны да имгәтте. «Имгәнгән күңел» дигән шигырем (1962) шуңа ишарә иде: «Офыкларны иңләп-буйлап очар бөркет чыпчык булып чүпли хәзер җирдә бөртек...» 1966 елда язылган «Югалган шагыйрь»дә дә шул фаҗига: «ерак төбәктә, өч йөз яшендә, ил белми калган зур шагыйрь үлгән...» «Чикләмәгез йөрәгемне, мең язмышка мең җырым бар!»— дип гаҗизләнеп кычкырган чаклар да булды (1961).

Һәртөрле тыюлар остарта, кинаяләп сөйләү әмәленә өйрәтә, диләр. Сәләтне үстерә, имеш... Икелерәк бу, юаныч кына түгел микән? Тыючыларның да Эзоп теленнән мәгълүматлылары, күз-колак була белүче сизгерләре бар иде шул, юлны гына түгел, юл араларыннан да укый беләләр иде... Хәер, язучының хәле элек-электән шулайрак булган, намуслы кеше алдында бер бурыч торган: теләсә нинди шаукымнарга карамастан, үз фикерең белән яшәү, принципларың кайбласыннан тайпылмау. Шәхес булган әдип бүтәнчә, җил каян иссә, шунда борылып яши алмый. Сәләте тулысынча ачылырга шарт булмаганда да иманын җуймаган, үз дигәнен әйтергә булдырган язучылар бездә дә бар.

Халык табигатендә дә төплелек, тиз бирешмәү сыйфатлары нигез булып ята, аның рухи тамырлары тарихи тирәнлектә, алышынмас һәм алдашмас-үзгәрмәс җырларында, бәетләрендә, мөнәҗәтләрендә, эпосларында. Гасыр гарасатлары шаулый да тына — җир кала, игенче кала, аның хезмәте кала. Ата-баба җиреннән, гореф-гадәтләреннән килгән күңел береккәнлеге, иманы, ышаныч-таянычы кала. Бирешми, югалмый. Тыныч яшәргә, эшләргә генә бирегез аңа. Яшьләрдә тотрыклылык азрак, тамыр ныгып өлгермәгән — алар модага тизрәк иярүчән, никадәр читтәнрәк, ятрак, сәеррәк булса, шулкадәр ныграк ябышалар. Шаккатырасы, үзенә каратасы килә бит. Рухсыз, әхлаксыз дүңгәләкләр шулай яраладыр...

Әйе, гомерләр катлаулы, фаҗигале чорларга туры килде. Күпме коелган кан-

яшь, корбан ителгән бәхетләр, ихлас инану һәм алданган өметләр — күпме язмышлар күз алдыннан үткән... Алар белән бергә ышангансың, яхшылык көткәнсең, ә изгелек дигәнең артында мәкер, вәхшәт булган... Барысы да күңел аша, йөрәк аша узган. Телисеңме-теләмисеңме, уйларыңа кагылган, иярткән, ялган тарафларга этәргән... Соңыннан пәйгамбәр булырга тырышучыларга елмаебрак карыйсың... Бүген уңга-сулга хакыйкать сибүчеләр күп, сүзләре дә актуаль. Тик таләпләре гел бүтәннәргә төбәлгән, кимчелекне гел читтән эзлиләр, табалар. Шактый еллар элек мин хикмәтле сүзләр китабымда: «Дөньяны үзгәртәм дисәң, үзеңнән башла» дигән идем. Ни дәрәҗәдә тотканмындыр ул киңәшне, аны да уйлыйсы бар...

Ил атмосферасында җылынулар булгалады. Тик «Январь яңгыры» гына булып чыкты алар. Ышанып-өметләнеп ачылган бөреләрне салкын куырды... Хәзерге үзгәртеп кору җиңәр дип ышанасы килә, чөнки чигенер урын калмады. Хәбәрдарлык чаңында — хакыйкатьтә аның көче. Һәркайсыбыз уйлана торган чак, чәчрәп чыгып көннең кадагына иске чүкеч белән сугып, күз буяу соралмый.

Элекке гадәт буенча, «модный» күренеп калырга теләүчеләр юкка ашыгалар. Язучы сүзенең бәһасен төшермисе иде. Һәркем һәрнәрсә турында сөйләү, барлык проблемаларны иңләргә-колачларга тырышу нәтиҗә бирмәячәк. Үз иҗат характерыбыз белән аныкланган даирәләр бар, шул юнәлешләрдә белебрәк, төплерәк эшләсәк, файдалырак булыр. Сез дә сорауның беренчесен үк культура министры, Язучылар союзы рәисе вазифаларына кергәнен куясыз. Проблемалар күп, аларны һәркайсыбыз белә. Әңгәмә уңаеннан конкрет уйланган, борчылганнарына туктарга җай чыгар дип беләм.

Сүзне «бәйрәм» дип башладыгыз, иҗатыма игътибарыгызга рәхмәт. Дөресен әйткәндә, бәйрәм көннәрендә гомер-гомергә эш тулгагы кузгала. Андый көннәрдә: «Әгәр мин каләмемне куйсам, туктап калыр сыман бу тормыш» кебек тоела иде. Иҗат кешесенең юлдашы — үз-үзеннән канәгать булмау, тынгысызлык... Илһам халәте дигән бәйрәмне генә таныйм.

— Бүгенге татар интеллигенциясе һәм татар теле... Атаң-анаң телен белмичә чын интеллигент булырга мөмкинме? Сезнең фикерегез ничек?

— «Татарстан» поездында бер рус интеллигенты белән... татарча сөйләшеп барган идек. Башта минем гаҗәпләнүемне күреп, аңлатып бирде: «Яшьлек эзләремнән йөрдем... Егерменче елларда Казанда эшләгән идем. Ул чакта дәүләт учреждениесендә эшләгән кешегә татарча белү шарт иде. Шул чакта өйрәндем. Онытыла төшкән төшүен — практика юк хәзер...»

Мәгънәле очрашу булган икән. Хәзер безнең интеллигенциягә җитәкчелек итүче интеллигентларыбыз да туган телен белми. «Онытa төшкән» генә түгел, онытып төшеп калган... Ә бит «практика» бар, һәрхәлдә, булырга тиеш иде! Телен белмәгәч, шул телдәге культурасын ничек аңлый инде ул иптәш?! Ничек җитәкчелек итә, ник бу эшкә алына?! Теләмәсә, ник мәҗбүр итәләр?! Белмәү аңа абруй өстәми. Мин залда утырам, күрәм, сүзенең үтемлелеген дә кимета... Демократия үскән чорда үз вазифаларын тиешенчә үти алсын өчен, аның тел белүен сораулары бар. Бер уңайдан искә төшерик — «интеллигент»ның «зыялы» дигән мәгънәсен белә микән ул иптәш? Кызганычка каршы, әдәбиятыбызны тәрҗемәдә укуга күчкән иптәшләр дә аз түгел.

Рус теле туган тел кебек үк кирәк, беркем дә киресен әйтмәс. Андый кешене очратканым юк — безнең тормышта ансыз булмый. Ә менә үзенең ана телен кирәкми диючеләр юк түгел. Белмәүләрен сиздермәскә тырыша беришеләр. Белүләрен яшерүчеләр дә бар. Тел яшерү гадәтен хәтерләтә бу. Элек киленнәргә таләп шундый иде: иренең өлкән туганы алдында кычкырып сөйләшергә ярамый. Тел кайтармасын, каршы әйтмәсен дигән, үзенчә тәртиптә тоткан бу гадәт бетте, хатын-кызның теле тәмам ачылды. Зыялыларыбызга да моны искә алырга кирәктер.

«Татарстан» поездындагы юлдашым белән очрашканнан соң, мин календарьда бер сәхифә күрдем, аны татарча-русча сүзлеккәябыштырып та куйдым. 1971 елның 24 июнь битендә иде ул, юлдашымның татарча өйрәнүенә сәбәпче булган документ: «Татарстан республикасында татар телен рус теле белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт теле итеп тану турында ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык комиссарлары Советы декреты игълан ителүгә (1921) 50 ел».

Әмма ни өчендер бу дата шып-шыпырт кына үтеп китте, алтмыш елы да искә алынмады. Ленин исән вакытта кабул ителгән ул декретның гамәлдән чыгарылганын күрмәдем. Бүген дә бик урынлы ул, күп проблемаларны хәл итүне җиңеләйтер иде. Хәзер бит нәкъ менә шулай — республикаларда ике телнең бер дәрәҗәдә янәшә яшәве турында сүз бара.

Рус теле нихәтле белемгә юл ача! Ә бит туган телне белмәү дә гасырлардан килгән мирас-хәзинәгә юлны бикли...

Әлбәттә, соравыгызга бер сүз белән дә җавап биреп булыр иде. Хәтта ул да артык, җавап — соравыгызда: «Атаң-анаң телен белмичә, чын интеллигент булырга мөмкинме?»

...«Татарстан» поезды Ленин юлыннан йөри!

— Әдәбият язмышы халык язмышы белән, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бик тыгыз бәйләнгән...

— Төрле гимннар тыңлаганым бар: аларда халыкларның өмет-ышанычы, горурлыгы, рухи ныклыгы чагыла. Гимннар илнең иреге, көрәше, җиңүе турында. Мөстәкыйль дәүләте булган халыкларның Гимннары була. Әмма татарның да Гимны бар. Рухи Гимны — Тукай сүзләренә җырлана торган «Туган тел!» Нәкъ менә шуны бер тыннан бердәм, уртак теләктән күтәреп алу хикмәтле — анда халыкның өмет-ышанычы, горурлыгы, рухи ныклыгы! Туган телдән башка мин юк икән дигәнне төшенеп алган халык.

Элегрәк мин бу хакта өлкән язучыбыз Әмирхан Еникидән:

— Халыкның горурлыгын ничек уятырга соң?— дип сораган идем. Ул уйланып, сабыр гына атлый. Аннары гади генә әйтеп куйды:

— Мәктәптән башлана — туган телдән. Шуңа инандырган очраклар булды минем тормышта...

Мәктәп димәктән, былтыр «Яшь ленинчы», «Ялкын» редакцияләре бергәләп Апаста укучылар конференциясе үткәрдек. Район мәктәпләреннән агылып килгән иҗат көчләрен күреп шатландык. Якташларым өчен мин дә горурланып утырдым. «Яшь ленинчы» газетасы редакторы, шагыйрь Роберт Миңнуллин үзе өчен бу якларны ачып:

— Йөрергә кирәк бу якка, бу төбәктә тоташ безнең укучылар икән!— дип гаҗәпләнеп һәм куанып әйтте.

Быел без Апаста тагын булдык. Бездән соң тиражлар шактый арткандыр, дисәк,— шактый кимегән булып чыкты. Апас урта мәктәбендә бөтенләй көтелмәгән хәл — йөзләп бала «Яшь ленинчы» белән «Ялкын»ны алудан туктаган. Сәбәбе — русча программа белән укуга күчкәннәр. Андый чакта җавабы әзер: ата-аналар соравы буенча... Райком вәкиле әйтүенә караганда, аңлатырга тырышып караганнар, колак салучы булмаган! Мәктәп диварларында бер кәлимә татарча сүз юк, хәтта татар теле кабинетына да үз телендә язылмаган. Советлар Союзындагы теләсә кайсы мәктәп дип була, минем туган якны гына танып булмый. Бу хакта мин үпкәләбрәк якташларыма очрашуда әйттем.

Бу нинди тарлык — татарлык? Бер телне үзләштерсәң, белгәнен онытырга дигәнме? Үзара сыешмыймыни алар? Бәхәссез: рус теле — зур дөньяга ачкыч, рәхмәт аңа, ярабыз, белергә тырышабыз. Моңа берәүне дә артык инандырасы юк. Шул ук вакытта, туган телне өйрәтүче укытучыларыбыз арасында да Социалистик Хезмәт Герое күрсәк күңелле булыр иде. Телгә игътибарның югары билгесе, рәсми мөнәсәбәт ул. Хәзер бу өлкәдә тырышлык бер дә ким соралмый.

Оныту бик тиз ул, онытуга хәтер кирәкми шул... Бездән соң Апаста фольклор белгече Рәшит Ягъфәров булып, матбугатта ачынып язды — укыдым, радиодан магнитофон язмасын ишеттерде — тыңладым. Әлеге мәктәптә балалар Тукайны, туган телне онытып баралар.

Әйе, туган телдә халыкның җаны, үлемсезлеге. Ватаныбыз азатлыгы, бәйсезлеге, балалары һәм оныкларының бәхетле киләчәге хакына корбан булган, үлемгә барган ата-бабаларыбызга ныклыкны шушы ышаныч биргән. Алар рухы рәнҗемәсен, Җәлилләр һәм Алишлар кайгырырлык булмасын иде. Туфан, Хәкимнәрнең сызлануы да безнең җанда-бәгырьдә, алар рухы да уяу. Инде шушы әрнүләрне халыкка тойдырасы гына калды. Безгә килеп җиткәч кенә мең еллык күңел җепләре, туган тел аһәңнәре өзелмәсен иде...

«Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?»— дип туган халкына талап тә куйган Тукаебыз. Ә без халыкны тулаем мактабрак ташламадык микән? Көфер сүз әйтмә, дисездер. Бар сәбәпләрне халыкка сылтарга җыенмыйм. Шулай да баланы нинди телдә укытуны хәл иткән һәркем халыкның бер өлеше ич. Шушы уйлар белән җәен Идел ярында йөргән чагында ишелгән ярдагы ачылган тал тамырларын күрдем. Әрсез бит тал дигәнең, корымаган-кипмәгән тамырлары, киресенчә, яфрак ярып үсеп киткән! Хикмәт — яшь үсентеләрдә! Безнең халыкның да эрозия, заман дулкыны ашый башлаган ярын яшь үсентеләр ныгытса гына. Хәзер инде Әмирхан Еникинең дә:

— Балалар бакчасыннан башларга кирәк... Гаиләдән!— диюе тикмәгә түгеллеген аңлыйм.

Ә горурлыкка килгәндә, аны инкарь иткән берәүнең матбугатта мәкаләсен укырга туры килгән иде. Ул В. Распутин белән килешмичә яза — имеш, милли горурлык үзеңнекен бүтән халыклардан өстен кую була. Ә ник әле алай артык күпертеп, кешеләрне өркетергә? Үз дәрәҗәсен белгән кешеләр дус була алмыймыни? Горурлык бетсә, аның урынын мескенлек, кимсенү ала. Кимсенеп яшәгән халыклар гына дус була аламыни?! Совет кешеләренең үз горурлыгы, дип бик дөрес әйткән Маяковский. Ул сүзләр әле дә искермәгән — без барча милләтләр бергә совет кешеләрен тәшкил итәбез. Горурлык — бушкуыклык түгел, ул сыйфатны аклар, аңа лаек булыр өчен һәрвакыт тырышып яшәргә, сынатмыйча эшләргә кирәк. Ягъни — яхшы булырга! Кимсенү исә стимул түгел, көчсезләндерә торган сыйфат. Горурлыгын җуйган кеше үзен яклый алмый, сеңә, бетә, аңарда омтылыш калмый. Ә бит халык аерым әнә шундый кешеләрдән җыела.

Укучылар күңелендә «тел дә тел дип сайрыйсың, ә үз балаларың?»— дигән сорау туарга мөмкин. Бәхеткә каршы, алар укыганда Галимҗан Ибраһимов исемендәге 89 нчы мәктәп тулаем татар мәктәбе иде, балаларыбызның дүртесе дә шунда укып чыктылар. Университетка кергәч тә тел проблемасы комачау булмады. Ике телне камил белү кешене баета гына, хәтергә яхшырак сеңә, чагыштыру мөмкинлеге була. Вазыйх Галимович Надриев җитәкчелегендәге тәҗрибәле, бердәм коллективны рәхмәт хисе белән искә алабыз. Сүз уңаеннан: Рим Хәсәнов музыка язган «Кыңгыраулы мәктәп еллары» исемле җырыбыз да шушы мәктәпкә багышланган иде. Кызганычка каршы, әлеге атаклы мәктәптә оныкларыбызга туган телдә уку насыйп булмады — Галимҗан Ибраһимов анда ялгызы торып калды. Исеме һәм бюсты белән. Үткәннәр сагында Бүгенге көн тора, ә Киләчәк Бүгенне дә, Үткәннәрне дә онытмасын иде!

— Балалар бакчалары... Кеше формалашуның тәүге баскычлары... Андагы тәрбияне үзебез теләгәнчә итү буенча бүген язучылар, китап нәшрияты нәрсәләр эшли алыр иде?

— Казан арты районнарының берсендә, авылда гаҗәп заманча һәм өр-яңа балалар бакчасы күрдек. Ике катлы, курчак өедәй матур җиһазланган. Җыйнак кына залы да бар, сәхнәсендә безнең шигырьләрне укыйлардыр, хәзер ишетербез, дип уйлап куйдым. Күргәзмә әсбаплар һәвәскәр эше түгел — махсус кайтартылган. Әмма берсе дә... туган телебездә түгел. Татарча китап та юк. Кем әйтмешли, имгә бер дә юк. Игенче балалары үсә бу бакчада. Эти-әниләренең һөнәрләрен танысыннар дип, иген бөртекләрен пыяла савытларда куйганнар. Ул бөртекләр миңа бик якын, кадерле. Бөртекләр әле йоклый, ә менә кырда шаулаганда безнең сүзләр, җырларны ишетерләрме?

Аяк очларына гына басып йөрдек — балаларның да төшке йокыда чагы иде. Туган тел өчен дә йоклаган бу нарасыйлар... Гөнаһсыз йөзләренә карыйм да, әрнеп, сызланып, киләчәкләре өчен гаепле тоям үземне... Мондый бакчаларда Казанда да булганым бар. Балаларыбызны «тәрҗемә» итә торган, «оригиналын» оныттыручы йортлар кебек тоела алар кайчак. Сөенечемә күләгә төшә — минем укучыларым булмас алар...

Оныкларым Айрат белән Айгөл, абыйлы-сеңелле, ярыша-ярыша Тукайны ятлады. «Су анасы»н, «Шүрәле»не. Озын-озын шигырьләр бит. Бала күңеленә сыя да икән дип, хәйран калып тыңлый идек. Айрат быел мәктәпкә бара. «Су анасы»н тыңлап тора да, инде ашкынып дәвам итәргә җыенмый: «Кечкенә чакта белә идем»,— дип кенә куя. Әлеге бакча «булышкан».

Оныклар үсеп җитте, аларга бирерлек рәсемле китапларым булмады... Яңаданяңалары чыга торды, әмма алар сурәтсез иде. Шул рәвешендә дә тиз алып бетерә килгән укучыларыма рәхмәт инде... Әйе, 1974 елда чыккан «Тылсымлы көзге» рәсемле иде. Ишеттем, Финляндиядә яшәүче милләттәшләр шул китап белән балаларына туган тел өйрәтә, диделәр. Күңелемә хуш килде бу хәбәр. Инде үзебезнең бакчаларда гына күрәсе калды...

Шул ук бакчаларга, ел саен, Мәскәүдә бизәлеп чыккан китаплар килә тора. Сабыйларның яшь аермаларын искә алып төзелә ул серияләр. Тәрбия программасы туган телебездә булмагач, Казанда андый китаплар чыкмады. Бу хакта мин Татарстан язучыларының соңгы ике съездында ачынып сөйләгән идем. Ниһаять, боз кузгалды, дияргә була. Мин сөйләгәнгә түгел, нәшриятта караш үзгәргәнгә. Безнең балалар әдәбиятында да салават күпере калка — зур тиражлар белән төсле китаплар чыга башлады. Сөенечле яңалык, үзгәртеп коруда күзгә күренгән эш бу! Үтемле китаплар сәүдә оешмаларына да эшне җиңеләйтә. Сусау да көчле мондый китапларга, әнә бит, йөзәр меңләгән тиражлар ничек тиз җыелган!

Күп елларга сузылган гозерләрнең гамәлгә аша башлавы өмет тудыра. Яшьләр журналы турындагы эпопея дә уңай тәмамланыр шәт. Ә бит озаккарак сузсаң, ул

журналны укучылар да калмавы бар, аларны да әзерләргә кирәк: нәниләр өчен «Веселые картинки» рәвешендәге журналга ихтыяҗ хакында, балалар әдәбияты турында сөйләгәндә, 1969 елны ук әйткән идем. Бала тәрбиялим дисең икән, һәр яшенә тәңгәл матбугаты да кирәк. Әлегә бездә өзеклек: укучылары «Ялкын»га киләсе нәниләр журналы юк, «Ялкын» һәм «Казан утлары»н ялгый торган яшьләр журналы юк...

«Азат хатын»га рәхмәт, тәкъдимемне кабул итеп, быел «Нәниләр дөньясы» дигән махсус сәхифәләр ачты, төсле, матур рәсемнәр белән бизәлеп чыга. Шуны күргән укучыларның нәниләр журналын юксынып язулары бик табигый: балаларны ана кайгырта ич... Стәрлетамактан язган өч бала атасының хаты бик урынлы. Туган телдә язмавыма сәерсенмәгез, үз телебездә уку мөмкинлеге булмады, инде балаларыбыз белеп үссен иде, дигән. Кызыктырып өйрәтү өчен нәниләр журналы кирәк. Тукаебыз көтә, дигән. Өченче баласы Тукай исемле икән... Туган телдән китмәвен белдереп, тел-иманын яңартып шул изге исемне кушкан абзаң! Бүгенге Тукайлар матур журнал көтә, алар аңа мохтаҗ, алар аңа зар-интизар! Әлеге журнал балаларның уртак бакчасы, күңел бакчасы, туган тел бакчасы булыр иде. Бөек Тукаебыз әйткән «күңел җимешләре», «җан азыклары» шунда үсәр...

— Бүгенге мәктәп һәм аның проблемалары турында нәрсә уйлыйсыз? Сез анда нинди зур үзгәреш күрергә теләр идегез?

— Гамәлдәге мәктәп реформасы үзгәртеп корудан алда чыгу сәбәпле... арталыкка дучар булды, ни әйтсәк тә, торгынлык еллары продукты ул. Мәктәпләр үзгәртеп коруга хезмәт итәрлек булганчы, аларда яңа бер реформа, бу юлы шул рухка җавап бирерлек реформа кирәктер. Нәкъ менә яңалык, алдынгылык китерәсе мәгариф чөлтәре— иң консерватив өлкә булып чыкты. Чын-чыннан новатор-педагоглар Шаталов, Амонашвили кебек фидакарьләргә юл бирмәүне, хәтта әзәрлекләүне бары тик шуның белән генә аңлатып була. Ә бит мәктәпнең киләчәге яңалыклар юлында. Хәзерге тупиктан башкача чыгу мөмкин түгел. Әнә, япон могҗизасы дип шакката икән дөнья — аның сере дә мәктәптән башлана бит...

Безнең мәктәп баштанаяк бюрократлашты. Заман таләп иткәнчә иҗади фикерләү белән түгел, хәреф ятлаучылык белән яши ул. Административ-команда методы белән эш итеп, шундый ук укучылар — әлеге системаның булачак кадрларын әзерли... Күнеккәнгә генә күрмибез, балакайларны гаскәр шикелле устав кысаларына кысрыклап кертеп бетерделәр бит. Пионер тормышы ритуаллары, атрибутлары казенный тәрбия итә, ихласлык, кешелеклелек сыйфатларын онытып җибәрә. Ул буыннан-буынга күчеп килгән пионер маршрутларын гына карагыз: анда бар нәрсә дә киштәләргә тезеп-тезеп куелган. Әчпошыргыч бертөрлелек, догматик нигезгә көйләнгән тормыш нинди иҗади фикер, нинди җан хәрәкәте уята алсын?! Ул кагыйдәләрне «иҗат иткән» укымышлылар, мөгаен, балачакта да балалык бәхетен кичереп карамаган кешеләрдер. Юкса, нарасый күңелен аз булса да төшенә алырлар иде...

Мәктәп белән укучы арасында уртак тел юк. Төрле «дулкында» эшләү төрле нәтиҗәләргә китерә: балалар арасында үз астыртын тормышлары, мөнәсәбәтләр чәчәк ата, тискәре тәэсирләр, мавыгулар көчле. Бүтәннәрен әйтеп тә торасы юк — токсикомания дигән нәрсә безнең «табыш».

...Макаренко искермәгән икән: мохтаҗлыкта туган башбаштаклык, кансызлык, җинаятьләргә караганда, яңа шартлардагы туклар азынуы белән көрәшү катлаулырак булып чыкты. Сәбәпләрен дә «буржуйлардан» гына эзләп булмый.

Ә бит балалар әдәбияты да заманында әнә шул мәктәп тормышына — юк, тирән агымнарына түгел, өсте шомартылган парад ялтыравыкларына иллюстрация, тагылма гына иде. Бәхеткә каршы, хәзерге балалар әдәбиятыбыз өчен ул чор артта калды. Бала күңеле ихлас сыену урынын әдәбиятта таба алсын иде. Әдәбият иң үтемле дәреслек бит ул...

— Ә дәреслекләр турында ни әйтер идегез?

— Яңа дәреслекне яңа ихтыяҗлар тудыра. Бигрәк тә хәзерге яңарыш, үзгәртеп кору чорында шулай бу. Производствода да иске машиналарны, станокларны яңалары алыштыра — шунсыз заман таләпләренә җавап биреп, заман тизлегенә ирешеп булмый. Рухи дөньяның үз «станоклары». Мәктәп дәреслекләре шуларның иң мөһиме. Ул бүгенгә карап һәм киләчәкне истә тотып төзелә, аның потенциаль мөмкинлекләре — сулыш запасы, алдан күрүчәнлеге булырга тиеш. Безнең хәзерге дәреслекләр исә көн таләпләренә дә җавап бирә алмыйлар.

Кулланыштагы дәреслекләр турында әйтер сүзләр күп. Бирәдә бер-ике күзәтүем белән уртаклашыр идем. Беренчесе. Шигырьләр күбрәк бәйрәмнәргә, мәгълүм даталарга багышлап язылган заманнар бар иде. Андый авторларны «датские поэты» дип тә шаярттылар — әдәбиятлар өчен уртак чир булды. Андый остарулар артта калды. Дәреслек төзүчеләргә читенрәк, датага багышланган шигырьләр аз хәзер. Шу-

лай да, «тырышалар», табалар... Куллануны җиңеләйтерсә дә, әдәби зәвык тәрбияләүдә комачаулый торган әлеге принцип үзәк урынны алып тора. Әйтик, балалар бакчасында Яңа елга, Совет Армиясе көненә, 8 Мартка һ. б. шигырь ятлаталар. Бала 1 класска бара, анда да дәреслек хронологик һәм сезонлылык принципларында төзелгән. II, III классларда да шул ук тәртип... Өч ел буе бер үк дәреслекне кабат-кабат укытабыз түгелме соң? Әсәрләр генә алмашынып тора бит. Мондый куелыш иҗади фикерләүгә өйрәтми, тапталган җиңел юлга күнектерә, фантазияне чикли.

«Дата фасыллары» буенча гына тормыш таныту әсәрләргә икенчел итеп, кимсетеп карауга этәрә, күңел кайту, гайрәт чигүгә китерә, балаларның күбесен әдәбияттан биздереп калдыра. «Өзек»ләр генә укый торгач, әдәбияттан тәмам өзелә баралар. Шигырь яратмаучылар, бизеп калучылар каян килә дисең?

Бер бездә генә түгел, илдә дәреслекләр шулай төзелгән. Темасы «кычкырып торган» әсәр сорый алар. Кыскасы, бүгенге балалар әдәбияты белән дәреслекләр арасында аерымлык яши. Кирәкле әсәрләр юк дияргә ашыкканчы, «дәреслек шигыре» төшенчәсен ачыкларга кирәктер.

Икенчедән. «Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар?» дибез дә, «начар» өлешенә күз йомып, бары яхшы үрнәк белән тәрбияләмәкчебез. Матурлык — үз урынында әйбәт. Әмма тормыш тәмле-татлы гына була алмый. Әче хакыйкатьне дә татысын бала. Юкса, төрләнгән күңелләр «чит бакчага» карый башлый — бозыклык җимешенә юлыга... Бүгенге таләпләр бернәрсәгә дә күз йоммаска чакыра. Ярамаган кыланышлары өчен оялту, уйландыру, кимчелекләреннән арындыру өчен балага гыйбрәтле хәлләрне дә күрсәтәсе иде. Юмор-сатира әдәби әсәрләрдә, рәсемнәрдә булсын, әчтәлеккә органик үрелеп барсын иде. Торгынлык чорында югалган ул сыйфатны кайтарырга вакыт! Кеше психологиясен соңыннан, «картаеп каткач буыннар», үзгәртү читен эш.

Дәреслек укыр-өйрәнер өчен кызыклы, мавыктыргыч булырга, балада иҗат дәрте уятырга тиеш. Бала үз җаны омтылганны тапсын. Тормышка актив катнашу теләге шулай туа, гражданинның төп сыйфатлары шулай тәрбияләнә.

Мәгариф министрлыгында дәреслекләрдәге торгынлыкны бетерергә омтылыш сизелә. Үземә дә бер дәреслекнең әдәби редакторы булырга туры килде. Биредә бер нәрсә ачык: дәреслекләрне элеккечә, төзәтеп-яңартып һәм ямаштырып, иске кысаларга салып кына максатка ирешеп булмаячак — чикләнгәнлек программаның үзендә үк бар. Әшне яңа программа төзүдән башларга кирәк. Белмим, консервативлыктан ничек арынылыр? Бөтен мәгариф челтәренең хәленә бәйле бит әле ул. Мәгарифебез үзе дә, классыннан күчми калган баладай, торгынлык елларында «утырып калган».

— Балалар өчен язучы яшьләр... Алар иҗатында бүген Сезне ниләр сөендерә? Кайсы яклар уйландыра, борчый?

— Иң әлек балалар әдәбиятының бер хасияте турында әйтер идем. Ул — шигырьләрнең олы тормышка тоташкан тирән мәгънәсе. Өстән генә карап фикер йөртүчеләр: тагын чебиләр, мәчеләр турында дип кимсетүчән. Заманында Чуковский да, Такташ та аз ишетмәгән мондый шелтәне. Әле дә балалар теленнән төшмәгән «Тәүфикълы песи»не генә алыйк. Көнкүрештән бер күренеш кенә сыман: катнашучылары әби, песи, маэмай. Ә бит егерменче елларда язылган мәсәл шикелле бу әсәрнең ишарәсе кисәтә: гафил булмагыз, икейөзле, нахакка бүтәннәрне гаепләүче мыштымнар бар, ди. Шул чорда җәмгыятьтә булган чирне күреп алган шагыйрь... Бала аңында шигырьнең бу икенче планы, төп эчтәлеге соңрак өлгереп житәр. Әмма ул күңелгә салып куелган. Табигыйдер, балага киемне дә үсәчрәк таман булыр дип, зуррагын алалар... Җәлилнең «Карак песие», тагын бер «песи»... «Саклый торган маеңны үзең ашап беткәнсең...» Әле шушы арада заводта каравылчыларның урлашуы турында укыгач, әлеге юллар искә төшеп, аптырап көлеп куйдым. Шигырьнең актуальлеген яңартып торалар! Мондый мисалларны бүгенге язучылар иҗатыннан да шактый китереп булыр иде. Сабыйларны уйланырга өйрәтә алар, дальтоник күңелле булмагыз, ди.

Балалар әдәбияты, коймалар белән аерылып яшәгән балалар бакчасы түгел, зур тормышның эчендә ул, бала күңеле белән тоташкан ул. Кызганычка каршы, аларга авыру-сырхауның да бер үкләре тия, бер үк микроблар үчегә. Грипп эпидемияләре генә түгел, әхлаксызлыклар да... Шуңа күрә, балалар әдәбияты рухи профилактиканы төп вазифасы итеп саный. Шулай ук, булачак укучыларны да кызыктырып, олы әдәбият дигән ерак офыкларга күңелләреннән житәклап илтеп житкерәсе бар...

Балалар өчен язучылар элек-электән сирәк булган. Бүген мин андый шагыйрь дип рәхәтләнеп Роберт Миңнуллинны әйтәм. Балалар күңеленә ихлас юлын тапты ул, олыларның да яраткан шагыйре. Олылар дөньясын балаларга якынайтса, зурлар

өчен язганнарында нарасыйларча сафлык-ихласлык үз иттерә. Р. Миңнуллин диган зур тәэсир даирәсе бар, укучылар шул дулкынга көйләнеп алды.

Шагыйрь бүген иң кирәкле фәннәрне — Туган ил, Туган тел, Кеше булу фәннәрен өйрәтә. Хикмәте шунда — өйрәткәнен сиздермичә, үз итеп, мөлаем елмаюга төреп бирә ул теләк-ниятләрен. Миңа аның олылар-балалар дөньясы арасындагы шартлы чикләрне онытгырып, тормышның уртак, актуаль проблемаларын балалар шигырендә чишә алуы ошый. Безнең бүгенге, җитлеккән балалар поэзиясенең төп сыйфатыннан, ирешкәннәреннән берсе бу.

Балалар өчен язган, үзенчәлекле талант булган, әле тиешенчә бәяләнеп җитмәгән Фәнис Яруллин, шулай ук Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Камил Кәримов, Марсель Галиевләрдә өмет бар. «Яшь дигәннәребез шулармы?» дисәгез, сәләтле Рәшит Бәшәров, Ләбиб Леронов, Рафис Корбанов, Рафис Гыйззәтуллиннар бар... Зиннур Насыйбуллин, Афзал Нигъмәтуллиннарны югалту үкенечле булды — һичшиксез чын балалар шагыйрьләре булып өлгергәннәр иде. Әсәрләрен тулы итеп бастырып чыгаруга әзерләү безнең балалар секциясе бурычы.

Яшьләр иҗатынданиләр сөендерә дисәгез, үз индивидуальлекләре белән ачылып, үзләренчә күрүләрен җиткерергә омтылу, дияр идем. Ияру, кабатлаулар юлында яңалык кәтми...

Инде уйландырган, борчыган якларга килсәк, болары барыбыз өчен дә уртак булганы: замана баласына хас күрү җитенкерәмәү, тормышның каршылыклы якларын, бар төрлелеген күрсәтүгә җөрьәт итмәү. Ә бит сиксәненче еллар башында балалар поэзиясендә моның үрнәкләре ачык күренде. Тагын да ни җитми дисәгез: балалар шагыйре булып туу, табигый берлектә, ясалмасыз, балалар белән сөйләшә алу җитенкерәми. Киң колач белән, жанрны үз итеп эшләү кирәк, шунсыз сәләт тиешенчә ачыла да һәм үзенчәлеген расый да алмый.

Балалар матбугатында күренгәләп торган укучылар иҗатын кызыксынып күзәтәм. Еш кына поэзиябезнең кичәге көненә ияреп, бүгенге сулышка кушылып китә алмыйлар. Язганнары ел фасыллары, дәреслек даирәсеннән, аның тарту көченнән уза алмый. Ә дәреслекләр, әйткәнебезчә, бала сәләтен йомык бер әйләнешкә кертә, эзләнү, үз халәтен үзенчә ачуга этәрми. Димәк, беренчедән, балалар әдәбиятының чын үрнәкләрен укучыларга җитәрлек итеп бизәп чыгару зарур булса, икенчедән, булачак укытучыларга да жанр үзенчәлекләрен җиткерердәй әзерлек кирәк. Бәйләныш, ориентирлар дөрес булырга тиеш. Педагогия институтлары, училищелары өчен татар балалар әдәбияты буенча махсус дәреслекләр булса иде. Ә бит белгечләре бар, юк түгел, ихтыяҗ да зур — хәл итәргә бик вакыттыр!

— Тормышыбыздагы яшьләр проблемасы. Сез ничек уйлыйсыз — соңгы елларда безнең бу проблема ни өчен аеруча кискенләште? Аның сәбәпләре, җирлеге нәрсәдә икән?

— Яшьләр турында хафалану яңа түгел. Раслап берничә цитата китерим. Беренчесе: «Безнең яшьләр тәрбиясез, җитәкчеләрдән көлә һәм картларны ихтирам итми. Хәзерге балалар тиранга әйләнде, бүлмәгә олы кеше кергәндә аягүрә басмыйлар, әти-әниләренә тел кайтаралар. Гап-гади итеп әйткәндә, юньсезләр алар.» Икенчесе: «Бүгенге яшьләр иртәгә идарәне үз кулына алса, илнең киләчәгенә бер дә өметем юк, ник дисәң, хәзерге яшьләр түзеп торгысыз, пырдымсыз алар, коточкыч инде!» Өченчесе: «Яшьләр тәмам азып-тузып, бозылып бетте. Явыз һәм белдексез алар. Кая инде элекке яшьләргә җиту! Бүгенге яшь буын культурабызны саклый алмас».

Инде бу фикерләрнең ияләрен атап әйтик: беренчесе — безнең эрага кадәр 470—399 елларда яшәгән Сократ, икенчесе — безнең эрага кадәр 720 еллар тирәсендә яшәгән Гесиод; өченчесе — әле күптән түгел Вавилон хәрабәләреннән табылган балчык чүлмәктәге язу. Чүлмәк 3000 ел хәрабә астында яткан... Күрәсез, яшьләр проблемасы үзе дә шактый «карт» икән. Андый үзара «ботка пешмәүләр» әүвәл дә булгалаган икән. Тегә чүлмәк тә тикмәгә генә ватылмагандыр әле!..

Менә шулай, шаяртыбрак котылыр идем дә, тормыш шәфкатьсез, үтә кырыс, бүгенге көнебездә дә төрлесе бар. Шатландырганы белән бергә, сискәндергән, хәтта чиркандырган хәлләр дә булгалый тора. Әйтик, Ленинград хәтле Ленинградта, фаҗига кичергән героик шәһәрдә... свастика таккан бер төркем яшьләр азынганны аңлап кара... Җир өстендә күмелми яткан сугышчыбызның, безнең өчен гомерен биргән якыныбызның баш сөяген таякка элеп шаярып йөрүче яшьләрне күз алдына китер... Шул ук вакытта, Казаннан барып, үз куллары белән шул сөякләрне билгесезлектән коткаручылар да безнең яшьләр бит! Картлар төрле булган сыман, яшьләр дә төрледер шул...

«Бурычын яшергән бөлгән, чирен яшергән үлгән», диләр. Башын комга яшергән тәвә кошыдай күпме еллар тормыштагы чирләрне күрмәмешкә салыштык — яшь-

ләрдә безгә ышаныч үлә язды... Инде бурычыбызны таныйк — рухи бөлгенлеккә төшүебез бар юкса. Битарафлык чәчтек — шайтан таяклары үрчеде... Комсомолның орденнары күкрәгенә сыймады, ә йөрәге суынды — кайнар йөрәкле яшьләр бүтән символлар эзли...

Җәмгыять — буыннар гомере белән чикләнеп, бүленеп куелмаган, үткәне белән бүгене бербөтен булып яшәүче, тереклек итүче организм ул. Тарихындагы сырхау-чирләрнең бүген сиздерүе шулдыр. Врач та, бала чакта нинди авырулар кичердегез, дип сорый. Егерменче гасыр буе кичергән фаҗига-тетрәнүләр, масса күләм хаксызлык-рәнҗетүләр, җәзалау-сызланулар эзсез югала дисеңме?

Соңгы елларда проблемаларның кискенләшүе — яшьләрнең шул хаталарны, догмаларны кире кагарга, санашмауга җавап итеп, теләсә нинди юл белән үзен расларга омтылудыр. Алар шәхес культы курку-өркүләреннән азат. Проблемалар да глобаль, бар дөнья белән уртак, аларга чикләр юк,— әхлак спидлары күңелләрне ашый. Әйе, йөгәнсезлекнең чигенә җиткән яшьләр дә бар. Күзгә кергән чүп булып, бәгырьгә кадалган шырпы булып әрнетә алар... Элек чәчәк авыруы бар иде, медицинада исеме генә калды. Әмма тормышта хәтәррәк чирләр чәчәк атты. Ул «чәчәкләр» дә соңгысы булмас, яңалары чыгар, дөнья бу, һәркайсы үз шарты туганны гына көтеп тора...

«Чир килә потлап, китә мыскаллап» диләр. Мыскыллап та китә әле... Бәхеткә каршы, төгәлрәге — бәхеткә уңай килеп тора — илдә савыгу-чистарыну чоры. Әмма шулай да, арыну кинәт булмас. Яшьлекнең сәламәт рухи үзәген югалтмаска иде.

Берзаман: «Картлар алай, картлар болай, диеп, шактый гомер үткән, яшьләр алай, яшьләр болай, диеп сукранып чак җиткән» дип шаярткан идем. Яшьләрне аңларга тырышу, аларга ышану кирәк, яшьлекне инкарь итү — картлыгыңны икърар итүдер... Яңалыкны-киләчәкне тоюыбыз картаймасын иде. Балаларына таяна алган, оныкларына ышанган кеше бәхетле. Һәркем үзенә — киләчәгенә хәзерләгән ышануын уйлап-барлап карасын...

— Яшь буынны тәрбияләү белән тыгыз бәйләнгән икенче бер проблема — хатын-кыз проблемасы. Җәмгыятебез өчен хәзер ул бик үткенәйде бит. Сез бу хакта ни уйлыйсыз? Нинди уңай чишелеш күрәсез?

— Ана — бар халыкларда да изге. Аналар фидакарьлегенә, сабырлыгына, миһербанлыгына һәйкәл булып җырлар туа. Шул изгелекне онытмаган балаларның рәхмәтле яратуының иң олысы — күңелләрдә. Ә хәзер безнең сүз күбрәк проблема тудырган аналар турында булыр, аерым кисәтеп куйыйк.

Борын-борыннан сәнгать шедеврларында аналар куенга сыенган баласы белән сурәтләнгән: табигать йөкләгән иң беренче вазифасы шул аның — кешелекнең үлемсезлеген кайгырту... Безнең чорда символ булып, бала урынын урак, я чүкеч алды... Хатын-кызны ирләр белән бер дәрәҗәдә хезмәтле иттек, җәмәгать эшенә күмдек. Хәзер төп мәшәкать аларда, ирләр хөрәсәнләнеп, гаилә кайгыртуны да тулаем аларга тапшырдылар. Ә бит бала тәрбияләүгә вакыт аз кала, шул максаттан карап эш сәгатьләрен кыскарткан чак та килер, шунсыз булмас.

Гаилә — җәмгыятьнең ячейкасы, дияргә яратсак та, ул максаттан читкә — мещанлыкка, чикләнгәнлеккә тарта торган оя кебегрәк саналды. Бала тәрбияләү эшкә комачаулаган мәшәкать чутында булды. Балага мәхәббәтне дә индустрияләштерергә тырыштык: ясле, бакча, мәктәпләргә тапшырдык.

Ниһаять, төшенә дә башладык бугай үзе, баксаң, хатын-кызның иң зур җәмәгать эше ... бала үстерү икән! Әмма мондый шөгыльдән бик теләп арынучылар күбәя башлады, үзләрен фаш итеп язган газеталарга төреп, урамдагы чүп савытына бала ташлап калдыручы аналар да бар... Ә бәлкем ул бүтән газета булгандыр: анысында бер ханым хатын-кыз карьерасы турында янып-ярсып урынлы таләп-дәгъвалар куеп язган иде. Бала тәрбияләү «карьерасы» турында гына бер сүз дә юк иде...

Заманында күп рухи кыйммәтләрдән ваз кичелгән, гореф-гадәт манаралары киселгән. Бала тәрбияләүдә һәр халыкның үз традицияләре бар иде. Үтәли җилдә йөргән узгынчы үрнәкләр тиз йога — күңелләрнең саклану иммунитеты беткән... Тормозы ычкынган адәм баласын әхлакый авария көтә: тотнаксызлык, гаилә таркалу, «бүлгәләнгән» балалар. Ирләрдән җаваплылыкны аз гына да киметмәгән халдә, французлар әйтмешли, сәбәбен хатын-кыздан эзләргә кирәк. Җәмгыятьнең рухи һәм физик сәламәтлек тоткасы — алар тотнаклыгында. Сабырлык, сафлык, самимилек белән яктырган татар карчыкларына карыйсың да, матурлык җанда, иманда икән, дип уйланасың, болар соңгылары була күрмәсен дип шомланасың...

Кара буяуларны артык куертмыйбызмы? Юктыр, күңел табигате дигән мохитнең пычрана баруына күз йомып кына котылып булмый. Юмор-сатира жанрында эшләгәннәр белә — гаилә, ир-хатын мөнәсәбәте, бала тәрбияләү турында язу «вак темалар белән мавыгу» дип бәяләнә килде. Баксаң, ул — әхлак, ул — иң мөһиме икән!

Сагаерга өйрәтелгән идек шул... 1980 елны балалар өчен «Әни дим, әчмә инде!» исемле шигырь яздым. Кульязмада укыган иптәшләр «әти» дип алыштырырга киңәш иттеләр. Юлга-юл тәрҗемә итсә хөрмәтле ханым: «Педагогик түгел бу!» — дип нәфрәтләнеп баш тартты. Шулай да шигырьне үзгәртмичә чыгардым: чирнең җитдилеген сискәндереп әйтергә кирәк иде.

Проблема, проблемалар... Нигә сорауда инде бер-бер артлы шушы сүз кабатлана. Балалар бакчасы, мәктәп, яшьләр, хатын-кызлар... Ул проблемалар төене җәмгыятебез хәленә-торышына «чиләп бәйләнгән». Бала һәм ананың рухи вә физик сәламәтлеге хәвефле хәлдә булуы комплекслы рәвештә, дәүләт дәрәҗәсендә генә уңай хәл ителә ала.

«Баланы тудыра ана, үстерә зам-ана» дип, заманаңы урынбасар-ана дип шаярткан идем берзаман. Проблемалы аналар үзләре дә замана җимеше булса да, гаепне заманага сылтау дөрес түгел. Шәхси җаваплылык, ата-ана бурычы бар бит әле. Бу инстинкт табигатьтә дә көчле — шунсыз тереклек яши алмый.

— Яшь буында шигърияткә мәхәббәт тәрбияләү буенча нәрсәләр эшләргә кирәк дип уйлыйсыз?

— Соңгы елларда кайберәүләр «халык шигырь укымый» дип ышандырырга тырышалар. Тырыша торгач, үзләре тәмам ышанып җиттеләр бугай. Әмма мине ышандыра алмадылар. Кемне укыйлар да, кемне укымыйлар бит! Үз җанына якын исемнәрдән халык кинәт кенә суынмый. Гаепне укучыдан түгел, поэзиядән дә түгел,— ә укылмаган исемнәрдән эзләргәдер?

Исмәгыйль Рәми шаяртып-үртәп әйтә иде:

— Шагыйрьләр ул халыкны гел шигырь укып тора дип белә инде: бер кулы сабан тоткасында, икенчесендә — китап, имеш...

Кемнең ничек укыганын яхшы белгән абзый әйтә иде моны. Ә без белмибез, бик күпләр үзе турында үзе оештырган легендага ышанып, исеме газета-журнал хроникаларында кабатланса, шуны халык тану, шул популярлык дип ышана, бүтәннәрне дә ышандырмак була. Үзеңне артык югары куеп мавыкканчы, мөнбәреңнән төшеп, күңелләргә якынрак килергә кирәктер. Укылмау ул ил-көн тормышыннан ерагаюда, үзең уйлап чыгарган ясалма тормышны җырлауда. «Халык ничек кабул итәр?» — дигән чорлар бар иде. Хәзер: «Тәрҗемәдә ничек яңгырар?» — дип хафалану өскә чыкты, ориентирлар үзгәрде. Бу хакта башлап язучы берәү кыйбласын ачык әйткән иде:

— Мин верлибр язам! Верлибрны бөтен дөнья телләренә тәрҗемә итеп була!

Теге верлибр дип әрле-бирле йөри, «дөнья телләре» генә әллә ни ашыгып төшми бугай...

Югарыга карап фикер йөртү, ярышу хисе әйбәт. Ул яшьләрдә дә булмагач, гайрәт кемдә булсын! Әмма без бит иң әүвәл үз халкыбыз өчен иҗат итәбез. Аның кайгысын кайгыртырга кирәк, уй-хисләребез аңа уртак таяныч булырга тиеш. Юкса тәрҗемәдә шигырьләре күренгәч тә, борын чөеп:

— Бөтенсоюз аренасына чыктым! — дип лаф орып йөрүчеләр бар. Мәскәүгә җитсәң дә, Мөслимгә җитсә бар әле, анда ни диярләр? Бусы инде яшьләргә генә кагылмый...

«Шигърияткә мәхәббәт тәрбияләү буенча нәрсәләр эшләргә кирәк?» дисез. Мәхәббәтле булырга кирәктер — күңелләр ымсынып тартылсын, әсәрләрдә максат-теләкләрен, язмышын тапсын укучы. Ә моның өчен күп тә түгел — бүген халыкны борчыганнарны йөрәк телендә өздереп әйтү генә кирәк...

Кешенең шигъри теле яшьлектә ачыла. Йөрәк тибешен ана мәхәббәте кузгатып җибәргәндәй, ритм, моңны да мәхәббәт уята: әти-әнигә, туган җиргә мәхәббәт булып, канында сайраган телдә туа шигърият. Кимемәс микән ул авазлар? Исеме генә татарча булган авторлар үрчи башлады — мәктәп тегермәне тартып биргән өр-яңа буын килә. Бу хәл мине уйландыра — безнең поэзиягә киләсе яшьләр китә бит...

...Табигатьтә җылылык идарә итә: яз килеп, кояш туры карый башладымы — бар тереклек һәм үсемлекләр дөньясы җанлана: үсә, күтәрелә башлый. Җәмгыять тормышындагы хәзерге дәррәү җылыну поэзиядә дә күтәрелеш тудырыр дип ышанам. Әдәбият тарихына күз салсаң да шуны күрәсең. Төрле буыннарның иҗатка килүе җәмгыять климатындагы үзгәрешләргә бәйле. Мин халкыбыздагы рухи көч чыганакларына ышанам, әлеге чор үз талантларын бирер дип беләм. Борынгыдан килгән аһәңнәрне бүгенгә ялгар ул — шигърияткә мәхәббәтне яңартып җибәрер.

— Әдәбиятыбызның киләчәге — яшьләр. Бу уңайдан Сез нинди проблемалар күрәсез?

— Мәйдансыз Сабантуен күз алдына китерә аласызмы? Анда да бит яшьләр көч сынаша, чыныга. Арадан иң осталары, батырлары сайланып, илгә таныла. Яшь язучыга да «яшь автор» дип аталу өчен мәйдан кирәк. Иң беренче проблема шул

дип саныйм. Әдәби мәйданыбыздан яшьләр таралганчы журнал мәсьәләсе, ниһаять, хәл ителергә тиеш. Аның еллар буе чигерелеп килүен бюрократиянең таш бәгыре, сәяси саңгыраулыгы белән генә аңлатып буладыр. Яшьләр белән аңлашу нокталары эзлибез. Әлеге журнал шул максатка хезмәт итәр иде ләбаса!

Хәзерге этапта иң мөһиме — мәктәпләр, андагы әдәбият сөючеләр белән эшләү, дияр идем. Чыганакларны югалтмыйк, гамьсезлек юшкыны күммәсен. Инде болай да өзеклек сизелә, яшьләр дигәнебез өлкәнәеп киләләр. Сәбәбе, әлбәттә, туган тел укытуга, төгәлрәге, укытмауга бәйле: туган тел дигән кислород җитмәде... Әйе, әдәбиятыбызның киләчәге — яшьләр һәм алар мәктәптән киләчәк. Безнең резерв шунда — мәктәпнең бүгенге хәле безнең киләчәк булыр.

Юаныргалык мисаллар да бар үзе. Хәсән Туфан якташлары — Аксубай районының Яңа Дума урта мәктәбендәге «Әллүки» әдәбият түгәрәгенә йөрүче укучылар белән телевидениедә очрашкан идек. Җитәкчесе — РСФСРның атказанган укытучысы Раушания Низамова. Ни өчен аерып алып әйтәм — җиргә нык береккән игенче балалары алар, барысы да җәйге каникулда ел саен тракторда, комбайнда эшлиләр, үз кичерешләре турында тәмләп, ихлас итеп, балаларга хас шаянлык һәм наянлык белән яза беләләр. Алар язганнан хезмәт кешесе рухы бөркелеп тора! Раушаниянең китапларында, чыккан үз хикәяләрендә дә шушы тормышның табигый сулышы. Ул да комбайнда эшли, хәтта әле районда призлы урыннар яулый икән! Үз тирәләренә җан җылысы белән балалар туплаган мондый шәхесләр безнең таянычларыбыз!

Үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык киңрәк тамыр җәя барган саен, Мәскәү, Ленинград, Оренбург, Уфа, Свердловск, Чиләбе һәм башка шәһәрләрдә әдәбият сөючеләр хәрәкәтенең тернәкләнүе, җанланып китүе сизелә. Хәтеремдә, 1964 елны, Хәсән Туфан белән бергәләп Әстерханга баргач, очрашудан соң агайлар урап алган иде: «Безгә шагыйрь калдырыгыз әле — хезмәт хакын түләп торыр идек! — диделәр. — Юкса, китаплар да килеп җитми бит...»

Әдәби сүзгә ни дәрәҗәдә сусау билгесе иде бу. Ул гына да түгел... Заманында бу төбәк тә, башкалар сыман, үзе әдипләр, культура әһелләренең талантлы яшьләрен биреп торган. Тукайның, соңыннан Җәлилнең бу якта каршылардай каләмдәшләре, фикердәшләре булган... Әйе, Идел күп елгалар, инешләр, чишмәләр, су асты чыганакларыннан туенып тора. Аркылы төшкән плотиналар гына тарихи хәрәкәтне туктаткан. Туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәдә дә бу шулай.

Шөкер, мөнәсәбәтләр ялгана башлады. Әмма күп нәрсәләрне югалтып та өлгердек. Түмән өлкәсендәге бер очрашу онытылмый. Клубка сыймаган авыл халкы ишекләрне каерып ачып, тәрәзәләрне алып, шунда ябырылды. Ә бит себер кышы иде, зәмһәрир суыгы кырыкның өстендә!.. Сөйләшү кайнар булды, ата-ана яшьләрнең әдәбият, культурабызга салкын каравын әрнеп сөйләде. Ул чакта ачыктан-ачык җавап биреп тә, тынычландырлык вәгъдә биреп тә булмый иде.

Заманында университетның фольклор экспедициясе белән һәм әдәбият атналыкларында милләттәшләр яшәгән төбәкләрдә булырга туры килде. Радио дулкыннары да барып җитми иде ул якларга. «Казан утлары»на язылсаң, бүтәнгә күчереп куялар. Әйтерсең лә чит мәмләкәт, әйтерсең лә безнең совет матбугаты түгел...

Ярый, үткән — беткән. Тик күп нәрсәләр кире кайтмаслык булып беткән дә шул. Калганнарын саклыйсы иде. «Азат хатын» журналы бөтен илдә ярты миллионга якын тарала икән, җиде миллионлы халыкка әллә ни тынычландырлык түгел. Шуларның күпмесе яшьләр микән? Әдәби журналыбыз укучыларының да шактые, яшьләре өлкәннәргә ялгана алмыйча, тиражлар өзелеп калмасмы? Ул яктан «Татарстан яшьләре»нең укучылары артканнан-арта баруы өметләндерә. Газетаның яшь укучы белән уртак тел табуы, кеше күңеленә якын серләргә һәм четерекле темаларга кыю алынуы нәтиҗәсе бу. Ул республикадан читтә дә тарала икән, элемтәләрне саклый дигән сүз.

Элек әдәбиятыбызга яшьләр бөтен союздан агылып килгән. Классикларыбызның туган төбәкләренә генә игътибар итегез. Бу очраклы хәл түгел, таралып яшәгән халкыбызның атаклы мәдәният үзәкләре күп булган. Хикмәт — мәдрәсәләрендә дә: «Галия», «Мөхәммәдия», «Хөсәения» һ. б. мәгърифәт йортларында. Сәнгатькә, әдәбиятка, гомумән культурабызга бик күпләрне биргән алар, төпченебрәк өйрәнә башласаң, исең китмәле! «1913 ел белән чагыштырганда» ул югалтуларны алыштырган үзәкләребез ниндиләр? Атаклы университетыбыз, педагогия институтында да сүрелү, сүлпәнләнү сизелә — ялкын юк! Әллә талантлы яшьләребезне бүтән белгечлекләр суырып алып бетерәме? Юкса бездә яшьләрне кайтырту, ярдәм итәргә әзер тору дәүләтебезнең көлсу туфраклы районнарына игътибарыннан ким түгел ләбаса? Тик менә уңыш булып кайтуы гына ничек булыр? Җавапны яшьләр әйтер. Иҗат иткән әсәрләре белән әйтсәләр иде.

— Әдәбиятыбыздагы сатира һәм юморның хәле, әлбәттә, Сезне дә борчый торгандыр...

— Агачның еллык боҗраларына карап елларның ничек килгәнен: яңгырлымы яки корымы икәнен, хәтта радиация дәрәҗәсен белеп була. Җәмгыятьнең хәле дә юмор-сатираның ничек үсүендә күренә. Ул бит турыдан-туры демократия дәрәҗәсен билгертә. Заманында: «Безгә Гогольләр, Щедриннар кирәк!» дип тәкрарланса да, үткен коралны кынысында тотуны хәерлерәк санадылар. Әлеге сатирикларны да, үткәннәрдән килгәнгә күрә генә хупладылар кебек. Зощенко иҗатын пыран-заран китергән мөнәсәбәт моның бүтәннәргә дә ишарәсе иде.

Шәхес культы фаш ителгәннән соң бу жанр тернәкләнеп алды. Әмма атмосфера тагын үзгәрде. Тормышны шомартып күрсәтүне алга сөргән торгынлык еллары туры сүзле жанрны санга сукмады. Нәтиҗәсе куз алдында: Гамил Афзал да лирикага авышты, ә бит аның үткен, халыкчан юморы үзе бер вакыйга булган иде! Тыйнак кына әйткәндә, үзем дә «Сөзгәк үгез маҗаралары»ның дәвамын вәгъдә иткән көе калдым. «Ә гомумиләштерсәгез, гомумән дәштермәбез!» — дип, шундагыча кисәтәләр иде шул. Балалар дөньясына китүемнең сәбәбе шунда, мин моны өзеп әйтә алам. Әмма үкенмим — юмор-сатираны яшәртү, балаларга якынайту булып чыкты ул. Өйрәнеп үссеннәр, кирәк булыр!

Моннан егерме ел элек язучылар җыелышында өлкән тәнкыйтьчебез Гази Кашшаф бер шигырь укыган иде:

*Төзүчеләр көне бар,*
*Геологлар көне бар,*
*Балыкчылар көне бар,*
*Шахтерларга да көн бар,*
*Химикларга да көн бар,*
*Милициягә көн бар.*
*Ник*
*Сатирикларга көн юк?*

Гази ага кырыс сөйләгәндә дә шәфкатьле елмая иде. Әмма минем бу шигырь Тукай клубында яңгыраган көе калды, матбугатка үтмәде. «Көн юк»ны тану шул булгандыр... Кызыгы шунда, хәзер исә: «сатирикларга көн бар бит» дип читкә алып куйдылар!

Ниһаять, кинаягә остарган жанрга авыз тутырып сөйләргә мөмкинлек туды. Тик менә кинәт саф һавага чыгып башы әйләнгән шәһәр кешесе сыман, сатириклар бу иреккә аптырабрак калдылар бугай... Аннары, тагын бер ягын исәпкә алыйк — иҗат ителгәннәрен дә барлау кирәк булыр. Бүген ачыктан-ачык күтәрелгән проблемалар заманында бик белеп кузгатылганнар! Менә ни өчен егерме еллап элек чыккан сатира актуаль яңгырый. Ул чакта аларны күрмәмешкә салышканнар. Күргәннәре исә, «һаман шул бюрократларга бәйләнәсез, таушалган тема!» — дип искәртәләр иде. Баксаң бюрократ дигәнебез бер дә таушалмаган, үрчегән-шәбәйгән, көчен сиздереп астыртын гына елмаеп тора... Ә укучыбыз (рәхмәт аңа) һәрвакыт сизгер, игътибарлы булды, шаяртып кына туры әйткән әсәрләрне телдән төшермәде, сәхнәгә чыгарды. Поэзиянең халыкка якынлыгын нәкъ менә шушы жанр югалтмый торды бит! Ә торгынлык еллары авазын җыелышларда әле дә ишеткәләргә туры килә: «мәзәк кенә» дип, жанрны кимсетеп карау бар. Әлеге ораторлар үзләре мәзәк хәлдә калганны аңламыйлар. Табигать андыйларны юморга саңгырау иткән. Әллә күрәкараумы?

Жанрны җанландыру, яңа сатириклар үстерү, актив гражданлык әдәбиятына тарту җәһәтеннән, арсеналда булганны туплап, антология сыман тулы җыентык чыгарыр чак җитте. Күп санлы һәм бик хәрәкәтчән үзешчән сәнгатебез, профессиональ артистларыбыз өчен кирәк ул популяр әсәрләр. Юкса китаплар тузып-таушалып беткән, сорап язган кешеләргә табыштырыр әмәл дә юк. Мәсәлән, «Шалт Мөхәммәтҗан»ым 1970 елны чыккан иде. Илнең төрле якларыннан килгән хатларның китапсыз калуы бик эчне пошыра.

Яшьләр һөнәрнең мактаулысына ябырыла. Әдәбиятта юмор-сатирага килүчеләр сирәк булды — мөнәсәбәтне күрделәр... Аннары, ул сирәк очрый торган талант. Яшьләр белән эшләгәндә мин шушы жанрга өндим. Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Рафис Сәлимҗанов иҗатларын хуп күрәм, өмет белән күзәтәм. Бар әле дары!..

Артталыктан чыгуда исә Язучылар союзында оештырылган, Альберт Яхин җитәкләгән махсус секция дә булышыр. Жанрның абруен күтәрергә, аз санлы сатирикларның китапларын күзгә күренерлек итеп чыгарырга иде. Ә бәлкем, «Юлдаш» исемле серия итеп, карикатурачылар белән бергә чыгарыргадыр? Укучыларга үтемле булыр.

тираж дип кайгыртасы булмас. Кесәгә салып, юлда уку өчен кулай форматлы итәргә мөмкин. Юмор-сатира безнең юлдаш, көрәштәш булсын иде! Сергей Антонов «Литературная газета»да уртак фикерне әйтте: «Торгынлык елларының иң төп симптомнарыннан берсе — юмор сүрелү... Әдәби талант дигән гомуми төшенчәгә юморны нечкә тою да кергәнен онытмаска иде! Үзгәртеп кору һәм тизләнеш өчен көрәштә сатира-юмор нәкъ менә алгы сафта булырга тиеш».

— Берәр шигыреგезнең язылу тарихы турында ишетү кызык булыр иде?

— Бәләбәй педагогия училищесыннан укытучы Илгизәр Гыйззәтуллин да шул хакта сорый. Ул «Нәсихәт» исемле ике юллы шигырьне атап әйтә:

*Исәннәрнең кадерен бел,*
*Үлгәннәрнең каберен бел!*

«Ул юллар хәзер мәкальгә әйләнде» дип яза. Чыннан да, матбугатта шулай атыйлар. Чирек гасыр элек язылган ул шигырьнең сәбәпчесе халыкның яраткан җырчысы Рәшит Ваһапов булды...

Гастрольдән кайткач, «Чаян»ның күңелле бүлмәсенә ул да кереп утыра иде. Берсендә шулай, Урта Азия тамашачыларының сагынып каршылавын, таныш җырчысында кунакта булуын сөйләде: квартирасы, дачасы да искитмәле икән... «Кунак ашы кара-каршы» дияр чакта, әлеге җырчы Казанга килгәч, качып йөрүен ачынып әйтте. Фатирны күрсәтергә оят, гарьлек — прокатка алган пианино бердәнбер бүлмәне тутырган, диде... Бик килешеп торган елмаюы бу юлы сүрелгән иде...

Күп тә үтмәде, 1962 елда атаклы җырчыбыз вафат булды... Ә үзе радиодан дәртләнеп-канатланып җырлый... Үлгәч тә халкына хезмәт итә талант иясе. Бәгырь телгәләнеп тыңлыйм — үкенеч калды, исән чакта кадерен белмәдек. Күңелгә тулышкан моңсулык шигырь юлларына сыймый. Язам, бозам... Ахыр чиктә бөтенләй сызып, әлеге ике юлны язып куйдым. «Акыл өйрәтү» икәнен аклап, «Нәсихәт» дип атадым. 1964 елны «Социалистик Татарстан» газетасында дөнья күрде ул. Инде газета үзе дә бу шигыремне «мәкаль, халык әйтмешли» дип яза. Авторы онытылган бу очрак шигырьгә иң югары бәядер...

Рәшит Ваһапов моңы әле дә күңелләрне җылыта. Әрнетә дә... Аның «халык дошманы» дип 1937 елда кулга алынган әтисенең кабере билгеле түгел икән. Мин моны әле генә белдем. Әзәрлекләүләр шаукымы җырчының да гомерен кыскарткан — илле дүрт яшендә арабыздан китте. Быелгы календарь битендә ул дата «1957» дип күрсәтелгән, белешмә-китап та шул ялгышны кабатлый...

Хәтерсезлек хәтәр!.. «Үлгәннәрнең каберен бел» дигән сүзләр мирасны онытмау турында кисәтү дә. Шактыйдан әйтеп килгән тәкъдимемне кабатлыйм — «Мирас» исемле альманах чыгуны җайга саласы иде. Күп нәрсәләрне теркәп-барлап барырга була. Анда аерым китапка ирешмәгән авторларның әсәрләре дә, хатлар, истәлекләр, фоторәсемнәр дә урын алыр иде. Кат-кат имлалар алмашынып та күпме хәзинә: алтын-мәрҗәннәребез күмелеп ята. Әкренләп тә, тизләп тә онытa-югалта барабыз. Бик кызыклы, гыйбрәтле олы шәхесләребез бар бит! Юкса тел даирәләре таратган варислар шәхси архивны кәгазь-мәгазь җыючыга тапшыра торалар... Саклап калырга иде, әле соң түгел!

Шигырьнең язылу тарихы кайчакта үзеннән кызыклырак та буладыр. Укучыга ачылмаган серләр кала. Буласы «Мирас» альманахында шундый бүлек ачып, бу хакта махсус яздырып та алырга була. Автобиографияләр дә булсын иде, әнә Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнең Мәскәүдә чыккан язмалары олы шәхесләрне тирәнрәк ачкан чын әдәби әсәрләр бит. Әлеге альманахның чынга әверелүенә ышаныч бар: нәшрият хуп күрә, республикада яңа оешкан «Мирас» комиссиясе исеменә дә ул җисем туры килеп тора.

«Җиде бабасын белгән — бәхетле булыр» дигән бабайлар, онытыласы килмәгән аларның. Шәҗәрәне Коръән читләренә теркәгәннәр. Кәгазьгә ни булмас дип күңелгә бикләткәннәр. Дога шикелле итеп. Тик догалар белән бергә онытылганнар алар, китаплар белән бергә утта янганнар... Хәзерге балалардан сорап карагыз: гасырның уннан бер өлешен сарыф итеп укыган, бихисап патшаларны ятлаган алар, ә үз бабаларын белми... Бәхетләре тулы булыр микән, бабалар рәнҗүе төшмәсме? Халкыбыз тарихына битарафлыкка, санга сукмауга өйрәтәбезме?! 1 сентябрьдә — Тынычлык дәресендә һәр укучы нәсел шәҗәрәсен барлап китерсә урынлы булыр иде. Шәҗәрә агачыннан сугышта каерылып калган ботак-тармаклар да онытылмасын. Каберләре мәгълүм булмаса, исемнәре югалмасын... Шәһәр, авылларыбызда зиратлар да ташланмасын иде, анда безнең тарих, матәм музее ул. Шәҗәрә буыннары кабер ташларына ничә төрле имла белән теркәлгән...

Казанның татар зиратындагы һәйкәл комплесында, сагышлы Ана янында, быел көтмәгәндә ак хәрефләрдән тезелгән шигырь юллары күрдем:

*Исәннәрнең кадерен бел,*
*Үлгәннәрнең каберен бел!*

— Киләчәккә нинди планнарыгыз бар?

— «Казан утлары»ның киләсе санында бер төркем шигырьләрем чыга. Журналда иң беренче күренүем 40 ел элек, нәкъ менә декабрь санында булган иде. Аларны Сибгат Хәким тәкъдим итте. Әдәби эшчәнлегемне шуннан башлап саныйм. Яшь язучыларның Беренче республика конференциясе дә шул айда булды. Безне Сибгат Хәким туплады. Яшь авторларны сугыштан соң беренче барлау булган ул, күбебез өчен әдәбиятта күк капусы ачылу булган.

Планнарга килсәк, «Илһамым-мәхәббәтем» исше, лирик язмалардан торган тагын бер китап әзерлим. Бик мәшәкатьле эш — бөртекләп сайлыйсы бар. Шулай да күңел ихтыяҗы алар.

Төрле елларда язылган яңа шигырьләр җыентыгым нәшрият карамагында. Лирика, юмор, сатира. Заманында язылып та, заманга «туры килеп бетмәгән» шигырьләр дә бар. Үзенә күрә алар да чор елъязмасы икән!

Тагын бер җыентык өешып ята, анысы әдәбият, каләмдәшләр турындагы уйланулар, истәлекләр, кыйссалар. Егерме ел элегрәк язылып та архивымда яткан «Шигырь турында хикәяләр» дә булыр анда. Хәсән Туфан турында, бүтән замандаш шәхесләр турында да кыска-кыска язмалар бар.

Балалар өчен яңа шигырьләр тупланып килә. Шәвәлинең «Яшь ленинчы»да күренүенә егерме биш ел тулды, аның турындагы шигырьләрне аерым чыгарасы иде.

Юмор-сатираны, шигырьләрне, әз-мәз мәзәкне, хикмәтле сүзләрне дә бергә туплап укучыга җиткерәсе иде. Чорыбыз да җанлы, тиз үзгәрүчән. Җәмгыятебездә уяну, уйлану, кыюлану процессы бара. Әмма әңгәмәне тәмамлап, болай дияр идем. Ул барыбызга да кагыла:

*Күп ул дөрес сөйләүчеләр,*
*Күп ул дөп-дөп-дөрес сүзләр!*
*Туктап тын алыйк беразрак:*
*Дөрес эшләүчеләр азрак...*

Библио-графия

# ТОРМЫШ ИМТИХАНЫ

Күренекле язучыларыбыз әдәби әсәрләр тудырудан тыш, автобиографик язмалар да иҗат итә торалар. Риза Ишморатның «Гомер сукмаклары» һәм «Дусларым, остазларым» дип аталган китаплары (Татарстан китап нәшрияты, 1987, 1988 еллар) әнә шул җөмләдән. Беренче китапка аннотациядә дә «өлкән язучыбыз әлеге китабында укучыларга үзенең тормыш юлы турында сөйли» дип әйтелә. Ләкин чынлыкта әлеге хезмәтләрне мондый кысага гына сыйдырып булмас кебек. Социаль тормышны тамырыннан үзгәрткән егерменче гасырның кеше язмышына ясаган гаять зур тәэсире турында бу китаплар дисәк, төгәлрәк булыр.

«Давылга табан», «Үлмәс җыр», «И мөкатдәс моңлы сазым!..» Әдәбият һәм театр сәнгатебез белән таныш кешеләргә бу өч исемне атау гына да драматургның төп иҗат юнәлешен билгеләргә ярдәм итәчәк. В. И. Ленинның зур көрәшкә ясаган беренче адымы нәкъ менә безнең Казанда булу һәммәбезне горурландыра. Р. Ишморатны исә, кеше һәм иҗатчы буларак, бу хәл аеруча илһамландырган — «Давылга табан» әсәре иҗат ителгән.

«Үлмәс җыр» — М. Җәлил образы аша кешенең ил һәм шәхес иреген яклап, фашизмга каршы көрәшен тасвирлады, бу тиңдәшсез батырлыкның асыл сәбәпләрен ачты.

«И мөкатдәс моңлы сазым!..» — бөек шагыйрь Габдулла Тукайның бөтен яшәеше һәм иҗаты белән халыкчыкы булуын яңа көч белән раслады.

Күрәбез, Р. Ишморат иҗатының хасияте — шәхесне һәм аның эш-хәрәкәтен иҗтимагый җирлектә ачу, теге яки бу чорга бәйле рәвештә герой эшчәнлегенең асылын анализлау. «Океан батырлары», «Кайту» кебек уңышлы әсәрләр иҗат иткәндә дә Р. Ишморат каләмен шушы максат йөртә.

«Гомер сукмаклары»н һәм «Дусларым, остазларым»ны укып чыккач, Р. Ишморат иҗатына карата булган мондый фикер тагын да ачыклана төшә. Әгәр кеше: «үтелгән гомер юлына әйләнеп караган чакларымда, зарланмыйм, тормышымнан канәгать... диңгездән бер нәни тамчы кадәр генә булса да, татар театрын, драматургиясен үстерүгә, димәк, культурабыз үсешенә бераз булыштым бугай. Шат мин моңа», дип әйтә ала икән, чыннан да, аның үткән юлы мәгънәле булган дигән сүз.

Әлеге китапларны укыганда, барыннан да элек кешеләр һәм аларның язмышы кызыксындыра. Без халкыбызның эшчәнлеге, тырышлыгы, киң күңеллелеге, характер ныклыгы белән горурланабыз. Ә ул асыл сыйфатлар кешедә ничек тәрбияләнә соң.

Менә булачак язучының әтисе Фәхретдин. Ярлы гаиләдән чыгып, үз тырышлыгы белән хәлфә һәм кечерәк бер авылның мулласы була алган кеше ул. Ләкин асылы белән ахирәткә түгел, бу дөньяга мөкиббән киткән. Кара син аның эш рәтен белүен, хезмәт яратуын, уңган хатыны белән бергәләп балаларда хезмәт сөючәнлек тәрбияләвен. Башкорт якларыннан Актаныш тирәсендәге Уразай авылына әйләнеп кайткач, иң беренче эш итеп җиләк-җимеш куаклары һәм агач утыртуын. Һәрхәлдә моның белән ул балаларына тормыш дәресе бирә, дөрес яшәүнең әлифбасын өйрәтә. Яки менә Фәхретдиннең дөнья гыйлеменә, укуга булган мәхәббәте. Үзе ярый инде, ярлы баласы булгач, сайланып торырга туры килмәгән, иске мәдрәсәдә мөмкин булганны укып, хәлфәлек итәрлек хәлгә килгән. Әмма аның моңардан гына канәгать түгеллеге әллә каян сизелеп тора. Кайдан тапса, шуннан китап ала, егерменче гасыр башында күпләп чыга башлаган газета-журналларны алдыра. Болар аның дөньяга карашын үзгәртәләр. Ул тора-бара диннән суына, муллалыгын ташлый. Туган авылында гади крестьян булып көн күрә. Хәтта революциядән соң большевиклар партиясенә теләктәш булып та языла. Кеше мондый эволюция үтсен өчен, аның күңелендә нинди көчле фикер каршылыклары булырга тиешлеге әйтмәсәң дә аңлашыла булса кирәк. Р. Ишморат әлеге китапларда бу турыда тулырак та яза алган булыр иде, әлбәттә.

Фәхретдин абзыйның улларын укытуга булган тырышлыгы да таң калдыра. Балаларның киләчәге, халыкка файдалы кешеләр булып үсәргә тиешлекләре турында ул аталарча кайгыртып тора. Янбарыс мәдрәсәсендә дә укытып карый ул аларны, әмма рәт чыкмаслыгын аңлагач, ерак дип тормый — Сараш авылының яңачарак укытыла торган мәктәбенә илтеп бирә. Минзәлә югары башлангыч мәктәбендә дә белем ала балалар.

Ничек итсә итә, улларының тормышка мөмкин кадәр әзерлеклерәк килүен тели. Менә кайда ул халкыбызның затлы сыйфатларының нигезе! Г. Бәширов, М. Әмир, Ш. Маннур, Ә. Еники һәм башкаларның автобиографик әсәрләрендә дә без моның шулай икәнлеген күргән идек.

Р. Ишморат истәлекләренең тагын бер игътибарга лаек ягы шунда — ул үз тормыш юлында очраган мәгърифәт, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре турында яратып, үз итеп яза, аларның холыкларының берәр ягын ачып бирерлек итеп сурәтли. Менә бертуган Шәриф һәм Сәгыйть Сүнчәләйләр. Сараш авылындагы рус-татар мәктәбендә дүрт ел уку дәверендә кечкенә Риза һәм аның абыйсы Зыя күңелендә тирән эз калдыра алар. Г. Тукай шигырьләрен беренче башлап үз әтиләреннән ишеткән малайлар инде аларны шагыйрьнең үзе белән якыннан аралашкан Сәгыйть абыйлары укуында тыңлыйлар. Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Дәрдмәнд. Укмасый исемнәре һәм әсәрләре белән дә Сүнчәләйләр аркылы танышалар. Сәгыйть Сүнчәләй гади хәлфә генә түгел, шагыйрь хәлфә. Бу исә шәкертләргә аеруча көчле тәэсир ясый. Ул гына да түгел, ул Гейне кебек дөньякүләм танылган шагыйрьнең «Әл-Мансуры»н тәрҗемә итүче. Балалар белән дәрестә генә түгел, башка вакытларда да очраша, җырлар өйрәтә, аларның яшь күңелен скрипка моңнарын кабул итәргә күнектерә. Болар барысы да Сүнчәләйләргә аерым бер мәхәббәт уята. «Туган тел»не яттан белмәгән һәм аның көен үзләштермәгән бер генә укучы да юк иде. Безнең белемебез, яшәвебез, бәхетебез әнә шул матур тел, туган телебезгә бәйләнгән кебек тоела иде безгә». Бала вакыттан нәни күңелгә салынган әнә шушы орлык алга таба әдәби иҗат дигән олы юлга алып килә.

С. Сүнчәләй шагыйрьлек ягыннан үзе Г. Тукай шәкерте. «Без аның белән (Г. Тукай белән — Ф. Г.) бик якын танышлар гына түгел, хәтта дуслар да», дип сөйли ул шәкертләргә. Г. Тукай вафаты турындагы хәбәрне алгач, Сәгыйть абыйларының зират коймасы буенда әле күптән түгел генә яшелләнеп чыккан үләнгә ятып, шул чирәмле җирне тырмый-тырмый елау күренешен укыганда, бу кайгының олылыгы бүгенге укучыны да биләп ала. «Тукай җаным, бәхиллә мине!» дип, С. Сүнчәләйнең үз-үзен белештермичә кычкыргалап куюы фаҗигане тирәнәйтә төшә. Болар — ун яшьлек малай күңелендә сакланып калган һәм Г. Тукайга халыкның, аның дусларының ихтирамлы мөнәсәбәтен күрсәтә торган хатирә. Р. Ишморат үз күңелендә йөрткән моңлы күренешләрне халыкка җиткерергә тиеш иде. Ул моны әлеге китапларында эшләгән дә.

Язмыш Р. Ишморатны Г. Тукайның тагын бер дусты — Ф. Әмирхан белән очраштыра. Казан театр техникумында классик язучы аларга әдәбият укыта. Билгеле булганча, Ф. Әмирханның аяклары йөрми. Р. Ишморат болай яза: «Фатыйх абыйның һәрвакыт диярлек каршысына чыгып, тарантастан күтәреп ала һәм классыбызга, өстәл артындагы урындыкка кертеп утырта идем. Аны күтәреп килгән өч-дүрт минут эчендә кызык-кызык әңгәмәләребез дә булгалап ала иде».

Ф. Әмирханның футуристларга, имажинистларга һәм башка шундый формаль агымнарга карата яшьләрдә тискәре караш формалаштырырга омтылуын да ул рәхмәт хисләре белән искә ала. Ф. Әмирханның Муса Җәлил иҗатына игътибар иткән булуын белү укучы өчен шулай ук кызыклы факт.

Р. Ишморат зур рәхмәт хисләре белән Г. Тукай, Х. Туфан, М. Җәлил, Һ. Такташ, К. Тинчурин һәм башкаларның да үз иҗат биографиясендә әһәмиятле роль уйнаулары турында яза. Шулай итеп, хөрмәтле әдипләребезне тагы да тулырак күрә һәм аңлый алу мөмкинлеге бирә.

Утызынчы елларның әдәбият үсешенә тискәре йогынты ясавын да онытырга ярамый. Тик автор алар турында дәшмәүне артыграк күрә. Ни өчен дигәндә, китаплар торгынлык дип аталган елларда — җитмешенче еллар уртасында язылган. Шуңа күрә авторның күңелдә булганын да әйтми калдыруы сизелеп тора. Хәер, ул моны үзе дә яшерми. «Укучылар, бәлки әйтерләр, тормыш юлың бик авыр һәм сикәлтәле булган, әмма син аны җиңеләйткәнсең кебек, диярләр. Хөрмәтле укучыларым! Нәкъ шулай. Тормыш юлымда очраган күп авыр хәлләр, вакыйгалар һәм явыз яки вак җанлы кешеләр, аларның эшәкелекләре турында язып торуны кирәк дип тапмадым. Ә сезгә, без үткән авыр юллар белән танышу, аны аңлау һәм нәтиҗә ясау өчен шушының кадәресе дә җитәр кебек». Әлбәттә, бу кадәресе өчен дә без Р. Ишморатка рәхмәт әйтәбез.

«Гомер сукмаклары» һәм «Дусларым, остазларым» — Риза Ишморатның, кеше һәм иҗатчы буларак, замандашлары һәм килер буыннар алдында биргән тормыш имтиханы. Бу имтиханны ул әйбәт кенә тоткан. Монысы — иң мөһиме.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

Редакциядән:

*Күренекле драматург Риза ага Ишморатка шушы айда 85 яшь тула. Күп санлы укучылар һәм каләмдәшләре исеменнән аны кайнар котлыйбыз, яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез!*

**Ибраһим Нуруллин**

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕГЕ ҺӘМ ҖӘДИТЧЕЛЕК ДИП ЙӨРТЕЛГӘН КҮРЕНЕШКӘ КАРАТА

*Бу мәкалә, «Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның формалашуы һәм үсеше» исемле докторлык диссертациясеннән (1967) алынган булып, вакытында басыла алмый калган иде. Диссертацияне «Өлгергәнлеккә таба юл» (рус телендә, 1973) дигән исем астында китап итеп чыгарганда да аны кертеп булмады. Кабат карап чыккач, мәкаләнең, кызганычка каршы, (әйе, әйе, кызганычка каршы) һаман әле актуальлеген югалтмаганлыгы күренде. Чөнки без анда күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итүдә алтмышынчы еллардан күп алга китмибез. Моның шулай икәнлегә принципиаль эчтәлекле бер гыйльми хезмәтнең дөньяга чыгуы белән өстәмә рәвештә раслана. Мин танылган шәрык һәм ислам белгече профессор Л. И. Климовичның «Мәгърифәткә хезмәттә. Төрки телдәге беренче газета «Тәрҗеман» һәм аны чыгаручы И. Гаспринский турында» дип исемләнгән күләмле мәкаләсен күздә тотам («Звезда Востока» журналы, 1987, 8 сан).*

*Русчадан тәрҗемә ителүен, кабатлаулардан котылуга һәм редакция үтенеченә бәйле кыскартуларны искә алмаганда, мәкалә үзгәртүсез басыла.*

АВТОР

Соңгы елларда беркадәр үзгәреш сизелсә дә, без һаман әле «җәдитчелек» һәм «мәгърифәтчелек» дигән ике нарат арасында адашып йөрибез.

Егерменче елларның әдәбиятчы һәм тарихчылары иске феодаль тәртип, иске идеологиягә каршы көрәшүче бер генә агым — үсеп килә торган капитализм интересына хезмәт итә торган җәдитчелек агымын гына беләләр иде. Г. Ибраһимов болай дип язды: «1905-07 ел революциясе алдыннан татар дөньясында яшь, ләкин тиз үсеп килгән яңа фикерле, Европача, реформа яклы татар буржуазиясе белән бөтен идеологиясен Көнчыгышка, бигрәк тә Урта Азиягә, Бохарага бәйләгән иске татар (кадим) феодализм калдыклары арасында каты көрәш бара иде».[1]

Көрәшүче шушы ике көчне XIX гасырның соңгы чирегендә кадимчелек һәм җәдитчелек дип йөртә башлыйлар. Башта бу атамаларны мәктәптә аваз методы белән укытуны яклаучыларны һәм моңа каршы торучыларны билгеләүдә генә кулланганнар. Соңга таба җәдит һәм җәдитчелек дигән төшенчәләр татар тормышын һәрьяклап үзгәртеп кору өчен барган хәрәкәтне һәм аның вәкилләрен белдерә башлаган. Бу бәйләнештә Г. Ибраһимовның түбәндәге сүзләре дә кызыклы: «Болар (аваз методын башлап кертүче И. Гаспринский һәм аның тарафдарлары — И. Н.) эшләре буенча шул Насыйрилар, Фәезхановлар көрәшкән фронтның бер тармагы иде». (7 т., 264 б.)

Шулай итеп ике лагерь, ике идеология. Бер якта искелекне, урта гасырча яшәүне яклаучылар; икенче якта — татар тормышының төрле өлкәләрен үзгәртеп кору өчен көрәшүчеләр. Алар арасында 1905 ел революциясенә кадәр дәвам иткән кискен көрәш.

XIX гасыр һәм 1905 елгы революция алды еллары татар әдәбиятына тукталып, Г. Ибраһимов М. Акъегет-задә, З. Бигиев, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинев, Г. Камал, М. Гафури исемнәрен санап китә дә иҗатлары турында мондый сүзләр яза: «Болар һәммәсе искене—феодализм калдыгын сүгәләр, җимерәләр, яңага, рус-европа мәдәниятенә чакыралар иде. Болар җәдит хәрәкәтен, дини реформацияне, Европа гыйлемнәрен яклау белән бергә, татарның гаилә, җәмәгать тормышына да кагылалар иде». (7 т, 265 б.)

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр сигез томда. 7 т. Казан, 1984, 260 б. (Алга таба текстта җәяләр эчендә том һәм бит саннары гына күрсәтеләчәк).

Игътибар итегез: хәзергә кадәр кайбер галимнәр тарафыннан реакцион җәдитчелекнең типик вәкиле итеп саналган М. Акъегет-задә исеме З. Бигиев янында тора. Соңрак начар мәгънәсендә җәдитче дип игълан ителгән Р. Фәхретдинев, Ф. Кәримиләр мәгърифәтче-демократлар Г. Камал һәм М. Гафури белән янәшә куелган. Соңрак икесе исә укыту-педагогика эшләрендә генә түгел, дини реформа мәсьәләләрендә дә Кәримиләргә фикердәш булганнар икән.

Күренекле әдәбият белгече Г. Сәгъди Г. Ибраһимов карашларын тулысы белән уртаклашкан: «Әлифба укытуда «ысулы саутия» кертелү һәм әлифбаны шул ысул белән укыта торган мәктәпләр ачыла башлау белән теге Каюмнар башлаган Европа фәннәрен укыту мәгънәсендәге «җәдитчелек хәрәкәте дә» гомумиләшеп, көчәеп китте».[2]

Күренә ки, Г. Ибраһимов һәм Г. Сәгъди уенча, Беренче рус революциясенә кадәр татар иҗтимагый фикерендә һәм әдәбиятында кадимчелеккә каршы бер-берсенә дошман булган ике лагерь түгел, бәлки бер генә лагерь— җәдитчелек кенә көрәшкән.

Тарихчылар, әдәбият галимнәре һәм педагоглар озак вакытлар Г. Ибраһимов карашларына таянып эш иттеләр. 30 нчы еллар ахырында кем тарафыннандыр кертеп җибәрелгән «мәгърифәтчелек» атамасы да моңа комачаулык китерми, ул «җәдитчелек» дигән сүзнең синонимы итеп йөртелә. 1950 елда да әле XX йөз башы татар әдәбияты турындагы мәкаләләр сериясендә Г. Халит «мәгърифәтчелек» терминын кулланганч, «Моңар чаклы бу хәрәкәт җәдитчелек дип аталып йөртелә иде» дигән аңлатма бирүне кирәк тапкан. («Совет әдәбияты», 1950, 2 сан).

Менә 1949 елда Б. Г. Гафуровның «Таҗик халкы тарихы» исемле китабы басылып чыкты. Сүз арасында автор җәдитчелек мәсьәләсен яңадан карау максатын да куя. Китапның бу мәсьәләгә кагылышлы төп пафосы җәдитчелек ул пантюркизм, һәм беркайчан да прогрессив күренеш булмады, дигән раслауга кайтып кала. Әнә шул китап бездә татар иҗтимагый фикеренә «ревизия» ясарга сигнал булды.

1950 елда Ф. Мөсәгыйть Г. Халитның югарыда телгә алынган мәкаләләрен элеп алып селкеп салды һәм В. И. Ленинның «Без нинди мирастан баш тартабыз» исемле хезмәтен кылыч итеп, «җәдитчелек» дип йөртелгән бердәм агымны ике мөстәкыйль кисәккә аерып ташлады: мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек. («Совет Татарстаны», 1950, 15 ноябрь). Мәгърифәтчелекне сыйфатлауда ул, Герцен, Белинский, Чернышевскийны эталон итеп алып, җәдитчелекне төрлечә каралтып, мәгърифәтчелеккә каршы куйды. Әнә шул рәвешле ике нарат үсеп чыкты, һәм без һаман әле шулар арасында адашып йөрибез. Бу буталчык мәсьәләгә ачыклык кертү максатыннан алга таба без XIX гасырда мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек дигән ике мөстәкыйль агым яшәгән дип фараз кылырбыз. Җәдитчелек үсеп килә торган татар буржуазиясенең идеологиясе, ә мәгърифәтчелек демократик катлауларның, башлыча крестьяннарның, мәнфәгатьләрен чагылдырган агым булсын. Инде килеп, үз-үзебезгә мондый сорау бирик: татар либераль буржуазиясенең идеологиясе — җәдитчелек дөньяга чыгышыннан ук реакцион күренеш булганмы?

Иң элек В. И. Ленинга мөрәҗәгать итик: «Шуны онытмаска кирәк: XVIII гасыр мәгърифәтчеләре (гомуми танылган фикер аларны буржуазия юлбашчылары рәтендә күрә) язган вакытларда, безнең 40 нчы елдан 60 елларга кадәр булган мәгърифәтчеләр язган вакытларда, барлык иҗтимагый мәсьәләләр крепостное правога һәм аның калдыкларына каршы көрәшкә кайтып кала иде. Яңа иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр һәм аларның каршылыклары ул чакта әле яралгы хәлендә иде. Шуңа күрә ул вакытта буржуа идеологларда үз файдаларын кузәтү һич булмады. Киресенчә, Көнбатышта да, Россиядә дә алар бөтен кешенең рәхәттә яшәячәгенә тәмам чын күңелдән ышандылар һәм шуны чын күңелдән теләделәр, крепостной стройдан үсеп чыга торган стройдагы каршылыкларны чын күңелдән күрмәделәр».[3]

Ничек була инде бу, феодаль тәртипләрне җимерү чорында барлык илләрнең дә буржуа идеологлары, шәхси исәп-хисаптан азат булып, прогрессив эш башкарганнар, ә татар һәм бүтән төрки милләтләр буржуазиясе идеологлары — җәдитчеләр генә беренче адымнарыннан ук, тар сыйнфый мәнфәгатьтән чыгып, зарарлы эш кенә эшләгәннәр. Бәлки татар буржуазиясе үтә агрессив һәм реакцион булып, идеологларында аз гына да прогрессивлык табылмагандыр? Тагын В. И. Ленинны укып карыйк: «Изелгән милләтнең һәрбер буржуаз милләтчелегендә изүгә каршы гомуми демократик эчтәлек бар, һәм менә шул эчтәлекне без һичсүзсез яклыйбыз, ә милли аеручалык омтылышын һич уртаклашмыйбыз, поляк буржуазиясенең еврейләрне кысу омтылышына һ.б., һ.б. каршы көрәшәбез».[4] Бу сүзләр 1913 елда, Россия яңа революциягә таба барганда,

[2] Татар әдәбияты тарихы. Дәреслек-кулланма. Казан, 1926, 70 б.

[3] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 2 т. Казан, 1953, 498—99 бб.

[4] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 20 т. Казан, 1960, 417 б.

буржуазия һәм аның идеологлары революцияне булдырмас өчен бөтенесен дә эшләгән бер вакытта язылганнар. Әнә шул чорда да изелгән милләтләрнең буржуаз милләтчелегендә — димәк, җәдитчелектә — изүгә каршы гомумдемократик элементлар булган икән. XIX гасырның икенче яртысы турында исә сөйләп тә торасы юк. Татар пролетариаты ул чакта аз санлы һәм зәгыйфь иде, революцион ситуация әле юк, һәм татар буржуазиясенең иминлегенә беренче куркыныч янамый иде. Аны патша хөкүмәтенең милли-колониаль политикасы гына чикли, ул рус буржуазиясе белән конкуренциядән зыян күрә, татар тормышының үзендәге феодализм калдыклары аның үсешен тоткарлый иде. Шуңа күрә, изелгән милләт буржуазиясе буларак, ул, феодализм калдыкларына каршы көрәш белән генә чикләнмичә, курка-курка гына булса да, абсолютизмга да каршы чыгарга мәҗбүр була. «Реформачы татар буржуазиясе, шөбһәсез, самодержавиегә, аның каты режимына каршы иде. Чөнки үзе теләгәнчә киңәеп, үсеп китәргә хөкүмәт ирек бирми... Ләкин бу каршылык эчтән рәнҗү, үзара җыелып зарланулардан күп үтмәде»,— дип язды Г. Ибраһимов. (7 т, 266 б.)

XIX гасырның икенче яртысында татар либераль буржуазиясенең уку-укыту эшләрен юлга салудагы тырышлыгын да онытырга ярамый. Мәгълүм булганча, татар мәктәпләренә хөкүмәт бер тиен дә акча бирмәгән, шуңа күрә җәдит мәктәпләре татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары акчасына яшәгәннәр. Үз вакытында Г. Ибраһимов та җәдитчелек хәрәкәтенең материаль нигезен татар буржуазиясенең субсидиясе тәшкил итте дип әйткән иде. «Бу көрәшләре, хәрәкәтләре белән,— дип яза ул,— татар буржуазиясе безнең тарихи үсүләребездә тарихи бер вазифа үтәде»[5].

Милләт файдасына йөз меңнәрчә акча тоткан зур сәүдәгәр Әхмәт бай Хөсәенов болай дигән: «Ислам милләте мотлакан укырга вә язарга белсен, төркичә вә русча үгрәнсен, дин танымаган мөселман баласы калмасын, һөнәрсез вә ялкау мөселман азайсын, милләт эчендә дөрес белүче вә гакыллы дин галимнәре вә гүзәл холыклы зыялылар хаҗәт микъдарында улып торсын!»[6] Күренә ки, ярым-йорты грамоталы татар бае да кесә мәнфәгатеннән югарырак күтәрелә алган.

Эре буржуазия үзе үк тарих кушуы буенча феодализм калдыкларын бетерүгә, капитализмны үстерүгә һәм, димәк, ахыр чиктә тарихи прогресска көч биргән бер вакытта аның идеологлары саналган җәдитчеләр ничек инде XIX гасырда ук тоташ реакцион булсыннар? дигән сорау туа.

Г. Ибраһимов һәм тарафдарларының карашын аударып ташларга алынган иптәшләр, логика дигән нәрсә белән исәпләшмәстән, җәдитчелек өстенә әллә ничаклы гаеп өяләр. Җәдитчеләр, күрәмсең, пантюркист һәм панисламистлар булып, «татар һәм башка мөселман халыкларын Россиядән аерырга, аларны череп беткән төрек солтаннары империясенең бер кисәгенә әверелдерергә хыялландылар». («Совет әдәбияты», 1952, 5 сан, 52 б.) Җәдитчелекнең лидерлары Беренче рус революциясе чорында кадетлар программасын кабул иткән «Мөселман иттифакы» партиясен оештыруның инициаторлары булдылар. Балкан сугышы вакытында (1912-13) төрекләрне якладылар һ.б., һ.б.[7]

Ләкин бит бу «гөнаһ»ларның һәммәсе дә җәдитчеләрнең 1905 елдан соңгы эшчәнлекләренә карый! Хәтта пантюркизм да, И. В. Сталинның «Милли мәсьәләдә партиянең чираттагы бурычлары» дигән мәкаләсенә бирелгән искәрмәгә ышансак (С. Батыев нәкъ шуңа таяна), шактый соң барлыкка килгән күренеш. «Пантюркизм,— диелә анда,— барлык төрки халыкларны төрек хөкүмәтенә буйсындыруны максат итә. Балкан сугышы (1912-13) вакытында күтәрелгән хәрәкәт»[8].

Яхшы, килештек, җәдитчелек, икенче төрле әйткәндә, XX гасыр башы либераль-буржуаз милләтчелек хәрәкәте 1905 елгы революция барышында һәм аннан соңгы елларда бөтенләе белән реакцион булсын (В. И. Ленинның буржуаз милләтчелектәге демократик элементлар турындагы сүзләре яктылыгында карасак, бусының да шикле икәнен күрербез). Ә 1905 елга кадәр? XIX гасырның икенче яртысында? Ул чакта бит әле «Мөселман иттифакы» партиясе юк, политик агым буларак пантюркизм да дөньяга чыкмаган.

Госманлы империясенең изге туфрагына аяк басу турындагы «хыял»га кинәрәк туктalык.

Җәдитчеләрнең мөселман халыкларын, Россиядән аерып алып, Төркиягә буйсындырырга омтылулары турында яза башлауларына унбиш еллап бар инде. Әмма дәлилсез язалар, фактларсыз. Бүтәнчә була да алмый. Акылы камил булган нинди сәү-

---

[5] Ибраһимов Г. Имля, тел, әдәбият мәгьәләләре. Казан, 1924, 20 б.

[6] Фәхретдинев Р. Әхмәд бай. Оренбург, 1910, 26 б.

[7] Карагыз: Хасанов Х. Х. Революция 1905-07 гг. в Татарии. М., 1965, 58 б.; Батыев С. Татарский джадидизм и его эволюция.—«История СССР», 1964, 4 сан.

[8] Сталин И. В. Сочинения. Т. 5, М., 1952, 403 б.

дәгәр яисә фабрикант җайланган, юлга салынган сәүдәсен, предприятиеләрен ташлап Төркиягә күчәргә, төрек патшаларына буйсынырга теләсен?

Ярый, буржуазиянең күчеп китүе турында сүз була алмасын. Бәлки ул татар халкы яши торган төбәкләрне Төркиягә кушарга теләгәндер? Бусы да көлке. Бер-берсеннән меңнәрчә чакрым ераклыктагы ике территорияне кушу фикере аек акыллы нинди кешенең башына килергә мөмкин? Җитмәсә ул территорияләрнең берсе — Россия кебек бөек державаның состав өлеше. Аннан соң, кемгә кирәк бу эш? Буржуазиягә кирәкми, хезмәт ияләренә — бигрәк тә.

Болары — фараз итү, фикер йөртү. Ә тормышта? Тормышта да шулай ук. Җәдитчелекне тәнкыйтьләүчеләрнең берсе дә шушы көнгә кадәр Россиядәге мөселманнар яшәгән җирләрне аерып алып Төркиягә кушу юлында, яисә инде татарларны һәм башка мөселман халыкларын Төркиягә күчерү юнәлешендә эш алып баруны раслый торган фактларны архивтан яки матбугаттан алып күрсәтә алганы юк. Дөрес, охранка канцеляриеләрендә яки карагруһчыл рус газеталарында без җәдитчеләрне сепаратизмда гаепләүне күп табабыз. Ләкин җәдитчелекне яманлаучылар боларны күрмәмешкә салышалар.

XIX гасыр ахырында мөселманнар күпләп-күпләп Төркиягә күчеп киттеләр бит диюләре мөмкин. Әйе, мондый хәл булган. Башлыча, Кырым татарлары киткән. Ә 1897 елда, халык санын исәпкә алу вакытында бу психоз Идел буе татарларына да йоккан. Ләкин моңа җәдитчеләрнең катышы юк. Төп сәбәп — хәерчелек, җирсезлек, башлыча, чукындырудан курку, иске карашлы руханилар тарафыннан куертылган дини фанатизм.

Бу бәйләнештә «җәдитчелек»нең баш идеологы И. Гаспринскийның күчеп китүгә мөнәсәбәте гаять кызыклы. «Тәрҗеман» газетасы редакторы егерме ел буе мөселманнарның Төркиягә күчүенә каршы чыккан. Күпсанлы мәкаләләрендә ул күченүне халык башына килгән бәла дип саный, Россиядән сезне беркем дә кумый, Төркиядә беркем дә көтеп тормый, ди. Бер мәкаләсендә мондый юлларны укыйбыз: «Күчеп китү уен читкә атып, тормышны яхшырту юлларын туган йорттан, аналар һәм бабалар йортыннан эзләгез. Персиядә һәм төрек дәүләтендә тереклек итү, икмәк бирә торган һөнәр табу гадәттән тыш кыен». («Тәрҗеман», 1900, 12 октябрь.)

Патша чиновниклары һәм карагруһчыл публицистлар И. Гаспринский эшчәнлегенә шикләнеп караганнар, алай гына да түгел, аны панисламизм, пантюркизмда гаепләгәннәр. Шундыйларга җавап итеп И. Гаспринский болай дип яза: «Көнчыгышта чыннан да панисламизм идеяләре таратыла», әмма «россиялеләр моңа иярергә тиеш түгелләр дип уйлыйм». Россия мөселманнарын берләштерү мәсьәләләренә (пантюркизмга) килгәндә исә, моңа ихтыяҗ юк, чөнки алар инде «уртак чикләр, уртак законнар белән берләшкән. Телисез икән, дип дәвам итә ул, мин аларның үзара якынаюын тиеш табам, «чөнки безнең тоткан юл Россиядә яшәүче барлык кабиләләр арасында һәм аларның барысы белән руслар арасында бердәмлек һәм дуслык мөнәсәбәте урнаштыруга кайтып кала». («Тәрҗеман», 1898, 19 июль.)

Әгәр без җәдитчеләрнең 1905 елга кадәрге эшчәнлеген күздә тотсак һәм әлеге атамаларга аерылып чыгу мәгънәсе салсак, китерелгән фактлар яктылыгында без җәдитчеләрне панисламизм һәм пантюркизмда гаепләүнең нигезсезлеген ачык күрербез.

Җәдитчелеккә кара мөһер сугучылар тагын бер дәлилгә — Тукайның «Китмибез» исемле шигыренә ябышырга мөмкиннәр. Әнә бит, янәсе, күчеп китүгә чакыра торган кампания алып барылган, аның башында буржуаз милләтчеләр, ягъни җәдитчеләр торган. Бу дәлилнең нигезсезлеген аңлар өчен шигырьне игътибар белән уку да җитә.

*Кара йөзләр безне булмас эшкә тәкълиф иттеләр:*
*— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит!— диләр.*

«Сезгә» дигән сүзгә игътибар итик. Үзен халык хезмәтчесе дип игълан иткән милләтче бу сүзне әйтә алырмы? Сез китегез, мин калам, дигән мәгънә килеп чыга ич. «Без китәргә тиеш, безгә монда ирек юк», дип әйтер иде ул. Тукайның монда ирек һәм җир таләп иткән татарларны Төркиягә куган рус карагруһчыларына каршы чыкканлыгы ачык булса кирәк. Шигырьнең соңгы юллары да шушы фикерне ныгыта. Алары русча язылган: «Если лучше вам, туда сами пожалте, господа!» [9]

Җәдитчелекне баштанаяк реакцион күренеш итеп караучылар аның уку-укыту өлкәсендәге эшчәнлеген дә киметеп күрсәтергә, яисә бөтенләй юкка чыгарырга омтылалар. Б. Г. Гафуров, мәсәлән, җәдит мәктәпләре берниндн эз калдырмадылар, алар «...эш белүче приказчиклар әзерләү өчен генә» [10] ачылганнар иде, дип яза. Безнекеләр

[9] Бу шигырьнең Дәүләт думасы утырышында Пуришкевич һәм Келеповский кебек карагруһчыларның, чыгыш ясаучы татар депутатын бүлдереп, «Әнә Төркиягә китегез!» дип кычкырулары уңае белән язылганлыгы күптән исбат ителде (1987 елгы искәрмә).

[10] Гафуров Б. Г. История таджикского народа в кратком изложении. М., 1949. 451 б.

аңа иярделәр. «Курсави һәм Хөсәен Фәезханов кебек реформаторлардан аермалы буларак,— дип язды С. Батыев,— җәдитчеләр татар капитализмының мәнфәгатен күзәтеп, яңа метод белән укыту мәктәпләрен күбәйтүгә көч куйдылар. Алар татар буржуазиясенең социаль заказын үтәделәр». («История СССР», 1964, 4 сан.) Димәк, җәдитчеләр Курсави һәм Мәрҗани кебек дин реформаторларыннан да «кайтышрак» булганнар, яңа тип мәдрәсәләр булдырып бер адым артка чигенгәннәр. Җәдит мәдрәсәләрен болай хурлау белән наданлык һәм фанатизм учагы булган иске мәдрәсәләрне өстенрәк санауга барып җитәргә мөмкин. Патша чиновниклары яңа метод белән укыта торган мәктәпләрнең хәвефле икәнен сизеп алып, нәкъ менә иске мәдрәсәләрне яклау һәм саклау юлына басканнар иде.

Шулай итеп, феодализм калдыклары белән көрәш төп бурыч булган чорда татар буржуазиясе идеологлары, ягъни җәдитчеләр, тар сыйнфый мәнфәгатьләр кысасында калмыйча, объектив рәвештә прогрессив эш башкардылар. Аларның эшчәнлеген, 1905 елга кадәрге һәм аннан соңгы ике чорга бүлмичә, бөтенләе белән реакцион дип бәяләү, соңгы чордагы «гөнаһ»ларын сылтау итеп, XIX гасырдагы файдалы эшчәнлекләрен юкка чыгару тарихилык принципларына, фәнгә каршы килә.

Ышандык булса кирәк, 1905 елга кадәр җәдитчеләр гаеп санарлык берни дә эшләмәгәннәр. Шулай булгач, җәдитчелек белән мәгърифәтчелек арасындагы аерма нәрсәдә? «Нарат»ның икенчесе ясалма түгелме?

Әгәр дә без «җәдитчелек» идеологы И. Гаспринскийның 1905 елга кадәрге уңай программасы белән танышсак, Беренче рус революциясенә кадәр мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек дигән ике агым ясарга һәм аларны бер-берсенә каршы куярлык нигез юклыгына тәмам ышанырбыз.

20 ел дәвамында «Тәрҗеман» газетасының игътибар үзәгендә яңача, аваз методы белән укырга-язарга өйрәтү һәм мәктәпләргә фән кертү мәсьәләләре тора. И. Гаспринский, моннан тыш, җир эшкәртүне яхшырту, сәүдә һәм промышленностьны күтәрү өчен фәннәрне үстерүнең кирәклеге мәсьәләсенә йөзләрчә мәкалә һәм корреспонденция багышлаган. Түбәндәге сүзләрне нәкъ менә ул язган: «Бөек кешеләр дигәндә без төрле заманнарда дөньяны канга һәм күз яшенә батырган атаклы басып алучыларны күздә тотмыйбыз... Дөньяның чыннан да бөек кешеләре алар — пар машинасын, локомотивны, пароход, телеграфларны уйлап тапкан, газаплы авырулардан дәва, дару ясаган яки акыллы фикерләр һәм омтылышлар үрнәге биргән гади кешеләр». («Тәрҗеман», 1890, 14 ноябрь.) «Мәгърифәтчеләр» дә, башлыклары Каюм Насыйри да шулай уйламаганмыни?!

Фәнни-техник прогрессны, И. Гаспринский фикеренчә, ничек тормышка ашырырга мөмкин? Моңа бер генә юл бар. Ул да булса — Европадан өйрәнү, аеруча рус фәнен һәм культурасын үзләштерү. Моның өчен исә иң элек рус телен өйрәнергә кирәк. («Үз хокукларыңны белү һәм аларны яклау һәм саклау өчен Россиядә русча белү тиеш»— «Тәрҗеман», 1889, 20 сентябрь). «Тәрҗеман» редакторы мөселман мәктәпләренә рус телен өйрәнүне кертү өчен дә армый-талмый көрәшә. Мөселманнар өчен махсус ачылган хөкүмәт мәктәпләреннән качмаска өнди, рус һөнәр мәктәпләренә, гимназияләргә, университетларга керергә чакыра. Ниһаять, И. Гаспринский русчадан тәрҗемә итүне даими рәвештә хуплый һәм бу эшне тагын да көчәйтергә чакыра. «Россиядә, табигый, рус әдәбиятыннан югарырак әдәбият юк,— дип яза ул.— Шуңа күрә Россиядә яшәүче кабиләләрдә милли әдәбиятка ихтыяҗ булса да, рус әдәбиятына ихтыяҗ тагын да зуррак». Төрки халыкларны Пушкин, Лермонтов, Гоголь, Толстой әсәрләре белән таныштыру, аныңча, гаять кирәк эш.

Тагын бер кызыклы фактка тукталып үтәсе килә. Татар мәгърифәтчелеге һәм җәдитчелеге, башлыча, әдәбият галимнәре тарафыннан әдәбият күзлегеннән карап өйрәнелеп килде. Бу аңлашыла да: урта гасырчылыкка каршы көрәшүчеләрнең иң күренекле вәкилләре язучылар иде. Әдәбият белемендә мәгърифәтчелек төшенчәсе килеп кергәч, җәдитчелек лагереннан иң элек К. Насыйри алынды һәм «штаты әле тутырылмаган» юнәлешнең башлыгы дип игълан ителде. Вакансияле урыннар берәм-берәм шул ук лагерьдан күчерелгән Г. Ильяси, Ф. Халиди, З. Бигиев һәм башкалар хисабына тутырылды. Шундый көн килде ки, җәдитчелекнең XIX гасырда иҗат иткән бер язучысы — М. Акъегет-задә генә калды. Әмма 1957 елда М. Х. Гайнуллин шушы «соңгы могикан»ны да мәгърифәтче дип игълан итте[11]. Мәзәк хәл туды: XIX гасыр җәдитчелек әдәбиятын хурлыйбыз, фаш итәбез, ә аның бер генә язучысы да, бер әсәре дә юк! Феодализм һәм клерикализмга каршы юнәлгән хәрәкәтне бер-берсенә дошман ике лагерьга бүлүчеләрнең позицияләре ныклы булмауны күрсәтмиме бу?

Әгәр андый ике лагерь һәм алар арасында килешмәүчән каршылык булса, көрәш барыр, бәхәс кызар иде. Әмма мондый хәлнең булганы юк, һәрхәлдә мәгърифәт-

[11] Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан, 1957.

челәрне җәдитчеләр белән «кычкырыштырырга» теләүчеләр үз карашларын расларлык бер факт та китерә алмыйлар. Хәер, К. Ф. Фасеев бер факт «тапкан». «1883 елгы календаренда Насыйров әйтә,— дип яза ул,— «бакчасарайныкылар», ягъни Гаспринский һәм башка җәдитчеләр, аннан көлгәннәр, аның татарларга рус теле өйрәтү эшчәнлегенә кимсетеп караганнар»[12]. Чынлыкта көлмәгәннәр дә, кимсетеп тә карамаганнар. Календарьның үзендә болай диелгән: «...гайре телдән ят сүзләр катыштырып сөйләшмәкемездән Бакчасарайда көлделәр». (Календарь. 1883 елгы, 28 б.) Күренә ки, сүз бөтенләй башка нәрсә турында бара.

Мәгърифәтче һәм җәдитчеләр арасындагы фикер берлеге, бер-берләренә булган симпатия турында сөйли торган фактларның исәбе-хисабы юк.

Мәгърифәтчеләр дип игълан ителгәннәрнең Гаспринскийга мөнәсәбәтеннән башлыйк.

Менә мәгърифәтчелек лагерена иң соңыннан күчерелгән М. Акъегет-задәнең «Хисаметдин менла» повестендагы баш герой — яңа метод белән укытучы идеаль хәлфә, күз яшьләрен йота-йота, «Тәрҗеман» газетасы укый. Гаспринскийның милләт язмышы турындагы сүзләре аңа шулай тәэсир иткән. Укуын дәвам иттерә алмыйча, «Афәрин, Исмәгыйль кардәшем»,— дип, газетаны читкә куя. Инде менә «ортодоксаль» мәгърифәтче Заһир Бигиевның Гаспринскийга мөнәсәбәте. «Тәрҗеман» редакторына ул түбәндәге хат белән мөрәҗәгать иткән: «Галиҗәнап мөхәррир әфәнде! Бакчасарайга баргач, миңа Кайтазан мәхәлләсендә сез нигезләгән җәдит мәктәбендә булырга туры килде. Мәхмүт әфәнде тарафыннан яхшы кабул ителгәнлегем хәлдә, мин бу уку йортында берничә сәгать булдым. Балаларның уңышы мине таң калдырды. Моннан сигез ай гына элек мәктәпкә йөри башлаган балалар татарча иркен укыйлар, язалар, Коръән укыйлар, арифметиканы, гыйльми хальне һәм география буенча башлангыч төшенчәләрне нигезле үзләштерәләр» («Тәрҗеман», 1891, 31 октябрь). Ә 1893 елда «Тәрҗеман»ның 10 еллыгы уңаеннан З. Бигиев котлау белән бергә газета файдасына 10 сум акча җибәргән.

Шактый өлеше соңрак революцион-демократия лагерена күчәчәк икенче буын мәгърифәтчеләре дә «Тәрҗеман»нан башлаганнар. Алар укый ала торган беренче газета шул «Тәрҗеман» булган, ул аларның күзен ачкан. «Закир Һади,— дип яза М. Х. Гайнуллин,— «...даими рәвештә «Тәрҗеман»ны укыган, анда күтәрелгән мәсьәләләр белән кызыксынган»[13]. Бу фикерне «Мәгъсүм» исемле повесте да раслый. Аның герое — идеаль шәкерт Исмәгыйль бәкнең «Ике батыр» исемле брошюрасын җылый-җылый укый. Шакир Мөхәммәдев, Галиасгәр Камал, Габдулла Тукай турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Фатих Әмирхан да, малай чагында ук, «Тәрҗеман»ның чираттагы санын түземсезләнеп көтеп алып, баштагы игъланнарыннан соңгы имзасына кадәр җентекләп укып чыга торган булган. «Минем белән бер партада утыручы балалардан мондыйлар күп иде,— дип өсти ул.— Вакытында зурлардан да мондый «Тәрҗеман» шәкертләренең булганлыгын беребез дә инкарь итә алмыйбыз» («Әльислах», 1908, 25 март).

Революцион-демократик позициягә баскан Ш. Мөхәммәдев «Хан кызы» исемле китабын хәтта 1908 елда И. Гаспринскийга багышларга һәм кереш сүзендә бу шәхеснең фидакарь эшчәнлегенә югары бәя бирергә мөмкин дип тапкан.

Сизеп торам, бу фикергә оппонентлар Тукайның «Тәрҗеман» һәм аның редакторын кискен тәнкыйть иткән фельетоннарын искә төшерергә ашыгалар. Әйе, «Шартлар» фельетонында Тукай «Мөселман иттифакы» партиясен яклаганы өчен И. Гаспринскийга очып куна. Әмма бу Гаспринскийның Беренче рус революциясе чорындагы эшчәнлегенә карый. Без исә аның 1905 елга кадәрге карашлары турында сүз алып барабыз. «Тәрҗеман»ның татарларга галякасы» исемле икенче фельетонында Тукай, татарларның 25 ел соңрак уянуларына сәбәп булды дип, газетаның хезмәтен бөтенләй сызып ташлый. Монда «Таң йолдызы» һәм үзе эшләгән «Фикер» газетасын тәнкыйтьләгәне өчен «Тәрҗеман»га нык ачуланудан килеп чыккан арттырып җибәрүне күрми мөмкин түгел. Әмма фельетонның азакгы юлларына игътибар итик. Тукай, беркадәр үз-үзенә каршы килеп, болай ди: без «ак күмәч булмаганда ипи ашаган һәм кыйбатлы тәмәке булмаганда — махорка чорнап тарткан төсле генә «Тәрҗеман»ны укыдык»[14]. Димәк, «Тәрҗеман» таш булмаган, кара булса да ипи булган. Бер генә ел элек ул: «Тәрҗеман» бу милләтнең дәрдене улсын тәрҗеман,— дип, газетаны хуплап язган иде ич.

«Тәрҗеман» һәм Гаспринскийга иң объектив бәяне үз заманында Ф. Әмирхан биргән. Ул «Тәрҗеман»ның Россия мөселманнарына сәяси яктан файдасы күп булмады

---

[12] Фасеев К. Ф. Из истории татарской передовой общественной мысли. Казань, 1955, 55 б.

[13] Татар әдәбияты. XX йөз. Казан, 1947, 22 б.

[14] Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 3 том. Казан, 1985, 235-236 бб.

дип саный. Сәбәбен Гаспринскийның, зззәрләкләуләрдән куркып, артык сак кылануында күрә. «Лакин,— дип яза ул,— «Тәрҗеман» газетасының миллатебезнең ни надан вә мөтәгассыйп вакытында мәктәпләремез ислахына иткән хезмәтләрен генә назар дикъкатькә алганда да: «Тәрҗеман» чирек гасыр үз җилкәсендә авыр йөк тартып килгән диярга мәҗбүрмез» («Әльислах», 1908, 25 март).

Монда шуны искә алырга кирәк: «Тәрҗеман»ның политик юнәлешен кабул итмәүләре (Тукайның — кискен, Ф. Әмирханның — йомшаграк)— Беренче рус революциясе барышында татар иҗтимагый фикеренең яңа баскычка күтәрелүе нәтиҗәсе. Аларның игътибар үзәгендә — газетаның XX гасырның башындагы политик юнәлеше.

«Тәрҗеман» үзе безнең мәгърифәтчеләргә нинди мөнәсәбәттә иде? Шулай ук уңай мөнәсәбәттә. Каюм Насыйриның барлык китапларына да, мәсәлән, уңай бәя бирелә. Бер мәкаләсеннән түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Насыйров әфәнде — яхшы гарәпчә, русча башлангыч белем алган. Шуңа карамастан, моңарчы дөньяви һәм әдәби китаплардан мәхрүм торган миллаттәшләренә ул егермегә якын төрле-төрле әсәр һәм тәрҗемә эшләп бирде. Игенчелек турындагы китабы өчен аңа аеруча рәхмәт» (1892, 10 декабрь). З. Бигиев әсәрләрен дә мактап яза. Телен «урам теле» дип яратып бетермәсә дә, Гаспринский Г. Камалның беренче пьесаларын да хуплаган.

Икенче буын «җәдитчеләр» Р. Фәхретдинев, Ф. Кәрими һәм «мәгърифәтчеләр» Ш. Мөхәммәдев, З. һади арасында да ызгыш күзәтелми. Ш. Мөхәммәдев «Шаркый рус» газетасында, мәсәлән, Р. Фәхретдиневнең «Мәшһүр хатыннар» исемле китабын күккә чөеп мактый.

Бу — «җәдитчеләр» һәм «мәгърифәтчеләр» арасында 1905 елга кадәр фикер берлеге яшәгәнлеге, аларны аеру өчен 50 нче еллар башында корылган койманың саламнан гына икәнлеге турында сөйләмиләрме? Ул фактлар Г. Ибраһимов һәм фикердәшләренең нигездә хаклы булганлыкларын расламыймы? Хәер, тарих һәм әдәбият белеме дә соңгы елларда 1905 елга кадәр феодализмга каршы лагерьның бердәмлеге турындагы фикергә таба авыша бара. 1957 елда ук инде М. Х. Гайнуллин, мәсәлән, XIX гасыр җәдитчелегенең прогрессив ролен, кыюсыз гына булса да, билгеләп үткән иде.

Шулай итеп, тәмам ышандык бугай: 1905 елга кадәр татарларда феодализмга каршы юнәлтелгән бер генә хәрәкәт булган. Соң бу юнәлешне ничек дип атарга? Г. Ибраһимовтан күчермә алып, «җәдитчелек» дипме? Бу атаманы кабул итсәк, кыенлыкларга юлыгачакбыз. Феодализмга, крепостнойлыкка һәм аның калдыкларына каршы юнәлгән хәрәкәт буларак мәгърифәтчелек дөньяның күп кенә илләрендә, шул исәптән, Россиядә бар иде. Соң җәдитчелек нәрсә? Дөньядагы нинди иҗтимагый күренешкә туры килә ул? Мәсьәләне болай кую конкрет күренешләрне мәгълүм схемаларга буйсындырырга тырышу итеп каралмаска тиеш. Чөнки барлык халыклар да, гомумитарихи закончалыкларга буйсынып, үсеш-үзгәрешнең бер үк төсле баскычларын, этапларын үзалар. Аерма булса да, вакыйкаларда, бер халәттән икенче халәткә күчеш формаларында гына. Иҗтимагый хәрәкәт һәм иҗтимагый фикердәге охшаш күренешләр әнә шуннан килеп чыга. Татарлар һәм Урта Азия белән Кавказда яшәүче халыклар, әйтик, Көнбатыш Европаның бер генә халкында да булмаган юлга — җәдитчелек юлына кереп киттеләрмени? Бу бит мөмкин түгел! Феодализм җимерелүгә йөз торган чорда татарларда мәгърифәтчелек булмау акылга сыймый.

Ачык булса кирәк, Г. Ибраһимовның «җәдитчелек» дигәне мәгърифәтчелектән бүтән нәрсә түгел. Бит ул елларда «мәгърифәтчелек» атамасы бөтенләй кулланылмаган.

Ризасызлык белдергән тавышлар ишетәкәндәй булам: ничек инде җәдитчеләрне В. И. Ленин Н. Г. Чернышевский карашларына таянып сыйфатлаган мәгърифәтчеләр белән бер тактага куярга мөмкин? Әйе, «Без нинди мирастан баш тартабыз» дигән мәкаләсендә В. И. Ленин, исемен атап әйтмәсә дә, Чернышевскийны мәгърифәтчелекнең типик вәкиле итеп саный. Әмма ул мәгърифәтчеләргә хас өч сыйфатны буржуаз экономист Скалдин әсәрләрен анализлаудан чыгара. Димәк, Чернышевский гына түгел, В. И. Ленинның үзенең сүзләре белән әйтсәк, әлеге «буржуа» да мәгърифәтче икән. Шулай булмаса, Ленин мәгърифәтчелеккә билгеләмә биргәндә аның әсәрләренә таяна алмас иде. 60 нчы еллар өчен Скалдинның типиклыгына шикләнмәсләрен алдан белгәндәй В. И. Ленин искәрмә бирә, ә анда түбәндәге сүзләр бар: «Эш барлык мәгърифәтчеләр өчен уртак булган һәм Скалдин да уртаклаша торган карашларда»[13].

Күренә ки, мәгърифәтчеләр дә төрле булган кебек, ул дәрәҗәгә ирешмәгәннәре дә бар икән. XVIII гасыр рус мәгърифәтчеләре һәм Скалдин тибындагы буржуаз мәгърифәтчеләр соңгыларына мисал була алалар. XIX гасырның икенче яртысында татар җәмгыятендәге феодализм калдыкларына каршы юнәлгән бердәм иҗтимагый хәрәкәт тә әнә шул типтагы мәгърифәтчелек, асылы белән буржуаз, шулай да мәгърифәтчелек иде.

Инде болай диюләре мөмкин: идея җитәкчеләре Гаспринский булган җәдитчеләрне мәгърифәтче ясау дөрес булырмы? Гаспринский бит капитализмны үстерүгә, буржуазияне күтәрүгә көч куйган, яңа метод белән укыта торган мәктәпләрдә дини тәрбия бирүне дә күздә тоткан, динне фән белән яраштырырга тырышкан, төрек теленә якын ясалма телне пропагандалаган, ниһаять, аның газетасы, дәүләт строена хәерхаһ булып, патшага һәм хөкүмәткә каршы бер сүз дә әйтмәгән.

Яхшы, болар барысы да шулай. Безнең танылган мәгърифәтчеләребез дә шулай түгелме? 1883 ел календарендә К. Насыйри, мәсәлән, кырык өч сәүдәгәр турында мәгълүмат бирә, аларны яхшы яктан сыйфатлый, үз акчаларына мәчет һәм мәктәпләр салдырган өчен ихластан мактый. Яки менә демократ Ш. Мөхәммәдевне алыйк. Үзенең повестьларында татар сәүдәгәрләрен ул башлыча эшне искечә алып барулары, фән-техника казанышларыннан җитәрлек файдаланмаулары өчен тәнкыйтьли. «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе» исемле повестенда идеаль фабрикантны мондыйларга каршы куя. Бусының эше майлагандай бара, акчасы һәм эшчәнлеге белән ул милләткә күп файда китерә.

Әйе, Гаспринский, Курсави һәм Мәрҗани эзеннән барып, динне чыннан да яңа шартларга яраклаштырырга, дини идеология биләмәләреннән фән өчен плацдарм яулап алырга һәм киңәйтергә теләгән. Дин белән арасын бөтенләй өзсен иде, динкме? Күпне таләп итәбез! Тагын К. Насыйрига мөрәҗәгать итик. Бөтенләе белән дин өйрәтмәләренә нигезләнеп әхлак турында китаплар язган кеше ул түгелме? Пәйгамбәрләр тарихы һәм ислам диненең бердәнбер хак дин икәнен исбат иткән әсәр аның каләменнән чыкмаганмы?[16]

Инде килеп, И. Гаспринскийның «патшага тугрылыгы» хакында. Аны демократ ясарга җыенучы да юк. Ул, башка халыкларның мәгърифәтчеләре шикелле үк, мәгърифәтле яисә конституцион монархия идеясеннән югары күтәрелә алмады. Казах халкының типик мәгърифәтчесе Абай турында Мохтар Ауэзов, мәсәлән, менә нәрсә яза: «Әхлак мәсьәләләрен аңлаткан чагында динчелек элементлары үзен сиздерә, монархия строен ул тияргә ярамый торган нәрсә итеп карый».[17] Яки менә таҗик мәгърифәтчелегенә нигез салучы Әхмәт Дониш «мәгърифәтле монарх турындагы утопик лозунгка мөрәҗәгать итеп, әмирне халыкны агартуның файдасына «ышандырсаң», Бохара чынбарлыгын үзгәртеп корып булачак»[18], дип ышанган. К. Насыйри турында да шуны әйтергә мөмкин. Календарьларының һәр санында ул патша гаиләсе һәм якыннары турында түбәнчелекле мәгълүматлар биреп бара.

Ниһаять, әдәби тел мәсьәләсе. Бу мәсьәләдә К. Насыйри белән И. Гаспринский чынлап та икесе ике карашта торганнар. Тик шунысы бар: И. Гаспринский алга сөргән тел «Тәрҗеман»ның 1903 елга кадәр төрки халыкларга хезмәт итә торган бердәнбер газета булуы белән аңлатыла. «Баштан ук без үз өстебезгә бик авыр һәм җаваплы бурыч алдык,— дип яза «Тәрҗеман» редакторы,— Касимнан Кашгарга кадәр барлык халыклар да аңларлык итеп язарга кирәк иде»— (1905, 4 ноябрь). Телгә ике төрле караш — И. Гаспринский белән К. Насыйри карашлары — мәгълүм бер вакытка кадәр килешеп яшәгәннәр.

Күренә ки, 1905 елга чаклы И. Гаспринскийның мәгърифәтче, дөрес, буржуаз, ләкин мәгърифәтче булуы бер дә гаҗәп түгел. Р. Фәхретдинев һәм Ф. Кәрими кебек «җәдитчеләр» турында исә сөйләп тә торасы юк.

Шулай итеп, кабатлап әйтәм, 1905 елга кадәр татарларда феодализм калдыкларын йолкып ташлауга юнәлдерелгән бер гомуми хәрәкәт кенә бар иде, һәм аны, һичшиксез, мәгърифәтчелек дип атарга кирәк, «Җәдитчелек» дигән терминны исә мәктәп реформасы өчен көрәшкә атама итеп калдыру кулай булыр.

Әмма шул гомуми хәрәкәттә абсолют бердәмлек хөкем сөргән дисәк, бу — хакыйкатькә туры килеп җитмәс иде. Әйтик, К. Насыйри белән И. Гаспринский, Р. Фәхретдинев белән З. Һади, Ф. Кәрими белән Ш. Мөхәммәдевләрнең аң-тойгылары, яраткан һәм яратмаган нәрсәләре арасындагы аерманы күрми мөмкин түгел. Гаспринский күңеленә, мәсәлән, әзербайҗан миллионеры Тагиев яисә фабрикант Акчуриннар якынрак булган. (Акчуриннарның берсенә ул кияү тия). Р. Фәхретдинев һәм Ф. Кәрими дә субъектив яктан алтын прискасы хуҗалары Рәмиевләргә күңел куйганнар. К. Насыйри, Ш. Мөхәммәдев һәм З. Һадиларга килгәндә, аларның йөрәге башлыча крестьяннар һәм шәһәр ярлылары, приказчик һәм шәкертләр өчен сызлаган.

---

[15] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 2 т. Казан, 1955, 498 б.

[16] Әхлак рисаләсе, Казан, 1890; Тәрбия китабы, Казан, 1891; Мохтасар тәварих әнбия, Казан, 1884; Гаканд рисаләсе. Казан, 1882.

[17] Мысли разных лет. Алма-Ата, 1961, 153 б.

[18] Гафуров Б. Г. Телгә алынган китабы, 452 б.

Ләкин баштагылары, күреп үткәнебезчә, ул чакта әле буржуаз чикләнмәгән һәм тар интерес белән яшәмәгән булып, гомум милләт турында уйлыйлар, чын күңелдән прогрессны яклыйлар, чын күңелдән милләтнең барлык катлауларының, шул исәптән ярлыларның ярыйсы гына мул һәм культуралы тормышта яшәүләрен телиләр иде. Соңгылары исә халык массаларының мәнфәгатен барыннан да өстен куйган хәлдә, дөньяга карашларының татар тормышында сыйнфый каршылыкларның җитлекмәгән булуыннан һәм дини-схоластик тәрбия алуларыннан чыга торган артталыгы сәбәпле, халыкның бәхетен һәм иминлеген тулаем милләтнең фәнни-техник һәм культура ягыннан күтәрелеше белән бәйләп карадылар. Ә мондый күтәрелештә, алар фикеренчә, татар капиталы җитди роль уйный. К. Насыйри, Ф. Халиди, Г. Ильяси, Ш. Мөхәммәдев кебекләрнең «мәгърифәтле» татар байларына «симпатиясе» әнә шуның белән аңлатыла (культура чараларына акчаны алар бирми кем бирсен?)

Сыйнфый симпатия һәм антипатияләре субъектив яктан туры килмәсә дә, әйтелгән сәбәпләр аркасында, «җәдитчеләр» белән «мәгърифәтчеләр» бергә бардылар. Бердәм хәрәкәт эчендәге ике тенденция исә билгеле бер вакытка кадәр яралгы хәлендә яшәде.

Әлеге тенденцияләр беренче тапкыр 1901 елда әдәби тел мәсьәләсе уңае белән үзләрен сиздерде. Г. Иманаев шул елны «Казан мөселманнарының язмалары» исемле мәкалә белән чыга, һәм болай дип белдерә: «Казан мөселманнарына атап чыгарылган китаплар, безнең фикеребезчә, саф Казан телендә язылган булырга тиеш. Менә ни өчен без И. Гаспринскийның татар телен «урам теле» дип атавы һәм бозылган татар телендә язарга чакыруы белән килешә алмыйбыз». («Волжский вестник», 1901, 13 январь.)

Мәгърифәтчелек хәрәкәтендәге либераль-буржуаз һәм демократик тенденцияләр арасындагы фикер каршылыгы 1903 елдан соң бигрәк тә ачык күренде. Бу хәл пролетариатның революцион көрәштә активлашуы, 1903 елда Бакуда, Тифлиста, Батумида булып узган зур стачкалар, анда «мөселман» эшчеләренең катнашуы, Баку, Казан, Уфа, Оренбург кебек «мөселман» үзәкләрендә марксизм идеяләренең таралуы белән бәйле иде. 1905 ел алды елларында революцион күтәрелеш һәм марксизм-ленинизм идеяләре тәэсирендә Закавказье һәм Идел буеның демократик элементлары да, җанланып китеп, көрәшкә тартылдылар.

Әнә шуның чагылышы буларак, Кавказда «Шәркый рус» исемле газета мәйданга килде (1903). Редакторы дөньяга карашы ягыннан демократ Мөхәммәт Шахтахтинский иде. Беренче көннәреннән үк газета, байлар мәнфәгатен күзәтүдә гаепләп, «Тәрҗеман»га һөҗүм итә башлады. Соңгысы үз чиратында «Шәркый рус»ны мөселманнар тормышына таркаулык кертүдә гаепләде. Татарларның демократик даирәләрендә дә, «Тәрҗеман»нан суынып, «Шәркый рус»ка күңел баглау сизелә башлый.


Бүтәнчә була да алмый иде. Ул вакытларда инде «Тәрҗеман»ның тел мәсьәләсендә генә түгел, бәлки иҗтимагый-политик мәсьәләләрдә дә демократиягә каршы позициягә баса башлаганлыгы сизелә. 1903 елгы стачкалар турында белдерүендә ул менә нәрсәләр ди: «Заводларны һәм тимер юлны туктату гаять зур зарар китерә» (1903, 14 июль). «Шәркый рус» белән бәхәскә кереп, газета болай ди: «...ярым грамоталы һәм ярым ач массаларга хәзер фәлсәфә түгел, башлангыч белем, эш белү һәм хезмәт күнекмәләре кирәк» (1903, 11 август). Шул ук санда И. Гаспринский азәрбайҗан «радикал»ларының үз эшчәнлекләрен уку-укытуны җайга салу белән генә чикләргә теләмәүләренә карата үкенеч белдерә һәм болай дип өсти: «Әмма радикальлек Европада яхшы. Бездә ул фикер төрлелегенә һәм талашка гына китерә». 1905 елда «Тәрҗеман», туа алмый калган Булыгин думасы хакындагы манифест уңае белән, мөселманнарны дошманлык орлыгы чәчмәскә, «яшәп килүче идарә итү тәртипләрен җимермәскә» чакырды (17 февраль).

И. Гаспринский һәм аның тарафдарлары, шулай итеп, демократиягә каршы позициягә күчеп, буржуаз милләтчелек лагере барлыкка китерделәр. Гомуммәгърифәтчелек хәрәкәтенең Ш. Мөхәммәдев, Г. Камал, М. Гафури кебек демократик карашлы вәкилләре исә революция елларында формалашкан революцион-демократик лагерьга килделәр.

Татарларда гомуммәгърифәтчелек хәрәкәтенең «соңгы пәрдәсе» әнә шулай ябылды.

1966—1987.

## Уфадагы культурабыз истәлекләре



**Видинеевның җәйге театр бинасы.**

Пушкин һәм Новомостовая урамнары почмагы.

*А. Тимергалина рәсеме.*

# ҖӘЙГЕ ТЕАТР

Уфаның культура тормышында театр сизелерлек роль уйнаган. Ләкин XIX гасыр ахырына кадәр шәһәрдә профессиональ труппа да, театр өчен төзелгән махсус бина да булмый. Төрле шәһәрләрдән килгән профессиональ һәм һәвәскәр труппалар спектакль-концертларын төрле биналарда — Зур Себер кунакханәсе, Дворяннар собраниесе һәм төрле клуб залларында куялар. Шундый биналарның иң билгелесе 1894 елда спирт һәм сыра заводы хуҗасы Видинеев тарафыннан агачтан салынган җәйге театр бинасы була. Ул Пушкин һәм Спасская (хәзерге Новомостовая) урамнары почмагындагы бакча эченә салынган. Зур булмаган ике катлы бу бина театр-сәнгать сөючеләрнең яратып йөри торган урынына әверелә.

Кыш көне күбрәк өйдә утырган шәһәр халкы җәйге театр ачылуга анда агыла. Театрда музыкант А. Носыров җитәкчелегендәге оркестр даими уйнап тора, сирәк булса да татар көйләре дә башкарыла (Октябрь революциясенә кадәр оркестр өчен милли көйләр сирәк эшкәртелгән).

Театр спектакль-концертлардан бушап тормаган. Октябрь революциясеннән соң, 1918 елда театр бинасы Уфа шәһәр коммунасы карамагына күчә. Театр урнашкан бакчага А. В. Луначарский исеме бирелә. Шул заманның көндәлек матбугатыннан күренгәнчә, монда мәдәни тормыш гөрләп торган. 1918 елның 31 июлендә «Көрәш» газетасында басылып чыккан игълан да нәкъ шул хакта сөйли: «Уфа шәһәр коммунасының, элеккеге Видинеев бакчасы театрында Уфа татар эшчеләр союзы янындагы музыка-драма җәмгыяте татарча театр куя. Тамашага әлегә кадәр татар сәхнәсе вә матбугаты галәме күрмәгән «Асия», дүрт пәрдәлек драма куела. Мөхәррире Сәгыйт Сүнчәләй. Мәсъүл (җаваплы) мөдир Шамильский».

«Нур» труппасының талантлы артисты Гыйлаҗ Казанский 1922 елны Уфада «Үрнәк» исемле татар театры труппасын төзи. Бу труппа составында Б. Болгарский, Ш. Шамильский, М. Мәһдиев, Ә. Зөбәиров, Н. Якупов, З. Богданова, Н. Таждарова, Л. Сыртланова, М. Мирвәлиева кебек күренекле артистлар уйнаган. Әлеге талантлы артистлар тырышлыгы белән труппа зур полотнолы пьесалар куя.

Театр үзе генә түгел, ул урнашкан бакча да төрле милләт зыялыларының күрешү, очрашу урыны була. 1924 елда Уфага килгән классик язучыбыз Фатих Әмирхан да була бу бакчада. Әдип янында татар зыялылары җыелып әдәбият, сәнгать турында фикер алышалар. Җәйге бакчаның шифалы һавасы әдипкә уңай тәэсир иткән булса кирәк. Кунак булып төшкән якын дусты Гарифҗан Мостафинга күңеле күтәрелеп кайта. Бу очрашу-күрешүләрнең берсендә әдип хөрмәт иткән күренекле татар язучысы һәм галиме Риза Фәхретдинев тә була.

Җәйге театрда чит шәһәрләрдән килгән музыкантлар, артистлар да чыгыш ясаганнар. Казаннан килгән талантлы скрипкачы һәм фольклорчы Хәсән Гобәйдуллин, скрипкачы А. Попов, үзбәк артистларыннан Карый Якупов, Тамара ханым һ. б. сәнгать әһелләре халыкка рухи азык биргәннәр бу театрда.

Уфаның җәйге театр урнашкан төбәге, гомумән, зыялылар, сәнгать әһелләре яшәгән җир була. Бакчаның хәзерге Новомостовая урамы ягына караган капкасыннан чыккач тезелеп киткән йортларда татар, башкорт әдипләре, культура эшлеклеләре яшәгән. Күренекле язучыбыз Сәгыйт Рәмиев, артист Гыйлаҗ Казанский, журналист Фәрхи Әхмәров, шагыйрь Төхфәт Чәнәкәй, артист Әмин Зөбәиров, күренекле нашир Ильяс Бораганский, башкорт мәгърифәтчесе Мөхәммәтсәлим Өметбаев һ. б. Уфаның шушы гүзәл почмагында гомер иткәннәр.

Театрга 20 нче еллар уртасында А. В. Луначарский исеме бирелә. Хәзерге көндә бу бинада җәйге кинотеатр урнашкан.

*Х. Гобәйдуллин һәм Җ. Миңнуллин тексты.*




# АРЧА

Археологлар борынгы болгар-татар шәһәре Арчаның яшәү чорын XIII—XVI йөзләр дип билгелиләр.

1236 елда Болгар дәүләте җирләре яулап алучылар тарафыннан буйсындырылганнан соң ирек сөюче болгар халкы әледән-әле баш күтәреп, ирек даулап яши. Шундый баш күтәрүләрнең берсе 1278 елда була. Бу турыда Әбелгази Баһадур хан үзенең «Төрки халыкларның шәҗәрәсе» һәм татар халкының күренекле галиме Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» әсәрләрендә язып калдыралар. Әбелгази язмаларында мондый юллар бар: «1266—1282 елларда идарә иткән Алтын Урда ханы Мәнге Тимер Болгар иленә, баш күтәргән халыкны буйсындыру өчен бара һәм ике ел буена сузылган сугышлардан соң, болгар халкын кабат буйсындырып, җиңү белән кире кайта». Мәнге Тимер Болгар илендәге бу чуалышларны бетерү өчен кайбер рус кнэзьләренең ярдәменнән дә файдалана. 1278 елдагы баш күтәрүләрне бастыруда актив катнашкан рус кнэзе Федор Ростиславовичка хан үзенең кызын кияүгә бирә һәм аңа тагын 36 шәһәр бүләк итә. Алар арасында Чернигов, Корсун кебек шәһәрләр белән бергә Арча шәһәре дә телгә алына. Бу турыда «Степенная книга» дип аталган чыганакта әйтелә. Рус елъязмалары язуына караганда Вятка ушкуйниклары 1379 елда Арча җирләренә яу белән киләләр, ә 1496 елда Арча шәһәренә Мамук җитәкчелегендә нугайлар һөҗүм итә. 1552 елда Казанны алу вакыйгалары белән берлектә Арчаны һәм Арча кнэзен кнэзь А. Курбский да искә ала.

Арча шәһәре турында галимнәрнең төрле хезмәтләре билгеле.

Е. Малов, мәсәлән, «Иске Казан шәһәрлеге һәм Арча шәһәре» дип аталган мәкаләсендә (1853) Арча шәһәренең ныгытмасы һәм аның җиде манарасы булганлыгын, аларның һәрберсенең урынын, төзелешен тәфсилләп сыйфатлый.

В. Л. Борисов, Арча тирә-юнендә яши торган татарлар сөйләвенә нигезләнеп, бу урында борынгы заманнарда шәһәр булуын, башта аның Алтын Урда ханнарына, аннан соң Казан ханлыгына караганлыгын хәбәр итә. Ул, 1900 елда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләренең XVI томы 3 чыгарылышында урнаштырылган «Казан өязе Арча шәһәренең борынгы манарасы» дип исемләнгән мәкаләсендә үзе барып күргән, ул заманнарда кечерәеп калган Арчаның тарихи истәлеге булган агач манарасы турында сүз алып бара. Вакытлар үтү белән нык үзгәргән һәм җимерелгән, әле Казан ханлыгы заманнарында зур әһәмияткә ия булган бу манараның кайчан салынуын һәм нинди вазифа үтәгәнен ачыкларга тырыша. Арчаның гербы имән агачларыннан төзелгән өч манарадан торган һәм басу уртасына урнашкан ныгытма-крепость формасын тәшкил итә. В. Л. Борисов Арча шәһәренең әле дә шушы гербка охшашлыгын яза. Ләкин манараларның башкалары җимерелеп беткән һәм аның бары тик берсе генә сакланып калган.

Н. И. Второв бу манараның әле Казан ханлыгын руслар яулап алганчыга кадәр булган чорларда ук төзелгән булу мөмкинлеген искәртә, чөнки аның төзелеш формасы, архитектурасы борынгы чорларда салынган шундый ук корылмалар стиле белән охшаш дигән нәтиҗәгә килә. А. Артемьев та шундый ук фикерне куәтләгән. Ул Арчада борынгы вакытлардан калган җир ныгытманың — валның саклануы турында яза. Кайбер галимнәр манараны корал саклау өчен, икенчеләре исә каравыл максатыннан чыгып төзелгән дип уйлыйлар. Ләкин ни генә булмасын ул русларның Казан ханлыгын буйсындырганчы булган чорларда төзелгән. «Казан елъязмачысы» дигән тарихи чыганакта мондый юллар бар: «Ул кала Арча дип йөртелә, нык итеп шәһәрчә корылган, манаралары һәм бойницалары бар һәм анда кеше бик күп, шәһәрне яхшы саклыйлар, аның әле беркайчан да алынганы юк. Ул Казаннан 60 чакрым ераклыкта, бик нык һәм үтә алмаслык, чытырманлы-сазлыклы җирдә урнашкан. Аңа бары тик бер юл белән генә килеп яки чигенеп була. Воевода кнэзь Симеон күрде: моны алай җиңел генә алып булмый, халкы бик күп, гаскәре генә дә 15 мең; шуннан соң ул туплар һәм пищальләр китереп аттыра башлады». Р. Г. Фәхретдинов Арча Алтын Урда чорының икенче яртысында, ягъни XIV йөзнең ахырларында һәм XV йөзнең башларында барлыкка килгән дигән фикер үткәрә. Бу фикерен ныгыту өчен ул Арча шәһәрлегендә табылган Җучи акчасын да нигез итеп ала.

Арча шәһәре стратегик яктан караганда башка болгар шәһәрләре кебек үк уңайлы урынга утырган. Тау өстеннән караганда аның тирә-ягындагы җирләр уч төбендәге

кебек күренеп яталар. Шәһәрлек хәзерге Арча эшчеләр поселогының үзәгендә, «Мещаннар чиркәве» урнашкан урында булып, Казан суының уңъяк яр буе һәм зур, тирән чокыр аралыгындагы өчпочмак рәвешендәге мәйданны биләп тора. Казан юлы белән килеп, Казан суы аша салынган күперне чыккач та, каршыда шул ук шәһәрлек күренеп тора. Шул юл белән Арчага менеп җитеп, үзәк урамга кергәндә, уң яктагы тирән чокыр аша аның борынгы урлары күренеп тора. Бу өчпочмакның як-якларында элек агач стеналар сузылып, алар арасына 6—7 манара да төзелгән булган. XIX йөзгә аларның берсе өлешчә генә сакланып калган булган инде. XVIII йөздә ныгытма-крепость әле тулысынча сакланган булса кирәк, чөнки шул заманның билгеле галиме И. Георги аның турында агачтан төзелгән ныгытмалары булган, ачык урындагы кечерәк шәһәрчек дип язып калдыра.

Арча сүзенең ничек килеп чыгуы күп кешеләрне кызыксындыра. Тарихи әдәбиятта Арча арлар, ягъни удмуртлар шәһәре булган дигән фикер дә бар. Бу фикер белән килешмәвен белдереп, Р. Г. Фәхретдинов хаклы рәвештә «Казан ханлыгының үзәк җирендә удмурт шәһәре бөтен бер татар князьлегенең башкаласы була алмый. Арча тирәсендә хәзерге вакытта бер генә удмурт авылы юк һәм алар элек тә булмаган. Без Казан суы бассейнын, шул исәптән Арча якларын да бик җентекләп өйрәнеп чыктык, тик бер генә удмурт археологик истәлеге дә тапмадык»,— дип яза. Арча атамасының барлыкка килүен ул артыш үсә торган тауга мөнәсәбәтле итеп карый. Чөнки төрки халыклар телендә арча «артыш» мәгънәсендә кулланыла. Бу фикер игътибарга лаек, чөнки башка болгар шәһәрләре атамалары, әйтик Тубылгытау һәм Җукатау да үзләре утырган тауда тубылгы һәм җукә (әдәби юкә) агачлары үсүгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр. Арча исеме дә башка болгар шәһәрләре кебек үк шушындый юл белән ясалган булырга мөмкин.

1552 елда Иван IV гаскәрләре Казанны алганнан соң Арчага стрелецлар һәм казаклар китереп утыртыла. Арча ныгытмалары русларга җирле халыкларның һөҗүмнәреннән саклану өчен әһәмиятле роль уйнаган.

Арча исемен йөртә торган бистә Ульяновск өлкәсендә дә бар. 1649 елда Казан өязенең Арча шәһәреннән 50 казакны җир белән тәэмин итеп Сельд суы янына, Сембер ныгытылган линиясен саклау өчен күчереп утырталар. Арчадан күчү сәбәпле бу казаклар бистәләрен үзләре элек яшәгән шәһәргә нисбәтле рәвештә Арча (Арск) дип атыйлар. Соңыннан бу бистәдән тагын кече Арча дип исемләнгән авыл да аерылып чыга. Аны икенче төрле Кротовка дип тә йөртәләр.

1938 елдан башлап Арча эшчеләр поселогы категориясенә кертелгән. Анда хәзер кирпеч заводы милли аяк киемнәре фабрикасы һәм башка төрле хуҗалык предприятиеләре бар. Арча елдан-ел матурая, үсә бара. Уникенче бишьеллыкның берсеннән-берсе зуррак планнарын җиренә җиткереп үтәргә тырышалар арчалылар.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# Гарәп элифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Өченче дәрес


Узган дәрестә әйтеп узылганча, гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар язуының юнәлеше уңнан сулга. Шуңа күрә бу язу системасының башка график үзенчәлекләре һәм алымнары шушы төп кагыйдәгә нигезләнә. (Таблицада язу юнәлеше нечкә уклар ярдәмендә бирелде, ә хәреф элементларын язу тәртибе рим цифрлары белән күрсәтелде). Әмма һәрбер кагыйдәнең чыгармасы булган кебек язуның юнәлеше мәсьәләсендә дә кайбер чыгармалар, аерым үзенчәлекләр бар. Әйтик, нокталар (сүз куш нокта турында бара) һәм саннар кире юнәлештә — сулдан уңга языла. Бу — иске татар язуының аерылгысыз хосусияте. Дөрес, саннарның уңнан сулга язылган мисаллары да очраштыргалый (мәсәлән, кайсыбер борынгы кабер ташларында), ләкин болар бик сирәк һәм нормага хилаф күренешләрдән.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: иске язуыбыздагы берничә хәреф элементы уңга юнәлешле. Алар — җим (ج، چ، ح، خ) һәм гайн (ع، غ) хәреф шәкелләренең аскы өлешләре. Шуны ук йай хәрефенең, бигрәк тә бары тик кульязмада кулланылган «йай мәгъкүс» (кире йай) шәкеле (ے) турында да әйтергә мөмкин.

Гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар язуы (куфи һәм тәгълик дип аталган язу төрләреннән башкалары) сулга авыштырыбрак языла. Моны аеруча «әлиф» һәм «ләм» хәрефләрен язганда истә тотарга кирәк.

Язылыш тәртибенең төп кагыйдәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) башта хәрефнең нигез шәкеле языла, мәсәлән: ٯ، ح، ٮ h. б. Аннан соң гына тиешле нокталар куела: ق، ج، ت h. б. Хәрефләрне кушып язганда да шундый ук эзлеклелекне сакларга кирәк: әйтик, әүвәл ٯ، حا، ٮا кебек шәкелләр язылып, соңыннан тиешле нокталар куеп чыгыла: ق، خا، تا. 2) Күп ноктаны хәрефләрдән торган сүзләрне язганда ике юлның берсен сайлау мөмкинлеге бар: а) әүвәл барлык нигез шәкелләрне язып чыгып, соңыннан нокталар кую, мәсәлән: ٯامس — قامش؛ سالىداىو — شاپلداتو؛ ٯاىماٯ — قایماق h. б.) нокталарны сүзнең бер өлешен яки бер иҗеген язып бетергәч төртеп чыгу, мәсәлән: башта قا, аннан соң یماق; башта قا, аннан مش h. б. Каләмне кәгазьдән алмыйча языла торган сүзләрдә ( محبت؛ نتیجه h. б.), әлбәттә, беренче ысулны гына куллану мөмкин.

Иске татар язуында кулланылган гарәп хәрефләре язу юлы сызыгына нисбәтән урнашулары җәһәтеннән икегә бүленәләр: сызык өсте хәрефләре һәм өлешчә сызык асты хәрефләре (аерым һәм

| Язылыш тәртибе | Хәреф шәкелләре |
|---|---|
|  | Әлиф<br>Би-шәкел<br>Җим- һәм Гайн-шәкел<br>Рә- һәм Даль-шәкел<br>Син-, шин- һәм Съад-шәкел<br>Тый-шәкел<br>Фи-, каф- һәм Уау-шәкел<br>Кәф-шәкел<br>Ләм-шәкел<br>Мим-шәкел<br>Һи-шәкел |

азаккы рәвешләр алына). Сызык өсте хәрефләре: ا (آ)، ب، پ، ت، ث، (ە) ه، نک، ڭ، گ، ک، ف، ظ، ط، ذ، د. Өлешчә сызык асты хәрефләре: غ، ع، ض، ص، ش، س، ژ، ز، ر، خ، ح، چ، ج، ی، (ـهـ) ـه، و، ن، م، ل، ق. Хәрефләрнең баш һәм уртадагы рәвешләре һәммәсе дә диярлек (ـهـ) ـه، ژ، ز، ر) хәрефләреннән башкалары) сызык өстендә языла.

Иске татар алфавитында үзеннән соң килгән хәрефләр белән кушылмый торган хәрефләр дә бар: ا (آ)، د، ذ، ر، ز، ژ، و.
Бу — нигез кагыйдә. Шуның белән бергә кайбер язу төрләрендә — тәүкыйг, мөсәлсәл, дивани, бигрәк тә рикъка төрендә — әлеге хәрефләрне соңгыларына кушу үзенә күрә бер норма төсен алган. Безнең Идел буйларында таралган кайбер кулъязмаларда да әлеге күренеш теге яки бу дәрәҗәдә күзәтелә һәм моның сәбәбе күп очракта тиз язарга омтылу белән аңлатыла.

Язганда, билгеле, сүзләрне юлдан-юлга күчерергә туры килә. Бу очракта гамәлдә ике төрле эшләргә мөмкин: а) Сүзне күчергәндә, аны болай бүлү кулайрак — беренче өлеше сулдан кушылмый торган хәрефкә тәмамланырга тиеш, мәсәлән, «артык» сүзе آر һәм تق өлешләренә бүленә, багана сүзе با (яки باغا ) һәм غانا (яки نا ) рәвешендә күчерелә һ. б. Әгәр сүз бер-берсенә тоташкан хәрефләрдән торса, аны бүлеп күчерү отышлы түгел һәм бу хупланмый да, чөнки болай эшләгәндә язуның гомуми тәэсире бозыла. б) Күп кенә очракларда сүзне юлдан юлга гомумән күчермәскә мөмкин. Моңа ирешү өчен юлның ахыргы сүзләрен йә сузыбрак (иске язуыбызда моңа чикләнмәгән диярлек мөмкинлекләр бар), йә киресенчә кыса төшеп язарга кирәк. Бу алымнарны үзләштерү әллә ни кыен түгел, моңа даими күнегүләр ярдәм итәчәк. Мисаллар:

آرتـق - آرتق؛ تجـلق - تجلق؛ باغانـا - باغانا؛ قازان - قازان һ. б.

Басма китаплар белән кулъязмаларда нокта кую рәвешләрендә кайбер аермалык бар. Мәсәлән, кулъязмаларда ике ноктаны күпчелек вакытта кыска гына сызык рәвешендә куялар (—), яки зигзагсыман иттереп ٮ . Өч ноктаны кыска сызык һәм нокта итеп ـٓ , яки өтер рәвешендә ٩ куялар. Урта гасыр төрки-татар кулъязмаларында кайбер хәрефләрнең ноктлары куелышында түбәндәге үзенчәлекләр дә күзәтелә. Мәсәлән, с, п, г хәрефләренең астына һәм ш хәрефенең өстенә вертикаль юнәлештәге икешәр нокта кую очраклары бар. Кайбер кулъязмаларда ر (р) хәрефенең астына бер, ә س (с) хәрефенең астына өч нокта куеп язу очраклары күзәтелә.

Тәкъдим ителгән язу үрнәкләрен һәм сүзләрне укыгыз һәм күчереп языгыз. Күнегүләрне шакмаклы дәфтәргә язарга киңәш ителә.

*Дәресләрне Җ. Миңнуллин һәм Р. Кадыйров алып бара.*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

22 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы ачык җыелышы булды. Җыелышта сүз Татарстан язучыларының чираттагы XI съездына әзерлек турында барды. Әлеге сөйләшүдә Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, председатель урынбасары Г. Рәхим, партия оешмасы секретаре Р. Мостафин, язучылар Г. Бәширов, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Җ. Тәрҗеманов, Р. Хафизова, Э. Рәшитов, Р. Хәлиуллина, М. Галиев, Мансур Вәлиев, Ә. Гаффар һ. б. катнашты.

## АБДУЛЛА АЛИШ ИСТӘЛЕГЕНӘ

26 сентябрьдә Татар дәүләт академия театрының М. Горький урамындагы бинасында күренекле татар совет балалар язучысы Абдулла Алишның туына 80 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Җыелышны Татарстан культура министры М. М. Таишев ачты. А. Алишның тормышы һәм иҗат юлы турында доклад белән Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре, филология фәннәре кандидаты Рафаэль Мостафин чыкты. Соңыннан А. Алиш әсәрләреннән төзелгән концерт булды.

## ЧАЛЛЫДА «КАЗАН УТЛАРЫ» КӨННӘРЕ

5—7 сентябрьдә Чаллы шәһәрендә «Казан утлары» журналы көннәре булып узды. Татарстан Язучылар союзының партоешма секретаре Рафаэль Мостафин, шагыйрь Шәүкәт Галиев, «Казан утлары»ның баш редакторы Ренат Харис шәһәрнең завод цехларында һәм төзелеш мәйданнарында, мәктәпләрдә һәм тулай торакларда журнал укучылары белән очраштылар, аларны татар әдәбияты һәм сәнгате яңалыклары, үз әсәрләре белән таныштырдылар.

Чаллы язучылар оешмасында «Казан утлары» турында кызыклы сөйләшү булды. Фикер алышуда катнашып, язучылар Г. Кашапов, Р. Хисмәтуллин, Ф. Дунай, Н. Мадъяров, В. Имамов һәм башкалар журналда басылып чыккан әсәрләргә карата үз фикерләрен белдерделәр. Ике як өчен дә файдалы сөйләшүдә Татарстан АЭСын кору, яңа төзелешләр киң җәелдергән чорда Кама буе табигатен саклап калу мәсьәләләре дә кузгатылды.

Шундый ук кызыклы очрашу КПСС шәһәр комитетында да булып үтте. Шәһәрдә барлыгы 16 кызыклы очрашу узды.

## РЕДАКЦИЯ КУНАКЛАРЫ

СССР һәм Венгрия әдипләренең үзара иҗади бәйләнешләрен тагын да ныгыту максатында, илебезгә венгр шагыйрьләре килгән иде. Цецилия Байчи, Янош Хай, Карой Чех, Андрош Петец (Венгрия), Александр Бобров, Равиль Бохараев (Мәскәү), Далила Бедианидзе (Тбилиси) составындагы бер төркем шагыйрьләр безнең республикабызның тормышы, культурасы белән танышып йөрде. Алар Татарстан китап нәшриятында, Язучылар союзында, В. И. Ленин мемориаль музеенда, В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсендә, Арча районының Кырлай авылында татар халык шагыйре Габдулла Тукай музеенда булдылар.

22 сентябрьдә алар «Казан утлары» журналы редакциясендә кунакта булдылар. Анда сүз нигездә Татарстан һәм Венгрия арасындагы культура элемтәләрен тагын да ныгыту, венгр һәм татар язучыларының, шагыйрьләренең китапларын һәр ике телдә чыгару турында барды.

Журналның баш редакторы Ренат Харис кунакларның сорауларына җавап бирде.

## ТЮРКОЛОГЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

7—9 сентябрьдә Фрунзе шәһәрендә тюркологларның V Бөтенсоюз конференциясе үткәрелде. Аның эшендә барлык тюркология үзәкләреннән 450 дән артык галим һәм белгеч катнашты. Татарстан делегациясе 22 кешедән гыйбарәт иде.

Конференциядә төрки телләрне тикшерүөйрәнүгә караган 200 дән артык доклад тыңланды. Конференциядә катнашучылардан галимнәребез М. З. Зәкиев, Ф. А. Ганиев, Г. Ф. Саттаров, В. Х. Хаков, Ф. И. Иосыпов, Т. Н. Галиуллин, Ф. Х. Хатыйпов, Р. К. Ганиева, А. Х. Халиков, Ш. Ф. Мөхәммәдъяров, Д. М. Исхаков, Ф. В. Әхмәтова ясаган докладлар уңай бәя алдылар.

Киләсе VI Бөтенсоюз тюркология конференциясен 1992 елда Татарстанның башкаласы Казанда үткәрергә карар кылынды.

# КЕШЕ КҮРКЕ — КИЕМДӘ

Өс киеме, киенү рәвеше халыкның гасырлар буена туплаган тәҗрибәсен, аның милли үзенчәлеген, этник төсмерен чагылдыра. Туку, тегү, чигү, бәйләү кебек сәнгать төрләренең һәммәсен берләштергән, гамәли сәнгатьнең һәркайсын үзенә туплаган гаҗәп катлаулы һәм табигый бер өлкә ул. Татар кием-салымының үзенчәлеген билгеләүче шартлар бик күп. Монда этник характерны да, табигатькә һәм географик шартларга бәйлелекне дә, кием хуҗасының кем, ничә яшьтә һәм нинди катлаудан булуын да һәм, әлбәттә, заманга хас аерым-аерым төсмерләрне дә күпләп санарга мөмкин. Әмма, ни генә булмасын, татар киеменең үзенә хас төсмерен, милли үзенчәлеген билгеләүче тотрыклы кануннар бар. Нәфислеккә һәм төсләр балкышына омтылу, төсләр нисбәтен, аларның талгын һәм кискен көчешен бертигез дәрәҗәдә оста файдалана белү, киемнең матурлыгына, уңайлылыгына омтылу — болар барысы да ата-бабаларыбызның тормыш тәҗрибәсеннән килгән кануннар.

Казан татарларының өс-баш киеме формалашуга халыкның нәкъ менә Көнчыгыш һәм Көнбатыш тоташкан тирәлектә яшәве, башка күрше милләтләр белән тыгыз элемтәдә торуы да нык тәэсир иткән. Әйтик, Көнчыгыш халыклары киеменә хас күп кенә элементлар татар киемендә җирле мөмкинлекләргә, географик шартларга бәйле рәвештә үзгәреш кичергән.

XIX гасыр татар хатын-кызларының өс-баш киеме аеруча бер тотрыклы үзенчәлеккә, классик үрнәккә ия. Каты якалы, изүле күлмәк. Аска таба киңәеп төшкән итәк. Дулкынланып торган, берничә рәт итеп тегелгән бәби итәк яки бөрмәле итәкләр аңа кабатланмас матурлык өсти. Күлмәк өстеннән бәрхет, парча, ефәк кебек төсле тукымадан тегелгән кыска җиңле камзул киелә. Күлмәклек өчен атлас, парча, ефәк, сатин кебек кыйммәтле тукымалар файдаланыла.

Киемдә төсләр балкышын арттыру өчен күкрәкчә, хәситә, беләзек, йөзек, алка, чулпы, таңкә кебек бизәнү әйберләре кулланыла. Бөрмәле һәм бәби итәкләр, энҗе һәм алтын чуклар, җиңсәләр, борма-борма җепләр, төймәләр белән бизәлгән өс киеме шактый катлаулы һәм саллы бер композиция хасил итә.

Аяк киеме, һичшиксез, күлмәктәге һәм камзулдагы төсләргә авазлаш була, бизәкле чүәкләр һәм чәмчәле читекләр өс киеменең ритмнарын, дулкынсыман аһәңнәрен дәвам итә.

Ә инде укалы яисә чигүле нәфис калфак шушы катлаулы композицияне төгәлли: аны тагын да җыйнакландыра, бөтенлек тудыра, хатын-кызның буй-сынына зифалык өсти. Калфак — татар хатын-кызлары киемендә төп бизәнү әйбере булган. Ничә яшьтә һәм дә нинди катлаудан булуга карамастан, һәр хатын-кыз аны яратып кигән.

Югары катлау вәкилләренең өс-баш киеме, гадәттә, тукымаларның, җепләрнең, бизәнү әйберләренең кыйммәтлерәк булуы, күлмәк тегелешенең яңа модага җиңелрәк бирелүе һәм катлаулырак итеп тегелүе белән генә аерылган.

Без журналның быелгы саннарындагы рәсемнәрдә татар хатын-кызлары киеменең кайбер үрнәкләрен генә күрсәттек. Чынлыкта исә Казан татарларының кием-салымы гаҗәеп күп төрле. Һәм бу күп төрлелек һич кенә дә милли үзенчәлек белән каршылыкка керми, киресенчә, халык арасында таралган сәнгать традицияләренең бик борынгыдан килүен, халыкның иҗат тәҗрибәсе байлыгын раслый.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музее хезмәткәре.

**Тышлыкның беренче битендә:** чигүле калфаклар.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# *Китаплар дөньясында*

## Хөрмәтле укучылар!

**Татарстан китап нәшрияты быел түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:**

**Мирсәй ӘМИР.** Әсәрләр. 3 том. Саф күңел. Роман-дилогиянең 2 китабы. Хөррият. Драма. 544 бит. Б. 2 с. 10 т.

**Гамил АФЗАЛ.** Шундый-шундый эшләр. Юмористик һәм сатирик шигырьләр. 224 бит. Б. 1 с.

**Фәтхи БУРНАШ.** Яшь йөрәкләр. Пьесалар. 256 бит. Б. 65 т.

**Ибраһим ГАЗИ.** Әсәрләр. 2 том. Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт. «Онытылмас еллар» трилогиясенең 2 китабы. 501 бит. Б. 2 с. 20 т. 3 том. Канатланыр чак. «Онытылмас еллар» трилогиясенең 3 китабы. 544 бит. Б. 2 с. 30 т.

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.** Дус кызым кияүгә чыга. Пьесалар. 440 бит. Б. 2 с.

**БАТУЛЛА.** Кичер мине, әнкәй. Пьесалар. 440 бит. Б. 1 с. 70 т.

Беренче карлыгачлар. Шигырьләр. Яшь шагыйрьләрнең күмәк җыентыгы. 216 бит. Б. 45 т.

**Мансур ВӘЛИЕВ.** Учагың сүнмәсен. Әдәби әңгәмәләр. 192 бит. Б. 35 т.

**Гайсә ГАТАУЛЛИН.** Очар кошлар кебек. Повесть һәм хикәяләр. 96 бит. Б. 20 т.

**Салисә ГӘРӘЕВА.** Тау сукмагы. Шигырьләр. 128 бит, портрет белән. Б. 45 т.

**Нәби ДӘҮЛИ.** Кояшка таба. Повесть. 248 бит. Б. 75 т.

**Һәдия ДӘҮЛӘТШИНА.** Ыргыз. Роман. 416 бит. Б. 1 с. 70 т.

**Хәмзә ЗАРИПОВ.** Варысы да яшьләргә кала. Язучылар белән әңгәмәләр, әдәби портретлар. 112 бит. Б. 40 т.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛИН.** Көрәшә. Поэма һәм шигырьләр. 80 бит. Б. 35 т.

**Зәки ЗӘЙНУЛЛИН.** Үрләр аша. Повесть һәм хикәяләр. 128 бит. Б. 35 т.

**Якуп ЗӘНКИЕВ.** Иртеш таңнары. Роман. 335 бит. Б. 1 с. 40 т.

**Ләис ЗӨЛКАРНӘЕВ.** Кар өстендә алмалар. Шигырьләр. 80 бит. Б. 30 т.

**Фәиз ЗӨЛКАРНӘЕВ.** Әверелеш. Шигырь парадокслары. Мәкаләләр. 120 б. Б. 20 т.

**Риза ИШМОРАТ.** Дусларым, остазларым. Истәлекләр. 176 бит. Б. 80 т.

Камыр батыр. Татар халык әкияте. Балалар өчен рәсемле китап. 20 бит. Б. 25 т.

**Сәет КАЛЬМЕТОВ.** Ялгышны төзәтү. Сәхнә әсәрләре һәм хикәяләр. 104 бит. Б. 30 т.

**Әнәс КАМАЛ.** Март бураннары. Пьесалар, хикәяләр, истәлекләр. 272 бит. Б. 1 с. 25 т.

**Флүс ЛАТЫЙПОВ.** Кырагай. Хикәяләр һәм лирик повесть. 88 бит. Б. 20 т.

**Нәҗип МАДЬЯРОВ.** Салават күпере. Балалар өчен шигырьләр. 128 бит. Б. 40 т.

**Зиннур МАНСУРОВ.** Ваем. Шигырьләр, поэмалар. 110 бит. Б. 40 т.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.** Чияләнгән төен. Повесть һәм хикәяләр. 208 бит. Б. 65 т.

**Роберт МИҢНУЛЛИН.** Безнең авыл зоопаркы. Балалар өчен шигырьләр. 78 бит. Б. 20 т.

**Рафаэль МОСТАФИН.** Җәлилчеләр. Очерклар, җәлилчеләрнең шигырьләре һәм җырлары. 264 бит. Б. 1 с. 10 т.

**Ибраһим НУРУЛЛИН.** Фатих Әмирхан. Документаль повесть. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән. 280 бит. Б. 80 т.

**Атилла РАСИХ.** Әсәрләр. 3 том. Сынау. Каһарманнар юлы. Романнар. 512 бит. Б. 2 с. 30 т.

**Роберт РӘКЫЙПОВ.** Хәтер урамы. Шигырьләр. 112 бит. Б. 40 т.

**Мәрди РӘФЫЙКОВ.** Ак дулкыннар. «Минем һөнәрем» сериясеннән. Балык үрчетүчеләр турында хикәяләр. 96 бит. Б. 20 т.

**Фәннур САФИН.** Чәчәк гомере. Шигырьләр һәм поэмалар. 150 бит. Б. 20 т.

**Кадыйр СИБГАТУЛЛИН.** Инану. Шигырьләр һәм поэмалар. 120 бит. Б. 50 т.

**Булат СӨЛӘЙМАНОВ.** Ак метеор. Шигырьләр. 112 бит. Б. 40 т.

Татар пьесалары. Антология. 1 китап. 736 бит. Б. 2 с. 10 т.

**Фатих ХӨСНИ.** Бер яшьлектә, бер картлыкта. Төрле еллар, төрле җырлар. 496 бит. Б. 2 с. 20 т.

**Нурислам ХӘСӘНОВ.** Язмышың сыналганда. Повесть, нәсер һәм хикәяләр. 104 бит. Б. 25 т.

**Шамил ШӘЙДУЛЛИН.** Көтелмәгән очрашулар. Юрист язмалары. 88 бит. Б. 20 т.

**Рәниф ШӘРИПОВ.** Ян, учагым! Балалар өчен шигырьләр. 38 бит. Б. 10 т.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.** Гөлләр иле. Шигырьләр һәм поэмалар. 104 бит. Б. 15 т.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН.** Кешелек тавы. Повесть, хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, очерклар. 256 бит. Б. 1 с. 10 т.

**Роберт ӘХМӘТҖАНОВ.** Орчык җыры. Шигырьләр, балладалар. 144 бит. Б. 50 т.

**Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ.** Йөрәк бәйрәме. Шигырьләр. 240 бит. Б. 95 т.

*Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша соратып алдырырга мөмкин: Адреслар: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой». 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1, отдел «Книга — почтой».*

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)